

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

4
1987

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## Бу санда


22 АПРЕЛЬ — В. И. ЛЕНИН ТУГАН КӨН

Ф. ЯРУЛЛИН. Ленин кулын тоеп. *Шигырь* . . . 3

М. МАЛИКОВА. Басып сайрар талы бар. *Роман* . . . 4
РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ. Бишташ. *Поэма* . . . 60
Ә. ЕНИКИ. Соңгы китап. *Повесть* . . . 76
Р. ЗАКИРОВ. Туган туфрак. *Шигырьләр* . . . 110
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Истәлек өчен — Гыйлемханга... *Повесть* . . . 112

МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

И. НУРУЛЛИН. Киләчәк яктысында . . . 140
М. ӘМИР. Чират. *Хикәя* . . . 143

ИБРАҺИМ ГАЗИНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

И. ГАЗИ. Без комсомол чакларда. *Парчалар* . . . 145

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Р. С. МӨБАРӘКҖАНОВ. Чирмешән буйлары ямьле *(Чирмешән)* . . . 148

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Д. ШӘРӘФЕТДИНОВ. Яңа гадәтләр, яңа йолалар . . . 151

ЖУРНАЛДА МӘКАЛӘ ЧЫККАЧ...

«Безгә ничек хезмәт күрсәтәләр» . . . 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Өметләр аклансын! *Яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәк өстәл янында* . . . 157

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. УРМАНЧЕЕВ. Кадерлерәк була бара . . . 161
М. ЮСУПОВ. Тукай турында яңа сүз . . . 165

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Җ. ТӘРҖЕМАНОВ. Профессор Г. Шәрәф шигыре . . . . . . . . . . . . 168
Г. ШӘРӘФ. Шүрәле белән очрашу. *Шигырь* . . 168
М. РӘХИМКУЛОВА. Тукайга мәхәббәт белән 170

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Хөсәения мәдрәсәсе. З. МӨХӘММӘТҖАНОВА *рәсеме* . . . . . . . . . . . . . 172
Җ. МИҢНУЛЛИН. Мәгърифәт учагы . . . . 173

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 50 ЯШЬ

Н. ХИСАМОВ. XIII-XIV гасырларда Идел буе төрки поэзиясе . . . . . . . . . . . 174

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

М. ӘХМӘТҖАНОВ. «Таһир белән Зөһрә» дастаны . . . . . . . . . . . . . 179

БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

Р. НИЗАМИЕВ. Кояш кайчан йоклый? . . . . 187
Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

22 апреля — день рождения В. И. Ленина: стихотворение Ф. ЯРУЛЛИНА.
Продолжение романа М. МАЛИКОВОЙ «Ивушка плакучая», повесть А. ЕНИКИ «Последняя книга», повесть Р. МУХАММАДИЕВА «Гилемхану — на память...», поэма Р. АХМЕТЗЯНОВА «Игра камней», стихи Р. ЗАКИРОВА, стихи для детей Р. НИЗАМИЕВА.
В номере отмечаются юбилеи видных татарских советских писателей М. Амира и И. Гази.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Черемшанского райкома КПСС Р. С. МУБАРАКЗЯНОВА.
«Наша мораль»— статья Д. ШАРАФУТДИНОВА «Новые обычаи, новые праздники».
«После нашего выступления» — ответы учреждений службы быта на статью «Как вас обслуживают?» (№ 1, 1987 г.)
В рубрике «Литературная критика» — молодые критики за круглым столом.
«Библиография» — рецензии на пятитомное собрание сочинений Г. Тукая и на монографию Р. Нафикова «Тукай и его окружение».
«К истории культуры» — стихотворение из архива профессора-лингвиста Г. ШАРАФА; заметки М. РАХИМКУЛОВОЙ о Г. Тукае.
Новая рубрика — «Памятники татарской культуры в Оренбурге»: медресе «Хусаиния».
К 50-летию со дня рождения Н. Хисамова — статья юбиляра о тюркско-татарской поэзии XIII-XIV веков.
«К истории литературы» — публикация кандидата филологических наук М. АХМЕТЗЯНОВА «Эпос «Тагир и Зухра».
«Дневник культурной жизни».
На наших обложках — кувшин XVI века и памятник Г. Тукаю в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, И. Ихсанова.*

Производствога бирелде 27.01.1987 ел. Басарга кул куелды 11.03.1987 ел. ПФ 05085. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67044. Заказ М-45. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

## Фәнис Яруллин

### Ленин кулын тоеп

Апрель, апрель! Бөек Ленин ае!
Күзләр камашырлык — дөнья якты.
Яз җилләре күкрәкләргә тула:
Сулышлар киң шундый, уйлар татлы...

Булды вакыт, чын хакыйкать сүзен
Буш рапортлар тавы басып китте.
Күпшы сүзләр җанны оеттылар,
Күкрәкләрдә вөҗдан черем итте.

Һәм күнектек, бик табигый санап,
Йокымсырап яткан шушы хәлне.
Уятырга бик-бик кирәк иде
Сизгерлекне — шушы олы Гамьне.

Килде Апрель, торып басты Вөҗдан,
Алсу пәрдә төште күзебездән.
Яңгырады бөек Ленин сүзе,
Юшкыннарны юып күңелебездән.

Күзгә бәреп әйткән туры сүзгә
Бик сусаган булган һәрберебез.
Хакыйкатькә түрдән урын биргәч,
Үсеп киттек, артты кадеребез.

Ленин белән булган чакта гына
Без — зур, көчле, горур — белдек шуны.
Алдыбызда безнең олы максат,
Иңебездә безнең Ленин кулы.

Шушы кулны тоеп атлыйбыз без,
Күзләр камашырлык — дөнья якты.
Күкрәкләргә тула яз җилләре,
Сулышлар киң шундый, уйлар татлы.

# Мәдинә Маликова

# БАСЫП САЙРАР ТАЛЫ БАР

РОМАН

## 13

Берзаман театрдан чыккан халык күптән инде таралып бетте, ә Рәмзи һаман күренмәде. Шәфика,аптырап, як-ягына каранып алды: төнге урамнан, гыйфрит күзләре төсле фараларын уйнатып, куркыныч җанварларга охшаган машиналар зур тизлек белән үтеп китә, тәгәрмәч асларыннан бозлы тузан сибелә, якты, җылы залдагы йөзләрчә кешеләрне бердәм җилкендергән хистән әле айнып та җитмәгән актрисаның җаны туңа иде. Бөтен дөнья — ачы җил дә, ертык болытлар арасыннан шикләнеп кенә карап куйган тонык ай да, тәрәзәләреннән караңгылык саркыган тын йортлар да — нечкәргән күңелгә читят булып тоела иде. Ниһаять, Шәфика Рәмзине монда очратып булмасын аңлады. Баскан урыныннан кузгалуга, аяк астындагы каты кар сыкранып куйды, бу аваз очлы кылчык булып йөрәкне чәнчеп алды.

«Аймылыш булдык, грим бүлмәсендә озак мыштырдадым шул,— дип, гаепне үзеннән эзләде Шәфика.— Рәмзи әллә кайчан өйдәдер инде»,— дип, үзен тынычландырырга тырышты. Ләкин аяк астындагы кар: «Ышанычсыз ул, ышанычсыз»,—дип ыңгыраша, ә бакчадагы агачлар ак кар өстенә кара күләгәләрен сузалар, гүя ки сафлыкны таплыйлар иде — болар барысы да күңелдәге шомны арттырганнан-арттырды гына.

Өенә кайтып, диван-караватны киңәйтеп җәеп азапланганда, бер конверт килеп чыкты. Күрәсең, аны Мөкәррәмә көндез үк почта тартмасыннан алып кертеп куйган да кызына әйтергә оныткан иде. Менә хәзер Шәфика, әнисенә аркасы белән борылып, шул конверттан чыккан дәфтәр битендәге язуны укырга азаплана, әмма эре зәңгәр хәрефләр аның күз алдында биешә, сикерешә, сүз булып оешырга теләми иде. Хәрефләрнең шулай чалыш-чолыш язылуыннан ук Шәфикадан көлү, аны мәсхәрәләү сизелеп тора иде. «Бикбауның бик күп кичләрне Балтачева белән үткәргәнен сез бездән яхшырак беләсез инде белүен, тик белмәмешкә салышасыз гына. Бу рәвешле икейөзлеләнү артист кешегә бер генә дә килешми. Андый хыянәтче ир сезгә ник кирәктер, һич аңлашылмый, ансыз да акчагыз җитәрлек, данызыз да, исемегез дә бар бит инде».

Ниһаять, бу сүзләрнең мәгънәсе Шәфиканың зиһененә барып иреште. Балтачева? Эльвира? Кит әле, булмасны... Шәфика ул шөкәтсез

---

Дәвамы. Башы 3 санда.

үрдәк бәбкәсен үзенең күгәрчендәй Рәмзие белән янәшә күз алдына китерергә тырышып карады — булдыра алмады. Янәшә торырлык та кешеләр түгел ләбаса алар! Әле кайчан гына Эльвира, монда килеп, Мөкәррәмәдән пылау пешерергә өйрәнеп йөргән иде, ул чакта Рәмзи аңа борылып та карамады, Шәфикага: «Ул кыз талантсыз, өметсез»,— диде. Җиен әтрәк-әләмне өйгә китереп йөртәсең, дигән сыманрак та әйткән иде әле!

Шулай булгач, ничек карасын инде ул Эльвирага!

Ләкин, утсыз төтен чыкмый, диләр бит. Бу хатка ни сәбәп булган икән соң?

Шәфика диңгез дулкынына эләккәндәй чайкалды, утны сүндереп, бер уйсыз-хиссез диванда утырды. Күпме утырганын, ничә сәгать үткәнен белмәде.

Ул Рәмзинең аяк тавышларын урамнан ук ишетә башлады бугай. Аның баскычта янгыраган һәр адымын үзенең йөрәк тибеше белән тәңгәл китереп утырды. Рәмзинең адымнары бик салмак иде, бер дә өенә ашкынганга охшамаган иде...

Ишек кыңгыравы дүрт тапкыр озын-озын итеп шалтырады, дүрт тапкыр Шәфиканың йөрәк тибешен туктатып торды. Ниһаять, күрше бүлмәнең ишеге ачылганы ишетелде, зал турыннан, авыр атлап, Мөкәррәмә узып китте:

— Шәфика, кызым, йоклап киттеңмени?

Рәмзи ишек катында бик озак кыштырдап чишенде, бүлмәгә кергәч, торшерның төймәсен таба алмый мыштырдады. Ут кабынгач, җәелгән урын өстендә бизәкле ак халат киеп утырган хатынын, аның кинәт кабынган уттан да йомылмаслык булып ачылган күзләрен күреп сагайды.

— Син йокламыйсың икән әле. Ә мин, уятмыйм дип, куркып кына шалтыратам тагын.

Рәмзинең соңарып кайтуы беренче генә түгел, Шәфика моңа күнеккән иде инде. Чыннан да, иҗат кешесен кысан киртәдә тотып булмый, андыйны Шәфика үзе дә яратмый. Режиссерның артистлар белән озаклап сөйләшеп утыруы да, композитор белән очрашкач, сәгатькә карарга онытуы да гаҗәп түгел. Иҗат кешесенә илһам расписание белән килми ул. Шуңа күрә башка чакларда Шәфика ире соңарганга борчылмый, кайда йөрдең дип, аның да җанына тими, тыныч кына ятып йоклый торган иде. Ләкин бүген алар театрдан бергә кайтырга сөйләшкәннәр иде бит!

— Ни җаным белән йоклыйм, бәлки син машина астына кергәнсеңдер? — диде Шәфика.

— Машина астына кергән булсам, синең болай көтеп утыруыңнан җиңеллек килер дип уйладыңмы әллә?

— Машина бәрмәгәч, ник соң вакытында кайтмадың? Мин сине спектакльдән соң эзләп йөрдем.

— Мин алданрак киттем шул. Даян, әйдә-әйдә, Шәфика безнең хәлыкны яхшы белә дип әйдәкләп алып китте. «Кадимбикә»дә бер мәсьәләне ашыгыч хәл итәсе бар иде.

Шәфика аның сүзләренә шиксез ышанды, аның тикшеренеп, фәлән вакытта ирем сезгә кермәдеме дип сорашып йөргәне гомердә булмады. Шуңа күрә Рәмзи үзен бик тыныч тотты.

— Мин сезнең холыкны беләм белүен дә, башкалар миннән дә күбрәк белә икән шул,— диде Шәфика һаман әле йомшап төшмичә.

Рәмзи ак водолазкасының итәген муенына кадәр күтәреп салып азаплана иде инде, Шәфиканың бу сүзләрен ишеткәч, күкрәк турына кире төшереп, борылып карады:

— Беләсеңме, Шафочка, Даян белән сүз көрәштереп тә мием чиреде, төн уртасында табышмаклар чишәр рәтем калмады. Әйтәсе сүзеңне ачык кына әйт, зинһар.

— Менә монда барысы да ачыктан-ачык әйтелгән.

Рәмзи күлмәгенең бер иңен салып өлгергән иде инде, икенчесен

кигән килеш, шул сәер кыяфәтендә язуны укып чыкты, аскы иренен бүлтәйтеп, күперенке мыегын тешләргә тырышкандай итте. Шушы гадәти хәрәкәттән башка, аның шома йөзендә бернинди үзгәреш тә булмады, күе, кыска коңгырт керфекләренең бөртеге дә селкенмәде. Гаепле кеше шулай тыныч була аламыни?

Менә ул хатны кире хатынына сузды:

— Артистларның тормышында казынып, гайбәт таратучылар бетмәде инде,— диде. Аның тавышында талчыкканлык сизелде.— Көнләшәләр. Кеше кызыгырлык итеп яшибез, димәк. Куанырга кирәк бу эшкә.

— Утсыз төтен булмый,— диде Шәфика, һаман әле тынычлана алмыйча.

— Минем янга бер-ике тапкыр килгән иде шул ул кыз. Берәр театрга урнашырга ярдәм сорый.

— Ә син ни дип җавап бирдең?

— Ни әйтим? Беләсең бит инде, өметле дип санамыйм мин аны. Әйдә, юк белән баш катырмыйк әле.

Ул шунда сүзнең тәмамланганын белдереп, водолазка итәген башына кайтарып салды. Аның эченнән бөтенләй үзгәреп чыккандай итеп:

— Йокы килә, соң бит инде,— дип куйды.

— Ашамыйсыңмыни? Әни пылау пешергән иде.

— Анысы әйбәт, ашамыйча булмас.

Тамагын ялгап, урынга ятканда, Рәмзи үзеннән дә, дөньядан да бик канәгать кыяфәттә иде. Шәфика аркылы сузылып, торшерның төймәсенә басканда, ул авызын зур ачып, озаклап, тәмләп иснәде. Бу минутта Рәмзи тук һәм сөйкемле, шома җанварга охшап калган иде. Ул таза, көчле беләген хатыны аша аңа тигезмичә генә сузды һәм шулай ук орынмыйча гына кире алды. Аннары иркенәеп, авыр итеп, диванны сыгылдырып чалкан ятты да, кинәт исенә төшкәндәй:

— Ә-ә, онытып торам икән,— диде,— бүген сине Хәбир эзләгән икән. Иртәгә шалтыратсын әле миңа дигән. Син менә утсыз төтен булмый дисең. Мин ни уйларга тиеш инде мондый очракта? — Аның тавышында ялкау гына үчекләп көлемсерәү сизелде.

— Ник эзләде икән?

— Сагынгандыр, бәлки.— Рәмзи караңгыда елмая иде. Аның бу ургәп елмаюы бүлмәне тагын да караңгылатып җибәрде бугай. Менә ул диванны шыгырдатып әкрен генә борылды да, иренчәк хәрәкәт белән кулын хатынының күкрәгенә аркылы салды. Шәфика бастырык белән бастырылгандай хис итте үзен, тыны кысылды.

— Я, ялагайланма әле,— диде ул һәм, иренең кулын күкрәгеннән алып, кирегә этте. Зур һәм авыр кул аның бу хәрәкәтенә бернинди каршылык күрсәтмәде, әйтерсең лә ул үзле балчыктан әвәләп ясалган иде.

Рәмзи стенага таба борылып ятты, берничә минуттан җиңелчә гырлый да башлады — ул, гөнаһсыз сабый кебек, изрәп йоклый иде инде.

## 14

Ә Шәфика йоклый алмады. Янында тигез сулап яткан кеше аннан ерагая, һаман ерагая бара сыман тоелды, кара төндә, карурманда бер ялгызы калгандай хис итте үзен. Чыннан да, иң якын кешеңнең күңеле әллә кайларда йөрсә, аның синдә, синең әрнүләреңдә һәм сызлануларыңда бер хәбәре дә булмаса, бу — шул ялгызлык дигән бәхетсезлек түгелмени? Әйе, аңлаешсыз бу дөнья, бик ышанычлы саналган дуслар да һич көтмәгәндә сөйгән ярларыбызны тартып алалар.

Бу дөньяда мең төрле афәт һәм хәсрәт бардыр, һәм аларның күбесе ни сәбәптәндер Шәфиканы әйләнеп үтми. Нинди генә кайгылар, сынаулар килмәде инде аның башына! Хыянәт дигән афәтне генә моңарчы кичергәне юк әле. Бәлки шуны кичерер чагы җиткәндер аның, бәлки язмыш аны шул сынау аша үткәрергә ниятлидер?

һәм Шәфика, моңаеп, башыннан узган аяныч хәлләрне хәтерләргә керешә. Биш айлык чагында басмачылар кулына эләгүен уйлады ул, әтисенең бик яшьли дөнья куеп, үзенең урам балалары арасында талкынып узган көннәрен хәтерләде. Балачагын кызганып, күңеле тулды. Аннан калганнары күпме бит әле!

Дөресен генә әйткәндә, Хәбир дә Шәфиканың тормышында үзенә күрә бер афәт булды.

Ә бүген ник эзләде икән соң әле ул Шәфиканы? Ничә еллардан соң нигә кирәксенде икән?

Хәзер бит инде Шәфика — элекке томрап торган, яшь, чибәр кыз түгел. Урамнардан узганда, аңа борылып карауның да сирәк, булганы да актриса Абилованы таныганга гына карый.

Ә Хәбир белән танышкан елларда аңа бөтенләй башка сәбәп белән, дөньяларын онытып текәләләр иде. Мәскәү метросының эскалаторында каршы яктан килгән халыкның башы гел аның тарафына борылган булыр иде. Күп муеннарны каерды Шәфиканың чибәрлеге. Мәскәүгә китәр алдыннан гына әнисе аңа комиссионный кибеттән ап-ак тун белән бүрек алып кидергән иде. Австралия товары иде бу. Шул бүрек астыннан бүселеп чыккан алтын бөдрәләр, янып торган бит очлары, зәңгәр күзләр һәм йөзнең һәр сызыгында камиллек, сафлык, әчкерсезлек...

Хәбир генә баштарак сер бирмәде, Шәфикага бөтенләй игътибар итмәгәндәй кыланып йөрде. Хәер, җае да булмагандыр, ул үзе башкаларның күз угында иде бит. Шулай булмый мөмкин дә түгел: студиягә кабул ителгән егетләрнең иң өлкәнсе ул иде. Хром итекләр, галифе чалбар, иңбашларында погон эзләре ярылып яткан бер җыерчыксыз гимнастерка һәм аның аркылы кабарып торган гайрәтле күкрәк. Уен-муен түгел — артиллерия капитаны. Аның шома коңгырт чәченнән алып, елтыр итек башларына хәтле дары исе сеңгән иде. Ә бу истән ул елларда күп кызларның башы әйләнде. Әгәр дә алар этюдлары өчен үзләренә партнер итеп аны — төз сынлы, киң җилкәле фронтовикны сайларга тырышканнар икән, бу гаҗәпмени? Әмма Шәфика аны чибәрлеге-кәттәлеге өчен түгел, бөтенләй башка нәрсә өчен күңеленә якын итә иде. Сугыш ялкынын үз йөрәге аша да үткәргән кызга ул, беренче чиратта, кешеләрне һәлакәттән яклап, дәһшәтләргә каршы барган изге зат иде. Тик моны Хәбир белми һәм шунлыктан Шәфиканы башкалардан аерып карамый иде.

Бер заман шулай Хәбирне өч-дүрт кыз берьюлы уратып алдылар. Минем этюд тегенди дә минем этюд мондый. Кая карарга белерлек түгел. Ә Шәфика читтәрәк басып тора, егетнең бушаганын көтә.

Ниһаять, Хәбир талчыккан карашын аңа төбәде:

— Ягез, хәзер сезнең чират.

Аның битараф, салкын кыяфәте, бигрәк тә «чират» дигән мыскыллы сүзе зиһенне чуалтып җибәрде. Шәфика егетне кинәт танымас булды, әйтерсең лә, капитанны шул минутта җен алыштырды — аны урлап китте дә урынына үзенең оятсыз, тәртипсез малаен бастырып калдырды. Шәфика башын югары күтәрде, нечкә үкчәләре белән тек-тек басып, егетнең каршына килде һәм, нишләгәнен үзе дә белеештермичә, аяк очларына күтәрелеп, үрелеп, яңагына сугып җибәрде:

— Менә сезгә минем чират!

Хәбирнең болай да карасу какча яңаклары тагын да каралыбрак китте, юка иреннәре кысылды, күзләре кабынды. Менә ул кулын күтәрде һәм... гимнастерка төймәләрен барлап чыкты, бил каешы янындагы тукыма җыерчыкларын гайрәт белән артка сыдырды. Аннары стройдагы кебек «кругом» борылды да бүлмәдән чыгып китте, кинәт урнашкан тынлыкта аның хром итекләре шыгырдавы гына ишетелеп торды.

Иртәгәсен Шәфика дәрескә алданрак килгән иде, ишектән кергән Хәбиргә йокысызлыктан тиранәеп калган күзләре белән куркынып карады. Егетнең туп-туры үзенә таба юнәлгәнен күргәч, сикереп торып чыгып качудан чак тыелып калды.

Әйе, Хәбир, тук-тук басып, итекләрен шыгырдатып, аның каршына килде, башын игәндәй итеп, маңгай чәчен сирпеде дә бик җитди, хәтта рәсми тавыш белән:

— Кичәге сүзем өчен мин сездән гафу үтенәм,— диде.— Ялгыш ычкынды. Мин сезне һич тә рәнҗетергә теләмәгән идем, үзем дә сезнең белән этюд уйнарга җыенган идем.

Ә Шәфика аның белән парлап уйнарга дип, этюдның үзәккә үтә торганын сайлаган иде. Бу әле аның сәләте ачылмаган, курсташларыннан калышып барган вакыты бит. Шуңа күрә көйдерерлек кайнар хисле роль уйнарга тели иде ул: бер яшь хатын үз иленең дошманына гашыйк була, мәхәббәттән башы әйләнеп, үзе дә аңлап бетермичә, ватанына хыянәт итә һәм шуның каты җәзасын ала.

Хәбир этюдны зур дикъкать белән һәм бик уйчан кыяфәттә укып чыкты да:

— Минем дә әзерләгән этюдым бар иде,— диде.— Танышып карамыйсызмы?

Аның сайлаганы «Курчак» булып чыкты. Шәфикага җан өргән, аны аякка бастырган, күңеленә ышаныч иңдергән «Курчак» булды ул.

Каян белде икән Хәбир кызның җаны моңга, музыкага сусаганын? Ул чакта Шәфика моны үзе дә аңлап житкерми иде бит әле.

Артистка Абилованы беренче булып Хәбир ачты. Тик Шәфика гына аның яхшылыгын бәяләп җиткермәгән икән. Аннан соңгы рәнҗүләр егетнең бу игелеген басып киткәндәй итте. Яшь чакларда безнең яхшылыкны-яманлыкны үлчи торган бизмәнебез бер яккарак авышучан була шул — без, вак кына нәрсәне үлчәүнең бер як тәлинкәсенә шапылдатып китереп салабыз да, аның тирбәлүдән туктаганын да көтеп тормыйча, бик мөһим, кайчакта бөтен язмышны хәл итәрлек нәтиҗәләр чыгарып куябыз. Кызганыч ки, безнең күңелдәге бизмәннәр еллар узгач кына төгәлрәк күрсәтә башлый.

Шәфика да Хәбирне шулай берьяклы гына күргән икән. Баштарак гел яхшы, гел ал да гөл итеп кенә күрде ул егетне.

«Курчак» этюды белән күп авылларны гизгәннән соң, җәйге каникулдан килгәндә, Шәфиканың торыр урыны юк иде. Хәбирләрнең бер күршесе каядыр төньякка китеп барган, бүлмәсе бушап калган икән. Шәфикага шунда урнашу кулай булып чыкты. Егет кызны шул бүлмәне күрсәтергә алып китте, анда кергәнче, үзләренең ишеген ачты һәм каршы чыккан чал чәчле, ыспай гәүдәле апага: «Әни, киленең белән таныш,— диде.— Аның исеме Шәфика була». Алар икесе — унсигезе тулмаган беркатлы кыз белән үткен соры күзле, кырыс карашлы апа — бер-берсенә соң дәрәҗәдә аптырашып караган килеш, шактый озак сүз таба алмый тордылар. Хәбирнең һәр ишарәсенә буйсынырга күнеккән «курчак» бу юлы да егеткә каршы килә алмады.

Хәбир — гаиләдәге алты баланың өлкәне, ә аның әнкәсе — тирәюньдә уңганлыгы, чисталыгы белән дан тоткан хатын булып чыкты. Ул бик зур дәрт белән киленен дә шундый ук өлгер һәм оста хуҗабикә итү чараларын күрә башлады. Әмма аның бу изге омтылышына һич көтелмәгән яктан каршылык күрсәтелде.

Бер көнне дәрестә Анна Ивановна Шәфикадан:

— Нишләттең син кулларыңны? — дип, бик усал итеп сорады.

Шәфика күгәргән бармак очларын учына йомарлады:

— Бәрәңге әрчегәннеке генә ул.

— Килегез әле барыгыз да монда, карагыз әле бу кызның кулларына! — диде Анна Ивановна барча шәкертләренә. Һәм Шәфиканың беләгеннән каты итеп тотып, кулын өскә күтәрде.— Бүген королева роленә репетиция ясарга килгән актриса бу. Королеваның кулы шундый буламыни? Кухарка син, королева түгел!

Кич белән каенана киленен янә кухняга дәшкән иде, Хәбир:

— Кая, ни эш бар, хәзер үзем ярдәм итешәм,— дип, гимнастерка җиңнәрен сызганырга кереште.

Әгәр дә Шәфика урынында дөнья рәтен яхшырак белгән, хәйләкәр һәм елгыр-уйнак берәр хатын булса, шул Хәбир белән матур гына гомер кичерерләр иде, кара эчле ир түгел бит ул. Ярсу атларны иярgә күнектерүнең үз ысуллары булган кебек, горур һәм дуамал холыклы ирләрне дә гаилә тәртәсенә кертүнең үз хикмәтләре бардыр, мөгаен. Гаилә — шул ук сәхнә мәйданы, анда театрдагыдан да яхшырак уйнарга кирәк, чөнки начар уйнасаң, иреңне югалтуың бар. Әмма Шәфика бу хакта ныклап уйлый белмәде һәм хәзергә хәтле тормышта уйнау осталыгына өйрәнеп житә алмады. Ул талга кунып сайраган былбыл кебек, жирдән бәреп чыккан саф чишмә кебек, риясыз һәм хәйләсез яшәвендә булды, уен-муен сәхнәдә генә килешә, ә чын тормыш эчкерсезлеккә, бер-береңә ышанычка нигезләнеп, үзеннән-үзе барырга тиеш дип санады. Иреңә ни уйлаганыңны ачыктан-ачык белгерт, хисләреңне яшермә, тыйма, ә ул сине аңлар — шулай дип уйлады ул һәм теге чакта яңагына чалтыраткач, Хәбирнең майлагандай жайланганы аның бу фикерен раслый да иде. Аңлашылмаучылык килеп чыкканда, араларны шул рәвешле жайлап жибәрергә тагын бер тапкыр талпынып карады Шәфика. Ул болай булды.

Шәфиканы ниндидер танышлары Колонналы залга концертка чакырганнар иде. Шул танышларының бер туганы — яшь, чибәр егет белән урыннары янәшә туры килде. Хәбир анда бара алмады, чөнки студиядә укыган чакта ук аны Кече театрга зур булмаган рольләр башкарырга чакыргалыйлар, ул шунда киткән иде. Теге егет Шәфикага елмаеп сүз кушкалады, тәнәфестә аның белән бергә йөрде, туңдырма белән сыйлады. Ахырдан танышлар бергәләшеп Шәфиканы өенә озатып куйдылар.

Ярый әле, егет артык бәйләнчек булып чыкмады, Шәфика белән ялгызы калырга тырышмады. Ул кичне Хәбир спектакльдән иртә бушаган да, Колонналы залның бер колоннасы артына посып, хатынын күзәтеп торган икән. Аны шундый эшкә сәләтле дип кем уйлаган.

Кояштай балкып кайтып кергән Шәфиканы ишек төбендә яңгыр болытыдай кара коелган Хәбир каршылады. Хатынының кулыннан ак тунын йолкып алып, аяк астына ыргытты да:

— Син үзеңнең ир хатыны икәнеңне беләсеңме, юкмы? — диде. Аның күзләре ачулы, аяусыз, ә тавышында тимер катылыгы һәм салкынлыгы бар иде. Гарьләнүдән Шәфиканың зиһене нәкъ теге вакытта студиядәге кебек чуалып китте. Ул, нәкъ шул чактагы төсле итеп аяк бармакларына күтәрелде дә каралып чыккан, бу минутта бөтенләй чит-ят булып күренгән йөзгә кизәнде. Шул мизгелдә беләге тимер келәшчәгә эләгеп, сынып киткәндәй булды. Икенче келәшчә Шәфиканың аяк астыннан каптырып алды да, өскә күтәрә башлады. Ул аяклары идәннән аерылганын тойды. Хәбир аның йөзен үзенең салкын күзләре турысына ук күтәрде дә әкрен, ләкин куркыныч итеп:

— Син бу гадәтеңне ташла, яме,— диде.— Капитан Батыркаевны тукмый торган адәм заты дөньяга тумаган әле.

Ни хикмәттер, беләгенең, иягенең авыртуы Шәфика күңелендә нәфрәт хисе уятмады. Тормыш хәлләрен әдәби әсәрләр белән чагыштырып бәяләргә күнеккән кыз курку аша, сокланып: «Отелло! — дип уйлады.— Көнләшүеннән ничек ярсыган бит мескенкәем! Димәк, яратуы чын икән!» Бичара, иренең туп-туры «яратам» дип әйткәне юк иде шул аңа.

Иртәгесен Анна Ивановнага иякнең һәм беләкнең нидән күгәреп чыкканын аңлатырга кирәк иде. Ярый әле, остаз бу юлы бик сак килде, Шәфика белән бөтен кеше алдында түгел, күзгә-күз калып кына сөйләште. Һәм бу вакыйгага бөтенләй көтелмәгәнчә бәя бирде:

— Сугышуын дәвам итә, димәк, фронтовик,— диде ул.— Сиңа, Шафочка, иреңнән кул күтәртергә һич тә ярамый иде. Хәзер чыда гына инде, ул сине атнага бер дөмбәсләп торачак. Ирләрнең кулы бер ычкынса, тыям димә.

Ялгышты Анна Ивановна, сүзе рас килмәде. Атна саен кыйнау булмады анысы. Чөнки үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә житеп каны кызган чагы сирәк була иде Хәбирнең. Начар кеше түгел иде бит ул, шул рәвешле

кызарга һәм үз-үзен белештермичә кул күтәреп сугышырга фронтның канлы, нәфрәтле, аяусыз юллары өйрәткән иде аны, канын сугыш бозган иде. «Сугыштан кайткан кеше кебек холыксыз»,— дигән сүзләрне Шәфика бик соң, театр тирәсендә болганып йөрүче Револ исемле яшь бер кеше авызыннан ишетте һәм шуны ишетүгә Хәбирне исенә төшерде, үзе кичергәннәрнең сәбәпләрен кинәт ачыклагандай булды.

Хәер, Шәфика үзе дә бик көйле, җайлы гына яши алмагандыр. Аның да гаебе табылып тора иде бит. Хатыны янында Хәбир үзен кырыс һәм каты куллы ата кебегрәк тота иде. Ә андый атадан Шәфика кебек тиктормас балага эләккәләп тора шул инде.

Казанга кайтуга, Шәфика Абилованың тормышы тоташ ыгы-зыгы белән уралып уза башлады: спектакльләрдә төп рольләр, радио һәм телевидение тапшырулары, үзешчәннәргә ярдәм итү, театр училищесында укыту. Шәфиканың күңел кошы көнкүрештән биеккә, тамаша залыннан күтәренке булып, яктырып торган сәхнә мәйданына очына, шунда талпына иде. Ләкин канатлы кош та оча-оча да җиргә кунарга мәҗбүр була. Ә җирдә баганадай нык һәм бөгелмәс Хәбир тора иде. Сәхнәдә алар — Курчак белән Оста, Отелло белән Дездемона — кызыгырлык пар иделәр. Ләкин, сәхнә артына атлауга, бу бердәмлек каядыр югала иде.

Шәфиканың әнисе Мөкәррәмә белән бергә яшәргә Хәбир риза булмады, яшь парга театр аерым бүлмә бирде. Шәфика иренең иңбашка таба киңәеп, билгә таба тараеп килгән өчпочмаклы аркасына карап кына да кәефен белергә өйрәнеп житте. Аның ачулы икәнен сизсә, йөрәге жу итә, әмма ул иренең кәефен үзгәртү — бер сүз яисә елмаю, ишарә белән аның күңелен күтәреп, уйларын үзгәртеп җибәрү җаена төшенә алмады.

Ярата идеме ул Хәбирне? Бәлки яраткандыр да. Әмма бу хисне көчлерәге, торган саен күңелне ешрак biләп алганы — курку хисе кысрыклый барды. Котың очып курыккан кешене яратып буламыни?

Шактый еллар дәвам итте бу шулай. Ләкин Шәфика кебек кеше кайчан да булса, ничек тә булса мондый хәлгә чик куярга тиеш иде. Һәм ул чик һич көтелмәгән рәвештә куелды.

Коммуналь квартирның зур гына кухнясында, тагын өч гаилә янәшәсендә, аларның да аерым өстәле, керосинкасы, чүп чиләге тора иде. Шәфика шул керосинка янында, телевидение тапшыруында башкарачак ролен ятлый-ятлый, пылау пешереп азаплана иде. Кәефсез иде ул, тамагы авырта иде, ләкин тапшыруны өзәргә ярамый, әзерләнергә кирәк. Ул чакта алдан барып язылулар юк иде бит әле, турыдан-туры эфирга чыгалар иде.

Хәбир репетициядән күтәренке кәеф белән кайтып керде.

— Циркка билет алдым.

Шәфиканың авырып торам диюенә артык исе китмичә:

— Юлбарыслар килгән анда. Җылырак киенерсең,— дип җавап бирде.

Шәфика циркта ерткыч җанварларның һәм акробатларның чыгышын аерата яратып карый, кыргый, көчле җан ияләрен бер ым белән буйсындыра белгән кешеләр анда чиксез соклану уята. Хәбир моны яхшы белә иде.

Аяз, салкын төн иде. Цирктан кайтканда, бик озак трамвай булмыйторды, алар җәяү кайттылар, туңып беттеләр. Өйгә керүгә, Хәбир, башым авырта дип, диванга барып ауды. Шәфика кухнядан пылау җылытып алып керде. Кабып карагач, аның шактый ук тәмсез икәнен сизеп, беленмичәрәк үтмәсме дип, пар бөркегән тәлинкәләр янына бер шешә шәраб чыгарып куйды.

— Монысы дару урынына,— диде. Ләкин хәйлә ярдәм итмәде, пылауны капкач, Хәбирнең сытык чырае тагын да ныграк сытылды.

— Синең аркада әллә нинди афәтләргә тарыйм инде,— дип, кашыгын кызгылт дөге өстенә ташлады ул.— Сиңа ярыйм, сиңа ерткычлар күрсәтим дип, үземә салкын тидердем менә.

Дәшми үткәрергә иде моны, тыярга иде Шәфикага үзенең тиктормас телен! Ләкин ул, һәрвакыт, һәр очракта дөреслекне өскә чыгарырга кирәк дигән кагыйдә белән яши, ул чакта да шулай иде, хәзер дә шулай.

— Син үзең алып кайттың бит билетларны, мине көчләп үзең алып чыгып киттең,— диде ул иренә.

Хәбир диваннан калкынгандай итте, Шәфика куркуыннан кызып, өстәлдән шәраб тулы стаканны алды.

— Якын киләсе булма, үтерәм!

— Кычкырма, тиле, күршеләр ишетер!

Чыннан да, тынып калган төнге йортта аларның тавышы ерак яңгырый кебек иде. Хәбир өстәл артыннан чыгып, хатынына таба атлады. Шәфика артка чигенә биреп, стакандагы шәрабны аның йөзенә сипте, ак күлмәк буйлап аккан кызыл тамчылар аның өнен алды. Ул карашын иреннән аера алмады, үзе чөйдән тунын алмакчы булып кармаланды. Кинәт нидер гөрселдәде, чылтырады, Шәфиканың аяк астына ялтыравык пыяла китекләре сибелде. Көзге төшеп чәлпәрәмә килгән икән. Шәфика бөгелеп ватыкларны җыймакчы булды, ялан балтыры, бармаклары кызылга буялганны күреп: «Карале, бу шәрабка икәүләшеп коендык бит, ә»,— дип уйлады.

— Нишлисең син? — диде Хәбир бу юлы йомшаграк тавыш белән.— Аягың киселде бит, кая бәйлим.

Аның йомшап төшкәнен күргәч, Шәфика котырып ярсыды:

— Якын киләсе булма! Аксын, бөтенләй агып бетсен каным! Болай яшәгәнче, үлгәнең артык!

Ул сүзләрнең иң ачыларын, иренең бәгырен кисәрлекләрен сайларга тырышты. Әгәр кешенең җаны сызлау сиңа ләззәт бирә икән, мондый очракта яратуга урын каламы?

Менә ул, күпмедер кычкырганнан соң, ниһаять, тынып калды. Алар икесе кара-каршы баскан килеш сүзсез тордылар, күңелдә ачу-ярсу урынын бушлык, кара бушлык биләп алды. Әйтерсең лә алар бик озак бау тартышканнар, кинәт кенә бау уртадан өзелеп, икесе ике якка мәтәлгәннәр. Ләкин бу бау өзелү генә түгел, бу — аралар өзелү иде.

Медпункттагы яшь, чибәр врач егет Шәфиканың ярасын бәйләргә шәфкать туташын чакырмады, бу эшне үзе башкарды.

— Минем Сезне сәхнәдә күп күргәнем бар,— диде ул, Шәфиканың балтырын ак марля белән ураганда. Егет бу сүзләрне башын күтәрми, әйтерсең лә, Шәфика өчен оялып әйтте.— Сәхнәдә Сезнең җаныгыз эчтән балкып тора. Минем Сезгә ихтирамым әйтеп бетерерлек кенә дә түгел.

— Сез мине дөрес аңламадыгыз, ахрысы,— диде Шәфика.— Мин көзгене үзем төшереп ваттым, аннары ялгыш ватыкларга тезләндем.

— Аңладым мин сезне, бик яхшы аңладым, Сез генә мине аңлап житкермисез булса кирәк.

Ул башы белән ак ишеккә, аның теге ягында, коридорда әрле-бирле йөренгән Хәбир тарафына ишарәләде.

Яшь егет актрисаның аяк-кулларын бәйләп һәм күңел ярасын ачып кайтарып җибәрде. Бу кыяфәт белән репетицияләргә йөреп булмый иде — врач аның кулына бюллетень тоттырды. Төннең калган өлешен Шәфика кухняда, өстәлгә башын салган хәлдә үткәрде, ире янына кермәде.

Иртәгесен Мөкәррәмә килгәч кенә, арада берни булмагандай кыланырга тырышып карады. Әнисен өйгә чакырды, чәй әзерләмәкче булды. Ләкин ананың үткен күзеннән берәр нәрсә яшереп буламы соң? Ул бүлмә уртасына кереп басты, башындагы шарфын рәтләштереп, бер диванда утырган киявенә, бер кызына карады да:

— Бүген төштә күргәннәрем рас булган икән,— диде.

Хәбир газета укып утыра иде, аның артыннан йөзен күрсәтмәде, бер сүз дә дәшмәде.

— Әйдә, кызым, безгә барыйк әле,— диде Мөкәррәмә.— Бик сагындым, бер сөйләшеп утырасы килә.

Шәфика шатырдатып шкафны ачты да кулына эләккән кием-салымын чемоданга ыргытырга тотынды. Чемоданның капкачы ябылмый иде, Шәфика аның өстенә менеп тезләнде. Шунда гына Хәбир, газетасын ташлап, урыныннан кузгалды:

— Кая, ябып бирәм.

Ул бик тыныч, бер генә дә каушамаган иде. Чемоданны кире ачып, бик иплэп кенә, әйберләрне пөхтәләп тутырды, капкачын ябып, бикләрен чалт итеп эләктерде, аннары тураеп басты да:

— Хәзер такси табып китерәм,— дип, пальтосы белән бүреген алып чыгып китте. Бәлки, ул — ана белән кыз киңәшсеннәр, суынсыннар, бер-берсенә акыл бирешсеннәр дип тә чыгып киткәндер. Ләкин Шәфика белән Мөкәррәмә тиз аңлаштылар. Ана кызына бер генә авыз сүз әйтте:

— Соңгарак калдым бугай. Алданрак килергә кирәк иде.

Алай да ул кызы белән киявенә аңлашыр өчен шуннан соң да бер мөмкинлек бирде әле: Хәбир, такси алып килдем, дип кергәч, алданрак чыгып китте, артыннан ишекне ныклап ябып куйды. Ишеккә ул чактагы мода буенча кызыл плюш пәрдә эленгән иде. Нәкъ сәхнә пәрдәсе төсле. Алар шул пәрдә фонында моннан унике ел элек башлап җибәргән спектакльнең эпилогын уйнадылар. Шунда гына Шәфика гаилә тормышының да спектакль икәнен, бу тамашадагы үз ролен начар башкарганын бераз аңлагандай булды. Ләкин уенны яңартырга соң иде инде. Ул, ире белән карашып торудан тизрәк котылырга теләп, чыгып китәргә омтылды, ләкин Хәбир ишеккә аркылы баскан, төп-төз тора, кузгалырга исәбе дә юк иде кебек. Шәфика ничектер аңа орынмаска тырышып, пәрдәне эчке борыс ягыннан күтәрде дә, шуннан сузылып, ишекне ачмакчы булды. Көче җитмәде. Хәбир бер адым читкә атлагач та, хатын пәрдәгә буталып азапланды, каушап төште. Ниһаять, Хәбир, аның иңбашы аша сузылып, ишекне төртеп ачып җибәрде. Әгәр шунда аның кулы җилкә аша өстән сузылып үтмичә, салмак ныклык белән Шәфиканың иңенә төшкән булса, аларның язмышы ничек дәвам иткән булыр иде икән? Аның кулыннан килгән таныш тәмле истән Шәфиканың башы әйләнеп киткән иде бит инде. Ләкин Хәбирнең кулы үзенә тиешле эшне машина төгәллеге белән башкарды — ишекне этеп ачты, бәрхет пәрдә ябылды һәм спектакль шуның белән тәмамланды.

Дөрес, баштарак Шәфика моның соңгы күренеш булуына ышанмаган иде әле. Ул өйдән чемодан күтәреп чыгып китүен үз-үзенә шаяру, ирен үчекләү дип кенә аңлатмакчы булды, Хәбир килер, шаяруның да бер чиге була, әйдә, кайтыйк, дип әйтер дип көтте. Ләкин Хәбир килмәде, кайтыйк та димәде.

Читен икән лә аерылышу хәлләре! Шәфиканың күңелен сызландырып, бер ничә моң хәтергә килде, колакта скрипка «Зиләйлүк»не сызып җибәрде.

Сизмисең бит син дә синең яннан
Нечкә күңел шагыйрь узганын,
Синең болай мескенләнгән хәлең
Аның күңелен ничек өзгәнен.

Нечкә күңелле шагыйрь урамда очраган бер бичара кызның да күңел газапларын тойган, шул кыз өчен күңеле өзелгән. Ә соң без иң якын кешеләребезнең кайгы-хәсрәтләрен шулай кабул итә алабызмы? Менә Шәфика белән янәшә аның иң якын кешесе ята, хатыны сызлаган җанына урын тапмаган сәгатьләрдә рәхәтләнеп йоклап ята...

Күңел сызлауларын уртаклашырдай кеше очрамады Шәфикага, юк, очрамады...

Бераздан күңелдәге музыканың яңгырашы әкренәйде, аның урынына хәтергә кайчандыр укылган сүзләр килде. Мәхәббәт — хезмәт ул, диелгән

иде анда, рух һәм кул хезмәте. Фәкать рухың һәм кулың туктаусыз хезмәт иткәндә генә, сөюне саклап була. Гашыйк булу — ул әле бер шырпы гына, сөю уты янсын дисәң, ягулыкны өстәп тор. Ә бәлки шушы хакыйкатьне аңлый белмидер Шәфика, хата ясыйдыр? Ул соң Рәмзинең көнелендә калыр өчен нишли, аның эчендә ни барын беләме? Көнелендәге әрнүләрен сизәме? Шәфикага ире кызганыч булып күренде. Әнә бит ул ничек таралып ята, хәзер берәрсе китереп сукса, үз-үзен яклап та кала алмаячак. Гайрәтле ирләрнең дә менә шундый көчсез чаклары була, һәм, шуны уйлап, Шәфика иренең таза, кайнар аркасына елышты. Үзеңнең бәхетеңне, байлыгыңны сакларга кирәк дип уйлады. Житте, язмыш Шәфика белән күп шаярды, моннан ары ул үз тормышын ныклап үз кулында тотар!

...Иртәгәсен уянгач, Рәмзи үз күзләренә үзе ышанмагандай, керфекләрен еш-еш каккалады: аның каршында, поднос тотып, ефәк халат кигән Шәфика басып тора иде. «Уяндыңмы? — диде ул йомшак тавыш белән.— Иртән торуга, авызыңа тәмәке кабасың, саулыгыңны бетерәсең. Башта берәр стакан кефир эчеп җибәр менә». Шәфика диван кырына урындык шудырып китерде дә, чәчәкле кара подносны куйды. Подноста бер чынаяк кефир белән кызгылт-сары калын пыяладан ясалган көл савыты тора иде. Рәмзи, мыек астыннан гына елмаеп, стаканга үрелде.



## 15

Хаким. Мин бу илне яулап алдым! Көч белән! Ут белән! Мондагы барча җан иясенә хәзер мин хуҗа!

Кадимбикә. Җаннарны, күңелләрне ут белән дә, ук белән дә яулап алып булмый, галиҗәнап.

Хаким. Бүгеннән бар халык миңа гына буйсыначак. Электән чыгарылган законнар юк ителә!

Кадимбикә. Законнарның йөрәк түренә язылганнары бар бит әле.

Хаким. Элекке кагыйдәләр, бирелгән антлар, вәгъдәләр онытылырга тиеш. Мин кешеләрне бөтен бурычларыннан азат итәм. Бер генә бурыч куела — миңа буйсыну. Минем сүзем — закон!

Кадимбикә. Ә тугрылык законнары? Аларны нишләтерсең?

Хаким. Кемгә тугрылык? Нәрсәгә?

Кадимбикә. Илгә тугрылык.

Хаким. Ил — минеке.

Кадимбикә. Хатыннарның ирләренә, ирләрнең хатыннарына тугрылыгы?

Хаким. Юк нәрсә.

Кадимбикә. Өлкән буынга, ата-анага тугрылык?

Хаким. Миннән олы кеше юк.

Кадимбикә. Илгә тугрылык бетсә — халык юкка чыга, иргә-хатынга тугрылык булмаса — нәсел корый. Халыксыз калсаң, нәселең корыса, ни кылырсың, галиҗәнап?

...Ясалма, ышанычсыз яңгырый иде бу сүзләр сәхнәдәге Наргизә авызыннан. Бик тырышып, кычкырып, өзгәләнеп әйтә үзе, әмма әйткәне йөрәккә ятышлы түгел.

Залда, үзенең яраткан урынында — уникенче рәттә репетициянең барышын күзәтеп утырган Сафиянең йөрәге дусты өчен әрни иде. Һәр мәсьәләдә илле төрле карар кабул итәргә мөмкин һәм һәр эшне илле төрле итеп башкарырга була дигән бер атаклы язучы. Тик шунысы бар: шул илле төрленең фәкать берсе дөрес, калганнары ялгыш, хата булып чыга. Бер үк сүзне артист та сәхнәдән илле төрле мәгънә, тавыш, аһәң белән әйтә ала, әмма аның иң дөресе һәм үтемлесе — бер генә, калган кырык тугызы ясалма яңгыраячак һәм йөрәкләргә үтеп кермәячәк. Наргизә шул кырык тугыз уйдырма арасында адашып йөри иде. Бу хәлгә эче пошкан Сафия борчылып: «Әнвәрбәков та өйдә юк бит ичмаса,— дип уйлап куйды.— Ул ничек тә ярдәм иткән булыр иде».

Баш режиссерны күрше республика театрына спектакль куярга чакырып алганнар иде. Ул югында бөтен эш Бикбауга тапшырылды.

Юллар чатына кинәт ялгызы чыгып баскандай булды Бикбау. Ул да алдында яткан илле сукмакның кайсыннан барса дөрес буласын аңлап житкерми, эзләнә, бәргәләнә иде ахрысы. Артистларны рухландыру өчен дә төрле чаралар кулланып карады режиссер. Наргизәне инде уйналып килгән спектакльгә — «Галиябану»га кертүе дә шул максаттан чыгып эшләнде.

Бу турыда Наргизә Сафиягә куанып, очынып сөйләде:

— «Галиябану»да Исмегөлнең дублеры булу — сиңа бик кирәк, ди Бикбау. Соңгы елларда сәхнәдән аерылыбрак тордың, хәзер яңадан чыныгу алырга кирәк сиңа ди. И, әйбәт тә инде безнең Рәмзи, әйе бит, дускаем?

Исмегөл белән алмашлап Галиябануны уйный башлагач, Наргизәнең кәефе тагандагы кебек үзгәрүчән булып китте: Галиябану аның күңелен күтәрә, ә Кадимбикә кәефен жимерә — тынын куырып, аска сөйрәгәндәй итә иде. Көннәрнең берендә ул репетициядән тәмам сөмсере коелып кайтып керде. Төлке тунын ишек төбендә иңнәреннән шудырып төшерде дә, биек үкчәле кызыл итекләрен дә салмыйча, түргә узып, караватка йөзтүбән капланды. Сафия, алданрак кайтып, чәй хәстәренә керешкән иде инде. Ул Наргизәнең итекләрен салдырды, бүреген, тунын чөйгә элде.

— Капланып ятма, сулышың кысылыр,— диде.— Болай жайсыз да.

— Нәрсәгә жайсыз? — дип сорады Наргизә мендәр астыннан.

— Чәй белән күзләреңне юарга уңайсыз. Кичке спектакльгә күз төпләреңне шешендереп бармассың бит инде.

— Ә мин еламыйм.

— Алайса мендәр астында мышкылдап ятма, кеше төсле итеп торып утыр,— диде Сафия.

Наргизә күз яшьләрен дускаена да күрсәтергә теләми иде. Ләкин ак мендәр сер саклый белми, дымлы таплар анда карасуланып ята. Наргизә, башын иеп, тавыш белән түгел, сулышы белән генә диярлек:

— Бәхет кошын эләктердем дип куануым юкка гына булган икән,— диде.— Ычкынды ул миннән, бер-ике каурыен гына калдырды да пырхылдап очып китте. Кадимбикә очты миннән, дускаем!

— Туктале, сабыр ит. Кайсы рольнең безгә ансат бирелгәне бар?

Сафия йомшак сүзе, каты чәе белән аның күңелен күтәрергә тырышты. Ләкин тынычлыкны бозучы табылды, коридор буйлап, каты-каты басып, болай таба килгән аяк тавышлары ишетелде, тыпырдатып, ишек кактылар. Икесе дә сискәнеп китте: бу рәвешле бармакларын биетеп фәкать Наргизәнең ире Низам гына кага белә иде. Икесе дә хәрәкәтсез тынып калды, коридорда да тынлык урнашты. Бераздан бармаклар ишектә тагын биешеп алды. Бүлмәдәгеләр һаман телсез утыра иде әле, дәшүче булмады. Шактый шулай торганнан соң, ниһаять, каты шыгырдап, әйтерсең лә шомлы бер көй сузып, әкрен генә ишек ачыла башлады. Хәерсез ишек, аның бу хәтле шыгырдаганын кызлар белми дә иде, тиз генә ачканда алай жанны өшетеп чинамый бит ул. Менә ишек ярыгы зураеп, анда Низамның кара бүреге астыннан түгәрәк карасу йөзе күренде.

— Мөмкиндер бит?

Жавап булмады. Ләкин ишек кире ябылмады. Низам бүреген салып кулына тотты да, салмак хәрәкәт белән бүлмәгә кереп басты.

— Саумысез!

Наргизәдән жавап булмады, Сафия аннан узып исәнләшергә кыймады. Низам, бүреганнән кар каккандай итенеп, кара кайры тун итәгенә суккалады.

— Минем сәламемне дә алучы юк хәзер бу өйдә, ә?

— Үзең дә белгәч, ник килеп йөрисең? — диде кинәт телгә килеп Наргизә. Аның кыяфәте горур, башы югары, йөзе тыныч иде, әле генә елап яткан иде дип әйтсәләр дә ышанмассың.

— Өмет йөртә инде кешене,— диде Низам ничек тә тыныч, иплэп сөйләшергә тырышып.
— Нинди өмет ул тагын? Кем өметләндергән иде монда сине? — Наргизәнең бу соравы мәсхәрәле яңгырады.
— Өмет шул инде — акылыңа килмәссеңме дим. Кеше бер дуамалланса, бер игә килә.
— Син мине ахмаклык эшләде дип уйлыйсың инде алайса. Дуамалландың димәкче буласың. Ялгышасың! Синнән әҗәткә акыл сорар көнгә калмадык әле. Шулай бит, дускаем? — Наргизә, Сафия тарафына борылып, елмайгандай итте.
— Кара аны, соңара күрмә,— диде Низам.
— Нәрсәгә соңарыйм?
— Минемчә, сиңа акыл сорарга бик вакыт. Бик! Режиссер абзаларың ахмаклыгыңны бөтен халыкка фаш иткәч, соң булмагае!
Низамның түгәрәк сөйкемле йөзе кинәт үзгәрде, кара-кучкыл иреннәре җәелеп, алар арасыннан ак, таза, үткен тешләр елтырады. Ерткыч тешләре, эләктерсә, өзә торганнар! Әнә нинди кыяфәткә дә керә ала икән әле бу чибәр егет! Театрдагы хәлләрне кайдан белгән диген! Күзгә-башка чалынып йөргәне дә юк бит үзенең.
— Син үз акылыңны ике кешегә җитәрлек дип саныйсыңмы әллә? — дип сорады Наргизә аннан.
— Һәрхәлдә синең кебекләр безнең кебекләрнең акыллы киңәшенә бик тә мохтаҗ әле,— диде Низам, бәхәстә өстенлекне бирмәскә тырышып.
Наргизә мәһабәт кыяфәт белән торып басты, ялкын кебек җирән бөдрәләрен чигәләреннән өскә таба бармаклары белән тарады, гүяки алар арасыннан иң ачы, иң үткен сүзләр эзләде.
— Акыллы ир үзен ташлап киткән хатыны артыннан бу рәвешле йөрми ул, иеме, дускаем?
Сафия спектакль алдыннан Наргизәне чыгырыннан чыгармаска, тынычландырырга кергән белә, бу сүз көрәштерүне туктатырга җай эзли иде. Тапкан бит көнен Низамы да! Тик ничек тыярга аларны? Катышыр идең, кара-каршы тәгәрәгән ике таш арасына барып кысылгандай булмагаең!
— Бүген авыр көн безнең,— диде Сафия.— Вакытсызрак әле бу сөйләшү.
— Сезнең җиңел көнегез, иркен вакытыгыз булганы бармы соң? — Низам, сулышына йотылып, сүз таба алмый торды.— Кеше төсле яшисезмени сез! Сәхнәдә буй күрсәтер өчен, ирне ташлап, баланы ятим итеп, үзең типкедә калу акыллы эшме әллә?
— Во-он! Биш ел җанымны ашаганың да җиткән! Во-он!

Низамның иреннәре күгәреп бөрелде, тешләрен каплады, әмма чыраеннан ерткыч кыяфәте китмәде. Менә ул бүреген батырып киде, ике кулын кесәсенә тыкты. Мөгаен, араларны җайларга, тыныч кына сөйләшергә ниятләп килгән булгандыр ул. Ләкин очрашу теләгәнчә барып чыкмады. Шуны аңлап, чыгып китәргә борылган да иде инде, кинәт нидер исенә төшкәндәй туктады, кесәсеннән нәрсәдер алып, Наргизәгә таба сузды:
— Юкка кычкырасың. Мин бит сиңа кирәк әйбереңне бирергә килгән идем. Онытып калдыргансың дип уйлаган идем. Хәзер инде беләм: син аны үзең ташлап киткәнсең ахрысы. Кирәге беткәндер, берәрсе килеп сүз кушканны көтеп йөрисеңдер.
Һәм ул, усал кизәнеп, кулындагы әйберне өстәл аша караватка тондырды. Наргизә аны шундук үрелеп алды — ул милиция сызгыручы икән. Сафия аны-моны аңлап җиткермәде — колак тондырып, җанны сискәндереп сызгыры чыелдады.
— Милиция! — дип кычкырды Наргизә иреннәреннән сызгыргыны алып.— Коткарыгыз!..
Сафия лып итеп урынына утырды, ә Низам усал итеп көлде:

— Бу шул соңгы сызгыруыңдыр инде, моннан ары сызгыртмаслар!

Һәм ишекне кисәк чинатып ябып чыгып китте. Наргизә, караватка капланып, бөтен гәүдәсе белән калтыранып шаркылдарга тотынды.

— Наргизә, тукта!

Ә ул көлә.

— Житте дим, Наргизә!

Ә ул шаркылдый да шаркылдый.

— Наргизә, тыел бераз! Кулга ал үзеңне!

Ә ул туктамый. Нишләргә? Сафия өстәл астында аунап яткан кечкенә кара сыбызгыны күреп, иелеп алды да иреннәренә китерде. Ачы чыелдау колакны ярды. Наргизә сикереп торып утырды, күзләрен сөртеп ишеккә карады.

— Син миңа шуны әйт әле, Наргизә: каян килгән сыбызгы соң бу?

— Аны миңа... өйләнешкәч тә... әле театрда эшләгәндә... Низам биргән иде...— диде Наргизә сүз аралаш сулкылдап.— Төнлә соңарып кайтасың... алай-болай бәйләнсәләр... сызгыртып кына жибәр... дигән иде...

— Кара, ник соң аны әйтми йөрисең? Ерак яшәүче кызлар күп бит бездә. Бүтәннәр дә алсын мондый сыбызгыны. Бик кирәк әйбер бит.

Ничек тә Наргизәнең уйларын таратып жибәрергә, Низамны да, Галиябануны да оныттырып торырга кирәк иде. Сафия сыбызгы белән бик нык кызыксынган булып кыланды, тагын бер тапкыр йомшак кына итеп сызгыртып алды.

— Берәр тапкыр кирәге чыктымы соң? — дип сорады.

— Булды бер тапкыр... Төнлә кайтырга автобус көтеп тора идем... Ленин районына сәгать уннан соң транспорт начар йөри бит... Шунда бер машина килеп туктады. Әйдәгез, ди, илтеп куям. Утырдым.— Наргизәнең сулкылдавы чыннан да сирәгәя башлады.— Киттек шулай. Дамбага барып житкәч, ниятен сөйли башлады бу. Мин сиңа күптәннән кызыгып йөрим инде, ди. Без, ди, очрашырга тиеш. Ирегез барын да беләм, әмма яратам, түзәр әмәлем калмады, ди. Менә шушы минутта минем белән очрашырга вәгъдә куймасагыз, мин сезне машинадан төшермим, хәзер үк үзем белән алып китәм, ди... Алып та китте дуылдатып. Ленин районының моңарчы күрмәгән аулак урамнарына барып кердек шулай. Әллә нинди озын-озын коймалар яныннан, дыңгырдык юллар буйлап куа гына бу. Бетте баш дип утырам, котылырга бер чара тапмыйм.

— Ә соң юри генә риза булып кылана алмадыңмы?

— Ну инде, дускаем, жыен әтрәк-әләмгә ялган сөйләп йөрергә... үз дәрәжәңне төшереп... Минем андый эшкә осталык юк, үзең беләсең!

— Шуннан?

Наргизә тәмам тынычланып килә иде. Сафия аның чынаягындагы суынган чәйне түгеп, яңаны, кайнарракны агызды.

— Шуннан ни күрим, бер почмакта милиция мотоциклы тора, янына милиционерлар чыгып баскан. Жанкисәкләремне күрүгә, әчкә жылы керде. Шулар турына житкәч кенә сыбызгыны сызгыртып торып жибәрдем, мин сиңайтим, котын алдым гашыйк егетнең. Мотоцикл турыннан зур тизлек белән үтеп киттек китүен, ләкин ишетәм, арттан да сызгырта башладылар. Борылып карасам, мотоцикл да кузгалды. Коелып төште кыю егет, машинасын юл кырыена борып туктады.

— Ә син?

— Ә мин чыктым да чаптым. Нишләгәннәрдер анда.

Наргизә көлеп жибәрде.

— Син моны Низамыңа сөйләдең инде, билгеле,— дип сорады Сафия.

— Минем авызда сүз тормаганын беләсең бит инде. Шундый кызыкны сөйләми ничек түзәсең!

— Ул шуннан соң сиңа, театрны ташла, дип бәйләнә башлагандыр да әле.

— Бу темага ул төрле очракларда, төрле вариацияләрдә минем нервыда һаман уйнап торды инде.

Наргизә әкренләп рәткә кереп бара иде. Ләкин бер-ике йотым чәй капкач, тагын чырае сытылды, күрәсең, эчендә һаман ут яна, кинәт дөрләгән ялкын теле белән вакыт-вакыт бәгырен өтеп ала иде.

— Үзең уйлап кара инде, дускаем, шушы хәлләрдән соң мин ничек итеп ирләрегезгә тугры булыгыз дип, халыкка акыл сата алыйм ди! Ирнең ниндие юк! Аларга тугрылыклы булабыз, дип, үзләре юкка чыксынмыни инде хатыннар?

— Кадимбикәнең Нариманы чын ир бит ул, идеал.

— Андый идеал ирләр юктыр ла ул дөньяда! Ышанмыйм мин, аңлыйсыңмы, ышанмыйм. Андый яратуга, андый тугрылыкка ышанмыйм. Юк ул андый мәхәббәт, булмаячак та. Бу спектакльне, беләсең килсә, әкият итеп, водевиль итеп куярга кирәк иде. Җыр-такмак белән, уйнапбиеп кенә. Эх!

Наргизә бүлмә уртасына чыгып басты да, сары күлмәге белән балкып торган гәүдәсен уйнатып, кулларын җәеп җибәрде:

— Сөям сине, сөям сине, сөям сине, чәчәгем!..

Ул дәртле, матур итеп җырламакчы булды, ләкин менә шушы берничә сүз дә аның тамагыннан көй белән түгел, әллә ниткән гырылдауга уралып чыкты. Наргизә үз колагына үзе ышанып җитмичә, тынып калды, аннары әкрен генә сузмакчы булды:

— Сөймә мине, сөй башканы, дигәнче сөячәгем...

Тагын карлыккан пышылдау, тагын көй чыкмый... Тавышы беткән иде Наргизәнең!

— Сафия, дускаем, ә Галиябану? Сәхнәдә ничек җырлармын?

Ул тагын җырлап карады — булмады. Тамагын кыргалады, кайнар чәй йотып куйды — ачылмады тавыш!

— Тизрәк Исмегөлгә әйтергә кирәк!

Наргизә ишеккә юнәлде.

— Исмегөл өйдә юк бит, «Казан сөлгесе» белән авылга киттеләр,— диде Сафия.

Наргизә ишекле-түрле йөренде, җырлап карады. Сөйләшкәндә сизелми, ә менә җыр чыкмый тамактан...

— Сафия, йөгер тизрәк Рәмзигә! Спектакльне алыштырсыннар!

Рәмзи театрдан киткән иде инде. Өенә шалтыратырга туры килде.

— Авырыймыни? — дип сорады ул хәлне аңлаткач.

— Юк, авырганы сизелми болай. Сөйләшүен дә әйбәт сөйләшә, җырлый гына алмый.

Рәмзи бераз тынып торды.

— Хәзерге минутта бернишләп булмый,— диде ул, ниһаять.— Спектакльне ничек тә үткәрергә кирәк. Наргизәгә әйт, сәгать биштә театрда булсын!

Анысы инде әйтмәсә дә мәгълүм: төп рольләрне башкаручылар болай да ике сәгать алдан җыелалар: иң мөһим күренешләрне, җырларны кабатлыйлар.

Сафия, чана сөйрәп, яслегә чапты. Ул, Илнурны ияртеп, театрга килеп кергәндә, Тәүфикъ, Наргизә, Рәмзи сәхнәдә иделәр. Оркестрның дирижеры Равил Сәләховка хәл аңлатылган; шулай, иптәшләр, героиняның тавышы юк, кайбер урыннарны кыскартырга туры килер, ә кайсыларын музыка белән генә үткәреп җибәрергә. Оркестр чокырындагы музыкантлар шым булганнар, пульт артына баскан яшь дирижер — кара фрагы да, актылык сибеп торган ак яка-манжетлары да әле генә энәҗептән төшкән, ә үзе яңа гына ясалган курчак төсле сөйкемле һәм нәзакәтле яшь егет — уң кулындагы таякчыкны «игътибар!» дигәндәй күтәргән килеш, сул кулы белән ноталар актара, аның алтын кысалы күзлегеннән үк соң дәрәҗәдә аптырашта калганы сизелеп тора иде. Әйе, аның күп әсәрләрне үзенчә аңлап, үзенчә яңгыратканы бар, әмма дә ләкин тавышсыз Галиябануның җырын халыкка ишеттерә алганы юк иде әле.

Сафия Илнурны җитәкләп, грим бүлмәсенә китте. Сәхнә артында

да шомлы халәт урнашкан, барысы да, каты авырулы йорттагы кебек, сагаешып калганнар иде. Ниндидер күңелсезлек булачагын сизгәндәй, һәммәсе дә залдан килгән тоның шауга колак салалар иде.

Тик тамашачылар гына әле берни белми, алар үзләренә күптән таныш, шулай булуга карамастан һәрвакыт тансык, күңелгә якын кыйссаны — ике гашыйкның җырлашып сөешү һәм җырлашып хушлашу тарихын тамаша кылырга килгәннәр иде. Ә бүген алар каршына җырламый торган Галиябану чыгып басачак. Ничек кабул итәр алар бу хәлне?

Менә Наргизә сәхнәдән чыгып, грим бүлмәсенә кереп утырды. Көзгегә карады.

— Күгәреп катканмын ич мин!

Ул бит очларына иннек ягарга кереште. Бераздан тагын агарынып киткәнен күреп, тагын сөртте кызыл буяуны.

— Карале, агарып каттым, йөз аклыгы буяу кызылын ашый,— дип сөйләнә иде. Сәхнәгә чыгар юлда артистлар, техник персонал җыелып, пышылдашып тора иде, Наргизә килә башлагач, алар икегә аерылып, уртадан юл ачтылар. Галиябану шул тере коридор аша үтеп, сәхнәгә чыкты. Беркем аңа дәртләндерерлек сүз әйтмәде, берәү дә елмаймады — кешеләрне шомлы юлга гына шушы рәвешле озаталардыр. Бары Сафия генә аның салкын бармакларын тотып алып, каты кысты:

— Ә син бирешмә!

Ә сәхнәдә сөенечле, матур күренеш — авыл киче. Менә Галиябанулар турыннан егетләр җырлап узды, менә Хәлил килде, җыр сузды. Менә тәрәзә ачылды. Дирижерның таякчыгы һавага күтәрелгән килеш туктап калды, тынлык урнашты. Наргизә тирән итеп сулыш алды да әкрен генә, бик әкрен генә җырлый башлады, зал кинәт бушап калгандай өнсез булды. Зал кызны аңлый, аның әкрен җырын йөрәгенә сеңдерә, ул Галиябануның әти-әнисе ишетер дип сакланып кына, егетеннән оялып кына тәрәзәдән караганын, җырлавы да яшьлек дәртеннән һәм сөю шатлыгыннан бөркеп чыкканлыгын белә иде. Галиябану әкрен башлый җырын, әмма күңеле очынып, мавыгып китә, саклыгын оныта, тавышы көчәйгәнен үзе дә сизми кала!

Сәхнә артыннан карап торган Сафия, дустына көч биреп, кулларын канат итеп җилпеп җибәрде: әйдә, кадерлем, әйдә, көчлерәк суз җырны, бәгырькәем! Бара бит, бара! Җырлыйсың, бик матур җырлыйсың, әнә, зал ничек тын калып тыңлый! Шул минутта, әйтерсең лә, Наргизәнең тавышына кушылып, Сафиянең куанычы да сәхнә артыннан залга ташып чыкты. Яшь дирижерның йөзе елмаюдан балкыды, аның ике беләгендәге аклык сипкән манжетлары акчарлаклар кебек баш очында шатлык белән җилпенде, оркестр җырны күтәреп алды. Зал, хәйран калып, кинәнеп, күптән таныш, күңелләргә күптәннән бик якын җырны тыңлады:

> Көн дә саен чыга алмыйм,
> Хәлил бәгърем, җанкисәгем,
> Әнкәемнән сүзләр бар.

Спектакльдән соң Наргизәнең тиз генә аңына килеп, җитез генә җыена алмасын белгән Сафия Илнурны тизрәк алып чыгып китәргә ашыкты. Малай күптән арган, грим бүлмәләре тирәсендә, әйле-шәйле килеп, миңгерәп йөри иде.

Өйгә чыгуга, киеренкелек бетте, көндезге борчулардан соң җанны бер тынычлану биләп алды. Йокымсыраган сабыйны чишендергәндә, аның татлы сулышын битендә тоеп, күңел тәмам эреде.

— Борын-борын заманда, кәҗә команда...— дип гадәттәгечә әкият сөйләргә кереште Сафия, аны яткыргач.

Йокы Илнурның куе керфекләрен йомшак җилемгә манып алган да, бер-берсенә якынайта, авырайта, ябыштырырга тырыша. Малайның бирешәсе килми, күзләрен зур ачып әкиятне тыңлап бетермәкче, әмма алтын керфекләр әкренләп зәңгәрсу күз алмасын каплый баралар, менә

инде күз агы сызылып кына күренә башлады, менә бөтенләй күренмәс булды... Сафия әле аннан соң да бераз, бала янында, аңа сокланып, күңел рәхәтлеге тоеп утырды.



16

— Исәнмесез, Гыйззәт абый. Ашыгыч йомышыгыз бармы әллә?

«Ни йомышы булсын аның миндә?» — дип уйлады Сафия үзе эченнән.

— Ашыгыч дип, бик ашыгыч та түгел түгелен. Син вәгъдәңне онытмагансыңдыр бит?

Сафия, гаҗәпләнеп, кашларын күтәрде. Вәгъдә? Нинди вәгъдә? Ул Гыйззәткә нинди дә булса вәгъдә куйганын һич хәтерләми иде.

— Соң теге... Бер сөйләшеп утырыр идем, дигән сүзеңне,— дип аңлатты кыенсыныбрак калган Гыйззәт. Сафия иркенәеп елмаеп җибәрде:

— Ә-ә, ул гынамыни? Берәр мөһимрәк нәрсә онытылганмы дип торам тагын. Сөйләшеп утырырга була анысы, ник булмасын.

— Бүген очрашуга каршы түгелме син?

— Бишкә хәтле генә була шул, Гыйззәт абый. Аннан соң спектакльгә әзерләнәсе.

— Шул бишкә хәтле генә булса да.

— Гафу итегез, Гыйззәт абый, мин Сезне кунакка чакыра алмыйм. Наргизә авырып тора әле безнең. Кереп, хәлен белеп чыгыйммы әллә? Бәлки, беразга...

Гыйззәт кара замша перчатка кигән кулын селтәде:

— Юк-юк, шундый сүзне Наргизәгә әйтәләр димени! Без инде моны икебез генә белик. Мин сине үзем кунакка чакырырга килдем.

— Чакырган җиргә бар, куган җирдән кач, ди халык,— дип шаярып җавап бирде моңа Сафия.

— Мин «Татарстан» гостиницасында сөйләшеп куйган идем.

Монысы Сафиягә ошап бетмәде.

— Кем белән, Гыйззәт абый? — дип сорады ул җитдиләнеп.

— Кирәкле кеше белән инде. Ничек соң, вәгъдәң ныкмы синең?

Сафия икеләнеп торды. Гостиница тирәсендә чуаласы килми иде аның килүен, ләкин бит олы кешене үпкәләтү дә яхшы түгел. Өстәвенә уйлап җиткермичәрәк вәгъдә дә бирелеп куелган икән. Гостиницада яшәүче берәр танышы янына алып бармакчыдыр инде. Бергәләшеп сөйләшеп утырырга... Сафия авырсынып кына булса да ризалашты. Әгәр баш тартса, Гыйззәтнең, күңеле гел начарлыкта икән бу кызның, дип уйлавы ихтимал иде.

Алтынчы каттагы бер бүлмәне Гыйззәт үз кесәсеннән ачкыч чыгарып ачты. Бу — гаҗәп иде. Сафия ник килгәненә үкенә башлады. Гыйззәт аның йөзе үзгәрүен күрде, ләкин бөтенләй икенчегә юрады:

— Мин өч сәгатькә дип сөйләштем, бер дә кыенсынып торма, борчучы булмаячак,— диде. Ул Сафиянең чәшке якалы гади генә коңгырт пальтосын, шундый ук гади, кечкенә чәшке бүреген алып чөйгә элгәндә, тәнкыйть күзе белән ныгытып карады, нидер әйтергә талпынгандай итте, ләкин тыелды. Үзе дә тунын-бүреген салгач, ванна бүлмәсенә кереп төзәтенеп чыкты, иркенәеп эчкә узды. Аның үз-үзен тотышыннан мондый бүлмәләрдә еш булганы, бу мохитка күнеккәне сизелә иде. Җылыга кергәч, аның чыраена төс иңде, пеләше дә яктырып китте бугай. Сафия тарсынып кына кәнәфинең читенә утырып, аны күзәтте, үзен тынычландырырга, күңеленә килгән ямьсез хисне куарга тырышты.

Чыннан да, нигә болай кыенсынып торырга? Әтисе кебек өлкән, мөхтәрәм кеше аны, әйтергә кирәк, шушындый шактый уңайсыз һәм четерекле урында очрашырга чакырган икән, моңа бик җитди сәбәп булырга тиеш. Аулак, тыныч шартларда гына сөйләп була торган бик тә мөһим сүзе бардыр аның Сафиягә. Ул, бәлки, әлеге дә баягы «Теге якта»

исемле пьесасы хакында сөйләшергә, үзенең намусы аклыгын Сафия каршында исбат итәргә телидер. Бик зур гаеп ташланды бит аңа теге чакта. Югыйсә мондый очрашуга башка ни сәбәп булуы мөмкин?

Чыннан да, Гыйззәт бик дулкынлана, бер урында тора алмый, һаман әрле-бирле йөренә иде әле. Ике карават, бер өстәл һәм кәнәфиләр куелган бу бүлмә, бер-ике кич кереп кунар өчен барлык уңайлыклары да булуга карамастан, котсыз иде, анда моңарчы булып чыккан бик күп кешеләрдән калган тынчу ис саклана иде. Сафия, күзенә ямь эзләп, көньяк-көнбатышка чыккан зур тәрәзәдән тышка, шәһәр йортларының тигезле-тигезсез, ямьсез түбәләре өстендә балкыган шәфәкъ яктысына карады. Сагышлы кояш баю ягына бара, үзенең соңгы нурларын бик саран гына шушы күңелсез бүлмә эченә дә суза иде.

Ниһаять, Гыйззәт, нәрсәгәдер тәвәккәлләгәндәй итеп, алгы бүлмәдән ак ырмаулы кара дипломатын алып керде, аның биген шартлатып ачты да, эре, кызыл алмалар чыгарып өстәлгә, Сафиянең каршысына куйды.

— Юылган, шул килеш ашарга була.

Аннары шампанский шешәсенең көмешкә уралган муенын гына күрсәтеп:

— Мин синең нинди шәрап яратканыңны да белмим бит әле. Зәвыгыңа туры китердем микән? — дип сорады.

— Кич спектакль бит, Гыйззәт абый. Безгә тамчы да ярамый.

— Шампанский тиз чыгып бетә бит ул. Кайбер артистлар, сәхнәгә чыгар алдыннан кыюлык өчен бер-ике йөз граммны юри салабыз, диләр бит.

— И, Гыйззәт абый, Сез шуңа ышандыгызмы? Шаярып кына сөйли бит аны безнең Зыятдин, кеше көлдерер өчен генә. Эчми ул үзе.

— Миңа барыбер, теләсә нишләсен. Алай да, мине ихтирам итсәң, бер генә йотым булса да авыз итәрсең инде.

Гыйззәт, малайларча каушап һәм каударланып, шешәнең көмеш башлыгын салдыра алмый азапланды. Сафия бер алманы алып тешләде. Аның тизрәк иң мөһим сүзне сөйләшәсе килә иде. Гыйззәт башлап җибәрергә кыенсынадыр дип уйлап, ул аңа кыюлык бирмәкче булды:

— Теге чакта, Сезнең пьесагызны укыганда, шундый күңелсез килеп чыкты. Артык кызып китте Җәмил абый. Үзе начар кеше түгел ул. Кеше котыртуына карый торган гадәте дә юк. Аңлап җиткермәгәндер инде...

Сафия уенча, бу сүзләрне ишеткәч, Гыйззәт сискәнергә, тынып калырга тиеш иде. Йөрәк ярасына кагыла торган сүз бит. Әмма Гыйззәт аны ишетмәде дә кебек, күбекле шәрапны стаканнарга салып азапланганда, кулы да тетрәнмәде. Стаканнарны тутырып, әмма ялтырап торган коңгырт өстәлгә тамчысын да төшермичә салганнан соң, ул үзеннән бик тә канәгать кыяфәт белән аягөсте торып басты.

— Әйдәле, бер утыру хөрмәтенә.

Аннары зур шоколадның көмеш тышчасын шытырдатып сыдырды, бер шакмагын сындырып алып, теш арасына кыстырды. «Куелган тешкә сыланып җайсызламый микән?» — дигән уй килде Сафиянең башына.

— Узган гомерләр искә төшкән саен, хәйран калам хәзер,— диде Гыйззәт, уйчан кыяфәткә кереп.

«Башлады»...— Сафия беркем белмәгән серне ишетергә әзерләнүдән эчке бер киеренкелек кичерә иде.

— Әйтсәм, ышанмассың: үз гомеремдә күңелем теләгән кеше белән яшәү насыйп булмады бит миңа.

Сафия бит очларының кызышканын тойды, ә менә тәрәзәгә, баеп барган кояшка текәлгән Гыйззәтнең чырае исә уйчан, тыныч калды.

— Беренче хатын белән сугыш башлангач кавыштык без. Мин заводта эшлим, язган әйберләрем матбугатта күренә башлады, пьесам куелды, ә ул — цехның комсомол секретаре. Миңа гашыйк икәне әллә каян сизелеп тора иде аның, ә минем баштарак нишләптер күңелем

ятмады. Әдәбият-сәнгать тирәсендәге кешене тели идем, иҗатымда терәк булырлыкны. Сугыш башлангач, уйлар да үзгәрде. Әллә исән калам, мин әйтәм, әллә юк, ичмасам бер кешене бәхетле итим. Тоттым да өйләнеп куйдым теге комсомол секретарена. Билгеле инде, озак яшәп булмады, язмыш мине еракларга алып китте, юллар уравычка әйләнде. Мин кайтканда, малай мәктәпкә йөри иде инде. Сагынышып күрешербез, бергә яшәүнең кадерен белербез дип уйлаган идем. Алай булып чыкмады. Мин инде аның белән гомергә бергә булырга бик риза, ә ул чит итә. Күзенең нуры кача иде мине күрсә. Бер сүрелгән мәхәббәтне кире кабызам димә икән. Бер көнне шулай өйдән чыгып киттем дә кире әйләнеп кайтмадым. Бөтенләй урамда калдым. Ул чакларда Казанда фатир табулары ифрат авыр иде. Ярый әле, бер танышым хәлемә керде, бер ялгыз хатын янына алып китте. Бүлмәсенең ике почмагына караватлар куелган икән. Без шулай икебез ике караватта бик күп төннәр үткәрдек. Өч айга сузылды шул хәл. Син моның ничек озак икәнен аңлап та бетермисеңдер әле. Кыш буе дигән сүз бит ул. Карлар ява, бураннар дулый, аннары бурәнәләрне шартлатып яра торган суыклар килә, көрт өсләре тыгызлана, кояш һаман биеккәрәк күтәрелә, карларны эретеп челтәрли... Өч ай буе ул хатын миңа бер ишарә дә ясамады, шунысы белән — тыйнаклыгы белән алдырды. Ул миңа күз карашы белән генә булса да ым какса, мин шундук борылып чыгып киткән булыр идем. Язгы бер төндә мин ике карават арасына сузылып яткан ай нурын үзем атлап уздым. Ул миңа: «Күпме теләсәң, шул кадәр бергә булырбыз, китәргә уйласаң, мин сине тотмам»,— диде. Ирегемне чикләмәде. Һаман шулай яшәп ятабыз менә.

— Ә соң беренче хатыныгыз, улыгыз? Алар ничек яшиләр? — дип сорамый булдыра алмады Сафия.

— Мин аны тәүбәгә килер дип уйлаган идем. Кайт, юләрләнеп йөрмә, дип хәбәр салыр дигән идем. Ә ул дәшмәде.

— Ничек яшиләр соң алар? — дип төпченде Сафия.

— Ничек-ничек? — Гыйззәткә бу сорау ошамады ахрысы.— Үзе белгәндер инде ничек яшәгәнен, миңа килеп әйтмәде. Миннән котылгач, рәхәтрәк булыр, дигәндер... Әйдә, бер генә йотым кап инде.— Гыйззәт гәүдәсе белән өстәл өстенә авышып, стакан тоткан кулын аңа таба сузды. Чәнти бармагындагы калын алтын балдагы тәрәзәдән төшкән шәфәкъ нурында тагын да кызылрак булып күренде. Сафиянең дәшми-тынмый утыруын ул үзенчә юрады:

— Син бер дә кыенсынма,— диде.— Без начарлык эшләмибез бит. Башка җирдә очрашсаң, танучысы булып тора, кая барма, машина фарасына эләккән куян кебек бит безнең хәлләр. Андый уттан адәм баласының түгел, кыргый җанварның күзе сукыраеп, зиһене чуала.

Ул йомшак, ак бармагы белән өстәлне ышкыштырып, аска карап, сүзен дәвам итте. Сафиягә аның йөзе күренми, каршыда йомры баш түбәсе генә тоныкъ елтырый иде.

— Менә, ниһаять, мин үз күңелемдә йөргән кешене очраттым. Анда мин теләгән бөтен нәрсә бар: матурлык та, тыйнаклык та, сафлык та, сизгерлек тә, акыл да. Гамьнәремне йөрәгенә бик якын ала торган изге җанны очраттым мин. Спектакльләрдән соң яшьләр белән бергә сәхнәгә очып менәргә талпынган чакларым күп булды. Менгән дә булыр идем, алдында баш игән булыр идем, ачуланырсың дип курыктым.

Сүзнең үзе хакында барганын Сафия шунда гына аңлады. Аңлады һәм оялуыннан бөтен тәне эсселәнеп китте. Шундый матур сүзләр белән аны мактыймыни әле бу Гыйззәт? Арттыра агай, юри генә сөйли!

— «Галиябану»да әллә ни күп тә сөйләмисең, ә шулай да, син сәхнәгә чыгуга, бөтен зал яктырып китә. Ул синең, кулларыңны җилпеп, баскан урыныңда гармун көенә тирбәлеп торуларың, аккош кебек салмак кына басмадан чыгуларың... Шунда минем тарафка да күз сирпеп аласың үзең. Бәлки, ялгышамдыр мин тиле? — Ул, башын күтәреп, Са-

фиягә текәлде, бераз тынып торды. Сафия чарасызлыктан аптырап, елмайгандай итте.— Хәер, минем кызган башка нинди уй килмәс тә бер күрергә зарыккан күзләргә ни күренмәс. Үзем синең карашыңны аулыйм, үзем үлеп көнләшәм! Сине халыктан көнлим, бөтен залдан. Бер уйлыйм, нишләп бу Әнвәрбәков сине генә Галиябану итми икән, дип, икенче уйлыйм, ярый әле төп рольгә куймаганнар, югыйсә бөтен егет-җилән сәхнәгә менеп, синең аягыңа егылып, миңа урын да калмас иде дип. Нича тапкыр чәчәк бирергә уйладым, кыюлыгым җитмәде. Ярый инде, рәхмәт Револга, соңгысында ул минем бер кәрзин чәчкәмне сиңа менгереп бирергә риза булды. Әйдә, шул чәчәкләр өчен күтәрик әле берне.

Сафия тиз генә аңлый алмый торды. Ни сөйли соң әле бу агай? Чәчәк җибәрдем, диме? Револ аша, ди. Димәк, теге бер кәрзин чәчәк Революның үзеннән түгел, Гыйззәттән булган икән ләбаса!

Гыйззәт Сафиянең йөзендәге үзгәрешне янә бөтенләй башка сәбәпкә юрады.

— Син бер дә курыкма, шампан шәрабын ахмаклар уйлап чыгармаган аны. Шәрап ул күңел кыршауларын бушатып җибәрә, ятсынуларны бетерә. Ә мин күңелемдә кыршау булуын теләмим бүген. Бетсен кыршаулар, таралып төшсен! Минем бөтен яшәешем, бәлки, менә шушы минутлар өчен генә булгандыр! Бу бәхетнең булуы мөмкинме? Әллә төшемә керә инде, билләһи! Чемет әле мине бер бик каты иттереп!

Аның ак манжеттан сузылып чыккан, сирәк кара төк белән капланган ак беләген күреп, Сафия ирексездән артка тайпылды — бу кул аңа гипстан ясалган кебек күренде. Әмма Гыйззәт моны сизмәде, ул тәмам чишелеп киткән, тезгенен чәйнәп чапкан ат кебек, күзенә ак-кара күренмәс хәлгә килгән иде.

— Ә шулай да, Сафиякәй,ниләр генә кичерсәм дә, саулык нык бит әле минем. Йөрәгем минутына алтмыш тибә, кан басымым йөз егермегә сиксән! Егерме яшьлек егетләрдә дә юк хәзер андый пульс, андый кан басымы! Минем гөрләтеп яшәрлек чутым бар әле, һәммә кешене көнләштереп!

Гыйззәт, урынында утыра алмыйча, сикереп торып, әрле-бирле йөренде. Ул Сафиянең дәшмирәк утыруын хуплау дип белә иде бугай. Күңеле очына, хисләре ташый иде аның. Ләкин бит шунысы да бар: икең күңелендә дә уртак хис кабынса гына бу рәвешле очыну килешә. Салкын кан белән күзәтеп утыручыга синең чамасыз хисләнүең көлке күренүе ихтимал.

Тагын Җәмил абзый искә төште. Аның пульсы да, кан басымы да Бикашиннан күпкә калыша торгандыр, мөгаен. Фронт юлларын намуслы узган кешеләрнең исәнлеге нык какшады шул, ай, нык какшады. Әнә, Сафиянең үз этисе кайчаннан җир куенында инде.

— Чын мәхәббәттән мәхрүм калдым, гомерем заяга узды дип уйлый идем, якты өметләрем бөтенләй өзелгән иде инде,— дип сөйләнде Гыйззәт.— Очрашканда, синең кинәт яктырып елмайганыңны күргәч, сүнгән өметем яңадан кабынды. Их, мин сине тезләремдә генә биетеп тотар идем! Әнә, Мәскәүдә бер танылган язучыны күреп кайттым әле: җитмешен тутыргач, унсигез яшьлек кыз алган. Тезендә генә уйнатып тота, шул хәтле килешә үзенә. Хатыны да күз өстендә каш кебек. Мин әйтәм: шундый бәхет эләксә, илдә бер итеп тота белер идем мин дә. Иң элек киендереп... Аннары машина кирәкме, яхшы квартирмы... Минем анлык чутым бар, калган гомергә җитәрлек, үземнән дә калырлык...

Сафия тәрәзәгә карап утыра иде. Анда, шәһәр йортлары өстендә, шәфәкъ яктысы киңәйгәннән-киңәя бара, күк гөмбәзенең яртысын диярлек кызылга, алга, шәмәхәгә манган. Шәфәкъләр һәр кич булып тора, әмма төсләре, рәвеше, муллыгы белән беркайчан да кабатланмый. Бу кадәр ачык төсләргә баен һәм киң җәелгәнен күргәне юк иде әле Сафиянең.

Аның уйлары чуалган, күңеле болгангандай итә, ничек тә булса Гыйззәтне бу сүз чаптыруыннан туктатасы килә иде.

— Карагыз әле, Гыйззәт абый, шәфәкъ нинди көчле бүген!

— Сәхнәдә дә син бөтенләй икенче төрле ялтырар идең,— дип, үз сүзендә булды Гыйззәт.— Асылташларның да кыйммәте эшкәртеп, ялтыратып, алтын эченә куйгач кына беленә. Чүп арасыннан эзләп алучы сирәк аны. Шуның төсле, сиңа да роль кирәк. Әгәр дә мин шушы күтәренкелек белән иҗат эшенә керешсәм, сиңа атап рольләр язсам, икебез дә ничек күтәрелеп китәр идек, ә? Үзең дә әйтеп торасың бит әле, яшьләргә биргесез син дисең, иҗат итәр чагың гына дисең!

Сафиянең башына кайнар дулкын бәрде: аның юри генә әйткән сүзләрен Гыйззәт әнә ничек кабул иткән икән бит! Чын-чынлап ышанган бичара. Әгәр дә берәр яшьтәше шундыйрак сүз сөйләп маташса, Сафия табар иде аның телен кисәр җайны! Ләкин бу бит өлкән кеше, гомер буе ихтирам ителеп килгән зур абый!

— Минем әле сине бик нык күтәрерлек көчем бар. Минутына алтмыш тибә минем йөрәк!

— Ә соң хатыныгыз? — дип сорады Сафия.

— Нинди хатын? Хатыным юк бит минем! Әллә кайчан аерылган!

— Хәзер торып ятканы соң?

— Ә, аны әйтәсеңмени? Ул бит минем законлы хатын түгел. Моңарчы яшәп ятканга да мең рәхмәт укый ул миңа. Чыгып китсәм, бер үпкә дә булмаячак. Ул яктан кыенлык юк. Синең генә ризалык кирәк.

— Сез мине... кыен хәлгә куясыз бит әле, Гыйззәт абый.

— Кайчан да бер тәвәккәлләргә тиеш бит инде кыз бала. Син — ялгыз кеше, үзеңә үзең хуҗа. Хәзерге егетләргә өмет аз аларга. Әнә, Наргизәне генә кара.

Ул чәнтиеннән калын балдагын тартып алмакчы булды. Балдак күнеккән төшеннән кубарга теләми иде. Ниһаять, бармагы — күгәреп, пеләше кызарып чыккач, Гыйззәт балдагын салып һәм, Сафиянең каршына басып, тантаналы кыяфәт белән аңа сузды.

— Менә монысы вәгъдә билгесе булсын.

Сафия утырган урыныннан сикереп торды:

— Вәгъдәләрне кара-каршы бирешәләр, ә минем каршы бирерлек бүләгем юк бит әле.

— Бусы истәлеккә генә, мине онытмаска.

Сафия аның кулын кире этәреп, ишеккә таба атлады. Борылып, тәрәзәгә күз салды да:

— Гыйззәт абый, шәфәкъ кичерәя бит,— диде. Күк йөзен яртылаш иңләп алган төсләр, чыннан да, шактый азайган иде инде.

— Нәрсә дисең? Көчәя дисеңме? Көчәяме?

— Гафу итегез, мин спектакльгә соңга калам.

Сафиянең шәфәкъ хакындагы сүзен ялгыш ишеткән Гыйззәт чиксез куанган, сүз таба алмый каударлана, Сафиянең пальтосын шкафтан алып кигезмәкче, тик җиңен кулына туры китерә алмый азаплана иде.

— Бу бишмәтләреңне чыгарып ташларбыз. Каракүл тун алырбыз... Махсус тектерербез... Иң танылган осталардан...

Бу хәлендә ул Сафиягә пьеса укыган чактагыдан да кызганычрак тоелды. Бу мескенне, бичараны шушы көлке куанычыннан кинәт кенә мәхрүм итә алмады ул. Каршы сүз әйтмәде, тиз генә саубуллашып, чыгып китте.

Лифт көтеп торырга сабырлыгы җитмәде, тизрәк урам салкынына, шәфәкъ яктысына чыгарга, күңеленә көя булып кергән сүзләрне ачы җил һәм кар аклыгы белән куарга ашыкты ул. Аның үкчәләре астында текелдәп калган баскычларның да, күксел пластик ябыштырылган култыксаларның да исәбе-хисабы юк иде, ахрысы, ай-яй ялгышкан, бик әчкәре кергән икән Сафия! Тәмам буталып бетә язган икән.

Менә, ниһаять, беренче кат, иркен вестибюль, пыяла ишекләр артында кар аклыгы күренә. Ләкин ул ишектән тиз генә чыгып китә алмады, кемдер артыннан дәшеп туктатты:

— Сафия?!

Ресторан ягыннан Револ чыгып килә иде.

— Нишләп йөрисең син монда?

— Районнан туганнарым килгән иде,— диде Сафия салкын гына.

— Районнан килгән кеше иң беренче итеп үзе театрга чаба иде моңарчы. Артистларның үз янына килгәнен көтеп ята торган нинди мәнсез туганнар ул?

Лифт ягыннан Гыйззәт килеп чыкты. Ул бүреген басып кигән, якасын күтәргән, тач менә революция елларында шымчылардан качып йөргән подпольщик иде инде.

— Сәлам бирдек, Гыйззәт абый! — дип гөрелдәп, ике кулын сузып аңа каршы атлады Револ.— Нинди җилләр ташлады Сезне монда? Әллә Сезнең дә туганнар килдеме?

— Исәнме, саумы, иминлекме? — дип, шома гына аның яныннан узып китү ягын карады Гыйззәт. Револ сәерсенеп карап калды. Гыйззәтнең пыяла ишекләр арасында буталып, урамга тиз генә чыга алмаганын көлемсерәп күзәтте.

— Ни булган әле бу абзыйга? Башка чакта очратса, яныннан җибәрми иде, бу юлы чөгә балыгы кебек шуып кына үтте дә китте.— Ул күзләрен майландырып, авызын ерды.— Әллә берәр хатын яныннан чыгып килүеме чукынмышның? Мондый картлар андыйга бик хирыс була.

Сафия бит очларының кызышканын тойды. Револ аңа бик текәлеп, күзләрен кыса төшеп карады:

— Туктале... Ул бит синә да сырлан урынына ябыша иде бүтән чакта. Бу юлы сәлам дә бирми үтте... Әллә... Әллә сез бергә идегезме?

— Син ник миңа теге чакта биргән чәчкәләрнең аннан икәнен әйтмәдең? — дип сорады Сафия ачу белән.

— Белмәдем бит мин, белмәдем синең өчен аннан чәчкә алуның бу хәтле куаныч икәнен...— Гаҗәпләнүдән Револның болай да озын, киң ияге тагын да нык салынып төшкәндәй булды.— Гади тамашачыдан дидем бит мин сиңа. Кем белгән аның сиңа гади тамашачы гына түгеллеген! Башка килерлек хәлмени! Кара син аны, ә! Мыскалланмаган ефәктәй кызларыбызны күз алдында харап итәләр бит бу карт иблисләр! Ә без, әдәп саклаган булып, авыз ачып йөрибез! Ну малай! Ну малай! Кемнән-кемнән, әмма синнән моны көтмәгән идем мин, Сафия.

Сафиянең бүлмәдә чакта ук кузгалган, ләкин анда тыеп торган ачуы берьюлы ташып чыкты:

— Ичмасам син телеңне тый! — диде ул һәм йодрыкларын йомарлап, кырт борылып, ишеккә юнәлде.

## 17

Кадимбикә. Мин сиңа сүзнең турысын әйтергә килдем, галиҗәнап.

Хаким. Миңа ялган сөйләргә кем җөрьәт итәр икән?

Кадимбикә. Син килгәнче бу урында гүзәл кала иде. Ә хәзер кара: мәетләр түшәлгән урамнарда янгын, хәсрәт, үлем хөкем сөрә. Анда син урнашырлык бер бина да калмады. Шуңа син монда, далада чатыр кордырдың.

Хаким. Җиңү корбансыз булмый.

Кадимбикә. Син минем ил-җиремне басып алдың, шәһәр-авылларымны яндырып, көл-күмер иттең, бихисап җаннарны кыеп, бик күп байлыклар җыеп алдың. Синең укчыларың минем өч углымны һәлак иттеләр.

Хаким. Син монда шуны әйтергә килдеңме?

Кадимбикә. Ә шулай да синдә, хакимдә, булмаган хәзинәм бар минем. Ул байлык минеке булып калды.

Хаким. Таба алмаслык итеп яшердеңме?

Кадимбикә. Ул байлыкны яшерергә кирәкми, чөнки аны беркем дә, хәтта синдәй кодрәтле хаким дә тартып ала алмый.

Хаким. Бу дөньяда кылыч белән яулап алынмаган нәрсә юк. Әгәр булса, алтынга сатып алына.

Кадимбикә. Яулап та, сатып алып та булмый торган байлык бар. Ул — ир-егетнең йөрәге. Минем иремнең йөрәге!

Хаким. Йөрәк?

Кадимбикә. Әйе, чын кешенең йөрәге.

Хаким. Бер колның йөрәгеме? Үз гомеремдә мин күпме йөрәкләрне таптап уздым!

Кадимбикә. Әмма аларның берсе дә синең хәзинәңне баетмаган. Шунлыктан синең күңелеңдә бик зур мохтаҗлык бар!

Хаким. Мохтаҗлык? Мин теләгәнемә ирешми калмыйм!

Кадимбикә. Ә мин күреп торам: синең күңел түрендә сүнмәс хәсрәт уты яна, йөрәгеңне сары сагыш талый.

Хаким. Зур дәүләтнең башында торган хакимнең ни гаме булмас!

Кадимбикә. Хәзинәләрең арткан саен, төп байлыгың кими бара.

Хаким. Кими?

Кадимбикә. Адәм баласының иң зур байлыгы — гомере. Хакимнәрнең дә шулай. Синең гомерең көннән-көн кыскара, аны бернинди алтыннар бәрабәренә дә озайту мөмкин түгел. Иксез-чиксез биләмәләреңне, алтын тулы казналарыңны ышанып тапшырырлык варисың юк синең — хәсрәтең шуннан.

Хаким. Бу сүзләрең өчен башың киселер! Кем әйтте сиңа моны?

Кадимбикә. Йөзең, күзләрең әйтте, галиҗанап. Хәсрәт йөзгә чыга ул. Синең яну-көюләреңне беркем аңламый, гамьнәреңне бөрәү дә уртаклашмый. Кара син әйләнеп тирә-ягыңа, ялчыларыңа, хатыныңа, улыңа. Синең януларыңны тоеп, сызланган берәү бармы? Үзәге өзелгән берәрсе бармы?

Кадимбикәнең бу сүзләре Сафиянең күңелендә һаман яңгырап торды: «Синең януларыңны тоеп, үзәге өзелгән кеше бармы бу дөньяда?» Чыннан да, дөньяда иң зур байлык шушы бит инде — күңел хисләренең уртаклыгы. Хаким бәхетле булмаган. Сафиянең дә юк андый кешесе, ул да бәхетсез. Моңарчы ихтирам итеп, зурлап йөргән кешесе дә аны кимсетте, күңелен җәберләде, ә Сафия аңа тиешенчә җавап та бирә алмады. Өстәвенә һич кирәкмәгәндә Револ очрады бит әле шунда, ул инде, үзенчә, начар уйлады Сафия турында. Хәзер гайбәт таратыр, Зыятдин кебекләр Сафиядән авыз ерып көләр. Кем аңлар аның хәлен, кем йөзен аклар, кем юатыр?

Театр тирәсендә Револ очраганда, Сафия куырылып килә, аның яныннан тизрәк үтеп китәргә ашыга иде. Ә Револ бик якын иткәндәй баш иеп сәлам бирә, икесе генә белгән уртак серләре бар кешедәй мәгънәле елмая, нәрсәгәдер ишарә ясагандай, үз итеп карый иде. Көннәр үтте, егет Сафиянең серен теш арасыннан чыгармады, гайбәтмазар иштермәде.

Ә бер кичне спектакльдән соң чыкканда, Револ Сафияне Җәмил абый куышы янында көтеп тора•иде. Ул бернинди шикләнүсез, икеләнүсез Сафиягә иярде, кеше-кара күрә дип тә тормады. Әйтерсең лә алар бу очрашу хакында алдан ук сүз куешканнар иде. Урамга чыккач, ул кесәсеннән кәгазьгә төргән өчпочмак чыгарып бирде:

— Нәрсәгә бу?

— Спектакль алдыннан артист тамагына ризык үтмәгәнен беләм бит мин. Аннары, өйгә кайткач, төн уртасында өсталегездән каткан ипи сыныкларын эзләп капмаланасыз. Минем белән йөргәндә, ач булмасын әле бу дип, ашханәдән махсус кереп алдым.

— Нәрсә, шуның өчен мин синең белән йөрергә тиешмени әле?

— Ну малай, тупас та сөйләшеп куясың инде кайчакта. Әгәр дә Револ дигән егет үзе белән урамнан узган өчен кызларга хак түли дип уйлыйсың икән, бик нык ялгышасың. Минем арттан урам буйлап әрмән коньягы болгап чабарга әзер кызлар бар, беләсең килсә! Әгәр алай сөйләшсәң, бир өчпочмакны кире. Мин сине кызганып йөрим тагын.

Егетнең «кызганып» дигән сүзе Сафиянең күңелен йомшартып җибәрде, ул ирексездән көлеп куйды. Тәмләп кенә салкын өчпочмакның почмагыннан тешләде. Чыннан да, ачыгылган иде.

— Я ярый, мин шаярып кына әйттем бит,— диде ул йомшарып.
— Чамасын белеп шаярырга кирәк.
— Йокы алдыннан бераз һава алып керү зыян итми инде анысы. Көн бик матур бит.
Чыннан да, кич җылы, ак, пакь һәм хыялый иде. Алар урам аркылы чыктылар да каршы яктагы бакчага таба киттеләр. Иренеп кенә төшкәләгән кар бөртекләре алар тирәсендә әйләнгәләде, аяк астына түшәлде, юлның карасын каплады. Мондый кичләрдә ак юллардан, сихерле томан белән өртелгән якты караңгылык эченнән барганда, үзеңне җирдән аерылгандай, кар бөртекләре белән бергәләп очкандай хис итәсең. Уйлар да, сүзләр дә ямьләнә, якты һәм канатлы кичерешләр хакында гына сөйләшәсе килә.
Сафия сүзне әкренләп һаман күңелендә йөргән уйларга — Кадимбикәгә күчерде. Образның зурлыгы, Наргизәнең аңа ачкыч таба алмавы хакында сөйләшеп алдылар.
— Ирләрнең хыялы гына инде ул Кадимбикә,— диде Револ.— Кызганычка каршы, андыйлар юк шул хәзер.
Сафия Наргизәнең: «Ышанмыйм мин дөньяда андый хатын булуына, ышанмыйм, ышанмыйм!» — дигәнен исенә төшерде. Менә хәзер аның белән дә бәхәсләшәсе килде.
— Бәлки, без күрә белмибездер андыйларны,— диде ул Револга җавап итеп.— Кара әле син менә тирә-ягыңа. Ак җир, ап-ак һава. Без аны кар дибез, кыш дибез. Ләкин әйдәле, шушы минутта бар белгәннәребезне онытыйк та, тирә-юньгә беренче күргәндәй булып күз салыйк.
— Яңа туган кебек дисеңме?
— Юк, яңа туган бала ни аңлый ул? Әйтик, без Африка кешеләре ди. Без җирне — кара, үләннәрне яшел була дип кенә беләбез, кышны гел күргәнебез юк ди. Шуннан кинәт кенә менә шушы кичтә, шушы бакчага килеп төштек ди.
Урам буендагы багана башларыннан зәңгәрсу нурлар, бакча артында биек йортның зур тәрәзәләреннән саргылт яктылык сибелә, агач ботакларыннан, кәүсәләреннән күксел күләгәләр төшә. Кар бөртекләре дә сизелер-сизелмәс кенә шәүләләр ясый, алар да биешә. Һәр яктылык нурының үз төсмере, һәр күләгә табының үз рәвеше.
— Ә бит бар шундый кешеләр,— диде Сафия.
— Нинди кешеләр?
— Төсләргә, матурлыкка беренче күргәндәй сизгер кешеләр. Рәссамнар, мәсәлән. Әгәр мин рәссам булсам, менә шушындагы яктылыкның бөтен төрле төсмерләрен тасвирлап бирер идем. Мин шундый итеп ясар идем: ак юрган астында җир йоклый, аңа тәмле төшләр керә. Менә ул йокы аралаш кына, дөньяда ни хәлләр бар икән дип, кулын сузган. Бу агачлар — җирнең куллары. Ә юрган өстендә шундый рәхәт, җирнең кулларын кире аласы килми. Ул кар бөртекләренең назын тоя. Аларны учына җыя.
Чыннан да, төз каеннарның, кәкре-бөкре кәүсәле өрәңгеләрнең һәм купшы чыршыларның ботак араларына урыны-урыны белән бүрек-бүрек кар җыелган иде.
Револ ничектер өнәп бетермәгән кебегрәк хихылдап куйды.
— Без инде әллә кемчә уйлый алмабыз. Үзебезчә гади генә уйларга баш җитсә, шуңа да бик канәгать.
— Еш кына без уйларга, аңларга иренәбез шул,— диде Сафия уйчан гына.— Шуңа күрә күп нәрсәнең асылын аңлап җиткермибез.
— Кышның асылы шул инде аның — бар нәрсәне туңдыра да бозландырып катыра.
— Әллә туңасыңмы? — дип сорады Сафия гаҗәпләнеп.
— Юк, бүген җылы җылысын. Әзрәк утырып торсак та була.
Револ агач диванда күпереп яткан көртне саклык белән генә сыпырып төшерде, кар, әкренәйтелгән кинодагы кебек, бик салмак, бик

йомшак агым булып, җиргә коелды. Сафия диванга утырды да янә сүзен дәвам итте.

— Әй беләсенме, җирнең пакьлеген күреп бетермәгән кебек, без кеше күңелендәге аклыкны да күреп бетермибез, минемчә. Без каралыкка күбрәк игътибар бирәбездер, бәлки.

— Аклык дигән нәрсә күз буяу өчен генә бит ул, Сафия малай! Мин менә күпме семьяларны беләм: болай, өстән караганда, кыланмышлары гел харап инде менә, бер-берсенең авызларына гына карап торалар. Ә актарыбрак тотынсаң... Я хода! Ниләр генә чыкмый аннан! Шулшул менә, кар астында кара җир. Җир генә булса да рәхмәт әйтер идең әле, аннан хуҗысы күпме!

— Минемчә, кар астында, яшел чирәм, гөл орлыклары.

Револ бик тирән итеп сузып, авыр сулады.

— Яз көне алып килермен әле мин сине бу бакчага. Нинди орлыклар күрерсең икән. Аяк басар урын булмый кайчакта. Кешеләр дә шундый. Инде ни ышанып йөрисең. Әй менә язмышның кызуы китереп бәрсә, шушы кар шикелле аклыгы эреп ага да бетә. Әллә ниләр килеп чыга шунда күңелләреннән. Күрдек инде, күпләрне күрдек. Бик ышанасы килә дә бит, Сафия малай, ышанычларны үзе белән алып китә шул андый ташулар!

— Ышанасың килгәч, ышан гына алайса.

— Менә анием кебегрәк кыз очраса, ышанып булыр иде. Минем эти сугыштан инвалид булып кайтты, гел урын өстендә диярлек ятты, тормыш алып баруда ярдәм итә алмады. Бөтен авырлык әни җилкәсенә төште. Балалар туа торды, үсә торды, әнинең зарланганын, этине каһәрләгәнен ишеткәнебез булмады. Менә нинди иде элекке хатыннар! Бу ир начар, миңа яхшырагы кирәк, дигән сүз юк, хаста карап гомер итү читен, дигән сүз юк. Балалар алдында ата — үз урынында, ана — үз урынында. Әгәр менә Кадимбикәне синең кебегрәк артистка уйнаса, мин аны үзебезгә алып барып, әнине күрсәтер идем.

— Наргизәгә күрсәтергә ярамыймыни әниеңне?

— Танымас дип куркам, аңламас дип. Бер дә кешенең күңелен аңлар төсле түгел. Ә менә сиңа күрсәтер идем. Дөньяда башка андый хатын юк. Минем әнине күздә тотып уйнарга кирәк Кадимбикәне. Пьесаны укыгач, Даянга да әйттем, әйбәт язгансың, дидем. Теге чакта, театр гастрольдә йөргәндә, Даянны үзебезгә алып кергән идем. Эти белән бик озак гөрләшеп-сөйләшеп утырганнар иде, анидән дә тегенемоны сораштырган иде. Чын язучы андый материалны ычкындырмый шул ул, менә дигән итеп язган пьесаны. Так что Кадимбикә — минем әни ул. Исеме дә әллә ни үзгәрмәгән. Минем әни — Әсмабикә.

Сафия уйга калды. Аның Кадимбикәне Револның әнисе итеп күз алдына китерәсе килми иде.

— Ничә бала соң сез? — дип сорады ул.

— Бишәү без, биш малай. Бөтенесе — минем кебек өрлек-өрлек егетләр. Эти белән әни сугыш алдыннан өйләнешеп кенә калганнар, балалары булмаган. Ә менә эти имгәнеп кайтканнан соң, бер-бер артлы туып кына торганбыз. Кайда хәзер андыйлар? Ун бармагыңны прожектор итеп эзләсәң дә, таба алмыйсың. Таптырырсың хәзерге хатыннардан биш бала! Бала кирәксенмиләр, ирне ир итә белү юк. Җир җимертеп эшләп йөргән ирләр ярамый хәзер хатыннарына.

Револ эскәмиягә иркенләп, җәелеп утырган да, алга табарак иелеп, тезенә таянып, сөйли дә сөйли, күптәннән эчен пошырып йөргән уйларыннан бушанасы килә иде ахрысы. Нинди генә уйлар йөрми кешеләрнең башында! Сафия аны гаҗәпләнеп, кымшанмый-бүлдерми тыңлады.

— Әйтик, менә минем төсле ир хатынына нәрсә бирә ала? — дип үзалдына уйлангандай дәвам итте Револ. Аның гөрелдек тавышы да йомшакланып, әкренәеп китте. — Ашарыңа ни телисең — рәхим ит. Кияреңә нәрсә кирәк — ефәкме, йонмы — пажалысты. Ә хатыннан нәрсә таләп

ителә? Ходай кушкан шул зур бер эш — балалар үстерү, йорт карау. Шул үзе зур бәхет түгелмени? Әнә бит сәхнәдән нинди матур итеп күрсәтәләр: хатын ирен ир урынында тотсын, аңа тугрылыклы булсын, авырлык килгәндә, ярдәм итешсен. Аны ятларга алыштырмасын, дөнья малын аннан өстен күрмәсен! Ә безнең заманда нәрсә килеп чыга? Иргә ярау, бала карау гына аз әле хатын-кызга, аның тагын нидер кырасы килә. Сәхнәгә басып, үзенә юк акылны бүтәннәргә өләшмәкче.

Сафиягә бу сүзләр таныш кебек тоелды. Тукта, кемнән ишетте соң әле нәкъ шундый фикерләрне? Ә-ә, Низам әйткән иде бит боларны, Наргизәгә «тиле» дип кычкырган көнне.

— Кемне сөйлисең син? — дип сорады Сафия Револдан.

— Әллә кая ерак барасы түгел, Наргизәне генә ал. Нәрсә булганып йөри инде ул сәхнәдә, ирен ташлап? Күтәреп алырлык талант булса, бер хәл иде.

— Ул — талантлы актриса,— диде Сафия.

— Беләбез инде. Андый талантлар сезнең театрда аннан башка да житәрлек. Сәхнәдә урта кул булып, икенче дә өченче булып йөргәнче, үз семьяңда беренче булып, ир ышыгында яшәсәң, яхшырак булмас идемени? Чын егетләрнең кадерен белү бетте хәзер.

Револ Сафиягә таба елышты. Аңардан ныклык, гайрәт бөркелеп тора, аның ышыгында чыннан язмышның жиле дә, суыгы да үтмәс кебек тоела иде. Ул үз сүзләреннән кызып булса кирәк, тун изүен чишеп, озын шарфын таратып жибәрде. Шушы тынлыкта, аулакта, жирнең кар астыннан сузылган куллары, салмак яуган кар бөртекләре һәм аларның күләгәләре ят күзләрдән яшереп торган чакта, яктылык белән караңгылыкның буталышыннан күзләр бәйләнгән һәм зиһен чуалган минутларда, чак кына туңдырып торган әкрен жилдән качып, шул тун чабулары эченә керү гөнаһ булыр иде микән?

Револ, сиздерми генә, уң кулын диван аркасы буйлап Сафиянең иңбашлары турына шудырды. Ә үзе һаман алга караган, һаман әле сагышлы, әкрен тавыш белән сөйли иде.

— Дөрес, яшьлектә йөрәк кызуын бер сүрелдереп алу кирәк. Үземнән беләм: сәхнәдә бер күренеп алу — яхшы нәрсә ул. Ә инде бу эштә әллә кая китә алмасыңны белгәч, үз өстеңә табигать йөкләгән изге бурычлар хакында да уйларга вакыт. Шулай бит, Сафия малай?

Сүзнең Наргизәдән үзенә күчкәнен Сафия шунда гына аңлап алды. Аңлады, әмма күңелендә ачу да, хәтта бернинди каршылык та тумады. Чыннан да, нәрсә бирә ул сәхнә? Анда жан жәрәхәтләре ала-ала йөргәнче, бер гайрәтле ир-егетнең ышыгында яшәү яхшырак булмас идемени? Хәзер, менә хәзер сихерле яктылык, аны адаштырып, тун чабулары арасына алып кереп китәчәк...

Сафия керфекләренә уралган кар бөртекләрен сыдырып төшерде дә кискен хәрәкәт белән урыныннан кузгалды.

— Туңдыра башлады. Салкын өчпочмак тамакны да киптерде.

Револ мондый кинәт күчешне көтмәгән иде булса кирәк, югалып калгандай булды.

— Салкын? Кая салкын булсын...— дип, чабуларын жыйды ул.

— Туңмасаң, утырып тор алайса. Ә мин кайтам,— диде Сафия, аны үртәп. Револның салмак кына күтәрелүеннән, иңбашлары салынуыннан хәтере калганы күренеп тора иде. Бүркенә сарган кар авырлыгы аның башын баса иде шикелле.

Алар, урамга чыгып, кире киттеләр. Икесенең арасыннан талгын жил үтә иде. Алар шулай, дәшми генә, капкага життеләр, аннан керделәр, ике йорт арасындагы тар аралыкка уздылар, ишек төбенә килеп бастылар. Револ хужаларча хәрәкәт белән Сафия аркылы сузылып, тышкы ишекне этеп ачмакчы булды.

— Ярый, хуш,— диде Сафия.— Тыныч йокы, тәмле төш.

— Нишләп, әле чәй эчәбез дигән идең бит?

— Эчәбез димәдем, эчәсе килә дидем мин. Килсә дә, түзәргә туры килер. Наргизә күптән йоклый инде, тәрәзәдә ут юк бит.

— Йокласын, аның безгә кирәге юк.

— Безнең дә аңа кирәгебез юк.

— Чит кеше түгел,— диде Револ, бу әрепләшүне мәгънәсезгә санап.— Дөнья күргән хатын, уртак тел табар идегез әле.

Соңгысын ул калтыранган тавыш белән әйтте. Уң кулы белән ишек яңагына таянып, Сафиягә якын ук килде, сулышы йөзгә бөркелде. Сафия артка тайпылды һәм гәүдәсе белән стенага бәрелде. Ул үзен камалышта калган җәнлек кебек сизде. Егетне этеп читләштермәкче булды, әмма таш кебек нык күкрәкле гәүдәне урыныннан кузгату аның өчен тау күчерү кебек булмас эш икәнен аңлады. Сафиянең йөрәге кара төндә фара яктысына эләккән куян кебек тыпырчынды. Бу хәлдән котыла алмасын аңлау аның сулышын кысты, өнсез итте.

— Җибәр...

Револның шундый зурлыгы, башы белән күкне каплап биегәеп торуы, күзләренең сәер ялтыравы куркыныч иде. Менә ул күзләр якынайды, якынайды, ярым ачылган иреннәр арасыннан тешләр агарып күренде... Хәзер алар йөзгә килеп терәләчәк, иреннәргә ябышачак. Шуннан? Кара елан чаккач, ни була соң? Сафия ычкынырга тыпырчынды, башыннан бүрегешуып төште. Ул җан ачысы белән талпынды да, маңгае белән кисәк, астан өскә, куркыныч елтыраган күзләрнең яктысын сүндерергә теләп кизәнде.

— Ах!

Сафия сулышы киңәйгәнен, тирәсе яктырганын тойды. Револ ике учы белән битен каплаган иде.

— Борынны җимердең бит, тиле!

— Әйттем ич мин сиңа, читтәрәк тор, дип! Мин, гомумән, тәнемә кагылганны яратмыйм.

— Нәрсә син кыланып маташкан буласың? Әллә кем түгел, утыздан узган! — Револ, тун кесәсеннән яулык чыгарып, битен сөртте, ак яулыкта кара таплар күренде.— Комы коелган картлар артыннан гостиницаларга чапкан башың белән, әллә кем дип белерсең! Алтыннары миңа калыр ди торгансыңдыр. Юкка өметләнәсең, хатыны сиңа тиенен дә бирмәячәк! Синең кебекләрне күп күргән монда. Министр дәрәҗәсендәге хатыннар күземә генә карап тора минем, беләсең килсә!

«Чыннан да, бая бакчада гел дөресне сөйләгән икән бу егет,— дип уйлады Сафия.— Аның өстән караганда ак булып күренгән җанында әнә ниләр ята икән. Бер бәрүдә тишелде күңеле, һәм аннан нинди әшәкелек ташып чыкты!» Бу кеше шулкадәр чит иде, Сафия аңа фикерен аңлатып булмасын шундук аңлады. Ул Револның мәсхәрәле сүзләрен көлемсерәп тыңлады: урамда өргән көчек белән сүз көрәштереп булмый бит инде!

— Син борыныңа кар куй,— диде Сафия тыныч кына.— Бәрелгән төшкә салкын файдалы. Моннан соң сакланыбрак йөрерсең инде.

— Кайда йөрисен синнән сорар көнгә калмаган!

— Хуш!

Сафия баскычтан көлә-көлә менде. Ләкин бу көлү күңел күтәренкелегеннән түгел иде, ул тиз узды һәм үзе артыннан моңсулык кына калдырды. Җәелмә ятакка урын әзерләгәч, Сафия аның кырыена утырды да, күрше ихатадан төшкән яктылыктан агарып торган тәрәзәгә карап, уйга талды.

Я дөнья, нигә шушы кадәр аяусыз син? Бармы синең авыр минутларда сыенып, күңелне ял иттерерлек бер әр саф, чиста почмагың? Әллә соң бу пакьлеккә күмелгән бакчалар, җирнең кар астыннан сузылган сизгер куллары кебек тынып калган агачлар, тирә-юньне сихри энгергә төреп яуган карлар — алар барысы да җанны адаштыру, саташтыру өчен генә яратылганнармы?

Ярамыйдыр, күрәсең, кешеләргә бөтен күңелең белән ышанырга.

ярамыйдыр кемне дә булса өзелеп, бирелеп яратырга. Сафиянең гомере буе олылап, ихтирам итеп килгән кешесе, якынрак килеп чыккач, нинди түбән җанлы булып чыкты. Ә бу Револ тагын! Нинди ямьсез кыланды, нинди тәмсез сүзләр сөйләде...

Сафия үзен бөтен дөньяда бер ялгызы калгандай хис итте, бөтен җир караңгыланган кебек тоелды аңа. Шунда аңа ерактан, бик ерактан нур чаткысы килеп ирешкәндәй булды. Бик ямансу чакларында нечкә күңелле кешеләр күктән үз йолдызларын эзләп табалардыр да, аның нуры алар күңеленә шушы рәвешле килеп иңәдер. Дөрес, Сафиянең күңеленә төшкән нур чаткысы галәмдәге ерак планетадан түгел, ә җирдән килде бугай. Шушы минутларда аны юксынган, аны уйлаган берәүнең сагынуы иде ахрысы ул. Менә бит ничек, бер-берсенә якын күңелләр меңнәрчә чакрым ераклыктан торып та серләшә, юатыша алалар. «Иртәгә иртүк, торгач та, мин аңа шушы төндә уйлаганнарым, аның дөньяда барлыгын искә төшереп юаныч тапканым турында бәйнә-бәйнә хат язармын»,— дип уйлап куйды Сафия.

## 18

Хаким. Син ялгышасың, ахмак хатын. Ялгышасың! Хакимнәрнең байлыгы алтын-көмеш белән үлчәнми. Нәрсә ул алтын-көмеш?! Минем төп байлыгым — хакимлек! Ә син беләсеңме, нәрсә ул?

Кадимбикә. Күз алдыма китерәм.

Хаким. Юк, син аны булдыра алмыйсың. Кая инде! Гомерең буе иреңнең, шуңа өстәп, ил хакименең колы ич син. Хакимлек ул — кешеләрнең, халыкларның язмышын менә шушында — уч төбендә тоту. Власть ул — язмышлар белән идарә итү, алланың үзе белән тиңләшү. Тәкъдир дәфтәрендә гомерең, бәлки, озын дип язылгандыр, ләкин мин башыңны шушы минутта кистерә алам, хода кушкан белән дә исәпләшеп тормыйм. Шуны аңласаң, син ничек тә миңа ярарга, күңелемне күрергә тырышырсың, һәр теләгемне үтәргә ашыгырсың. Чөнки язмышың, яшәешең минем кулда. Кара син бу җиргә, бу илгә, әгәр телим икән, мин аны кара күмергә әйләндерә алам!

Кадимбикә. Көл итә алырсың, әмма гөл итә алырсыңмы? Илне гөл итү хаким кулыннан килә торган эшме?

Хаким. Монда хәзер мин ни телим, шул эшләнә. Телим икән, бар халыкны сугышка куам, кешеләр, минем биләмәләремне киңәйтү, меңнәрнең язмышын минем кулга китереп салу өчен, җаннарын кыячак. Менә нәрсә ул — власть. Син әле аның нинди ләззәт биргәнен, күңелне ничек очындырганын белмисең. Бичара, бер йолкыш әсирнең йөрәген хәзинәгә санап йөргән буласың... Әй, кем анда, керегез әле!

*(Газизҗан керә.)*

Хаким. Чакыр ялчыларны.

*(Ялчылар керә.)*

Хаким. Бу хатынны киендерегез.

Газизҗан. Ничек итеп, галиҗанап?

Хаким. Минем уң кулымда утырырлык итеп.

*(Кадимбикәгә асыл киемнәр кидерәләр.)*

Хаким. Утыртыгыз.

*(Тәхет янәшәсенә алтын урындык куеп, Кадимбикәне шуңа утырталар.)*

Хаким. Бу хатынга кадер-хөрмәт күрсәтегез.

*(Нигъмәтләр кертеп, алдына тезәләр.)*

Хаким. Аның күңелен ачыгыз.

*(Музыкантлар, җырчылар, биючеләр керә.)*

Хаким. Аның һәр теләге үтәлсен.

*(Ялчылар Кадимбикәнең аягына егыла.)*

Хаким. Әйт, Кадимбикә, ни телəгең бар?

Кадимбикә. Миңа... кылыч кирәк!

Хаким. Кылыч! Мә, ал минем кылычны.

*(Кадимбикә сикереп торып, кылычны кынысыннан суырып ала.)*

Хаким. Син сугыш коралын кулыңда нык тотасың икән.

Кадимбикә. Без яшьтән үк золымга каршы сугышырга әзерләнеп үстек.

Х а к и м. Ләкин житәрлек өйрәнмәгәнсез икән. Жиңелдегез.

К а д и м б и к ә. Көрәш әле дәвам итә.

Х а к и м. Мин сине башка нәрсә өчен сугышырга өйрәтә алам. Власть өчен. Ул чакта син, бәлки, тагын да батыррак булырсың. Властьның тәмен белгәч кешенең гайрәте, тәвәккәллеге нык арта. Әйт, тагын ни теләгең бар?

К а д и м б и к ә. Теләгем бар?

Х а к и м. Власть теләкләрне арттыра бара ул. Өсте-өстенә, өсте-өстенә... Нәрсә кирәк?

К а д и м б и к ә. Баш кирәк.

Х а к и м. Нинди баш?

К а д и м б и к ә. Хыянәтче башы.

Х а к и м. Нинди хыянәтче башы? Әйт, хәзер аны алтын тәлинкәгә салып китереп бирерләр. Синдә минем холык күренә!

К а д и м б и к ә. Миңа менә шушы хыянәтченең башы кирәк! *(Газизҗанга кылыч белән ишарәләп күрсәтә.)*

Г а з и з ж а н. Галиҗәнап!

Х а к и м. М-м, шушы башмыни?

К а д и м б и к ә. Әйе, мин хәзер шушы башны алдымдагы алтын тәлинкәдә күрергә телим. Шунда мин ышаначакмын властьның ләззәтенә, тәменә, җанны җилкендерерлек көченә!

Х а к и м. Властьның тәмен татып карыйсың киләме?

К а д и м б и к ә. Әйе.

Х а к и м. Чын хакимнәрчә бу теләгең.

Г а з и з ж а н. Галиҗәнап, ярлыка!

Х а к и м. Күрәсеңме, властьны? Ул аллага тигез, миңа табына, миңа сәҗдә кыла. Газизҗан, мин синең язмышыңны шушы хатын кулына тапшырам. Мәрхәмәтне син аннан сорап ал инде. Мин, хыянәтче башын бирәм дип, вәгъдә биреп ташладым бит, вәгъдәсен үтәми калу хакимгә килешми.

Г а з и з ж а н *(үрмәләп барып, Кадимбикәнең аягына егыла)*. Кадимбикә! Без бер халыкның балалары бит, Кадимбикә. Бер шәһәрдә, бергә уйнап үстек, Кадимбикә. Мәңгелек колың булырмын, Кадимбикә. Бөтен теләкләреңне үтәрмен, Кадимбикә!

Х а к и м. Татлымы власть, Кадимбикә?

К а д и м б и к ә. Татлы, галиҗәнап.

Х а к и м. Әле син, ул башны алтын тәлинкәдә күргәч, чын ләззәтне белерсең.

К а д и м б и к ә. Әйе, галиҗәнап, бу — чыннан да минем өчен иң зур ләззәт булачак.

Г а з и з ж а н. Кадимбикә, мин сине бөтен бәлаләрдән коткарырмын! Монда хәйләсез яшәп булмый, Кадимбикә! Мин бөтен хәйләләрне беләм, Кадимбикә!

К а д и м б и к ә. Миңа синең башың гына кирәк.

Г а з и з ж а н. Кадимбикә, мин сине беләм бит, син гадел хатын бит. Кешене үлемгә хөкем итү өчен, аны башта хөкем итәргә кирәк бит. Закон буенча хөкем итәргә тиеш бит, Кадимбикә! Хөкем итсеннәр мине башта! Гадел хөкем сорыйм! Закон буенча!

К а д и м б и к ә. Алаймы? Закон канаты астына посмакчы буласыңмы? Ләкин син иленнең барча законнарын таптадың. Алар сине якламый хәзер. Намус хөкеме белән мин сине үзем хөкем итәм һәм хәзер үк җәзасын да бирәм! *(Кылыч белән селтәнә.)*

Х а к и м *(аның кулын тота)*. Тукта! Сабыр. Син миннән бу башны аласың. Ал. Әмма мин бернәрсәне дә бушка бирмим. Бу баш өчен син миңа хак түләргә тиеш.

Г а з и з ж а н. Галиҗәнап!

Х а к и м. Дәшмә!

К а д и м б и к ә. Хак? Хаин башы өченме?

Х а к и м. Хаким кулындагы һәрнәрсә бик кыйммәт тора.

К а д и м б и к ә. Ни сорыйсың?

Х а к и м. Күңелеңне, Кадимбикә. Акылыңны, хисләреңне. Мин сиңа власть бирермен, бу башны кисәргә дә, әгәр телисең икән, бүтәннәрне дә. Тик моннан соң ярдәмчем булырга, мине кайгыртырга, мине уйлап яшәргә тиеш булырсың.

К а д и м б и к ә. Минем күңелем, хисләрем, җаным? Бер хаин башы бәрабәренәме? Ай-һай кыйммәт сорыйсың, галиҗәнап!

Х а к и м. Мин баш — бәһаләрне үзем куям!

Кадимбикә. Ул чакта, үз җанымны саткач, хаин башын кисәргә ни хакым кала соң? Хыянәтчегә хөкем чыгарырга ни хакым була?

Шәфика репетиция барышын бельэтаждан күзәтеп тора иде. Аның монда беренче килүе, Рәмзигә күренеп, борчып йөрергә моңарчы уңайсызланды. Шуңа күрә залга да сәхнә артыннан төшмәде, парадный яктан кереп, өскә менде. Баштарак ишек янында яшеренеп кенә карап торды, аннары, мавыгып китеп, эчкәрәк узды. Бу күренеш аңа хисси яктан ифрат киеренке булып тоела, әсәрнең үзәге дә шунда кебек. Мондый бәрелеш вакытында тамашачының йөрәге туктап торырга тиеш! Ләкин, Хаким-Җиһангирның гайрәтенә карамастан, репетиция сүлпән бара. Наргизә бала-чага уены уйный, шуның белән вакыйганың фаҗига утын сүрелдерә дә куя. Кая китә соң аның кайнап торган дәрте? Шуның боламыклыгы аркасында алгы планга Газизҗан-Зыятдин калкып чыга, куркак җанның әле Хаким, әле Кадимбикә аяк очына баш орып, идән буйлап үрмәләп йөрүе көлке иде. Ләкин бу күренештә халыкны көлдерү урынсыз. Нәрсә калыгып утыра соң әле анда, партерның беренче рәтендә Рәмзи? Ник туктатмый бу кәмитне? Ник сәхнәгә сикереп менми?

Әллә соң ул үзе игътибарны Зыятдингә юнәлтергә кирәк табамы? Ләкин бу бит әсәрнең төп фикеренә каршы килә!

Шәфика, дулкынланып, саклыгын онытып, бельэтажның барьеры кырыеннан уртагарак узды. Ул биредә ялгызы түгел икән лабаса, барьерга күкрәге белән ятып, тагын берәү сәхнәне күзәтә икән бит. Якын ук килгәч кенә, Шәфика аның Эльвира икәнен таныды. Кыз да сынын турайтып басты, гадәтенчә кискен итеп, гасабиланган хәрәкәт белән, маңгай чәчен уңга сыпырды, ләкин чәче аны тыңламады, тар маңгаен кире каплады. Алар сәлам бирешеп, ым кагышкандай иттеләр, аннары икесе дә сәхнә ягына борылдылар. Шәфика басып торды, Эльвира янә барьерга ятты. Ләкин янәшә булу икесенә дә комачаулый, дикъкатьне тарата иде. Шәфика никтер сер бирергә теләмәде, чыгып китә алмады, нәрсәдер аны шул кыз янында торырга мәҗбүр итте.

Бу хәлгә иң әүвәл Эльвираның сабырлыгы төкәнде. Ул тураеп басты, шартлатып, сумка бигеп ачты, аннан кечкенә ак тартма чыгарды. Аның сигарет кабы икәне Шәфиканың зиһененә бераздан гына барып җитте. Эльвира, кабаланып, тагын сумкасын актарды, ниһаять, тагын нидер табып алды — анысы зажигалка икән, челт иттереп кечкенә ялкын телен кабындырып сүндерде. Бу — Эльвираның остазы белән исәпләшмәве, үзен аңа каршы куюы, баш күтәрүе иде. Аңарчы да кызның тәмәке белән шаярганы сизелә иде, билгеле, тик Шәфика моны белмәмешкә салыша, теге үзе дә, инсаф саклап, бу ярамаган гадәтен остазыннан яшерә килде.

— Син нәрсә, Эльвира, биредә тартмакчымы әллә?

— Чыксам, компания составить итмәссездер бит.

Кыю сөйләшә кызыкай, хәтта әдәпсез.

— Ә нәрсәгә сиңа компания?

— Сөйләшәсе бар иде, Шәфика Сафиулловна.

«Шәфика Сафиулловна» дигәне дә мыскыллаган кебегрәк килеп чыкты моның. Ә сүзе теленнән ычкынырга тора иде бугай, чыгып сөйләшмәсәләр, шунда ук әйтелер иде, мөгаен. Шәфика сәхнә ягына, ниһаять, урыныннан кубып, кулларын болгап, Наргизә каршына менеп баскан Рәмзи тарафына карап куйды. Кызык, нинди киңәш бирер, сәхнәдәге хәрәкәтне кайсы тарафка борыр икән ул? Моны бик беләсе килә, ләкин Эльвира текәлеп карап торганда, ирен күзәтергә никтер кыенсынды Шәфика.

— Чыгып сөйләшик алайса,— диде ул, көрсенүен эченә яшереп.

Коридор салкынча, шыксыз, аргы баштагы лампочканың ачы яктылыгы эчне пошыра иде. Зажигалкадан сикереп чыккан нәни ялкын теле Эльвираның шәмәхәгә буялган озын тырнакларын, сөяк белән тире-

дән генә хасил нечкә кулын яктыртып алды. Менә ул, күкрәгеп тутырып, ирләрчә тавышланып төтен суырды. Аның бөтен кыяфәтеннән: «Ә мин синнән тамчы да курыкмыйм, күз алдыңда теләгәнемне эшлим, ни уйласам, шуны әйтә алам»,— дигәне күренеп тора иде. Шәфика аның каршында үзен кинәт кечерәеп киткәндәй хис итте. Менә Эльвира кечкенә сумкасының нечкә бавын иренчәк хәрәкәт белән ашыкмыйча гына уң иңбашына элде, уң кулының терсәге белән сул учына таянып, янып торган сигаретын бармаклары арасында бөтергәләде, аның кызыл утына текәлеп, уйларын тәртипкә салгандай итте. Бик мөһим сүз башламакчы иде ул, күрәсең, ләкин ни хакта икәнен Шәфика һич чамалый алмады. Дөресрәге, чамаларга курыкты. Менә, ниһаять, Эльвира тәвәккәлләде булса кирәк, күзләрен зур ачып, туп-туры остазының йөзенә текәлде. Моңарчы Шәфика аны үзеннән кечкенә дип йөри иде, хәзер генә икесенең дә буйга бер чама икәнен белде: кызның күзләренә туры карар өчен, аңа башын туры тотарга кирәк икән.

— Беләсезме, Шәфика Сафиулловна, мин Рәмзине яратам бит.

Бу сүзләр Шәфиканың йөзенә тәмәке сасысы белән бергә уралып килеп бәрелделәр.

— Әйе, мин Рәмзине я-ра-там.

Каян ишетелде бу сүзләр? Түшәмнән караңгылык булып ишелдеме, әллә аргы баштагы лампочканың аяусыз яктысы булып сибелдеме?

Шәфиканың күңеле бу сүзләрнең чын мәгънәсен, дәһшәтен кабул итәргә әзер түгел иде. Ул аларны җиңеләйтергә, күбәләк канаты куеп, очырып, таратып җибәрергә омтылыш ясады.

— Яраталар шул аны,— диде җиңелчә генә.— Талантлы бит ул, актер буларак та, режиссер буларак та. Тик бөтен көче белән ачылып кына житә алганы юк әле хәзергә.

Эльвира янә сигаретын суырды, муенын алга суза төшеп, гәүдәсе белән Шәфикага табарак авышты:

— Сез мине аңламадыгыз, Шәфика Сафиулловна. Әллә юри генә аңламамышка салышасызмы? Ул миңа актер яки режиссер буларак кына түгел, аннан да бигрәк ир кеше буларак ошый. Минем... Рәмзигә кияүгә чыгасым килә.

Шәфиканың кинәт теле шешеп, зураеп китте, авызына сыймас булды, бөтенләй әйләнми башлады. Ул аяк өсте саташа иде бугай. Яман төш күргәндә дә шулай була бит кайчак, әйтер сүзеңне әйтә алмый гаҗизләнәсең. Имеш, сәхнәгә чыгып басансың, ә ролең онытылган. Партнерларың да, тамашачылар да сиңа текәлгән, ә син ни дияргә белмисең, әйтим дисәң, телең кузгалмый. Ничә тапкыр Шәфиканың шулай саташып ятканнан соң манма тиргә батып уянып киткәне һәм, уянгач, ярый әле, төш кенә булган икән дип, шөкерана кылганы бар! Артист өчен шуннан да куркынычрак саташуның булуы мөмкин түгел.

Бу юлы да саташамдыр дигән уй килде аның башына. Я булмаса шаярадыр гына Эльвира. Менә-менә ул елмаеп җибәрер дә: «Ышандыгызмы инде, Шәфика Сафиулловна, миннән чын актриса чыгарына? — дип әйтер кебек иде.— Мин инде Рәмзинең үзенә болай уйнап күрсәтмәм, Сез аны минем талантыма үзегез ышандырыгыз».

Ышандырыр Шәфика, Рәмзине генә түгел, Әмирнең үзен Эльвираның талантына һәм аны театрда калдырырга кирәклегенә, бүген үк ышандырыр, тик менә бу кызый үзенең сүзләрен шаяруга, уенга гына чыгарсын. Хәзер, менә хәзер үк Шәфиканы бу саташудан гына коткарсын.

Ләкин Эльвира үзгәрми, елмаймый, шаярганын белдерми, күзләрен зур ачып, оятсыз караш белән Шәфикага текәлеп торуында иде. Шәфика, ниһаять, йон бияләй чәйнәгәндәй телен әйләндерә алды, аның авызыннан бер сүз чыкты:

— Ә мин?

Ул үз тавышын ишетмәде, әмма Эльвира аны аңлады:

— Сез! Сезнең турыда сөйләшеп тә булмый, Шәфика Сафиуллловна! Ни җитми Сезгә? Бөтен нәрсәгә ирештегез бит инде. Акча, исем, квартир, дан... Ни кирәк Сезгә тагын?

Роль бит бу, роль! Кайсыдыр бер спектакльдән бик таныш сүзләр бит болар. Тик менә хәзер кайсыннан икәнен искә төшереп кенә булмый, баш эшләми! Ә Эльвира туктамый сөйли:

— Сезгә ир кирәк түгел, ирек кирәк. Гаилә богавы Сезне чикли генә. Рәмзи кебекләрдән Сез бер башка өстен бит, ник кирәк ул Сезгә?

Бик таныш сүзләр бит болар? Кайдан таныш соң, кайдан?.. Шәфиканың зиһене кинәт яктырып киткәндәй булды: әйе, кат-кат күз алдыннан узган сүзләр болар, тик бернинди спектакльдән дә түгел, ә хатлардан. Соңгы вакытта әледән-әле килгәләп торган имзасыз хатлардагы сүзләр бит бу. Шәфика аларны почта тартмасыннан алып, ачып кына карый да, шундук чүп савытына ыргыта, ләкин күзгә барыбер, «ник кирәк Сезгә андый ир?» дигән сүзләр чалынып кала.

Шунда гына Шәфика Эльвираның уен-муен белән шөгыльләнмәгәнен, ниһаять, аңлады. Бу кыз һөҗүмне күптәннән алып бара, тик Шәфика гына моны аңламый, дөресрәге, аңламаска, күз йомып яшәргә тырышып йөри икән бит. Әллә соң теге хатларны Эльвира үзе үк язды микән?

— Ә соң... Рәмзи үзе ни әйтә?

— Сез беләсез бит инде, Шәфика Сафиулловна: ул Сезгә буйсынып яшәргә күнеккән. Курка ул Сездән. Ләкин курку ул әле ярату дигән сүз түгел!

Курку — ярату дигән сүз түгел! Курыккан кешене яратып булмый! Бу хакта Шәфика үзе дә кайчандыр бик күп уйланган иде бит. Хәбир белән яшәгәндә уйланды ул ярату һәм курку турында. Каян белгән моны бу кыз, кем сөйләгән? Ничек, ни рәвешле ул, Шәфиканың килбәтсез үрдәк бәбкәсенә санап йөргән шәкерте, остазының үткәннәренә, уй-хисләренә, хәтта киләчәгенә, бөтен язмышына хуҗа булырга үзен хокуклы дип саный ала? Һәм кайчан булган бу үзгәреш — аларның үз урыннарын алышып, Эльвираның тилгән булып баш очына күтәрелүе һәм Шәфиканың сары чебешкә әверелүе?

Шәфикага куркыныч булып китте. Ул бар көчен җыеп:

— Кит, күземнән югал,— дип кенә әйтә алды.

Эльвира иреннәрен кыйшайтып көлемсерәде, күзгә туры карап, сигаретын суырды. Аннары бик әкрен генә борылып, коридор буйлап китеп барды. Аның кара свитеры сыланып торган арык аркасыннан ук үз-үзеннән бик канәгать икәне күренеп тора: ул Шәфиканы каушатырга теләгән, аны куркытырга исәп тоткан һәм бу морадына ирешкән иде.

Ераклашкан саен, Шәфикага аның гәүдәсе зурайган кебек тоелды. Менә ул үзенең кара күләгәсе белән Шәфиканы бөтенләй каплады, менә лампа яктысын сүндерде. Һәм Шәфика дөм караңгылыкта калды бугай.

Берни уйламый, берни сизмичә, бөтенләй эреп киткәндәй юк булып, ул шулай күпме торгандыр, белмәде. Кемдер аны иңбашыннан тотып селкегәнгә айнып китте.

— Син нишләп монда качып торасың? — диде аңа Зыятдин.— Эзли-эзли җаннарым чыкты. Радиокомитеттан Батыркаев үзе кереп чакырды инде. Язылырга соңарабыз бит, көтеп торалар. Онытмыңмыни сәгать икегә анда керергә икәнен?

Әйе-әйе, анда керәсе иде бит әле. Теге көнне Хәбир аны Рәмзи аша шуңа эзләткән икән: радиода Даян Ризвановның иҗаты турында тапшыру әзерлиләр, шунда «Кадимбикә»дән зур гына бер өзек алып, инсценировка ясамакчы булганнар, һәм бу эшне башка театрның баш режиссеры Батыркаевтан эшләтергә карар кылынган, чөнки хәзерге көндә радио эшләре белән мәшгуль булырга Бикбауның мөмкинлеге дә, вакыты да юк иде. Кадимбикә ролен Хәбир Шәфикага бирде, спек-

такльнең театрда бара торган составыннан Зыятдинны гына чакырып, Хаким ролен үзенә алган иде.

Алай да Шәфика:

— Ник соң Наргизәне чакырмыйсың? — дип сорады.

Хәбир аңа гаҗәпләнеп карады:

— Син барында аны уйлап тормадым инде.

Актриса буларак, ул һаман да әле Шәфиканы бик югары куя һәм, дөресен генә әйткәндә, ярата да иде.

— Нык качкансың син монда,— диде Шәфикага Зыятдин.— Ике иреңнең берсе дә эзләп табарлык түгел. Ярый әле үзем бар, кешеләрнең югалган хатыннарын эзләп табып бирергә. Мин булмасам, ничек табышыр идегез икән? Әйдә-әйдә, аякларыңны цементлап ябыштырып куймаганнардыр бит монда.

Шәфика чыннан да табаннарын идәннән көчкә аера алды.

— Сиңа монда торасы түгел иде,— дип дәвам итте Зыятдин, коридор буйлап барганда.— Залга кереп карарга иде үзеңнең Рамзесыңның нишләгәнен.

Ул Рәмзине борынгы Мисыр фиргавене Рамзес белән чагыштырып үчекли, туры килгәндә аңа: «Ә-ә, Рәмзис Беренче, театр фиргавене, кайчан пирамида сала башлыйсың?» — дип уза торган иде.

— Эшләре болай барса, театрда Рамзесның династиясе озакламый киселәчәк,— диде ул Шәфикага.— Спектакльне ул бик шәпләп кенә провалга таба алып бара.

## 19

Х а к и м. Арзан дисең? Бу адәмнең башы синең йөрәгеңә тормый, димәк? Ә мин синең җаныңны бушка да ала алам. Газизҗан!

Г а з и з җ а н. Тыңлыйм, галиҗәнап!

Х а к и м. Син үз җаныңа ни хак сорыйсың?

Г а з и з җ а н. Минем җаным болай да синеке, галиҗәнап. Бөтенләе белән синеке. Аңа өстәп бөтен мал-мөлкәтем синеке. Ал гына, үзеңнеке генә ит мине. Бүтәннәр кулына гына бирмә!

Х а к и м *(Кадимбикәгә)*. Ишетәсеңме?

Г а з и з җ а н. Әгәр башымны кисәсең килсә, кис, галиҗәнап. Тик, зинһар, үз кулың белән кис, кылычны бу хатынга тоттырма.

Х а к и м. Кем кулыннан үтсәң дә, барыбер түгелмени?

Г а з и з җ а н. А юк, галиҗәнап. Бу хатын кулыннан һәлак булу — ир кеше өчен мәңгелек хурлык. Ә синең кулдан баш киселү — үзе бер дәрәҗә. Хакимнең үзе тарафыннан җәзаланган дип, тарихка язылып калыр.

Х а к и м *(Кадимбикәгә)*. Ә син минем белән янәшә утыруның кадерен белмисең.

*(Кадимбикә дәшми)*.

Х а к и м. Күрәм: син чыннан да миңа җаның-тәнең белән бирелгән кеше икәнсең, Газизҗан. Моның өчен ни бирим сиңа, әйт!

Г а з и з җ а н. Бу хатынны җәзала, галиҗәнап. Дошманың ул синең, һәлак итәргә җай эзләп йөри!

Х а к и м. Аның хакында, хаким кулыннан үтте дип, тарихка язылсынмы?

Г а з и з җ а н. Юк-юк, галиҗәнап! Аның өчен артык зур дәрәҗә булыр ул! Син аны ялчыларыңнан җәзалат!

Х а к и м *(кылычын аңа суза)*. Мин бу эшне сиңа кушам.

Г а з и з җ а н. Рәхмәт, галиҗәнап, рәхмәт! Мин синең ышанычыңны аклармын!

Х а к и м *(Кадимбикәгә)*. Менә күрдеңме инде властьның нәрсә икәнен?

К а д и м б и к ә. Юк, мин бөтенләй башка нәрсә күрдем.

Х а к и м. Нәрсә?

К а д и м б и к ә. Залим адәмгә власть бирергә ярамаганын! Әгәр ул властька ирешсә, аны юк итәргә кирәклеген!

Х а к и м. Газизҗан, кушканны үтә!

Г а з и з җ а н. Кадимбикә, бәлки, синең үләр алдыннан әйтер сүзең бардыр?

К а д и м б и к ә. Минем хыянәтче белән сөйләшә торган сүзем юк.

Х а к и м *(Газизҗанга ым кага)*. Әйдә.

*(Газизҗан кизәнә, Кадимбикә нидер пышылдый. Соңгы мизгелдә Хаким Газизҗанның кулын тотып ала.)*

Х а к и м. Кычкырыбрак әйт сүзеңне, Кадимбикә, ишетмим.

К а д и м б и к ә. Минем сүзем сиңа түгел.

Х а к и м. Син, җан бирер алдыннан, ходайга ялварасыңмы? Аңа сыгынасыңмы? Ходай тәгалә сиңа ярдәм итә алмый, ул ерак. Син миңа ялвар, миңа сәҗдә кыл. Мин! Фәкать мин генә ярдәм итә алам сиңа бу минутта!

К а д и м б и к ә. Минем сүзем сиңа да, ходайга да түгел. Минем соңгы сүзем бүтәнгә.

Х а к и м. Кемгә?

К а д и м б и к ә. Мин ирем белән хушлашам.

Х а к и м. Ирең белән?

К а д и м б и к ә. Әйе, мин аның белән бәхилләшәм.

Х а к и м. Ләкин ирең сине ишетми, бәхилләшүең аның колагына барып ирешмәячәк!

К а д и м б и к ә. Дөрес, синең зинданнарыңда диварлар калын, минем өнем үтеп керерлек түгел. Ләкин йөрәк хисләренә таш диварлар да киртә була алмый, аларны туктатып булмый!

Х а к и м. Күрәм: синең акылга утырасың юк. Газизҗан!

*(Газизҗан тагын кизәнә. Хаким аны тагын туктатып кала.)*

Х а к и м. Ярый, мин сине җәзалауны кичектереп торам. Тикшереп карыйк әле: ни рәвешле барып ирешә икән хисләрең иреңә! Тагын шунысын да белик: башыңны, хисләреңне күпмегә бәяли икән ул? *(Ялчыларга.)* Бу хатынны Хаким нәселе кебек киендерегез!

*(Кадимбикәгә таҗ кидерәләр, өстенә кыйммәтлә чапан ябындыралар, урындыкның биегрәген кертеп, югарырак утырталар.)*

Х а к и м. Ирен китерегез монда!

Шәфикага Хәбир белән уйнау элеккечә үк җиңел иде. Бер уйласаң, сәер аларның үзара мөнәсәбәте: уйнаганда, алар бер-берсен якын итеп дәртләндерә, илһамландыра беләләр. Шәхси мөнәсәбәтләре ничек кенә үзгәрмәсен, иҗатта бу рухи якынлык гомер буена сакланды. Дөрес, аерылышкач, аларга берничә ел партнерлар буларак очрашырга туры килмәгән иде, ә менә хәзер бик дустанә көрештеләр, әйтерсең, арада бернинди салкынлык та булмаган.

Радиокомитетның тавыш үткәрми торган калын ишекләре артына, микрофоннар каршына янәшә утыргач, Шәфика үзендә гаҗәеп бер тынычлану, шул ук вакытта дәртле күтәренкелек тойды. Яшәсен эш, яшәсен иҗат! Күңел яраларына алардан да шифалырак тагын нинди дәва бар? Кысан гына бүлмәне алар зур бер дөнья итеп киңәйттеләр, үзләре дә Хакимдәй, аның белән тиң сөйләшерлек Кадимбикәдәй күтәрелеп, зур рухлы кешеләр булып киттеләр. Каршыдагы киң пыяла тәрәзә аша күрше бүлмәдәге приборлар, пульт янында басып торган яшь режиссер егет белән кырыс чырайлы оператор күренә, кайчак алар, бүлмәнең саңгырау тынлыгын бозып, динамик аша артык нык кычкырып дәшеп куялар, ләкин бу сирәк, берәр хата киткәндә, язылуны өзеп торганда гына эшләнә, Шәфика, Хәбир, Зыятдин исә мавыгып уйныйлар, шуңа күрә ялгышмыйлар да иде.

Язылу тәмамланып, тәрәзә өстендәге «Микрофон эшли» дигән язу сүнү белән, Зыятдин ашыгып чыгып китте. «Мин бүген обед та ашамаган әле, монда Хәбир безне кайгырта белмәс»,— диде ул. Ә Шәфика ничектер тиз генә китә алмады. Кадимбикәнең дөньясы нинди генә шомлы булмасын, аннан аерыласы килми, чөнки аның үз дөньясы аннан шөбһәлерәк иде. Ул, нидер көткәндәй, сораулы караш белән Хәбиргә текәлде. Әле моңарчы ул элекке иренә игътибар белән карамаган, фәкать куе, көчле, интонацияләргә бай һәм хакимнәргә хас ышанычлы тавышын гына тыңлаган икән. Хәзер менә, бөтенләй чит кешене күзәткәндәй, баштанаяк карап чыкты. Элеккечә үк ыспай гәүдәле Хәбир, сыны төз, хәрәкәтләре төгәл, ипле. Коңгырт-яшел костюмы да, офицер кителе төсле, гәүдәсенә сыланып тора. Ә менә йөз... Йөзенә еллар үз

тамгаларын салып узганнар. Ул тагын да бераз озынчаланып, ничектер кибебрәк киткән шикелле, тиресе юкарган, яңак уртасыннан, ирен читләреннән сызыклар сузылган. Күз төпләре каралыбрак тора, маңгай чәче сирәгәйгән, юкарган.

Ул да, ничектер кызык кына елмаеп, Шәфикага текәлгән иде. Алар, язылу бүлмәсеннән чыгып, шулай бер-берсенә карашып, алгы, кечкенә бүлмәдә басып тордылар. Аннары караңгы коридордагы йомшак диванга утырдылар.

— Син бүген в ударе,— диде Хәбир.— Мин әле бу хәтле булырсың дип көтмәгән идем.

— Нинди булырмын дип көтмәдең?

— Кадимбикәне бу дәрәҗәдә көчле бирә алырсың димәгән идем. Әзерләнергә вакыт булмады бит.

— Мине театрда бик әйбәтләп әзерләп җибәрделәр бүген,— диде көлеп Шәфика. Аның көлүе ачы иде.— Кадимбикәнең орлыгын салдылар миңа бүген.

— Рәмзиме? — Хәбирнең тавышында шикләнү ишетелде.

— Юк, ул түгел. Минем башка шәкертләрем дә үсеп җитте бит инде. Остазларын өйрәтә башладылар.

— Каты өйрәтәләрме?

— Җанны алгандай итәләр.— Шәфика тагын көлде.

— Шулай укмыни? — дип, бик җитди итеп сорады Хәбир. Ул инде Шәфиканың болай гына көләргә тырышканын, асылда исә эчендә бик зур борчуы барын, шул борчуын кем белән булса да уртаклашасы килгәнен сизеп алган иде.

— Бүген берсе килеп, миннән Рәмзине сорады,— диде тагын мәзәк сөйләгәндәй кыланырга тырышып Шәфика. Ләкин аның тавышы моның шаяру түгеллеген, эшнең бик җитди икәнлеген белдереп, сызлану аша чыкты.

— Нәрсә дип сорый? — диде Хәбир, аңа таба гәүдәсе белән борылып, сагаеп.

— Яшь актрисалар яшь режиссерны нәрсәгә сорый соң инде? Үзенә ир итәргә.

Шәфика чын-чынлап көлмәкче булды, ләкин аның хихылдавы ясалма килеп чыкты.

— Шулай укмыни! — диде Хәбир уйланып. Ул Шәфикадан читкә, коридорның каршы стенасына карап, бераз уйланып торды.— Рәмзиең миннән уздырган икән. Мине синнән килеп сораучы булмаган иде бит әле. Ничек соң? Бирергә булдыңмы иреңне кешегә?

— Нишләп алай дип уйлыйсың?

— Күңелең яхшы бит синең, кеше сораса, соңгы әйбереңне бирергә риза. Ир кадерен дә белеп бетерми идең.

— Син мине гомергә аңламадың, Хәбир! — Монысын инде үзеннән өзеп әйтте Шәфика.

— Юк, чыннан да, нәрсә дидең соң ул шәкертеңә?

— Күземә күренмә дип куып җибәрдем.

— Анысын дөрес иткәнсең.

— Рәмзигә сөйлим әле, бер кызык булыр.— Шәфика тагын бу вакыйганы шаяруга әйләндермәкче булып карады. Ләкин Хәбир җитди калды:

— Шундый сүзне иргә сөйлиләрмени? Рәмзине үзәксез, сыек адәм дигәч тә, ул үзен чын ир дип уйлыйдыр бит! Ике хатынның аны бер кулдан икенчесенә тапшыру хакында әйткәләшүләрен ишетү чын ир кешегә бик күңелле дип беләсеңме әллә? Чын ир кеше кем белән яшәргә кирәген хатыннардан сорап тормый, үзе хәл итә! Да, мөшкел икән алайса шәкертеңнең хәлләре!

— Аның хәле мөшкелме? — Шәфика аңламый торды. Ул, киресенчә, үзен бик мөшкел хәлдә дип исәпли иде.

— Аныкы булмый, кемнеке булсын. Ул инде Рәмзине үз ягына аударырга күп тырышкандыр. Эше барып чыкмаган, димәк. Рәмзи белән борчагы пешсә, синең янга килеп, ялынып йөрмәс иде! Бөтереп алып кына китәр иде Рәмзиеңне! Сизми дә калыр идең!

Шәфика бу яктан уйлап карамаган икән әле. Моны ишеткәч, аның эченә җылы керде, моңарчы ясалма елмаюдан тартышып торган бите, тынычланып, үз хәленә кайтты. Хәбир аның йөзендәге үзгәрешләрне текәлеп күзәтеп утыра, ләкин Шәфика моны сизми иде.

— Ә шулай да гамьсез үк йөрмә,— диде Хәбир, аны кызганып.— Андый кызлар синең өше риясыз җаннарны кәкре каенга терәтү җаен барыбер таба. Кешегә бирәсең килмәсә, нык тот Рәмзиеңне.

— Ничек итеп? Мин аңа ябышып йөри алмыйм ич инде?

— Хатын-кызның ирләрне үзенә бәйләргә мең хәйләсе бар.

— Мин андыйга оста түгел шул, үзең беләсең,— диде Шәфика, зарлангандай итеп.

— Беләм... белмәгән кая! Режиссер буларак мондый әсәрне сәхнәгә куярга туры килсә, мин бу рольне башкаручы актрисага бер киңәш бирер идем бирүен...

— Нинди киңәш? — диде Шәфика өмет белән.

Хәбир яңакларына тирән сырлар салып, аңа бик сынап карады.

— Андый очракта бала табарга кирәк хатыннарга.

Шәфика, кызлар кебек оялып, башын читкә борды. Бераз зиһенен җыеп, дәшми торды.

— Үзең белән яшәгәндә, бер дә алай дими идең,— диде, ниһаять.

— Син Кадимбикәнең бар сүзен дә хәтерлисеңме?

— Нинди сүзен?

— Нәрсә ди әле ул Хакимгә? Чын егет булып үсәрлек уллар саф мәхәббәттән, бер-береңне тугры яратудан гына ярала ди. Дөресен генә әйткәндә, син мине яратмый идең бит, Шәфика. Хәтерлисеңме, Колонналы залга минсез генә концертка барганыңны?

Хәтерләмиме соң! Шуннан соң беренче тапкыр күз төпләрен күгәртеп дәрескә барган иде бит инде Шәфика.

— Ул кичне янында утырган егеткә ничек елмайганыңны хәтерлисеңме? — дип дәвам итте Хәбир.— Синең беркайчан да миңа алай елмайганың булмады.

— Кит инде, булмаганны, ничә ел торып...— димәкче булган иде Шәфика, Хәбир аны тыңламады.

— Син миңа этиенә елмайгандай гына елмая идең. Чынлап яратуыңны көтеп йөрдем мин, шуннан соң балабыз булыр дип уйладым. Ә син бар күңел җылыңны менә шул боламык Рәмзигә бирдең.

Шәфика кулы белән аңа ишарә ясады, сүзенә каршы төшмәкче булды. Хәбир аңа авыз ачарга ирек бирмәде:

— Хәер, син — беренче түгел, хатын-кыз мескенрәк ирләрне ярата инде ул, чөнки аның яратуы кызганудан башлана. Башта кызгана, аннары гашыйк була. Әгәр кызганасың икән, җибәрмә Рәмзиеңне, бала белән бәйлә дә куй. Дәртең көчле, күңелем сизә, ана була аласың әле син.

Шәфика башын иде. Хәбир ул белмәгәнне аңлый, аннары тормыш тәҗрибәсе дә чагыштыргысыз иде: аның инде ике баласы бар, бу хатыны белән савыт-сабалары шалтыраганы сизелгәне юк. Кем белә, ул бу киңәшләрне, бәлки, үз тормышыннан чыгып бирәдер?

Һәрхәлдә Шәфиканың аңа каршы куярлык нигезле фикере юк иде.

## 20

Спектакльне тапшыру көне җитеп килә, ә Наргизәнең тамагы рәтләнеп беткәне юк иде әле.

Сафия дустына шифалы чәй эчертеп, бәрәңге пары сулатып, аркасын «бом-бенге» белән ышкып, сихәтләндерергә тырышты.

Хәер, чәй әзерләү, бәрәңге пешерү, арка ышку ишесе читен түгел, анысын искә алмасаң да ярый. Иң кыены — Илнурны яслегә йөртү иде. Баланы сигезгә хәтле илтеп житкерергә кирәк, ә соң ятарга күнеккән артистның үзе өчен караңгыдан кузгалу бер газап булса, артист баласының тәмле йокысын бүлеп, уятып алып чыгып китү — мең жәза икән.

Шулай икәүләшеп жәзалана торгач, Сафия белән Илнур тәмам дуслашып беттеләр. Кич кайтканда көлешә-көлешә кайталар. «На-на!» — дип, чыбык селки чанада утырган Илнур. «Һи-а!» — дип титаклап чаба Сафия. Шулай чабып капкадан килеп керә, ишек төбендә Илнурны, күтәреп, кочагына ала, аның шома яңагына иреннәрен терәп, хуш исен исни. Бер кулда — бала, икенчесендә чана. «Һи-а!» — дип, баскычтан икенче катка йөгереп менә Сафия. Аның колак төбендә, күгәрчен булып, Илнур гөрелди. Менә алар ишекне киң итеп ачып жибәрәләр:

— Без кайттык!

Шулай дуылдап, бер кичне үз бүлмәсенә кайтып кергәч, Сафия кыенсынып китте: өйдә кешеләр бар икән, ул кызулык белән күрми дә тора. Өстәл янында ике ир кеше утыра. Берсе — Револ, икенчесе — ак йөзле, уртасы уемлы, чыгынкырак иякле, киң маңгайлы, утызлар тирәсендәге ир кеше. Ул башын борып Сафиягә карагач, гажәпләнгәндәй булды, урыныннан күтәрелә төшеп, башын иеп сәлам бирде. Аннары карашын каршында эленеп торган портретка төбәде. Тагын Сафиягә таба борылды. Ул Сафияне портреты белән чагыштыра, бу чагыштыру аны ни сәбәптәндер гажәпләндерә иде.

— Исәнмесез!

Илнур борсалана иде, Сафия тиз генә аның тунын салдырды да, почмаккарак алып барып, чүлмәккә утыртты. Ишек янындарак кулына сары күлмәген тотып торган, үзе халат кигән Наргизә:

— Ярый, кайтып життең әле,— диде.— Бу иптәшләр акт төзергә килгәннәр менә.

— Нәрсәгә?

— Бүлмәне тикшерәләр,— диде Наргизә.

— Ник тикшерәләр аны? — Сафия берни аңламый иде.— Булдымы, Илнур?

— Кайсыгызның баласы соң бу? — диде Револ, малайның жирән чәченә карап.— Кыяфәте Наргизәнеке, караучысы Сафия.

— Сиңа барыбер түгелмени? — диде Сафия.

— Интернатка урнаштырырга кирәк аны. Котылыбрак торырсыз.

— Үзем дә күптән шуны уйлап йөрим дә, жаен гына белмим,— диде Наргизә.

— Әллә кайчан миңа әйтәсегез калган. Иртәгә үк өч айлык санаторийга илтеп тыгабыз аны.

Сафиянең баядан бирле берәр төртмәле сүз әйтәсе килә иде, тыела алмады, тупас итеп сорап куйды:

— Син нәрсә, кеше язмышы белән уйнарга килдеңме әллә монда?

— Кайсы кеше? Нинди язмыш?

— Ә баланы ят кулларга илтеп тапшыру аның язмышы белән уйнау түгелмени? Ай-яй жиңел сөйлисең! Алар, бичаракайлар, караңгы төшә башлауга, ишектән күзләрен алмыйлар, әниләрен көтәләр. Бүтәннәрдән соңга калдырсам да, йөрәгем әрни минем. Шуңа менә биш тулганчы ашыгып кайтабыз да. Шулай бит, Илнур? Аны ятимнәр янына илтеп тыгарга, ике хатын-кызга бер сабый безгә артыкмы әллә? Әйдәле, Илнур, чәй куеп эчик әле!

— Без дә монда тикмәгә генә килмәдек, сезне кайгыртып йөрибез,— диде Револ коры гына.— Бу иптәш менә РСУдан, төзүче-инженер Әхмәтнуров Нигъмәтжан. Бинага нинди ремонт кирәклеген ачыклый

Сафия анда-санда штукатуркасы кубып төшкән, каралган почмакларга, ишек кырыеннан ертылып киткән, төссезләнгән, керләнгән обойларга карады.

— Без җимергән бина түгел,— диде йомшара төшеп.— Безгә хәтле үк шушындый иде.

Болай булгач, кунакларга ачык йөз күрсәтергә кирәк иде. Наргизә күршегә, Исмегөлләр бүлмәсенә күлмәген алыштырырга кереп китте, театрга китәргә кирәк иде аңа. Акт мәсьәләсен хәл кылу тагын Сафиягә йөкләнде. Ул, егетләрнең күңелен күрергә кирәклеген исәпкә алып, чәй әзерләде.

Кайнар чәй Әхмәтнуровның да телен ачты.

— Да-а, артистларны да гел генә кадердә яшәтмиләр икән,— диде ул, түшәм асларын күздән кичереп. Аның тавышы күңелгә ятышлы икән.

— Ә кем кадерләсен аларны? — диде Револ.— Ник кадерләсен? Алар бит хәзерге заман эшчеләре кебек кадерле халык түгел, монда кил дә монда кил дип, һәр тарафтан чакырып торучы юк. Аларны моннан себерке белән куып та чыгарып җибәрә алмыйсың. Абзарда яшәсәләр дә риза, тик сәхнәгә генә чыксыннар. Беләсең килсә, монда әллә ничә буын артистларның шушы рәвешле гомере узган инде. Ә шулай да чәйне тәмле пешерәсең икән, Сафия. Киләсе юлы бәлеш тә өлгертсәң, тагын да шәбрәк булыр иде.

Ул үзен бик тыйнак, бик инсафлы тота, әйтерсең лә, Сафия белән ике арада бернинди ямьсезләнешү дә булмаган, әйтерсең лә, алар гомер буе яхшы таныш булып кына яшәгәннәр. Аның шушы рәвешле тыйнак сөйләшүен күргәч, Сафия дә төкселәнеп азаплануның килешмәячәген аңлады.

— Ярдәмегез тисә, бәлештән эш тормас,— диде.

— Авыл чәе тәме килә,— диде Әхмәтнуров.— Мөмкин булса, тагын берне генә ясагызчы. Шикәр кирәкми, чәйнең тәмен боза.

— Монда эшне озакка сузмаска иде инде, иптәш Әхмәтнуров,— диде Револ.— Үзең күрәсең, бу почмакларга карап, артист кешенең ничек күңеле үссен дә, ничек итеп ул гүзәл образлар тудыра алсын? Тәзүчеләр, матур спектакльләр карарга теләсә, артистларны да матур йортларда яшәтсеннәр.

— Бу арада безнең эш бик тыгыз әле, андый зур мәшәкать кузгалмый торса да ярар иде, — диде Сафия.

— Ни булган ул хәтле?

— Иртәгә «Кадимбикә»нең просмотры була.

— Харап икән, сездә ул атна саен була, ә төзәтү ун елга бер ясала, ачуым килмәгәе.

— Наргизә төп рольдә.

— Сезнең роль уйнамаган көнегез юк, ә Әхмәтнуров кебек дәрәҗәле иптәшне гомергә бер генә эләктереп була.

Бу сүзләрне тыңлаганда, Әхмәтнуров ничектер йомшак кына көлемсерәп куйды. Ә Револ астыртын мәгънә белән Сафиягә бик төбәп карап алды.

— Ягез алайса, акт кәгазегез әзер булса, кул куям да, мине гафу итегез, — диде Сафия. — Илнур белән безнең дә театрга керәсебез бар.

— Кеше баласын сөйрәп йөргәнче, үзеңнекен булдырыр идең, — диде Револ уйчан гына.

— Сез минем гаилә хәлемә акт төзергә килмәгәнсездер бит?

Сафия, Әхмәтнуров сузган кәгазьне рәтләп укып та тормыйча кул куйды да, ашыкканын сиздереп, кием шкафын ачты. Алай да, тегеләр чыгып киткәч, нәрсәгәдер сагаеп, уйланып калды. Тукта әле, төзү оешмасына Револның ни катышы бар соң? Нәрсә дип әле, шул хәтле тырышып, Сафияләрне кайгыртып йөри башлаган? Теге адәм дә сәер күренде. Сафия аның документын да сорамады, Наргизә дә сорамаган-

дыр, мөгаен. Кызык ясап, Сафиядән көләргә җай эзләп кенә йөрүе түгел микән бу Револның? Ә бәлки, алар менә хәзер рәхәтләнеп хахылдашалардыр? Җитмәсә, теге кәгазьгә ниләр язылганын да рәтләп укымады бит Сафия...

Ул, борчылып, тәрәзә янына килде, пәрдәне кайтарып, урам якка карады.

Нәкъ шул минутта Әхмәтнуров та, борылып, башын күтәрде һәм Сафия карап торган тәрәзәгә текәлде. Алдарак барган Револ да башын борды. Күрше ишегалдындагы якты лампаны инде кабызганнар, егетләр ак кар өстендә аермачык күренә, аларның йөзендә чагылган шаян елмаю да бик ачык шәйләнә иде, Револ иптәшенә нидер әйтеп, башын селкеп куйды. Сафия, үзеннән-үзе кызарынып, артка чигенде: кеше әллә ни уйлар тагын!

## 21

Хаким *(Кадимбикәгә)*. Шушымы? Шушы бичара адәм — синең иреңме?

Нариман. Мин — бичара түгел. Мине, җәзалап, шушы кыяфәткә керттеләр.

Хаким *(Газизҗанга)*. Сөйләш!

Газизҗан. Бичара буласың килми, димәк. Зинданда тоткынлыкта ятасың килми, шулай бит? *(Нариман дәшми.)* Галиҗәнап рәхимле. Ул сиңа бик зур мәрхәмәт кыла, сине азат итәргә боера. Кием-салым, азык-төлек бирерләр.

Нариман *(Хакимгә карап)*. Шуның өчен мин нишләргә тиеш инде?

Хаким *(Кадимбикәгә)*. Башы эшли, малның һәм властьның кыйммәтен аңлый!

Газизҗан *(Нариманга)*. Бу игелеге өчен галиҗәнап хак сорамый. Аңа синнән берни кирәкми.

Нариман *(Хакимгә)*. Бурычлы итеп куймакчы буласыңмы?

Газизҗан. Галиҗәнапның шарты бик кечкенә — оныту. Син онытырга гына тиеш. Үзеңнең кемлегеңне, кемгә нинди вәгъдәләр, антлар биргәнеңне — барысын да оныт. Яңадан туган кебек яши башла. Хәзер менә, бу хатын минеке түгел дип әйтсәң дә шушы минуттан ирекле буласың.

Нариман. Бер әсирне иреккә чыгару өчен шундый хак сорыйсыңмы, Хаким? Кыйммәт, ай-һай кыйммәт куясың бәяне!

Газизҗан. Син бу хатынны үзеңнең ирегеңнән дә кыйммәтрәк бәялисеңмени?

Нариман. Мин үз хокукымны югары бәялим.

Газизҗан. Сиңа хокуклар бирелер. Яшь хатын алырсың. Галиҗәнап хөкемендә кызлар җитәрлек, сайлап алырга мөмкинлек алырсың.

Нариман. Аз, бик аз!

Газизҗан. Игелекнең кадерен бел! Күрмисеңмени, син кайда да бу хатын кайда? Ул барыбер синеке түгел!

Нариман. Бу зиннәтле киемнәр аңа юкка гына кидерелмәде, бу урынга ул бушка гына утыртылмады димәкче инде син, Хаким?

Хаким *(Газизҗанга.)* Сора: бу адәмнең йөрәге ни тоя икән?

Газизҗан. Әйт: йөрәгең ни тоя?

Нариман. Мин йөрәгемне дошманга ачмыйм.

Кадимбикә. Нариман...

Хаким. Дәшмә!

Газизҗан *(Нариманга)*. Күзең күрәдер бит?

Нариман. Әйе, күзләрем куркыныч нәрсә күрә. Моны күрү — дошманның зинданында ятудан да аянычрак, чөнки дошманнан яхшылык көтеп булмый, ә синең өчен янган-көйгән бердәүнең дөньяда яшәвен белеп тору тоткынга да көч, өмет бирә. Кадимбикә! Синең хыянәтең минем өчен дошман һөҗүменнән мең тапкыр яманрак! Дошманның явызлыгын беләсең, аңа күңел әзер тора! Ә син, син!..

Кадимбикә. Нариман! Мин...

Хаким. Дәшмә! *(Көлеп.)* Ә син, ахмак хатын, йөрәк сизә, дисең!

Газизҗан *(Нариманга.)* Шулай булгач, бу хатын сиңа ник кирәк? Галиҗәнап болай да сиңа хакны артык күп түли түгелме? Синең бер сүзең

өчен: бу хатын минеке түгел, мин аннан баш тартам, дигән сүзең өчен, ирек, ризык, кием, яшь хатын...

Х а к и м *(Газизҗанга ым кага.)*

Г а з и з ж а н. Әйе, өстәп, җир кишәрлеге дә бирерләр. Үткәннәреңне генә оныт. Тормышны яңабаштан башла. Сине кыйнаучы булмас, үз көнеңне үзең күрерсең. Уйлап кара: кара зинданнан соң — якты көн, кыйналулардан соң — тыныч тормыш. Күз алдыңа китер. Иң мөһиме — бернинди үкенеч, кайгы-хәсрәт юк, чөнки бөтенесе онытылган, хәтердән чыгарып ташланган! Үткәннәрне уйлау — җан газабы гына ул. Син барча ваемнардан азат булырсың. Шул бер сүзеңне генә әйт.

Н а р и м а н. Ярый, әйтәм.

Г а з и з ж а н. Күптән шулай кирәк иде. Юк нәрсә өчен бәхәсләшеп маташасың.

Н а р и м а н. Әйтәм!

Х а к и м *(Газизҗанга)*. Ирек кәгазен әзерләсеннәр!

Г а з и з ж а н. Әйт сүзеңне!

Н а р и м а н. Сүзем шул: минем дошманга бирер бер нәрсәм дә юк. Мин хәтта үземә хыянәт иткән бәндәләрне дә үз хөкемемдә калдырам, дошманга бирмим. Мин аларны үзем хөкем итәчәкмен, үз законнарым белән! Бу — минем хатыным! Һәм минеке булып кала!

Сәхнәдә «Кадимбикә»не кабул итү өчен күрсәтәләр иде. Иң авыры менә шушы инде — спектакльне беренче тапкыр күрсәтү. Бу көнне залда халык аз була. Әмма болар — гади тамашачы түгел, ә бәлки сәхнә законнарын тирәннән аңлаган, һәрхәлдә, үзләрен шундый дип санаучы кешеләр: культура өлкәсенең җитәкчеләре, тәнкыйтьчеләр, журналистлар, язучылар. Алар тып-тын утыралар, ни уйлаганнарын белеп булырлык түгел, тик шулай да сагаю, кимчелекләрне тотып алырга тырышу сизелә һәм бу артистларны каушата иде. Соңрак, спектакль план буенча бер-бер артлы уйнала башлагач, сине сәхнәдә танып, хуплап, аз гына табышыңа да куанып, хаталарыңны күрмичәрәк уздырып җибәрә торган гади тамашачы каршына чыгу бөтенләй икенче бит ул: сулышлар иркенәя, дәрт өстәлә, илһам килә.

Ләкин ул көннәргә юл менә шушы сират күпере аша — сәнгать советы каршында уйнап үтә шул.

Сафия спектакльне яттан белә, шунлыктан аның күңел күзе сәхнәдән бигрәк залга, анда берән-сәрән сибелеп утырган кешеләрнең тамашаны ничегрәк кабул итүенә юнәлтелгән иде. Спектакль нинди генә булса да, беренче егерме-утыз минуты бара әле, аны халык сагаеп һәм, ни булыр икән дип кызыксынып карый. Шул арада мавыктырып алып китмәсәң, залның дикъкате тарала башлый. Андый хәл бик аяныч, таралып киткән спектакльне янә бер йодрыкка төйнәү ифрат кыен. Бу юлы шулай булды да. Әйе, тамашаның кызып-кызып киткән минутлары, залдагыларның тураеп утырган, елмаеп куйган чаклары булгалады, тик болар томанлы төндә җемелдәп узган очкын кебек чагылып кына узды. Спектакль кешеләрне үз артыннан иярте алып бара алмый, аксак ат кебек адым саен сөртенә, тукталып кала иде. Миләрне әкренләп томан чорнап алгандай итте, инде анда-санда чагылып узган очкыннарны да зиһен тотып алмый башлады.

Алтынчы рәтнең уртасында утырган Рәмзи Бикбауның водолазкасы әйтерсең лә хәсрәттән агарган иде. Менә, арттан кузгалып, Шәфика Абилова алга таба узды, Рәмзи янына утырып, иңе белән аңа табарак авышты, гүяки аңа көч бирергә теләде. Кырыйдан сулкылдаган тавыш ишетелде: анда театр училищесы студенткасы Эльвира Балтачева урындык аркасына капланып елый иде. Ник елый икән ул? Әллә аның — залдагы бердәнбер кешенең — спектакль белән мавыгып китүе, андагы фаҗигале вакыйгалардан тетрәнүеме бу?

Рәмзидән берничә утыргыч аша баш режиссер Әнвәрбәков утырган. Аның өчен спектакльдәге һәрнәрсә яңалык — ул әле кичә генә күрше республиканың башкаласыннан кайтып төште. Һәм бу яңалык

бик үк куанычлы түгел иде ахры. Кыяфәте бик җитди баш режиссерның сыны, кылдай тартылып, хәрәкәтсез калган, йомры башын алгарак иеп, керфек тә какмый, сәхнәне күзәтә. Аның янәшәсендә утырган Даянның йөзендә елмаю, тик бу елмаюда газап һәм ярсу ачысы ярылып ята.

Газапларның да бер чиге була — спектакльнең ахыры, ниһаять, житте, залда ут кабынып, сәхнә шыксызрак, күңелсезрәк булып күренде, андагы чатырның аннан-моннан корыштырылганлыгы, агачларның катыргыдан укмаштырылганлыгы ныграк күзгә ташланды. Барысы да урыныннан кузгалып, тизрәк сәхнәгә аркалары белән борылды.

Залдан чыгып барганда, Сафия белән Әнвәрбәков янәшә туры килделәр.

— Я, ничек соң? — дип сорады Әнвәрбәков.

— Минә худсоветта әйтерләр инде, — дип, шома гына җавап бирде Сафия. Ләкин Әнвәрбәковтан алай ансат кына котылып буламы соң?

— Мин синнән худсовет фикерен сорамыйм, үзеңнең тәэсиреңне әйт, — диде Әмир һәм маңгай астыннан таләпчән кисәтү белән карады.

— Пьеса миңа бик ошый, — диде Сафия. — Ләкин...

— Я, я! Нәрсә «ләкин»?

Сафия тотлыгып калды. Дусларының хезмәте турында яхшы сүз генә әйтәсе килә, ләкин ул ялганлый да алмый иде.

— Табышлар күп, — диде ул. — Шуларны үстереп, бер ритмга салып эшләсәң...

— Бөтен хикмәт ритмда инде алайса? — диде арттан көлемсерәгән тавыш. Сафия борылып карамады, күрмәсә дә таныды: аларның сөйләшкәнен Зыятдин тыңлап килә иде. Сафия, башын күтәреп, Әмирнең күзләренә туп-туры карады да:

— Бу әсәрне мин сәхнәгә бөтенләй башкача куяр идем, — диде. — Әйе, бөтенләй башкача!

## 22

Әнвәрбәков бүлмәсендә аяк тавышлары ишетелми — идәнгә тоташ кызыл чуар келәм җәелгән. Кергән кешеләр сүзсез генә стена буена тезелгән урындыкларга утырыштылар, бу тынлык нервыларны тагын да киеренкеләндерә иде. Бүлмәгә әйтерсең лә электр көчәнеше таралган. Уен түгел, тулы бер коллективның айлар буе башкарган эшенә хөкем чыгарырга җыелдылар һәм куанычлы карар чыгару мөмкинлеге дә күренми иде бит! Бер-берсенә текәлеп карау уңайсыз, башка нәрсәләр турында сөйләшү урынсыз иде, шуңа күрә кайсы — түр стенаны биләп торган кара шкафларга, андагы китапларга һәм театрга бүләк ителгән сагынмалыкларга, кайсы ишек кырыена эленгән Хуҗа Насретдин сурәтенә карап утырдылар. Хуҗага рәхәт, ул бу җиһанның һәртөрле көйсезлекләрен авыз ерып кына үткәрә. Әнә бит хәзер дә, ишәгенең койрыгына карап атланган да көлә рәхәтләнеп!

Бүлмәдәге тынлык барысын да баскан иде кебек. Зур өстәл артында тәрәзәгә аркасы белән утырган Әнвәрбәков та сүзне әкрен тавыш белән башлап җибәрде, совет члennарыннан фикерләрен әйтүен үтенде. Берәм-берәм урыннарыннан кузгалып, мөмкин кадәр йомшаграк итеп, тискәре фикер ташын мамыкка урабрак сөйләргә тырыштылар.

Драматург Даян Ризванов карап-карап, көлемсерәп, башын чайкап утырды да, йөрәк ярсуына түзә алмыйча, үзенә сүз бирелгәнне дә көтеп тормастан, сикереп торып, аягүрә басты. Аның көчле тавышы сувенирлар тулы шкафларга, стеналарга бәргәләнеп, биек бүлмәне тарсынып яңгырады:

— Булмаган бу, иптәшләр, турысын әйтеп сөйләшергә кирәк, барып чыкмаган! Минем бу әсәремне тарихка кереп калырлык итеп

куярлык булсаң гына тотынырга кирәк иде! — Ул почмактагы урындыкта тураеп, тәрәзәдән каядыр еракка карап утырган Рәмзигә таба кизәнгәндәй, кулын селтәде. — Спектакльне бу дәрәҗәдә эшләү режиссерга да, театрга да оят булырга тиеш!

Әмир, аны тәртипкә чакырырга теләгәндәй, күпереп торган чәчләрен җилпеп, башы белән ишарә ясады, ләкин драматург моны күрмәде.

— Әсәрне яшь режиссерга, яшь башкаручыларга биреп, баштук та театр дөрес эшләмәде, — дип тыела алмый дәвам итте Даян. — Мондый әсәрне сәхнәгә кую — спортта рекорд кую белән бер ул, беләсегез килсә. Тренировкасыз гына уңышка ирешеп булмый, әзерлексез спортчыдан дөнья рекордын куюын таләп итеп көчәндерә башласаң, аның буыны сына. Рәмзине дә, Наргизәне дә гаепләргә җыенмыйм. Минемчә, аларга артык авыр йөк салынган. Театрның төп көчләрен җикмичә генә, бала-чага уены корырга исәпләгәнегезне алдан ук әйтергә кирәк иде, иптәш Әнвәрбәков! Мин бу пьесамны алып китеп, архивыма гына салып куйган булыр идем. Сезнең дә намусыгыз чиста булып калыр иде!

Ул урынына утыргач, бүлмәдә урнашкан киеренке тынлык колакларны чыңлатып торды. Менә бу тынлыкта салмак, әкрен хәрәкәт белән Бикбау торып басты, водолазка итәген тарткалап куйды һәм, Ризвановтан аермалы буларак, бик әкрен тавыш белән, үзалдына гына сөйләнгәндәй итеп, тәрәзәдән күзен алмыйча, әйтерсең лә, бирерәгеләргә түгел, ә бәлки шул тәрәзә артында күренми генә тыңлап торучы билгесез кешегә мөрәҗәгать иткәндәй:

— Мин күреп торам: монда мине аңламаячаклар, — диде. Ул шушы тынычлыгы белән генә дә күпмедер дәрәҗәдә үзенең хаклы булуын һәм, барыннан да бигрәк, Ризвановтагы дуамаллыктан, сүзне уйламый сөйләүдән өстен икәнлеген расларга тели иде. Ул ургыган хисләрен яшерә белде, тавышы калтырамады, йөзе бозылмады. — Монда искечә эшләргә, искечә фикерләргә күнеккән кешеләр утыра. Минем бөтен ялгышым, хатам өлкәннәргә иярергә тырышуда, алар артыннан баруда да инде, беләсегез килсә! — аның бу сүзләреннән һәммәсе калкынып куйдылар. — Ясалма тавыш белән сөйләү манерасы, артык күтәренкелек, һәр сүзгә басым ясау... Мин бүген бер нәрсәне аңладым: элеккечә эшләргә ярамый. Бөтенләй башкача, өр-яңача фикерләргә кирәк. Яшьләрчә. Заманча.

— Соң, алай бик акыллы булгач, эшләргә дә кирәк иде, нәрсә монда безгә акыл сатасың, — диде Даян гадәтенчә ачы көлемсерәп. Бикбау аның тарафына күз дә салмастан:

— Мин үз юлымны табып җиткермәгәнмен әле. Юлны табу ансат та түгел ул, — диде.

— Син юлыңны башка пьеса белән эзләрсең инде алайса, яме! — диде аңа Даян. — Безгә шул иске стиль белән бик әйбәтләп куйсалар да ярап торыр. Без күнеккән!

Әмир, бармаклары белән өстәлгә шакылдатып, аны тәртипкә чакырды.

Бикбауның бу чыгышы барысының да канын кыздырып, телен ачып җибәрде. Уен-муен түгел, ничә еллар буе спектакльләре гөрләп барган, ил-халык каршында макталып килгән театрның эшенә тел тидерде, барысын да искелектә, артта калуда гаепләде бит. Әле үзенең рәтле эш күрсәткәне юк!

Чыгышлар бик хисле булды, тавышлар көрәеп китте, күзләрдә очкыннар уйнады. Төп фикернең буталчыклыгы, образларның эшләнеше, мизансценалар, декорация, яктырту турында сөйләнде, һәркайсыннан гаеп табылды.

Бикбау карашын тәрәзәгә текәгән килеш тып-тын утырып тыңлады. Әйтерсең лә, монда сөйләнгән кайнар нотыкларның аңа берниндә катнашы юк иде. «Ахмаклар, — дип уйлады Рәмзи, — ничек вакланалар

бит! Мизансцена, яктырту! Аның ишесен төзәтү берни түгел. Хикмәт андамыни!»

Хикмәтнең нәрсәдә икәнен яшь режиссер үзе дә аңлап җиткерми — иң аяныч мена шунда иде.

Сәнгать советының фикере бердәм булды: спектакль уңышсыз чыккан, аны бу хәлендә тамашачыга тәкъдим итеп булмый. Шулай итеп, коллективның берничә айлык хезмәте юкка чыгарылды.

Спектакльне яңабаштан куярга туры киләчәк иде.



## 23

Өйгә кайтып керәсе килми, Наргизәнең күзләренә карау читен булачак иде. Ишек ачылуга, улын күрсә, күңеле бераз йомшар дип өметләнеп, Сафия Илнурны бакчадан иртәрәк алырга булды.

Ул шулай Наргизәнең ачуыннан бала аркасына ышыкланмакчы булып кайтып килгәндә, тышкы ишектә, чиләк, пумала тоткан бер ир кеше белән бәрелешә язды. Ир кеше аның каршына туктады да, ачулы кыяфәт белән:

— Исәнмесез! — диде ничектер басым ясап.

Артистларга кайчак бөтенләй чит-ят кешеләр дә сәлам биреп уза, шунлыктан Сафия аңа җентекләп карамады, гадәтенчә ягымлы итеп «Исәнмесез» дип кенә узып китмәкче иде, ләкин теге юл бирмәде, бусагага аркылы басып торуында булды.

— Мин сезнең өчен тырышып йөрим тагын, ә монда рәтләп каршы алучы да юк, — диде ул ачулы тавыш белән.

Шунда гына Сафия аңа, күтәрелеп, дикъкать белән карады. Аның каршында кичә Револ белән килгән Әхмәтнуров дигән кеше басып тора иде. Акбурга, буяуга тапланган комбинезон аның кыяфәтен бөтенләй үзгәртеп җибәргән, танырлык та түгел.

— Ә, Сезмени әле бу, гафу итегез, — диде Сафия.

— Эшләргә булгач, эшләргә кирәк, эшлисегез килмәсә, кичә үк баш тартасыгыз бар иде, — диде Әхмәтнуров уемлы ияген чөеп. Сафия чын-чынлап кыенсынып китте: иптәш аларга яхшылык теләп йөри, ә аңа ачык чырай күрсәтү дә юк.

— Сез, зинһар, авырга алмагыз инде, — диде ул. — Болай ук тиз тотынырсыз дип уйламадык бит без. Аның әле кәгазьләре йөрисе булыр, югары оешмаларның карарын көтәсе булыр, дип уйлаган идек.

— Кәгазь йөргәнен, карар чыкканын көтегез инде алайсе, — диде Әхмәтнуров горур гына һәм Сафия яныннан үтеп китмәкче булды. Шунда гына кыз бик зур нәрсәне ычкындырганын аңлап алды: кәгазь йөрүдән булмә рәтләнми, авыз ачып торганыңа мең үкенерсең, соң булыр! Аннары тагын шунысы: бу Әхмәтнуровның җилкәсе шактый калын күренә, Наргизә каршына кергәндә, аңа ышыклану ышанычлырак булачак иде.

Сафия, Илнурны җиргә бастырып, ике кулы белән Әхмәтнуровка ябышты:

— Зинһар китмәгез! Зинһар үпкәләмәгез! Мин авыр сүз әйтмәдем бит! Өйгә кереп сөйләшик инде зинһар!

Шактый ялындырды Әхмәтнуров. Сафиягә иң матур елмаю белән елмаерга, күзләрен мөлдерәтеп карарга, иң татлы сүзләр эзләргә туры килде:

— Инде менә шушы сабый белән икәүләшеп күзегезгә зар-интизар булып карап торганда, күңелегез бер дә йомшармас микәнни? Бәгырегез таш түгелдер бит? Хәтерегезне калдырган булсам, турысын әйтегез, тик китмәгез генә!

Әхмәтнуров бер Сафиягә, бер аптырап тасраеп торган Илнурга карады да:

— Ярар, — диде теләр-теләмәс кенә. — Сындырдыгыз тәки.
Ләкин ишектән беренче булып керергә риза булмады. Кулындагы Илнур да Сафияне дускаеның һөҗүменнән саклап кала алмады. Идән уртасына баскан Наргизә аны күзләреннән яшел ут ачып каршылады:
— Мин сине просмотр бетүгә йөгереп чыгарсың дип көткән идем!
— Илнурны иртәрәк алдым әле. Спектакльгә әзерләнебрәк кирәкгә...
— Юхаланма! — диде Наргизә, якын ук килеп. Буйга шактый калкурак булганга, өстәвенә чәчен дә тузгытканга, ул шомлы булып күренде. Сафия хәтта арткарак тайпылды. — Башымны ашарлар дигән шик бар иде күңелемдә, тик син мине сатарсың дигән уй килмәгән иде!
Сафия, аның авыр сүзләреннән сакланырга теләгәндәй, ике кулын йөзе турына күтәрде.
— Наргизә! Синең өчен миннән дә ныграк хәсрәтләнгән кеше юк бит, дускаем!
— Беләбез! Белә-әбез! Бөтен сүз синнән башланган. Син кем ул хәтле, худсовет членымы әллә? Әнвәрбәковка ялагайланып, минем юлга аркылы басасың! Җитмәсә, бала артына ышыкланмакчы!
Артта, «эһ-эһ» дип, Әхмәтнуров тамак кырып куйды. Ачыргаланып, бала елап җибәрде. Ләкин Наргизә аларны ишетер хәлдә түгел иде. Ул сары көлмәктән, сары хәсрәт булып, әрле-бирле йөренә, баш өстендә ялкын телләредәй чәче җилпенә иде.
— Төшләремә кергән иде шушылай буласыларым, — дип өзгәләнде ул. — Бәләкәй чакта ук төшемдә күргән идем. Арбада барам, барам, барам... Янымнан ике яклап һау-һаулап эт өере чаба. Бөтенесе бозау хәтле, усал, куркыныч... Тәрлесен уйладым, тик, җан дускаем шул өергә кушылыр дип кенә юрый белмәдем...
— Наргизә, тынычлан, Наргизә...
— Тынычланыргамы? Миңамы? Шушы хурлыктан соңмы? Хәсрәтенә түзәр идем. Мин көчле кеше, күп нәрсәгә чыдый алам. Хыянәткә түзми күңел. Дусның астан чагуына җан сыкрый! Мә, ал, үзеңә булсын! Син күптәннән шуңа кызыгып йөрисең бит инде!
Ул сумкасын актарып, кәгазь төргәк тартып чыгарды да Сафияга таба ыргытты. Ике дәфтәр итеп тегелгән кәгазь битләре, җилпенеп, шапылдап, идәнгә килеп төштеләр. Сафия иелеп алды — болар «Кадимбикә»нең бер нөсхәсе һәм роль тексты иде.
Әхмәтнуров тагын тамак кырды:
— Сезнең монда бер әзерлегегез дә юк бугай әле...
Сафия аны тагын җиңеннән тотып алды, тагын елмайды. Әхмәтнуровның күзләренә туп-туры карап, бер гөнаһсыз сабыйларча ачык итеп, эчкерсез итеп елмаерга тырышты.
— Сабыр булыгыз, — диде. — Роль уйныйбыз бит без. Бик җаваплы роль. Бик катлаулы. Ышандыра бит, әйеме, ышандыра бит?!
Әхмәтнуров, шикләнеп, ярсыган Наргизәгә текәлеп карап торды.
— Ышандыра, ышандырмаган кая, — дип куйды сузып кына.
— Сез безгә игътибар итмәгез. Сез үз эшегезне башлагыз!
Сафия Илнурны күтәреп алып, күз яшьләрен сөртте.
— Хәзер, Илнурым, күз нурым...
Әхмәтнуров биек баскычын алып килгән икән, коридордан шуны алып керде дә бик тәвәккәл кыяфәт белән ишек янына сөяп куйды һәм аңа менеп, шыкы-шыкы штукатурка коя башлады.
— Каягыз, бергәләшеп кәмит уйныйк алайса.
— Таптыгыз вакытын, — диде Наргизә бер мәлгә айныгандай булып. — Әйе, дустының шушындый минутында ремонт кайгысы кешеләрдә. Кая, китер әле баланы! Нечего аның белән спекулировать итәргә!
Ул Илнурны, акыртып, Сафия кулыннан йолкып алды да ишектән чыгып китте.

— Чукынып китегез! Ник шунда бөтен йортын ишеп төшермисез!

— Ни булган аңа? Бая да мине пәри кебек котырып каршы алды? — дип сорады өстән Әхмәтнуров.

— Бик зур күңелсезлек килде әле. Сез гаеп итмәгез инде. Кайгысыннан башын җуйган ул, — диде Сафия.

— Ни булган ул хәтле? — дип борчылып сорады Әхмәтнуров.

— Бүген безнең яңа спектакльне комиссия кабул итмәде. Наргизә анда төп рольне уйный иде.

— Роль өчен шушы хәтле бетеренергә... Берәр туганы үлгәнме әллә дип торам...

— Артист өчен бик авыр хәл инде бу. Сез аны гаепләмәгез. Үз-үзен белештерми генә сөйләве. Күңеле начар түгел аның. Менә күрерсез: сәгать тә үтмәс, кире кайтып та төшәр.

Сафия, шулай сөйләнә-сөйләнә, әйбер-караны җыярга, җыеп бетереп булмаганы өстенә иске клеенка, кәгазь-гәзит ябарга кереште. Ремонтның нәкъ шундый чакка туры килүе аның өчен яхшы булды әле. Нишләр иде ул шушы минутларда? Ике дус, үпкәләшеп, болганышып ятырлар иде. Ә монда олы мәшәкать купты, теләсәңтеләмәсәң дә, бу егетнең кул арасына керергә, ярдәмләшергә кирәк иде.

Ул бик саклык белән, кадерләп кенә стенадан портретны алды, чиста тастымалга урап, чемоданга салып куйды. Иелгән хәлендә, дөньясын онытып, уйланып торды. Баскыч өстендәге Әхмәтнуров, текәлеп, аны күзәтә иде — Сафия моны сизмәде.

## 24

Утырыш тәмамлануга, иң беренче булып ишек янындагы урындыктан Рәмзи кузгалып чыгып китте. Секретарь бүлмәсендә Шәфика көтеп утырган икән, ирен күрүгә, сикереп торды, кулларын сузып, каршысына килеп басты, текәлеп, күзләренә карады. Йөзендә, карашында йөрәк әрнү һәм кызгану — әйе-әйе, Рәмзине кызгану галәмәтләре.

— Я, ничек, нәрсә хәл иттегез?

Рәмзинең саруы кайный башлады. Сорап торган була бит! Ә үзе ничек буласын алдан ук сизде! Бөтенесен аңлый, ахмак түгел! Спектакль барышында ук, бөтен зал аша килеп, гәүдәсе белән иренә терәк салгандай елышып утырганыннан ук аермачык билгеле иде инде аңлаганы. Ул чакта ук Рәмзинең башына: «Спектакль уйный тагын бусы да, начар уйный!» — дигән уй килгән иде һәм читкәрәк күчеп утырырга теләге бик көчле иде, тик кешедән генә яхшысынмады, шул кыенсынуы аркасында газап өстенә газап алды — Шәфиканың партнерына әйләнеп, үзе дә кәмит уйнап утырды дияргә була. Хәзер менә хатыны шул кәмитнең дәвамын уйнатмакчы. Тамашачылары да әзер — әнә арттан бер-бер артлы чыгып киләләр. Иренә теләктәш, изге хатын ролен уйный Абилова, сүзләре дә күп спектакльләрдә колакка чалынган репликага охшаш: «Я ничек?» — имеш...

Рәмзи ике куллап хатынының иңнәреннән тотты да, сак кына, әмма көч белән читкәрәк этте:

— Кайткач сөйләшербез. Син кайта тор, минем эшем бар әле. Кичке ашка мине көтмәгез.

Шулай диде дә, уңга-сулга карамый, вестибюль аша үз бүлмәсенә кереп, ишеген эчтән бикләп тә куйды. Бераздан бик әкрен, кыюсыз гына ишек шакыганнары ишетелде: «Шәфика!» — дип уйлады Рәмзи. Ачу белән, мыегын тешләштерде, урыныннан купмады.

Әйе, шулай итеп, барысы да хәл кылынды, димәк!

Башкалар бер кызып сөйләштеләр дә өйләренә таралыштылар. Җитәкчеләрнең, тәнкыйтьчеләрнең эше шуның белән тәмам. Алары тиз

арада үз мәшәкатьләренә чумар, бу хәлләрне онытыр. Спектакльдә катнашкан артистларга килгәндә, аларга бераз авыррак, билгеле, ләкин барыбер баш китәрлек вакыйга түгел. Аларның бер ише кайткач хатынына эчен бушатып җиңеллек табар, икенчеләре — хатын-кыз җенесеннән булганнары, мендәргә капланып елап булса да юаныр. Алай гына тынычлана алмаганы, эченнән генә режиссерны тиргәп, ачуын басарга тырышыр. Дөрес, бераз вакыт барыбер аларның эчен тырнап торыр әле бу уңышсызлык, ләкин, гомер узу белән, аны башка куанычлар һәм көенечләр күмеп китәр, тормыш үзенекен итәр.

Тик Рәмзи күңелендә генә төзәлмас яра һәм бик ачы сабак булып калыр ул. Чөнки бу — аның өчен уңышсызлык кына түгел, ә бәлки бөтен киләчәкне билгели торган бер борылыш та иде.

Рәмзи үзен, аяк астындагы сукмагы кинәт өзелеп, упкын каршында басып калгандай хис итә иде. Алга барыр юл юк, як-якка киткән сукмакларның да очы күренми, каядыр кыялар артына кереп югала.

Нишләргә? Кая барырга? Үз-үзеңне кая куярга?

Күңелне кимсенү һәм үз акылыңа, сәләтеңә ышаныч какшау изә: ул айлар буе уйлап йөреп тә башы җитмәгән нәрсәләрне бүтәннәр бер күз салуда күреп алды бит... Димәк, ул режиссер буларак бернигә дә ярамый дигән сүз.

Телефон шалтырады. Рәмзи күнегелгән хәрәкәт белән аңа сузылган иде, аңына килеп, кулын ярты юлда туктатты. Тагын Шәфикадыр. Юк, кирәкми! Рәмзи аның нindирәк тавыш белән ниләр әйтәсен болай да бик яхшы белә. Бүген күпкә чыдады, инде хәзер дә хатынын тыңларга түземе җитмәячәк иде Рәмзинең.

Иҗади дуслык, бердәм гаилә диләр алар хакында. Әгәр чыннан да шулай булса икән! Ул чакта Рәмзи, ике дә уйлап тормыйча, Кадимбикә ролен Шәфикага биргән булыр иде. Күпне күргән-кичергән хатын, сәхнә тәҗрибәсе бик бай, халыкның мәхәббәтен казанган актриса. Ләкин... артык нәфис, артык хатын-кыз... Нечкә тавыш белән ясалмарак,назлы сөйләшү манерасы да, соңгы вакытта тулышып киткән гәүдәсе дә, аяк атлаулары белән үк ирексездән ирләрнең дикъкатен җәлеп итүе дә килешми, бу очракта ярамый. Кая! Рәмзи алдан ук белеп торды: бу спектакльне кую мәсьәләсендә алар беркайчан да уртак бер карашка килә алмаячаклар. Шуңа күрә бит инде Бикбау, алдап-йолдап, хәйләләп булса да, хатынын башта ук бу эштән читләштерергә тырышты, төп рольгә Наргизәне алды.

Бусы да буш түгел — ачы-төчене татыган хатын. Башыннан шактый күп нәрсә узган: мәхәббәт, бала табу, яраткан кешесеннән күңел бизү... Аңлый белгән кешегә анысы да — зур сабак. Һәм сәләтле иҗат кешесенә — сәнгатьтә тирәнлеккә ирешү мөмкинлеге. Ә Наргизәдә сәләт тә, аңа өстәп теләк тә, хис тә бар. Ни җитми тагын?

Ныклы җирлек — пьесада исбатланган хакыйкатькә ышану җитми. Иман җитми! Бу җитмәүчелекне Наргизә тышкы шапырыну, ясалма хисләнү белән алыштырырга тырыша.

Тик шунысы бар: гадәти көнкүрештә кеше эчендәген яшерә ала, эчтән калтыраса да, тыштан ялтырауны булдыра. Әмма сәнгатьтә иҗат кешесенең бөтен күңел почмаклары ахырынача ачыла, анда бернәрсәне дә яшерү мөмкин түгел. Тыштан караганда ялкын бөркеп торган Наргизә дә ачылды әнә. Ачылды һәм күңеленнән суык җил бәреп чыккандай итте. Салкын күңел белән иҗат итеп булмый, Наргизә дә, элек алган сабакларны искә төшереп, сәхнәдә нәкъ Абиловача йөри һәм сөйләшә башлады.

Әйе, яшь режиссерга электән килгән кысадан чыгарга ирек бирмәделәр, Наргизә кебекләр аның аягына тышау булып уралды. Нинди аяныч хәл!

Рәмзи, урыныннан кубып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөрергә кереште. Ахырда, урындыкка тезен бәреп, авыртудан айнып китте: кич җит-

кән, караңгы төшкән, ә ул ут кабызырга да оныткан икән. Озакламый кичке спектакльгә халык җыела башлаячак, ә аның кеше чырае күрәсе килми иде. Өйгә дә аяк тартмый тартуын, ләкин монда да калып булмый — ул, кая барасын белмичә, ишеген бикләп, урамга чыкты.

Бакча турыннан узып бара иде, кемдер каты итеп аның кулыннан тотып алды:

— Стоп, машина! Юкса хәзер авариягә юлыгасың!

Һәм, кар өстенә сибелгән сөмбел кебек, тирә-юньгә әкрен, назлы көлү авазы сибелде. Бу шулхәтле көтелмәгәнчә килеп чыкты, Рәмзи беразга айный алмыйчарак торды. Бүгенге көнне, бу кичтә шушылай йомшак, иркә итеп көлүчеләр дә бар микәнни әле?

Аның каршында, күзләрен зур ачып, Эльвира басып тора иде. Көлә үзе, ләкин баганадан төшкән лампа яктысында аның күз төпләрендә яшь тамчылары елтырый иде шикелле. Бәхет балы белән бергә әрнү ачысы да бар иде бу көлүдә. Менә ул аяк очларына күтәрелде, менә Рәмзинең мыегына үрелде, иреннәрен аның бит очына терәде. Иреннәре кайнар, ә Рәмзинең кулына тотынган бармаклары боздай салкын иде кызның. Рәмзи аны аркасыннан кочып алды һәм кызның бөтен гәүдәсе белән үзенә таба авышканын, сыенганын тоеп алды. Ул шундый якынайды ки, Рәмзинең туны белән Эльвираның пальтосы аша йөрәге дөпелдәп бәргәндәй итте.

— Бүлмәдә ут та яндырмыйча шундый озак ялгызың бикләнеп утырдың! — дип, тавышсыз, сулыш ялкыны белән генә пышылдап әйтте кыз.— Автоматтан шалтыратып та караган идем, трубканы алмадың. Сөйләшәсең килмәдеме?

— Син дип белмәдем шул...

— Йөрәгең минеке кебек кабынмаган шул әле! Әгәр яна башласа, мин шалтыратканны шундук сизәр иде.

— Янмаган кая! Көл булам инде...

Рәмзи, авыраеп киткән башын иеп, яңагын Эльвираның йомшак бүрек түбәсенә терәде, бүген беренче тапкыр булса да бераз җиңеллек тойды.

Алар җитәкләшеп, әкрен атлап, урам буйлап киттеләр һәм үзләре дә сизмәстән, театр училищесының ике катлы бинасы каршына килеп чыктылар. Кайбер тәрәзәләрдә ут яна, анда дәресләр бара иде әле. Рәмзи кызның нечкә бармакларын кысып тотты да ишеккә таба әйдәде, Эльвира кыюсыз гына, ләкин карышмыйча, аңа иярде.

Иң беренче класс бүлмәсенең ачкычы ишектә иде. Ачып керделәр. Утны кабызмадылар. Тәрәзә рамы урамнан төшкән яктылыкны бүлеп, Эльвираның уң яңагына, күзенә кара күләгәсен салган, аны сәер дә, серле дә итеп күрсәтә иде.

— Әкият сөйлимме? — дип сорады Эльвира, каршысындагы урындыкта утырган Рәмзигә таба гәүдәсе белән авыша төшеп.

— Дөресен генә әйткәндә, бу арада әкиятләрдән гарык булынган иде инде, — диде Рәмзи көлемсерәп.

— Ә мин сиңа андыйны түгел, чын әкият сөйлим. Тыңла!

Эльвира кузгалып, аның янәшәсенә утырды һәм култык астына сыенып, шыпырт кына сөйли башлады:

— Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник булган заманда, җиде диңгез артында дөньяга килгән ди бер малай. Ел үсәсен ай үскән, егет булып җиткән ди бу. Егет булып җиткәчтен, бәхетен эзләп киткән ди. Бара икән, бара икән, бер кош килеп кунган моның каршына. «Егеткәй, егеткәй, кая бер ялгызың барасың болай?» — дип сорый икән бу. «Бәхет эзләп барышым», — ди икән моңа егет. «Минем дә бәхетем әллә кайларда адашып йөри, ал мине үзең белән», — ди икән моңа кош.

Эльвира тынып калды.

— Я, шуннан, иярткәнме соң егет кошны үзенә?

— Ә син нәртер иденме?
— Белмим шул, кошы ниндидер бит!
— Кошы тыштан караганда матур да, көчле дә булып күренмәгән, — диде Эльвира, эчтән көрсенеп. — Шулай да егет йомшак күңелле икән, аны куып җибәрмәгән, оч алайса янәшә дигән. Киткәннәр болар, егет юл буйлап атлый, кош читтәнрәк бер очып, бер кунып бара икән. Берзаман ни күзләре белән күрсеннәр: юл кинәт өзелгән, каршыларында упкын пәйда булган ди боларның.
«Каян белгән бу минем уйларны?» — дип, үзалдына гаҗәпләнеп уйлап куйды Рәмзи.
— Кош өчен упкын нәрсә, очып кына кичә ул аны. Ә егеткә нишләргә? «Тотын минем канатыма!» — ди икән аңа кош. Егет икеләнеп калган, көче җитмәс, егылырмын дип курка икән ди.
— Куркырсың да! — дип куйды Рәмзи.
— Син шулай куркакмыни?
— Миндәй егетне күтәрерлек кош кайда соң ул?
— Ә, бәлки, ул кош тыштан караганда гына кечкенә, көчсез күренәдер? Ә бәлки, аның йөрәгендә синең хакка таулар күчерерлек гайрәт бардыр? Сине упкын кичертерлек кенә түгел, җир читенә алып китәрлек көче бардыр аның? Ә икенче ярга аяк бассаң, элекке яшәеш, элекке танышлар бар да артта калгач, яңа кешеләр арасында яңа театрда... Талантлы режиссерга нинди мөмкинлекләр ачылмас!
Эльвираның кайнар тәне Рәмзинең култык астында кош баласы кебек тыпырчынды. Егетнең күңеленә чыннан да канат үскәндәй булды. Ә нигә, дөрес түгелме әллә? Бер талпынып очарга да барысыннан берьюлы котылырга, яңа урында гел үзеңчә яши һәм эшли башларга!..
Рәмзи кызны күкрәгенә кысты:
— Ә мин болай да аргы ярда инде. Синең канатыңа тотынып очып киткәнемне сизми дә калдым ахрысы...
Эльвираның сулышы татлы һәм баш әйләндергеч хуш исле иде, ул Рәмзине хыялый томанга урап алды, әйтерсең лә бөтен дөньядан аерды...
Кинәт коридорда аяк тавышлары ишетелде, кемнәрдер бикле ишекне тарткалый башлады. Алар икесе дә сулыш алырга куркып, тынып калдылар.
— Шушы бүлмәдә, рояль өстенә куйган идем, онытып калдырганмын, — диде тыштан бер кыз. — Әле генә ачык иде бит, кем бикләде икән соң?
— Иртәгә алырсың, торыр әле шунда, — диде икенче тавыш. Монысы егет кеше иде.
— Иртәгәгә хәтле аны ятлап та киләсе бар бит әле, — диде беренчесе.
— Әллә каерып ачыйкмы соң? — Ишек шактый ук каты зырылдый башлады. — Һи, моның йозагы көчкә эләгеп тора, хәзер ачабыз аны!
Рәмзи кинәт айнып китте. Әгәр шунда бәреп керсәләр һәм аларның кыяфәтен күрсәләр...
— Туктале, ватмый тор, — диде тыштан кыз тавышы. — Сорап килик әле, ачкычын табып булмасмы.
Тагын бераз сөйләшеп тордылар да китеп бардылар, коридорда адымнар әкренләп ерагайды. Рәмзинең күңелендә ипле гаилә тормышы белән яши торган кешеләргә хас чисталык, талым, таләпчәнлек хисе кузгалды.
Аның иңнәре тураеп, куллары йомшаганын сизгәч, Эльвира моны башкага юрады: Рәмзи тегеләрнең кире борылып килүеннән шүрли дип уйлады. Рәмзи дә кызның ни уйлаганын сәләтле режиссер сизгерлеге белән тоеп алды, үзалдына елмайды — кош кебек кайнар һәм юка тәнле бу кыз да аны аңламый иде.
— Ә мин бүген еладым, син күрдеңме? — дип сорады Эльвира.
— Кайчан, ник еладың?

— Залда, просмотр вакытында...

— Кеше алдында түгелгән күз яшьләре ышандырмый мине, —диде Рәмзи, аның тавышы ничектер суынып киткәндәй булды. — Сәхнә уены кебек тоела. Әйдә, тегеләр әйләнеп килгәнче, китик моннан.

Эльвира тирән итеп көрсенде, ләкин каршы сүз әйтмәде, урындыктан пальтосын алды.

Аны фатирынача озатып куйгач, Рәмзи, кире әйләнеп, училищега килде. Рояль өстендә кәгазь-фәлән юк, күрәсең, алып чыгып киткәннәр иде инде. Рәмзи урындыкларны тезде дә, тунын җәеп, сузылып ятты. Гадәттән тыш арган-талчыккан һәр кеше кебек ук, тирән дә, тынгысыз да йокыга китәр алдыннан, аның томанланган зиһенендә әле Шәфиканың кайгыртучан йөзе, әле Эльвираның күз төбендә яктырган яшь тамчылары чагылып узды. Берсе — һаман хәтерне яңарта, бәхетсезлеккә искә төшерә, икенчесе, киресенчә, барысын да оныттыра.

Ләкин берсе дә Рәмзигә чын мәгънәсендә юлдаш түгел шул. Әгәр аны чынлап та аңлый белгән, аңа ныклы терәк булырлык кеше табылса икән. Ул чакта мондый хәлләрне кичерү күпмегә җиңелрәк булыр иде бит!

## 25

Бикбау спектакльне яңадан кую эшенә җиң сызганып керешергә бер дә ашкынып тормый иде әле. Аның беренче уе — артистларга, баш режиссерга, гомумән, театрга кул селтәп, башын алып кая да булса олагу, шул рәвешле үзен тәнкыйтьләгән барлык кешеләрдән, язмышның үзеннән үч алу иде. Дөрес, бу фикер иң беренче булып Эльвира авызыннан чыкты чыгуын, ләкин ул бик тиз Рәмзинең күңелендә дә тернәкләнә башлаган иде.

Училище урындыкларында төн үткәргәннән соң, ул өенә бик батыраеп кайтып керде. Шәфиканың сабыр канатлары кыскалыгын, ярсыганда үз-үзен белештермәгәнен бик яхшы белә, шуңа күрә ишек ачылуга чыраена берәр әйбер килеп бәрелсә дә, уңлап-суллап яңаклый башласалар да, гаҗәпләнмәскә дип, алдан ук үз-үзен әзерләп куйды ул. Чәпчесен әйдә, дуамаллансын, ямьсезләнсен, пыр туздырып, өйдән үк куып чыгарсын! Бигрәк яхшы, Рәмзигә шул гына кирәк тә. Әштә көн күрсәтмиләр, өйдән куалар, андый чакта нишләсен ир кеше? Аңа шул бер генә чара — әкияти кош канатына ике куллап ябышырга да, күзне йомып, аның ихтыярына бирелергә генә кала.

Бу хакта уйлау барлык дәгъва-низагларны җиңел генә үткәреп җибәрергә көч һәм үзенә бер татлы ләззәт тә бирә иде.

Ишекне озак ачмый торырлар дип уйлаган иде. Ләкин ул кыңгырау төймәсенә орынып та өлгермәде, әчке якта ашыгыч адымнар ишетелде. Шәфика затлыга кия торган зәңгәр күлмәген кигән, чәчләрен дулкын-дулкын итеп күпертеп куйган, иреннәрен кызарткан — шундый җыйнак-пөхтә, өйдә чакта аның таркаулыгына, хәтта репетицияләргә кергәндә дә авырлык беләнрәк җыенуына күнеккән Рәмзи моны бер күз салуда искәреп алды. Бизәнгән, матурланган, алай да күз төпләре күгәргәне, йөзе суырылганы сизелеп тора иде. Ә күзләре... Күзләрендә Рәмзи көткән ачу-ярсуның әсәре дә юк, киресенчә, газап һәм сызлану иде, алар да шундук юк булды, куанычлы балкү белән алышынды.

— Кайларда йөрисең син, кайда? — диде Шәфика әкрен тавыш белән сузып. Һәм иренең күкрәгенә яңагын куйды. — Мин бөтен танышларга шалтыратып бетердем инде, «скорый»дан әллә ничә тапкыр сораштым! Моргка да шалтыратмакчы идем — йөрәгем җитмәде! «Бездә ул», — дип җавап бирүләреннән курыктым!

— Нәрсә шул хәтле кешене бимазалыйсың, — диде Рәмзи кибәк чәйнәгәндәй сүлпән генә. — Бер-бер хәл булса, хәзер үзләре килеп әйтә бит алар. Минем кесә тулы документ лабаса.

Шәфика ике учын аның түшенә терәп, маңгае белән күкрәк турына бәргәләде.

— Документ! Дөньяда ни булмас! Син шундый хәлдә идең бит! Шәһәр буйлап эзләргә чыгып китәргә тора идем инде! Әйт: кайда кундың?

Аның чәче Рәмзинең муенын, ияген кытыклап, элекке чакларны, соңарып булса да, иҗади уйлану-табышлардан очынып, чиста намус белән иркенәеп кайтып кергән кичләрне искә төшерде. Шәфикадан бик нәфис, татлы ис — Яңа ел бәйрәменә Рәмзи бүләк иткән француз хушбуе исе аңкый иде. Кар яуган кичне алып кайтып бирде ул аны. Әле кайчан гына иде бит, ул кичне яуган карлар җирдә нык ята, кымшанмый да әле. Ә күпме үзгәреш булды! Күңел язы күптән узып, анда да кыш килде. Җирдәге карлар эрер-бетәр, ә күңел, бәлки, гомерлеккә бозлангандыр...

Ни сөйли соң әле бу хатын? Йомшаклыгы, җылы назы белән күңел бозларын эретмәкчеме шулай?

Ялганлап торуның мәгънәсе юк иде. Рәмзи, Шәфиканы читкәрәк этәреп, тунын салып чөйгә элде дә, хатыныннан бигрәк, коридорның аргы башында ак шәленә уранып басып торган Мөкәррәмәгә әйткәндәй:

— Училищеда, — диде.

— Кайсы училищеда? Нишләдең анда? Шалтыратып булмадымыни? Мин монда акылдан шаша яздым бит инде! — дип, миңгерәгәндәй сөйләнүендә булды Шәфика. Тулышып киткән гәүдәле, түгәрәк йөзле хатынның бала-чагадай сабырсызланып, беркатлы такылдавы Рәмзинең күңеленә тиде, үсмер кыяфәтле булса да, бик өлгергән акыллы Эльвира искә төште. Җир белән күк арасы!

— Искә килмәгән шалтыратырга, — диде Рәмзи, каенанага ишетелсен өчен, янә тавышын күтәребрәк. — Баш каткан иде бит.

Һәм, хатынын калдырып, зал ягына кереп китте.

— Анысы шулай инде, аптырарсың да, — дип, аның белән килеште арттан ияргән Шәфика. Ул ире өчен янганын һәр ишарәсе, хәтта сулышы белән үк сиздерергә тырыша иде. Затлы күлмәк өстеннән чигүле алъяпкыч бәйләгән хатыны, зал белән кухня арасында йөреп, чәй табыны әзерләгән арада, Рәмзи аны тәнкыйть күзеннән үткәреп карап утырды һәм гаеп өстенә гаебен тапты. Хәтта аның пөхтәлеген дә яратмады. Болай киенеп-ясануы уңганлыгыннан түгел, вакытын кая куярга белмәвеннән генә дип уйлады. «Төн буе керфек какмаган, ирен көтеп утырган, ә сабыр итә, көтә белми, шуңа үзенә бер шөгыль булсын дип азапланган инде», — диде эченнән. Бу ихласлыгы, бала-чагадай беркатлы кылануы тагын! Олыгаеп килгән хатынга алай капчыгын төбеннән тотып селкү килешми ләбаса, аз гына серлерәк булу да зыян итмәс иде!

Хәер, бик үк ихлас микән әле? — дип, икенче яктан уйлый башлады тагын. Ире читтә кунып кайткач, хатын күңелендә шик тумас, көнләшү кузгалмасмыни? Өсте-өстенә имзасыз хатлар килеп торганда. Тик Шәфика көнләшүен яшерә беләдер, күрәсең. Ә бәлки, аны гына да түгел, дер. Ире белмәгән серләре тагын бардыр әле!

Шәфика иренең үзенә яратмыйча, өнәмичә карап утырганын тоеп йөри, ләкин моны үзгәртүнең чарасын белми, фәкать каушый, тагын да ныграк миңгери генә иде.

Чәй эчәргә утыргач, ул күңелсез тынлыкны бозарга кирәк тапты.

— Син бирешмә, — дип башлады сүзен. — Иҗат эшендә һәркем башыннан уза инде андый хәлләр. Артык авырга гына алмаска кирәк. Бөтен эшеңә яңачарак карап, өр-яңадан...

Ни тыелырга тырышса да, чыдап бетерә алмады Рәмзи, балкашыгын чынаяк читенә шартлатып ташлады да:

— Сабак өйрәтми генә чәй эчәргә ирек бир ичмасам! — диде.

«Китәргә, китәргә, бөтенесен ташларга да китәргә!» — дигән уй сулкылдады аның кайнарланган миендә.

Театрга кергәч, Әнвәрбәков белән каты гына чәкәләшеп алдылар. Дөрес, баш режиссер сүзне бик тыныч, көндәлек гадәти эш турында сөйләшкәндәй башлап җибәргән иде. Барысын да онытырга, ничекничек итеп спектакльне өр-яңадан куярга, баштагы табышларны соңыннан гына искә төшереп кертергә имеш...

— Нәрсәгә аны миңа сөйләп торасыз, онытыгыз да искә төшерегез үзегез, — диде Рәмзи. — Сез әнә нинди оста бит!

— Кеше бозганны төзәтеп йөрергә ашкынып тормыйм әле. — Әмир аңа кисеп карады. — Үзең бозганны үзең төзәтергә өйрән, күптән балигъ булган.

— Ә мин үземне ни дә булса бозган дип исәпләмим һәм төзәтергә уйлаганым да юк.

— Мондый рухта уртак тел табып булмый, без синең белән болай эшли дә алмаячакбыз, Бикбау иптәш.

— Мин дә нәкъ шулай уйлыйм, — дип, мәсхәрә белән җавап кайтарды Рәмзи. — Менә, бер мәсьәләдә фикерләребез уртак икән бит! Гаризаны хәзер үк язып кертимме?

Әнвәрбәков керфеген дә селкетмәде.

— Андый гаризаларны директор караганны беләсең бит, — диде тыныч кына. — Сау бул хәзергә.

Рәмзи, ачуыннан буылып, чыгу ягына борылган иде, бизәкле келәм читенә сөртенгәндәй тукталып калды: ишек янындагы рәсемнән аңа Хуҗа Насретдин карап тора, ул, ишәкнең койрыгына ябышып атланган да авызын ерып көлә иде. Рәмзинең үзенә дә бу хәлләр көлке булып тоелып куйды. Ул, ашыгып, бүлмәдән чыкты да, каты шартлатып, ишекне япты. Шунда ук, секретарь өстәле янына басып, эштән китәргә теләве хакында гариза да язып калдырды.

— Әйдә, китәбез, бөтенесенә төкерәбез дә китәбез, — диде ул кичен Эльвира белән очрашкач. Ул кызны сак кына кочып, аның бүрек төбәсенә йөзе белән капланды. Бүрек Шәфика чәченнән күпкә йомшакназлырак, ә аннан аңкыган тире исе француз ислемаеннан күпкә тәмлерәк тоелды. Яшь кызның хушбуйлар белән мавыкмавы да күркәмлек өсти иде.

— Китәбез! — дип, аның күкрәгенә сыенды, сеңде, бөтенләй егет белән бер булып бетте Эльвира.

— Мин упкынга сикерергә әзер бүген. Ярый әле син бар, канатыңа күтәр дә алып кит мине тизрәк!

— Алам! Алам да беркем буе җитмәслек биеклеккә күтәрәм, беркем карашы җитмәслек ераклыкка алып китәм мин сине!

Эльвира, кулларын аның иңенә салып, битенә үрелде, татлы һәм исерткеч бал булып иреннәренә ягылды.

Алар, аулаграк урын эзләп, елга порты ягына ук барып чыкканнар иде. Бу тирәдә кышын аеруча тыныч була, кырыйларына текә итеп кар өелгән юллардан машиналар сирәк уза. Караңгы һәм серле — нәкъ гашыйклар күңеленә хуш килә торган! Әнә якында гына күтәренке юлдан поезд узып бара. Аның эчендә җылыдыр, яктыдыр, ямьледер сыман, андагы кешеләрнең бер гаме дә юктыр шикелле. Яхшы кәефле ул кешеләрне кайсы тарафларга, нинди бәхетле якларга алып китүе икән бу житез поездның?

— Әйдә, шушы поездга ук утырабыз да китәбез!

— Монысы китеп барды бит инде, — диде Эльвира күңелле ямансулау белән.

— Вокзалга барыйк алайса. Аннан поездлар сәгать саен китеп тора.

— Билетны кайсы калага хәтле алырбыз икән?

— Еракларак. Беренче поезд кая булса, шул якка.

— Владивостокка, — дип көлде Эльвира, уенга кушылып. — Я

Ташкентка. Барабыз, барабыз, атналар буе. Күз күрмәгән калага, күз күрмәгән кешеләр арасына килеп төшәбез бер заман. Акчаң күпме синең?

Күз алдында рәшә булып шәйләнгән әкияти дөньяны сөртеп алгандай итте бу «акча» сүзе. Рәмзи — гаилә башы, акчаны хатынга кайтарып бирергә күнеккән. Дөрес, Шәфика тиен саный белми, иренең кесәсен тикшереп тормый, шулай да Рәмзидә унбиш-егерме сумнан артык акча сирәк йөри. Әйе, ул хәзинә белән генә әллә ни ерак китеп булмый! Ләкин чигенү дә мөмкин түгел иде инде.

— Минем хәзер билет аласы гына калды инде, — диде ул, Эльвираның йөзен үзенә якын ук китереп. — Театр белән араны өздем, бүген көндез гариза язып калдырдым.

Эльвираның чыраеннан елмаю качты, борыны очлаеп килгәндәй булды, күзләре түгәрәкләнеп ачылды:

— Театрдан киттем дисеңме? Бүгеннәнме?

— Ә ник аңа гаҗәпләнәсең? Кичә без бу хакта сөйләштек бит инде.

— Әйе, әйе, — дип, аның белән килешергә ашыкты Эльвира. Ул каушап калган иде, кечерәеп киткәндәй булды — аяк очларына күтәрелеп торган җиреннән бөтен табанына басты, читләште. — Ләкин бүген үк димәгән идек. Бик капылт килеп чыга бит әле бу. Күзне йомып, суга чумгандай...

— Үз-үзен аз гына булса да ихтирам иткән кеше мондый очракта нәкъ шулай эшли дә инде, — диде Рәмзи.

Эльвира аны култыклап алды да елга портының караңгы һәм шомлы бинасына табарак әйдәде. Аңа фикерен тупларга кирәк иде.

— Үз-үзен ихтирам иткән кеше чуму турында гына түгел, су өстенә калкып чыккач, кеше көлкесенә калмау хакында да уйларга тиеш бит әле, — диде ул. — Итәгеңә ут капкандай ашыгып чыгып качсаң, җиңелү, дошман сүзен өскә чыгару була түгелме? — Эльвира иңе белән аның беләгенә сарылды. — Минем канатлар да ныгып җитмәгән бит әле. Өч айдан, диплом алгач, алар бик кодрәтле булачак булуын да, хәзергә каурыйларның үсеп кенә килгән чагы шул!

— Алайса болай итәбез: мин үзем генә китәм дә барып урнашам. Аннары син килерсең. Бигрәк әйбәт булыр, әзерләнеп көтеп алырмын.

Эльвира аның беләген нык итеп үзенә кысты, тун һәм пальто аркылы да сизелде: нечкә булса да, көчле иде кызның кулы! Шул хәрәкәттән үк Рәмзи кызның уйларын аңлап алды: Эльвира аның үзен генә җибәрергә теләми, шикләнә, ышанмый. Анда, яңа урында, яңа кешеләр арасында ятларга күз салыр дип уйлый. Яшь, чибәр артисткалар һәр театрда җитәрлек! Эльвира өчен Рәмзинең шушында, гайрәтен чигергән хатыны янында яшәп ятуы хәерлерәк иде, әлбәттә.

Ләкин моны ачыктан-ачык әйтеп булмый бит инде, һәм кыз хәйләгә күреште:

— Ә нигә әле без, җыен ахмак сүзенә карап, үзебезгә үзебез көйсезлек эшләргә тиеш? — дип сорады ул. — Һәр эшнең җаен, вакытын чамалап башкарырга була бит.

— Ничек? — дип көлемсерәп сорап куйды Рәмзи. Ә үзе эчтән генә: «Тагын ниләр уйлап чыгарыр икән бу?» — дип уйлады.

— Син театрда чакта Әнвәрбәковның кул-аягы бәйле, чөнки бу спектакльне фәкать син генә коткара аласың, — диде Эльвира батыраеп. — Син барда ул бу эшкә тотына алмый, яшь режиссерның кулыннан эшен тартып алса, оятына көч килер! Димәк, ул ничек тә синең көйгә торырга мәҗбүр булачак. Әгәр син, чәпчеп, эштән китеп барсаң, ул чакта Әнвәрбәковка бөтен юллар ачыла: спектакльне үзе куя, һәм халык алдында йөзе дә ак була. Хәзерге көндә синең өчен театрда булуың мең мәртәбә яхшырак! Әйдә, ялынып карасыннар әле, артыңнан инәлеп йөрсеннәр!

— Күңел тартмаган эшкә тотыныргамы? Хур булганнан соңмы?
— Хурлык дияргә, кеше әйберен урлап тотылмаган ла син!
— Иҗат эшен ерып чыга алмаган кешегә халык каракка караган кебек карый, беләсең килсә! Начар сәнгать әсәре — караклык ул — кешенең вакытын урлау дигән сүз!
— Син әле беркемнең дә вакытына кул сузмаган, спектакль кую эшең ярты юлда гына. Һичкем сине гаепләми. Алар бик үтенгәннән соң гына, үз дәрәҗәңне бик белеп кенә ризалашасың...
Рәмзи нидер әйтмәкче иде, Эльвира, беләген нык кысып, аңа дәшмәскә боерды.
— Ризалашкан булып кыланасың... — дип тәзәтте ул сүзен. — Эшне мөмкин кадәр сузасың... Ул арада башка театрларда яшь режиссерга нинди мөмкинлекләр барын белешәсең. Бик ялынып чакырган җиргә кадерле кеше булып барып төшәсең аннары. Кочак җәеп каршы алырлык булсалар гына. Бу инде сиңа, күз йомып, суга чуму түгел, ә бәлки ак пароходның өске палубасында китү була.
— Кош канатына ябышып очу түгелмени?
— Анысы инде синең ихтыярдан гына торачак. Лачынның канатлары ныгыган булыр һәрхәлдә!
— Ә спектакль каламы шулай?
— Әй, эт ашасынсана! — дип, кулын селтәде Эльвира. — Әнвәрбәков очлап чыгар әле. Ә синең ник киткәнеңне беркем аңламый калыр. Андый очракта һәркем үзенчә фараз итә, ә фаразның очы җитәкчегә барып тоташа. Талантлы, яшь кешегә үсәргә мөмкинлек булмагандыр инде дип уйлыйлар. Әллә хак түгелме? Шул рәвешле син бернинди вакланусыз, нервы талкымый гына...
Эльвира үз-үзеннән бик канәгать рәвештә, тамак төбе белән генә көлеп, Рәмзинең беләген ике учы белән иркәләп-сөеп куйды. «Хәйләкәр, чукынмыш!» — дигән уй килде егетнең башына. Ләкин ышандыра, мавыктыра! Тик сак булырга кирәк үзе белән. Бу сиңа ачык авыз Шәфика түгел, үзеңне әвәрә итеп, әйләнчек сарыкка әверелдергәнен сизми дә калуың бар! Сүзенең төбендә ниндидер ямьсезлек бары сизелә иде сизелүен, ләкин шунысы әйбәт: көч җитмәскә — көчәнәсе, баш җитмәскә — тотынасы, җылы өеңне ташлап, әллә кайларда каңгырап йөрисе юк, бөтенесе җай гына, үзеннән-үзе эшләнәчәк икән бит!
Алай да бу хакта Рәмзинең, ялгызы калып, ашыкмыйча уйланасы килә иде.
— Алайса, хәзер нишлибез инде? — дип сорады ул Эльвирадан.
— Хәзерме? Хәзер...
Эльвираның егет беләгенә тотынган кулы кинәт егәрен югалткандай булды, авыраеп, аска тарта башлады. Кыз, читтән җавап эзләгәндәй, башын уңга-сулга боргалады. Сөйгәнен хатыны янына кайтарып җибәрәсе килми иде аның, билгеле. Ләкин нишләмәк кирәк: үз фатирына, авыру карчык янына ир-ат алып кайтып кундыра алмый иде шул ул.
Алар яныннан, аллы-артлы әллә ничә төрле утларын җемелдәтеп, выжлап машиналар узып тора, тротуарларда әрле-бирле халык йөри, тыгызланып тезелеп баскан бишәр-ундүртәр катлы биналар йөзләгән тәрәзәләреннән яктылык сирпи — әмма миллионлаган халкы булган зур калада бичара ике гашыйкка сыеныр бер почмак юк һәм бу очракта Эльвира булып Эльвира да чарасыз иде.
Нихәл итәсең, бу юлы да элекке очрашулардан соң булган хәл кабатланды: алар, саубуллашып, һәркайсы үз өенә кайтып киттеләр.
Икенче көнне иртән баш режиссер театрда Бикбауны гадәттәгечә берни булмагандай бик тыныч каршылады. Әйтерсең, кичә алар кычкырышмаганнар һәм Рәмзи бернинди гариза да язмаган.
Ул гаризаның язмышы ахырда Рәмзигә караңгы булып калды. Театрның директоры — күп еллар актерлык тәҗрибәсе булган, сәхнә әһелләренең холкын яхшы белгән һәм көен табарга өйрәнгән, акыллы һәм зирәк хатын Мәрьям Бавлинская укыгандырмы аны, юкмы — бил-

гесез, һәрхәлдә ул бу хакта Рәмзигә беркайчан да сүз әйтмәде.

— Ә-ә, синмени әле бу, бик вакытлы килдең, — диде Әнвәрбәков Рәмзигә. — Даян да монда. Сез икегез сөйләшә торыгыз, мин бер-ике мәсьәләне хәл итәм дә озакламый бушыйм.

Рәмзи драматургны үз бүлмәсенә чакырды.

## 26

Нәкъ шул вакытта грим бүлмәләре янындагы залда Җиһангир белән Сафия очраштылар.

— Син, Сафия, заявка бирдеңме соң әле?

— Нәрсәгә, Җиһангир абый?

— Кадимбикәгә.

— Башкаручылар исемлегенең башында Бикташева фамилиясе торса, күпләрнең зиһене чуалмасмы соң, Җиһангир абый?

— Ә нәрсәсе гаҗәп аның?

— Бикташеваның гел исемлекнең ахырында булуына күнегеп беткәннәрдер инде. Мин, Җиһангир абый, шушы театрда гына исемлекнең астына төштем. Укыганда гел беренче идем. «А»га фамилия юк иде безнең класста.

— Аның каравы бездә җитәрлек. Син болай гомер буена койрыкта калмагаең.

Сафия бер генә минутка уйланып торды.

— Заявка бирү генә аз, Җиһангир абый. Миңа Сезнең ярдәм кирәк.

Җиһангир аны күз карашыннан аңлады.

— Хәзер үк тәвәккәллибезме соң?

Ул, кыюлыгың җитәрме дигәндәй, Сафиягә сынап карады.

— Мин әзер, Җиһангир абый.

Алар Бикбау бүлмәсенә барып кергәндә, режиссер белән Даян Ризванов нәрсәдер бик кызып-кызып сөйләшеп утыралар иде. Сүзләре матурга охшамаган, икесе дә кәефсез күренделәр. Сафия белән Җиһангирның «Кадимбикә»дән өзек уйнап күрсәтергә теләгәнен ишеткәч, Даян утырган җирендә гадәтенчә алга бөгелә төште, читкә карап көлемсерәде һәм башын чайкап куйды: «Шул гына җитмәгән иде монда!» Бикбауның болай да кырыс чырае тагын да караңгыланды, ул, аскы иренен бүлтәйтеп, мыегын тешләштергәндәй итенде.

— Уйнагыз, — диде ул салкын гына.

Ни кыюланып керсә дә, Сафия бераз икеләнеп калды: кыяфәтләре бер дә миһербанлы күренми, юньлегә булыр микән?

— Вакытсыз кердек бугай. Бәлки, соңрак очрашырбыз?

— Бик вакытлы. Автор да карасын. Вакытында фикерен әйтеп куяр.

Бикбау мәгънәле итеп драматургка карап куйды, тегесе читкә текәлгән килеш, канәгатьсезлеген белдереп, «һм» диде.

Җиһангир Сафияне, иңнәреннән тотып, ишек тарафынарак этәрде. Үзе бүлмә уртасына чигенде дә, шаярып, «әйдә, бирешмә!» дигәндәй күз кысты. Шундук үзе кинәт үзгәрде, мөлаем абыйдан кырыс, тәкәббер, ышанмаучан, гайрәтле иргә — Хакимгә әверелде, карашыннан һәм йөзеннән боз салкыны бөркелде.

— Тәхет корбаннар өстендә утырса гына нык була, — диде ул аяусыз каты тавыш белән.

Хаким. Әйе, корбаннар өстендә, кан өстендә. Корбаннарсыз гына тәхетне яулап алып та, саклап калып та булмый. Утырган тәхетең нык булсын өчен, аның нигезен һәрвакыт сугарып торырга кирәк. Кан белән сугарырга кирәк аны!

Кадимбикә. Кан белән? Корбаннар өстендә тотарга?

Хаким. Менә, утырып кара әле, үзең дә ышанырсың. *(Кадимбикәне тәхетенә утырта.)*

Хаким. Сизеләме ныклыгы?

Кадимбикә. Сизелә... Каты икән!

Хаким. Мин аның нигезен бик яхшы ныгыттым. Һәм ныгытып торачакмын!

Кадимбикә *(утырган урынында чайкалып куя)*. Аһ!

Хаким. Тәхет нык булса гына, Хакимне барча адәмнәрдән югарырак күтәрә, аны ходайның үзенә тиң итә!

Кадимбикә. Аһ!

Хаким. Син моны аңлап бетермәдең әле, тәхетнең ныклыгы синең тамырларыңа үтмәде, бәгыреңә барып житмәде әле!

Кадимбикә *(егыла язып)*. Аһ!

Хаким. Син әле андый урында утыра да белмисең! Әйе, тәхеттә утыру сирәк адәмнең көченнән килә!

Кадимбикә. Анда... Иремне җәзалыйлар...

Хаким *(тынып тора)*. Берни ишетелми. Каян беләсең?

Кадимбикә. Сызланам... Аңа орган саен, минем тәнем сызлана...

Хаким. Юкны сөйләмә! Тәхеткә утырган кеше аны уйларга тиеш түгел. Нигезне ныгытырга, тагын да биегрәккә күтәрелергә, колачны тагын да киңрәк җәяргә! Менә шуны уйларга тиеш ул! Ә ул эшләр барысы да корбаннар сорый!

Кадимбикә. Корбаннар? Әгәр ансыз мөмкин түгел икән, иң беренче итеп мин үз җанымны, үз канымны корбан итәр идем!

Хаким. Аннан ни мәгънә?

Кадимбикә. Мин канымның һәр тамчысын илемнең туфрагына сибәр идем, әгәр шул тамчылардан гөлләр үсә торган булса!

Хаким. Юкны сөйләмә! Әгәр син чыннан да шушы тәхеткә ныклап менеп утырсаң... Әгәр сине утыртсалар, кулыңа чыннан да чиксез власть бирсәләр, нишләр идең, син шуны әйт!

Кадимбикә. Иң беренче итеп, мин казнадагы бөтен байлыкны барларга кушар идем.

Хаким. Һәм минем дөньяда иң бай хаким икәнлегемне белер идең.

Кадимбикә. Ул байлыкны нәрсәгә тотарга икәнен ныклап уйлар идем.

Хаким. Байлык белән бөтен нәрсәгә ирешеп була! Минем хәзинәләрем чутсыз, шуңа күрә кодрәтем дә чиксез!

Кадимбикә. Бу җимерелгән каланы элеккечә гүзәл итеп торгызырга боерыр идем.

Хаким. Әйе-әйе, аның уртасына моңарчы беркайда булмаган, күз күрмәгән, колак ишетмәгән гүзәл сарай салдырырга. Минем сарай булыр ул, аңа барча хакимнәр таң калыр!

Кадимбикә. Мин шагыйрьләргә, рәссамнарга, җырчыларга иҗат өчен юл ачар идем.

Хаким. Алар минем сурәтне ясау өчен, мине мактап җырлау өчен кирәк!

Кадимбикә. Илдә иминлек урнаштырып, балалар шат, сәламәт үссен дип кайгыртыр идем.

Хаким. Әйе-әйе, миңа коллар кирәк, коллар! Алар үрчеп, үсеп торсын. Кадимбикә! Мин яңа биләмәләр яулаганда, тәхетнең нигезен кан белән сугарганда, син минем өчен боларның барысын да эшли алыр идең!

Кадимбикә. Аһ... *(Егыла.)*

Хаким. Ни булды? Нәрсә? *(Якын килеп карый.)* Һушсыз. Әй, кем бар анда?

*(Газизҗан керә.)*

Хаким. Чакырыгыз табипларны! Һушына китерсеннәр!

Газизҗан. Табипларны? Әсирне каратыргамы?

Хаким. Әйткәнне үтә!

Газизҗан *(соң дәрәҗәдә аптырап)*. Хәзер-хәзер, әйтермен, галиҗәнап. *(Чыгып бара.)*

Хаким. Кая киттең, ахмак?

Газизҗан. Терелтергә кушасың бит, галиҗәнап. Ашыгам, югыйсә әсирнең җан биреп куюы бар.

Хаким. Нинди әсир? Кем хакында сөйлисең син?

Газизҗан. Нариман әсирне, галиҗәнап. Ул һушыннан язды бит.

Хаким. Сез чыннан да аны җәзаладыгызмыни? Дөресмени ул сүз? Табиплар монда килсен, монда! Менә бу хатынны карасыннар! Тизрәк!

*(Газизҗан чыга).*

Хаким. Гаҗәп... гаҗәп... үзенә үлем янаганда, керфек тә какмаган иде, кайдадыр читтә ирен җәзалаганга монда торып һуштан яза. Әгәр мин сызлансам, кем шулай тоя моны? Кем минем белән беррәттән газаплана?.. Юк андый кеше. Шушы хатын кирәк миңа. Ул минеке булырга тиеш! Терелтсеннәр, аякка бастырсыннар... Ләкин, ире үлсә, аның да җан бирүе ихтимал бит әле. Әй, кем анда! Нариман дигән әсир янына табиплар җибәрегез. Аны да карасыннар! Терелтсеннәр!

Шуннан соң бүлмәдә тынлык урнашып, күпмедер вакыт Сафия йөрәге дөпелдәгәнен генә ишетеп торды. Менә, ниһаять, бу тынлыкны Даянның көр тавышы ярып узды:

— Башка роль беткәнмени Сезгә, ә? Житте инде шул бер Кадимбикә өстендә тәҗрибәләр үткәрергә! Театрдагы бөтен артисткаларны анда сынап карарга димәгән!

Бикбау аның сүзен гүяки бөтенләй ишетмәде дә, Сафиянең каршына ук килеп басты да, беренче тапкыр күргәндәй, текәлеп, сынап, йөзенә карап торды, шул ук вакытта бик үк дикъкатьле дә түгел иде кебек, әйтерсең, ул башында чагылып узган ниндидер фикерне тотарга тели һәм тотып ала алмый иде. Шулай үз уена мавыккан хәлдә кире чигенде, бераз тәрәзәгә карап торды, аннары борылды, Җиһангир белән Сафиянең һаман әле бүлмәдә икәнен кинәт исенә төшергәндәй:

— Ярый, уйлашырбыз, — диде.

Артистлар чыгып киткәч, ул бүлмә буйлап йөренергә кереште. Даян, кычкырып-кычкырып, нидер сөйли, ләкин аның сүзләре Бикбауның зиһененә барып ирешми иде. Сафия белән Җиһангирның уены аның уй-фикерләрен өр-яңа, бөтенләй булмаган юнәлешкә борып җибәргәндәй иткән иде. Бик гади, үз әниең кебек таныш һәм күңелгә якын, шул ук вакытта әкияттәгечә серсез һәм көчле иде бу Кадимбикә.

— Бәлки, вакыйгаларны сугыш тәмамланудан түгел, ә бәлки сугышның барышыннан башларгадыр?

Аның әкрен, уйчан тавыш белән әйткән бу сүзләреннән драматург сискәнеп туктап калды. Ул, әллә ялгыш ишеттемме, дигәндәй сәерсенеп карап торды, аннары үзалдына сөйләнгәндәй:

— Әйе-әйе, — диде. — Яңа пьеса язарга кирәк Сезгә. Монысын чыгарып ташларга да иртәнгә икенчесен язып китерергә. Сугыш барган чакны күрсәтеп. Ай-яй, югары фикердә икән Сез минем турыда, иптәш режиссер! Рәхмәт инде ышанычыгызга!

— Туктале, фикерне бутама... Сүз әйтергә ирек бирмисең, тамак киереп кычкырырга гына торасың... Ташла әле шул малай-шалай гадәтен... Димәк, сугыш... Аны язып торырга да кирәкмидер. Нәрсәгә язарга, бара бит ул сугышлар, туктап торганнары да юк. Вьетнам... Ливан... Кинохроникадан алырга була. Пәрдәне экран ясыйсың да кинопроектор белән төшерәсең. Тамашачы бүгенге афәтләрне, хакимнәр әмере белән бүген кылына торган вәхшилекне күрә. Ул аларны болай да белеп тора, билгеле, ләкин без аның исенә төшерәбез. Шул рәвешле спектакльдә булачак вакыйгаларны алдан ук бүгенге көн, бүгенге кешеләр язмышы белән бәйләп куябыз. Ничек, синеңчә? Димәк, музыка, экранда бүгенге көндәге сугыш күренешләре...

— Озаккамы инде? — дип, мыскыллы елмайды Даян. Ул ничектер басыла төшкән, уйлана башлаган, ләкин әле моны сиздерәсе, тиз генә бирешәсе килми иде.

— Юк, озакка сузарга кирәкми. Бу — үзенә күрә бер камертон кебек кенә. Шуннан...—Рәмзи туктап калды. — Шуннан пролог белән бу күренешләрне ничектер бәйлисең. Әйе, бәйләргә кирәк. Бәйләргә... Син ничек уйлыйсың?

— Мин үзем уйлаганымны язып бирдем инде. Син уйлан хәзер!

— Бәйләргә... Аны гади генә эшләргә була. Залдан берәү чыга да әйтә.

— Ни дип?

— Ә ул гади тамашачы ди. Тамаша карарга килгән. Аның сугыш күренешләрен күрәсе килми...

Даян аның сүзен дәвам итте: «Туктагыз! Житте, туйдык инде сугышлардан! Мин тамаша карарга килдем монда. Яшәү турында, игелек турында, мәхәббәт турында матур кыйссалар карыйсым килә! Кеше рухының зурлыгын, сафлыгын күрәсем килә! Һич булмаса кызык күрергә телим!»

— Нәкъ шулай. Шуннан соң сугыш күренешләре бетерелә. Берәү чыгып, тамашачы белән сөйләшә башлый...

— Анысы синме инде?

— Юк, нигә мин?

— Ә кем соң? Ул бит таләбен режиссерга белдерә.

— Режиссерга ярамый... Микрофон аша, күренми сөйләшсәң генә инде.

— Ни дип әйтмәкче буласың инде?

— Ярый алайса, диярмен. Сугыш беткән ди. Юк, алай түгел, бик борынгы заманнарда...

— «Борын-борын заманда, кәжә команда, саескан сотник, үрдәк урәтник булган заманда, беткән ди, тәмамланган ди, ниһаять, озак барган каты сугыш...»

Бикбау Даянга сокланып, яратып карады:

— Нәкъ менә шулай. Күрәсең, яза да башладың. Ә дәгъвалашып маташасың тагын. Димәк, үрдәк урәтник булган заманда... Шуннан соң пәрдәне ачабыз, анда пролог — яу кыры, синең теге ике хатының Сафия белән...

— Сафия түгел! — Даян янә кыза башлады. — Сафия түгел — Исмегөл! Исмегөлне куясың Кадимбикәгә! Мин сиңа алдан ук әйткән идем бит: бу роль Исмегөлгә атап язылды!

Рәмзи аңа өлкән абыйсы кебек сабыр гына карап торды да:

— Ярый, анысы да синеңчә булыр, — диде. — Ике составка икесен куярбыз: Сафияне һәм Исмегөлне.

*Ахыры киләсе санда.*

## Рәшит Әхмәтҗанов

# БИШТАШ

*Таш, батмыйча,*
*Су өстендә йөзеп йөрде...*

Кол Гали.

### Поэмага чакыру

Бер елмайдым, биш моңайдым.
Сизмәдем дә, таңнар атты.
Балкый-балкый, кояш мине
Тау астыннан эзләп тапты.

Мин бит әле ул чакларда
Гөл бөртеге сыман гына.
Үлемнәрдән кача-кача,
Кердем кояш кочагына.

Очалмадым — авырлыгын
Дөнья салды канатларга.
Көч һәм кодрәт бирде тагын
Таш ватарга,
Таш ватарга!

Каршылады Әлмәт мине,
Ташларына ташлар бәреп,
Ул ташларны җыя килдем,
Куя килдем мин күтәреп
Күңел дигән корабыма,
Җаныма — җыр кәрванына...
Тау кадәрле йөк төядем
Үз аңыма,
Дәрманыма.

Менә монсы — моңсыз башка
Якын барып бәрәсе таш,
Ә монысы — оятсызның
Алларына куясы аш.

Ә болары куркак башын
Яуда саклап калган ташлар,—

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ *(1941) — шагыйрь, «Гомер чишмәсе», «Җан яктысы», «Кавышыр көн» һ. б. унга якын шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Алыйм,
куркак йә аларны
Батырларга бәрә башлар.

Монсы, менә, ялгыз юлчы
Бәргән таштыр бүреләргә,—
Бирмәгән ул бүреләргә
Сәфәрчене бүлгәләргә...

Таш — авырлык. Икмәк түгел —
Бирә алмыйм беркемгә дә.
Йортлар салам суешлардан
Исән калган тереләргә.

Һәр терегә кирәк оя:
Бөркетләр кыяга куя,
Бөҗәкләр ярыкка сыя,
Карлыгачлар ярга уя.

Агач башында да — оя,
Яфрак астында да — оя.
Кемдер оясыннан туя, —
Йөри-йөри башын җуя.

Үземә дә кордым оя —
Нигезендә ташлар ята.
Ә кемнеңдер нигезендә
Башлар ята,
Башлар ята.

Таш астына салсам да мин
Җанның сыгып кайгыларын,—
Онытмагыз түбә астында
Мәңге гашыйк йөрәк барын.

Сөюемнең яктысыннан
Балкып тора тәрәзәләр.
Кайгыларда бу, димәгез,
Аларда ут сүнсә әгәр.

Шакымагыз тәрәзәмә,
Әллә, диеп, йокладыңмы?
*Балачакка барып киләм,*
*Сүндереп мин утларымны...*

• • •

...Утырам ташлар өстендә.
Күздә яшь яңа кипкән.
Көлмәкне,
Ашар икмәкне
Сугышлар талап киткән.

Шатлыгым — «бишташ» уены.
Ә кайгым — ачлык, ачлык.
Ачлыктан котылу өчен
Урманга кереп качтык.

Урманнан чыкканчы, кайгы
Таш булып калган катып...
Ташлар өстендә утыра
Балачак чәчәк атып.

Йә табышлар, йә танышлар —
Ташлары ла ташлары!
Учка салгач, алар никтер
Авырая башлады.

Бөтен нәрсә авырайды,
Җиңел әйбер калмады.
Авырлыгын күтәргәнгә,
Дөнья безне аңлады.

Белдек: җанны, канны, аңны
Җиңә икән җиңеллек.
«Җиңелмәскә!»— дидек тә без,
Авырлыкка җигелдек.

Авырлыктан яңарды гел
Каныбыз һәм аңыбыз.
Тик шулай кочаклый алды
Бу дөньяны җаныбыз...

Инде чәчләрем — ак чәчәк.
Һаман таш җыям җирдән:
Бәхетләр җиңә килгәнгә,
Тәхетләр җимерелгән.

*Ташларны күккә чөям мин.*
*Чиртеп бергә җыярмын,*
*Биш шигъри йөзегемә*
*Җем-җем кашлар куярмын.*

## Беренче таш

*...Ә бу ташың, кешем,*
*Телсез калган*
*Иң борынгы матдә... Син — телле!*
*Син — йөрәкле! Җиргә син кирәкле*
*Кояшның нәкъ үзе шикелле.*

Бу таш... болгар бабам торган йортның
Нигезеннән купкан, күрәсең.
Мин абындым аңа.
Телсез кинәт
Телгә килде:
— Нигә тибәсең?!

Ник тибәсең миңа?
Югыйсә бит
Ил хәсрәте иңгән таш булам.
Син яшәгән җирнең иң борынгы
Бер кисәге булам, и олан!..

Сабыр итеп тора. Тагын башлый:
— Әй, адәмгә дөнья нәрсә ул?!

Җирдә сәфәр итә башлагач та,
Бер аягын ташка кисә ул.

Исе китә! Ташны кулга ала:
«Карасана! Кисә икән бит!
Әгәр аны бәрсәм мин күршемә,
Бу аланнан качып китәр бит.
Ризыклары калыр иде аның...»
Һәм ул, ташны бәйләп таякка,
Гамьсез генә җимеш эзләп йөргән
Бер адәмгә бәрә... Озакка
Дуслаша ул аннан ташлар белән:
Ташсавытлар, балта ясый ул.
Аннан ташны кеше муенына
Бәйли башлый... суга ташлый ул...

Ут тоткандай, ташны кулга алдым:
Бәр — ватылмый,
Яндыр — янмый ул.
Киткәннәрне җибәрмичә, гүя,
Килгәннәрнең җанын барлый ул.

Баскан җирем белән мине бергә
Сил каерып ташлар иде дә,—
Соңга калды. Берни кузгаталмас
Борынгы таш инде күңелдә!

Әлмәт Ае, газиз әнкәм сыман,
Барлап, багып торды төн ката...
Һәм таш мине җир өстенә җәйгән
Тавышына салып йоклата.

Мин төш күрәм:
Борынгының берсе
Балта тоткан, сырлый иң алдан
Үзен мәгърүр кеше иткән көчнең
Сурәтләрен тораташлардан.

Үзен тәмугъ утларына салган
Аллаларны ясый аннан соң.
Аллаларның берсе дәшеп куя:
«Ахры, бездән алда тугансың?!»

Ташбалтадан гайре кулга тотар
Юньле коралы да юк аның.
Аны бары кемдер хуплап тора:
«Талантлы син, Кеше туганым!»

Һәм талантлы менә шул кешедән
Күз алдымда корбан чалдылар.
Көчләп авыз иттерерләр иде...
Йокылардан йолкып алдылар
Ташны көйдерерлек каргышлар да
«Коткарыгыз!» дигән тавышлар.
Алар арасында ераклардан —
Туганнардан килгән тавыш бар:

— Җир өстендә күпме агач үссә —
Барсына да кеше астылар!

Алсу шәфәкъ шаһит —
Ул бит безнең
Битне сөрткән канлы тастымал...

Тавышлардан дәһшәт купмасын дип,
Сабырлыклар, җаным аркылы,
Сынган сөякләрне ялгый торган
Тылсым булып ташка саркыды.

Тарих анналларын актара Ай:
Халык каны тамган битләрне
Кат-кат укый... кайсы баскынчының
Кай җирләрдә башы беткәнне...

* * *

Йокыларны учагыма ягам:
Яфрак-яфрак ялкын телләре
Каеннарга кабынмыйча гына
Шигыремне сөйләсен әле.

Йокыларны учагыма яктым.
Күз йомалмам бүтән ахрысы.
Котылдым ла кыргыйлардан, дисәм,—
Шуларныкы... пожар яктысы...

Юл күрсәткән йолдызларны йота.
Терелгәннәр, гүя тегеләр:
Кыйтгаларда яңа мәҗүсиләр,
Корбан чалып, биеп йөриләр.

Муенга таш бәйләп, су төбенә
Ташлаучылар шактый юл узган:
Ут ыргытып утырмакчы алар,
Безнең өскә җидегән йолдыздан...

Йолдызларга җитәр кулларыма,
Карурмандай моңлы башыма,
Кылыч сындыралган сүзләремә,
Су өстендә йөзгән ташыма,
Халкым йөрәгенә кил, Киләчәк,
Яшәргә кил!— чыктым каршыңа.

Илләр җаны булган уяу ирләр
Йөрәгенә кил син туп-туры!—
Сиңа дәшә шулай... аллалардан
Алда туганнарның бер улы.

— Уят, дисең,— оят!— барламасаң
Җир йөзендә асылларыңны.
Сизми калуың бар,
үзеңнең дә
Алар кебек асылганыңны.

Ә кулдагы ташың... телсез калган
Иң борынгы матдә... Син — телле!
Син — йөрәкле! Үлемнәрне үтер,
Алып бабаларың шикелле.

## Икенче таш

*...Тик шагыйрьләр яклаганга гына,*
*Җирдә исән калдык, күрәсең.*

Кешеләрне аскан залимнең бу
Кара кабер ташы.
Җирдән гүя чыгып карап тора —
Исән аның башы.

Күзе бар күк явыз Кисекбашның —
Кол Галине эзли.
Икенче кат үтерергә теләп,
Эзли — өмет өзми.

Чекерәеп күзгә карап тора:
«Мин — тарихың», имеш.
Ярамыймы әллә тарихың, ди,
Мин калдырган килеш?!

Мин бит аның үз кулларым белән
Башлам бабын ерттым,
Уртасын да аның тәмләп кенә,
Ие, чәйнәп йоттым...»

Әлмәттә яз. Тереләрне күккә
Тарта ил Кояшы!
Яшел үләннәргә күмеләчәк
Тиздән «залим башы».

...Бу хәл моннан мең ел элек булган,
Залим яшь чагында,—
Иң сөекле кәнизәге үлгән
Аның кочагында.

Шашып кала: «Үлде бердәнберем,
Ник башкалар тере?!»—
Үтерелгән шунда исәннәрнең
Күренгәне бере.

Үз чираты җиткәч, Гали аңа:
«И падишам, дигән,—
Синең гүзәлең бит бары сине
Сөймәгәнгә үлгән.

Минем җанга күчкән сиңа тиеш
Мәхәббәте аның.
Менә мине тотып утта яндыр,—
Койма халык канын!

Йөрәгемнең көлен сипсәң әгәр
Аның йөзләренә,—
Җил тизлеге белән җан иңәчәк
Синең гүзәлеңә...»

Сөйгәненә шулай гына барып
Булачагын белгән,—

Шагыйрь утка кергән... Патшаның тик
Ау этләре өргән.

Уттан килгән — утка китсен, диеп,
Яндырганнар аны.
Менә шулай сөйгән ярын коча
Кол Галинең җаны...

Шактый озак без карашып тордык
Икәү кара-каршы!—
Кулга алдым. «Бишташ» уенына
Ярар «патша башы».

Җиргә бәрдем: чәчелделәр таштан
Гасырлар һәм еллар...
Бу туган җир ташы!.. Сөенечтән
Беренче таш елар.

Бер тауныкы алар. Аерган тик,
Залим биргән җәза.
Үз язмышын каргап, бу кара таш
Безгә шигырь яза...

* * *

Яра-тамгаларын юам, юам...
Ун гасырны чайкыйм киемдә.
Зәй сулары ташка тигән саен,
Әрнүләрем кими минем дә.

Бүгенге гамь... ямь инәчәк ташка,
Күз нурыма гына төренсен.
Терелтүнең тылсымнарын монда
Миннән башка тагын кем белсен?

Күңел генә бер кагылып куйсын:
Илһамымның тылсым-кодрәте
Бөек Колның
ут-каберен эзләп
Очып барган аккош сурәтен
Җанландырыр! Канатына языйм
Иманымның шигырь-сурәсен...
Тик шагыйрьләр яклаганга гына,
Җирдә исән калдык, күрәсең.

Исән калдык!
Исәннәргә калды
Исәпләргә сыймас мираслар.
Мөһер кирәк түгел,— моны ташка
«Уел» җыры уелып раслар.

Гали рухы дәшә:
— Бер бомбага
Син саркофаг яса ташыңнан,—
Бомбаларны, кеше, оялмыйча
Кошлар оясына ташыган.

Бер бомбага яса.
Җир шарына

Кирәк булмас — әгәр шартласа...
Барыбыз да Галәм бәгыреннән
Мордар китәчәкбез ләбаса!

## Өченче таш

*...Яши-яши, күптән инандык без,*
*Үз илендә йөрәк янмаса:*
*Тумаска да мөмкин,*
*Ә тумасаң —*
*Үлмәскә дә мөмкин ләбаса.*

Хисләремә генә ут кабынган,
Кан тимәгән күлмәк тәнемдә.
Күрәләтә сөю кылычына
Башын куйган Таһир хәлендә,

Иелдем дә алдым илем ташын
Җаным җәйли торган җәйләүдән.
Тау булгандыр, бәлки... нәни генә
Бер тылсымлы затка әйләнгән.

Ни булганбыз элек Галәмдә без,
Кем булганбыз — дусмы, көндәшме?..
Таш сүземне сабыр гына бүлеп,
Тик мин аңлар телдә эндәште:

— Йә, сиңа бәхет кирәкме?—
Таш өстенә яшең тамсын,
каның тамсын —
үсеп чыгар.

— Сиңа мәхәббәт кирәкме?—
Дөрлә, дөрлә... таш эресен,
таш эресен —
каршы чыгар.

— Йә, озын гомер кирәкме?—
Бер ташыңны дошман алса,
кол ясаса —
кылыч чыгар!

Алга, алга! Гомер — алда.
Йөрәк чыдар,
йөрәк чыдар...

Тау — бер ташка әверелгән чакта,
Авырлыгын кая аткандыр;
Үзең тамчы-тамчы таралсаң да,
Кешеләрне табып шатландыр.

Бергә таралыйк, таш: вак-вак ватып,
Мин һәркемгә бирим өлешен,—
Яуган яңгыр кебек тигез иңсен
Кешеләргә кылган бу эшем.

Бер кисәген салам үз иленнән
Хәер сораучының кулына.

Әйтеп салам: менә шушы таштан
Бәхетеңне тап син — шул гына!

Яңа дәверләргә атлаганда,
Кем хәленә кермәс юлдашның.—
Үзен-үзе җәлләп елаучыга
Бер кисәген бирәм бу ташның

Әйтеп бирәм:
— Кешедәге көчне
Куркаклыгың белән каплама,—
Хәрәкәттә генә саклана ул,
Ул — мәңгелек тере тантана!

Кулларыңа бирәм.
Башка бәргән
Ташлардан да кеше юл сала.
Һәм исбатлый: киләчәккә барып
Була икән ташлар яуса да...

* * *

Әле кичә генә Адаш абый [1]:
— Сөйләт,— диде,— серен ташларның.
Алар белә, белә күптән,— диде,—
Ни күргәнен безнең башларның.

Үзеңнеке булгач, таш та җылы,
Кулың туңган — җылыт әле,— ди.
Хәйләкәр ул абый,— ташлар аша
Минем ятим җанны иркәли.

— «Аш белән бәр», диләр. Тыңлама,— ди.
Таш белән бәр — әгәр тисәләр.
Аш белән күп бәрдек,
Ә барыбер
Тамырыңнан сине кисәләр...

Андыйларга мин тау белән бәрдем:
Йортлар салдым — белдем китәсен!
Табан астындагы җирдән кояш
Хет бер гөлне күккә күтәрсен.

Шундыйларның менә тагын берсе
Чатябышты бүген юлымда.
Нинди максат, нинди уйлар белән
Йөри икән, дисәм, ул монда...

Сорау белән килгән:
— Тау бәралгач,
Алыптан көч алып килдеңме?—
Үз илеңнән, үз телеңнән калып,
Озаграк яшәр идеңме?..

Теге ташның тагын бер кисәген
Бу адәмгә бирәм сындырып,—

---

[1] Адаш абый — атаклы төзүче, Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаров. Әлмәттә аның кул астында ташчы булып эшләдем.— Автор.

Кулга алу белән, сихерләнеп,
Тезләнә ул, жиргә баш орып.

«Мөртәт йөзен танып калыгыз»,— дип,
Яшен яктысында ялтырап
Китә дә таш... аңа җавап бирә:
— Син килдеңме бездән җан сорап?!

Алып булмый аны. Һәм шулай ук
Булмый аны сиңа биреп тә,—
Кояшта ул,
суда,
көлдә,
гөлдә —
Хәрәкәттә яши — иректә!

Комсыз тота, йота алмый аны,—
Яши-яши күчә яшьләргә...
Мөмкин түгел,
безне һәм кояшны
Өйрәтергә ничек яшәргә.

Өстәп куям: яшәп инандык без,
Үз илендә йөрәк янмаса:
Тумаска да мөмкин,
Ә тумасаң —
Үлмәскә дә мөмкин ләбаса!

## Дүртенче таш

*...Әйдә, таш, безнең кулга күч:*
*Үлемгә бәрсәң генә —*
*Сөрмә була алачаксың*
*Шагыйрьләр каләменә.*

Аяз көннәр белән бергә килде.
Күрергә дип мин дә йөгердем...
Галәм түрләреннән урап кайткан
Космонавты кебек шигырьнең,
Уртабызда калды...
Төбәлдем мин,
Чәчләренең күксел агына,—
Ул нәкъ тере Әбугалисина!
Илдә торып, илне сагына.

Бер сәфәрдә биш кыямәт кичеп,
Илем, сиңа кайтып булганын
Сагыш сихерләре ярдәмендә
Исбат итте миңа Туфаның.

Туфан килә дигәч,
Күз нурына
Коендырдык Әлмәт каласын.
Кунак булгач, әйдә, йортыбызга —
Җаныбызга кереп карасын.

Җан — азатлык таҗы!
Өйләребез —

Намустай ак Чупай ташыннан.
— Күрче,— диде,— таш гасырдан алып
Бар гүзәллек монда ташынган.

Гүзәл йөк төягән кәрваннарга
Охшатып ул һәрбер факелны,
Яшь калада йөрде, җыры белән
Яклый-яклый безнең акылны.

Урамнардан узды,
Робагыйлар
Язган сыман ап-ак ташларга.
— Яңа йортның әле түшәме юк,
Ә бит мөмкин яши башларга!

Учак кабызырга мөмкин,— диеп
Әйтте шагыйрь, сабыр сөенеп.—
Җидегәннәргә менеп җитәрсез бит,
Таш өстенә болай таш өеп...

Җитез генә җиргә иелде дә,
Уч төбенә кунды вак ташлар:
— Бер алманы бишкә бүлгән кебек,
Күрегез,— ди,— нинди охшашлар!—
«Бер алманы бишкә бүләек», дип,
Өйрәтми җыр алма бүләргә,—
Сез әзерме, диеп сорый халык,
Бер-берегез өчен үләргә...

Күккә чөйде аннан.
Ташлар җиргә
Әллә төште, әллә төшмәде?..
Минем үз тарихым: Туфан өч көн
Ташчы булып бездә эшләде.

Бәхет өчен барган көрәшләрдә
Кемнәр зирәк, кемнәр алдынгы?—
Шулар өчен Әлмәт каласында
Шигъри байрак элеп калдырды.

* * *

Әй, җирдә — чиксез Галәмнең
Шигъри йөрәгендә
Яшәгән өчен генә дә
Бәхетләр арта миндә.

Көнозын ташлар күтәреп,
Кул тала, җаным арый.
Шул чакта Казан ягыннан
Сәламли Хәсән абый.

Гүя Җир шарын тотып ул,
Мин әле күрмәгәнне
Күрсәтә:
— Күз сал, Рәшит,—
Бөреләр үлмәгәнме?

Кар өстеннән яланаяк
Тауларга менеп китеп,
Бөреләргә әфсен укыйм,
Сихерче сыман итеп.

Уйларым күбәләк булып
Куна яз гөлләренә.
Берсенең, әнә, уртада
Кан тигән күлмәгенә.

Бозлардан гына арын, җир,
Карлардан гына арын,—
Табигать исбат итәчәк
Дөньяда Туфан барын...

* * *

«Җирем — гөлләр бакчасы», дип,
Кешенең җырлаулары —
Кайчагында үзе өчен
Шатлану икән бары.

Ышанмасаң, күзләреннән
Гөлләрен алып кара,
Ә үзен, шакаллар улап,
Давыллар дулап йөргән
Далага салып кара,—
Куркудан елар. Гөлләрен
Онытып, үзен уйлар.
(Ярын онытkан егеткә
Нәрсәгә кирәк туйлар?)

Ә гашыйк соңгы сулышта,
Гөлләрен барлый-барлый,
Шакалларны буып ташлар,—
Ялгызга шул да ярый.

Ерткычны буып үтерү —
Ярты егетлек кенә.
Туфан кук, туган телеңә
Кайтып җит әле менә!

* * *

Туган җир — ташлар бакчасы.
Бу ташым — яшен ташы.
Дүртенче ташым! Әйдә, бер
Сөйләшик кара-каршы.

Таш җавап бирә:
— Елларны
Уздырдым әрәм генә,—
Сөрмә буласы таш идем
Туфанның каләменә.

Язар иде минем белән:
«Үлемне бергә-бергә
Үтерегез! Бәхиллек юк,
Ярамый җиңелергә!»

Яшен ташы,
шагыйреңнең
Тавышын таныйсыңдыр,
Яманга тотып бәрергә
Син дә бит ярыйсыңдыр.

Әйдә, көч безнең кулларга!
Үлемгә бәрсәң генә —
Сөрмә була алачаксың
Шагыйрьләр каләменә...

## Бишенче таш

*...Җилләргә булсаң тамыр —*
*Алар да илдә калыр.*

Тәмамлыйм дип торганда
Җырымны —«Бишташ»ымны —
Кем кулыдыр таш атты
Тәрәзәмә... башыңны
Аерам, дип, уеңнан.
Соңга калды. Уйларым
«Бишташ»ыма уелган.

Мең валчыкка ватылды
Тәрәзәм пыяласы,—
Коштай очып, кулыма
Кунды ташның яңасы.

Күрәсезме, охшаган
Кара елан күзенә;
Тора-тора иш була
Киек болан күзенә,
Шул боланны ботарлап
Ташлар бүре күзенә...
Нигә бу таш тамчы да
Охшамый соң үзенә?

Бәрсәләр дә башыма,
Бу таш та бик кадерле.
Хак-кыйммәте бер үктер —
Тарихтамы, хәзерме?

Менә, карап торыгыз,
Күккә чөям мин аны.
Күпме биек мең#әр ул,—
Хөкемемдә калганы.

Күтәрелсә никадәр —
Нәкъ шушы биеклектә
Алтын өеп куегыз!
Ким булмасын бөртек тә...

Әнә шундый кыйммәте
Илдәге һәр ташымның.
Йә, кем ала?
Юк, бирмим!—
Уе бетәр башымның.

* * *

Йә, кем бәрде? Әллә соң
Берәр шаян баламы?
...Казанына таш салып,
Аш кайнаткан ананы
Күрүчеләр булганын
Белми әле балалар.
Калмаса бер ярмасы,
Ачлык буса баласын —
Таш кайнаткан аналар,
Аш кайнаткан аналар...

Бала бәргән булсачы?!
Кайсы ата баласы?
Ул кемнәрнең дошманы,
Кемнәрнең күз карасы?

Аңлатыр аңа дөнья:
Ташлар бәрү ни була?—
Ашка бәрү ни була,
Башка бәрү ни була?

Ни ул — ташка табыну,
Ни була — таш ябыну?
Үз ташыңа абыну —
Үз башыңа абыну...

Һәм таш бәреп бу Җирне
Җимереп тә булганын,
Үтереп тә булганын,
Кешене — үз туганын.

...Ул әле килә генә,
Ул әле көлә генә,—
Ә сөю кереп җиткән
Җыр булып йөрәгенә.

*— Әй, илләрем, илләрем,*
*Давылларым, җилләрем!*
*Җилләргә булсаң тамыр,*
*Алар да илдә калыр.*
*Илдә калырлар иде,*
*Яфрак ярырлар иде...*

## Поэма белән саубуллашу

Җан — синеке, Яшәү!
Сабый чактан
Таш өстендә чәчәк булырга
Өйрәттең дә... чиксезлегең хәзер
Ни хыялга сыймый, ни уйга.

Син бәйләдең җанга, җырга керттең
Һәр бөрене, һәрбер тамырны.
Төн буена җирем чәчәк ата,—
Иртәгәсен кояш танырмы?

Үзенекен кояш онытмый ул:
Тау астында үскән талын да,
Тора-тора, инде таш урманга
Әверелгән агачларын да.

Хәзер беркем балта чаба алмый —
Җәзалардан азат алары.
Тик, «Ни күрер башлар», дигән сыман
Шомланалар дәрья таллары...

«Ни булса да,
Җирне минем хәлгә
Калдырмагыз,— дидер таш агач,—
Дар агачы кебек торам менә,
Сандугачлар килеп кунмагач...»

Күктән безне ай-йолдызлар күзли:
Һәрбер йөрәк — сихри бер учак!..
Раслый алам: алар җылысында
Таш агач та яфрак ярачак.

Йомышлары төшкәч, дуслар эзли:
«Син кайда соң?»,— диләр. Ишетәм.
Тик күрешер көннәр — таш агачка
Сандугачлар кунар көн икән...

Ташлар булып суга батмадым мин,—
Ага-ага кайттым яңадан;
Ташлар булып җирдә катмадым мин,
Каным саркып торгач ярадан.

Яратырга соңармадым. Җанда
Йолдызлардан яуган сагыш бар.
Ә җырларым минем — каным тамган
Таш өстеннән җыйган табышлар.

Васыяте шулай юлда йөртә
Утларда күп янган нәселнең,—
Сайладым мин кипкән иреннәргә
Су тигереп китү кәсебен.

Халкым иген иккән кырда йөрим,
Сайламыймын урын биектән.
Болыннарда сандугачлар белән
Сайрашырга җаным күнеккән.

Шушы болыннарда
Үз халкыннан
Аерылган күпме батырны
Сандугачның моңлы фәлсәфәсе
Кызганмыйча ташка катырды...

Кулларымда һаман ташлар уйный.
Кемнеңдер тик йөзек кашында
Балкып китә ташы,
сөйләгәндә
Моңнан килгән «зарар» хакында.

Ул сөйли.
Мин йөзек кашын тыңлыйм:

«...«Туган тел»гә кемнәр ташлана,—
Алар өчен җирдә мәсхәрәле
Җиңелүләр шуннан башлана...»

Бу сүзләрне үзем дәвам итеп,
Таш күңелләр эрер моң кушам.
Ачык итеп йолдызларга сөйлим,
Балкый-балкый гүзәл сагыштан.

Хак-табигать белән бертугандыр
Иманыбыз безнең, телебез.
Бер балкыштан!.. Димәк, чордан-чорга
Яшәүләрне яклап йөрербез.

Шуны сөйли-сөйли кар яуса да,
Яшел яфрак куна куакка...
«Яфрак-яфрак» бомба яудырсалар —
Җил тилмерер сыңар яфракка.

Җирне шушы соңгы хәсрәтеннән
Арындырмый калмас моңнарым...
(Илгә булмастайны —
беркайчан да
Мин каныма манып тормадым).

Китәм
Җирнең суларыннан — сулыш,
Утларыннан сагыш алырга.
Тамчы-тамчы тамып күлләренә,
Күккә менеп яфрак ярырга!

Җимереп тә бармыйм,
җиңелеп тә,
Җиңел узмыйм чорны җай табып.
Туры атлыйм. Җирләр тетрәгәндә
Китсәм-китәм бераз чайкалып.

*Ә Иделләр ага илләр буйлап,—*
*Рухи Кораб иңли киңлекне...*
*Янмый калганнарын суга сала*
*Кемдер көчләп таккан кимлекнең.*

*Ташлы таулар югарыдан торып,*
*Иңдерәләр җанга зурлыкны.*
*Халкым башы түгел,*
*хәтта җирнең*
*Ташы күтәралмый хурлыкны.*

*Бездә яши шундый бер өстенлек:*
*Уттан алда мөмкин балкырга.*
*Бөек халкым — давыл кочагында,*
*Минем җаным шунда — Халкымда!*

*Кулларымда һаман ташлар уйный...*

.................

## Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

Сугыштан соң, илленче еллардан башлап, Дәүләкәнгә еш кайтып йөрсәм дә, «Ачлы күл»гә бер генә тапкыр да барып чыгарга туры килмәде. Теләк, әлбәттә, бар иде, күрәсем бик килә иде, ләкин ул теләкне берничек тә гамәлгә ашырып булмады (транспорт юк, җәяү барырга ерак, ә җигәкчеләрдән сорарга кыюлык җитмәде). Кайткан саен шулай, фарыз эшне үти алмагандай, китек күңел белән китеп барырга туры килә иде... Ә еллар һаман уза торды, «Ачлы» үзе дә миннән гүя ераклаша барды, кайтып күрә алуыма өмит тә бетә язган иде. Әмма безнең бу «Жигули»лар заманында еллар буенча үтәлмәгән теләгең бер көн, бер сәгать эчендә дә үтәлергә мөмкин икән. 1983 елның август урталарында авылдашым профессор Сөләйман Еникеев миңа шалтыратты: «Әмирхан, без иртәгә өч кеше минем машинада Уфага чыгып китәбез, теләсәң, сине дә алабыз»,— диде ул.

Шунда ук минем телемә, моңарчы йоклап яткан уйны кемдер төртеп уяткандай, үзеннән-үзе бер сорау килде:

— Ә «Ачлы күл»гә тиябезме?

— Әбәзәтелне! — диде Сөләйман.

Һәм шулай итеп, икенче көннең иртәсендә, без дүрт Каргалы төмәне, Жигули машинасында Уфага табан чыгып та киттек. Баручыларның миннән кала берсе Сөләйманның якын дәдәсе (аталары бертуган) Рәүф абзый, икенчесе Сөләйманның бертуган энесе, күптән түгел гарәп илләреннән кайткан инженер Фәрит иде. Машинаны да бик җилле генә ул алып бара. Юлыбыз — Чистай, Әлмәт, Бөгелмә аша. Артык кызу чапмадык, урман ышыгында туктап, ял да иттек, Чистай белән Бөгелмәне дә карап уздык.

...Хәзер инде юлыбыз — туп-туры «Ачлы күл»гә... Хәер, юл үзе бик турыдан түгел иде, Бүздәк аша шактый урап барырга туры килде. Төш вакыты якынлашканда гына «Ачлы» буйларына барып чыктык. Ләкин Сөләйманның башта Кыдырач авылына керәсе килде — малай чагында атасы белән шул авылда булгалаган икән. Ярый, малайчак хакына без риза, бәлки анда кымыз да булмасмы әле... Киттек Кыдырачка... Ул «Ачлы»дан 5—6 чакрым читтә иде. Урманлы тау буена утырган урта зурлыктагы башкорт авылы. Киң генә урамыннан карана-карана барып, ахырда колхоз идарәсе каршына туктадык. Сөләйман килеп йөргән чакларда атасының монда якын танышлары булган, хәзер инде алар юк... Бердәнбер сугыла торган капка — ул да булса колхоз идарәсе... Кердек, исәнләштек, кемнәр икәнебезне әйттек. Колхоз председателе үзе юк иде, ләкин телефон белән эзләп таптылар —озакламый килеп тә җитте. Кул биреп таныштык. Безнең Казан чаклы ерак җирдән килеп чыккан кешеләр булуыбыз аны бераз аптырашта калдырды шикелле. Ләкин, әзрәк сөйләшеп, безнең дә шушы якларда туып-үскән кешеләр икәнебезне белгәч, ул, ниһаять, тынычланды, хәтта беркадәр ачылып та китте. Сәрвәр Әюпов фамилияле бу сабыр-басынкы гына егет үзе дә бирегә председатель булып, Дәүләкәнгә якын гына Исмәгыйль авылыннан килгән икән. Мин дә бит инде Дәүләкәннеке — шулай итеп, без якташлар да булып чыктык.

---

Ахыры. Башы 3 нче санда.

Аның колхозына, Кыдырачтан башка, «Ачлы»га якын тагын берничә авыл керә икән — шуңа күрә колхозның исемен дә «Ачлы күл» (башкортча «Аслы күл») дип калдырганнар. Һәм бик дөрес эшләгәннәр. Халык телендә борыннан яшәп килгән, жире-суы белән бәйләнгән матур исемнәрне колхозга биреп саклау,— миңа калса, күркәм эш. Туган-үскән илгә хөрмәтне дә көчәйтә ул.

Кызу эш өсте булуга карамастан, Әюпов иптәш вакытын бездән кызганмады. Кырлар буйлап чабудан туктамаган үз машинасына мине һәм Сөләйманны утыртып, «Жигули»ны исә артыннан иярте̄п, безне «Ачлы күл»гә алып китте. Авыл читендәге кымызчылар өеннән зур гына савытка кымыз да салдырып чыкты. Борылмалы юллардан барып, «Буранғол»ны да үткәч, безне «Нора» тавына алып менде... Менә сиңа «Ачлы күл»!.. Ачлыкай!.. «Нора» өстеннән бөтен иңе-буе белән күренеп ята. Әнә бер башы, әнә икенче башы, әнә нәкъ каршыда, моннан илле жиде ел элек килеп, безнең «сәхрә кылып» яткан урыннарыбыз... Күл читендәге зур, кызыл ташлары да ята икән әле... Мин үзем — хискә тиз бирелүчән кеше, хыялымнан бер вакытта да чыкмаган шушы жиргә ашкынып килдем, әмма ни гажәп: мин тыныч, мин берни дә кичермим, мин тик искә генә төшерергә тырышам. Ничек аңларга мондый хәлне?.. Артык күп еллар үтеп китү моңа сәбәп микәнни, шуның аркасында үзеңнең үткәнеңә битараф калып була микәнни?.. Ераклашу һәм ятлашу шушымыни инде ул... картлык галәмәте?!

Әйе, каршымдагы «Ачлы» — шул ук «Ачлы», зураймаган да, кечерәймәгән дә кебек, тик көне бүген жилле булганга күрә, күл өсте жыерчыкланып, караңгыланыбрак тора. Шулай да мин аңарда шактый зур үзгәреш күрдем: кайчандыр таш табактагы су шикелле чип-чиста күлнең хәзер күп кенә жирен камыш басып киткән... Кайдан бу камыш, сәбәп нәрсәдә?.. Элекке заманда «Ачлы» әйләнәсендәге жирләрнең төрән кермәгән чирәмлек булуын әйткән идем бугай. Безнең заманда исә ул чирәм жирләрне чәчү кырларына әйләндергәннәр. Ел да сөрәләр, ел да нидер чәчәләр һәм ел да кар, яңгыр сулары сөрелгән жирнең туфрагын күлгә агызып төшерә. Менә шуңардан күлдә камыш, күлдә ләм, һәм табадай төбе дә аның баткакка әйләнеп бара торгандыр. Күл өчен бу зарарлымы? Камышлар, ләмнәр һаман шулай баса барса, «Ачлы»дан нәрсә калыр? Элек бит «Ачлы» чисталыгы белән дан тота иде, шифалы санала иде. Халык сихәт теләп, аның комында күмелеп ятарга, суында коенырга килә иде...

«Нора» өстендә Кыдырач кымызын да эчтек, Сөләйманның энесе безне фотога да төшерде — инде кузгалырга да ярый иде (председательнең вакыты белән исәпләшмичә булмый). Ләкин «Ачлы»дан тиз генә аерылып та китәсе килми, бигрәк тә аргы якны бер әйләнәсе килә иде. Шунда бит инде күл буеның иң матур урыннары... Кайчандыр йөргән, таптаган жирләр... Әюпов туган, минем теләкне сизгәндәй, безгә шул яктагы ял базасында кунып китәргә тәкъдим итте. «Алай буламы соң?» — дип сорагач, ул кыска гына итеп: «Эшлибез аны»,— диде. Без бер-беребезгә караштык та риза булдык.

Базаның директоры Дәүләкән кешесе икән — Әюпов безне менә шуңа ерактан килгән кунаклар итеп тапшырды. Директор безне ике катлы йортның югарыдагы ике бүлмәсенә урнаштырды. Шунда ук ашау-эчү дә тәкъдим ителде. Ләкин без башта чыгып, йөреп кайтырга булдык.

Базаның урнашкан жире, өч ягын да тау әйләндереп алган, ачык ягы «Ачлы»га карап торган зур бер аланлык иде. Тау буйларында куе агачлык, ачыграк урыннарда билдән куе үлән, тик аланлыкның урта бер жире генә яшел чирәм. Без менә шул чирәмдәге сукмактан күлнең ярына килдек, уңайлырак жиреннән су читенә — комлыкка да төштек.

Бу инде «Ачлы» үзе, аның борын-борыннан ук кошларны, жәнлекләрне, кешеләрне үзенә тартып торган көмештәй саф суы. Ялкау гына чайкалып, читендәге комлыкны «ялап» ята... Керәп карыйсы иде бит, теге еллардагы кебек колач салып, бер иңлисе иде бит!.. Дәрт сүнүен сүнмәгән дә, тик дәрманны кайдан алырга?.. Юлдашларга карыйм, Рәүф абзый белән Сөләйманның керергә исәпләре юк, куркалар... Ә менә Сөләйманның энесе Фәрит чишенде һәм кереп тә китте. Салкынмы, тирәнме дип тә тормады егет!.. Юк, болай булгач, миңа да куркып тору оят. Бер яшьлектә, бер картлыкта — тапшырдык!..

...Чишенеп керүгә, «Ачлы» өтеп алгандай итте. Бер-ике тапкыр чумып, чиркануны качыргач кына йөзеп киттем. Ничава, түзәрлек. Суы шундый ук чиста да, йомшак та икән, йөзүе дә ничектер жиңел һәм рәхәт!.. Әйләнеп килеп баскан идем, төбе дә тап-такыр. Моннан ярты гасыр элек тә шулай түгел идеме соң?! Юк, тиз генә бирешмәс әле бу асыл күл, борынгы сафлыгы, чисталыгы, экиятләре белән сакланыр әле ул! Көче-кодрәте зур аның, тик кеше дигәнең кадерен генә белсен иде!

...Сулар кереп, чистарып-жиңeлаеп кайтуыбызга мул табын әзер иде. Безне ике чибәр татар кызы кунак иттеләр. Казаннан ук килүебезне белгәнгә күрәдер инде, үзләренчә чын хөрмәт күрсәтергә тырыштылар...

Бу сәфәр, әйткәнемчә, 1983 елның августында булды. Сез, хөрмәтле укучым, бәлки игътибар да иткәнсездер инде — минем кайчандыр булып киткән җирләремә әйләнеп кайтуым яки кайчандыр миңа якын булган кешеләр белән яңадан очрашуым 40—50 еллардан соң гына кабатлана. Ни өчен бу чаклы күп еллар узгач кына дип гаҗәпләнергә мөмкин... Мин менә хәзер шуның сәбәпләрен ачмакчы булам. Бу исә шушы озын язманың иң җитди ноктасына җиттем дигән сүз.

* * *

Вакыт — рәхимсез, сиздермичә генә үтүен белә. Инде август аена да кердек. Дим буйларының иң киеренке һәм иң көчелле зур эше — печән өсте дә үтеп китте. Киң тугайлар печән кибәннәре белән чуарланды. Аларга карагач, ничектер ямансу-моңсу да һәм... җанга җиңел дә булып китә. Ямансу, чөнки кадерле җәй үтеп бара, җанга җиңел, чөнки күз алдында әнә нинди муллык!.. Моны күрмичә һәм моңа сөенмичә мөмкин түгел. Чәчәкле, хуш исле болын үләнен ашаган сыерларның сөте нинди куе, сарыкларның ите нинди тәмле, атларның көчелләре нинди көр булачак! Мин — Дим буеның ризыкларын татып калган кеше, тәме-ләззәте әле дә онытылмый кебек, шуңадыр инде су буендагы болыннар миңа бик якын да һәм бик кызганыч та!

...Үтте, сизелмичә дә калды, менә китәр көннәребез дә җитте. Фәтхелислам белән Хәбибрахман үзләренең уку йортларына кайтырга тиешләр, минем өчен исә ул мәҗбүри түгел. Мин — ирекле кеше, расчет алып кайткан кеше, миңа китмәскә дә була яки теләсәм кайсы якка чыгып китә алам. Әмма мин, студент шикелле үк, Казанга ашкынам, Казансыз мин инде тора алмыйм, язмышым минем шунда, күрәчәкләрем мине шунда тарта. Әлбәттә, ап-ачык максатым бар: мин быел, һичшиксез, берәр уку йортына керергә тиешмен. Башкача ярамый, башкача мөмкин түгел, хәтта әдәбиятка керү дә минем өчен ул хәтле үк зарури түгел. Дөрес, язучы булу хыялы миндә яши, әмма аның өчен дә бит белем алу кирәк.

Безне адәм иткән — уку,
Адәмне алга илткән — уку,
Илтеп күккә җиткән — уку,
Уку, уку, уку,

— ди бит әнә Сәгыйт абзый Рәмиев тә!..

Кыскасы, без яңадан Казанга юл тоттык. Әйтергә кирәк, былтыр гына әле Казан каласы күпләр өчен әллә кайда бик еракта кебек иде, чакырып-дәшеп тә, берәүне дә кузгатып булмый иде, быел исә, Шәвәлидән күрмәле дигәндәй, безнең арттан шактый гына яшьләр иярделәр (бүтәннәр салган сукмактан атлавы җиңелрәктер ахрысы). Шулар арасында Казак Усман да бар иде. Без бер-беребезне бик аз белә идек, Дәүләкән кебек кечкенә җирдә торсак та, юньләп аралашканыбыз юк иде. Ләкин нindидер бер эчке сизенү белән мин аның миңа начар караганын тоеп йөри идем. Һәрхәлдә, мин аңардан яхшылык көтми идем... Төрле вакыттарак килеп, уку йортларының бусагаларын тап-тап йөри торгач, кызларыбыз белән егетләребезнең кайберләре Татрабфакка, кайберләре исә Педтехникумга кергәннәр. Ә Казак Усман туп-туры Совпартшколага барып кергән дип ишеттек. Ул — Дәүләкәннең «карт» комсомолы, ихтимал, «направление» белән килгәндер дә... Гомумән, социаль чыгышы әйбәтләргә һәм комсомолларга укырга керүе ул чакларда бик җиңел иде.

Минем укырга керү мәсьәләсе шактый ук катлаулы иде. Вузга мин керә алмыйм, чөнки урта белемем юк. Димәк, башта урта белем алырга кирәк. Моның өчен нинди уку йортын сайларга?.. Аның әле стипендиясе белән торыр җире булуы да минем өчен бик мөһим, чөнки өйдән миңа ерак калада яшәрлек ярдәм булмаячак — мин моны белеп үк килдем.

Казанда ул елларда эшче-крестьян яшьләренә махсус урта белем бирә

торган ике зур уку йорты бар иде. Берсе аның Татрабфак, икенчесе — университет каршындагы Госрабфак (ягъни дәүләт рабфагы)... Уйлап тордым-тордым да менә шушы Госрабфак дигәненә сугылып карарга булдым. Социаль чыгыш ягыннан минем анда үтүем икеле иде. Шулай да, формаль яктан караганда, үтәргә дә тиеш кебекмен. Кулымда атайның кустарь булуы турында белешмә бар — сатуын ул 25 елның язында ук ташлаган иде. Ә дөньяга килгән чагымда, атам-анам авылда торганнар, чын крестьян булганнар — димәк, чыгыш ягыннан да туры килә дигән сүз... Шул рәвештә, мин крестьян гаиләсендә туган кустарь баласы буларак рабфакка үттем. Бу бит 1926 ел иде, чыгыш мәсьәләсендә артык төпчену булмагандыр ахрысы, чөнки ул елны мулла, сәүдәгәр балаларыннан төрле уку йортларына керүчеләр аз булмады. Социаль чыгышка аеруча әһәмият бирү, каты таләп кую һәм яшереп кергәннәрне куплап сөрү бераз соңрак, 1927—1928 елларда башланды. Бу «кызык» вакытлар турында сүз булыр әле.

Ә бүгенгесе көндә мин — Госрабфак студенты!.. Казан университетының аудиторияләрендә укып йөрим. Островский урамындагы торак йорттан урын бирделәр, стипендия дә тәгаенләделәр. Күпме икәнен хәтерләмим, һәрхәлдә студентларча яшәргә житәрлек (чамалап кына тотканда) — хәзер инде «белем гранитын», тешләрне сындырмыйча, иплэп кенә кимерәсе калды. Әмма «кимерүе» жиңел түгел иде, чөнки бөтен укулар рус телендә бара, ә саладан килгән татар малайларының русчасы — үзегезгә мәгълүм инде! Хәер, мондагы укытучыларыбыз барысы да диярлек университетның үзеннән яки элекке гимназияләрдән — чәйнәп салгандай бик шәп төшендереп бирә торганнар иде.

Казанда укырга килгән татар яшьләре елдан-ел күзгә күренеп арта бара. Былтыр да аз түгел иде, быел исә аеруча күп... Кайдан гына килмәгәннәр — Себер, Урал, Донбасс, Ырынбур, Әстерхан, Саратов, Сембер, мишәр яклары Касим, Тамбов, Пензадан, кыскасы, санап та бетерерлек түгел. Әмма иң күбесе — Башкортстаннан татар һәм башкортның иң күп жиреннән. Тиз арада Казанда аларның үзләренә аерым Башземлячество дигән җәмгыятьләре дә оешты.

Хәзер инде татар яшьләре бөтен вузларда һәм техникумнарда укып йөриләр. Шулай да аларның аеруча күп тупланган берничә «ноктасы» бар иде: болар Көнчыгыш педагогия институты (ВПИ), Татрабфак, Педтехникум, Театр техникумы һәм РТЯ ягъни татар телен гамәлгә ашыру курслары (кайчагында көлеп, Рокыя курслары дип тә атыйлар иде). Боларга керүе дә жиңелрәк булгандыр, ахрысы... Укучылары да, әйтергә кирәк, бик дәртле яшьләр иде, үзләрен бик хөр тоталар, әдәби хәрәкәткә дә бик актив катнашалар иде (билгеле булганча, соңыннан язучы булып танылып китүчеләрнең бик күбесе шулар арасыннан чыкты). Бу уку йортларының кайберләрендә, мәсәлән, Татрабфак белән Педтехникумда атна саен диярлек әдәби кичәләр була торган иде. Хәзерге Фәннәр академиясе филиалының утырышлар залында үтә иде ул кичәләр (монда Татрабфак иде)... Уеннар кызып житкәч кенә залга Такташ белән Кутуй килеп керәләр — алар инде яшьләрнең кумиры, ә кумирлар, үзегез беләсез, соңгарак калып йөриләр. Шуңа күрә аларны шаулап-алкышлап каршы да алалар.

Мин монда ТКУны телгә алмадым әле. Ягъни Татар коммунистлар университетын... Заманында бу бик танылган уку йорты иде. Урнашкан жире башта Горький урамындагы хәзерге травмотология институтында булса, соңыннан Арча кырындагы элеккеге Духовная академия бинасына күчте. Укучылары да политик җәһәттән бик чарланган үткен-чая егетләр иде — шул елларның әдәби хәрәкәтендә алар бик актив роль уйнадылар.

Мине дә, билгеле, әдәбият дөньясы бик кызыксындыра иде. Укуга дигән вакытын кысып булса да әдәби кичәләргә, язучылар жыелышына йөрергә тырыша идем... Нилэр бар соң бу әдәбият дөньясында, кемнәр нәрсә эшлиләр анда?.. Сорауны болай зурдан куйгач, укучының да миннән, табигый, көлүе ихтимал. Хәлбуки, мин бит былтыр гына әдәбият дөньясының бусагасын атлаган идем — менә быел да шуны ук кабатларга туры килә әле миңа... Кыскасы, һәм ерак, һәм югары әле ул дөнья миннән!.. Нәшрият белән редакцияләрнең дә кайда икәнен юньләп белмим әле мин... Бердәнбер барып йөргән жирем — әлеге шул «яшь язучылар түгәрәге»... Һәр жыелышта диярлек Такташ, Кутуй, Нәжми, Туфан кебек, инде танылып та, шактый ук шау-шу да кузгатып өлгергән һәм популяр да булып киткән шагыйрьләр катнаша иде. Өлкән яшьтәге исемлерәк язучылар монда юньләп күренмиләр яки бик сирәк кенә килеп чыккалыйлар иде.

Быел, ягъни 1926 елның көзендә, Казанга читтән укучылар күп килгәнгә күрәдер инде, әдәбият түгәрәгендә дә шактый гына яңа кешеләр күренә баш-

лады. Аларның кайберләре яшькә миннән олырак иде бугай, ләкин, тулаем алганда, барысы да миңа тиңдәш бер чамадагы егетләр иде. Тиңдәшләр булгач, мин аларны тизрәк белергә дә тырыштым һәм, озакламый, я сорашып, я танышып, һәркайсын белдем дә диярлек. Өчесе — Башкортстаннан килгән Фатих Кәрим, Сагыйт Агиш, Мирсәй Әмир, ә берсе — Әстерхан егете Габдрахман Минский булып чыкты. Шул ук көзне булса кирәк, Гази Кашшаф (ул чакта Кашшаф Гази) белән дә таныштым, Әсгать Айдар белән Демьян Фәтхине дә күрдем. Фатих Хөсни белән соңрак очраштык шикелле... Кыскасы, таныш-белешләрем күбәйде. Мәгәр мин аларның берсе белән дә артык якынаеп китә алмадым. Бәлки, төрлебез төрле җирдә укыганга күрәдер, ә бәлки субъектив сәбәпләр дә булгандыр. Мин, мәсәлән, кешенең үзе тарафыннан әзрәк кызыксыну сизмәсәм, аңа якынаерга ничектер җөрьәт итә алмый идем... Кешеләр белән мин, гомумән, авыр танышам — бу минем күптәнге бер кимчелегем.

Тагын бер бик мөһим моментны әйтергә кирәктер: әле генә мин атаган иптәшләр барысы да диярлек әдәбиятка кыю һәм җиңел кереп киттеләр. Озак та үтми, аларның исемнәре газит-журнал битләрендә еш кына күренә башлады. Билгеле, алар талантлы егетләр иде, әмма талант өстенә башка сыйфатлары да булгандыр инде (мәсәлән, тәвәккәллек, тырышлык, үзенең көченә нык ышану кебек сыйфатлар). Аннары, рус әйткән «везение» дигән нәрсә дә бар бит әле: кайчагында кешегә бәхет капкасы ачылып кына тора!.. Менә, әйтик, Габдрахман Минский — мәһабәт, матур, ягымлы, кыланышларында әзрәк аристократлык та сизелгән Әстерхан егете — тиз арада Такташ, Кутуй, Туфан кебек авторитетлар белән якынаеп, аларның үз кешесе булып китте. Исеме дә аларныкына кушылып йөри башлады... Дөрес, яшьрәк, дәрәҗәдә түбәнрәк, әмма аңа зур киләчәк юрадылар.

Мирсәй Әмир, хикәяләр язу белән генә чикләнмичә, шулай ук бик тиз үзен әдәби хәрәкәтнең актив эшлеклесе итеп тә күрсәтә башлады. Мужикларча салмак кына, әмма туры бәреп, усал чыгышлар ясый торган иде ул... Ике Фатих — Хөсни белән Кәрим — шулай ук күзгә күренеп күтәрелә баралар. Язганнары газит-журналларда чыгып кына тора... Фатих Кәрим шуның өстенә, Минский шикелле үк, Такташ белән дә якынаерга өлгерде. Күрәсең, зур шагыйрь белән яшь шагыйрьне бер-берсенә тартканниндидер рухи уртаклык булгандыр инде.

Минем үз уңышларым исә алай мактанырлык түгел иде. Бик аз язам, дөньяга аз чыгам. Чыкканнары да — вак-төяк әйберләр генә... Миннән шагыйрь чыкмасын мин белдем инде, әмма күңел дигәненең шигырь сыманрак нәрсә язуны һаман сорап кына тора. Мондый хәл, әлбәттә, минем яшьлегем белән бәйләнгән булырга тиеш. Ул заманда безнең әдәбиятта «нәсер» дигән бер жанр яшәп килә иде (ак шигырь дә диләр аны). Минем әле «Аң» журналында бу нәсерләрне укыганым да бар иде. Соңгы елларда бездә аның зур остасы булып Мәхмүд Максуд абый танылды... Нигә миңа да үземне шул «нәсер»дә сынап карамаска?! Чәчмә сүзгә сәләтем бар кебек, әнә «Озын көй тыңлаганда» дип аталган һәм «Безнең юл»да басылган беренче әйберем дә нәсер иде бит... Һәм мин ул нәсерләрне язгалап карадым, аларның кайберләре шул ук журналда басылып та чыктылар. Ләкин берәүнең дә игътибарын үзләренә юньләп җәлеп итмәделәр бугай... Чынлап та, күләмнәре белән бик кечкенәләр, мәгънә ягыннан да сайлар, кыскасы, шома гына язылган вак кына әдәби парчалар. Бәлки аларның зур журналга үтүе дә шул «шома» теле аркасында гына булгандыр... «Телең бар»,— дип әйтә торганнар иде миңа әдәбияттагы таныш-белешләр дә...

Әмма, юк, нәсер белән генә ерак китеп булмаячак иде. Җитди прозага тотынган чагында гына, берәр төрле хикмәт килеп чыгуы мөмкин иде. Мин моны үзем дә аңлыйм кебек. тик менә зур эшкә ничек итеп тотынырга гына белмим... Беренче кышта моңа, билгеле, уку да комачаулык иткәндер — дәресләр күп, укуы шактый авыр, таләпләр дә зур иде. Миңа бигрәк тә укудан артта калырга ярамый иде... Бусы тышкы сәбәп, әмма бик җитди эчке сәбәп тә бар иде. Нәрсә турында, ничек итеп язарга — менә иң төп сәбәп, миңа калса, шушы сорауда иде бугай... Дөрес, бу — һәрбер язучы алдында торган гомерлек сорау, иллә мәгәр ул сорау минем алдыма башта ук ничектер аеруча җитдиүткен булып килеп басты. Әйе, башта ук мин бер нәрсәне аңлагандай булдым: мин ияреп кенә яза алмыйм икән, миңа үземнекен табарга һәм үзем хис иткәнчә язарга кирәк икән. Ә заман бик катлаулы, мин әле яшь, тәҗрибәсез, тынгысыз дөньяга яңа чыгып кына киләм — билгеле инде, миңа «үземне табу» бер дә ансат булмады. Бик озакка сузылды ул аптырап эзләнүләр...

Язу эше кешенең характеры белән дә, шәхси язмышы белән дә һәм заман шартлары белән дә бик тыгыз бәйләнгән. Характерымны хәзергә әйтеп тормыйм,

ә менә язмыш белән шартлар турында сөйләмичә булмый (бу ике нәрсәнең бер-берсеннән аерылгысыз булуы аңлашылса кирәк)... Әлбәттә, мин үзем кичергән, үземә кагылган кадәресен генә сөйләячәкмен.

Казанга килеп торган шушы ел ярым-ике ел эчендә миңа нәрсә ачылды, нәрсә күрдем мин? Барысыннан да элек, революциянең дәвам итүен күрдем дип әйтер идем (яки тойдым дип). Әйе, ихлас, Октябрьдә башланган революциянең бездә һич туктаганы юк икән, хәзер ул иске дөньяны тәмам бетереп, яңасын кору өчен дәвам итә һәм итәчәк икән... Нэп дигән нәрсә ул кыска гына чигенү, вакытлы гына тынып тору булган, имеш! Аның шулай буласын башта ук сизәргә мөмкин иде инде, чөнки иске дөньяга нәфрәт, ачу нэп вакытында да бетеп тормады. Әзрәк йомшарып, тыныбрак торган чагы, бәлки, булгандыр, иллә мәгәр тиз арада ул яңадан көчәя башлады... Революциянең максаты изге — сыйныфларны бетерү юлы белән, башта социализм, аннары коммунизм төзү... Ә моның өчен бөтен иске дөнья калдыкларына, барлык эксплуататор сыйныфларга каршы рәхимсез каты һөҗүм алып барырга кирәк диләр. Һәм бу һөҗүм — иҗтимагый тормышта булсын, идеология фронтында булсын, шул җөмләдән әдәбият өлкәсендә дә бик тиз җәелә һәм отыры көчәя бара иде. Әдәбиятта әле ул һөҗүм үзен аеруча нык сиздерә башлады — без моны Фатих Әмирханны җирләгән чакта ук инде күреп уздырган идек.

Кыскасы, минем, Казанга килеп, укый һәм язгалый башлаган чагым әнә шундый хәтәр бер вакытка туры килде. Хәтәр дим, чөнки бөтен фронт буйлап көчәя барган һөҗүмнең миңа да китереп бәрүе мөмкин иде. Иң элек, билгеле, чыгыш ягыннан... Социаль чыгыш өчен укудан куып чыгарулар башланган иде инде... Гадәттә, бу фаш итү юлы белән эшләнә иде. Фәлән Фәләнов мулла яки сәүдәгәр малае дип язып бирсәләр, артык тикшереп тормастан, куалар да чыгаралар. Эш шуңа кадәр барып җитте ки, кайбер мулла малайлары, үзләренә шик-шөбһә төшмәсен өчен, бүтәннәр өстеннән әләк язып бирә башладылар. Әләккә теләсә нәрсә язып була, шуңа күрә ул әләк дип атала да. Бу очракта инде синең укырга бик сәләтле булуың да, җәмгыятькә файдалы кеше булырга теләвең дә коткара алмый.

Социаль чыгыш мәсьәләсе ул елларда шундый зур бер әһәмияткә ия булган, күрәсең, хәтта газит-журнал битләрендә шигырь бастырган кайбер яшьләр имзаларыннан соң «ярлы баласы» яки «эшче баласы» дип тә өстәп куялар иде. Мәгәр алар арасында да алдашучылар булган икән. Бервакытны минем Ярми дустым (былтыр «Шәрык» китапханәсендә танышкан егетем) журналда чыккан шигырь астындагы «ярлы баласы» дигән сүзнең «ярлы»сын сызды да өстенә «кулак» дип язып куйды. Мин гаҗәпләнеп: «Нигә алай итәсең?» — дип сорагач, ул тыныч кына: «Беләм мин ул малайны, безнең күрше авылдан, атасы настоящий кулак!» — дигән иде.

Әйткәнемчә, «фаш ителү» куркынычы минем өчен дә бар иде. Чыгыш мәсьәләсендә хәзер ташлама юк. Әгәр берәрсе минем атайның кайчандыр аяк өсте булса да сату итеп йөрүен куертып язса, шул инде җиткән, рабфак белән бәхилләшергә туры киләчәк. Хәзерге көндә атам бит сату итми, кустарьчылык белән шөгыльләнә дип акланып маташу да ярдәм итмәячәк.

Былтыр һәм быел Казанга укырга килгән Дәүләкән яшьләренең миңа мөнәсәбәтләре төрлечә. Берәүләрнең бик яхшы, икенчеләрнең яхшы да, начар да түгел, ә кайберләрнеке коры-салкын гына... Шулай булуы бик табигый — адәмнәр арасында мөнәсәбәтләрнең беркайчан да бер төрле генә була алганы юк әле. Кыскасы, алар арасында миңа хәерхаһлары булган шикелле, һичшиксез, кырын караучылары да булырга тиеш иде. Бу соңгылары арасыннан, әйткән дә идем бугай, минем өчен аеруча хәтәре — ул да булса Казак Усман иде.

Хәлбуки, без бер-беребезне бик аз белә идек. Бер үк Дәүләкәндә үскән малайлар булсак та, мин, мәсәлән, аның атасы кем булуын да, кайда торуларын да ачык кына белми идем. Мәктәптә укыганда да, җәйләрен уйнап йөргәндә дә, үсә төшеп, концерт-спектакльләргә катнашкан чакларда да миңа аны күрергә дә, аның белән аралашырга да туры килмәде.

Казак Усманны якыннанрак белгән иптәшләр аны бик һавалы-коры кеше диләр иде. Миңа исә аның белән бары Казанда гына әзрәк очрашырга туры килде. Бер тапкыр, кемгәдер ияреп, аңа барып та чыккан идем. Әйе, чынлап та, егет үзен эре һәм горур тота белә икән шул... Кыяфәт тә шундыйрак — житди чырай, салкын күзләр... Әмма мине аның бер кителмәгән сыйфаты бик гаҗәпләндергән иде: ул, баксаң, Чехов хикәясендәге табут ясучы Яков кебек, скрипкада уйный икән ләбаса! Хәер, ул үзе башлап бу хакта бер сүз дә әйтмәде. Тик китәр алдыннан, мин стенада эленеп торган скрипканы күреп: «Бу кемнеке, кем уйный?» — дип сорагач кына, Казак Усман гади бер нәрсә турында әйт-

кәндәй: «Мин уйныйм!» — дип кенә куйды (менә сиңа коры кеше!). Кызганычка каршы, уйнаганын ишетергә туры килмәде, чөнки ул үзе андый теләк сиздермәде, һәм без дә, ни өчендер, үтенеп сорап тормадык. Электән килгән табигый якынлык булмагач, коры сөйләшеп утыру белән генә чикләндек тә чыгып киттек.

Мондый очрашудан соң миндә икеләнү, ике төрле уйлау ирексездән башлана иде. Бердән, Казак Усманга ышанмавым, миңа каршы ни дә булса эшләр дигән шигем, үзеннән-үзе көчәя иде кебек: икенчедән, үзе ул, очрашканда, начар карашын бирничек тә сиздермәгәч, яхшы ук тынычланган кебек тә була идем. «Чынлап та,— дип уйлый идем мин,— ни өчен әле ул миңа каныгырга тиеш?! Әллә минем атайның таш магазиннар тотмаганын белмиме ул. Казак Усман шулай ук Дәүләкән егете?! Монда әле чыгышлары белән миннән «зурраклар» да укып яталар, ә минем хакым булмасын, имеш!..»

Әнә шулай ачынып уйлый идем мин, һәрбер адәм баласы шикелле, тискәре якны киметебрәк, уңай якны исә арттырыбрак...

Хәлбуки, ай артыннан ай уза, укулар әйбәт кенә бара, ахырда кышкы каникул да килеп җитә. Без әле, мондагы авылдашлар, каникул вакытында Дәүләкәнебезгә кайтып, атна-ун көн буена уеннар, кичәләр үткәреп, дөньясын шаулатып та киттек (һаҗәр белән беренче мәртәбә кинога баруым да шул чакта булды). Казанга кайту белән, тагын студент тормышы, тагын укулар башланды. Инде җылы язга да күп калмады... Уку елының ахырына якынлашабыз, бәлки, тынычланырга да вакыттыр, онытырга, һәртөрле шик-шөбһәләрне күңелдән чыгарып ташларга?! Әмма... юк, тынычланырга иртәрәк булган икән әле. Көннәрдән беркөнне торак йорттагы бүлмәгә кайтып керсәм, минем караваттагы мендәр өстендә записка ята. Кулга алу белән, белдем — Казак Усманнан!.. Минем исемне «Әмир» дип түгел, «Амир» дип куйган (дәшкәндә дә ул шулай русчалап: «Амир»,— дип дәшә торган иде). Кызык, нинди йомышы төште икән минем бүлмәгә беренче мәртәбә аяк баскан бу бик «важный» иптәшнең?.. Хәер, мин шулай уйлап алганчы, кыска гына язманы бер күз ташлау белән укып та чыктым. Анда болай дип язылган иде: «Амир, син рабфактан үзең чыгып китмәсәң, без сине кудырабыз, учти шуны!» Имза юк, билгеле, кирәге дә юк. Аңладык, төшендек... Шулай да мин бүлмәдәш иптәштән: «Кемнәр килгән иде»,— дип сораган булдым. Ул: «Ике егет килгән иде,— диде,— берсе кәкрерәк борынлы, ак чырайлы, икенчесе арык кына, кара чәчле».— дип тә өстәде... Билгеле инде, аксылы — Казак Усман, карасы — һәрвакыт аңа тагылып йөрүче Хәйдәр... Бу егет миңа күптән таныш, кайчандыр бергә мәдрәсәдә дә укып йөрдек, үткән көз генә, безгә ияреп килеп, Татрабфакка керде, ләкин укуының рәте-юне булмагандыр, чөнки электән үк кемгә дә булса ияреп йөрергә гадәтләнгән бер ялкау иде. Менә бит монда да тапкан ияртүчене — алгы тәгәрмәч кайдан барса, арткысы да шуннан барачак, әлбәттә.

...Алай, мәсьәлә ачык. Егетләр миңа ультиматум куйганнар: рабфактан табаныңны ялтырат!.. Бу нәкъ Казак Усманча: башта үзенең өстенлеген, көчен күрсәтергә теләгән ул!.. Яшерен донос язып бирүгә караганда, бу әйбәтрәк тә түгелме соң әле?!. Миңа уйларга вакыт бирә, үз иркем белән чыгып китәргә мөмкинлек бирә! Бу бит әле үзенә күрә олы җанлылык күрсәтү дә, шайтан алгыры!.. Молодец, Казак!.. Синең миңа укырга ирек бирмәсеңне мин күптән белеп тордым, әмма менә болай эшләвең өчен хәтта рәхмәт тә әйтергә була!

Әйе, мин артык борчылмадым, записканы тагын бер кат укыдым да ертып ташладым... һәм, бер дә баш ватып тормыйча, укуны хәзергә дәвам итәргә булдым. Ультиматумның срогы юк бит, нигә ашыгырга?.. Казак Усманга бит мине үз ихтыярына буйсындыру мөһимрәк, бәлки әле, каршына барып, минем ялваруымны да көтә торгандыр... Анысы булмаячак, әлбәттә, ә рабфактан чыгу-чыкмау мәсьәләсен мин үзем хәл итәчәкмен.

Укуларны дәвам иттерергә күп калмаган иде. Тагын ике айдан мин беренче курсны тәмамларга тиеш идем. Насыйп булырмы-юкмы, ләкин балта чапканчы, кискән җан тарта, ди — һичнигә карамыйча, укуны очларга кирәк иде... Апрель-май да узды, июньгә дә кердек. һәм мин бәла-казасыз гына беренче курсны, ниһаять, бетереп чыктым... Хәзер инде мөһим бер мәсьәләне — кая китүне хәл итәргә кирәк иде. Минем хәлдәге студент өчен җәйне берәр җирдә эшләп үткәрү яхшырак булган булыр иде, әлбәттә, мәгәр, башта әйткәнемчә, үпкәләрем таза түгел, чехоткага әйләнү куркынычы бар, ә бу афәттән котылу өчен, миңа яхшы һава, таза ашау кирәк. Боларны мин Дәүләкәнемә кайтып кына таба алам, билгеле... Аннары, бөтенесе кайтканда, мин генә кайтмыйча калсам — моны качу-яшеренү дип аңлаулары да бик мөмкин иде. Шуңа күрә тоттым да, үземә дус һәм дошман булган егетләрдән калмыйча, атам йортына кайттым.

һәртөрле фани исәпләрдән дә бигрәк, туган өйгә тарткан иң көчле нәрсә — ул да булса, һичшиксез,— сагыну иде. Гаҗәп иде бу... Бер кыш эчендә тузанлы Дәүләкән үзе дә, бөтен әтрафындагы табигать тә, аеруча шунда калган дуслар да шулкадәр сагындыра иде ки, бер генә җәй кайтмыйча-күрмичә калу да үкенечле бер зур югалту булып тоела башлый иде... Бәлки, бүтәннәр өчен ул алай ук та булмагандыр, иллә мәгәр мин кул-аягым белән шул Дәүләкәнгә, шундагы дусларга бәйләнеп беткән идем. Кайткан саен беренче көннән үк шулар арасына кереп китәм, шулардан һич аерыла алмыйм, хәтта атам-анама күрсәтмәгән игътибарны да күбрәк аларга күрсәтә идем... Ахмак яшьлек!

Ул чакларда мин бик актив малай идем. Үземнән зурракларга кушылып, бөтен уеннарга, кичәләргә, компанияләргә чын ихластан катнашып, чаба-чаба йөри идем. Миндә җәмәгать эшенә зур дәрт бар иде, ни эшләсәм дә бары күңел кушуы буенча гына эшли идем һәм, билгеле инде, яраклашу дигән нәрсәне бөтенләй уйлый да белми идем (хәер, соңыннан да яраклашу-ялагайлану кебек бик «кирәкле» сыйфатлар минем табигатемә ят булып калды). Мине күптән белгән дусларым да миңа ышаналар, мине үз-якын итәләр иде — һәрхәлдә, алар тарафыннан бернинди дә хөсетлек сизми идем. Әмма ләкин шул ук вакытта миңа кырын караучыларның да барлыгын беләм... Булмыймы соң! Монда бит әле миңа ультиматум куйган Казак Усман, Хәйдәрләр компаниясе дә бар. Хәйдәр безнең арада һаман көлеп-шаркылдап йөри, ә менә Казак бик сирәк күренә иде. Гаҗәп бу кеше — үз тиңнәре белән уйнап-көлеп йөрүне бөтенләй белми диярлек, әллә тәкәбберлеге кушмый, әллә инде сүлән шикелле читтән генә күзәтергә ярата?! Ул мине онытмаган шикелле, мин дә аны оныта алмый идем — тик аның турында уйламаска гына тырышам. Дөнья күңелле, кояшлы, рәхәт — кадерен белеп калырга кирәк ләбаса!.. Тукта, оныта язганмын: шушы җәйне бит Һаҗәр Ыслак егетенәияреп китте... Казактан башка да булган икән минем гамьнәрем...

Инде китәр вакытым якынлашкач, бер дустым миңа сер итеп кенә әйтте: «Беләсеңме, Казак Усман сине батырырга чамалый бит, өстеңнән язып, шуңа кайберәүләрдән кул да куйдырган»,— диде. Мин төпченеп-сорашып тормадым — кемнәр кул куйганын юри беләсем килмәде (я араларында ышанычлы дуслар да булып куяр!). Ә Казакның, иртәме-соңмы, кара ниятен үтәячәген мин инде белеп тора идем.

...Август урталарында (башкалардан алданрак), миңа бердәнбер изгелек теләүче, хәер-догада торучы атам-анамны бераз аптыраште калдырып, тагын шул ерактагы таш калага китеп бардым.

* * *

Минем өстән рабфакка «материал» килгәнме-юкмы, мин моны бервакытта да ачык кына белә алмадым. Чөнки рабфактан мин үзем, үз теләгем белән чыгып киттем (бу турыда рәсми белешмә дә миндә сакланган икән). Хәлләр шулай булгач, мин инде үз аягым белән чыгып китүне артыграк күрдем, билгеле.

1927 елның көзе. Озакламый Бөек Октябрьгә дә 10 ел тулачак. Революция дәвам итә!..

...Авыллардан, заводлардан, шахталардан укырга, ябырылып, яшьләр килә. Хезмәт ияләренең үз белгечләре, үз укымышлылары булырга тиеш — яңа җәмгыять хәзер шуңа мохтаҗ... Димәк, чыгышлары белән чит саналганнар читкәрәк китеп торырга, әнә шул меңләп килгән чын эшче-крестьян яшьләренә юл бирергә тиешләр. Бик аңлаешлы түгелме соң бу?! Әлбәттә, аңлаешлы... менә хәзер!.. Мин бит бүген язам, илебез үткән юлны ачык күреп, үземчә дөрес нәтиҗә ясыйм. Ә теге чакта, ягъни 27 елның көзендә мондый ачык аңлау миндә мотлак булмагандыр, аңлау урынына ризасызлык һәм рәнҗү булгандыр. Чөнки мин дә бит адәм баласы, укыйм дип, җәмгыятькә файдалы кеше булыйм дип, шушы таш калага ашкынып килгән яшь кенә бер шәкерт!.. Юк, дуслар, бер дә җиңел булмагандыр миңа икенче тапкыр укудан аерылулар... Әмма ничек тә түзәргә, күтәрергә, киләчәктән өмитне өзмәскә кирәк иде.

Социаль чыгыш белән бәйләнгән кеше язмышының инде бер уңай мисалын китерү дә бик урынлы булыр дип уйлыйм. Минем белән бергә килгән Фәтхелислам дусны Казан, әйтерсең, көтеп үк торган — ишекләрен киң ачып каршы алды ул ятимлектә үскән бу грузчик баласын! Текә баскычтан менгәндәй, Фәтхелислам гаҗәп тиз югары күтәрелде. 1931 елны төзүче-инженерлар институтын уңышлы тәмамлады. Шунда ук аспирантурада калып, аны бетергәннән соң, кандидатлык яклый, доцент исемен ала, башта декан, аннары укыту эшләре буенча директор

урынбасары булып билгеләнә. Ә сугыш алдыннан инде Фәтхелислам Мансур улы Хәкимовны төзүче-инженерлар институтының ректоры итеп билгелиләр. Менә аның ун ел эчендә үткән юлы. Билгеле, бу чыгыш нәтиҗәсе генә түгел иде — яшьтән укырга бик сәләтле булу өстенә, ул үзен зур дәүләт эшләрен үти алырлык булдыклы, тырыш, чын коммунист итеп тә күрсәтә белде (1931 елдан партия члены). Сугыш вакытында да ул фронттагы бер авиачастьтә «Смерш» (контрразведка) начальнигы булып хезмәт итә, орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Фашизмны тар-мар иткәннән соң, Казанга кайтып, сугыш елларында ябылып торган институтны яңадан ачып, беренче көненнән үк шуның ректоры булып эшли башлый. Институт өчен яңа бина да салдыра. Шулай дәвам итә аның җаваплы һәм зур дәрәҗәле хезмәт юлы. Бу вакыт эчендә ул берничә мәртәбә Казан шәһәр советының депутаты булып та сайлана. Җыеп кына әйткәндә, аның язмышы да бөек революция нәтиҗәсе иде, әлбәттә!

Фәтхелислам әнә шулай үсеп-күтәрелеп китсә дә, безнең арадагы яшьтән үк башланган дуслык бетмәде-өзелмәде. Күрәсең, Дәүләкәннән икәү бергә житәкләшеп чыгып китү безне бер-беребезне яхшы ук бәйләп өлгергән булган — төрле сәбәпләр аркасында ерагаеп торган чакларда да без бу бәйләнешне ничектер күңелебездә саклап, аңа тугрылыклы булып кала алдык.

Илленче елларның башларында безнең янда гына дүрт катлы таза бер йорт салып куйдылар. Менә шул яңа йортның өч бүлмәле әйбәт, иркен квартирасына Фәтхелислам да гаиләсе белән күченде. Шулай итеп, Дәүләкәндәге шикелле, без яңадан күршеләр булдык, һәм, билгеле инде, ешрак очраша да, үзара йөрешә дә башладык.

...Берәр уңай белән мәҗлес үткәргәндә, Фәтхелислам безне дә бер вакытта да диярлек чакырмыйча калмый иде. Ә кунаклар, аның үзе кебек, институт кешеләре яки төзүче-инженерлар була торган иде. Әйбәт җыештырылган залда яхшы ризык, төрле эчемлекләр куелган зур өстәлнең ике ягына кадерле кунаклар тезелешеп утыра, ә табынның түр башында бәрхет тышлы йомшак креслода Фәтхелислам Мансурович үзе утыра... Кайчандыр, бүкәнгә утырып, пима төпләгән, ачлы-туклы яшәгән ярлы малай!.. Бүген исә ул түр башында, чөнки ул мәҗлес хуҗасы һәм зур бер институтның ректоры, әмма иң гаҗәбе — аңарда шушы өстенлеге белән һичбер төрле эреләнү дә, масаю да юк. Киресенчә, ул үзен бик табигый тота, гүя искитәрлек берни дә юк монда, тик үз бәясен яхшы белүчеләрдә генә була торган бәйсезлек белән горурлык чамалы гына сизелә аңарда. Ләкин болары да аның «ректор» булуыннан килгән нәрсә түгел иде. Мин менә аны күптән белүче кеше буларак әйтә алам: безнең Фәтхелисламда яшьтән үк үзен һәрвакыт, һәр урында әнә шулай дәрәҗәсен төшермичә акыллы-тыйнак тота белү бар иде. Мондый сыйфат яхшы тәрбия алган, эчке культурага ия кешеләрдә генә очрый бугай... Ә үтә ярлылыкта атасыз үскән Фәтхелисламга кайдан килгән ул?! Күп сыйфатлар, билгеле, нәселдән килә, ихтимал, атасы яки анасы ягыннан сакланып килгән әнә шундый күркәм бер сыйфат аңа да күчеп калгандыр. Ул бит үз гомерендә бер тапкыр сүгенгән кеше дә түгел. Мулла балаларында булмаган әдәп-инсаф бар иде аңарда!..

...Шулай да язмышның серләренә (яки мәкерлегенә) төшенүе бик читен. Кеше тормышта барысына да ирешә, әмма иң кадерлесен югалта. Менә Фәтхелислам белән дә шундыйрак хәл булды: илле яшеннән үк диабет белән авырый башлады, бик озак җәфаланды, ахырда шул авырудан үлеп тә китте... Әйе, әйтәсе дә түгел, үкенечле үлем! Яшәргә тиешле һәм хаклы кеше иде әле ул!..

* * *

Инде минем мәсьәләгә күчик. Уку турындагы сүзне ничек тә ахырына кадәр җиткерергә булыр... Күргәнегезчә, миңа рабфактан китәргә туры килде. Әмма уку теләге миндә сүнмәде, яшем үтмәгән, вакыт бар, киләчәктә берәр уку йортына керә алырмын әле дигән өмит, әлбәттә, калды. Тик моның өчен миңа үземнең социаль хәлемне яхшыртырга, ягъни башта кая да булса кереп, тагын күпмедер эшләргә кирәк иде.

Ярый, шулай карар да кылдык ди. Әмма кая кереп, кем булып эшләргә?.. Казанда эш табуы җиңел түгел, эшсезләр дә бар иде әле ул елларда... Шуннан мин кая да булса читкә китү турында уйлана башладым. Озакламый Җәләй исемле бер танышымны очраттым — ул да минем кебегрәк бер хәлдә икән — каядыр укыган, ни өчендер таш-

лаган, шулай ук эш эзли икән. Менә шул иптәш әйтте миңа: Урта Азиядән, укытучылар җыяр өчен, вәкил килгән, шуны табып, сөйләшеп карыйсы иде диде. Мин дә риза булдым моңа... Шул вәкилне эзләп, Наркомпроска киттек. Барган чакта мине һаман бер уй борчыды: укытучылык бик дәрәҗәле зур эш, мин шул эшкә ярыйммы-юкмы? Дөрес, рабфакта бер ел уку да минем белемемне шактый ук арттырган иде, һәрхәлдә, укырга-язарга өйрәтерлек кенә чамам бар иде. Әмма тәҗрибә дә, документ та — бернәрсәм дә юк, һәм җибәрүләренә ышанычым да бик аз. Илла мәгәр Урта Азиядә ул чакта укытучыларга кытлык зур булгандыр инде, вәкил иптәш безне, бик хуп дип, берсүзсез укытучылар итеп җибәрергә риза булды. Тиз арада тиешле кәгазьләрне дә язып бирде, шуның өстенә тимер юлда скидка белән барыр өчен литера дигән нәрсә һәм күпмедер акча да кулыбызга тоттырды... Әнә шулай ансат кына һәм тиз генә эшләнеп ташлана иде кайбер эшләр ул заманнарда!

Без инде, инебезгә канатлар чыккандай, тиз генә юк-бар әйберләребезне култык астына кыстырып, вокзалга түштек тә күңелгә ничектер якын тоелган, әмма күз күрмәгән кайнар коямлы ерак илгә ансат кына китеп тә бардык. Юлыбыз Мәскәү аша Сәмәркандка чаклы иде... Әмма... кызык бу язмыш дигәнең, кайвакытта һич көтелмәгән борылыш ясый да куя!.. Булгалады андый хәлләр минем белән дә, һәм менә беренчесен монда — Мәскәүгә килеп җиткәч татырга туры килде... Ташкент поезды төнлә генә китәсе булганга күрә, без көн буе диярлек башкала белән иркенләп танышып йөрдек. Минем бит аны беренче генә күрүем, шунлыктан аның бик буталчык урамнарын, төрле зурлыктагы, төрле төстәге йортларын, бихисап кибетләрен карап йөрү гаҗәп кызыклы иде (гомумән, мин беренче күргән шәһәрләрне исем китеп, карап йөрергә яратам). Мәгәр, буталчык Мәскәүнең кай җирләрен күрдек, кай төшләрендә булдык — мин аны беркайчан да әйтеп бирә алмас идем. Билгеле, Кызыл Мәйданнан башкасын.

Шулай күпмедер йөреп арганнан соң, иптәшем, бүтән барыр җир калмагандай, көтелмәгән бер тәкъдим ясады:

— Әйдәле, Татбашбюрога[1] кереп чыгыйк, анда ниләр бар икән?

Мин икеләнә калдым: шундый зур җиргә безне кертәләрме соң?!

— Кертәләр! — диде иптәшем,— анда минем бер танышым эшли...

Ярый алайса, киттек... Озакламый ничәдер катлы чибәр генә бер йортка барып кердек. Исәнләштек. Җәләй, танышы янына утырып, әкрен генә сүзгә дә керешге. Ләкин бераздан бүлмәдәге бүтән иптәшләр дә безнең белән кызыксындылар булса кирәк, торып, якынрак килеп, җайлап кына сораша башладылар: кемнәр без, нишләп йөрибез, кайларга таба китеп барабыз?.. Без кыскача гына сөйләп бирдек. Шуннан соң араларыннан бер дәүрәк абзый безгә Казанда бирелгән кәгазьләрне күрсәтергә кушты. Без аны-моны уйламыйча гына чыгарып бирдек. Ул барысын да ашыкмыйча гына карады, аннары бик гади генә итеп безгә әйтте: «Ни өчен әле сез әллә кайдагы Сәмәркандка китеп барасыз, безнең үзебездә эш беткәнмени? Әнә Донбасс шахтерларына укытучылар җитми. Юк, туганнар, без сезнең юлыгызны үзгәртергә мәҗбүрбез... Рәхим итеп, Донбасска китәсез, юлы да кыска, эш тә анда җитәрлек!»

Шулай диде дә, безнең ризалыкны да көтмичә, икенче бирәүгә яңа кәгазьләр әзерләп бирергә кушты. Әле дә хәтерлим: литерадагы «Сәмәрканд»ны кызыл кара белән сызып, өстенә Донбасс каласының исемен язып куйдылар.

Шулай итеп, Татбашбюродан безне, ике мәхлукне, ак пахта иленнән кара күмер иленә борып чыгардылар. Бу, әлбәттә, юнәлешне генә түгел, безнең язмышларны да, әйткәнемчә, икенче якка бору иде. Мәгълүм ки, ул елларда Урта Азиягә киткән татар яшьләренең бик күбесе шунда торып, төпләнеп тә калды. Кем белә, бәлкем мин дә туган якларга кире борылып кайта алмаган булыр идем.

Донбасс үзәге ул заманда Юзовка дигән шәһәр иде (хәзерге Донецк). Без менә шул округ үзәге урнашкан шәһәргә җибәрелгән идек. Аңа килеп җитү белән, без Донбасста икәнебезне бик ачык сиздек: мондагы һавада төчкелтемрәк күмер исе дә газ исе иде... Беренче тапкыр иснәргә туры килгән бу сәер исләр безгә бераз гына дәрт тә өстәп җибәрде — без бит данлыклы Бөтенроссия кочегаркасында!

Округ партия комитеты каршында ул чакта татар бүлеге эшли иде — кулыбыздагы язулар белән менә шунда барып кердек. Хәтеремдә: ул бүлектә

[1] Ул елларда партия Үзәк Комитеты каршында Татар-башкорт бюросы дигән бер орган эшли иде. (Ә. Е.)

партия эшләре буенча — Сәфәров дигән абзый, ә комсомол эшләре буенча ак чырайлы, арык кына Ширинский дигән егет эшли иде (соңыннан, татарлар арасында эшләү бетерелгәч, алар икесе дә Казанга кайттылар, Ширинский безнең китап нәшриятында да эшләде). Алар безне бик әйбәт каршы алдылар һәм тиз арада икебезне ике якка эшкә дә җибәрделәр. Минем ликбез укытучысы булып бара торган җирем Буденовское рудоуправление дип атала иде.

Чынлап та, кызык заманнар булган икән. Уйлап карагыз: һәрбер рудоуправление карамагында, татар шахтерлары арасында ана телендә укыту-агарту һәм культура эшләре алып бару өчен, махсус куелган, хезмәт хакы алып эшләүче ике кеше була торган иде. Аларның берсен — парторг, икенчесен профорг дип йөртәләр иде. Менә шулар, иңнәренә кыр сумкасы асып, шахтадан-шахтага җәяү йөреп, әнә шул бик кирәкле изге эшләрен алып баралар иде. Күбесе кайчандыр үзе шахтер булган яки гражданнар сугышында катнашкан урта яшьләрдәге гаҗәп тыйнак, ярлы, өс-башы да хөрти генә, әмма үз эшләренә беткәнче бирелгән гадел коммунист абыйлар иде.

Әнә шундый җәяүле агартучыларның берсе мине зур гына бер шахтага илтеп урнаштырды да инде. Ул Шакиров фамилияле, чегәндәй кап-кара бер мишәр абзый иде. Казармаларга алып кереп, шахтерлар белән дә таныштырды. Икәү бергә, укый-яза белмәүчеләрнең күпме икәнен ачыклап, исемлекләрен төзеп, группалар оештырдык. Шундый ук эшләрне тагын ике шахтада башкардык — мин бер-берсенә якын торган өч шахтада укытырга тиеш идем.

Бу эшләрне шулай тәмамлагач, Шакиров абзый миңа кайбер киңәшләр биреп (мәсәлән, укытканда, нык торырга, таләпчән булырга кушып), үз юлы белән җәяүләп кенә бүтән шахталарга китеп барды...

Инде, эшкә керешкәнче, үз хәлем турында да берничә сүз. Иң элек кайда тору мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде. Килгән көнне үк Шахтком кешесе мине поселоктан бер ярты чакрым чамасы читтәрәк, үр өстендәрәк ялгыз гына торган зур бакчалы бер йортка илтеп куйды. Йорт үзе дә зур, таза, уникеләп бүлмәсе бар, идәннәре паркет, мичләре ап-ак чыпаяк кирпечтән — кайчандыр монда шахта хуҗасы үзе торган булса кирәк. Хәзер исә нигәдер бөтенләй буш диярлек, бары ике бүлмәсендә генә ике ялгызак кеше торып яталар икән. Өченчегә менә мин килдем.

...Ә монда сентябрь ае бик җылы, бик йомшак, бик тымызык иде. Буш сәгатьләремдә ялгыз башым бакчага чыгам. Үләннәр инде саргайган, ә агачлар әле яшел. Монда алма, груша, кара җимеш агачлары күп, җирдә җыелмыйча сибелеп яткан груша, сливалар күп, койма буйларындагы вак куакларны кызыл карлыган сырып алган — шуны кабып карагач, үземне нечектер алпавыт имениесендә кебек хис итә башлый идем. Бәлки кызыл карлыганны моңарчы ашап карамаганга күрә, миндә шундыйрак хис булгандыр... һәм тагы да иң гаҗәбе — менә хәзер дә үз бакчамда үскән шул карлыганны капсам, әлеге хуҗасыз йорт, ташландык бакча күз алдыма килә — гүя мин Чехов заманындагы иске, таныш бер имениегә яңадан борылып кайткандай булам...

Шулай да кызыклы, серле, аз гына эчпошыргыч ул ямансу йорттан миңа озакламый чыгып китәргә туры килде. Шахтер абзыйларга якынрак торырга кирәк иде. Тиздән, кемнеңдер ярдәме белән, мин поселоктагы әйбәт кенә бер украин гаиләсенә «нахлебник» булып кердем. Ягъни тору һәм ашау-эчү хуҗадан, ә мин шуның өчен аена 25 сум түләргә тиеш идем. Шулай итеп, минем тормыш ансат кына көйләнде. Хәзер инде, култык астына дәреслек белән дәфтәр кыстырып, өч шахта арасында мәгърифәт орлыгы «сачеп» йөрисе генә калды. Шахтерлар сменалап эшләгәнгә күрә, укыту эшләре дә шуңа көйләнгән иде: иртән икенче сменага төшүчеләрне, ә кичке якта беренче сменадан кайтучыларны укытам. Һәр шахтаны атнасына ике тапкыр йөреп чыгам. Укыта торган җирем сезонниклар тора торган озын баракның «Кызыл почмагы»нда... Ишектән кергәч, тәрәзә яклап такта белән генә бүлеп алынган бу кечкенә бүлмәдә бер-ике озын өстәл, берничә озын эскәмия һәм стенага сөяп куйган кара такта тора — без, мөгаллим буларак, шул такта янына басып, ана телебездә дәрес алып барабыз. Тыгыз, әлбәттә, ләкин группалар зур түгел, сыябыз.

Биредә бер мөһим моментны әйтеп үтмичә булмый: һәр шахтада диярлек татар шахтерлары бер-берсеннән шактый нык аерылган ике төркемгә бүленә. Берсе — һәм күбрәк өлеше — акча эшләр өчен авылдан килгән сезонниклар. Боларның тамыры авылда, хуҗалыклары да авылда — инде өйләнергә яки йорт торгызырга кирәк булса, алар, күмәкләшеп, шахтага киләләр. Төп максатлары акча эшләү булгач, алар эштән башканы белмиләр, кирәксә, ике смена да эшлиләр, берниндн конфликтка кермиләр, эчүдән дә тыелалар, акчаны кы

сып кына тоталар — кыскасы, тырыш, уңган, күндәм шахтерлардан саналалар. Минем укучыларымның да күбесе шулар иде. Әйбәт егетләр, инсафларын югалтып бетермәгәннәр, миңа да күбрәк искечә, «мөгаллим» дип дәшәләр иде... Бу халык, авылда кыр эшләрен бетереп, сентябрьдә генә килә, ә апрельдә инде җыйган акчасын учлап, чемодан-капчыгын бүләкләр белән тутырып, кайтып та китә.

Икенче төркем исә шахтаның үзендә төпләнеп калган, йорт-җире, гаиләсе белән торучы шахтерлар иде. Кайбер шахталарда бу төркемне дә күп диләр, ләкин, мин торганда, бер биш-алты гына йорт булгандыр. Болар инде чын мәгънәсендә шахтер — эше дә, тормышы да бары шахта белән генә бәйләнгән. Поселокта да алар — мөхтәрәм кешеләр, таза торалар, йорт-җире дә таза, сыер да асрыйлар. Аннары шахта төбендә күмер ташып сукырайган атларны алып менеп суялар икән (билгеле, күпмедер түләп). Итен сезонникларга саталар, ә үзләре ел әйләнәсе симез казылыктан өзелмиләр.

Бу ике төркемнән башка шахта белән нык бәйләнгән тагын бериш кешеләр бар иде. Алар күп түгел, алар аз, әмма шуңа карамастан, бик билгеле-ләр... Сезонникларга кермиләр, чөнки күптән авылдан өзелгәннәр, туган нигезләрен онытканнар, кардәш-ыруларыннан да аерылып беткәннәр. Шахтада төпләнеп калучылар рәтенә дә кермиләр, чөнки тора торган йорты да, гаиләсе һәм бала-чагасы — бернәрсәсе дә юк. Кашы да күзе... шул гына!.. Бер урында озак тукталып калырга яратмыйлар, шахтадан-шахтага күчә-күчә, бөтен Донбассны инде айкап чыкканнар. Эшләргә дә артык һәвәс түгелләр, теләсә забойга төшә, теләмәсә — юк. Бернинди тәртипне, авторитетны, законны танымыйлар. Кыскасы, алар утны-суны кичкән һәм җиз торба аша да үткән «ала канат» — сукбайлар. Усал халык, эре, һавалы халык, вак-төяк белән кулын пычратмас, әмма инде һичкемнән, һичнәрсәдән куркып та тормый... Шуңадыр ахрысы, сезонниклар, күп булсалар да, алардан шактый ук шүрлиләр иде. Шундый «ала канат»ның берәрсе шахтага килеп чыкса, баракка кереп, иң түрдән үзенә урын ала, үзен «авыл мокытларының» химаячесе итеп таныта һәм барысы өстеннән дә командовать итәргә тотына... Инде баш булып алгач, шахтерларга аш пешерүче юан балтырлы маржаларның берәрсе янына кереп, шуның белән чаршау артында тора да башлый. Сезонниклар аңа дәшмиләр, кагылмыйлар, әйдә, ашасын-эчсен, маржа янында йокласын, тик гауга чыгармасын да пычак кына уйнатмасын.

Ә тулаем алганда, Донбасска килеп, шахтерлар арасында эшләү минем өчен һәр җәһәттән гыйбрәтле дә, файдалы да булды. Иң элек мин шахтаның нәрсә һәм шахтерның кем икәнен белдем. Җир өстендә эшләсәм дә, бернichә тапкыр смена белән бергә, кулга шахтер лампасы тотып, шахтага да төштем, егетләрем эшләгән забойларда да булдым. Әйтергә кирәк, ул чакларда шахтада бернинди механизация юк иде әле, шахтерның бердәнбер эш коралы — кәйлә, шуның белән ул утырып та, ятып та, каты күмерне чаба. Авыр һәм хәтәр хезмәт (забой ишелеп, күмер астында калулар да булгалый). Пычрак эш. Күмер тузаны кулга, биткә батып керә, кат-кат юып та бетми, шахтерны әнә шул «сөрмәләреннән» дә танып була. Эше беткәч, көн яктысына ул, морҗадан шуып төшкәндәй, кап-кара булып килеп чыга. Ялгышмасам, ул чакта ук инде шахтерның эш көне алты сәгатьтән артмый иде бугай.

Үземдә укыган егетләрнең һәм укымаган абзыйларның да миңа мөнәсәбәтләре яхшы иде. Алар тарафыннан бу егет бик яшь бит әле, ни күргән дә ни белә ул дип, санга сукмыйча карауны мин бервакытта да тоймадым. Атаң кем дип сораучы да булмады. Беренче тапкыр мин монда җан тынычлыгы татыдым.

Шулай ук рус, украин кешеләре белән дә арам һәрвакыт кешеләрчә әйбәт булды. Электән үк инде алар татарга ияләшкәннәр, ят күрмиләр, яшәү һәм эшләү гел бергә диярлек. Инде үзем торган украин гаиләсендә мин бер семья кешесеедәй яшәдем. Кызганычка каршы, хуҗаларның исемнәре онытылган, ә менә балаларыныкы шушы көнгә кадәр ничектер сакланган: җиткән кызлары Катя, үсмер малайлары Сергей исемле иде. Шуларга ияреп, мин киногa да бара идем.

Поселокның барак тибында бер катлы озын гына клубы бар, шунда атнасына бернichә мәртәбә кино күрсәтәләр, ә кинодан соң, эскәмияләрне стена буена этәреп, танца башлап җибәрәләр. Танцасыз бер кино да узмый торган иде. Гади генә киенгән егетләр һәм кызлар шунда ук, дәртләнеп, чаштыр-чоштыр әйләнергә дә тотыналар... Хәзер дә әле үкенәм шул чакта танцавать итәргә өйрәнмичә калуыма, югыйсә бит Катя туташ, әйдә, өйрәтәм дип, мине кыстап та караган иде. Әлеге дә баягы кыюсызлык! Кайтып китәргә көчем

житмичә, бер читтә, әллә кемдәй, уйчан-ялгыз гына карап утырган булам. Хәлбуки, миңа игътибар итүчеләр дә булган икән. Бервакытны хуҗа малае Сергей кулыма записка китереп тоттырды. Укыйм, русча: «Әгәр теләсәгез, без таныша да алабыз»,— дип язылган иде. Кемнән бу?... Әзрәк эссе дә булып китте миңа... Сергейдан сорыйм, ул каршы якта утырган бер кызны ымлап кына күрсәтте. Кыз, безнең якка карамаска тырышкан булып, кырын-текә генә утыра. Ә записканы хәйләкәр язган — инициативаны миннән көтә... Туташым бик бай, бик модный киенгән, помада-пудралар сылап, бик нык бизәнгән, һәм шуның белән тутый коштай бүтәннәрдән аерылып та тора. Күрәсең, гади шахтер кызы гына түгелдер... Әмма, ходаем, йөзе-бите аның шадра ич! — бернинди бизәнү яшерә алмаслык шадра!.. Кирәк ләбаса!.. Күзләре матур, иреннәре тулы, гәүдәсе дә сылу гына булса кирәк... Кызганыч, бик кызганыч!.. Мәгәр танышырга да, озатырга да үземне мәҗбүр итә алмадым. Һәм курыктым да мин: кызның яратып китүеннән курыктым, чөнки кешене кызгана торган йомшаклыгым бар, алла сакласын!..

Клубка барган саен, аның, горурлыгын сакларга тырышкан хәлдә, барыбер нидер көтеп, һаман миңа каравын үзем дә тоя идем. Авыр хәл. Нишләргә дә белмим. Килмәскә, күренмәскә микән әллә? Ләкин, тора-бара, бер нәрсәне аңладым: монда егетләр, кызлар ишсез йөрмиләр икән. Чынлапмы, юри генәме, һәрбер егетнең һәм кызның йөргәне бар. Безнең Катяның да егете бар, клубтан кайткан саен, ишек төбендә сәгатьләр буенча сөялешеп торалар... Атаанасы да бер сүз дә әйтми... Димәк, монда ялгыз булырга ярамый, ялгызны бик тиз күрәләр, ә танышып китүләре бик ансат икән. Мин торган йорт каршында гына су колонкасы бар иде. Көн дә бер-ике тапкыр шул колонкага тыгыз пальто кигән бер зифа гына кыз килә иде. Ап-ак чырайлы, кап-кара күзле чын украин кызы!.. Әлеге дә баягы Катя, орыша-орыша, мине менә шул чибәр белән таныштырды. Исеме Женя икән. Бик шат табигатьле, юктан да, тәңкәләр сипкәндәй, көлеп җибәрергә ярата... Шулай итеп, мин дә көтмәгәндә генә ухажер булып киттем. Билгеле, аякларга да эш артты. Клубта Женя белән бергә утыра башлагач, теге йөрәкне ирексездән сызландырган кыз да миңа нидер өмет итеп караудан туктады.

Минем матди ягым да монда бик яхшырды. Сәгатьләп түлиләр, эш хакым аена 90—100 сумга чаклы барып җитә. Нахлебник булып торган өчен хуҗаларга аена 25 сум түлим, ә шуннан артканы кесәмдә әйбәт кенә утырып кала. Ул чакта муллык иде, арзанчылык иде (мәсәлән, бостоннан теккән костюм 40—45 сум тора). Безнең поселокта атна саен кичерәк кенә базар була иде. Көзгә байлык, якын-тирә хуторлардан, бричкаларга төяп, алма, груша, карбыз, кавын китерәләр. Май, каймак, үзләре тутырган колбаса, көйдергән чучка баласы, тагын әллә ниләр кирә торган иде. Йомры вак кавыннарның тәмле хуш исен әле дә онытканым юк әле. Кыскасы, Донбасстагы шикелле минем хөр, иркен, мул торганым башка бервакытта да булмады. Аннары әллә һавасы килеште, әллә таза ашау нәтиҗәсе — үпкә авыруым да шушында ябылып бетә язды.

Әмма һәр нәрсәнең, һәр рәхәтнең бер ахыры килеп җитә. Кыш үтеп, язга керү белән укыту эшләре сүрелә башлады. Ә майда инде, сезонниклар китеп беткәч, бөтенләй туктады. Минем дә эшем, ниһаять, төгәлләнде. Көзгә чаклы мин буш... Май ахырында, тиешле расчетларны алганнан соң, өс-башымны әйбәт кенә юнәтеп, өйдәгеләрнең һәркайсына бүләкләр дә алып (беренче мәртәбә!), калган ярыйсы гына акчамны да учлап, мин, Мәкәрҗәдән кайткан шикелле, бик һәйбәт кәеф белән Дәүләкәнемә кайтырга чыктым. Хуҗаларым, кайбер таныш-белешләр, шулар арасында көләргә дә, еларга әзер торган шомырт күзле туташым да, бик җылы итеп: «Тагын да килегез!» — дия-дия, мине озатып калдылар.

Һәрбер торып киткән җир — бигрәк тә тыныч, бәхетле торган җир — күңелләрдә озак саклана. Башта сагындырып йөдәтә, яңадан барасы килеп китә, аннары, вакыт узу белән, әкрен генә ераклаша, тоныклана, әмма барыбер гомер ахырына чаклы онытылып бетми. Донбасс белән дә шулайрак булды. Бер-ике тапкыр күрер өчен генә булса да барырга талпынып карадым, ләкин минем өчен анда кызык калмаган иде инде. Утызынчы елларның башыннан татар шахтерлары арасында ана телендә агарту, укыту эшләре бетерелде. Бу эшләрне алып бару өчен махсус куелган кешеләр — һәртөрле парторглар, профорглар да таралышып беттеләр. Мәгәр тормышларын электән үк шахта белән бәйләгән татар шахтерлары үз урыннарында һәмишә калдылар.

* * *

Ясиноватая дигән зур станциядә поезддан-поездга күчеп утырганнан соң, мин Пенза-Самара аша исән-имин Дәүләкәнемә кайтып җиттем. Әйдәгеләр исән-саулар, билгеле, олыгая төшкәннәр, атакайга инде 56 яшь, инәйгә әзрәк артыграк та булырга тиеш. Елдагыча, минем кайтуыма бик куандылар, бу юлы бигрәк тә, чөнки мин дә инде, үсә-зурая төшү белән бергә, әнә Донбасс кебек җирләргә барып, укытучы булганмын, акча эшләгәнмен, бөтенәеп, бүләкләр белән кайтканмын — әйе, минем өчен ниләр уйлап юанулары аларның йөзләреннән дә «укып» була иде... Үзләре бер көе тыныч кына торып яталар, сыерлары сөт бирә, кош-корт асрыйлар, карт һаман да тимер чыбыктан таба асларын үрә икән.

Кыскасы, инәй әйтмешли, ходай җан биргәнгә юнь бирә.

Дәүләкәннең үзе турында да, анда үткәргән ялым турында да бу юлы язып тормыйм, җитәр, бер үк нәрсәне күпме язарга була?! Дөрес, үзгәрешләр бар: Дәүләкән әкрен генә үсә, җанлана, авылдан килгән яңа кешеләр дә күренә... Һәм без дә үсәбез, без инде чын егетләр, кызларыбыз да чын туташлар. Яңа хисләр, яңа уйлар, яңа гамьнәр безнең башларда... Читкә китүчеләр дә әкренләп арта бара, ләкин күпләп китү юк әле, анысы соңрак булачак.

Минем өчен исә зур үзгәреш — быел күршемдә Һаҗәр юк. Хәтерлисездер, ул былтыр Ыслак егетенә ияреп киткән иде. Мин буш хәзер, җаным зынҗырлардан азат, тик сагышлардан гына азат түгел...

Тагын нәрсә?.. 1928 ел нэпның соңгы елы булса кирәк. Бу инде шактый нык сизелә. Вак-төяк сәүдәсен белеп яки үзе белеп ташлаучылар арта бара икән. Авылларда да икмәк тирәсендә хәлләр отыры кискенләшә дип сөйлиләр... Тагын бер елдан илдә «бөек борылыш» башланачагын әле ачык кына белүче юк. Ләкин шулай да ул борылышның давыл шикелле якынлашып килүен халык инде ничектер сизеп тора. Бераүләр аның килеп җитүен кулларын уа-уа көтә, икенчеләр дәшми, колак сала һәм уйлана, өченчеләр исә чынлап куркуборчылу кичерә булса кирәк... Бөтен кешенең язмышын тамырдан үзгәртәчәк ул «бөек борылыш» — бишектә яткан сабыйныкына чаклы!.. Тик әле берәү дә хәзергә ачык кына күз алдына китерә алмый үзенең шәхси язмышын. Бүгенгесе белән яши адәм баласы!

Менә мине дә язмышым һаман Казанга дәшә, Казанга өстери. Гүя зур илдә минем өчен бүтән урын юк, гүя укып, белем алыр өчен, бүтән шәһәр беткән. Ләкин Казан ычкындырмый, Казан тарта. Ул татар мәдәниятенең кыйбласы, татар әдәбиятының үзәге — шушы якты рәшә минем хыялымда уйнаклый, шуңа омтылам, шуңа таба барам мин... Мәгәр аңа илтеп җиткерәсе юлның минем өчен ничаклы озын буласын һич тә чамалый белмим. Гомеремдә күп мәртәбә алдады мине хыялым!..

Иртә кузгалган кошлар шикелле, мин дә августның беренче яртысында ук Уфа аша тагын Казанга юл тоттым. Елга якын аерылып торганга күрә, мондагы хәлләрне ачык кына белми идем. Ниләр бар, ниләр көтә безне бу тынгысыз калада?.. Уку йортларының тулай тораклары бу вакытларда әле буш тора. Мин дә РТЯ курсларында укучы бер танышым янына вакытлыча кереп тордым (РТЯның бер тулай торагы Гоголь урамында тыштан бик матур, ләкин эченә карболка исе сеңеп беткән ак йортта иде. Хәзер бу йортта — безнең филармония). Көн дә шәһәр буйлап, анда-монда баргалап йөрим. Һәм иң беренче кеше итеп, урамда һич көтмәгәндә генә Сәгыйт абый Сүнчәләйне очраттым. Безгә ул якын кеше, бала чагымнан ук күреп беләм — әлбәттә, бу очрашуга бик куандым. Бәлки берәр ярдәме тимәсме дигән өмет тә күңелемә килгәндер. Ләкин Сәгыйт абыйда ниндидер сүлпәнлек сизелә иде, гүя үз кайгысы үзенә җиткән, шуңадыр ахры, минем хәлем белән күп кызыксынмады. Азрак сөйләшеп торды, язасың икән, журналда хикәяңне күрдем, тырыш, ташлама, диде (шул елны «Безнең юл»да «Вакытсыз сулды» дигән хикәям басылган иде. Соңрак ул хикәя турында Садри абзый Җәләл дә миңа берничә җылы сүз әйткән иде). Сәгыйт абыйның кайчандыр Тукай белән якын мөнәсәбәттә булуын, хатлар язышуын мин белми идем әле, әмма төскә ничектер затлы чибәр, үзенә бер йомшак ягымлы тавышлы, беренче карауга, шактый һавалы-горур күренгән, ләкин нигәдер гел генә уйчан-моңсу Сәгыйт абыйга минем хөрмәтем генә түгел, мәхәббәтем дә зур иде. Ул былтыр Казанга килеп, бер ел чамасы татар мәдәнияте йортында гыйльми сәркәтип булып эшләгән, хәзер аны ташлаган, яңадан Уфага китәргә җыенып йөри икән. Казан урамында очраклы рәвештә генә бу безнең иң соңгы очрашуыбыз булды, шуннан соң инде миңа аны бүтән күрергә туры килмәде.

Язу турында сүз чыккач, бу урында шуны да әйтеп үтү кирәктер дип беләм. Донбасста чакта өч шахтада укытып йөргәч, мин язуга бер дә вакыт арттыра алмадым. Казан гәзитләренә бары берничә хәбәр җибәрү белән генә чикләндем. Ләкин Дәүләкәнгә кайткач, Донбасс турында очерк сыман бер әйбер язган идем. Казанга килгәч тә мин аны «Кызыл Татарстан» гәзитәсенә кертеп бирдем. Шактый вакыт яткannan соң, сентябрь ахырларында гына ул нәрсә «Кара күмер илләрендә» дигән исем белән, гәзитәдә бер подвал булып, басылып та чыкты. Өлкә гәзитәсенең икенче битендә «подвал биләү» яшь язучы өчен зур дәрәҗә инде ул, билгеле... Әмма, ходаем, нишләткәннәр минем әйберне?! Башыннан ахырына кадәр брак булып чыккан лабаса, бер генә сүзен дә танырлык һәм укырлык түгел! (хәрефләр кәгазьгә яртылаш кына төшкән). Бары мәкаләнең исемен дә, минем фамилияне генә укырлык... Бу, һичшиксез, брак иде — әйтерсең, юри үч итеп шулай чыгарганнар. Гәзитәнең бөтен тиражы да шундый булып чыкканмы — әйтә алмыйм, тикшерергә туры килмәде, әмма кулымда сакланган нөсхәдә исемем бар, әйберем юк! Гәзитәләрдә аерым сүзләр, хәтта җөмләләрнең бозылып басылуы гадәттә еш очрый, иллә-мәгәр бөтен бер подвал текстны танымаслык итеп чыгару — валлаһе әгъләм — тарихта булдымы икән?! (төпченергә яратучылар «Кызыл Татарстан»ның ул номерын бәлки эзләп тә табырлар). Әгәр гәзитәнең бөтен тиражы да шулай бозылып чыккан булса, минем, Донбасс турында язганым эзсез югалды дигән сүз.

Хуш, төп максатка килик әле... Төп максат укырга керү иде бит... Ләкин кая, ничек итеп?.. Казанда уку йортлары күп, мәгәр, кайсына гына керим дисәң дә, синнән «социаль чыгышыңны» сораячаклар. Дөресен генә әйтсәң, алмаячаклар, ә алдашу юлына басасы килми. Хәтта атамның бүгенге көндә кустарчылык белән шөгыльләнүен, үземнең исә ике кыш инде хезмәт итүемне күрсәтеп, үтә калсам да, миңа барыбер тынычлык булмаячак. Әлеге Казак Усман һәм аның койрыклары өстемнән «бывший сатучы малае» дип язып бирәчәкләр. Һәм куылыр өчен шул җитә дә калачак, чөнки «бывший» да ул чакта бик начар исәптә йөри иде. Гомумән, уку йортларын «чит элементлардан» чистарту нәкъ шушы 1928 елдан башлап аеруча көчәйде. Кем син, нинди кеше синнән чыгачак — артык тикшереп тә тормыйлар. Инде танылып өлгергән шагыйрь Фатих Кәримне дә, мулла баласы дип, техникумның соңгы курсыннан чыгарып җибәргәч, башка чыгышы «начар» егетләргә һәм кызларга нәрсә генә кәтәргә кала?!

Керердән элек, чыгарыңны уйла дигәннәр тәҗрибәле картлар... Менә мин дә көне-төне шул хакта уйларга мәҗбүрмен: нишләргә, ничек итеп бу каты төенне чишәргә? Асылда бит сүз тормышта үз урыныңны табу турында бара. Ул урынны мин уку аша гына таба алырмын дип уйлый идем. Шуның өчен менә өченче тапкыр Казанга да килдем... Хәлбуки, минем өчен уку йортларына юллар хәзергә ябык икән әле, тагы да күпмедер кәтәселәр бар икән, инде алай-болай итеп керә алсаң да, соңыннан юк кына берәр аркасында сөрелүең дә бик мөмкин икән. Ә сөрелеп чыгу керми торуга караганда күп тапкыр начаррак түгелме соң?!

Казан урамнарында әнә шундый авыр уйларга бирелеп, каңгырап йөргән чакта, миңа ничектер Яңа Бистәгә, мех фабрикасы ачылуга багышланган тантанага барып чыгарга туры килде. Бу вакыйганың буласын гәзитәдә эшләүчеләрнең берәрсе әйткәндер ахрысы, чөнки мин редакциягә ара-тирә кергәләп йөри идем... Август ахырлары булгандыр, көннәр эссе, трамвайлар ул якка йөрми — тирләп-пешеп җәяүләп кенә киттем. Ачылачак фабрика Зур Ямашев урамының аргы башында ук икән, мин барып җиткәндә, тантана башланган иде инде... Фабрика ихатасына шактый гына халык җыелган, митинг бара, кызыл комач белән әйләндереп алган трибунадан кайнар нотыклар сөйлиләр. Тын гына яткан татар бистәсендә яңа фабрика ачылу зур вакыйга, иптәшләр, бу илне индустрияләштерүнең башы булачак диләр сөйләүчеләр... Соңыннан кунакларга фабриканың эчен дә күрсәтеп йөрделәр. Хәтта иң ахырдан татар ашлары белән чәй дә эчерделәр.

Мондый тантананы минем беренче күрүем иде, ул миңа бик ошады, ничектер рухландырып та җибәрде. Шушы рухлану белән кайтып, мин яңа фабрика турында тиз генә мәкалә дә язып ташладым. Эпиграф итеп, мәкалә башына Такташның: «Ә урамда, язның килерен белми, җылап утыра песи малае...» дигән шигъри юлларын да язып куйдым. Һәм ул нәрсә берничә көннән «Кызыл Татарстан»да «Яңа гудок» дигән исем белән басылып та чыкты. Исемемә игътибар итегез: иң мөһиме — фабриканың озын трубасы икән!.. Мәкаләнең үзен дә мин «Таңнарның тынлыгын ертып, мәчетләрнең диварларын тетрәтеп, тагын бер яңа гудок Яңа Бистә өстендә үкерә башлады...» дип бетергәнмен (моны укыгач, ирексездән үземә: «Калай әтәч!» — дип әйтәсем килеп китте: дөньяны

дер селкетергә бик ярата идек без ул чакта!) Мөһим бер вакыйга турында төпле, тыйнак кына итеп язасы урында, кызганычка каршы, әнә шулай чаманы белмичә, шапырынып язганмын икән шул мин дә!

...Ярый, фабрика ачылды, мәче тиреләрен мех итеп чыгара да башлады ди, ә миңа нәрсә эшләргә соң?! Болай яшәп булмый бит. Ашарга ризык, кунарга урын кирәк ләбаса!.. Ахырда мин, озак баш ватып тормастан, тагын шул ук Яңа Бистә якларына тәпиләп кенә киттем. Баруым яңа фабрикага кереп булмасмы дигән өмит белән иде. Һәм, бәхетемнән диимме, мине фабрикага учетчик итеп алдылар. Шул рәвешчә, 1928 елның җылы көзеннән башлап, мин яңарак кына туган, ләкин тиз арада даны таралган «Меховойда» эшли башладым. Кем әйтмешли, дөнья бу!.. Әле кайчан гына ачылу тантанасында кунак булып йөргән идем, ә хәзер менә җилкәмдә эт-мәче тиреләрен ташыйм.

Әйтергә кирәк, Казанда мехлар эшләп чыгару бик тиз үсеп китте. Егерме сигезенче елны беренче фабрика ачылса, ике-өч елдан инде аның икенче, өченче, хәтта дүртенче фабрикалары да сафка бастылар. Дүрт ел эчендә мин мехлар танырга өйрәндем, мех сортлау цехының мөдир ярдәмчесе дә булып эшләдем, ахырдан күпмедер вакыт БРИЗ мөдире дә булып тордым (БРИЗ — рационализаторлар һәм уйлап табучылар бюросы). Меховойларда эшләү минем яшьлегемдә тирән эз калдырды, искә төшерерлек хәлләр дә аз булмады, ләкин мин аларның берсенә дә тукталып тормыйм, чөнки төп сызыктан читкә тайпыласым килми. Ә төп сызык — әлеге шул уку мәсьәләсе... Бу мәсьәләдә дә Меховойларда эшләүнең файдасы тиде дияргә була — миңа да, ниһаять, укырга юл ачылды.

Казанда ул елларны хезмәтне фәнни оештыру институты бар иде (русча — ИНОТ). Урнашкан җире Горький урамында, радиокомитетка каршы, хәзерге поликлиника бинасында иде. Ә мин үзем шуннан ерак түгел, түбәндәрәк, Куйбышев (ул чакта — Кооперативная) урамында тора идем.

ИНОТ — гадәттәге югары уку йорты түгел, аның эше фәнни тикшеренүләр алып бару һәм производстволарга ярдәм итү, ләкин ул үз тармагы өчен кирәк булган кадрларны әзерләү белән дә шөгыльләнә иде. Менә шул институт каршында бер заман психотехниклар хәзерләп чыгару өчен бер еллык семинар оештырыла. Әллә үзем белеп, әллә җибәрү буенча — хәзер инде әйтә дә алмыйм — мин шушы семинарга 1932 елның башында кереп, 33 елның гыйнварында аны уңышлы гына тәмамлап, «психотехник» дигән исемне алып чыктым (таныклыгы хәзер дә үземдә саклана)... Хуш, кем инде ул психотехник, нинди рәк белгеч, һәм эше аның нидән гыйбарәт?.. Әгәр онытып бетермәгән булсам, мин аны болай аңлатыр идем: психотехник — ул производствода эшләүче кешенең психологиясен һәм физик сәләтен өйрәнү нигезендә аның эш урынын һәм эш алымнарын мөмкин кадәр рациональ итеп оештыручы белгеч — шушы аның төп эше, төп бурычы... Безне шуңа өйрәттеләр. Без, фабрика-заводларга барып, андагы эшчеләрнең ничек эшләүләрен махсус методлар ярдәме белән күзәтергә, өйрәнергә һәм уңай якка үзгәртергә тиеш идек. Төп максат, билгеле, һәр эшченең эшен җиңеләйтү белән бергә, эшләп чыгаруны арттыру иде.

Психотехника — ул үзе Америкада туган нәрсә, аны уйлап чыгаручы һәм гамәлгә куючы, ялгышмасам, Тэйлор дигән бер инженер булган. Капиталистик производствога аның зур файдасы тигән булырга тиеш — менә шуннан аны бездә дә куллана башлаганнар иде.

Семинарны уңышлы гына бетергәнгә күрә һәм производствода эшләвемне күздә тотып булса кирәк, мине шул ук институтның үзенә эшче-аспирант итеп тә алдылар. Эшче (рабочий) аспирант булу өчен монда югары белемле булуың шарт түгел, шуның белән ул, әйтик, вузлардагы аспирантлардан аерыла да. Укырга сәләтең булса, башың эшләсә, шул җиткәндер ахрысы... Мине дә бер үк вакытта махсус программа буенча укытырга һәм эшләтергә дә тиешләр иде.

Шулай итеп, мин утыз өченче елның башыннан институтка күчеп, әйбәт кенә стипендия алып, укый да, эшли дә башладым. Хәзер инде абзагыз «фән кешесе», фәнни тикшеренүләр алып баручы — урау юллар белән булса да төп максатыма, ниһаять, ирешәм бугай... Эшләр ничава, әйбәт кенә бара, психотехниканы яратып та киткән идем, ләкин... татарның бер усал мәкале бар: хәерченең итәгенә бодай салсаң... карга килеп чүпли имеш!.. Нәкъ шуның шикелле, сыймады минем бәхетемә «фән кешесе» булулар, тагын җимерелде дә төште. 1934 елга кергәч, безнең институтта «психотехника» дигән нәрсәне фән буларак бетерделәр. Баксаң, ул, ягъни психотехника, капиталистик илдә эшләүчеләрне тагы да ныграк эксплуатацияләү өчен туган нәрсә икән (әлбәттә, шулай!), шуңа күрә аңа безнең социалистик производствода урын булмаска

тиеш, кирәге юк, бетәргә тиеш! Бу институтның үзендә туган караш түгел иде, ул каяндыр югарыдан боерык рәвешендә килде булса кирәк. Инде психотехника үзе фән буларак бетерелгәч, аның өчен кадрлар әзерләп азаплануның да кирәге бетте. Миңа да, башны түбән салындырып, иңләшеп-яратып өлгергән институтым белән хушлашырга туры килде. Алай гына да түгел, ике ел ярым шуңа бөтен өмитемне баглап, укып йөрүләрем төтен шикелле юкка чыкты да куйды.

...Мәрхүм атакай бик аптырауга төшкән чакларында өзгәләнеп: «Ик-ки, егетләр!» — дип әйтә торган иде. «Эх» кына җитми, ул көчсез... Менә миңа да, башны селкә-селкә: «Ик-ки, егетләр!» — диясе генә калды.

Хәер, кайберәүләр, бәлки кашларын җыерып, монда ул кадәр уфтанырлык нәрсә бар дип әйтерләр. Имеш, психотехниканы бетергәннәр! Әллә бер аны гынамы? Шул ук елларда педагогия институтларында «педология» дигән бер предметны да бетергәннәр иде. Аннары сугыштан соң да, кайбер фән тармакларын зарарлы яки кирәксез табып, «ябулар» булгалады. Аңа карап, дөньяның беткәне, прогрессның туктаганы юк лабаса!..

Бик дөрес, дөньяның беткәне юк, һәм тормыш та дәвам итә. Без дә аның арбасыннан төшеп калмадык, озын юллар үтеп булса да, кайбер нәтиҗәләргә ирештек. Сүз тик монда шул юлны ничегрәк үтү турында гына бара. Һәркемнең бит үз юлы... Күрдегез инде, минем юлым уңышлы булып чыкмады. Ләкин моның белән мин башкаларның да юлы шулай булды дип әйтергә җыенмыйм. Совет вузларын бетереп чыккан мулла һәм сәүдәгәр балалары ул елларда да аз булмады. Тик шулай да аларның күпчелеге миннән бер-ике ел алданрак кереп, укуларын бетерергә өлгерделәр, яки инде миннән шактый соң килеп, башкарак вакытка туры килделәр. (1934 елны булса кирәк, Сталин авызыннан: «Атасы өчен улы җавап бирми» — дигән сүз чыкканын ишеткән идек — менә шуннан соң, укырга кергәндә, социаль чыгышка артык зур әһәмият бирми башладылар шикелле)... Ә минем укырга омтылуым егерменче елларның ахырына, нәкъ менә «чит элементларга» каты һөҗүм барган вакытка туры килде. Нишлисең, заманның барышы шулай булгач?! Аның каравы, меңнәрчә эшче-крестьян яшьләре нәкъ шул елларда төрле совет вузларын бетереп чыктылар... Теге кашын җыеручы иптәш бик дөрес әйтә: минем укымыйча калуымнан прогресс әнә очы кадәр дә оттырмады. Ләкин шулай да мин үз хәлем турында язуны кирәк таптым, чөнки бу да без кичергән тарихның бер сәхифәсе иде.

* * *

...Инде мин әдәбият дөньясына күчәргә тиеш. Сүз минем язучы булырга азаплануым турында барачак (Казанга килүдән икенче максат шул иде бит). Ләкин ул еллардагы әдәбият дөньясы миңа ургылып аккан язгы ташуны хәтерләтә. Шавы әле дә булса колагымда... Һәм менә бүген дә гүя шул хәтәр елганың ярында аптырап басып торам: ничек кенә итеп бу болганчык ташуны кичәргә икән? Кыюлык та җитәргә тиеш, укучыны да өркетмәскә кирәк! Төрлечә баш ватып карадым. Баштарак бик тәфсилләп язарга да уем бар иде. Аннары бу гаять җаваплы «теманы» ерып чыга алмам, буталып бетәрмен дип курыктым да, әллә бөтенләй язып тормаска микән дигән фикергә дә килгәндәй булдым. Әмма... язучы була торып, ничек инде язучылык язмышының турында дәшми калырга мөмкин ди?! Ярамый ич, булмый ич алай! Ахырда, җанны артык кыйнамас өчен, тоттым да шундый карарга килдем: язарга, иллә мәгәр, бары үземә кагылган кадәресен генә! Миңа кагылганы — минеке, мин беләм, җавабын да үзем бирәм... Тарихны тулырак белергә теләүчеләр әнә китапларга мөрәҗәгать итсеннәр — әдәбият дөньясын яктырткан төрле әсәрләр бездә аз түгел.

Мин кыскача гына сөйләп күрсәтергә теләгән дәвер егерменче елларның икенче яртысы белән утызынчы елларның беренче яртысына туры килә, ягъни бер 7-8 ел вакытны эченә ала. Минем дә 16 белән 23 яшьләрдәге чагым була... Менә шушы елларда инде миңа азрак язгаларга да, әдәбият дөньясында бераз кайнашып йөрергә дә туры килгән иде. Әгәр бу елларга тулаем кыска гына характеристика бирергә кирәк булса, мин аны революциянең дәвам итүе дип атар идем. Әйе, 1917 елны башланган социалистик революция нәпны кысрыклый-кысрыклый дәвам итмәктә! — мин моны Казанга килеп, бераздан язучылар арасына керә башлагач та ачык сизгәндәй булдым. Һәркемнең үзенә дә, эшенә дә бары сыйнфый көрәш күзлегеннән карый торган замана иде бу!..

Бу вакытларда Казанда әдәбият дөньясы, Тукайчарак әйтсәк, шәп кенә кайнамакта иде инде. Революциядән соң гына мәйданга күтәрелеп чыккан

яңа, яшь көчләр — Шамил Усманов, Һади Такташ, Кави Нәжми, Г. Толымбайский, Гомәр Гали, Гадел Кутуй (аз гына соңрак Хәсән Туфан) — менә шулар ул чакта әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торалар. Алардан шактый өлкән, революциягә чаклы ук инде яза башлаган Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин кебек абыйлар аз гына читтәрәк һәм өстәрәк торалар иде бугай — хәер, мин моны үзем чамалап кына әйтәм (яшьләр җыелышында алар сирәк күренәләр иде). Әдәбиятның танылган бәхәссез лидеры, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимов иде. Әмма аны да зур җыелышларда гына күрә идек.

Ул елларда Казандагы барлык иске әдип, шагыйрьләр дә, Тукайдан кала, исәннәр иде әле. «Искеләр» булып саналсалар да, алар барысы да 40 яшьләр чамасындагы кешеләр иде. Мин аларның күбесен үзем күрдем — Фатих Әмирханны, Галиәсгар Камалны, Җамал Вәлидине, Гали Рәхимне, Габдрахман Сәгъдине, Садри Җәләлне, хәтта «Заман» календарен чыгарган Шәрәфетдин Шәһидуллинны да — китап кибетендә бергә эшләдек. Бу абыйларның күбесе, язу эшләрен ташламасалар да, әдәби хәрәкәттән, билгеле, читтә торалар иде. Хәер, бер Габдрахман абзый Сәгъди генә яшь язучылар җыелышына чакыру буенча доклад яки лекция сөйләр өчен килгәли иде. Гадәттә, ул тулы гына чибәр хатынын ияртеп килә, һәм докладын тыңлаганнан соң, аны бик каты тәнкыйть итеп озаталар иде.

Хуш, ә нәрсә хас иде соң ул чактагы әдәби хәрәкәткә? Бер сүз белән генә әйткәндә, көрәш — кискен көрәш! Һәм отыры көчәя барган көрәш дип тә өстисем килә... Мин җыелышларга йөри башлаганда, бу көрәш төрле -измнар (әдәби агымнар) арасында гына бара кебек иде, шуңа күрә андагы бәхәсләр никадәр кызу-кайнар булсалар да, артык хәвефле түгел иде әле... 1927 елны миңа, хәтерләсәгез, Казаннан китеп барырга туры килде. Егерме сигезенче елның көзендә, яңадан Казанга килеп, җыелышларга йөри башласам, монда көрәшнең характеры бик нык үзгәргән — ул инде ачыктан-ачык сәяси төс алган. Бу инде көрәш кенә дә түгел, ә чын мәгънәсендә һөҗүм — бөтен искегә, иске әдәбиятка, иске язучыларга каты һөҗүм!.. Әлбәттә, бу пролетариат әдәбияты өчен буржуаз әдәбиятка һөҗүм иде (Фатих Әмирханны башта ук буржуаз әдәбиятның атасына әйләндерделәр, ә соңга табарак хәтта Тукайга да чират житте — аны вак буржуа шагыйре ясадылар.) Озакламый Татар пролетариат язучылары ассоциациясе төзелде һәм «Һөҗүм» сүзе әдәби журналның исеменә дә күчте: «Безнең юл» урынына «Атака» чыга башлады.

Иске язучыларны «попутчиклар» дип кенә йөртәләр иде. Аларны да үзләренә аерым бер оешмага тарткан булдылар («Совет язучылары җәмгыяте» дип атала иде шикелле), ләкин анда да, чистарту ясап, кайберләрен чыгарып та җибәрделәр. Мин, мәсәлән, Садри Җәләлне, Ченәкәйне, тагын кемнедер чистартканда булдым. «Чистарту» махсус оештырылган хөкем итү белән бер диярсең, чөнки монда «чистартылучыны» гел гаепләү, гел кара ягу, әллә кайчангы гөнаһларны казып чыгару — мәгәр аның хезмәтләре яки язганнары турында бер яхшы сүз, бер аклау сүзе юк. Шуларның барысын да үзе күргән Ярми дустым күптән түгел Ташкенттән миңа хат язды: «Хәтерлисеңме, Садри Җәләлне «чистарткач», ул бичара: «Ник кенә шул «Дим буенда»ны яздым икән!» — дип утырып җылады?!.» Хәтерләмәгән кайда ул! («Дим буенда» — Садри Җәләлнең революциягә чаклы ук язган романы)... Эш шуңа кадәр барып житте ки, «искеләр»не җыелышлардан куып чыгара башладылар. Әле дә күз алдымда, «Мәдәният йорты»нда язучыларның чираттагы җыелышы башлангач кына, ТАПП житәкчеләреннән берәү торып: «Монда Хәсәнгата казый малае Габәшн утыра икән, без аның җыелыштан чыгып китүен таләп итәбез», — диде... Һәм беренче татар операларын язышкан композитор Солтан Габәши, торып, бүреген батырып киеп, бөкрәеп кенә, залдан чыгып китте.

«Искеләргә» генә түгел, яңаларга да чират житте — ТАППның үзендә дә чистарту башланды. Мин бу чистартуның нәтиҗәләрен матбугаттан гына укып белдем: тәнкыйтьче Гази Кашшаф белән шагыйрь Демьян Фәтхине ТАППтан чыгаралар, ә Һади Такташны, берәүгә дә куелмаган зур таләпләр куеп, нык кисәтү белән генә калдыралар... Такташка инде байтактан бирле я үзенә, я язганнарына каныгу бара иде, ә хәзер әнә гомеренең соңгы елында каты тәнбиһ!.. Олы шагыйрьнең «Киләчәккә хатлары» әнә шул бәйләнүләргә биргән җавабы булмады микән дип уйларга да бик мөмкин.

Әмма ул елларда иң күп, иң нык кыйналган кеше, мөгаен, шагыйрь һәм драматург Фәтхи Бурнаш булгандыр... Әйтергә кирәк, бик мәһабәт, мөлаем бер кеше иде ул. Гәзиталарда аның хакында ниләр генә язмадылар?! Ахырда «солтангалеевчелеккә» бәйләп, аны (һәм Галгәф дигән тагын бер язучыны) махсус тикшерү җыелышы үткәрелә. Мин үзем ул җыелышта булмадым, ләкин

шунык стенографик отчеты итеп чыгарылган китап соңыннан кулыма килеп керде. Укып карагач, исем-акылым китте — ниләр генә өймәгәннәр аның өстенә?! Әлбәттә, бу ачыктан-ачык хөкем итү җыелышы булган. Бурнашның иҗаты турында махсус куелган доклад та: «Сарайлар, ханнар, князьләр, морзалар шагыйре Фәтхи Бурнаш» дип аталган! Кыскасы, бөтен иҗатын юкка чыгарганнар... Җитмәсә, шул җыелышта Кутуй мәрхүм: «Фәтхи Бурнаш иҗатына без «Сулф»[1] исеменнән 25 нче елны ук үлем карары чыгарган идек», — дип тә әйткән... Моны мин элек белмәгән идем, укыгач, хәйран калдым — кирәк бит шул хәтлегә барып җитәргә!

Хәлбуки, дөнья бит ул,— мишәр абзаң әйтмешли, куласа — әйләнә дә бер баса! Озак та үтми, Кутуйның да баш өстендә яшен чатнады — «Җидегәнчелек»тә гаепләнеп, берничә ел әдәбияттан аерылып торды. Билгеле, «җидегәнчелек» соңыннан бер уйдырма булып табылса да, мәрхүм Кутуйга аның кәсафәтен шактый ук татырга туры килгән иде. Шунысы тагын аяныч-көлке — Тукай клубындагы бер җыелыштан инде Кутуйны, Бурнаш белән икесен бергә, куып чыгаралар. Моның кайбер шаһитлары хәзер дә исәннәр әле...

Әлбәттә, болар барысы да яхшы ният белән — пролетариат әдәбияты хакына эшләнә (ул чакта «совет әдәбияты» дип сөйләмиләр иде әле). Бәхәскә урын юк, авыз ачарга ирек бирмиләр, кешене түгел, үзеңне яклап та бер сүз әйтә алмыйсың... Ләкин ызгыш-талашларга, «фаш итүләргә» карамастан, әдәбият яши, язучылар яза, нәкъ шушы тынгысыз елларда «Тирән тамырлар» да, «Урал эскизлары» да, «Киләчәккә хатлар» да дөньяга килеп чыга. Тормышның серләренә исең китәр! Мәрхүм Кутуй да бит үзенең иң яхшы әсәрен — «Тапшырылмаган хатлар»ны нахакка гаепләнү ачысын татыганнан соң иҗат итте.

Әмма иң аянычы шунда ки, бу яңа әдәбият өчен шулкадәр аяусыз сугышкан яңа көчләрнең үзләренә дә ахыр чиктә бер үк фаҗига килде — гүя үзләре тырыша-тырыша дөрләтеп җибәргән утта янып, көлгә әйләнделәр... Боларны искә төшерү бик авыр, онытасы, хәтердән йолкып ыргытасы килә — әмма ләкин тарих битләреннән берничек кенә дә җуеп ташлавы мөмкин түгел, кала, барыбер кала ул! Илләмәгәр гаделлек тә үлми, бетми, юкка чыкмый, соң булса да, өскә калкып чыга ул! Мең шөкер, партиянең кыю тәвәккәллеге аркасында, нахакка харап булучыларның («искеләрнең» һәм «яңаларның») үзләре булмаса да, һич югы исемнәре акланып кайтты.

Минем әдәбияттагы беренче адымнарым әнә шундый елларга туры килде. Беренче адымны җиңел генә ясасам да, әллә ни ерак китә алмадым. Мин бик яшь идем әле, бик тиз хискә бирелүчән идем... Уйлыйм ки, укырга керү мәсьәләсендә туган авырлыклар да минем рухымны төшергән булырга тиеш. Борчып торган кайгың барында нәрсә генә яза аласың ди?! Аннары, тәҗрибә бик бәләкәй иде бит әле, еш кына күңелдә туганны ничек итеп язарга белмичә азапланып бетә торган идем. Шигырь бөтенләй чыкмый, мин моны башта ук белдем, шуңа күрә «нәсер» дигән чәчмә парчалар язгалап карадым. Хикәяләр язуга егерме сигезенче елдан башлап кына керештем (алар да күп түгел). «Дус кеше» исемле повестем 1929 елны аерым китап булып чыкты. Тагын нәрсә? Колхозлашу башлангач, «Яз баласы» дигән повесть язган идем, анысы ни сәбәптәндер дөньяга чыкмыйча калды... Кыскасы, иҗади активлык җәһәтеннән мин замандашларымнан шактый артта калдым һәм язучы буларак нык̧лап таныла да алмадым. Бәлки әле бу хәерлегә дә булгандыр. Әмма, шуңа да карамастан, әдәбият әһелләре миңа игътибар итәләр, мине исләрендә тоталар. Җай чыкканда, исемемне җыелышларда һәм матбугат битләрендә телгә дә алгалый торалар. Мәгәр бервакытта да мактап түгел, гел каты тәнкыйтьләп тә сүгеп...

Ләкин хикмәт нәрсәдә соң? Ни өчен миңа мондый игътибар? Бер дә юкка гына түгелдер ич?! Билгеле, күпмедер гаеп минем үземдә дә булырга тиеш.

Ахрысы, мин катлаулы заман өчен ипсезрәк кеше булып туганмындыр инде. Иң элек, тартай теленнән табар дигәндәй, миңа күбрәк җыелышта-мазарда чыгып әйткән берәр сүзем өчен кыйналырга туры килә иде. Хәлбуки, сүзгә бик нык колак сала торганнар иде, хата сүз өчен гафу итү юк иде, ә минем авыздан, күрәсең, дөресе белән бергә хатасы да ычкынгандыр инде. Һәм, гадәттә, мине язган әйберләрем өчен түгел, әнә шул әйткән сүзләр өчен тотып «пешерәләр» иде. Тик мишеньга бер әйләнү генә кирәк, шуннан соң инде җай чыккан саен бәрә торалар (хәтта гөнаһсыз сүзең өчен дә), чөнки моның бер куркынычы юк, беркем алдында җавап бирәсе дә юк, ә «уяулыкны» күрсәтер өчен, бу бик әйбәт сылтау... Кыскасы, мин элек тә һәм соңыннан да язсам — ота, сөйләсәм оттыра торган бер кешегә әйләнеп киттем.

---

1 Сулф — сул фронт.

Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйләнгән күңел һәм намус эше иде. Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язарга тиеш дип уйлый идем. Ләкин, бер бәхәс чыкканда, миңа әйттеләр: «Син үзең белгәнне, үзең уйлаганны эчеңдә калдыр, ә безгә менә без таләп иткәнне яз!» — диделәр. Әмма үз күңелеңдә тумаганны заказ буенча гына язу? Юк, мин моны аңлый да, кабул да итә алмый идем. Характерым белән мин әрсез, үҗәт кеше түгел, ишектән кусалар, тәрәзәдән керә белмим, ә кемгә дә булса ярау-ялагайлануны, гомумән, табигатем күтәрми. Шуңадыр инде миңа вакыт-вакыт бик авыр булып китә иде. Андый чакта ирексездән күңелгә Чеховның: «Ненавижу насилие во всех ее формах!» — дигән сүзләре килмичә калмый иде. Әйе, дөньяга күз ачылыр-ачылмас, хаклы-хаксызга төрлечә кыерсытуларны шактый гына татырга туры килде — тышка чыкмыйча, эчтән кипкән күз яшьләре дияр идем мин аларны... Хәер, ул чакта гынамы соң?!

...Әкренләп мин әдәбияттан ераклаша башладым. Өмитле эш күренми иде ул тирәдә минем өчен, ә яшәргә, көн итәргә, гаиләне карарга кирәк. Илдә чыпчык үлми дигәннәр, безгә дә насыйбы табылмасмыни?! Аеруча өмитемне әлеге хезмәтне фәнни оештыру институтына баглаган идем... Шул рәвешчә, утызынчы елларның беренче яртысыннан алып, мин язудан туктадым һәм әдәбияттан киттем... Китәр алдыннан дип әйтимме, «Көзнең бер кичендә» дигән вакыйгасы бик куркыныч хикәя язган идем, ул ничектер «Совет әдәбияты»нда басылып та чыкты. Шуның белән тәмам, бетте, туктадык. Аннары, озакламый, миңа читкә дә китеп барырга туры килде.

1937 елның җәендә Кырымда ике ай чамасы дустым Хәбибрахман карамагында яшәдем (ул үзе мине чакырып алган иде). Хәвефле вакыт, җан тыныч түгел, кая барырга, нишләргә белмичә аптыраган чагым... Китәр вакыт җиткәч кенә, Хәбибрахман мине кыстый-кыстый, Ялтага, Галимҗан ага Ибраһимов янына алып барды. Сүз дә юк, авыру әдип белән бу очрашуның миңа тәэсире бик зур булды. Әгәр мин 1955 елны партия Үзәк Комитетына Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул утыз җиденче елда әдипне үз күзләрем белән күрү миңа ул хатны тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

Язу белән бер сихерләнеп өлгергән кешегә аңардан тәмам айнуы бик читен булса кирәк. Еллар буе язып та, дөньяга чыга алмаган, ләкин шуңа да карамастан, язуыннан туктамаган фидакарьләр дә була бит әле. Менә мин дә, еллар үтеп, әзрәк тынычлана төшкәч, шул җүләрләр шикелле, тагын бер талпынып карарга булдым. 1940 елны Үзбәкстанда чакта бер комедия язып, шуны Казанга, Риза агай Ишморат исеменә җибәрдем. Ә Казанда нәкъ шул чакларда сәхнә әсәрләренә ябык конкурс игълан ителгән булган икән. Риза абзый минем әйберне дә, чын исемем урынына «Шәмгун» дигән имза куеп, тоткан да шул конкурска биргән. Конкурс барышында комедия өч кеше кулында булып, өч рецензия язылган — Риза абзый ул рецензияләрне соңыннан миңа җибәрде. Аларның берсе Муса Җәлилнеке, икесе — Ибраһ Гази белән Рахман Ильясныкы. Билгеле, үз фикерләрен алар әсәрнең авторы кем икәнен белмичә язганнар (конкурс ябык бит). Ибраһ Гази белән Рахман Ильяс үзләренең русча язылган ярты битлек кенә рецензияләрен дә комедияне катгый рәвештә кире каккканнар (ягъни әсәр, аларча, бөтенләй яраксыз, тик Ибраһ Гази гына ахырдан «әсәрнең теле яхшы, талантлы кеше язган булса кирәк» дип өстәп куйган). Ә менә Муса Җәлил үзенең ике биттән артыграк рецензиясендә әсәргә, иренмичә, тулы анализ ясап, башта аның уңай, отышлы якларын күрсәтеп чыга, аннары инде аерым-аерым кимчелекләренә туктала. Әйтергә кирәк, чын җаваплылык тоеп, кеше әйберсенә мөмкин кадәр игътибарлы һәм гадел булырга тырышып язылуы белән Мусаныкы тегеләрнекеннән бик нык аерылып тора (бу рецензияләрне мин югалган дип йөри идем, ләкин быел иске кәгазьләрне актарган чакта табылдылар. Хәзер үземдә саклана).

Иртә уңмаган кич уңмас диләрме әле, шуның шикелле минем бу талпынып каравым да өмитләнеп көткән нәтиҗәне бирмәде. Яңадан инде мин сәхнә әсәре язарга тотынып та карамадым. Сәхнә әсәре — оста итеп «ясауны» сорый торган жанр. Ә мин ясый белмим — яза гына беләм икән.

Шуннан соң бер ел да үтмәде, гарасат купкандай, кинәт дәһшәтле сугыш башланды. Ил өстенә килгән бу куркыныч афәт көне-сәгате белән кешеләрне тигезләде дә куйды, бөтен халыкны Ватанны саклап калу өчен изге сугышка дәште һәм күтәрде. Бер ай да үтмәгәндер, мине дә алып, фронтка озаттылар.

Сугышның рәхимсез каты үз кануннары бар. Солдаттан алып, генералга чаклы шул кануннарга беткәнче буйсынырга мәҗбүр: кая кушсалар, шунда барасың, кая куйсалар, шунда торасың... Җиңү хакына үлемгә керү дә әнә шул канун белән бәйләнгән.

Менә миңа да, өч ел ярым хәрәкәттәге армиядә булып, рядовой солдат өстенә төшә торган барлык фронт михнәтләрен татырга туры килде. Дөрес, алгы сызыкта булмадым, чөнки безнең ротаның вазифасы башка иде, ләкин әлеге каты канунга буйсынып, мин дә кая куйсалар, шунда тордым, кая җибәрсәләр, шунда бардым.

Әмма иң гаҗәбе: әнә шундый гадәттән тыш шартларга барып эләгүемә карамастан, миндә ничектер үзеннән-үзе язасы килү теләге кабынды. Күргәннәр шулкадәр яңа, шулкадәр зур, куркыныч-фаҗигале һәм гыйбрәтле иде ки, аларның һәммәсен дә эчкә сыйдырып бетерү генә һич тә мөмкин түгел кебек иде. Сугыш — әшәке нәрсә, кешенең табигатенә каршы нәрсә, берәүнең дә үләсе килми, сөйгән ярыннан аерыласы яки балаларын ятим калдырасы килми — миллион солдаттан сорап чык — һәркайсы шулай диячәк, үләсем килми диячәк. Әмма инде иленә-йортына басып кергән дошманга каршы ул бөтен ачу нәфрәтен туплап сугышырга, үтерергә һәм үләргә әзер... Күрәсең, болар барысы да, өлешчә генә булса да, тышка чыгарга, кәгазь өстенә төшәргә юл эзләгәндер инде.

Мин форсат эзли башладым. Күңелемдә күргәннәрдән туган уем бар — шуңардан бушанып өчен, миңа аулак урын кирәк. Ниһаять, кырык беренче елның җәендә, запасной полкта чакта, кыска ял вакытларында иптәшләрдән яшеренеп кенә, «Бала» дигән беренче хикәямне яза алдым. Яшеренеп кенә дим, чөнки нидер язып маташуыңны, бигрәк тә язучы икәнеңне сиздерергә ярамый — шунда ук ялгыз «ак карга»га әйләнеп калуың мөмкин. Солдатлар һәр җәһәттән бер төсле булырга тиеш, берәүнең дә башкалардан аерылып торырга хакы юк. Аннары бернинди командир да сиңа, хикәят язып утырыр өчен, бер сәгать тә вакыт бирмәячәк — хатны да һәрбер солдат, буш вакытны көтеп алып, кайда туры килсә, шунда тиз-тиз генә сызгалап ташлый... Ә бит солдат өчен өеннән хат алу яки сагышларын өенә язып җибәрү — бердәнбер юаныч!

Шулай да мин өч ел дәвамында, әнә белән кое казыгандай, берничә хикәя яза алдым: «Бала»дан соң «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге»— менә бөтен язганым... Язылган берсен Казанга «Совет әдәбияты» журналына җибәрә тордым, һәм гаҗәпләнүемә каршы, алар барысы да җиңел генә басылып та чыктылар.

Сугыш кыры үлем кыры булса да, мин әнә шул хикәяләремдә яшәү турында, тереклекнең үлемнән көчлерәк булуы турында язарга тырыштым... Юк, үлем тереклекне бервакытта да җиңәчәк түгел!..

Бу иман бөтен кешегә хас икән. Мәсәлән, сугыш кырында һәркөнне йөзләпмеңләп кеше кырылса да, бер генә солдат та үзенең шулар арасында үлеп ятуына ышанмый. Бәлки, акылы белән монда егылып калуның никадәр тиз, никадәр ансат булуын аңлый да торгандыр, әмма күңеленнән барыбер ышанасы килми, өмитен бер генә минутка да өзми, яралансам да, исән калырмын әле, ходай кушса дип, эченнән генә үзен юата. Ихтимал, шушы үлмәсенә ышану аны ут эченә алып та керә торгандыр.

Безнең ротада командирлар һәм политруклар еш алмашынып торды. Аларның төрлесе булды, ләкин соңрак килгәннәрдән Левченко фамилияле политрук солдатларга аеруча ошаган иде (сүзеннән бигрәк кайгыртуы белән). Миңа да аның мөнәсәбәте әйбәт кенә иде... Язгалап маташуымны ничектер белгәч, бер очрашканда, ул миннән сорады: «Сержант, син нинди телдә язасың?» Мин кыенсынып кына, татар телендә, дидем (кыенсынуның сәбәбе — татарча язуымны һич көтмәгәндә рота старшинасы күреп алгач, мине бик тиргәгән иде. Политрук үкенгән сыман: «Алай икән, без аңларлык түгел икән шул! — дип куйды, аннары нидер уйлап, тиз генә өстәде: — Хәер, ротада татарлар байтак кына бит, нигә шуларга укымаска, ә сержант?!» — «Ярыймы соң?» — «Ник ярамасын? Хәтта кирәк ул, мин үзем аны Сезгә оештырам!» — диде политрук, гүя мине рухландырырга теләп, һәм, озак та үтми, бер көнне кичкә табан, эштән һәм посттан азат барлык татар, казах, үзбәкләрне (аның өчен барысы да татар!) урман кырындагы ачыклыкка җыйды. Бер утызлап кеше куе үләнгә, аякларын бөкләп, түгәрәкләнеп утырдылар. Политрук кыска гына кереш сүз әйтте, мине алларына бастырып, үзенчә зурлап таныштырды, аннары «берәр шәп кенә әйбер» укып җибәрергә кушты. Мин шул чакта солдатларга «Ялгыз каз» дигән хикәямне укыдым. Әлбәттә, уңайсызланып, шикләнә-шикләнә укыдым, чөнки бик күпне күргән, ут эченнән дә өтелеп чыгарга өлгергән, күбесе инде олы яшьтәге солдатларга бер япа-ялгыз каз турындагы хикәя ошамас, вак, әһәмиятсез нәрсә булып кына күренер дип курыккан идем. Әмма... нәтиҗә һич көтелмәгәнчә килеп чыкты: хикәяне шылт та итмичә тыңладылар һәм бик яраттылар. Хикәя аларда әллә никадәр истәлекләр уятты, шуларны сагынып яки уфтанып исләренә төшерделәр — кыскасы, тансык бер мәҗлескә җыелгандай тарала

алмыйча шактый озак утырдылар. Билгеле, моның сәбәбе хикәя «шәп» булудан гына түгел иде. Хикмәт шунда ки, дошманны «әһ» тә димичә үтерә алган солдат жан иясе хайваннарны сугыш жирендә аеруча ярата, аларга бервакытта да кул күтәрми, киресенчә, сакларга тырыша, хәтәр-куркыныч жирдән аларны куып жибәрә. Бу әлеге дә баягы адәми затның тереклеккә бөтен жаны-тәне белән бәйләнгән булуыннан килә — хикәя исә аңардагы шушы табигый инстинктны көчәйтеп кенә жибәргәндер, күрәсең...

Мәгълүм ки, татар язучыларының да бик күбесе фронтларда булдылар, фашист илбасарларына каршы сугыштылар, кайберләре сугыш кырында газиз башларын да салдылар. Әмма шунысы бик гыйбрәтле: кем, кайда, нинди генә шартларда сугышмасын, берсе дә каләменнән аерылмады, Ватанга мәхәббәтен һәм дошманга нәфрәтен юеш окопта ятканда да яки башын палач балтасы астына салганда да язуыннан туктамады... Мин исемнәрен китереп тормыйм — сез аларны яхшы беләсез. Шуңа күрә үземнең фронт шартларында язгалавымны зур фидакарьлектән санамыйм, тик шулай да фронтка эләккәч кенә, яңадан язарга теләк уянуын, азмы-күпме яза алуым, ниһаять, журнал битләрендә басылып та чыгуым минем өчен бик тә әһәмиятле иде. Бу бит, насыйп булса, әдәбиятка яңадан кайта башлавым дигән сүз!

...Каты-канлы сугыш көтелмәгән дәрәжәдә озакка сузылды. Аның кайчан бетүе турында кешеләр күпме төшләр күрмәде, күпме юраулар булмады! Әмма иң туйдырган, үзәккә үткән нәрсәнең дә ахыры бер килеп житә. Исәннәр, ниһаять, күрделәр бәдбәхет сугышның да беткәнен! Бөек Жиңү көне!.. Шатлык-сөенечнең чиге булмады, һәм кайтмый калганнар өчен түгелгән ачы күз яшьләре дә аз булмагандыр ул көнне...

Адәм барысын да күтәрә, барысына да түзә — чөнки яшәргә кирәк аңа, яшәргә! Канындагы гомерлек өндәүгә буйсынып, ул кайгыларын онытырга, жиңнәрен яңадан сызганырга тиеш. Сугыш бетте — михнәт бетте дип тынычланырга иртәрәк. Эш әле бик күп булачак, авырлык, кытлыклар да булачак, бәлки тамак та тиз генә туймас, өс-баш та тиз генә бөтенәймәс, мәгәр сыйрат күперен кичкәннәргә имин, тыныч, тук тормыш, һичшиксез, киләчәк. Ил әнә шул юнәлештә атлый хәзер...

Минем үз хәлемә килгәндә дә, шөкер генә итәрлек. Гаиләм исән, картлар исән, сугыш алар өчен дә бетте — мин үзем март аенда ук армия сафыннан азат ителгән идем. Башта «Совет әдәбияты»нда бик аз гына эшләп алдым. Аннары радиокомитетка күчтем, әдәби-драматик тапшыруларны оештырып йөрим, айлык хезмәт хакым килеп тора... Жәйге һәм көзге айларда сугыш беткән жирләрдән бер-бер артлы язучылар кайттылар, берьюлы әдәбият дөньясы жанланып, союзда очрашулар, аралашу-йөрешүләр ешаеп китте. Миңа күңелле иде. Иске дуслыклар яңарды (аеруча Әхмәт Фәйзи белән), яңа дуслар да табылды. Кайтучыларның күбесе фронт гәзитәләрендә эшләгәнгә күрәмедер, погонлы офицерлар иде, ләкин монда инде без погоннарны салганбыз, майор да юк, рядовой да, барыбыз да әдәбият әһелләре — үзара мөнәсәбәтләр дә жылы, дусларча иде. Әйткәнемчә, безне башта ук дәһшәтле сугыш тигезләгән иде, һәм шушы Ватан хакына туган бик кадерле тигезлекне без әле тоеп яши идек.

Әйтергә кирәк, минем кебек яңадан әдәбиятка кайтырга тырышкан кеше өчен бу тигезлек белән татулыкның әһәмияте аеруча зур иде. Нәкъ шул чакларда мине фронтта язган хикәяләрем өчен Язучылар союзына алдылар. Әмма... ни гажәп? — дөнья миңа бер елмайса, артыннан ук тагын чыраен сыта! Нигә ул алай, сәбәп нәрсәдә? Инде тынычландым, инде миңа да юллар ачык дигәндә генә, һич көтелмәгән бер хәл мине тәмам аптырашта калдырды. Нәрсә булды дисезме?

...Әлеге фронт хикәяләремне Татиздат кечкенә бер китап итеп чыгарырга булды. Биш-алты гына хикәя кергән бу кәгазь тышлы кечкенә жыентык минем күп еллардан соң дөньяга чыгачак беренче китабым иде. Билгеле, мин аның чыгуын бик көтә идем... Менә шуның сигнальные килгәч кенә, минем үземә әйтеп тә тормыйча, әлеге «Ялгыз каз» хикәясен китаптан чыгарып ташладылар. Мин, белеп алгач та, нәшрият редакторларына йөгереп бардым: нигә, ни өчен? Ярамый диләр. Ни өчен ярамый?.. Ярамый, вәссәлам! — аңлатып тору да юк... Китапның редакторыннан сорагач, ул да төшереп калдыру ягында, хикәя идея ягыннан тотрыксыз имеш!.. Ходаем, ни дигән сүз бу?! Шуннан соң мин тиз генә Союз идарәсенә гариза язып бирдем — әлбәттә, яклауларына бик нык ышанып... Күпмедер вакыттан соң, берничә кеше жыелып, миннән башка гына гаризаны караганнар... Нәтижәсен миңа мөхтәрәм бер язучы әйтте: «Хикәягезне китаптан чыгарып ташлап, бик дөрес эшләгәннәр!» — диде ул, хәтта тавышын да калынайта төшеп (ачуы килгәндә аның шулай, тавышын калынайтып, һәр сүзенә басым ясап

әйтә торган гадәте бар иде)... Шуның белән мәсьәлә хәл ителде — хикәя китаптан төшеп калды... Мин хөрмәтле язучы белән бәхәскә кереп тә тормадым, чөнки хикәядә һичбер төрле гаеп юклыгы миңа көн кебек ачык, ә бу эшнең төбендә бөтенләй башка сәбәпләр ятканын икенче җирдән эзләргә кирәк иде. Хәер, артык эзләп торасы да юк: мин үзем кеше һәм язучы буларак кемнәргәдер ярамый идем. Бары шулай гына аңларга мөмкин иде бу хәлне ул чакта.

— Тукта! — диярсез, бәлки, сез. — Болай ук катгый нәтиҗә ясарга иртәрәк түгелме? Бер хикәя мисалында гына... Китаптан берәр әсәрне төшереп калдыру нәшрият практикасында булгалап тора... Сезнең нәтиҗә рәнҗү аркасында гына тумады микән?!

Әйе, шулай булуы да бик мөмкин... Ләкин менә сезгә тагын бер мисал. 1948 елны мин күптән уйлап йөргән «Тауларга карап» исемле хикәямне бетереп, «Совет әдәбияты»на илтеп бирдем. Үтмәде, басмадылар. Мин монда берәүнең дә фамилиясен атап тормыйм, алар барысы да хөрмәткә лаек язучылар иде. Журналда утыручы әнә шундый хөрмәтле язучыларның берсе хикәянең ни өчен «үтмәвен» борын эченнән генә миңа болай аңлатты: «Хикәягездә сүз күп, хәрәкәт аз, аннары бик хискә бирелеп язылган», — диде... Ярый, шулай да булсын ди. Әмма, басмас өчен, бу сылтау гына җитәме? Ул үзе романнар язучы, ә мин хикәя, повестьлар язам. Хәлбуки, әдәбиятны аңлаган кеше белергә тиеш — хикәя кайчагында эчтәлеге белән романга торырлык та булып чыга. Классик әдәбияттан моның мисалларын күп табарга була. Минем монда хикәяне мактап торасым килми, татар әдәбиятын укучыларга ул билгеле булырга тиеш — уналты елдан соң мин аны, кыскартыбрак булса да, «Азат хатын»да бастырып чыгардым, аннары инде ул бөтен җыентыкларыма да керде. Укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан аның хакында миңа мактаудан башка сүз ишетергә туры килмәде. Ләкин мин бит теге чакта «үтмәүнең» сәбәбен ничектер аңларга тиеш?! Сәбәбе нәрсәдә? Зарарлы әсәрме яки начар язылганмы? Юк, берәү дә моны исбат итеп маташмый. Димәк, миңа тагын шул ук нәтиҗәне ясарга туры килә: хикәя үзе ничава да, авторы әллә нindирәк. Ипсез кеше, чыкмый торуы әйбәтрәк!

Алдарак телгә алынган «Нәгыймә Таждарова» монографиясе белән дә шундый ук «бәхетсезлек» килеп чыкты. Заказ буенча килешү нигезендә язылган әсәрне ВТО (театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге) тотты да кабул итүдән баш тартты (Гази Кашшаф мәрхүм аңа бик төпле, уңай рецензия дә язып биргән иде югыйсә). Баш тартуларның сәбәбен хәзер инде әйтә дә алмыйм, әмма боручысы гаять усзүзле кеше иде.

Бер-бер артлы килеп торган бу «казалар» минем хәлемне бик читенләштерде. Матди яктан да бик кыйналдым... Ә мораль ягын әйтеп торасы да юк! Гүя кемнәрдер миңа юри менә аяк чалалар — ирексездән, теләмәсәм дә, шулай уйларга мәҗбүр идем. Бик химаясыз идем мин ул чакта...

Ләкин бит әле мин — Язучылар союзы члены, язарга хаклы гына түгел, тиешле дә кеше. Язу инде төп эшем, төп кәсебем... Тик мин, акча табар өчен, күбрәк тәрҗемә белән шөгыльләнәм, хәтта кеше өчен дә тәрҗемә иткәләдем. Әмма бу «кәсеп» мине һич тә канәгатьләндерә алмый иде, мин дә үземнекен язарга тиеш — кырыкка җитеп килә бит инде... Башта уйлар күп, күңелдә ышаныч аз, нәрсәгә тотынырга да белмим.

Ахырда, якын дустым Хәбибрахманга барып, зарымны сөйләдем. Ул, әдәбияттан читтә торса да, заманны бик яхшы аңлый иде. Миңа әйтте: «Син үтә современный бер әйбер язып ташларга тиеш — шул гына синең хәлеңне җиңеләйтәчәк!» — диде.

Әлбәттә, бу дөрес киңәш иде. Хуш, нәрсә «үтә современный» хәзер? Менә ил алдында беренче нәүбәттә торган зур бурычларның берсе — колхоз хуҗалыгын аякка бастыру — һичшиксез, бик кирәкле тема. Авылны элек мин яхшы ук белә идем, ләкин сугыштан соңгы авыл белән танышлыгым аз... Шуны истә тотып, союздан бер айлак иҗат командировкасы алдым да Апас районындагы Әтрәч авылына китеп тә бардым. Бу кыш үзәге иде, ә яз башын шул ук районның икенче читендәге Балтай авылына барып, тагын бер өч атна «колхозны өйрәнеп» яттым. Бик файдалы булды минем бу барып «ятуларым» — күп нәрсәне күрергә һәм аңларга ярдәм итте. Кайткач инде шушы ике авылда күргәнишеткәннәрдән чыгып, мин колхоз темасына ашыкмыйча гына, әдәби ягы да әйбәт булсын дип тырыша-тырыша, 5-6 табаклык бер повесть яздым. Исемен дә үтә заманча «Рәхмәт, иптәшләр!» дип куйдым (ә дөресен әйткәндә, исем табуда осталыгым юк диярлек).

...Повесть җиңел үтте, җиңел басылды. Мәшәкатьсез генә аерым китап та булып чыкты. Тәнкыйть тә яхшы каршы алды. Хәтта теге «Ялгыз каз»ны «суйган» мөхтәрәм язучы да повесть турында берничә мактау сүзе әйтте...

Менә бит ул үтә «современный» әсәр язуның файдасы! Абзагызның эше көйләнә бит болай булгач! Язучы буларак минем дәрәҗәм дә үсә төште, позициям дә бераз ныгыды кебек... Дөрес, соңрак мин үзем ул отышлы әсәрнең берәү дә әйтмәгән кимчелеген сиздем сизүен... Кимчелек аның исемендә үк иде. Ягъни авыл советы сессиясендә каты тәнкыйть ителгән ферма мөдире Нургали (повестьның төп герое) соңыннан үзенең хатасын аңлап, тәнкыйть итүчеләргә күңеленнән рәхмәт укый башлый!.. Я, фальшь түгелме бу? Кемнең, кайчан тәнкыйть итүчеләргә рәхмәт укыганы бар әле? Тот капчыгыңны! Әллә бәлки киләчәктә укырлар?! Нигә көләсез? Әдәбият алга да карарга тиештер ләбаса!...

Шулай да повестьның үзенә рәхмәтне әйтергә кирәктер — ул минем авыр хәлне шактый ук җиңеләйтте. Инде уңышны беркетер өчен, тагын шундыйрак бер отышлы нәрсә язасы иде дә бит, ләкин мин, тиле, чыгымчы аттай яңадан буразнаны боза башладым. «Саз чәчәге» исеме белән бер райком секретареның обывательгә әйләнүе турында повесть яздым. Аннары, ул гына җитмәгәндәй, тагын да зуррагын «Рәшә»не язган булдым. Бусы инде «коеп куйган» обыватель турында... Бик кыенлык белән булса да алар журнал битләрендә басылып та чыктылар. Иллә мәгәр «Рәшә»не китап итеп чыгара алмыйча йөдәп беттем... Билгеле, алар икесе дә тәнкыйтькә юлыктылар. Бигрәк тә «Рәшә» — китап булып чыккач, бер философ аны бөтенләй тетеп ташлады... Үрмәләп менгәндә генә, мин тагын түбәнгә тәгәрәдем бугай... Хәер, повестьларны яклап чыгучылар да табылды, аеруча яшьләр арасыннан. Шулай итеп, фикерләр капма-каршы икегә аерылды, ләкин аларның кайсысы өстенлек алачак — бу кадәресен вакыт кына хәл итәчәк иде.

...Кыскасы, мин әдәбиятка авыр кердем, озак кердем. Бик озак мин үземне язучы дип атарга да кыймыйча йөрдем (тыйнаклыктан түгел, ә үземә ышанып бетмәүдән). Әйберләрем авыр уза, кат-кат төзәтергә туры килә, күп бәхәс-тартышлардан соң гына үткәзеп була торган иде. Кайчагында әнә шулай тауга каршы таш тәгәрәткәндәй азапланырга туры килә иде.

Ләкин моның сәбәбен бары редакторларга гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде (ул да бит ике башлы түгел, басып чыгарган һәр сүзе өчен җаваплы). Миңа калса, авырлыкларның төп сәбәбен әдәбиятның үзеннән эзләргә кирәк. Фикер аңлашылсын өчен, тагын сугыш вакытын искә төшерик. Ул чакта әдәбият алдында бер генә изге бурыч иде — Ватанны яклау... Һәм язучы да үзенең каләмен бары әнә бөек максатка хезмәт иттерә — башкасында аның хәзергә эше юк. Шуңа күрә, әгәр дә яза алсаң, бастырып чыгаруы да авыр түгел иде.

Сугыш бетеп, тыныч тормыш башлангач, әдәбиятның да бурычлары, билгеле, катлауланды. Өстәвенә әлеге вульгар социологизм яңадан көчәйде, каяндыр конфликтсызлык теориясе килеп чыкты... Нәрсә турында ничек итеп язарга?.. Мондый сорау һәр заманда, һәрбер язучыда туа, әмма җавабын һәркем үзенчәрәк табарга тырыша. Һәм, шушы төп мәсьәләне хәл иткәндә, язучының тормышта күргәннәре дә, заманны аңлавы да, ниһаять, характеры да чагылмыйча калмый...

...Менә миңа да үз җавабымны табарга кирәк иде. Күргән-кичергәннәрнең бу китапта язылган кадәресен сез беләсез инде, ә язылмый калганы аның тагы да күбрәк, һәрхәлдә «материалым» җитәрлек дип әйтсәм килә. Һәм бу «материал» турыдан-туры заман белән бәйләнгән, билгеле, шуңа күрә мин заманны һәрвакыт каты тоеп яшәдем дип әйтә алам, әмма аның һәр әверен, һәр борылышын яхшы аңлап бардым дип әйтергә җөрьәт итмәс идем. Ә кемнең заманны аңлап бетергәне бар? Ул бит өзлексез үзгәреп торган чиксез диңгез. Кыскасы, минем бу хакта артык җәеләсем килми, чөнки язучының заманны ничегрәк аңлавын аның әсәрләреннән эзләргә кирәк... Язучы үзе нәрсә әйтмәс — бакырын алтын итеп күрсәтүчеләр дә очрый кайчакта.

Инде характерга килсәк, моны язучының үзеннән башка кем генә аңлата алыр икән?! Бик четерекле нечкә эш бит — әсәрдә язучының үз йөзен күрү... Халыкта мал иясенә охшый дигән сүз бар, бәлки шуннан чыгыбрак аңлатырга кирәктер... Мин, мәсәлән һәр эштә гадилекне, табигыйлекне яратам, һәм әсәрләрне дә мөмкин кадәр гади, табигый итеп язарга тырышам. Мин шулай ук ачык, ихлас булуны яратам, һәм әсәрләремдә дә фикернең ачык, хисләрнең ихлас булуына омтылам. Аннары мин ялганны, фальшьне, ялагайлыкны бер дә яратмыйм, һәм язган чакта, шулар начар ис шикелле әсәремә кермәсен дип, бик сакланам. Янә мактануны да, дан артыннан чабуны да бер дә яратмыйм, һәм, сез күрәсездер, минем геройларым — күбесенчә бик тыйнак инсафлы кешеләр.

Тагын нәрсә? Иҗат — изге гамәл. Әдип, Тукай әйткәнчә, дөньяга «күкрәк тәрәзәсен» ача. Бу минутларда ул һәртөрле тормыш ваклыкларыннан арынган булырга тиеш. Иҗат өчен иң кирәге — җан тынычлыгы. Әмма минем тыныч җан белән эшкә утырган чакларым сирәк булгандыр... Шуңадыр ахрысы, мин

үземнең язучы булып китүемә әле дә еш кына гаҗәпләнеп куям.

Ә шулай да 12-13 яшемдә үк көнелемдә туган хыялыма, әкренләп үрмәли торгач, ирештем, ниһаять! Хәзер инде мин шактый танылган карт язучы... Аксакал! (дип тә җибәрәләр). Язучылык — минем төп кәсебем. Настроение юк дип тормыйм, көн дә эшенә ашыккан хезмәткәр шикелле, мин дә көн саен диярлек эшемә утырам. Арган чакларым була, туйган чакларым була, ләкин бизгән чакларым булмый. Бизү — яшәүнең мәгънәсен югалту булыр иде.

Язу — акыл һәм йөрәк эше — миңа калса, иң авыр эш. Таләпләр күп, җаваплылык бик зур. Менә шул җаваплылыктан курыкмас өчен, язучы кеше иң элек, ничек дим, үзенең төп максатын билгеләргә тиеш (кыйбласын дип әйтергә дә ярый). Ә максат ул — нәрсәгәдер инану, нәрсәнедер бик нык теләү диган сүз... Бары шул нигездә генә иҗат итәргә мөмкин.

Моны раслар өчен, үземнән мисал китерсәм, гаеп итмәссез дип уйлыйм. Баштарак әйткәнемчә, фронтка эләгеп, сугышның нәрсә икәнен күргәч, миндә яңадан котылгысыз язу теләге уянды. Сугыш — коточкыч афәт, әмма тереклек үлемнән көчлерәк! Менә шушы үзеннән-үзе диярлек күңелдә яралган уй-теләкинану мине иң кыен шартларда да кулыма каләм алырга мәҗбүр итте дә инде.

Сугыштан соң да миңа шундый бер көчле теләк, шундый бер якты маяк кирәк иде. Хәлем авыр, язучы булып каламмы-юкмы — минем алда әнә шундый читен мәсьәлә тора. Ә теләксез һәм маяксыз юл табу мөмкинмени?! Әмма нәрсә теләргә, нәрсәгә омтылырга соң минем газиз башка?! Мин гаделлеккә бик мохтаҗ идем, минем төрле шик-шөбһәләрдән котыласым килә иде, ихтимал, шулар нәтиҗәсендә булса кирәк, миндә ирексездән: «Кешеләр гадел, намуслы булсын иде!» — диган теләк туды. Һәм шушы ихлас теләк минем иҗатымда төп максатка да әйләнде: кешеләр гадел, намуслы булсын!— менә нәрсә хакында мин язарга тиеш.

Иллә мәгәр, кешеләрне яхшырту өчен, аларның кимчелекләрен фаш итәргә кирәк булды. Нәтиҗәдә «Саз чәчәге», «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять», «Вөҗдан» кебек әсәрләр язылды. Алар хакында бәхәсләр туды, каты тәнкыйтьләр дә ишетергә туры килде. Ләкин әлеге ихлас теләгем миңа ул тәнкыйтьләрне күтәрергә, үземне хаклы дип санарга бик нык ярдәм итте.

«Рәшә»дәге Зөфәр Сабитов — үз бәхете өчен генә яшәүче һәм бу бәхетне бары байлыктан гына эзләүче тип. Ул әле «инсафлы» егет, эчми-тартмый, дәүләт малын да үз кулы белән урламый (аңа китереп кенә бирәләр). Шулай да кайбер тәнкыйтьчеләр Зөфәр Сабитовны безнең җәмгыять өчен типик түгел дип таптылар. Хәтта чынбарлыкны бозу диеп бәяләделәр (рәшә кояш яктысын каплый янәсе!.. Ә тормыш нәрсә күрсәтте? «Рәшә» язылганнан соң, 5-10 ел да узмагандыр, Зөфәр ише «типик» булмаган кешеләр, безнең җәмгыятьтә яңгыр артыннан калыккан гөмбәләр шикелле, берьюлы ишәеп китте. Байлык артыннан куу, малга табыну, хәрәм юллар белән акча табарга тырышу социаль бер чиргә әйләнде дияргә дә ярый. Мин инде бу чиргә дучар булган кешеләрнең әхлакый яктан да әкренләп бозыла башлавын — комсызлык, көнчелек, хәйлә-мәкерлек, икейөзлелек, алдашу-ялганлау кебек гадәтләргә бирелеп китүләрен әйтеп тә тормыйм.

«Авыруын яшергән — үләр» диләр иде элек. Хак сүз. Әлбәттә, мин моның белән тормышның якты-уңай якларын да, гадел, намуслы кешеләрнең күбрәк булуын да һич инкарь итмим. Әмма безнең җәмгыятьнең тазалыгы өчен борчылу, аңардагы кимчелекләр өчен көенү, шуларны фаш итүдән курыкмау һәм бетерергә өндәү, — миңа калса, һәрбер намуслы язучыларның патриотик бурычы ул. Асылда язучының гражданлык йөзе дә шуның белән билгеләнә түгелме соң?!. Моның өчен классик әдәбиятны искә төшерү дә җитсә кирәк.

Мәгәр укучы: «Бу абзый үзе болай әйбәт кенә икән дә, тик менә башкалар гына начар икән шул», — дип уйлый күрмәсен. Юк, мин үземне башкалардан һич кенә дә аерырга теләмим. Мин дә кеше, һәм кешегә хас кимчелекләр миндә дә бар (аларны санап тормыйм — я арттырып җибәрермен). Гомумән, беркемне дә, шул җөмләдән язучыны да идеаллаштырырга ярамый. Безнең барыбызга да — гади эшче һәм колхозчыдан алып галимгә һәм министрга чаклы — әкренләп булса да, һаман камилләшергә һәм яхшырырга кирәк. Һәр җирдә, һәр эштә бары тик гадел һәм намуслы булып калу безнең төп кешелек сыйфатыбыз булырга тиеш. Социалистик җәмгыятебезнең тазалыгы, сафлыгы һәм раслануы, ахыр чиктә шуңа бәйләнгән... Бигайбә, мин башкача уйлый алмыйм!

...Инде миннән, ярый, аңладык, соң үзегез язучы буларак язмышыгыздан канәгатьме дип сораулары мөмкин. Тулаем алганда, әйе, канәгать... Иң мөһиме — язганнарымны укучы кабул итте, укучы яратты. Ә мин моны язучы өчен иң зур мөкафәттән саныйм. Шулай ук, тора-бара, өлкән язучылар да, яшьрәкләр

дә, әдәби тәнкыйть тә мине таныды, тану гына түгел, артыграк мактый да башлады. Кыскасы, әкренләп барысы да — исеме дә, даны да, бүләге дә килде миңа... Дөрес, кайбер канәгатьсезлек күңелдә саклана-саклануын — мәсәлән, аз сәяхәт иттем, дөньяны аз күрдем, нәфислек белән гүзәллекне дә аз күрергә туры килде — ә боларны мин язучы кеше өчен бик зарури нәрсәләр дип саныйм... Инде байлык белән мәхәббәткә килгәндә, балачактан ук хәтердә сакланган бер мәзәкне искә төшерергә була.

...Акколай авылының бер башкорт малае урамда иптәшләренә мактана икән:

— Һәй, тәмле дә соң аккалач!

— Китче! Әллә ашадың?

— Агаем Эткол базарында берәүнең ашаганын карап торган, — димеш малай эре генә.

...Мәзәк аңлашылса кирәк!

Хәер, зарлану язык булыр. Язучының бәхете — язганнарында. Әйткәнемчә, мин канәгать. Иҗат юлымның башы никадәр авыр булса да, ахыры, шөкер, уңышлы булып чыкты дип әйтә алам. Дөрес, һәр уйлаганымны яза алдым, һәр язганымнан канәгатьмен дип әйтергә җөрьәт итмәс идем. Бу инде һәрбер язучы өчен дә шулайдыр. Чын язучы гомере буена өч вакыт эчендә яши: үткәнне онытмый, бүгенгене күрә, киләчәкне уйлый... Үлгәндә дә ул, солдат шикелле, алга карап үлә торгандыр...

Бөек Гоголь: «Минем исемем үземә караганда бәхетлерәк булыр», — дигән. Мин, әлбәттә, Гоголь түгел, аның сүзләрен үземә күчерергә дә уйламыйм, әмма кайбер олы шәхесләрнең исемнәре үзләренә караганда чыннан да бәхетлерәк була. Тарихта моның мисаллары күп — безнең Тукай, Җәлил, Сәйдәшне искә төшерү дә җитә. Аларның бәхетләре — мәңгелек!.. Андый бәхет үзе эзләп таба лаеклы кешесен... Дәгъва итү мөмкин түгел.

Алты елдан артыграк оясыз буйдак булып йөргәннән соң мин, 1931 елның көзендә, Гөлсем исемле сылу гына кызга өйләндем. Бик гадәти һәм табигый эш, билгеле... Тик шулай да өйләнүнең нәрсә икәнен ничектер кыскача гына аңлатасы килә. Халыклар телендә «Рубиконны үтү (яки кичү) дигән кинаяле бер әйтем бар[1]. Мәгънәсе — хәлиткеч кыю адым ясау... Нәтиҗәсен алдан күреп бетерү мөмкин түгел. Әмма адымның үзен кеше ышанып-теләп ясый — бусы бәхәссез. Өйләнү — әнә шундыйрак нәрсә ул, минемчә.

1932 елның җәендә инде мин яшь хатыным белән беренче һәм соңгы мәртәбә Дәүләкәнгә кайттым. Вокзалда безне атакай каршы алды. Йортыбыз станциядән әллә ни ерак булмаса да, ул, яшь килен хөрмәтенә, безне бер башкорт агаеның читән тарантасына утыртып алып кайтты... Әйе, соңгы кайту, соңгы күрү, соңгы йөрүләр...

Ял вакытыбыз беткәнче, инәйнең майлы коймакларын, куе каймакларын ашап, көннәребезне күңелсез-сүлпән генә үткәрдек тә яңадан Уфа аша үзебезнең исле-тузанлы ташкалабызга юнәлдек. Шуннан соң миңа егерме ике ел Дәүләкәнне «онытып» торырга туры килде.

Әмма бу кайтуыбызның бик мөһим бер нәтиҗәсе булды. Шактый гына сөйләшү-киңәшүләрдән соң, атакайларны да Казанга күчерергә кирәк дигән карарга килдек. Икесе дә картаеп баралар, ялгызлар, энем дә кайдадыр читтә йөри, килерләре юк диярлек, карап торган бер сыерлары бар, ләкин аны асравы да читен булачак, чөнки кышын базарга печән бөтенләй чыкмый башлаган (Дим тугайларына карап, печәнсез утыр, имеш!..) ...«Ни булыр, нәрсә көтә безне?» — ди атакай, авыр көрсенеп.

Менә шундый хәлдән чыгар өчен, нишләргә кирәк?.. Уйлаштык-киңәштек тә хәзерге шартларда бергә оешып яшәүдән башка чара юк дигән нәтиҗәгә килдек. Шуннан соң инде йортны исән-имин чагында сатып, атакай белән инәй, быелдан да калмыйча, безнең янга күчеп килергә тиеш булдылар.

Әлбәттә, аларга картайган көннәрендә гомер иткән җирләреннән кубарылып күчену җиңел эш түгел иде. Борын заман кешеләре, биш-алты буын һичкая кузгалмыйча, бер урында яшәгәннәр (мәсәлән, шул ук Каргалы кешеләре), ә хәзер, җил куалаган «пәри арбасы» шикелле, алар кайдыр тәгәрәргә тиешләр. Безнең атакай 1910 елны зур өмитләр белән Каргалыдан Дәүләкәнгә күчеп килә. Аңа ул чакта әле 36 яшь кенә булган һәм ике авыл арасы да 40 чакрымнан узмаган. Икесе дә — аның өчен туган туфрак, ә Дәүләкәнне ул аеруча яратып яшәде... Инде менә шуның бәрәкәтле туфрагыннан тамырың белән кубарылып, мең чакрымдагы күз күрмәгән таш калага күчеп кара син!.. Әмма бүтән чара юк.

[1] Рубикон — борынгы Галлия белән Италия чигендәге елга исеме.

Шул ук утыз икенче елның көзендә йортыбызны ниндидер бер оешмага алты меңгә сатып, октябрь урталарында булса кирәк, атакай белән инәй Казанга күчеп килделәр. Үзләре алар күтәрә алганча төен-чемоданнар белән генә килгәннәр иде, иллә мәгәр бөтен йорт әйберләрен зур сандык-әрҗәләргә тутырып, малый скорость белән багаж итеп салганнар. Күпмедер вакыттан соң алары да исән-имин килеп житте. Минем исем китте — кием-салым, урын-жир, савыт-сабаларын гына түгел, трюмо-көзгедән алып бал мичкәсенә, кисәү агачына хәтле барлык нәрсәләрен салган булганнар, хәтта комганнарын да калдырмаганнар. Өч самавыр гына килгән иде. Тормышта барысы да кирәк була, янәсе!.. Шул нәрсәләрдән миндә хәзер бары инәйнең кызыл такыясы белән «Гарднер» фабрикасы эшләп чыгарган бер китек чынаяк кына торып калды.

Атайлар миңа дип килделәр бит инде. Ә мин үзем дә ул чакта хатынның әниләрендә торып ята идем. Кешеләрнең күңелләре киңрәк булган, күрәсең, әби дигәнем өч житкән кызы өстенә минем картларны да сыйдырды...

Ишектән керүгә, тәрәзәсез дөм караңгы кечкенә бүлмә бар иде — аларны шунда урнаштырдык. Артларыннан килгән сандык-әрҗәләрен ишегалдындагы утын сараена «төйгечләп» тутырдык. Кыш чыкканчы, алар шунда яттылар — ни хикмәттер, тиючә булмады (әллә ул чакта караклар азрак иде инде?!)... Атакай тик ятарга өйрәнмәгән, аңа нинди дә булса бер шөгыль кирәк. Шәһәри Казан белән күпмедер танышкач, үзе йөреп, Микоян фабрикасының әрҗәләр ясый торган цехына эшкә дә керде.

Билгеле, «әбиләр» өстендә озак яту мөмкин түгел иде — мин үзебезгә торыр урын табу хәстәренә керештем. Картның кулында йорт саткан акчасы, ул аны күз карасыдай саклый, безнең исәп менә шул акчага кечерәк кенә булса да бер йорт табу иде. Язга чыккач, мин бу эшкә чынлап торып тотындым. Казанның йөрмәгән жирен калдырмаганмындыр, шулай да күбрәк шәһәрнең югары ягыннан эзләдем. Күп игъланнар укып, күп урамнарны таптап йөри торгач, мин ахырда Арча кырыннан бер кечкенә агач йорт таптым. Хуҗасы — ялгыз бер маржа. Йортның өч бүлмәсе, кухнясы һәм тышкы коридорында зур гына чоланы бар. Ишегалдында бүрәнәдән салган сарае, утынлыгы, кар базы һәм безне бик кызыксындырган, йорт артында буш яткан бер биш сутый чамасы жире дә бар икән. Кыскасы, бу йорт күңелгә хуш килде, һәм без хуҗа хатын белән ничек тә килешү ягын карадык. Мәгәр бер кыенлык чыкты: йортның кухня белән янәшә зуррак бүлмәсендә ирле-хатынлы ике кеше тора икән. «Алар чагачакмы соң?» — дип сорагач, хуҗа хатын туп-туры: «Чыгара алсагыз», — дип кенә җавап бирде. Алаймыни, ә эш нәрсәдә?.. Баксаң, бу үзләрен «элекке партизаннар» дип атаган ирле-хатынлы кешеләр кайчандыр законсыз рәвештә аның бүлмәсенә басып кергән булганнар. Билгеле, зур гауга чыккан, айларга сузылган ызгыш-талаш киткән, ләкин хуҗа хатын, күпме тырышса да, барыбер аларны куып чыгара алмаган. Киресенчә әле, тегеләр үзләре моны төрлечә җәберли, кысрыклый башлаганнар... «Ялгыз башым мин аларга каршы тора алмыйм, — ди хуҗа хатын, — шуңа күрә йортымны сатып китәргә дә булдым,» — ди... Без икеләнә калдык: нишләргә?.. Күңелгә охшап өлгергән, бәясе дә безнең көч житәрлек бу гаугалы йортка аяк атлап керергәме-юкмы? Шул ук вакытта хуҗа да ашыктыра, күрәсең, бездән башка да «кодалап» йөрүчеләр бар... Шуннан артык баш ватып тормыйча, тәвәккәл таш йоткан дидек дә килешергә булдык, чөнки без инде «партизан»нан түгел, иблиснең үзеннән дә курыкмас хәлгә килеп житкән идек. Килешенгән бәясен тулысынча түләп, алу-сатуны тиешле урыннарда рәсмиләштереп, үзебезнең инде законлы йортыбызга төянеп тә килдек. Безнең килү, хуҗа хатынның чыгып китүе бер көн эчендә булды. Шуның аркасында теге «партизаннар» хуҗалар алмашынганын ничектер абайламыйча да калдылар. Әмма безнең күченгәнне күргәч, аларның кашлары жимерелде. Шунда ук безгә карата бик агрессив булачакларын сизендек, ләкин күрмәмешкә салынып, тыныч кына урнаша бирдек. Без бит әле өч ир кеше (энемнең дә Казанда чагы), шуңа күрә аларга артык игътибар итмәскә дә була иде.

Хәер, соңрак та без тыйнаклык һәм чыдамлык саклaverдык, йортның законлы хуҗасы булсак та, аларны чыгару турында сүз кузгатмадык — безгә хәзер беркем белән бернинди низагка кермичә генә урнашу, төпләнү, торып китү кирәк иде. Картлар исә безнең аеруча юашлар, ничек тә тату булырга тырышалар, ләкин бу куркудан гына түгел, ә якын күрше белән дошманлашып яшәүне белмәүдән, өйрәнмәгәннән иде.

Әмма тегеләр беренче көннән үк диярлек безгә шактый күп этлекләр эшләп карадылар. Бигрәк тә жиз самавырдай жирән, таза хатыны бичара инәйне бик җәфалады. Инәйнең эше гел кухняда, үзе бер авыз сүз русча белми, ә теге

жирән аңа акыра да жикеренә, мич-плитәгә якын жибәрми, савыт-сабаларын алып ыргыта, жылы су салып куйган комганын да берничә мәртәбә ишегалдына чыгарып атты. Инәйнең утырып елаган чаклары булды. Ләкин ул түзде — ходай үзе аңа түзәргә кушкан иде.

Инәй генә түгел, барыбыз да түзәргә тырыштык, чөнки аларны тыярлык көч-чара бездә юк иде. Шуны чамалап булса кирәк, алар безгә каршы этлекнең зуррагын да эшләделәр — «чит элементлар» өстебезгә басып керде дип, донос та яздылар (Кечкенә түгәрәк сакаллы, пөхтә генә йөргән минем картны алар «бывший мулла» дип уйлаганнар)... Миңа кайбер урыннарга барып, акланырга туры килде.

Әмма гаҗәбе шунда ки, болар бүген этлек эшләп, иртәгә шуны онытa торган кешеләр иде. Аларның яраткан эше — карта сугу... Икәү генә уйнап туйгач, хатын белән мине дә, берни булмагандай, үзләренә карта сугарга чакыралар иде. Кайчагында жирән маржаның ире — шоп-шома елтыр битле, базык-йомры гына Сембер мишәре, атай белән сөйләшер өчен, безнең якка да чыгып утыра иде... Әнә шундый татулык урнашкан көннәр дә була иде безнең шәһәр читендәге бәләкәй йортта...

Без инде бу «фатирчылар»дан бервакытта да котыла алмабыз дигән фикергә дә килгән идек. Ләкин... бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына диләрме әле — шуның төслерәк һич көтелмәгән котылу бәхетенә без дә ирештек. Кышны үткәреп, җәйгә чыккач, боларга Ташкенттан бер пар кунак килде. Ходай бирмеш, һәр көн ашадылар-эчтеләр, таңга кадәр шаулап утырдылар, көндезләрен шәһәргә, бакчаларга чыгып йөрделәр. Мәгәр ки, безнең шанлы Казаныбыз кунакларга ни сәбәптәндер бер дә ошамаган, һаман үзләренең Ташкентларын, андагы мул-тук тормышны «үтереп» мактыйлар икән... Мактау белән генә чикләнмичә, хуҗаларны да үзләре белән бергә Казанны ташлап китәргә бик кыстаганнар булса кирәк... Ә безнең «партизаннар» — теләсә нинди мәсьәләне дә артык баш ватмыйча гына чишәргә өйрәнгән кешеләр. Бәс, Ташкент Казаннан шәбрәк булгач, алар тоталар да кунакларына ияреп, җылы-җимешле якка китеп тә баралар. Шулай итеп, безгә, бүлмәне бушатыр өчен, кыл да кыймылдатырга туры килмәде.

Дөресен генә әйткәндә, без аларның чынлыкта кемнәр булуын да белмичә калдык. «Партизаннар» дип тырнаклар эченә алып язуым да йорт хуҗасыннан ишетеп калганга күрә генә... Чынмы-ялганмы — төпченергә яратмыйм, үзем дә төпченүдән туеп беткән. Гаугасыз гына аерылыштык — шуңа без бик шөкер!..

Хәзер инде үзебез генә хуҗа булып, тыныч кына яшисе калды. Атакай алтмышын тутырса да, нык, җегәрле карт әле, инәй дә бер генә көн дә эшсез торырга өйрәнмәгән. Алар, үз сүзләре белән әйткәндә, тормыш корырга ярата-лар — төпле итеп, ныклы итеп — яшәүнең мәгънәсен дә шуннан гына табалар. Өченче тапкыр инде аларның яңа урында, яңа баштан «тормыш корулары» — зарланмыйлар, авырсынмыйлар, тик бер ходайдан иминлек кенә телиләр. Без исә таяныч һәм булышчы — шуңа ышанып килделәр дә алар.

Аерым ишегалды булгач, башта тавык-чебеш үрчетә башладылар, аннары, тәвәккәлләп, сыер да алдылар (кош-кортсыз, сыерсыз торуны алар тормышка да санамыйлар иде)... Ул елларда безнең йортлар каршында иркен генә ялан бар иде, шунда терлек йөри, көтү җыелып, шуннан Казанка буена төшеп китә торган иде. Әмма сугыштан соң, бигрәк тә соңгы 15-20 ел эчендә бу тирәләр шул кадәр үзгәрде ки, хәзерге биек йортларда торучылар мондагы яланны да, тирән чокырны да, кечкенә агач чиркәүне дә, билгеле, күз алларына да китерә алмыйлар. Без үзебез дә 35 ел күршеләр белән аралашып яшәгән бәләкәй йорттан зур йортка — шуның өч бүлмәле, санузеллы бер «секциясенә» кереп бикләндек. Күптән инде вак йортлар сүтелеп, бакчалар киселеп бетте.

...Янә килеп, атакай йортыбыз артында буш яткан биш сутый чамасы җирне әкренләп бакчага әйләндерде. Аның өчен бу бөтенләй яңа эш иде. Әмма, шуңа карамастан, ул йөреп-сорашып һәм бик күп көч салып, менә дигән бакча үстерде (билгеле, минем дә шактый көчем керде). Безнең бакчада Казан туфрагында үсә торган җимеш агачларының барысы да бар иде. Мәгәр шуларның иң шәбе Владимирский дип аталган кара чия агачы иде. Карт аны каяндыр читтән алып кайтып утыртты. Якын-тирә бакчаларда да бу чия бик сирәк күренә иде. Безнең туфрак килеште булса кирәк, бик тиз алындылар, өч-дүрт ел эчендә яшьрәк алмагачларны да узып киттеләр — алар чәчәк атканда, бөтен бакча ак күбеккә күмелә торган иде... Чия, — гомумән, әрсез агач, бу «каранын» да үсентеләре күп була иде — без аларны сорап килгән таныш-белешләргә күп өләштек. Кайбер язучыларның бакчаларында да безнең татлы чия хәзер дә әле үсеп утыра торгандыр.

Сугыштан соң, без тагын бер ояга җыелдык. Әнем дә фронттан исән-сау

кайтты. Яшәү шартлары, билгеле, җиңел түгел иде, ләкин аңа әллә ни исебез китми, чөнки сугыш җиңү белән бетте, без исән калдык — менә шуның шатлыгы белән бернинди авырлыкка да бирешмичә яшәргә була иде. Хәзер инде, башта хыял иткәнчә, бергә оешып кына, җиң сызганып тора башларга кирәк... Кирәк тә бит, әмма тормыш дигәнең явыз каенанадай берәр төрле әшәкелек эшли дә тора. Без кайтканда, сәламәт кенә йөргән инәй җәй ахырына таба ничектер, әкрен генә хәлсезләнә башлады. Эче авыртудан зарланды, ашаудан калды. Күзгә күренеп саргайды һәм ябыкты... Шулай да ятмаска тырышты, йөреп азапланды, ләкин барыбер ятарга мәҗбүр булды. Күрәбез, инәйнең хәле шәптән түгел, ниндидер әшәке чир ябышканга охшый. Ул вакытта врач чакыртулар авыр иде, ярый әле үзебезнең якын туганнардан Рәкыя апа белән Суфия — икесе дә врачлар — килеп карадылар. Инәйнең янына утырып, хәлен сорашып, әйбәтләп карагач, иреннәрен кысып, бер-берсенә карашып, уйланып тордылар да әйттеләр:

— Җиңгәчәйне берәр яхшы белгеч-хирургка күрсәтергә кирәк, — диделәр. Һәм ул чакта дан тоткан хирурглардан профессор Харитоновны чакырырга куштылар.

...Андый мәшһүр белгечнең өйгә килүенә ышаныч аз иде, шулай да мин, Вишневский клиникасына барып, үтенеп карарга булдым. Һәм гаҗәпкә каршы, бу зур гәүдәле мәһабәт профессор үтенечемне кире какмады. Адресны язып алды һәм иртәгә фәлән сәгатьтә көтәргә кушты (бу инде аның тарафыннан врачлык вазифасын үтәү генә түгел, бер татар карчыгына карата олы җанлылык күрсәтү дә иде, минемчә).

Икенче көнне без, Хөзер Ильясны көткәндәй, аны көтеп алдык. Әйткән сәгатендә килде, чишенде, инәй янына узды, без ашыгып куйган урындыкка утырды, авыруга бераз карап торды да минем аша хәлен сорашты, шуннан соң инәйнең күкрәген тыңлады, ап-ак таза кулы белән күлмәк аша гына эчен кат-кат баскалап карады — инәй шул чакта бик ыңгырашты... Карап бетергәч, профессор кулын әйбәтләп юды да өстәл янына рецептлар язарга утырды. Шул чакта безгә инәйнең хәлен дә аңлатты: бавырында яман шеш булса кирәк, бердәнбер чара — операция, әмма авыр операцияне житмештән узган карчык күтәрә алмас диде. Язып калдырган дарулары авыртуны басар өчен — инәй шуларны эчеп, тыныч кына ятарга тиеш икән... Без профессорга кат-кат рәхмәтләр әйтеп, урамга чаклы озатып калдык (билгеле, без аңа күпмедер гонорар да бирдек — ул шуны карамыйча гына пальто кесәсенә салды).

Инәйдә яман шеш — бу рак дигән сүз... Ләкин ракның ни дәрәҗәдә әшәке авыру булуын, аңардан котылу мөмкин түгеллеген без әле яхшылап белми дә идек (һәр заманның үз авырулары була, күрәсең. Без тиф, туберкулез, эч китү, бизгәкләрне күреп уздырдык, ә рак белән йөрәк авыруы сугыштан соңгы елларда гына көчәеп китте)... Хәлбуки, атаклы профессор үзе килеп, карап киткәч, бездә нииндидер өмет тә туган кебек булды. Аның язып калдырган даруларын эчергәч, инәйнең үтә газаплы авыртулары да гүя басыла төште. Әмма ул мескинә иртә яуган кар шикелле көннән-көн сыза-бетә барды. Шулай ук өзелер микәнни?.. Атакай көне-төне яныннан китмичә карады... Ә көннәрдән беркөнне инәй аңардан мунчага илтеп юындыруын сораган. Өч ай буена урын өстендә хәрәкәтсез яткан авыруның бу соравы бик аңлашыла иде, әмма моны ничек итеп үтәргә?.. Шәһәр мунчаларының берсенә дә, билгеле, алып барып булмаячак... Ярый әле, ерак түгел Клыковка очында бер танышларның ак мунчалары бар иде — атакай, үзе барып, иплән кенә сорагач, ягарга рөхсәт иткәннәр. Мунчаны кызу гына ягып уздыргач, атакай кайтып, инәйне әкрен генә торгызып, аякларына пима, өстенә бәрхет тышлы төлке тунын кидереп, минем ярдәмем белән бәләкәй чанага утыртып, сак кына тартып алып китте. Числосын ачык кына хәтерләмим, ләкин бу салкын декабрь ае иде һәм беренче кар да җиргә яткан иде инде.

Шактый вакыт узганнан соң, кызарган, тиргә баткан атакай үзе генә мунчадан кайтып керде. Без куркудан коелып төштек: ни булды? «Алып кайтырлык хәлем калмады, — диде атакай өзек-өзек сулап. — Бар инде, улым, син алып кайт...»

Мин, тиз генә өстемә киеп, бүрекне эләктереп, мунчага йөгердем. Барып керсәм, инәй мунча алдында, такта стенага авыша биреп, утырып тора — аягында пималары, өстендә туны... «Инәй, мин сине алырга килдем» — дидем, һәм ике куллап сак кына күтәреп алдым — ул, кипкән көлтә кебек, җип-җиңел иде. Шул чакта гына инәй миңа дәште: «Улым, синмени бу?» — диде һәм аның күкрәгеннән үзенекенә һич охшамаган сабый балаларныкыдай бик нечкә

згыйфь кенә тавыш чыгып куйды. Йөрәгем аллә нишләп китте, тез буыннарым хәлсезләнде — бу инде дөньядан китә башлаган кешенең тавышы иде. Инәйнең көннәре генә түгел, сәгатьләре дә санаулыга калганын мин шул чакта бик ачык сизгәндәй булдым.

Әйе, ул, бичара, мунчага илтүне юкка гына сорамаган икән. Аңлаганкөткән һәм үзенең соңгы сәгатьләрен саф килеш, пакь килеш каршы алырга теләгән... Чынлап та, ике-өч көннән инәйнең хәле кичкә табан кинәт начарланды, телдән калды, беребезне дә танымас булды. Атакай, баш очына утырып, ясин чыга башлады. Ул төн буе инәй яныннан кузгалмады... Өй эче тып-тын, тик ике кызым гына татлы йокыда... Серле-хәтәр мизгелне көткәндә, күңелгә ниләр генә килми! Чыкмаган җанда өмит бар диләр — без дә могҗиза булмасмы дип көткән идек, әмма могҗиза булмады. Иренеп кенә ата башлаган салкынтоманлы таңда инәй, ниһаять, йокыга талгандай, тавышсыз-тынсыз гына дөньядан үтте...

Өебезгә кергән беренче зур үлем, беренче иң зур хәсрәт... Әҗәленә тигән чир икәнен белсәк тә, җан өшеткеч газапларын күреп торсак та, ана кешенең үлеме белән килешүе бик авыр — гүя үз гомереңнең иң газиз өлеше синнән китә, әйләнәндә һәм күңелләрдә шунда ук салкын бер бушлык туа...

Мөселман йоласы буенча мәетне озак тотарга ярамый, үлгән көнендә үк җирләргә дә кирәк иде. Без энем белән загска бару, кабер казыту кебек эшләр артыннан йөрдек, ә карчыклар, инәйне юып, кәфенләп, барлык шәригать кушканнарны үтәп, озатырга әзерләнделәр. Мөмкин кадәр җиренә җиткереп, күркәм итеп «алла хозурына» озату бичара атакайның ул көнне бердәнбер кайгысы һәм юанычы иде бугай...

Әзерләп бетүгә ике җигүле ат та килде (ул чакта автобус дигәннәренең эзе дә юк иде). Юрганга төргән инәйне иплән кенә чыгарып, үрәчәле чанага салдылар. Чананың канатларына атакай, энем, мин, тагын якыннардан берике кеше тезләнеп утырдык. Икенче үрәчәле чанага озата баручы картлар утырдылар. Әкрен генә кузгалдык. Капка төбендә «бабушка» белән саубуллашырга килгән күрше-тирәдәге маржа түтиләр, кайбер ир-атлар, үзебезнең якыннарыбыз боек кына өелешеп калдылар.

Кабер әзер, казучылар, көрәкләренә таянып, көтеп торалар иде. Кыска көн инде сүнеп тә бара, шуңа күрә җирләүне кызу тоттылар. Инәйне, юрганын ачып, кабер якасына куйгач, энем белән миңа кабергә төшәргә куштылар... Һәм без, «ике бөртек», инәйнең ак кәфенгә төргән юка-җиңел генә гәүдәсен иплән кенә алып, ләхеткә куйдык (хәтерлисездер, кечкенә балачагыбызда безне «Хәдичәттәйнең ике бөртеге» дип йөртәләр иде). Кабердән чыккач та, мин тизрәк бер читкә киттем...

Җирләү беткәч, меңләгән каберләр арасында тагын бер яңа кабер калдырып, без, караңгы төшкәндә генә, суынып беткән өебезгә кайтып кердек. Мондый көнне барысы да онытыла — ашау-эчү дә, хәтта ни дә булса уйлый алу да!..

...Уйлар соңрак килә башлый... Җитмеш өч яшендә үлеп киткән инәй бу дөньяда ни генә күрде? Бәлки кыз чагында, яшь килен булып төшкән вакытларында дөньяның бер кадәр ямен күреп калгандыр, әмма гомеренең иң күп өлешен гел эш-мәшәкатьтә азап-борчылу белән, бигрәк тә безнең өчен ут йотып үткәрде. Безнең белән бит ул юньләп яшь алмыйча да калды — без, «Сак белән Сок» шикелле, ничә тапкыр икебез ике якка киттек тә югалдык. Мондый хәл өчен кем генә, нәрсә генә гаепле булмасын, иллә мәгәр бичара ана алдында билгеле бер гаеп тоймыйча, гомер буе үкенү хисе кичермичә калу мөмкин түгел. Һәм, әйтергә кирәк, бу үкенү хисе, бәгырьдәге сызлавык шикелле, шушы көнгә кадәр, инәй яшеннән узып китсәм дә, мине һаман да ташлаганы юк әле... Уйлыйм ки, ана бик яшьли үлеп китсә дә — ана, ә баласы — сакалы агарып бетсә дә — бала — мәңге бурычлы бала!..

Инәйнең үлемен бигрәк тә атакай бик авыр кичерде. Асылда бит алар бөтен гомерләрен диярлек икәүдән-икәү генә уздырдылар — бу исә, илле өч ел буена бер-берсенә гел мохтаҗ булып яшәү дигән сүз... Михнәте-рәхәте, шатлыгы-кайгысы — барысы аларның бергә булган. Шуңадыр инде, атакай инәйне бик озак оныта алмады, безгә һаман: «Инәгез кебек зат нясен, юк, тапмассыз», — дип сөйләде, ә күңеле тулып киткән чакларда үзалдына әкрен генә: «Ятим калдым ласа!» — дип елап та ала торган иде. Без аның бу «йомшаклыгына» гаҗәпләнә идек, хәтта кәефебез дә кырыла иде, чөнки картлыкта ялгыз калуның нинди зур бәхетсезлек булуын без әле уйлый да белми идек.

Әмма үлгән артыннан үлеп булмый — инәйдән башка гына яшәп ятабыз. Сугыштан соңгы еллар безнең өчен җиңел булмады. Алдарак күрдегез инде: минем әдәбият тирәсендә эшләрем бик авыр бара иде. Кәеф начар, баш бөлген-

лектән чыкмый, киләчәгем дә билгесез... Ә атакай һаман үткәнен сагынып сөйли, минем исә сагынып сөйләрлек бернәрсәм дә юк әле. Миңа киләчәкне уйларга, киләчәкне кайгыртырга кирәк. Менә шул нигездә безнең араның салкынаеп киткән чаклары да булгалады. Янәсе, ул сату итмәгән булса, миңа да болай азапланырга туры килмәс иде... Билгеле, мондый уй кәефнең бик начар вакытында гына туа торган иде. Югыйсә, мин атакайга андый гаеп ташлауның бер ахмаклык кына булуын яхшы аңлый идем. Октябрь революциясе аның гомерен нәкъ урталай бүлде (43 яшендә була ул шул чагында). Димәк, аның яшьлеге, өлгергән ир чагы, барлык өмит-хыяллары теге заманда торып кала. Ә ул заманда сату итү хәләл кәсеп, законлы бер эш булып саналган... Я, шуннан соң ничек итеп кешене ник сәүдәгәр булдың дип гаепләргә мөмкин ди?!. Атакай яхшы укый, яхшы яза белә иде, әгәр социалистик революция бер 50 ел алданрак килсә, ул да, билгеле, сәүдә юлы белән китмәгән булыр иде. Яки, киресенчә, революция бер 50 елга соңга калса, хәзерге минем замандашларымның күпмеседер сәүдәгәр, мулла, мәзин булып китәрләр иде. Нигә, шулай түгелмени?.. Асылда бит кешенең кем булуын үз дәверенең иҗтимагый шартлары билгели (әйтик, элек мулла буласы урынга кемдер безнең шартларда галим булып китә)... Юк, мин атамны берничек тә гаепли алмыйм...

Алар, ягъни атам белән анам, гади кешеләр иде, гадел кешеләр иде — «ярамый, гөнаһ!» дигән нәрсәне беләләр иде. Һәрхәлдә, иманы да, чын аңы да булмаган хәзерге берише бәндәләрдән алар кешелек сыйфатлары белән күп өстеннәр иде... Һәм мин моны бер аларга карата гына әйтмим. Күптән күзәтеп киләм: чын инсафлы кешеләр борынрак заманның авыл картлары, әбиләре һәм укымышлы зыялылары арасында, ни хикмәттер, ешрак очрый иде. Күрәсең, аларга әхлак кагыйдәләре, нәселдән үк күчә килеп, каты тәрбия белән кереп калган булырга тиеш.

Атакай, инәйдән калып, унөч ел яшәде. 1958 елның шул ук декабрь таңында, озак авырудан соң, 84 яшендә вафат булды. Каберләре янәшә, зиратның көнбатышында, Тукай яныннан кереп киткәч... Инәйгә гади ташны атакай үзе яздырып куйдырган иде (ташта «Нигъмәтҗан зәүҗәсе» дигән сүзләр дә бар). Атакайга шундый ук ташны мин куйдырдым. Соңрак тимердән гади генә чардуган да эшләттем... Каберләренә баргалыйм. Еллар уза, ташлар туза, мин үзем дә әкренләп аларга якынлашам...

* * *

Дөньяда ике генә бәхәссез хакыйкать бар: туу һәм үлем. Без менә шул ике араны узабыз. Һәм, үзебезне белә башлаган көннән алып, иң якыннарыбызны — ата-ана, кардәш-ыру, дус-ишләрне югалта-югалта килеп җитәбез соңгы сәгатебезгә... Һәммәсен искә төшереп бетерерлек тә түгел. Әле шушы әсәрне язу дәвамында да кемнәрне генә югалтмадым! Срур тутакай, Гыйниятулла абзый, Хәбибрахман, Рәшид, Мортаза дусларны... (боларның кайберләре хакында, онытмаган булсагыз, бу китапта язып та узган идем)... Аларның һәркайсы китапның баш өлешләрен укыганнар иде, үз фикерләрен миңа телдән яки хат аша әйткәннәр иде, инде ахырын көтәләр иде... Әмма, кызганычка каршы, минем китап алар өчен чынлап та укылып бетмәгән «соңгы китап» булып калды.

Мин бик озакка сузылган шушы озын язманың ахырына якынлашып киләм. Соңгы сүземне дә әнә шул үлгән һәм исән яшәгән дусларыма багышлыйсым килә. Кеше кешедән башка яши алмый — бу да аксиома!.. Дус кирәк, сердәш кирәк, ярдәм кулын сузучы кирәк. Шуларсыз безнең әйләнәбездә салкын бушлык хасил булыр иде. Мин, табигатем белән кешегә тиз генә якыная алмасам да, чын дуслар табу ягыннан үземне бәхетле булдым дип әйтә алам (сүз монда вакыт сынавын узган гомерлек дуслар турында гына бара). Шулай ук үземнән күп олы иске буын кешеләре белән аралашуның да миңа йогынтысы зур булды. Бу җәһәттән ике җизни тиешле кешенең минем язмышымда никадәр мөһим роль уйнауларын әйтмичә уза алмыйм. Аның берсе Шәриф Хәмидулла улы Сүнчәләй — аның хакында китапның алдагы өлешләрендә язган идем инде. Икенчесе — Закуан Сафа улы Богданов... Казандагы төзүче-инженерлар институтының кафедра мөдире, математик, геодезия белгече, сугыштан соң Ленин ордены белән бүләкләнгән татар укымышлысы... Заманында Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә дә укыткан... Шәриф җизни дә, Закуан җизни дә татарча һәм русча төпле һәм ныклы белемне революциягә чаклы алганнар. Мин аларның үз телебездә шундый иркен сөйләшүләренә һәм матур язуларына һәрвакыт сокланa идем.

...Миңа яшьтән үк алар белән якыннан аралашырга туры килде. Очрашулар, утырышулар, сөйләшүләр күп булды. Һәр икесе дә табигатьләре, тәрбияләре һәм кешелек сыйфатлары белән затлы-өстен кешеләр иде. Һәрхәлдә, минем өчен — мин аларның үрнәк булырлык кешеләр икәнен һәрвакытта тоеп яшәдем. Алар миңа бервакытта да мораль укымадылар, әмма аларның «өстен торулары» мине гүя түбәнгә тәгәрәүдән гел саклап килде.

Кешенең кешегә йогынтысы гаҗәп икән ул. Кайчагында чын затлы кешене күреп кенә белү дә сине әдәп киртәсендә тота. Мисал рәвешендә бер гыйбрәтле хәлне искә төшерәсем килә...

Закуан җизнинең Василий Андреевич Яблоков дигән якын танышы бар иде. Бу — Казан университетының карт профессоры, үтә интеллигент бер кеше, борынгы дворяннар нәселеннән булса кирәк. Бер үк урамда торгач, алар, ягъни Закуан җизни белән профессор Яблоков, кичләрен гел бергә йөрергә чыга торганнар иде. Достоевский урамының очына кадәр килеп, тимер юл чокыры буенда озак кына йөргәннән соң, кайтырга борылгач, алар, безнең бакчага кереп, бераз ял итеп китәләр иде. Закуан җизни атакай белән сөйләшергә ярата иде. Өйдә булсам, мин дә яннарына чыгып утыра идем.

...Әнә шундый гадәти генә бер эш — керәләр, азрак ял итәләр дә чыгып китәләр. Ләкин аларның болай дусларча бергәләп йөрүләре һич көтмәгәндә өзелде дә куйды.

1965 елның кышында өрлектәй тап-таза Закуан җизни, гриптан соң инсульт булып, кинәт үлде дә китте. Әйтерсең, кышкы салкын аяз көндә яшен сукты — шундый вакытсыз һәм мәгънәсез үлем булды бу! Ә арык-юка гына гәүдәле карт профессор калды — җизнидән соң озак яшәде әле ул. Һәм, иң гаҗәбе — шушы миннән бик күпкә өлкән мөхтәрәм кеше, урамда очрашкан саен, минем белән эшләпәсен күтәрә төшеп, иелә биреп, кул кысып исәнләшә башлады. Һәрдаим: «Ваше здоровье?» — дип, бер генә сорау бирә, аннары яңадан, эшләпәсен күтәрә төшеп, кулны кыса да, ашыкмый гына, үз юлы белән китеп тә бара... Кабатлап әйтәм: бу ритуалны хөрмәтле профессор очрашкан саен үтәмичә калмый иде. Баштарак мин бик уңайсызлана идем: ходаем, ни өчен мондый нәзакәтлелек, мин бит аңа беркем дә түгел ләбаса?! Тик, бераз иләшә төшкәч, картның миңа игътибарын азрак аңлагандай булдым: мин бит Закуан Сафичка, якынмы-еракмы, туган тиешле, ә Закуан Сафич аның иң хөрмәт иткән кешесе булган... Бәс, шулай булгач, очрашканда, кулны кысып, исәнлекне сорамыйча үтеп китәргә ярыймы соң?!. Бу тәрбия, егетләр, безнең бик күбебезгә җитмәгән тәрбия!..

Инде замандаш дусларыма килгәндә, аларның барысы да диярлек әдәбиятны яраткан, күп укыган, ләкин әдәбияттан читтә торган кешеләр иде. Бәлки шуңа күрәдер дә минем алар белән дуслыгым тотрыклы һәм озак дәвамлы булды.

Менә Хәсән дустым Җәгъфәров! Педагог, тәҗрибәле укытучы, озак еллар техникум директоры булып торды. Күп укыган, күпне белә, китапка комсыз (мин аңа җибәргәләп торам), кыю фикерле, бәхәсне бик ярата — очрашканда, төннәр буе утырсак та, безгә вакыт җитми, сүз бетми кала. Сугыштан соң яңадан табышып, менә инде кырык ел я очрашып, я даими хат язышып торабыз.

Мин тагын мәрхүм Рәшид дустымны тирән юксыну белән исемә төшерәм. Без фронтташ дуслар идек, 1941 елның июлендә, бер эшелонга төяләп, фронтка киттек, бер частька эләктек, сугыш беткәнче диярлек, бергә хезмәт иттек. Тик армиядән бушавыбыз гына бер вакытка туры килмәде — мин 1945 елның язында ук бушадым, ә ул калды һәм бик озакка... Сугышның сәер бер хикмәте дип әйтергәме инде — фронтка нестроевой булып кына эләккән минем шушы гаять тыйнак-юаш дустым, сугыш беткәч тә, армиядән китәргә теләмәде. Гүя ул шунда үзенең туган йортын да, яраткан эшен дә тапты — бөтен гомерен соңгы көненә кадәр армия хезмәтенә бирде. Нәкъ кырык ике ел өзлексез хезмәт итеп, рядовой солдаттан майор дәрәҗәсенә менеп житте. Каты авырып, Казанга кайткан чагында да, аның өстендә погонлы китель иде әле...[1] Әмма ул һич тә сугыш кешесе түгел иде.

Рәшид Таһир улы Ильясовны укучыларга якыннанрак таныштырасым килә. Ул безнең мәшһүр мәгърифәтче галимебез Шиһабетдин Мәрҗани токымыннан, ягъни Рәшиднең әнисе Нәгыймә апа — Мәрҗани кызының кызы булган. Әтисе Таһир Ильяс — шулай ук тарихта мәгълүм кеше, дин әһеле, гарәп теле буенча зур галим, «Әлмөфит» дигән беренче «Гарәпчә — татарча» зур сүзлекне чыгаручы да ул... Революциягә кадәр «Мөхәммәдия»дә укыткан, егерменче елларның башында күпмедер вакыт «Шәрык академия»сенең профессоры да булып торган

* Ул 1983 елның ноябрендә вафат булды.

(«Шәрык академиясе» дип ул чакта хәзерге педагогия институтын атаганнар булса кирәк).

Рәшид әнә шундый нәселдән. Ләкин ул үзе турында күп сөйләргә яратмый иде, шуның аркасында мин аның ата-бабасын шактый еллар узгач кына белдем. Рәшид мәрхүмне әүлия бер кеше иде дисәм дә, һич арттыру булмас. Үтә инсафлы, үтә әдәпле иде ул — үз гомерендә бер тамчы хәмер капмады, бер тапкыр да тәтен суырмады. Хәтта фронт шартларында да!.. Монда кешенең җанын тиз күреп була. Күпме тапкырлар бик әшәке бомбежкаларга эләккән чакларыбыз булды, җаныбыз табаныбызга китә иде, ә бу ак чырайлы, күзлекле егет шул чакта да тынычлыгын җуймады, аз гына да курку-каушау күрсәтмәде.

Сугыштан соң табышкач, без хатлар язышa башладык, хатлары да саф татарча матур, акыллы язылган була иде. Миннән биш яшькә кечерәк булса да һәм иске мәдрәсәне күрмәсә дә, ул гарәп телен дә әйбәт кенә белгән икән (бала вакытында атасыннан белеп калырга өлгергән). «Соңгы китап»ның баш өлешләрендә, хата киткән гарәп сүзләрен төзәтеп, миңа хат та язган иде. Кырык ел читтә, башка халыклар арасында яшәсә дә, Рәшид үзенең туган телен дә, туган әдәбиятын да, туган халыкның күркәм сыйфатларын да онытмады, җуймады, һәрвакыт кызыксынып, белеп торырга тырышты. Бабасы Мәрҗани кебек «бөтен» кеше иде мәрхүм!..

Мин монда барлык замандаш дусларымны санап чыгуны максат итеп куймадым. Алай итсәм, сүз бик озынга китәр иде... Кемнәр, ниндирәк кешеләр белән якыннан аралашуымны күрсәтер өчен, шушы телгә алынган берничә замандашым җиткәндер дип уйлыйм. Хуш, бу өч танышымы миңа кайсы яклары белән якын, кадерлеләр?.. Алар, — әйткәнемчә, әдәбият әһелләре түгелләр, әмма әдәбиятны яхшы аңлаучылар һәм кулларына төшкәнне укып баручылар. Журналда басылган яки китап булып чыккан әйберләремне мин үзем аларга җибәрә идем, ә алар укыйлар да үз фикерләрен миңа ачык кына язып җибәрәләр. Миннән аларга берни дә кирәкми, бернинди шәхси мәнфәгать күзәтү юк, һәм шуның белән алар сүзе минем өчен кыйммәтле дә иде.

Без — замандашлар, бер үк чорларны кичергән кешеләр, бер-беребезне күптән инде яхшы беләбез, һәм шушы нигездә башланып та китте безнең арадагы дуслыклар. Әмма дуслыкны чын иткән, нык иткән нәрсә — бер-береңә ышану... Кеше булып калуыбызга ышану дияр идем мин. Хәтерләр калганда да, бәхәсләр туганда да — теләсә нинди хәлләрдә дә!.. Әнә шундый ышану туган иде безнең арада да. Бик кадерле нәрсә ул ихлас дуслык!

Ләкин сездә, укучым, ни өчен язучы дусларыгыз турында бер сүз дә юк дигән сорау туарга бик мөмкин. Әйе, мин алар турында язуны хәзергә калдырып торырга булдым. Даими аралашып яшәгән кешеләр хакында арттырмый-киметми һәм берәүне дә үпкәләтми язуы шактый четерекле-читен эш... Әлбәттә, минем бик күптән дус күргән, яраткан, хөрмәт иткән язучыларым бар, шулай ук ярата, якыная алмаганнарым яки, кайчандыр якын күреп тә, соңыннан гайрәтем чиккәннәре дә юк түгел. Кыскасы, язучыларга кагылмыйча узуымны, шәт, аңларсыз дип уйлыйм...

...Шулай да... әмма шулай да мин бер шагыйрь турында кыскача гына булса да әйтмичә уза алмыйм. Ул үзе дөньяда күптән юк инде, ләкин исеме аның теләрдән төшмәс булды... Әйтергә теләгәнем — Муса Җәлил турында... Мин аның белән егерменче елларның икенче яртысында танышкан идем. Һәм, ни хикмәттер, шушы читтән Казанга вакытлыча гына килеп йөргән шагыйрьгә шактый ук якынлашырга да өлгердем. Шулай итеп, Муса белән дусларча аралашу бер биш-алты ел дәвам итте, ләкин 1934 (яки 35) елдан алып сугыш башланганчыга кадәр безгә бүтән очрашырга туры килмәде (бу вакыт эчендә мин Казаннан ике мәртәбә китеп тә тордым)... Хәзер менә Мусаның без аралашкан чаклардагы кыяфәтен, шәхси сыйфатларын, хәтердә кайсы яклары белән сакланып калуын арттырмыйча-киметмичә күз алдына китерергә тырышам. Җыйнак гәүдәле кечерәк кенә егет. Үзе дә, өс-башы да гади генә. Холкы-тотышы белән тыйнак, күп сөйләргә яратмый — бигрәк тә, үзе турында, инде сөйли башласа, хис кешесенә хас булганча, бераз кабаланыбрак, дулкынланып сөйли (кызганыч, миңа аны бер тапкыр да трибунадан тыңларга туры килмәде), кешегә мөгамәләсе йомшак, тынлый белә, фикерен уйлап әйтә, үзен өстен кую яки мактану дигән нәрсә аңарда юк, шулай ук акыл сатарга, кеше өйрәтергә дә яратмый иде, минемчә — тагын нәрсә?.. Безнең бит әле дәртле, яшь чакларыбыз — билгеле инде, уен-көлке, җыр-музыканы бик ярата идек. Белмим, кем генә ул чакта менә сугыш булыр да, Муса барыбызны да таң калдырырлык батырлыклар эшләр дип уйлый алды икән?! (мөгаен, Мусаның үзенә дә андый уй юри генә дә килмәгәндер). Ул бит шагыйрь, нечкә күңелле шагыйрь — ә шагыйрьне без канлы сугыш кырында

түгел, бәлки шигърият бакчасында күрергә гадәтләнгәнбез. Һәм аның кыюлыгын да ялкынлы сүзләреннән котәбез... Шуңадыр ахрысы, мин хәзер дә әле Мусаның тәненә уратылган чәнечкеле тимерчыбыкны өзәргә омтылган һәйкәлен хәтеремдә яхшы сакланган чын тере Муса итеп таный алмыйм. Әмма аңлыйм: бу инде образга әверелгән Муса, һәм без аны әнә шулай фашизм зынҗырларын өзүче образ итеп кабул да итәбез.

...Язмышның серләренә төшенеп бетәрлек тә түгел. Сугыш башланудан берничә ай элек кенә Муса Җәлилне, үзенең соравы буенча, Язучылар союзы идарәсе председательлегеннән азат иткән булганнар. Әгәр шул урынында калган булса, ихтимал, аны фронтка җибәрмәсләр дә иде. Әмма язмыш аңа икенче бер бөек миссияне йөкли: ул газиз башы бәрабәренә бөтен дөнья алдында фашизм тырнагына эләккән татар солдатларының йөзләрен акларга тиеш була... Һәм үти ул бу гаять куркыныч изге миссияне үзенең көрәштәш унбер иптәше белән бергә!.. Кайдан бу батырлык? Мусаның үзенә килгәндә, минем ни өчендер беренче нәүбәттә аның батырлыгын хәтеремдә ачык сакланган тыйнаклыгы һәм шагыйрь җанлы булуы белән бәйлисем килә... Шул гынамы диярсез, бәлки... Калганын башкалар әйтер... Һәрхәлдә, мин Муса батырлыгын аның табигатеннән аерып карый алмыйм. Ул — минем өчен абстракт образ түгел, ә конкрет тере кеше — үлсә дә, легендага әйләнсә дә!..

* * *

Инде менә язманың ахырына да җиттек. Тәмамларга вакыт. Болай да бик озакка һәм бик озынга сузылды. Хәлбуки, шуңа карамастан, мин бөтен белгәнемне һәм уйлаганымны монда язып бетердем дип әйтмәс идем. Мөмкин дә түгел бу, чөнки безгә вакыт хуҗа, без вакыт таләбенә буйсынабыз. Укучы да моны исендә тотсын иде. Бәлки, киләчәктә мин әйтеп бетермәгәнне тикшеренүчеләр әйтеп бирерләр — алар бит кайчагында үзең белмәгәнне дә казып чыгаралар.

Язманың «Соңгы китап» дип аталуын күпләр яратмадылар. «Соңгысы булмасын!» — дигән теләк белдерүчеләр дә булды. Рәхмәт, аларга!.. Илебез бик әһәмиятле, бик җаваплы чорны кичерә. Партия халыкка әйтте: «Социализмны камилләштерергә кирәк», — диде. Сүз дә юк, бу һәркемнең күңелендә яткан кайнар теләге — һәм бу изге теләк, бу бөек максат өчен яшәргә дә, эшләргә дә була әле...

...Әнә шул якты өмит белән без дә хәзергә каләмебезне куйдык. Хушыгыз!..

*1985 ел, октябрь.*

## Рифгать Закиров

### Туган туфрак

Кыр ягыдай ачык җаным:
Эчемдә ни — тышымда шул.
«Туган туфрак» — димәс идем,
Бар булганым шушында шул!..

Туган туфрак — кара туфрак,
Ак бәхетем балкыган җир.
Монда күпме кайгыларым
Чүбек булып талкынгандыр...

Кыр ягының якынлыгы
Аннан гына түгел ләкин,
Бу якларда хыял татлы,
Йөзләр якты, күңелләр киң.

Су басса да нурлы бу як!
Тик аз гына моңсуырак:
Үрләр ерак, су мулырак,
Кыр-туфрак дымсуырак...

### Сулар ага, җилләр исә...

Сөеп-сыйпап акса да су,
Юаш кына какса да су,
Боз астында калса да су,
Ярны ишә, комнар күчә...

Тамчы булып тамса да су,
Ташкын булып ташса да су,
Җыелып-тынып ятса да су,
Ташны тишә, юлны кисә...

Бусаң, сыймый кысага су:
Кысрыклый — кыса да су,
Тарая кыр, сыгыла басу —
Бар авырлык җиргә төшә?!.

---

РИФГАТЬ ЗАКИРОВ *(1938) — «Шахтер моңы» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Бер шик туа ихтыярсыз:
Я су әрсез, я без гамьсез...
Су буйларсыз... Ни уйларсыз?..
Дип гөнаһсыз җилләр исә.

## Билгесез югалган солдатларга

Сез киләсез агымсулар аша,
Сез киләсез шаулы еллар аша;
Сез киләсез һаман
Безгә табан,
Һәйкәл булып торып баса-баса.

Сез чыгасыз кичеп сазлык аша,
Сез чыгасыз килеп ялкын аша...
Сез үткән чик ераклашкан саен
Үлемсезлек сезгә якынлаша!

Сез билгесез.
Әмма сез үлемсез —
Сез торасыз басып нык җирлектә;
Сезне сугыш бер үтерсә, халык
Хәтерендә кабат мең терелтә!

Сез узарсыз заман-чорлар аша,
Яңгырарсыз яңа җырлар аша.
Сез барырсыз һаман
Алга табан,
Таңнан — таңга, ерак елларгача!

................

**Ринат Мөхәммәдиев**

# ИСТӘЛЕК ӨЧЕН — ГЫЙЛЕМХАНГА...

ПОВЕСТЬ



Ниһаять, соңгы үрне менеп, тау итәгендә таралып яткан авыл каршына килеп чыкты Гыйлемхан. Туктап калды. Күкрәк тутырып сулыш алды. Күпме гомер җанын иләсләндереп берөзлексез үзенә тартып торган төбәк, балачак хатирәләрен, үсмерчак һәм яшьлек елларының бәгырьгә уелган сукмакларын саклаган җир — туган авыл шушы була... Кулындагы чемоданын язгы йомшак чирәм өстенә куеп, уч төбендәгедәй күренеп торган авылга хәйран озак карап торды ул. Тау итәгеннән үк аккан инеш, аның куеныннан ургып чыккан чишмәләр, аркылыга-буйга сузылган урамнар, тар тыкрыклар — һәммәсе үз урыннарында кебек. Ара-тирә бушап калган йорт урыннары күзгә чалына. Моннан, югарыдан караганда, авыз эчендәге бушап калган теш урыннарын хәтерләтә сыман әлеге урыннар. Туган авылы белән алыш-бирешне югалткан, нәсел-ыру тамырын өзгән бер ул гына түгел иде, күрәмсең...

Челләдә исеп куйган кайнар җилдәй тәэсир итте бу манзара, күңелендә каршылыклы хисләр уянып алды. «Димәк, авылга юлны онытучылар байтак икән әле»,— дип аклану эзләргә тырышты ул. Әмма тамак төбенә килеп буылган төер тынычланырга ирек бирмәде. Бушап калган йорт урыны — теш казнасындагы чокырлар гына түгел шул. Тешнең алтынын, тимерен, фарфорын, үзеңнекеннән аерып булмастаен да куйдыртып була. Ә йорт урыннары — әйләнә-тирәсен тигәнәк, алабутакычыткан баскан чокыр гына түгел. Һәркайсы язмыш дигән сүз. Нәсел чылбырын дәвам итәргә тиешле дистәләгән язмышның чит җирләрдә җирсеп сагынуыннан уелган яра урыннары алар.

Беренче тәэсирләрен җиңеп, үз-үзен кулга алды ул. Һәм барларга кереште: авылдан кемнәр киткән, анда кемнәр калган... Өске урамда Кәрам абыйлар урыны бушап калган. Ат караучы иде. Ат җене кагылган кеше. Менә сиңа мә, Кәрам абыйлар нигезе бушаган... Миңзифа апа, Мәрьям апалар да сынган булып чыга — сугышта ирләрен югалтып, мәңгелек толлыкка дучар ителгән хатыннар...

Янәшәдә кырмыска оясы булган, күрәмсең, тынгысызланып, аяккулларын сыпыргалап алды ул. Кырмыска гына булса икән, Мөгтәсим абыйлар нигезе дә ятим түгелме соң?! Җиде кыз үстерә иде алар хатыны белән. Иң олылары, Миңсылу исемлесе, Гыйлемханнан яшь ярымга гына кече. Димәк, Миңсылу да киткән булып чыга. Ә аның Миңсылу тормыш корган, балалар үстергән йортның тәрәзә йөзлекләрен генә булса да урамнан бер күреп узасы килә иде...

---

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(1948) — прозаик һәм тәнкыйтьче. «Беренче умырзая», «Ак кыялар турында хыял» исемле повестьлар авторы. Әдәби тәнкыйть һәм балалар әдәбияты өлкәсендә дә эшли.*

Әле һаман авылның чит-читләрен күзәтә иде Гыйлемхан, туган нигезгә күз төшермәскә тырышты моңарчы. Көтеп алынган бәхетле мизгелне беразга гына булса да кичектереп торырга ниятли идеме, әллә киресенчә, ул тарафка караудан курыктымы... Моңаеп утырган иске җимерек йортны яисә шул йорт торган урындагы буш нигезне күрергә әзерләнгән иде ул. Кырык ел чамасы элек тәрәзәләренә үзе такта кадаклап киткән, канаты салынган коштай бераз чүгә төшеп, аны озатып калган иске йорт күренмәде. Аның урынына алты почмаклы яңа йорт калкып чыккан. Үз күзләренә ышанасы килми торды бер тын. Аның саен вак кырмыска тынгылык бирмәде, аяк-кул белән генә чикләнмичә, берничәсе яка эченә үк үрмәләргә өлгергән иде инде. Ул да түгел, кул аркасын артыш куак чәнчеп алды...

Юк, туып-үскән нигезенең буш торуын, җимерек каралты-кураларның сыкрау авазын ишетергә теләмәгән иде ул. Әмма кемдер, башка чит бер кеше, аның туган нигезенә күз явын алырлык йорт салып чыгар дип тә башына китермәде.

Авылга кайткач, кемгә төшү, кайда тукталу хәл ителмәгән иде әле. Аяклар туган нигезгә каерды. Су буеннан күтәрелгән тыкрыкның уртасыннан җәт-җәт атлап менде ул. Бер кулына — олы кара чемодан, икенчесенә өстендәге костюмын салып тоткан. Гүя аны аяклары түгел, күзгә күренмәгән могҗизалы канатлар, җан ашкынуы алып бара. Авылга килеп чыккан сәер юлчыны танырга теләгәндәй, тәрәзәләргә капланып калган хатын-кызда да, үзе артыннан ияргән малай-шалайда да гаме юк иде аның. Әнә, тагы бераз, тагы ике-өч йорт үтәсе дә, аннан... Ул туган нигез бусагасында...

— Абзый кеше, сиңа нәмә кирәк?—дигән сораудан сискәнеп китте ул.

Гыйлемхан, карашын чиксезлеккә текәп, койма читендә үсеп утырган карт каен кәүсәсенә сөялеп тора иде. Әтисе яшь чакта утырткан өч каенның берсе... Фронттан кайгылы хат килгәч, шушы каен төбендә үскән бәпкә үләннәрен тырный-тырный үксегәне хәтерендә. Көтү каршылаган чакта шул каеннан чыбык сындырып алганы өчен югары очның Расих атлы малае белән борын җимергәнче әүмәкләшкәне... Әнисенең: «Каеннар әтиеңнең төсе»,— дигән сүзе...

— Абзый дим, сиңа дәшәм, син чукракмы әллә?! — дип дәште аңар янә теге тавыш.

Капка төбендә шырпы кабыннан китеп алынган чыра белән теш каезлап торган бу ир уртасы кешене Гыйлемхан танымады. Шуңа ни дияргә белмәде, әле үзенең аяк очына, әле ялгыз каенның бирчәеп чыккан калын-кара кайрыларына карангалап торды.

— Чукрак кына түгел, телсез дә ахры...— дип сөйләнде капкадан чыгучы үзалдына. Гөманлавының дөреслегенә шиге калмаган иде, күрәсең. Шулай да, Гыйлемханның карашыннан күпмедер сынау төсмере сиземләп, бу юлы инде тавышын күтәрә төшеп, тагы дәште:

— Нәмә кирәк дим?.. Чукрак что ли?..

Русчасы чамалы булгандыр, аның сүзләре бу юлы бермәбер дорфарак яңгырады.

— Өч каен иде, икесен кая куйдың? — дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Гыйлемхан. Җаныннан саркып чыккан иң авыр сорау иде бу.

Хуҗа кеше каушый төште, хәтта теш казый торган чырасын теленә ябыштырып төкерде. Күрәмсең, көтелмәгәнрәк булып чыкты сорау. Ул бит аны телсез-чукрак бер чит кешегә чыгарган иде. Ялгышкан түгелме? Теле дә бар, ишетә дә икән бит. Өстәвенә, әллә кайчан кискән, онытылган каеннарны таптырып маташа. Сәер кеше булып чыга түгелме соң әле бу?..

Хуҗа кешенең бер мәлгә югалып торуыннан файдаланып, Гыйлемхан аңарга үз сүзләрен кире кайтарды:

— Синнән соравым... Нәмә кирәк? Чукрак что ли?..

Ирексездән, икәве берьюлы елмаеп куйдылар. Уйламаганда-көтмәгәндә килеп чыккан бу шаярту хуҗа кешегә ошап китте ахры, шундук кулын сузып, Гыйлемхан каршына исәнләшергә килде ул.

— Исәннәрме, абзый кеше?! Нәҗип булам. Бригадир.

— Әйбәт кенә, энекәш, аллага шөкер. Гыйлемхан. Үзем пенсионер.

— Ә-ә,— дип һава иснәп куйды хуҗа кеше, төс-кыяфәтенә «әллә кем түгелсең икән әле...» дигән бер мәгънә чыгарып.— Җил сугарып, корыны бушка аударып йөрү инде алайса?.. Тә-әк,— дип сузып куйды шундук, алдагы сүзләренә җавап кайтарып ара калдырмыйча.— Кай яклардан җил ташлады, пенсионер абзый? Ниләр кырып, ниләр майтардыгыз инде?..

Хуҗа кешенең үз-үзен тотышы, аның сүз сөреше сару кайнаткыч иде. Мыскыл катыш бирелгән сораулар да күңеленә барып тимәде түгел. Шулай да, туган авылына кайтып, анда очрап сүз кушкан беренче кеше белән үк ачуланышу башка сыймый. Кешесе дә килде-китте түгел, аның туган нигезенә хуҗа булып калган... Булдыра алганча тыныч һәм ипле итеп җавап кайтарырга тырышты Гыйлемхан:

— Кемерово дигән җирне ишеткәнегез бардыр?.. Шахтада эшләдем. Соңгы арада, җир өстенә күтәрелгәч, балта-пычкы токаларга туры килде.

— Шахтер, димәк,— дип җанланып китте хуҗа кеше,— нигә аны баштук шулай димисең. Балта-пычкы, имеш... Пенсионер, имеш... Пенсионер дигән сүз юк авылда. Җегәре бар һәркем эштә безнең. Картыяше дөнья куа. Пенсия алам дип, кул кушырып утыручы юк. Шахтер!.. Менә монысы башка нәрсә. Шахтерлар почетта!

— Алай икән...

— Ай-һай, чумадан зур синең,— дип, каен төбенә таба ымлады хуҗа, аның саен сөйләшәсе, төпченәсе килеп. Һәм бөтенләй уйламаган җирдән, серле генә күз кыса төшеп, сорап куйды.— Акчамы?..

— Анысы да бар...

— Шахтерлар акчаны көрәп ала диләр шул...

Ни дияргә белмәде Гыйлемхан, дәшми калу иде уенда. Әмма авызын ача төшеп, үзенә текәлгән, җавап көткән хуҗаның күзләрендәге ихлас, балаларча кызыксынуны күргәч, дәшми булдыра алмады.

— Шахтермы?.. Акча түгел, күмер көри шахтер.

— Ну, күпме?.. Әйт, шулай да күпме төшә?..

Җавап бирмәсәң, менә хәзер буылып үләм дигән сыман, кабаланып, сусап көтә иде хуҗа җавапны.

— Күпме дип... Әйбәт кенә эшләп килгәндә, дүрт йөз чамасы чыгып бара иде үзе...

Бригадирның исе китмәде андый акчага, күбрәкне көткән иде булса кирәк, кулын гына селтәде.

— Шул тикле җирләргә китеп йөрмәсәң дә эшләп була ич аны. Әнә, минем олы малай Чаллыда эшли, кечесе авылда, комбайнда, билләһи газим, синнән ким алмыйлар. Хатын сыер сава, үзем бригадир,— дип, янә үзенең кемлеген, күкрәк какмаса да, масаю катыш горурлык белән искәртергә кирәк тапты.— Айга шул, уртача, мең тирәсе кайтып тора. Бәрәңгесе, яшелчәсе — бакчадан, тегесе-монысын да сатып алмыйсың... Ә инде ит-сөт дисәң...— Мәгънәле генә пауза ясап, муеннан дигәнне аңлатты, бармагы белән ияк турыннан аркылы сызып күрсәтте.— Ну, калганын, калганын сатабыз. Ел тәүлегендә бер-ике төшәдер анысыннан да. Җитә шунда, безгә, мужик халкына...

Сөйләгәннәренә таң калып тыңлаганны, шаккатканны, тел шартлатканны көтә иде бугай хуҗа кеше. Гыйлемханның исе китмәде. Авылда тормышның бөтәя баруын ул болай да чамалый иде инде. Бригадирның сөйләгәненә ләм-мим сүз кузгатмастан, баядан бирле тел очында торган соравын бирергә ашыкты:

— Каеннарның башка икесе корыдымы?

Янә, каян белә соң әле бу чит-ят кеше аның койма читендә үскән каеннарның исәбен, диган уй кузгалып алды бригадирда. Югыйсә төпләрен куптарып атканга да бишбылтыр. Авылга килгән-киткән кешегә охшамаган, танымаса, төсмерләр иде бит ул аны.

— Корымады. Кистем,— диде ул дорфа гына, үзенең берни аңлый алмавына кәефе кырылып.

— Ничек? Ничек кистең?!

— Менә болай, автопычкы алып чыктым да газга бастым. Шалт бер каен, шалт икенчесе... Өченчесенә өлгерә алмый калдым... Кече малай җылап кайтып керде. Бәләкәй иде шул... «Тимә каенга,— ди.— Мин бит аның әкәен яратам»,— ди... Шул калудан калды.— Һәм, ниһаять, кызыксынуы чамадан ашып, сорарга мәҗбүр булды ул: — Билләһи газим дим, абзый кеше, син ул каеннарның өчәү булганын каян беләсең?

Тирән сулыш алды Гыйлемхан:

— Сиңа ни зыяны тиде ул каеннарның? Ничек кул күтәрдең, ни дип кистең син аларны?

Сорауның болай куелуы тәкәббер хуҗага ошап җитмәде, әлбәттә.

— Нәмә утырту, нәмә кисү — минем эш, абзый кеше. Үз хуҗалыгым.— Ә тагы бер тын уйланып торгач, ачыклык кертергә кирәк тапты: — Каен да булдымы агач?!. Аңардан кем файда күргән... Мужик кына булсак та, беләбез... Ну, алмагач яки чия булса, агач башка — эш башка ул чакта. Ашап та, сатып та була аларын. Каен... ул нәрсә? Күз көеге. Башка берни түгел, урманда да үстермиләр ич аны хәзер... Утынга дисәң инде... Утынга бара. Теге икесен мин аның шулай иттем дә. Мичкә яктым. Вәссәлам! Ә хәзер утын кирәкми. Газ!

Хуҗа кешенең теленә салынырга яратуын Гыйлемхан чамалап алган иде инде. Әмма әлегәчә төшенә алмый газапланды: мин-минлеге, мактанчыклыгы шул дәрәҗә идеме аның, әллә аны түбәнсетеп, аны үртәргә маташамы ул? Шулай да, сүзне икенчегә бору уе белән, хуҗаның салпы ягына салам кыстырырга булды:

— Өйнең шәбен салгансың бит, ә?!

Күз алдында үзгәреп, балкып китте хуҗа. Авыз читләре җәелә төшеп, тартышып-тартышып куйды аның, күзләренә очкын йөгерде. Һәм әлеге көтелмәгән борылыштан, ни дияргә белми югалып, йомшарып калды.

— Әллә ошады? — дип сорап куйды ул үзен дә белешмәстән. Ләкин бу халәт озак дәвам итмәде, үзен кулга алырга өлгерде бригадир.— Мужик кына булсак та, үзебезгә күрә ярап тора шунда.

— Бер диган ич. Авылда бер диган йорт...

— «Авылда бер» дип, абзый кеше, арттырып җибәрәсең анысы. «Авылда бер» кирәк түгел безгә.

— Йортың әйбәт, Нәҗип. Мин аны авылга кергәнче үк, тау башыннан ук чамалап өлгергән идем...

— Юк, абзый кеше, безгә авылда бер диган йорт ярамый. Һәр нәрсә дәрәҗәңә күрә булырга тиеш. Әйтик, председательнекеннән уздыра аламмы мин?.. Ярамый! Ярамый, абзый кеше! Председательнеке — персидәтелчә, бригадирныкы бригадирча булырга тиеш. Миндә өйнең сигез тәрәзәлесе булса, аңарда — уникеле. Аңарда «Волга» икән, миңарга «Жигули» да җитеп ашкан. Чама белү зыян итми юкса...

— Шулай укмы?..

— Айдан төшмәгәнсең ләса... Я, әйт, кайда, кайсы авылда, кайсы шәһәрдә, кайсы илдә нәчәлник кешенең үзеннән уздыручыны ошатканы бар? Син теге, мужик дигәч тә, безне наданга чыгарма, абзый кеше. Без дә алны-артны аерырга өйрәнгән.

— Ә менә безнең шахтада...— дип, чынлап фикер алышырга керешкән иде Гыйлемхан, сөйләргә ирек бирмәде, ярты сүздән бүлдерде хуҗа кеше:

— Беләм, абзый кеше, беләм... Шулай кыланып, авторитет яуларга

йөрүчеләрен дә беләм. Урламай, эчмәй, хатын-кыз белән дә чуалмай дип әйтәсең килә... Бәлки, эшкә дә җәяү йөри торгандыр әле?.. Ишеткән бар андыйлары турында да... Ләкин ни өчендер бераздан аларның теге тимер яшникләреннән, сейф диләрме әле, алтын килеп чыга. Әнә безнең районның теге ни начальнигы да җиде-сигез ел үтүкләнмәгән костюмнан йөрде...

Нәҗипнең яман «чире» — башлаган сүзне әйтергә ирек бирми, әңгәмәдәшен ярты юлда бүлдерү гадәте Гыйлемханга да күчеп өлгерде ахры... Ул да, аның ни сөйләячеген алдан ук чамалап (хезмәт урыныннан яман файдаланып, ниндидер махинацияләр юлы белән шыпырт кына, яшертен генә еллар дәвамына байлык туплап яткан адәм затлары очраштыра ич кайда да), сүзгә ялганырга ашыкты.

— Бар, Нәҗип дус, кызганычка каршы, андыйлар да бар. Ә мена бөтен житәкчене бер чыбыктан сөрүең ошап җитми миңа...

Өлкән кешенең үзенә хөрмәт белән дәшүе бригадирга тәэсир итми калмагандыр. Ул да, бер генә тапкыр булса да, үзенең килешкәнлеген белдерүдән тайчанмады.

— Юк, мин әйтмәем, бөтенесе бер чыбыктан сөрелгәндер дип... Мин үзебезнекеләрдән чыгып фикер йөртәм. Бардыр... Тик минә аның нәчәлниге рәтле булса, хатынын кая куясың? Ай-һай, яман да була соң нәчәлник хатыннары! Ир-ат мескен нишләсен, колак итен ашап торсалар, буйсынмый да булмый... Бер юрган астында йоклагач, кая барасың. Дөньяны бит, нәләт төшкән, шул хатын-кыз бутый аны...

Килешсә-килешмәсә дә, баш кагып торды Гыйлемхан, бригадирның ихластан, чын күңелдән фикер уртаклашуы ошап китте күңеленә.

— Менә минекен генә алыйк,— дип дәвам итте Нәҗип.— Үзе болай, түрдәге креслога җәелеп утырып өйрәтүче дә булмасын ди... Эшен умырып эшли. Өйдә дә житешә, ул кадәресенә тел-теш тидерә алмыйм анысы. Тик минә шул, нәләт төшкән дидем бит әле, өйрәтергә ярата. Йорт диде, йорт салып кердем. Капка диде, капкасын торгыздым. Машина да аныңча... Карар вакыты булмаса да, телевизор алдырды. Төслесен! Билләһи газим менә, маркаларына тикле белеп сөйләшә. Күрәсең, сыер имие тартканда да телевизор барлыйлар... Беркөнне әйтә: «Безнең завферма,— ди,— өй түбәсен калайдан яптырып куйган,— ди.— Буяп та җибәргәч, күз явын алып тора менә,— ди.— Ә син, бригадир булып та...» — ди. Шиферын куптарып, калайдан ябарга туры килде түбәне. Менә шулай, абзый кеше, башыңа төшсә, башмакчы буласың икән аны... Бүген иртән тагы яңалык алып кайткан: «Түбән оч бригадиры өй күтәрткән,— ди.— Безнекеннән биек түгелме, ходаем»,— ди. Шуны карарга чыгып бару иде дә, син очрадың...

Ни дияргә мөмкин, бәхәсләшеп тормады Гыйлемхан.

— Алай икән...— белән чикләнде һәм, китәргә җыенып, чемоданына үрелде.

Бригадир да, сәгатенә күз төшереп алгач, кабаланып, кузгалырга итте. Шул рәвешле, хушлашырга да онытып, икесе ике тарафка китеп аерылышалар иде инде. Әмма тагы бер мәртәбә туган нигезенә күз салып алган Гыйлемхан дәшми булдыра алмады:

— Нәҗип дус, тәрәзәләрең йөзлексез түгелме соң?..

Әле беренче күрүдә үк, бу йортның кайсыдыр ягы күңеленә бигүк ятып бетмәгәндәй тоелган иде аның. Әмма кай ягы килеп җитмәгән — шушы вакыткача ачык кына төшенә алмый тора иде. Баксаң, тәрәзәләр йөзлексез икән. Дүрт яктан дүрт такта кадаклап куйганнар да, вәссәлам.

— Нәрсә, минем тәрәзәләргә нәмә булган? — дип, берни аңышмый туктап калды хуҗа кеше.

— Тәрәзәләрең йөзлексез икән ич.

— Ул ниткән йөзлек тагы?.. Йөзлекнең мин кыштырдап торганын гына беләм,— дип, үзенең тапкырлыгыннан кәефе булып, елмаеп җибәрде ул.

— Тәрәзәләрнең чит-читләрен бизәкләп эшлиләр... Йөзлек диләрме, кашагамы, наличникмы — хикмәт исемдә түгел.

Хуҗа кеше берни аңламыйча карап торды-торды да кул селтәде.

— Хет син катырма инде башны... Кешенекеннән ким түгелме? Түгел! Нәмә кирәк тагы... Хуш, абзый кеше, хуш!



* * *

Туганнан туышкан апаларында тукталды Гыйлемхан.

— Гыйлемхан... Гыйлемхан энем кайткан минем,— ди-ди куанды апасы, келәт белән өстәл арасын таптарга керешеп.

Язмыш үзенекен иткән: сугыштан кайтмаган ирен гомере буе көтеп, берьялгызы чәч агарткан, бөкре чыгарган Дәүапасы тәмам бетерешкән иде аның. Төшереп бәйләнгән чуклы яулык уртасында нибарысы аркылыга-буйга ергачланган җыерчыклардан гыйбарәт нәни какча йөз утырып калган. Салынып төшкән иңбашларына борчак-борчак бизәк төшерелгән аксыл-зәңгәр күлмәк эленгән. Шул күлмәкнең ике ягыннан чәбе таякларыдай шәрәләнгән калак сөякләре төртеп тора. Менә авам, менә җимереләм дип торган салам түбәле иске каралтыны хәтерләткән гәүдәне бары кулындагы таяк кына тотып тора сыман. Юынылмаган иске куак таяк аның үз буе кадәр диярлек, һәм ул аңар, таянудан бигрәк, алга авышкан гәүдәсен терәү, сөяп тору өчен хезмәт итә иде, күрәмсең.

— Гый-лем-хан, Гыйлемхан энем кайткан бит минем,— дип кабатлады ул аның саен. Елмаерга тели иде булса кирәк үзе, һәрхәлдә, чын күңеленнән куанып дәшә иде. Әмма, тармагында кышка калып бөрешкән, төсен югалткан чия сыман ирен читләре, эчкә батып, күләгәдә яшеренгән күзләр аның күңелендәге куанычка битараф иде. Ыжгырып котырган буранда кыек читендәге чәрдәкләнгән такта чыгаргандай калтыранулы аваз бер көчәя, бер сүнә...

— Дәүапам,— дип, малай чактагыча дәште аңар Гыйлемхан. Түзмәде, тулышкан күзләрен күрсәтүдән уңайсызланып, аны уң кулы белән кочагына алды. Кочагына алды алуын, әмма абайламады — әллә апасын, әллә бушлыкны кочаклады. Аның култык астында идәнгәчә салынып төшкән борчак-борчак бизәкле күлмәктән башка гүя һични юк иде. Дөрес, анда олы җан бар иде, әмма тән барлыгын ул тоймады.

— Гыйлем-ха-ан энем кайткан бит,— дип кабатлавыннан туктамыйча, ул өстәл почмагына килеп сөялде, бер кулына ак шадра тастымал алып, чәй тәлинкәләрен сөртергә керешге. Үтә пөхтәлек белән барын да җиренә җиткереп хәстәрләде ул. Бераздан моңарчы сандык өстендә утырган Гыйлемханны өстәл янына чакырып, аңарга таба өстенә нәни мендәр салынган урындык этеп куйды. Ак күмәч, шикәр һәм май өстенә капланган чигүле ак тастымал да ачылды. Өстәл түрендә утырган самавыр байтактан кайнап чыккан иде инде, күтәрелгән парда лебер-лебер җиз түбәтәйләре сикергәләп тора. Өй эчендә җылылык хөкем сөрә, табында нур балкый иде...

Еракта, бик еракта калган балачак хәтирәләре яңарды Гыйлемхан күңелендә. Сагындырып кына кунакка төшә иде ул бу өйгә. Апасы белән җизнәсе аны олы кунак сыман үз итеп каршылар, һәм әлеге шул дәү сандык өстенә утыртырлар иде. Сандык өстендә күп утырырга өлгерми, апасы аңар уч тутырып чикләвек китереп бирә. Гыйлемхан, иләнгән гадәте буенча, кулына чүкеч алып, тупсага барып атлана һәм чарт-чорт чикләвек ватарга керешә. Бераздан үзен җизнәсе дәшеп ала (зур гәүдәле баһадир кеше иде аның җизнәсе). Тез өсләренә утыртып «атта» юырттырырлар иде. Малай өчен шуннан да зур бәхет булмагандыр...

Җизнәсенең өстәл каршындагы стенада эленеп торган зурайтылган рәсеменә озак кына карап торды Гыйлемхан. Гомерләр... Нинди кешеләрне алып китте сугыш! Их, әгәр ул сугыш чыкмаган булса, дөнья нинди

ямьле булыр иде хәзер. Картлык көнен аның Дәүапасы шундый хәлдә, әлегедәй иске өйдә каршылаган булыр идемени... Әгәр сугыш булмаса... Гыйлемханнар туган нигез таркалыр идемени шулай... Әтисен югалтты. Нәселдәге ир-ат заты кырылып бетте. Окоп казырга барган җиреннән үпкәсенә салкын тидереп кайткан әнисе дә, аны унбиш яше тулыр-тулмас чакта, берьялгызын калдырып китте. Әгәр сугыш булмасамы?.. Авылдан бер адым да читкә китәчәк түгел иде ул. Үңҗиде яшьлек егет өчен туып-үскән йорт тәрәзәсенә такта кадаклап китү җиңел булгандыр дисезме?!. Киткәндә дә күп булса бер-ике елга, өйләнер һәм сыер сатып алырлык акча юнәтү нияте белән кузгалган иде бит ул. Өйләнүен өйләнде, сыерсыз да яшәп була икән җирдә, тик менә туган авылга кайтыр ара табылмаган. Гомер узган да киткән... Бер түгел, ун табылыр иде кайтып килер вакыт. Башта — бераз акча юнәткәнче диде. Аннан өйләнеп үк куйды. Хатын дип, хатынның туганнары, балалар дип узган да киткән вакыт. Берөзлексез хәтерендә йөрткән туган авылга өлеш чыкмаган, авыл үземнеке — качмас, дип уйланылганмы?!. Хәер, монда кеме бар иде соң аның, хатынын, балаларын ияртеп, кемгә кайтып төшәргә тиеш иде соң ул? Аркылы такта кадакланган җимерек, ташландык өйгәме?..

Хатыны көньякныкы, Кара диңгез буенда туып-үскән иде аның. Шахтерлар өчен пансионатка барган җиреннән очратты һәм алып та кайтты ул аны. Ел саен, чираттагы ял җиттеме, аның туганнарына юл тоттылар. Кайтып керсә, шахтер кияүләренең бер алдына, биш артына төшеп торырлар иде. Зур бакча, бакча уртасында ике катлы йорт. Йортның идән астында баз, ә базда булмаган нәрсә юк. Кош-корт, ким дигәндә өч баш дуңгыз — сый-хөрмәт булып тора...

Кара диңгез ярын ел да сагынып кайта иде. Хатын, балалар турында әйткән дә юк... Авылын да сагынмады түгел, сагынды Гыйлемхан. Әмма бу әчтән яну, яшертен сагыну иде, гаиләсенә кат-кат әйтүдән уңайсызланды ул хакта. Гомумән, хатынын, соңрак балаларын үзенең туган авылына ничек итеп тартырга белмәде ул. Диңгез яры белән тиңләшү, сүз көрәштерү мөмкин идеме соң?!

Гомер узганы сизелми калды шулай итеп. Инде уллары-кызлары, үз тормышларын корып, төрлесе-төрле якка таралышты. Оныткаңда бер бәйрәм белән котлаган открыткаларыннан гайре хәбәрләшкәннәре дә юк диярлек. Акча-фәлән кирәксә генә инде... Хатынын элеккечә Кара диңгез тартты. Ә ул менә гомерендә беренче кат, тавыш-гауга һәм үпкәләшләр бәрабәренә булса да, диңгез тартуын җиңеп, туган авылына кайтты. Алдагысын күз күрер...

Стенадагы фоторәсемнәргә текәләп уйга чумган икән. Дәүапасы дәшми генә аңарга каршы утыра. Уңайсызланып куйды Гыйлемхан, җылы өй түренә узганына ни гомер, ә рәтле-башлы хәл белешкәне дә юк әлегәчә. Дәүапасы ике кыз үстергән иде бит. Алар кайда, алар ничек?..

— Хәзер би-и-ит,— дип, җырлагандай суза төшеп, ипле генә сүз башлады карчык. Тавышы бик зәгыйфь ишетелсә дә, аңлашыла иде.— Балалар хат язарга яратмый инде анысы. Кайта да алмыйлар. Оныкларым гына үскән чакта «бәбүсә» дип әткрет җибәргәли торган иде. Алар да күптән үсеп җитте. Онытгылар хәзер... Юк, рәнҗемим, рәнҗемим. Үзләре генә исән-сау була күрсеннәр дә балаларының балаларын сөяргә насыйп булсын үзләренә дип, көненә өч мәртәбә дога кылам...

— Алай икән...— дип көрсенеп куйды Гыйлемхан. Дәүапсының үзеннән шактый ук өлкән кызларын исемнәре белән хәтерләми иде инде ул. Шуңа ничек итеп сораштырырга, ничек хәлләрен белешергә җай таба алмый торды.— Кызларың соң, Дәүапа, еракгамы, кай якларда?

— Хәзер би-и-ит, адәм баласының барып чыкмаган җире юк,— дип, яулык читен, иләнгән гадәте буенча, иягенә таба тартып куйды ул. Ипле генә сөйләргә кереште: — Минем кызлар да шул — берсе әшрикъта

булса, икенчесе мәшрикъта. Олысы, Гөлчирәсе, Бохарада яшәп ята. Бала-чагасы да шунда. Зу-ур бакчалары да бар икән, алмасын-хөрмәсен үзләре үстерә икән. Болай, кайтып күренмәсәләр дә, кияү әйбәт кеше икән үзе... Гөлсинәсе Кимероуда инде аның, ире шахтыда, бик зур кеше диләр...

Дәүапсы үзенең кияве шундый зур эштә эшләгәнне әйтеп, күңеле булганын һич яшерми, бераз туктап торды. Чәй йотып алды. Ә Гыйлемханның чәч төпләре чемердәп куйды, Дәүапасының кече кызы, туган тиешле апасы белән бер үк шәһәрдә гомер итеп ятышлары икән ләса. Күрү түгел, ишеткән-белешкәннәре дә юк. Колагына ишетелә дип тора, кабатлап сорады. Шунда, Кемеровода икән, бәлки күрше урамда ук яши торганнардыр, кем белгән бит аны. Кая барып чыктык соң без?!. Нәрсә булды безнең белән?! Нигә шул кадәрле гамьсез икән бу адәм баласы дип, үз-үзен битәрләде ул. Ә Дәүапасы сәйләвендә булды:

— Кызым белән бик әйбәт торалар. Үзен эшләтмичә, өйдә генә тота икән. Бер малай үстерделәр. Пәрәхудка укып, әмериканнарга тикле йөзеп йөри икән. Атналар-айлар буе балык тоталар икән... Балыгы юктыр инде аның, балыгы булса, ул тиклем йөрмәсләр иде... Балыкны әйтәм, хәзер ул безнең инештә дә калмады бит инде. Исән генә була күрсеннәр...

— Гөлсинә хат язамы соң, апа? — дип, Кемеровода яшәгән кызы хакында бер-бер мәгълүмат аласы килеп, сорарга ашыкты Гыйлемхан. Барысын белеп торгач, әллә хәбәрләшеп торалармы икән диган уй туып алган иде.

— Хәзер би-и-ит, балалар хат язарга яратмыйлар,— дип, кызын акларга ашыкты ул янабаштан.— Анысы тормышка чыкканчы гына язды, хаты килмәгәнгә күп, бик күп икән инде... Бер егерме еллар бардыр. Ара да якын түгел, вакыты да юктыр инде...

«Соң, Дәүапа, ул гомер хатлары килми торгач, аларның хәлләрен, оныгыңның кемгә укып, кем булуын, кай якларга йөзүен каян белеп торасың?» — дип сорыйсы килгән иде Гыйлемханның. Әмма үз-үзен тыяр көч табып өлгерде. Хакыйкатьтә карчыкның инде байтак гомерләр кызларыннан хат-хәбәр алганы булмаган. Ә менә күңеленнән ул алар белән берөзлесез сөйләшеп, хәбәрләшеп яши икән. Һәм үз хыялы җимеше булган шул хәбәрләргә юанып, шуларны чынга санап, берьялгызы тик яши бирә. Кызлары хакына яши, үзен күптән оныткан кызлары хакына...

Гөлчирә белән Гөлсинә бу хакта белмиләр, әлбәттә. Алар инде әниләрен күптән җир куенында дип саныйлардыр, бәлки. Үзләрен карынында йөртеп, тәрбияләп үстергән газиз ананы оныткан ул хатыннарны ничек җир күтәрә?.. Мөгаен, алар үзләре дә ана яисә күптән әби дә булып өлгергәннәрдер. Үчти-үчти итеп оныкларын сөя, тәрбияли, аларны әхлакка өйрәтә торганнардыр. Дистә еллар дәвамына газиз анага кош теледәй хат язып сала белмәгән балалардан нинди тәрбия?.. Ул сабыйлар кем булып үсәр икән?!

Шундук, эчке бер сиземләү белән туктап калды Гыйлемхан. Ә үзең?.. Үзең кем? диган сорау китереп сукты аның чигәсенә. Башкаларга гаеп ташлау җиңел ул... Туган авылыңнан чыгып киткәнеңә күпме иде?.. Син дә балалар тәрбияләдең түгелме, әлегәчә оныкларыңны үчти-үчти итәргә ашкынып торасың! Әллә син үзең ерак киткәнсеңме алардан?.. Синдә дә бардыр ич ул намус, вөҗдан, хәтер диган төшенчәләр! Нигә дәшмисең?! Авылыңа кайттың да изгегә әверелдеңме?! Кайтуын кайттың, әмма сине монда танучы да юк бит хәтта. Туган авыл дип лаф орма, алар өчен син юк инде. Күптән онытылган, хисаптан чыккан. Әллә бар, әллә юк син алар өчен. Үз нигезеңдә кем урнашып, кем яшәгәнлеген дә белмәдең ич әлегәчә... Бусагасын атлап кергәч кенә белдең ич син Дәүапаның исәнлеген. Аның дөньяда булу-булмавы хакында башыңа да китереп карамадың шушы көнгәчә... Кайтып баш орыр урының булмагач килеп чыктың монда... Нәрсә, сукмагыңа мендәр салып көтүче бар дип белдеңме?.. Тот капчыгыңны...

Ташкын булып өстенә ишелгән, җир тетрәү булып убылган сораулардан аны Дәүапасы йолып алды:

— И-и-и, Гыйлемхан, Гыйлемхан...— диде ул, дәшми утыруыннан уңайсызлык кичереп. Көлсу туфрак төсенә кергән коры тире һәм шул тире өстенә чыгып шәлберәешкән кан тамырларыннан гына гыйбарәт кулы белән аңарга таба үреләә төште. Гүя, еракта калган еллардагыча, аның башыннан, тырпаеп торган колакларыннан бер сыйпап алырга талпынуы иде.— Менә бит, син дә кайтып төштең, алланың рәхмәте төшкере.

— Апа, Дәүапам,— дип, суырылып урыныннан торды Гыйлемхан. Сак кына апасының иңбашына кагылырга итте ул, әмма бармак йөзләре янә күлмәктән гайре һични тоймады. Һәм шул калкынудан кире утыра алмады, башын салындырып, болдырга чыгып китте.

* * *

Иске каралты-кура тирәсендә җанын кая куярга белми йөргән көннәренең берсендә көтелмәгән табылдык очрады аңар. Дәүапасы келәтендәге шүрлекләрнең берсендә торган тартмага күзе төште. Имән тактадан эшләнгән бу тартма аның әтисенеке иде, анда балта остасының эш кораллары тутырылган. Шунысы гаҗәп: күпме еллар үткән, әмма балта, өтергә, төрле нечкәлектәге пычкы һәм бораулар, шактый ук тутыккан булуларына да карамастан, көйләгәндә-хәстәрләгәндә эшкә яраклы иделәр әле.

— Йортыгызны сүткәндә, хуҗа булып калган Нәҗипнең хатыны төшерде,— дип аңлатты Дәүапасы.

Эш кораллары тутырылган тартма гына түгел, күпкә әһәмиятлерәк иде аның өчен бу табылдык. Ата-бабадан калган иң кадерле ядкарь... Канатланган сыман хис итте ул үзен, рухланып, матур уйларга бирелде. Сапларын алыштырып, тарттырасы-иплисе җирләрен карап, чарлап куйгач, җан керде эш коралларына. Ә тартманың өске почмагына кыстырылган, әтисенең иң кадерләп саклаган эш коралы — артыш саплы пәкегә берни булмаган диярсең: бүген саплагандай таза сакланган сап, чалгы очыннан эшләнгән пәкесенә хәтта тутык та кунмаган. Хәзер үк кулыңа ал да кәрнизләргә, тәрәзә йөзлекләренә бизәк уерга кереш, сынатачак түгел. Менә нинди табыш... Димәк, бу эш кораллары аны көткән булып чыга, еллар белән хисаплашмый көткән.

— Рәхмәт... Рәхмәт...— дип бер үк сүз кабатлады ул үзалдына. Кемгә әйтелә ул рәхмәт: әлеге эш коралларын ясаган әтисенә, бабасынамы, әллә аларны саклап тоткан Дәүапасынамы, имән тартмага яисә эш коралларының үзләренәме — аңламассың.

Табылдыклар арасында аны аерата куандырганы ярым ай сыман бөгелеп торган артыш саплы пәке иде. Гади пәке генә түгел, теләсә нинди катлаулы нечкә эшләрне башкарып чыгу өчен көйләнгән эш коралы. Әтисенең ул корал белән ничек горурланганын яхшы хәтерли, шул пәке очы белән аның юка тактага бизәкләр уйганын бер генә тапкыр сокланып күзәтмәгән Гыйлемхан. Шуңа ул аны кулына алып, озак кына сокланып карап торды. Артыш саплы пәке аңар бәхет китерергә, югалтканнарын кире кайтарырга тиеш тоелды, шуңарга чын күңелдән ышанды ул.

Эшне Дәүапасының йорт-җирен аякка бастырудан башлады Гыйлемхан. Балачакта бергә уйнап үскән, бергә эшләп үскән дусты, авылдашы берничә чакрымда гына урнашкан зур урман хуҗалыгында директор булып эшли икән. Шуны ишеткәч тә, ике уйлап тормый, янына китте. Очрашты, күреште... Һәм ике-өч көн дигәндә, зур «КамАЗ»га бүрәнә һәм такта-борыслар төяп, апасының ишегалдына кайтып керде. Дирек-

торның үз кеше булуыннан файдаланып түгел, һәр бүрәнә, һәр тактасына кәгазь яздырып сатып алды.

Нәселдән, ата-бабадан килгән һөнәр җене кузгалды Гыйлемханда. Мактаулы исеме булган балта остасы иде аның әтисе. Сугыш алды елларын искә төшерде ул. Халык яңа тормышның асылын аңлап, җиң сызганып эшли, аякны киң җәеп яши башлаган гына еллар иде. Йорт җиткерүчеләр, каралты-кура яңартучылар күзгә күренеп артып киткән чак. Аның әтисенә авылдашлары гына түгел, бөтен тирә-юньнән килә торганнар иде. Яңа өйнең кәрнизен, тәрәзә йөзлекләрен генә булса да аңардан эшләтергә тырыштылар. Нинди бизәкләр, чәчәк-кош рәсемнәре, ай-йолдызлар сурәте чигеп эшли иде ул аларны. Кул арасына керә башлаган бердәнбер улы Гыйлемханны да үзеннән калдырмады. Такта башы тотып тору өчен генә түгел, сигез-ун яшьлек малай кулына үзенең пычкы, өтерге-борау ише, башка һичкемгә тоттырып та карамаган иң кадерле эш коралларын ышанып тапшыра иде ул. Хәтта артыш саплы пәкесен дә... Кат-кат өйрәтеп, үз һөнәренең бөтен нечкәлекләрен төпченеп аңлатырга омтыла иде мәрхүм.

Әтисе ясаган тәрәзә йөзлекләре калмаган инде авылда. Урамнарны кат-кат урап йөрсә дә, әтисе кулын очратмады Гыйлемхан. Кырык-кырык биш ел эчендә авыл өр-яңадан сүтеп корылган диярсең. Элеккегеләре белән чагыштыргысыз зур-иркен йортлар калкып чыккан. Инде усак бүрәнәләрдән генә түгел, бу яклар өчен сирәк эләгә торган, чәере алынмаган нарат яисә кирпечтән үк җиткерәләр икән йортны. Әмма шунысы гаҗәп: авылда, күз явын алырлык түгел, хет азмы-күпме матур дип әйтерлек ник бер тәрәзә йөзлеге, ник бер кәрниз күренсен. Менә дигән йорт җиткерәләр, ә кәрниз, тәрәзә йөзлекләренә, капка-коймаларны чәчәкләп-чуклап бизәүгә берәүнең дә кулы җитмәгән — шомартылган нарат тактаны буйдан-буйга кадаклаганнар да куйганнар. Ничек аңларга белмәде ул моны...

Черегән бүрәнәләрен алмаштырып сипли торгач, атна-ун көн дигәндә, Дәүапасының терәүгә калган иске өен аякка бастырды ул. Күтәрешергә кирәк чыкканда, җәйге ялга кайткан, өйалды түбәләренә менеп, кояшта тәнен каралтучы күрше егетен дәште. Механизатор егетләр аңар менә дигән ярдәмче — домкратларын биреп торды. Ярдәм кулы сузудан берәү дә тайчанмады. Шулай итеп, җиргә чүккән иске йорт яшәреп, күкрәген киерә төште. Түбә җимерелер хәлгә җиткән иде, шуңа аны өр-яңадан сүтеп япты. Кыекларын, кәрнизләрен кулыннан килгәнчә матур итеп, хәтта бизәкләр салып эшләргә тырышты.

— Кирәкмәс иде, Гыйлемхан, көчеңне юкка куясың,— дип карышты Дәүапасы әледән-әле.— Ашын ашаган, яшен яшәгән бит инде мин...

— Юкка түгел, апа, синең өй матур булырга тиеш...

— И-и-и, Гыйлемхан, Гыйлемхан,— дип дәшә ул тагы, бер тын аның кәрниз тактасына төрле зурлыктагы бораулар белән бизәкләр уйганын күзәтеп торгач.— Койган да куйган дим, тач атаң икәнсең... Ничек онытмадың, кулыңа балта-пычкы йогып кына тора икән бит?!.

— Үземә генә дә, апа, ике тапкыр өр-яңа йорт салып чыктым мин анда... Агачтан җиткердем, авылча итеп. Кулга корал алып йорт җиткерү ир-ат өчен үзе бәхет ич ул, Дәүапа...

— Син инде, Гыйлемхан, алай чуклар ясап торма, азапланма дим...

— Булгач-булгач матур булсын, кем өе дигәндә, минем Дәүапамныкы диярлек булсын,— дип, кул аркасы белән маңгай тирен сөртеп куя, гәүдәсен турайта төшеп, билен язып ала Гыйлемхан.

— И-и-и, Гыйлемхан, Гыйлемхан...— дип үзалдына көйли-көйли бакча капкасыннан чыгып югала карчык.

Тәрәзә йөзлекләренә ул иң соңгы чиратта гына керешә. Аның өчен үтә җаваплы эш иде бу. Эш кенә дә түгел, сынау. Сынауның да нинди әле. Үз-үзен ул хәзер бары тик эшләгән эше белән генә күрсәтә, раслый алачак иде авылдашлары каршында.

Баш күтәрми, ял белми, өлгеләр әзерләде иң элек. Сызды, бозды. Яңадан сызды... Ләкин үзенекен итте. Толь кисәкләренә төрле-төрле бизәкләр төшереп чыкты. Бары шуннан соң гына берсеннән икенчесе нечкәрәк пычкыларын эшкә җикте, бораулар төрле-төрле бизәкләр уйды. Артыш саплы пәке дә кулына йогып кына торды, ни теләсә, шуны башкарып чыгарга ярдәм итте. Ясаган йөзлекләре болындагы чәчәкләрне хәтерләтте. Чәчәкләр һәм тәлгәшләр өстенә як-яктан сандугач сурәтләре килеп кунды. Шуларны буяп җибәргәч, йортның йөзе яктырды, нурланып балкырга кереште.

— Бу нәрсә, тавык кетәклеге буламы?..— дип дәште аңар әлеге дә баягы бригадир, урам уртасында туктап калган «Жигули» тәрәзәсеннән башын чыгарып.

Урындыкка басып, соңгы йөзлекне урнаштырып әвәрә килгән чагы иде Гыйлемханның. Чакырмаган җирдән килеп чыккан бригадирның төртмәле сүзенә игътибар итмәскә тырышты.

— Телеңә салынырга өлгерерсең, әйдә, бер ярдәмең тияр, тотыш әле,— дип җавап кайтарды җилкә аша.

Шунысы гаҗәп: бригадир карышмады.

— Куркыттым дип уйлый күрмә, болай, үз итеп кенә тотышсам инде,— дип сөйләнә-сөйләнә чыкты ул кабинасыннан.— Мужик кына булсак та, әдәп бар әле ул бездә. Өстәвенә син үз кеше икәнсең ич... Нәмә дип аны теге көнне яшереп маташтың? Ташландык нигезеңне яңартучы икән бит мин...

— Чүкечне бирсәңче... Бераз күтәрә төш. Тагы... Тагы бераз. Тагы бераз. Булды. Селкетмә, шулай гына тот,— дип әмер биреп торды Гыйлемхан һәм колак артына кыстырылган эре кадаклар белән тәрәзәгә йөзлекне ныгытып та куйды.

— Өлкән кешегә булышуның зыяны тимәс, саваплы эш,— дип, үзенчә шаяртмакчы булды бригадир.

— Син шундый сүзләр беләсеңме?!.

— Белмәскә... Син нәмә, безне, мужик кына дигәч тә...

— Үз апам ич, мин булышмый, кем булышсын.

— Башкаларга булышмас идеңме? — дип, хата сүз әйтүдә тоткан кеше сыман, эләктереп алды бригадир.— Әйтик, менә миңа?..

— Нәрсә, сиңа да ясаргамы? — дип үзе ясаган тәрәзә йөзлекләренә ымлады Гыйлемхан.

— Һәй, абзый кеше,— дип, чертләтеп читкә төкереп алды бригадир һәм канәгать елмая төшеп тезеп китте.— Билләһи газим, сәер кеше икән син... Ни пычагыма кирәк соң бу нәмәрсә? Кеше көлдерергәме? Аны куйдырудан ни файда миңа, я әйт, ни дәрәҗә?..— Бераз гына туктап алгач, шаярусыз-нисез өстәп куйды.— Әллә ыштанны салдырырга җыенасың инде минем?..

— Сиңа болай, бер тиенсез, бушка гына ясап бирәм,— дип ихластан аңлатырга, шулай кирәклегенә төшендерергә теләде аны Гыйлемхан.— Үзең әйтәсең, әнә, син дә бит чит-ят кеше түгел, Нәҗип.

— Башны катырма, абзый кеше. Кирәкмәй!

— Мин сиңа тагы да матуррак итеп эшләрмен. Урамнан узган кеше хәйран калырлык булыр. Кем өе дигәндә, Нәҗипнеке дип мактанырлык, менә күрерсең...— дип, салпы ягына салам кыстырудан да тайчанмыйча үгетләргә кереште, күндерермен дип уйлады ул аны.— Мондый гына түгел. Яңа өлгеләр әзерләрмен... Чигеп ясалгандай булыр, Нәҗип. Синең яңа өйгә ул, күрерсең, аеруча килешеп торачак.

— Булды. Бетте! — дип, биш бармагын киң җәеп, ике кулын тәрәп куйды, каршы төште бригадир.— Ясыйм, имеш... Чигәм, имеш... Беләсең килсә, абзый кеше, өй түгел, кулъяулык та чикмиләр хәзер. Заман башка, мода башка. Бетте, бу хакта сөйләшмибез.

Кинәт борылып, фырт кына машинасына таба атлады ул. Кузгалып киткәндә, Гыйлемханны үртәгәндәй, елмаерга да онытмады.

...«Заман башка, мода башка», имеш... «Кулъяулык та чикмиләр...» Соң, чикмәсәләр... Димәк, начар! Матурлыктан кемгә зыян тигәне бар? Байлык, муллык белән генә бармый дөнья. Булсын, алары да булсын, әмма алар матурлыкка киртә түгел, мәйданга әверелсен. Матурлыкның урыны түрдән булырга тиеш»,— дип фикер йөртте ул. Бригадир сүзләре нык кына рәнжеткән иде үзен.

Гомерендә бер тапкыр чигелгән кулъяулык бүләк иттеләр аңарга. Анысын да кулга түгел, кичен эштән кайтуына капка келәсенә элеп киткәннәр иде. Сугыш тәмамланган елның икенчесендә... Үтүкләнгән, пөхтә генә дүрткә бөкләп, кәгазьгә төрелгән кулъяулык иде ул.

Яшьлегенең иң кадерле истәлеге итеп саклады ул бу кулъяулыкны, туган җирдә, бөреләнеп тә, чәчәк атарга өлгермәгән беренче хисләре ядкаре итеп. Әле дә булса кулъяулык аның куен кесәсендә йөри. Кайчандыр егет җанын иләсләндереп торган хушбуй исе инде күптән очып югалган югалуын, әмма яшел челтәрле ак кулъяулык читенә чигелгән күкчәчәкләр һаман булса саф, үзләренең табигый төсендә саклана.

Күкчәчәк... Аның яшьлегедәй гади чәчәк. Моннан дүрт дистә еллар элгәре, энә тотып, сукыр лампа каршында төннәр буе утырган авыл кызының тәүге хисләредәй саф һәм эчкерсез чәчәкләр. Күкчәчәкләр...

Кулъяулыкның икенче бер почмагына, кыйгачлап, алсу ефәк җептән сүзләр чигелгән: «Истәлек өчен — Гыйлемханга. М.дан».

Миңсылу бүләге иде бу. Үсмер кызның төн йокыларын калдырып әзерләгән, атналар-айлар буе тиешле кешесенә ничек тапшырырга белми йөдәгән беренче һәм ихлас бүләге... Миңсылу бүләге. Шунысы үкенечле: ә ул аңар, кулъяулыгыңны алдым дип, күреп бер рәхмәт тә әйтә алмады бит. Китте... Кайтырмын дигән иде... Аның ул китүен әлеге чиккән кулъяулык хәтта ашыктырган да иде булса кирәк. Ашыгыч рәвештә юлга әзерләнүе тизрәк кире әйләнеп кайту теләгеннән иде ич. Әмма шул китүдән кире кайта алмады. Китте дә югалды. Миңсылуны да онытты, авылын да... Оныту идеме икән бу?.. Алар бит берөзлексез аның күңелендә булды. Ләкин тормыш агымы шундый итеп эләктереп алды, ияртеп китте ки, үз-үзенең кай тарафка акканын, кая килеп чыгачагын абайлар ара да калмаган. Гомер узды шулай. Ә хәзер, әнә, Миңсылу яшәгән өйнең нигезендә алабута белән кычыткан үсә...

* * *

Урман хуҗалыгыннан яздырып алган сөян такта бетмәгән иде әле. Вакытын бушка уздырмады Гыйлемхан, икенче көнне үк тәрәзә йөзлекләре ясарга кереште. Үзенең туган нигезенә, шул нигездә төпләнгән бригадирга дип, атап ясады. Атналар буена ишегалдыннан чыкмый әвәрә килде. Кисте, ышкылады, кулына карандаш алып, такта өстенә сурәтләр ясады. Аннан янә пычкы, бораү эшкә кереште. Артыш саплы пәке иң нечкә чигелешләргә җан өрде... Ким дә түгел, артык та түгел, төгәл сигез йөзлек ясады. Тәрәзә каршында дәшми-нитми генә ак яраңгөл чәчәкләре артыннан ишегалдына текәлеп утырган Дәүапасыннан башка һичкемне күрмәде ул бу көннәрдә.

Үз эшенең нәтиҗәсен күрү, мөгаен, кешенең иң олы горурлыгыдыр. Тәрәзә йөзлекләрен каршыдагы коймага терәп тезеп чыкты да, үзе болдырга барып сөялде Гыйлемхан. Ниһаять, иркен сулыш алды... Күңелдәгечә булган иде, нәкъ хыялындагыча... Туган якка бер әйләнеп кайтса, йорт җиткерү һәм тәрәзәләренә әнә шундый якты йөзлекләр ясап кую күптәнге хыялы иде аның. Үз өен генә түгел, бөтен урамны матурлап, авылга нур, яктылык һәм ямь өстәп торсын ул ясаган тәрәзә йөзлекләре. Узып барган һәммә кеше күрсен, тукталып, сокланып карап торсын. Туган ягының иркенлеген, аның урман-болыннарындагы чәчәкләрнең төрлелеген сыйдырырга тырышты ич ул аларга. Нәкъ хыялындагыча

итеп... Күрсен, соклансын сабыйлар. Яшьләр, өлкәннәр карашларын аера алмый торсын... Матурлыкның берәүгә дә зыян салганы юк. Мондый тәрәзә йөзлекләре авылның элек-электән мактанычы иде. Онытылмасын, яңарсын шул гадәт. Күзләр, күңелләр тупасланмасын. Матурлыкка табыныр вакытлары калсын авылдашларының...

Әнә шундый тәрәзә йөзлекләре ясау турында хыялланган иде ул. Үзенә булмаса, туган нигезенә ясады. Ул аларны бүген үк, ә бәлки иртәгәсен таң белән менгереп урнаштырачак. Таң атканда, иртәнге кояш нурларында ул ясаган тәрәзә йөзлекләре аеруча бер матурлыкка төренеп яшь башларга тиешле иде аның уйлавынча.

Шулай итте дә. Икенче көнне иртүк, әле көтү куганчы ук, кичтән белешеп куйган атны җигеп кайтты ул. Тәрәзә йөзлекләрен, сак кына күтәреп, арбага төяде. Бер-беренә ышкылып, бәрелеп, төсләре китмәсен, ватылмасын өчен, араларына иске одеял, капчык ише нәрсәләр кыстырды һәм кузгалды... Үзенең туып-үскән нигезенә төбәп кузгалды... Теге чакта аның тәкъдимен чынга алмаган, көлгән иде бригадир. Бүген башкача сөйләшер. Гыйлемхан ясаган тәрәзә йөзлекләрен генә күрсен...

Дилбегә очын кулына урап, арба белән янәшә атлады ул, утырып тормады. Утырыйм дисә, урын бар иде арбада. Атка авыр булыр диган уйдан да түгел... Үзенә урын бар, күңеленә кысан иде арбада. Кош булып талпынган җаны сыешмады.

Киң урамның уртасыннан барды алар. Ат ашыкмады. Хәер, аны куалаучы да булмады. Тын гына, ипле генә атлавын белде ат, гүя төнге йокысыннан арынып җитмәгән иде әле ул. Ә аның белән янәшә атлаучы чал чәчле ир-ат инде арбага гына түгел, киң урамга сыеша алмый башлаган иде сыман... Бил һәм гәүдәсенә төшкән еллар йөге дә онытылган, күкрәкне киерә төшеп, әле иртәнге йокыдан арынмаган авыл урамын урталай ярып бара ул. Кәеф күтәренкелеге, күңел көрлеге, үз-үзеннән канәгатьлек аның килеш-килбәтеннән һәм һәр хәрәкәтеннән үк күзгә ташланып тора. Ничә еллар аерылып торганнан соң әле беренче тапкыр, менә шулай күкрәк киереп атлавы иде аның туган авылы урамыннан.

«...Күрәсезме, кайттым! Туган авылыма кайттым,— дип дәшә сыман ул авылдашларына.— Сез мине танымаган булдыгыз, оныткансыз. Ә мин исән-сау. Онытмадым сезне, кайттым. Сезгә кирәгем дә чыгарга тора әле минем... Балта остасы Габделхак турында ишеткәнегез бардыр, булмый калмас. Мин шуның улы булам менә, Габделхакның бердәнбер улы Гыйлемхан. Аның эшен дәвам иттерергә тиешле кеше. Соңарып булса да кайттым, кабул итегез!.. Күрәсезме, тәрәзә йөзлекләре алып барам. Иң элеккеләре — туган нигезгә. Аннан сезгә дә булыр. Күкрәктә дәрт, беләктә җегәр җитәрлек әле минем... Габделхак улы Гыйлемхан үзенең туган нигезенә тәрәзә йөзлекләре куярга менеп бара, күрәсезме?!.»

Ялгыз каен каршына китереп туктатты ул атын. Урамда кеше-кара күренми иде әлегә. Гыйлемхан, ике уйлап тормастан, тәрәзә йөзлекләрен капка төбенә бушатырга керешге. Хуҗа кешене дәшеп тормады, капка төбенә килеп туктаганны ишетми калмас, үзе чыгар диеп көтте. Ләкин өй ягыннан, кетәклектә кычкырган әтәч тавышыннан гайре, шылт иткән аваз да ишетелмәде.

Чиләк-көянтә асып судан кайтып килгән сылу яшь хатын дәште аңар:

— Нәҗип абыйлар өйдә түгелдер шул инде,— диде, йөгереп диярлек барган көйгә аңар таба борыла төшеп.

— Шушы вакыттанмы? Кайда соң алар? — дип гаҗәпсенде Гыйлемхан.

Кай арада үтеп тә киткән иде инде хатын. Әмма ат янында торып калган чит кешенең сорауларын ишеткәч, тукталмый булдыра алмады.

— Үзе нәрәттәдер, идарәдә,— диде ул еш-еш сулыш алып.— Сылу



*А. Тимерғалина рәсеме*

апа җәйләүдә. Сыер савучылар автобусы да әллә кайчан төшеп китте инде.

Һәм ничек тукталган булса, шулай ук җәт кенә борылып китеп тә барды яшь хатын. Үзе китте... Ә бит алмаларындагы алсулык, карашындагы якты нур Гыйлемхан каршында эленеп калды. Бу яшь килен, әллә кайсы ягы белән генә, аның күңелендәге Миңсылуга тартым тоелды. Гүя Миңсылу үзе, шушы яшендә яшьлек сылулыгын җуймыйча, Гыйлемханны көткән... Янтая төшеп, сыңар кулы белән зәңгәр көянтәсен кочаклаган көйгә ашыгып китеп барган шул гәүдәнең серле чайкалышларыннан күзен ала алмый карап торды ул. Авылның чишмәдән су алып килүче юыртак киленнәреннән дә сылурак хатын-кыз юктыр.

«Бригадир Нәҗипнең хатыны Сылу атлы икән»,— дип уйлап куйды Гыйлемхан. Матур исем!.. Әмма шул Сылуның гомере буе күңелендә йөрткән Миңсылу булу ихтималын уена да китереп карамады. Хакыйкатьтә, чит җирләргә китеп югалу түгел, Миңсылуның авылдан бер карыш читкә тайпылганы да булмады. Әти-әнисе сеңелләре белән Себердәгениндидер төзелешкә ялланып китеп барганда да, өлкән кызлары, үзенчә сәбәбен табып, авылда калды. Яшьлегендә күңеленә кереп калган Гыйлемханны көтеп яшәде ул. Бер ел түгел, биш кенә дә түгел, егерме бише тулганчы көтте. Булды, сорап килүче, артыннан йөрүчеләр булды, барысын кире борды, ярәшкән егетем бар, ди-ди көтте. Әмма нинди егет, ул шулай өзгәләнеп кемне көтә — монысы бары тик үзенә генә мәгълүм иде.

Ул елларда авыл кызы өчен егерме бишкә җитүнең ни икәнлеген беләсезме икән? Ул яшьтәге кызлар инде күптән «сазаган» исемен күтәрергә мәҗбүр була. Шуның өстенә әле яман телләрне, аларның «бер-бер гөнаһысы бардыр...» дип гөман кылуларын кая куясың.

Шулай итеп, егерме бишкә кадәр көтте Миңсылу. Хат-хәбәре булмаса да, көтте. Тик көткәне генә кайтмады, китте дә суга төшкәндәй юк булды... Шул елларда авылга каяндыр, Агыйдел буйларыннанмы, гайрәте ташып торган бер татар егете агроном булып килде. Күрде һәм капланды, халык әйтмешли. Үзеннән ике-өч яшькә кечерәк булган шул егетнең гозерләүләренә каршы тора алмады Миңсылу. Бәлки, көткән дә булыр иде, ә егерме биш яшьне кая куясың?!. Шулай итеп, алар — Миңсылу белән Нәҗип — тормыш корып җибәрделәр.

Әмма Гыйлемхан болай булыр дип башына да китереп карамады. Бу хакта башкалардан да бер авыз сүз ишетмәде.

Капка бикле булып чыкты. Ни эшләргә белми, әле ялгыз каенга текәлеп, әле калай түбәле йортка күз салып, арлы-бирле урыс капка тирәли йөренде Гыйлемхан. Тәрәзә йөзлекләрен шулай капка төбендә, урам уртасында калдырып китәсе килми иде аның. Байтак көтеп-көтеп тә, хуҗа кеше күренмәгәч, иялләшә төште, күрәмсең, кыюланып китте. Нигә дип әле тәрәзә йөзлекләрен куеп ук карамаска?.. Үзе кайтуына сигез тәрәзәсе бер булып ялт итсен, көлеп торсын, ни дияргә белмәс, сокланудан исе-акылы китәр бригадирның. Һәм ул, тәвәккәлләп, өй каршындагы бакчаның нәни капкасын ачты, тәрәзә йөзлекләренең берсен күтәргән көйгә кереп тә китте.

Шулай да, хуҗаның үзеннән башка урнаштыру яхшы булмас, көтәргә кирәктер, киңәшеп, бергә-бергә эшләү дөрес булыр, диген уй тыеп торды аны бер тын. Әмма түземлек, сабырлык шулай да җитенкерәмәде. Ни булса булыр дип, бары берсен, вакытлыча, кадак очларына эләктереп кенә булса да куеп карарга җөрьәт итте...

Биек итеп өелгән таш нигездән төшәргә өлгермәде, урамның аргы ягыннан тавыш ишетелде.

— Бу нәмә бу!? Бу нинди башбаштаклык... Милиция чакыртыйммы? Милиция...— дип, әллә каян кычкырырга кереште өенә кайтып килгән бригадир.

Югалып калды Гыйлемхан. Кыяр түтәлендә караклыкта тотылган

малай сыман коелып төште. Ул да түгел, өй эченнән балалар елаган аваз колакка чалынды. Монысы инде бөтенләй башына да килмәгән яңалык иде. Өйдә балалар булган икән ич... Дөньяларын онытып изрәп йоклап яткан сабыйларны куркытып уяткан лабаса.

Таныш тавыш ишетеп булса кирәк, эчке яктан тәрәзәгә ике ыштансыз малай килеп капланды. Сулкылдый-сулкылдый елый иде балалар, моңарчы ничек тын да чыгармый ята алганнардыр?.. Кулларын яман болгап урам аша чыккан бабаларын күреп алгач, тәрәзә кагып кычкырырга тотынды алар:

— Бабай, ба-ба-ай, өйне җимелә-лә-ә-әл...

Оныкларының курку баскан йөзләрен күргәнче үк дөньясын оныткан иде бригадир.

— Син нәмә, үз акылыңдамы?..— дип, кулларын йомарлап туп-туры Гыйлемханның өстенә килде ул.

— Белмәдем, Нәҗип... Белмәдем балалар барын...— дип, гафу үтенгәндәй каефсез генә рәшәткә читенә барып сөялде Гыйлемхан. Кулыннан көч качкан, тез буыннары тотмас хәлгә килгән иде бу көтелмәгән тамашадан. Хәтта үз-үзенә кызганыч тоелды ул шунда.

— Нәмә, шаштыңмы әллә? Бу нәмә бу?.. Сиңа нәмә кирәк?.. Нәмә җитми сиңа, карт тиле...— дип җикеренде, ду килде хуҗа кеше.

Нәрсә генә дисә дә, ул хаклы иде. Берни әйтеп булмый, хаклык аның ягында. Сорамый-нитми, кешенең өенә барып ябышырга ни хакы бар?.. Кем биргән аңар андый хокукны? Үз акылында булган кеше шулай итәме?! Аңардан кем сораган... Карт тиле дими, ни дисен... Йортның хуҗасы — Нәҗип, шуңа күрә ни әйтсә дә килешә аңарга.

— Белмәдем, Нәҗип туган, белмәдем... Малайлар үсеп җитте диден, кем уйлаган бит аны...

— Белмәдем... Белмәдем, имеш. Үсеп җиткән малайлар, өйләнмәскә, печән ашап торырга тиешмени?..— дип, бераз сүрелә төште хуҗа кеше. Әмма уңайсызланып, югалып, койма читендә бөрешеп калган өлкән кешегә ихтирам турында, аның хәленә керү турында уена да китереп карамады.— Белмәсәң, бу такта кисәкләрен кем сорады синнән?..

— Мин аларны синең өйгә, сиңа, үз нигеземә атап ясаган идем...

— Үз нигезем... Сатып алган җиреңме әллә? Тапкан, үз нигезе, имеш.

Дәшмәде Гыйлемхан. Ә хуҗа кешенең үз туксаны туксан, җавапка мохтаҗ түгел иде ул.

— Бу тишек-тошык нәмәләреңне,— дип, капка төбендә өелеп торган тәрәзә йөзлекләренә ымлады Нәҗип,— хәзер үк төя дә чүплек башына илтеп ташла. Кеше көлдермә, абзый кеше!

Гыйлемхан кулындагы балтаны тартып алып, ялт кына өй каршындагы бакчага кереп китте ул. Тагы бер мизгелдән тәрәзә яңагына кагылган ялгыз йөзлек каерып атылган иде инде. Башта нигез ташына килеп бәрелде тәрәзә йөзлеге, аннары кыйшаеп, мал симертү өчен үстерелгән азык чөгендере түтәленә барып ауды. Атып төшерелгән аккош сыман сыкрап куйды, бәргәләнде йөзлек.

Гыйлемханның бәгырендә дә ниндидер нечкә бер кыл зеңләп өзелде. Кинәт күзаллары караңгыланып алды. Дәшмәде, ни дип дәшә ала иде соң ул? Шулай бер тын онытылып торгач, иләп кенә арбага тәрәзә йөзлекләрен төяргә кереште...

— Әйдә, абзый кеше, сузма. Төя дә юлыңда бул. Эш калдырып, башны катырып йөрмә,— дип ашыктырып торды бригадир. Һәм бакча эчендә таралып яткан мәсхәрәләнгән тәрәзә йөзлеген койма аша үзе алып ыргытты.— Ятмасын бакча чүпләп, ал монысын да...

Ат кузгалды, кайтыр юлга борылды. Тыныч кына, иппе генә атлап китте ат. Аркасына килеп кунган чебен-черкиләрдә дә гаме юк иде, башын түгел, хәтта койрыгын кыймылдатмады. Үзен беренче тапкыр гына җигүләре булуга да карамастан, арба почмагында тәрәзә йөзлек-

ләренә сөялеп, бөрешеп утырган кешенең хәленә керүе иде гүя. Әледән-әле тәгәрмәч бүкәннәре генә чәкүшкәләргә бәрелеп чыелдашкан аваз чыгарып барды. Тугымга кидерелгән тимер кыршау астында, тешне камаштырып, комлы тузан шыгырдады.

Кояш өй кыекларына житеп үрләгән иде инде. Капка асларыннан урамга берән-сәрән тавык-чебеш чыга башлаган. Су буена таба төркем-төркем каз-үрдәк йөгерә. Көтү куып кайтканнан соң бераз иркенләгән хатын-кыз, бала-чага үтеп торды урамнан. Тик боларның берсе дә жәлеп итмәде Гыйлемханны. Аларның да аңарда гаме юк. Кем ул? Шушы вакыттан арбага ни төяп, кайдан кайтып килә? Ул хакта ялгышып кына булса да ник бер адәм заты кызыксынсын. Туган авылы уртасында япа-ялгыз иде ул. Берәүнең дә аңарда эше юк, һичкемгә аның кирәге калмаган.

Күңел төшенкелеге чамадан ашып барган шул мизгелдә берәү аңар сәлам биреп узды. Колакка гына ишетеләме дисә, теге тавыш янә кабатланды:

— Исән-саулар гынамы дим, Гыйлемхан кордаш.

Атын туктатып башын күтәрде ул. Каршысында култык астына балта кыстырган өлкән яшьтәге ир-ат басып тора иде. Ләкин ул аны тану түгел, төсмерли дә алмады.

— Әллә танымыйсың инде, кордашыңны да оныткансың? — дип, кулын сузды кеше.— Кайтканыңны ишеткән идем. Килеп чыгарга гына вакыт тими... Әйбәт булган, әйбәт.

Менә сүнәм, менә сүнәм дип торган утны тергезеп жибәрделәр-мени, күңеле булып, жанланып китте Гыйлемхан. Кадакланган сыман утырган жиреннән сикереп жиргә төште ул. Һәм үзенә кул биргән кордашының кем булуын ачыкларга да онытып, әйтеп салды:

— Тәрәзә йөзлекләре кирәкме үзеңә? Менә, сигезен дә ал, бушлай бирәм...

Авызын колагынача ерып, иркенләп бер хәл белешергә, бергә үткән балачак хатирәләрен бүлешергә дип торган ир-ат, колагы ишеткәннәрдән үзенчә нәтижә ясап, сагаеп калды. Нәрсә дип жавап кайтарырга белми торды. Дәшми калуны да өнәмәде.

— Ә-ә-ә, менә нәрсә төяп кайтып киләсең икән әле син,— дип, Гыйлемханның күңеле булсын өчен генә, арбага тигез итеп хәстәрләп өелгән тәрәзә йөзлекләренә күз салды.— Әйбәт, әйбәт булган болар, кордаш.

— Ал, хәзер үк бирәм. Үзем ясадым. Әйдә, утыр, илтик хәзер үк. Үзем илтеп куям,— дип, кабалана-ашыктыра башлады Гыйлемхан. Тәрәзә йөзлекләренә хужа табылуга аз гына да шиге калмаган иде инде аның.

— Син, кордаш, ул тикле куалама инде. Тәрәзә йөзлекләренә барып терәлмәгән иде шул әле... Малайны башка чыгарып йөрү минем. Өй житкерә, шуңа ярдәмгә менеп барам.

— Соң, өй житкерәбез дисең түгелме — үзеңә кирәкмәсә, улыңа булыр. Бигрәк яхшы, яшьләр торасы өй матуррак булсын,— дип, тагы жанланып куйды һәм, атын борырга теләп, дилбегәгә үрелде.

— Юк, кордаш, кирәкмәс. Малай белән дә сөйләшмәгән, ашыкмый торыйк.

— Мин бит аны шул көе, бушка гына,— дип кабатлады Гыйлемхан, әлеге карышуның сәбәбенә төшенә алмый.

— Үпкәләмә, кордаш, бушка да кирәкми.

— Ничек алай?.. Менә дигән тәрәзә йөзлекләре ич. Өр-яңа... Сигезәү. Кирәксә, тагы ясармын.

— Үпкәләмә, кордаш, кирәкмәс. Хәзер тәрәзә йөзлекләрен куеп маташмыйлар инде.

— Соң, йөзлексез тәрәзә буламы, каян таптыгыз аны?! Ал, йортың яктырып китәр. Яңа йортка килешәчәк алар, күрерсең.

— Аңлыйм, кордаш, аңлыйм. Ләкин кирәкмәс. Башка чакта, яме, башка чакта,— диде дә китәргә үк җыена башлады авылдашы.

— Кордаш дисең... Кордаш булгач, син белергә тиеш, тәрәзә йөзлекләре — йортның күрке. Йортыңа гына түгел, урамга, авылга ямь биреп торыр.

— Куймыйлар аны хәзер. Урамда, авылда минем эшем юк. Әнә, авыл сәвите бар, сайлап куйдык, кайгыртсын!

— Йорт бит синекедер?

— Минеке булмый, син бит урамны бизәтмәкче миннән...

— Үзебез үскән чакларны хәтерлисеңдер ич. Йөзлексез тәрәзә булмый. Авыл булып, авылның да, әнә, каршысындагы тау йөзенә артыш куаклары утыртылган. Бабайлар утырткан аны, кыргый түгел ул. Миңа калса, кордаш, йөзлексез бер генә нәрсә дә булмый: тәрәзә дә, авыл да... Йөзлегеннән мәхрүм итсә, аларны кеше генә мәхрүм итә ала. Кешегә үзен, дөнья йөзлеген югалтмый саклау турында да кайгыртыр чак бит хәзер...

Әллә ишетте, әллә юк ир-ат, Гыйлемханның ихластан борчылып сөйләгәннәренә исе китмәде аның.

— Юк, кордаш, дөнья үзгәрә тора шул. Юкка гына куласа димиләр аны,— диде дә, уртак сүз таба алмадык ахры дигәндәй, уңайсызлана төшеп, китәргә кузгалды. Әмма күңелендә миһербанлык уяндымы, берникә адым атлагач та, борыла төшеп ул янә кордашына дәште.— Син үпкәләмә инде. Берни эшләп булмый, үпкәләмә!..

Култык астына балта кыстырып, улына йорт җиткерешергә менеп барган яшьтәше артыннан озак карап торды Гыйлемхан. Чаттан борылып, каралты-куралар артына кереп күмелгәнче, аңардан күзен алмады... Танымады. Тану түгел, аңламады, аңлый алмады ул үзенең бергә уйнап үскән авылдашын. Йортны, урамны бизәп торырга тиешле ул тәрәзә йөзлекләренең ни дип әле кирәкләре бетсен икән? Тәрәзә йөзлекләреннән алар хәтта курка, чирканалар да түгелме соң — ничек аңларга белмәде ул бу күренешне.

Күргән-ишеткәннәре дә чамадан ташып ашкан иде югыйсә. Гыйлемхан барыбер тынычланмады. Авылдашларына ышанычы сүрелмәгән иде аның. Нindидер аңлашылмаучылык кына түгелме бу?.. Үҗәтлек белән барыбер үзенекен итәргә карар кылды ул. Һәр очраган кешене туктатып, арбадагы тәрәзә йөзлекләрен тәкъдим итеп йөрергә кереште. Илтеп куям, үзем урнаштырып ук бирәм, дип тәкъдим итте. Алай да ризалата алмагач, авылны аркылыдан буйга иңләп, яңа йорт җиткерүчеләрнең капкаларын шакып үтте. Тәрәзә йөзлекләренә хуҗа табылмады.

Көннәр уза торды... Гыйлемханның гына күңеле үсмәде. Вакытын мөмкин кадәр ялгызы үткәрергә тырышты ул. Су буйларыннан әйләнеп кайтты, ындыр артларыннан кат-кат үтте. Артышлы тау башына менеп, сәгатьләр буена көндәлек мәшәкать белән ыгы-зыгы килгән авыл урамнарына текәлеп утырды. Кая гына барып чыкмасын, авылдашлары күңелендә матурлыкка урын калмавына ышанасы килмәде аның, ышана алмады. Авылның әйләнә-тирәсе, бар табигате чын матурлык тантанасы иде бит.

* * *

...Тагы күпме шулай дәвам итәр, әлеге ялгызлыкка ул тагы күпме түзә алган булыр иде икән, әйтү кыен. Ләкин вакыйгалар гел уйламаган, көтмәгән җирдән кинәт кискен борылыш ясап куйды. Бу борылышка өлкә газетасының дүртенче битендә басылган фоторәсемнәр сәбәпче иде. Авыл аша узып киткән фотохәбәрче, гади бер кызыксыну белән, аның Дәүапасы йортын төшереп алган һәм газетада бастырып чыгарган булып чыкты. Янәшәдә тәрәзә йөзлекләренең һәм карниздәге бизәкләрнең

зурайтылган сурәте дә бирелгән. «Нурлы Аланда авылны төзекләндерүгә зур игътибар бирелә. Йортларның ныклыгын, эчке уңайлыкларын гына түгел, тышкы матурлыгын да кайгырта монда авыл төзүчеләре һәм житәкчелек. Фоторәсемдә — шундый йортларның берсе»,— дигән сүзләр язылган иде рәсем астына. Сүзләрендә шактый гына күпертү булса да, рәсемдә чынлап та Гыйлемхан сипләгән җыйнак кына, гадәти генә авыл өе иде.

— Карале, чынлап та матур бит, ә... Рәхмәт сиңа, авылыбыз данын күтәргән өчен,— ди-ди, газета битенә күрсәтте шушы уңай белән аның янына махсус төшкән колхоз җитәкчесе.— Өлкә газетасында мактау безгә еш эләкми, рәхмәт!

Татар тотып карамый ышанмас, дигән сыман, газетаны кулына алып, хәйран озак карап торды Гыйлемхан. Көтелмәгән яңалык иде бу.

— Рәхмәт инде, рәхмәт,— диде ул үзе дә күңеле булып.

Председатель белән Гыйлемханның шулай кәефләнеп сөйләшкәнен тәрәзә төбендә үскән ак ярангөл аша тын гына ялгыз карчык күзәтеп утырды. Килүченең кем булуын танымаса да, ишегалдында ят кеше күренү аның өчен куаныч иде булса кирәк.

— Бәясеннән тормам, яса миңа да шундый тәрәзә йөзлекләре,— дип мөрәҗәгать итте җитәкче.

— Бар, ясаганнары да бар,— дип, куанычыннан кабалана-кабалана ишегалды түрендәге иске каралтыга таба ымлады Гыйлемхан.— Ошаса, бүген үк алыгыз. Ничәү кирәк?..

— Унике генә,— дип канәгать елмаеп куйды җитәкче.— Өй ярарлык анысы, әле узган ел гына җиткереп кердем. Тик әнә шул, нәрсә дип язганнар әле?.. Шунысы гына юк.

— Тәрәзә йөзлекләре.

— Әйе, тәрәзә йөзлекләренә генә житешелмәгән... Матур ич, әнә ничек матур торалар,— дип гәҗиткә күрсәтте ул тагы. Үзенең шул фоторәсемдәге йорт ишегалдында басып торуын да онытып, һаман гәҗитне кулында болгады.

Кайчандыр мал лапасы булган каралты астына керде алар. Пөхтә итеп әрдәнәләп өелгән тәрәзә йөзлекләренең икесен ишегалдына алып чыгып, болдырга сөяп куйдылар.

— Болармы?! Болармы?! — дип, үз-үзен кая куярга белми ишегалды буйлап йөгеренә башлады җитәкче.— Минеке! Минекеләр!.. Бүген үк, хәзер үк алам үзләрен — һәм ялт кына урам капканы ачып, шоферына хәбәр салды.— Илдус... Илдус, дим. Әйт берәрсенә, тәрәзә йөзлекләрен хәзер үк миңа менгереп куйсыннар. Урам як тәрәзәләргә дип әйтергә онытма.

— Сигез генә, сигез генә бит,— диде Гыйлемхан акланырга җыенган гаепле кеше сыман. Әле һаман күзе күргән, колагы ишеткәннәргә ышанып җитми иде булса кирәк.

— Булсын... Сигез генә булсын. Алам! Тагы дүртне генә ясарсың ич?.. Материалны төшереп аударырлар. Хакын хәзер үк бирәм,— дип куен кесәсенә тыгылды җитәкче.

Ут капкандай каршы төште Гыйлемхан:

— Кирәкми... Акчасы кирәкми.

— Ярый алайса, соңыннан хисаплашырбыз, ихтыярың,— дип, кесәсеннән тартып чыгарган кулын Гыйлемханга сузды җитәкче.— Тагын дүртне. Килештекме?..

— Килештек.

— Такталарны кичкә төшерерләр. Менә дигән нарат такталар бар.

— Нарат бармый. Нараттан ясамыйлар тәрәзә йөзлеген.

— Нәрсә кирәк, имәнме әллә? — дип елмайды җитәкче.

— Кәрниз-йөзлекләрне сөян тактадан эшлиләр. Эшләргә дә йомшак, ярылмый, чиста да килеп чыга сөяннеке.

— Булыр, сөян такта булыр. Теге, кайрысы төшерелгән юка дисең?

Колхоз җитәкчесе артыннан капка ябылгач та, болдыр баскычына

барып утырды Гыйлемхан. Үзен ничә көннәр дәвамына газаплаган халәттән әле һаман айнып бетә алмый иде ул.

Эшсезлектән иңрәп йөрүләр бетте. Мәгънәсезгә узган көннәр артта калды. Ялгызлык онытылды. Кулга эш табылды, җанга тынгылык килде. Иртәдән кичкә кадәр баш күтәрми тәрәзә йөзлекләре ясады ул. Колхоз җитәкчесенә вәгъдә иткәннәрен тәмамлап өлгермәде, башта берән-сәрән, аннан бер-бер артлы капкадан кеше өзелмәде. Авылдашлар килде. Хәл белешергә килделәр. Танышырга, күрешергә дип килделәр. Әлбәттә, сүз уңаена, бер җай китереп, һәркайсы үзенә тәрәзә йөзлекләре кирәклеген әйтергә онытмады.

Авылдашларының гозерләп сораган үтенечен кире какмады Гыйлемхан. Берәүгә дә: «Булмый, эшләмим»,— дип җавап кайтармады, иртәме-соңмы, һәркайсына ясарга вәгъдә биреп барды. Кайчан өлгерү, ничек житешү хакында уйларга башына да китмәде, куана-куана бирде вәгъдәләрен.

Әмма Нурлы Алан алай кечкенә авыл түгел. Йортлар саны гына да ике йөздән артып китә. Ә тәрәзәләр?! Шуларның һәркайсына йөзлек кирәк. Моңарчы тәрәзә йөзлегенең ни икәнлеген белмәгән, аның хәтта ничек аталганлыгын да ишетмәгән кешеләргә кирәге чыкты. Һәркайсына тиз булсын, матур булсын... Ә Гыйлемхан — бер генә. Бер ялгызың түгел, бишкә ярылсаң да, тәрәзә йөзлекләре ясый торган тулы бер цех ачып җибәрсәң дә, өлгерерлек түгел.

Шулай да куанды Гыйлемхан. Үз хезмәтенең авылдашларына кирәкле булуын тоеп, ихластан куанды. Күкрәктә җан, беләктә җегәр булганда, куанмаслыкмы?.. Ниһаять, туган авылы Нурлы Алан урамнарына үзе теләгәнчә бизәк сала, нур иңдерә алачак ул. Авылдашлары каршында бурычын кайтара, аклана алачак. Туган җиргә нык итеп басып йөрү хокукына ирешәчәк.

Җиң сызганып, такта шомартып яткан чагы иде. Капка ачылып, анда чираттагы авылдашы күренде. Теге чакта урамда очрап, үзенә сәлам биргән кордашы иде бу.

— Исәннәрме, Гыйлемхан кордаш, бер көе генәме,— дип, әллә каян ук күрешер өчен ике кулын сузып килде ул.

— Рәхмәт, яхшы гына иде болай.

Менә, эшлим, дигәнне аңлатып, як-ягында тау-тау өелеп торган такталарны айкап алды Гыйлемхан күз карашы белән.

— Алай икә-ән,— дип сузып куйды килүче, сүзне нидән башларга белми кыенсынып.— Эшләр гөрли дисең инде?

— Эш җитәрлек.

— Яхшы, кордаш, яхшы... Минем дә шул мәшәкатьләр белән йөрү иде бит әле. Ничек булыр икән дим?..

Теге чакта урамда булып узган очрашуны истә тотып булса кирәк, килүче кеше, ничектер, тартына төшеп, уңайсызлану кичереп сөйләшә иде аның белән. Үзенә «кордаш» дип дәшүченең кемлеген әле булса хәтерли алмаса да, каршы төшмәде Гыйлемхан, ризалашты.

— Булыр,— диде.— Боерган булса, эшләрбез.

— Ни бит, кордаш, миңа күп кирәк. Үземә дә, улыма да булсын иде...

— Үзеңә дә, улыңа да булыр. Нindирәк бизәкле итеп ясарга соң?

Әйтер сүзе бетмәгән иде әле кордашының, ул янә бер ара тартынып торды.

— Бизәге дип, анысын үзең карар идең... Тизрәк булса икән, кордаш?..

— Монысын вәгъдә итә алмыйм, чират,— дип, кабат ишегалдының буеннан-буена тезелеп киткән такта өемнәренә күрсәтте Гыйлемхан.— Чиратны сакларга туры килә.

— Син, кордаш, теге чактагы өчен үпкә тотасыңдыр...— дип, үзе искәртергә кирәк тапты килүче. Юкса, Гыйлемхан аның уңайсызлануын болай да күреп тора иде инде.— Малайга гына булса да эшлә инде чи-

ратсыз? Хакын кызганмабыз... Күпмедән ясыйсың соң?

— Үпкәләштән булмасын, чиратсыз булмый.

— Соң, аның караву, мин бит аның хакын түлим. Икеләтә булыр, кордаш. Башкалар унны бирсә, мин — егерме, алардан егерме икән, миннән — кырык!.. Хикмәт хакында түгел, тизрәк кенә булсын. Башкалардан алдарак...

— Без бала-чага түгел, сатулашмыйк, булдыра алмыйм.

Тыйнак һәм иple генә күренсә дә, үзенекен итәргә өйрәнгән кеше булып чыкты аның яшьтәше. Максатына ирешми һич туктар чамасы күренми.

— Мин синең хәлне аңлыйм, Гыйлемхан кордаш,— дип дәвам итте ул аның саен.— Яман ат чыгарудан куркасыңдыр. Дөрес анысы... Ләкин миннән шикләнмә, шушында килешкән шушында калыр. Алайса, әйдә, үзең әйт хакыңны. Күпме?! Үзебез генә белербез, малайга да белгертмәм.

— Такталарыңны төшер. Баш-башларына үз тамгаңны салырга онытма. Чират житкәч тә эшләрмен,— дип, кулына бизәкләр чигү өчен хезмәт иткән нечкә пычкысын алды Гыйлемхан. Гомер кичергән, тәжрибә туплаган өлкән кешеләрчә килеп чыкмады аларның сөйләшүе, шуңамы, кәефе нык кына кырылып өлгергән иде.

Әмма яшьтәше, теше-тырнагы белән диярлек, үзенекен итәргә маташты һаман. Аңларга теләмәде, аңлаудан узган идеме...

— Син дә минем хәлгә керергә тырыш инде... Малай бит минем гараж мөдире. Башкалардан калышу килешеп бетмәс аңар, аңла, Гыйлемхан!.. Син дә кире китәргә җыенгандай күренмисең. Кул — кулны, ике кул битне юа, диләр. Яшәргә, нигез яңартырга уйласаң, кирәк чыкмый калмас. Машина-трактор заманы.

Җавап үзгәрмәде. Күңелсезләнеп, атлар-атламас кына чыгып китте кордаш тиешле кеше. Гыйлемханның да кәеф күтәрелмәде. Тактаның ботаклысы туры килгәнгәме, әллә кул астындагы кораллары үтмәсләнде — эш бармады ул көнне.

Ишегалды такта өемнәре белән тулды. Капкадан хәл белешергә килүчеләр өзелмәде. Күпме гомер инде Гыйлемхан алны-ялны белми тәрәзә йөзлекләре ясый. Ә Дәүапасы көннең-көн буена тәрәзә төбендәге ап-ак чәчәккә төренгән яран гөл арасыннан ишегалдына текәлеп утыра... Күңелендә ни булганны, аның нинди уйларга чумып утырганын һич аңларлык түгел, соңгы арада күлә дә, елый да алмас хәлгә килгән иде инде ул. Карашы кая төбәлгәнне дә аңламассың...

Авыл гөрләп тора. Авылдашлар дөнья куа. Кырдан иген кайта, бәрәңге... Тракторлар, үкереп, силос таптый... Хезмәт көненә тигән бодай олауларга сыймый... Тезелешеп су буеннан кайтып килгән каз-үрдәк кагынганда, бакчаларда тупырдап алма коела... Бурадай сыерлар, көтүдән кайтып керергә өлгерми, кукуруз басуына шыла... Ындыр артында, җир тырмашып, ике яшь үгез сөзешә...

Гыйлемханның күңел тыныч түгел. Әлегәчә аның туган нигезендәге тәрәзәләр йөзлексез моңаеп утыра. Күз күрмәгән, хыял ирешмәгән йөзлекләр ясарга иде үзләренә... Башка берәүнекен дә кабатламаган, авылда тиңе булмаган йөзлекләр. Озакка сузмый ясарга иде, туган нигезне җәберсетү ярамас... Бригадир үзе киләчәк, сорап, гозерләп киләчәк — монысына шикләнмәде ул. Бер көн түзәр тагы, икене түзәр, әмма артык булдыра алмас... Ләкин ул йөзлекләр нинди булырга тиеш соң? Нинди бизәкләр төшерергә үзләренә?.. Гади һәм бер үк вакытта матур да булырга тиеш алар. Әмма ул чигешләрне кайдан табарга?..

Һәм көннәрдән бер көнне тапты: үсмер елларының бердәнбер истәлеге булган чигүле кулъяулыкта икән ич ул бизәкләр. Күкчәчәкләр... Яшьлек таңында үзенә ихластан кулын сузган һәм аның өчен инде күптән томаннар артында, билгесез еракларда калып эзсез югалган үсмер

кыз — Минсылу чәчәкләре... Бер карасаң, иң гади һәм гадәти чәчәкләр. Ә үзләре нәфис, җыйнак һәм кабатланмас матурлыкка да ия... Тәрәзә йөзлекләренең як-ягында өчәр күкчәчәк зәңгәр нур сирпеп торырга тиеш. Нәкъ кульяулыктагыча... Ак йөзлектә янып торган күкчәчәкләр... Үзенең хыялында кинәттән генә балкып туган шул сурәтне күз алдына китергәч, канатланып, рухланып китте ул.

Ә шул ук сурәтне эти-әнисеннән, чит күзләрдән яшереп, кайчандыр берьялгызы төннәр буе ефәк җепләр белән чигеп чыккан Минсылуны нинди хисләр биләп торды икән... Кичекмәстән, хәзер үк эшкә тотынырга дигән нәтиҗәгә килде. Шуны башкарып чыкканда, туган нигез каршында гына түгел, үзенең тәүге хисләре алдында да күпмедер аклану табачак түгелме ул?! Бәлки, үз гомерендә башкарган иң җаваплы эшләрнең берсенә тотынуыдыр аның... Башкарып чыкса, күңелендә берөзлексез төзәлмас яра булып сыкрап торган үкенү тойгылары да бәлки басыла төшәр... Туган нигез хакына! Бары хәтердә генә сакланган авылдашы Минсылу хакына!.. Ясый башлаган йөзлекләрен бер читкә куеп торып, иң җаваплы эшкә әзерләнергә кереште ул. Яр читеннән тын гына, ипле генә йөзеп барган көймәнең кинәт, туксан градуска борылып, шаулы диңгез уртасына, дулкыннар кочагына ташланганыдай булды бу. Күз алдында чит-читләре челтәрләп чигелгән күкчәчәкле кульяулык торды аның. Шуны өлге итеп сөян такталарга күчерәсе, җан өрәсе калган иде. Күкчәчәк таҗындагы төсләр гаммасын, нечкә борылышларны җиренә җиткереп сурәтли алырмы ул...

* * *

Беренче йөзлекнең як-ягында күкчәчәкләр балкып кабынган иртәдә, капканы киереп ачып, бер ат йөге такта төягән бригадир килеп керде ишегалдына.

— Көтмәдеңме? — дип кычкырды ул, үз кыланышларыннан үзе канәгатьләнеп көлә-көлә.— Мөхәммәт тау янына килмәсә, тау Мөхәммәт янына килә диләрме?! Үзем килдем менә...

Исәнләшү, хәл белешү юк, җигүле атын ишегалды уртасына туктатты да арбадагы йөкне бәйләгән бауны чишәргә кереште Нәҗип.

— Тәрәзә йөзлекләре һәм кәрниз,— диде ул такталарына күрсәтеп.— Материал шәп, кара аны, бутый күрмә! Бер ботак табарсыңмы икән, карале, кара...

Гыйлемхан хәйран калып күзәтте аны. Кешене тану өчен бер күрешү генә аз диләр, хак икән. Авылга кайтканына инде ни гомер, әмма һаман бригадир турында төгәл генә фикер туплый алганы юк иде әле аның.

— Менә шулай, абзый кеше. Син Нәҗипне гади бер мужик, рәдәвой бригадир дип кенә уйлыйсың. Ә дөнья син уйлаганнан катлаулырак... Карале бу такталарны, карале... Тагы кемдә бар шундый такталар, күрсәт, кем китерде?!

Такталар белән шаккатыра алмавын аңлап алгач, өстендәге зәңгәр халат кесәсенә кулын тыгып, ишегалды буйлап атлап китте ул.

— Болар нәрсә?.. Болар да эшкә ярыймы? — ди-ди, авылдашлары китергән такталарга күнитек борыны белән төртеп-төртеп узды. Кире әйләнеп, Гыйлемханга җиткәндә генә туктап калды. Башын күтәрде һәм бик әһәмиятле сер чишкәндәй пышылдады.— Бажалары пилорамда эшләми, хикмәт шунда!..

Моңарчы түзгәннәре дә җитеп ашкан иде Гыйлемханның, чыгырдан ычкынган бригадирның кыланышларын артык күрәсе килмичә, башын иярга мәҗбүр булды ул. Бераздан шомартылган такта өстенә өлге куеп, кулына карандашын алды. Ә бригадир, аның әлегәчә үзенә ләм-мим дәшмәвен искәрмәде дә булса кирәк, дәвам итте.

— Димәк, килештек,— диде ул, кулын-кулга шапылдатып.— Тәрәзә йөзлекләре! Сигез! Һәм дә кәрнизләр! Шартым шул — кешенекеннән ким булмасын!

Бу юлы да җавап биргәнне көтмәде. Җавапның уңай булырына ул шикләнми дә иде, күрәсең. Сәгатьләр буе янәшә торып, гәпләшеп тә, әңгәмәдәшенең үзенә дәшмәвен абайламаган булыр иде бригадир. Ни генә кыланмасын, Гыйлемхан аңарга дорфа сүз әйтергә, яисә чыгар юлына озатып, капкага күрсәтергә җөрьәт итмәячәк. Шулай да дәшми булдыра алмады ул аңарга.

— Кирәкләре чыктымыни?

— Чыкмаса, йөрмәс идем. Минем эш беткән, башка мәшәкать калмаган дип уйлыйсыңмы?!

— Уйламыйм. Шулай да, нигә кирәкләре чыкты әле?

— Нигә... Нигә...— дип, сабыйны үртәгәндәй авызын турсайтты, иңбашларын җыергалап алды ул.— Кем чакырып кайтарды сине? Я, әйт, кем сорады, ни пычагыма кайттың син монда? Син — авылны, авыл сине оныткан. Нәмә эзләп кайттың син?..

— Зыяным тидеме әллә? — дип, мөмкин булганча тынычлыгын саклап сорап куйды Гыйлемхан.

— Ну, ярар, кайттың да ди... Кем сораган иде синнән тәрәзә йөзлекләре, кәрниз дип коткы таратырга!

Соңгы җөмләне ул янә, төкерек чәчә-чәчә, иреннәрен турсайтып, бигрәк тә «тәрәзә йөзлекләре» һәм «кәрниз» сүзләренә мыскыллы басым ясап, сузып әйтте. Гыйлемханның да күзләр бәйләүле түгел, әлбәттә, барын күрде, аермачык тоеп торды ул. Шулай да сабырлыгын җуймады.

— Мин сине аңламыйм, Нәҗип,— диде ул, үзен чынлап та берни аңламаган кешегә чыгарып.— Сиңа кирәкме ул йөзлекләр, әллә юкмы?

— Кирәкмәсә, йөрмәс идем.

— Кирәккәч?..

— Син кайтмасаң, бер мәшәкать кимрәк булыр иде дим. Нәрсә, авыл кешесенең башка эше, башка кирәге беткән иде дисеңме? Болай да... кыл сыймаган чакта эч пошырып йөрисең. Кайттың да, шул тишек-тошыклы такта кисәкләрең белән башны катырып, авылны аякка бастырдың.

— Алай икән,— дип сузып куйды Гыйлемхан.— Соң, вакытың да булмагач, кирәкләрен дә күрмәгәч, ник йөрисең? Ясамыйбыз аны! Сине дә, мине дә мәҗбүр итүче юк, ясамыйбыз.

— Ясарсың!.. Терсәкне тешләп булмай аны, абзый кеше, тотынгансың икән, күзләрең чекерәйгәнче ясыйсың инде хәзер.

— Ошыймы соң? — дип, үзе дә көтмәгәндә кинәт кенә күкчәчәкле тәрәзә йөзлегенә таба борылды Гыйлемхан. Ул бит аны барыбер Нәҗипкә күрсәтми кала алмый иде, йорт аныкы.

— Бумы? — дип, бер тын җитдиләнеп игътибар белән карап торды Нәҗип һәм иреннәрен турсайтты.— Нәрсә соң бу? Мыскыл итәсең, начальник... Чүп үләне генә җитмәгән иде тагы.

— Күкчәчәкләр...

— Сиңа — күкчәчәк, миңа — чүп үләне... Юк, бу миңа бармый! Төртерсең шунда башка берәүгә.

Күзаллары караңгыланып алды Гыйлемханның, бугазына каты төер килеп тыгылды. Әмма бирешергә, сер бирергә ярамый иде — бу соңгы мөмкинлек. Соңгысы... Туган нигезгә хуҗа булып калган кеше тора каршында! Ата-баба нигезе...

— Сиңа дип ясадым, ал Нәҗип?!

— Мыскыл итмә, абзый кеше!

— Монысын ошатмасаң, мин сиңа башканы ясарга җыенмыйм. Бу минем, беләсең килсә, бу минем...— Тамак төбенә килеп тыгылган төер сүзен дәвам итәргә ирек бирмәде аңарга. «Җанымны, бөтен көчемне куеп эшләгән иң кадерле эшем»,— дип әйтә алмады Гыйлемхан, башын читкә борды.

Бригадир исә берни аңламады. Кеше хәленә керү, башкаларны аңларга омтылуның, гомумән, ни икәнлеген белми иде булса кирәк ул.

— Ясарсың, абзый кеше, ясамый кая китәсең... Ясата торган нәрсә

булганда ис китте юк анысы,— дип, ул халат кесәсен селкетеп вак акчаларын шылтыратып куйды.

Сүзгә ихтыяҗ күренмәгәч, дәшми калуны хуп күрде Гыйлемхан. Ә бригадир дәвам итте:

— Әйтсәм әйтәем инде, абзый кеше, иң элек син ир-егетләрчә эш итә торган бул. Миңа атап ясадым дигән йөзлекләрне председательгә сатып җибәргәнсең...

«Хәтер шәп икән моның, үзенә кирәклене онытмаган,— дип уйлап куйды үзен кулга алырга өлгергән Гыйлемхан.— Теге чакта колагына да элми кыланган иде, ә бүген әнә ничек сукалый...»

— Ярар, персидәтелгә булсын да ди, ул хуҗа кеше... Хуҗа кеше алдында тәлинкә тоткан бер син генә түгел. Ә менә завфермага, түбән очтагы бригадирга ясамый торганда да ярар иде. Миннән узып, кем соң алар ул тикле?..

— Сиңа кирәкмәделәр бит.

— Ул чакта кирәкмәде, хәзер — кирәк.

— Нинди йөзлекләр кирәк соң сиңа, я әйт?!

— Бу чүп үләнлесе кирәкми,— дип, янә үзенә атап ясалган тәрәзә йөзлегенә кул селтәде ул.— Нинди дип... Теге ябага тайларныкы ише генә булмасын инде.

«Ябага тайлар» дигәне үзеннән яшьрәк булган икенче бригадир һәм ферма мөдире була икән.

— Нинди сурәт төшерергә инде, нинди бизәкләр? — дип, соравына ачыклык кертте Гыйлемхан. Үзе ясаган тәрәзә йөзлекләренең авылдашларына кай яклары ошаганлыкны күптән беләсе, ишетәсе килә иде инде аның. Юкса, «яхшы» диләр, «булган бу, рәхмәт» диләр, кай җире күңелдәгечә булган, ләм-мим.— Әйтик, күгәрчен кунганы кирәкме, сандугачлысын ошатасыңмы? Як-якларына балан тәлгәшләреме, әллә...

— Ябага тайларныкыннан шәбрәк булса, сандугач сурәте ясыйсыңмы, миңа димәгәе, ботыннан эләктереп, бака элеп куясыңмы — синең эш. Кайтыш кына булмасын! — Һәм ул янә халат кесәсенә сугып алды.— Акча бар.

— Күпме бирерсең икән? — дип, үртәгәндәй, ачу катыш елмаеп сорады Гыйлемхан.— Шулай да, күпме?

Акча турындагы сүзне килгән бер кеше кузгата иде аның каршында. Сатулашулардан шома гына шуып чыга килде әлегәчә, башка вакытта яисә соңрак килешербез дигән сылтаулар белән кичектерә барды. Әмма шул ук вакытта ул яхшы белә: араны өзми торып, бер генә кешедән дә котылу юк аңарга. Кеше, гомумән, бурычлы йөрүне яратмый, ә мөстәкыйльлекнең түмен белгән авыл кешесе — аеруча. Эшләткәнсең икән — түләргә, эшләгәнсең икән, хакын алырга тиешлекне һәркем яхшы белә. Мондый чакта тартынып, боргаланып торуны төрлечә аңлаулары мөмкин, күбрәкне өмет итә икән диярләр. Туган хакына, дуслык хакына, күрше хакына дип ярдәмләшүләр дә онытыла язган икән ич инде. Бердәнбер нәрсә — өй күтәргәндә өмә ясау гадәте яшәп килә, анысына да кеше башына бер яртыдан алдан ук хисап ясалган булырга тиеш.

Гыйлемхан шахтерлар поселогында яшәгәндә дә аз ясамады тәрәзә йөзлекләрен. Эштән бушадымы, кулына балта-пычкы ала торган иде. Үзе кебек авылдан килеп, шахтада төпләнеп калган бик күп егетләр анда да агачтан йорт җиткереп чыкты. Мөмкин кадәр авылчарак яшәү җаен чамалый иде һәркайсы. Идел-Урал төбәкләреннән килгән татармы ул, рус егете яисә украинлымы — барысын берләштергән уртаклык — һәркайсы туган ягын, авылын сагынып яши. Үзе йорт җиткереп, сыерын асрап, бәрәңге утыртып дөнья көтүдән җаннарына тынгылык эзлиләр кебек иде алар. Тәрәзә йөзлекләрен, кәрниз, кыек һәм капка түбәсе ише урыннарны аңардан ясатырга тырыштылар. Татарныкын гына түгел, рус һәм украин халкының да традицион милли орнаментларын өйрәнергә туры килде аңар. Чөнки барысына да туган төбәк чигелешләре кирәк иде. Билгеле, берәүгә дә рәхмәт өчен генә ясамады.

Ә монда, туган авылында, хәлләр башкачарак иде. Туган җир һәм авылдашлары каршында түләп бетергесез бурычка чумган кеше ич ул. Еллар, дистә еллар дәвамына җыелып килгән шул бурычны ул ничек итеп кайтара ала?! Кайтармый торып, җанына тынычлык иңәчәк түгел. ...Теге чакта да бит еллар авырлыгы аңар гына килмәде. Авыл белән, ил белән күтәрде халык. Икмәк, бәрәңге җитмәүне сылтау итеп, башкалар да, авылын ташлап, шахтага чыгып киткән булса, ни калыр иде Нурлы Аланнан?! Китмәгән, түзгән авылдашлар. Үзләре өчен генә түгел, аның өчен дә тырышканнар, түзгәннәр. Авылының шулай исән-сау һәм төзек булуы иң олы куаныч түгелмени!.. Димәк, ул бурычлы. Һәм туган җир каршындагы шул бурычны ул кайтарырга тиеш. Авылдашларына үзенең кирәклеген тоя башлагач, аның ничек канатланганын күрмиләрме?!.

Акчадан баш тарту дигәннән, ул хакта авылда төрле имеш-мимешләр дә йөри икән инде. Берише: «Башына тай типмәгән кеше акчадан баш тартмас, бераз җиңеләеп кайткан икән, шахтада күмер чапканда башына зур таш төшкән икән»,— дип, аны кызганып сөйләсә, теге чакта урамда очраган һәр кешегә тәрәзә йөзлекләре тәкъдим итеп йөргәнен дә тәфсилләп искә алса, икенчеләре: «Карарбыз... Үз бәясен күтәреп сатулашучы түгелме?..» — дигән шикнең раслануын көтеп яши икән.

Шул соңгыларының берсе Нәҗип булып чыга, күрәмсең. Акча турында сүз чыккач та, кәефе күтәрелеп, янә авызын җәеп җибәрде ул.

— Хе, Нәҗип ялгышамы соң,— дип, кулларын кесәсеннән чыгарды һәм дәү-дәү атлап Гыйлемханның каршысына ук килеп басты.— Килешәбез, абзый кеше, болай бултгач, килешәбез. Сиңа ничек: акчалатамы, әллә такта белән, икмәклатә, печәнлатә кирәк булырмы?..

— Кайсын да булдырасыңмы?

— Соң... Сүзне бушка сибә торган гадәт юк анысы. Килештекме?— дип, авыз читләреннән төкерек чәчеп елмаеп җибәрде ул. Акчалата түләмәү җае чыгып тору аның өчен куаныч иде, күрәсең.

— Мин күп сорасам... Каян табарсың?

— Сорау синең эш, табу — минеке!

Бу уенны артык сузар түземлеге калмаган иде Гыйлемханның. Тагы бер мәл дәшми-нитми генә сынап карап торды да йөзенә бәреп әйтте ул аның. Хәтта үзе өчен көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты бу кыюлыгы:

— Бар, Нәҗип, олак моннан! Зинһар, югал күземнән!

Бригадир исә әлеге борылышка һич әзер түгел иде, колагы ишеткәнгә ышанырга белми катып калды. Әмма күпкә түгел, шундук кулга алды үзен.

— Рас икән, ычкынган!.. Башына тай типкән ич моның,— диде ул, Гыйлемханнан бигрәк үз-үзенә дәшкән сыман.

Муенында кан тамырлары бүртеп чыкты, бит мускулларыннан кырмыскалар чабышып үтте Гыйлемханның. Иреннәр кысылды, бармаклар, җыелып, бер йодрыкка тупланды.

— Эзең булмасын,— дип кычкырды ул, тешләрен кысып.

Нәҗип бер ара дәшмәде. Дилбегәне кинәт тартып, атын кире борды да җәт кенә такталарын ишегалдының урта бер җиренә аударып атты. Шулкадәр тиз һәм көтмәгәндә башкарып чыкты ки ул боларны, туктату түгел, карышырга да өлгерми калды Гыйлемхан. Ә бригадир инде, аякларын киң җәеп, арбага ук менеп баскан иде.

— Нәрсә, азмыни?!. Сиңа акча кирәкмени!.. Ш-шы-ша-абашник,— дип, еландай ысылдап җикеренде ул. Атын капкага юнәлтте.

— Такталарыңны ал. Мин аларга ягылачак түгел!..

— Ух, ш-шы-ша-абашник... Ясарсың, ничек кенә ясарсың... Закун бар... Сәвит власты... Ясатырбыз...— дип кычкырды да, атына яман кизәнеп, урамга чыгып чапты ул. Соңгы сүзләре капка төбендә, ишегалдында, Дәүапасының тәрәзә йөзлекләрендә һәм кәрниз очларына эленеп калды: «Ша-баш-ник...»

Тәрәзә төбендәге ак ярангөл чәчәкләре арасыннан күзәтеп утырган Дәүапасының йөзендә һичнинди үзгәреш сизелмәде. Салам түбәле ярым җимерек иске каралтыга терәп урнаштырылган верстагына килеп таянды Гыйлемхан. Кул астында булсын өченгә, билгеле бер тәртип белән тезеп куелган эш коралларын күздән кичерергә керешге... Җаның теләгән бизәк уеп була үзләре белән. Беренче тапкыр күргән кешедәй, һәркайсын аерым-аерым кулга алып, әйләндерә-әйләндерә карап торды. Ата-бабадан калган соңгы истәлекләр... Туган нигезен ул саклый алмады. Гомумән, юл ябылды туган нигезгә, моннан ары аягы да тартмас... Өтерге һәм бораулар... Артыш саплы пәке... Саплары кылдан тарттырылган нечкә пычкылар... Нәсел җебенең соңгы ядкарьләре! Карап торышка гадәти, хәтта хәзерге техника заманы өчен үтә гади дә тоелырга мөмкин булган әлеге эш коралларында ул әтисенең кул җылысын, аның бармак эзләрен, чигәсеннән тәгәрәп тамган тир кайнарлыгын тоя иде кебек. Әтисе генә түгел, бәлки бабасыннан калган эш кораллары бардыр арада. Бүгенге балта осталары тарафыннан күптән онытылган, әмма урыннарына алмаш табылмаган эш кораллары... Алар дәшми, билгеле. Һәм дәшмәячәк, чөнки телләре юк...

Эш коралларыннан күзен ала алмады Гыйлемхан. Ата-бабадан калган ядкарь генә түгел алар. Җан тынычлыгы китергән хезмәтнең нигезе, таянычы. Шулар ярдәмендә матурлык эзләгән, матурлык тапкан көнәр — гомеренең берни белән дә алыштыргысыз мәгънәгә ия мизгелләре. Корал эшли, кул мактана дип, юкка гына әйтми халык. Әлеге эш коралларының берсе, икесе генә житенкерәмәсә дә күңелдәгечә ясый алмаган булыр иде ул тәрәзә йөзлекләрен...

Җан тынычлыгы гынамы... Авылдашлары белән якынайтты, өзелгән, югалган туганлык һәм кардәшлек җепләрен табышты ич аңарга әлеге эш кораллары. Чөнки тәрәзә йөзлекләре юллап килүчеләр әледән-әле үзләренең кем улы, кем кызы һәм кайсы тармактан, кайсы чыбыктан Гыйлемханнарга кардәш тиешлеге турында да житкерергә онытмыйлар иде. Баксаң, ярты авыл кардәшләрдән гыйбарәт икән ләбаса... Булсын, кардәш булсын, кордаш булсын, авылдаш булсын — һәркайсы изге төшенчә. Шуңа да араламый ич ул аларны, форсат чыкканга куанып, һәркайсына якты күңелә карап торачак тәрәзә йөзлекләре бүләк итә.

...Эш коралларыннан күзен ала алмады Гыйлемхан. Туган авылына кайтып, ул кичергән күңелсезлекләр, җанын рәнҗеткән борчуларның очы да шуларга барып тоташа иде бит. Авыл урамнарын, чишмә һәм су буйларын бер күрергә зарыгып кайтучы ул гына түгел. Башкалар да кайта авылга. Аны әлеге «башкалар»дан аерып, үзгә шартларга куйганы да шул ук эш кораллары түгелмени?! Капка төбе саен туктап, билгә таянып хәл-әхвәл белешеп, тегене-моны искә алып сөйләшү, башкалар күк кунакка дәшеп, кунакка йөрешү әллә аңар харам булыр идеме?! Кем ирек бирми, нәрсә каршы төшә аңарга да шулай яшәргә? Ата-бабадан калган һөнәр! Һәм әлеге дә баягы шул эш кораллары... Кайтып төшкән көнне үк туган нигезендә торган йортның кәрнизләре (буйдан-буйга кадакланган тоташ тактаны кәрниз дип әйтү урынлы түгел, билгеле), кашсыз-керфексез күзләрне хәтерләткән тәрәзәләр әчен пошырган иде. Аннан авыл урамнары аша үткән саен күңеле сызды. Үзенең төзеклеге белән алай аерылып тормаса да, кайчандыр зәвык белән ясалган тәрәзә йөзлекләре, кәрниз һәм капкалары, хәтта коймалары Нурлы Аланның кабатланмас йөзен тәшкил итә иде бит. Авылның гына түгел, һәр йортның үз йөзе, үз бизәкләре бар иде. «Нурлы Алан осталары тактага балта очы тигерсә, чәчәк хасил була»,— дигән әйтем онытылган. Исеменә җисеме туры киләме икән аның хәзер?!

...Анысы бер хәл. Тәрәзә йөзлекләрендә генә түгел хикмәт. Соң чиктә, йөзлекләрсез дә яшәү мөмкин. Күңелләрдә матурлыкка омтылыш сүрәнләнүе аяныч. Күңел йөзлекләре мортаю... Соңгы араларда «матурлык» төшенчәсе, иҗтимагый төшенчә булуыннан туктап, йозаклы фатир һәм кү-

целләргә кереп чикләнмәдеме?!. Ә муллык һәм байлык, киресенчә, күңелләрне шәрәләндереп, тышка бүселеп чыккан. Әле кайчан гына авыл кешесе урамга чыгып бер әйләнеп керүне үзе өчен ял итеп кабул иткән. Зәвык белән бизәкләп эшләнгән җыйнак өйләр, чирәмгә, бәбкә үләннәренә тереңеп утырган тигез иркен урам, пөхтә итеп себерелгән капка төпләре, койма читендә үсеп утырган ак каен һәм миләш, шомырт агачлары — боларның берсе дә дәрәҗә яисә байлык күрсәткече саналмаган. Матурлыкка булган табигый ихтыяҗ, омтылыш тудырган аларны. Йомшак чирәмгә басып, яланаяк каз бәбкәсе көтеп йөргән малайлар өчен авыл урамы — матурлык чыганагы, үзенә күрә күргәзмә залы, сынлы сәнгать музее вазифасын үтәгән. Алмалы көянтәгә җиләкле чиләкләрен асып чишмә башына төшкән кызлар да су гына түгел, күңелләрен мөлдерәтерлек хис, тойгы алып кайткан. Кызлар гынамы, хәтта карт-корыларның урамга таянып чыккан таягы да бизәк яисә сырсыз булмас иде...

Матурлык турында уйларга, матурлыкка сокланырга авыл кешесенең вакыты калмый хәзер, диләр... Авылда мәшәкатьнең бетеп торганы юк, дөрес анысы. Әмма кая киткән соң ул вакыт? Игенче кулындагы уракны алыштырган комбайннар тартып алганмы аны?.. Матурлыкка вакыт түгел, табигый ихтыяҗ кирәк.

Ясаган тәрәзә йөзлекләрен мыскыл итеп, бригадирның аны үз нигезеннән куып җибәргән, өй борынча йөреп тә, шул йөзлекләргә урын табалмыйча, кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булган көнен хәтерләде Гыйлемхан. Искә алуы да җиңел түгел иде ул вакыйгаларны, эсселе-суыклы булып китте. Бер мизгелгә күңелендә ачу, ниндидер усаллык һәм үч алу тойгысы кузгалып алды. Тик торганда, сау-сәламәт кешенең йөрәге чәнчеп алгандай булды бу, ничек туса, шулай югалды да.

Боларны нигә дип искә төшерде соң әле ул? Бары да үткән, артта калган — онытырга вакыт. Авылдашлары да үзгәрде кебек, һәммәсенә тәрәзә йөзлекләре, кәрниз кирәк. Тиз булсын, күршенекеннән ким булмасын, диләр. Матурлыкка омтылыш югалмаган, димәк... Әмма күңелне берөзлексез, идән астында кыштырдаган тычкан сыман, нидер борчып, тынгысызлап тора. Торган саен арта, ишәя бара иде бу тынгысызлык. Әрсезлек белән тәрәзә йөзлекләре юлларга керешкән авылдашларын күргән, алар белән сөйләшкән саен арта барды ул. Урамны, авылны матурайту ихтыяҗы йөртми иде шул аларны. Башкаларда булган өчен кирәк. Башкалардан калышмау өчен, үз күршесен, авылдашын, хәтта үз туганын уздыру өчен кирәк тәрәзә йөзлекләре! Мал җыеп дөнья куунын чираттагы бер чагылышы гына икән ич болар һәммәсе... Көнчелек, бер-береңнән уздырырга тырышу — бу нәрсә, әллә милли характермы безнең?!.

Гыйлемхан — шул ярышка, узышка яңа юнәлеш бирүче. Үз иманына хыянәт түгелме соң бу? Көнчелек, бер-береңнән уздыруга омтылыш, комсызлык, пәри туен хәтерләткән шул афәткә тагы күпме хезмәт итәргә тиеш ул?.. Шуның өчен ашкынып кайткан идеме туган ягына? «Ш-шыша-абашник...» дигән сүз ишетер өченме?! Шундый мыскыллауны күтәрерлегең булгач, ни өчен дип җир астында күмер көрәп уздырдың гомереңне?!. Башкалар таба ич, син дә берәр җаен тапмый калмаган булыр идең...

— Ш-шы-ша-абашник...

Сискәнеп як-ягына каранырга кереште ул, чын-чынлап ишетелә, яңгырый иде теге яман аваз. Көчәйгәннән-көчәя барып яңгырый...

Ә тәрәзә каршында, ак ярангөл чәчәкләренә күмелеп, Дәүапасы утыра.

— Ш-шы-ша-абашник...

Бригадирның пычкы чүбе исе килеп торган өр-яңа такталары ягыннан ишетелгәндәй булды ул аваз. Аларны башка өемдәгеләре эләктереп алды... Соңгыларына тәрәзә йөзлекләре кушылды. Сибелеп яткан, алка сыман бөтәрләнгән йомычкалар дәррәү купты. Җил чыгып, пычкы чүбе күтәрелде... Аны үртәп ду килә иде ишегалды.

— Ш-шы-ша-абашник...

Ишетмәскә теләп, колакларын томалады Гыйлемхан.

Ә Дәүапасы һаман ак ярангөл чәчәкләренә күмелеп тәрәзә төбендә утыра...

Көчәйгәннән-көчәя барды аны ләгънәтләгән тавыш. Верстак читендәге эш кораллары, чарасыз калып, аның күзенә текәлгән. «Бер-бер чара күр, син бит кеше. Коткар безне бу түбәнлектән»,— дип сыкрана иде сыман ата-бабадан калган эш кораллары... Күкчәчәкләр уелган ялгыз йөзлек тә сулып калган. Чүп үләне дип кире кагылган чәчәкләр... Күкрәк кесәсендәге чигелгән кулъяулыкка ут капкандай булды кинәт...

Биреште Гыйлемхан, үз-үзен кулдан ычкындырды. Җанын кыршау сыман буарга керешкән аваздан котылыр җай тапмагач, кабаланып, дөньясын онытып, бригадир китереп аударган такталарны бакча якка ташырга кереште ул. Ни теләгәне, нәрсә кылганын белешми ташыды...

Бакчаның ерак почмагында чүмәлә итеп өелгән бәрәңге чүбе бар иде. Күкерт сыман тиз кабынып, дөрләп янырга кереште бәрәңге сабаклары. Алар белән бергә такта янды, бригадирның сөян такталары. Әмма теге яман аваз аның саен тынмады. Бүре булып улады, елан сыман ысылдады тавыш: «Ш-шы-ша-абаш-ш-ш...»

Гарьлегеннән ни эшләргә, нәрсә кылырга белмәде Гыйлемхан. Ут тирәсендә ыгы-зыгы килде, арлы-бирле йөренде ул. Үз-үзен белешерлек хәлдә идеме соң... Ялгыз башын кая куярга, ни эшләтергә белмичә, янә ишегалдына атылып чыкты. Ә анда күкчәчәкләр уелган тәрәзә йөзлеге... Моңаеп, уңайсызланып, алай гынамы, хәтта аңарга рәнҗеп утыра сыман тоелды күкчәчәкләр.

Шушы хәлдә торып калган сыңар тәрәзә йөзлеген һәм күкчәчәкләрне мондый түбәнлектән ул ничек коткара ала иде соң?.. Җәт кенә иңбашына салды да бакча түренә — дөрләп янган учакка таба алпантилпән атлап китте. Ике олы хис — Гыйлемханның туган нигез һәм Миңсылуга булган мәхәббәтен берьюлы мәңгеләштереп торырга тиешле тәрәзә йөзлеген ут телләре ялмап кына алды. Янды... Чарт-чорт килеп дөрләп янды күкчәчәкләр. Утлы күмергә әверелгәч тә, бер тын таралмый, уалмый торды әле алар. Хәтта күлендә дә зәңгәрлек бар иде сыман...

Теге яман тавыш аның саен миен боргычлады, җанын кимерүдән туктамады: «Ш-шы-ша-абашник...» Тагын ишегалдына чыкты. Утлы өермәгә әверелеп, шушы авазны ишетергә дучар ителгән эш коралларына ташланды...

Тәрәзә төбендәге ак ярангөл аша күзәтеп утырган Дәүапасы керфек тә какмады.

...Утны сүндерергә йөгерешеп кергән күрше-күлән учак читеннән чигүле ак кулъяулык табып алды. «Истәлек өчен — Гыйлемханга! М. дан». Телдән-телгә күчеп йөргән бу сүзләрнең янгынга кагылышы юк диделәр. Кулъяулыкны шундук оныттылар.

Бераздан шул ак кулъяулыкны күкрәгенә кыскан Миңсылу бер читтәге киртәгә барып сөялде. Аңарга игътибар бирүче булмады. Ә кара күмергә әйләнгән такталарын танып алган бригадир Нәҗип аты-юлы белән сүгенергә тотынды...

Гыйлемханны шул көннән соң күрүче булмады авылда. Имеш, ул үзе дә утка ташланган икән дип сөйләде берәүләр. Билгесез тарафка узып баручы поездга утырганын күреп калучылар булган дип тә чыгардылар. Ләкин, боларның кайсы дөрес булгандыр, тәгаен генә белүче юк иде.

*Аккош күле — Казан*

**Ибраһим Нуруллин**

# КИЛӘЧӘК ЯКТЫСЫНДА

Мирсәй Әмирнең иң яхшы әсәрләрен — хикәядәнме ул, повестьтанмы, роман яки пьесаданмы — кабат укыйм да элегрәк туган фикеремнең дөреслегенә тагын бер кат ышанам: үлгәч тә яшәвен дәвам итә, калка, зурая бара торган әдипләр җөмләсенә керә икән ул!

1937 елда язылган бер хикәятендә иске абзар-араннарда көн итүче терлек-туар һәм кош-кортлар яңа хәбәр ишетәләр: аларга дип яңа йортлар салып яталар икән. «Бар командировкага,— диләр кәҗә тәкәсенә,— белеп кайт: күчәргә ярарлыкмы, юкмы». Кәҗә бара, карап йөри һәм кайтып әйтә: юк, җәмәгать, анда күчәргә ярамый, чөнки, ди, тәрәзәләре, зур булса да, пыяласыз, ишекләре бөтенләй юк, идәннәре йомычка һәм бүкән башлары белән тулы. Кәҗә тәкәсе, ди автор, күргәннәрен түкми-чәчми дөрес итеп сөйләде. Әмма ул «...салынып ята торган яңа каралтыларның кичә ни хәлдә булулары һәм иртәгә ни хәлдә булачаклары турында фикер йөртү кадәр тирәнлеккә бара алмаган иде».

Бик тә мәгънәле бу язма минем хәтер сандыгыннан түбәндәге бер вакыйганы тартып чыгарды.

Татар дәүләт академия театрының художество советы утырышы. Культура эшләренә кагылышлы урта дәрәҗәдәге бер җитәкче иптәш тә бар. Менә ул бервакыт драматургларны тормыштан артта калуда гаепләп сөйләргә керешә. Кыза барып һәм бик шәбәеп, болай дип тә җибәрде: «Кайда Гаганова хәрәкәте турында пьесаларыгыз?» Утырышта М. Әмир дә бар иде. Менә ул сүз алды һәм, гадәтенчә, сабыр гына, вәземләп кенә сөйли башлап, якынча мондый фикер әйтте: «Язучының бурычы узганнарны теркәп бару булмаган кебек, теге яки бу карарны иллюстрацияләү дә аның вазифасына керми. Гаганова турында мин ул хәрәкәт башланудан унбиш ел элек язган идем».— һәм ул... «Миңлекамал» драмасын атады.

Ике очракта да социалистик реализм методының иң мөһим сыйфаты турында сүз барганны укучы чамалагандыр дип беләм. Уңай яңалыкны яралгы хәлендә үк тотып алып, үстеребрәк, зурайтыбрак тасвирлау принцибы бу. Икенче төрле әйтсәк, тормышны өченче чынбарлык — киләчәк яктылыгында чагылдыру, барны булырга тиеш белән органик берлектә күрсәтү.

Әнә шул принципны тормышка ашыруның төп чарасы,— мәгълүм булганча, уңай герой. Менә ни өчен бу мәсьәлә дә М. Әмирнең һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Чыгышларында һәм мәкаләләрендә ул моңа еш-еш кайта торды, бервакыт хәтта кимчелексез уңай герой концепциясен дә күтәреп чыккан иде.

Мирсәй Әмирнең сүзе эшеннән аерылмады: аның иҗаты уңай герой ярдәмендә чынбарлыкны үсештә чагылдыру принцибын тормышка ашыруның гаять отышлы мисалы булып хезмәт итә ала.

Менә 1933 елда басылып чыккан «Безнең авыл кешесе» исемле повесть. Үзәктә — өч персонаж. Яңа шартларга җайлашып алып, артель председателе булуга ирешкән мәкерле, каты бәгырьле һәм акыллы кулак Миргали. Кайда кыен, кайда өзеклек, шунда җибәрелә торган нык куллы чын коммунист Бикташев. Миргалигә бәйле хәлдә калып, кулак йогынтысында яшәп килгән колхозчы Сабир. Төшерелгән «председатель» белән яңасы арасында рәхимсез көрәш башлана. Бикташев ягыннан бу Сабир һәм Сабир кебекләр өчен, ахыр чиктә социализм тантанасы хакына барган көрәш. Колхозчылар алдында Миргалинең йөзен фаш иткәч, Бикташев, болай ди: «Мине ялгыз дип белдеңмени син? Чит авыл кешесе дип белдеңмени син Бикташевны?!» «Безнең авыл кешесе ул Бикташев!» — дип, Сабир аваз салгач, аның сүзен күтәреп алалар: «Әлбәттә, безнең авыл кешесе!» — Әнә бит ничек: үз авылларыныкы ят булса, чит авылныкы — үз кеше. Кешеләрне урынчылык, һәм кардәш-ырулыктан бигрәк, уртак идея берләштерә икән.

1936 елда дөнья күргән «Агыйдел» повесте сугышка кадәр кулдан төшерми, чират торып укыла торган әсәрләрнең берсе булып киткән иде. Бүген дә аны яшьләр генә түгел, өлкәннәр дә яратып укыйлар.

Әсәргә мондый уңыш китергән сәбәпләр байтак. Теманың актуальлеге, тормыш материалының кызыклы булуы да бар монда. Сюжетны композицион яктан үткен һәм мавыктыргыч итеп кора белү дә бар. Тапкыр һәм эчке мәгънәгә ия булган детальләрне табып үйната белү дә күзгә ташланып тора (авыл кулагы Тәкъвә Сәхәүнең малайлар төкереген кәвеше белән ышкып баруын гына хәтерлик. Акча түгелме, янәсе).

«Агыйдел» повестен озын гомерле иткән төп сәбәп исә шул заманның иң күркәм, иң алдынгы кешеләрен әсәрнең үзәгенә куеп, тормыштагыча җанлы, катлаулы һәм каршылыклы итеп, ә кайберләрен калкыта, күтәрә төшеп һәм беркадәр романтизм буявы кушып сурәтләвенә кайтып кала.

Менә җиләк-җимеш, яшелчә үстерүгә җаны-тәне белән бирелгән Тешсез Ибрай. Авылны гына түгел, бөтен волостьны ул яшелчә белән күмү турында хыяллана. Менә совет шартларында да кулак һәм кулак иярченнәренең рәхәт яшәвенә йөрәге янудан бунтарьланып йөри торган партизан Имәли. Менә һәр нәрсәгә кулы ята торган бай күңелле батрак Кучәрбай. Хикәяләүче сыйфатында тәкъдим ителгән Ильясны да болар янына теркәп кую дөрес булыр. Ул — шәһәрдә укый торган гадәти авыл малае. Дөньяга күзе ачылган, ярыйсы гына белем туплаган, политик яктан да оятка калдырырлык түгел.

Әсәрдә язучы тарафыннан аеруча яратып язылган һәм, бүтән персонажлар янына куеп караганда, бер башка югары тора торган ике герой бар. Болар — Гаяз белән Артыкбикә.

Эшче гаиләсендә туып-үскән Гаязны зирәк, үткен, кыю дип сыйфатласак, бу әле күп нәрсә аңлатмас. Чөнки әлеге сыйфатларның һәркайсы аңа икеләтә, өчләтә арттырып бирелгән. Аңа, башсызлык дәрәҗәсенә җиткән батырлык белән берлектә, аек акыл белән кушылган ихтыяр көче хас. Моңа тагын политик яктан әзерлекле булганын да өстик. Яңа гына үсмерлектән чыккан шушы кала егете күмәк хуҗалык өчен башланган көрәштә әйдәп баручыга әверелә. Зурайту, калкытып кую, арттыру юкмы монда? Әлбәттә, бар. Әмма тормыш чынлыгын бозмый торган арттыру бу.

Артыкбикә — шулай ук зурайтылган һәм романтизм буявы йөгертелгән образ. Тугызынчы бала булып туганга күрә (җитмәсә, кыз!), аңа шундый исем биргәннәр. Хәзер бу исем икенче мәгънә алган: бүтәннәрдән аерылып тора торган, бүтәннәрдән һәрьяклап артык кыз. Таң калдырырлык матур, саф күңелле, горур. Яңа тормыш өчен көрәш эшенә бөтенләе белән бирелгән комсомолка.

«Агыйдел» повестеның уңышы башлыча әнә шул ике персонажга бәйле булганлыкка шикләнмәскә мөмкин.

Ниһаять, «Миңлекамал». Бу пьесаның «алтын фонд»ка кереп калу сәбәпләре дә якынча шул ук: драма жанрын сорый торган тормыш материалы, композицион яктан оста оештырылган булу, тапкыр һәм отышлы детальләр, ягымлы юмор. Төп сәбәп исә — Миңлекамал образы.

Миңлекамал М. Әмир күрергә теләгән «кимчелексез уңай герой»ның иң уңышлысы дисәм, шаять ялгышмам. Ләкин пьедесталга бастырылган җансыз сын дигән сүз түгел әле бу. Аның үткер почмаклары, чатлы-ботлы яклары да бар. Әмма аларны кимчелек яисә җитешсезлек дип атау бик үк төгәл булмас. Болар — Миңлекамалның шәхес буларак үзенчәлеге, аның характеры. Уңай сыйфатларын бер фокуска җыя, туендырып тора һәм ныгыта торган үзәк сыйфаты исә — чын мәгънәсендә партиялелек, идеялелек.

Колхоз оештырып, аякка бастыру өчен көрәшеп яшәгән сөекле ирен кулаклар үтергән. Эшләрнең киреге китүен күреп, Миңлекамал, ире башлаган эшнең дөреслеген исбат итәр өчен, укытучылыгын ташлап, колхозда эшләргә керешкән. Мал фермасында зур уңышка ирешеп, шик белдерүчеләрнең гайбәт сүзләрен ишеткәч, кыр эшенә күчкән. Анда да, «җеннәре булышып», уңышка ирешкән. Бөек Ватан сугышы башланып, ил үлем куркынычы астында калгач, күрше авылда Совет председателе булып эшләгән Миңлекамал үз колхозына председательлеккә тәкъдим итүләрен үтенеп райкомга килә.

Язучының әсәрне оештыру, драматизмны көчәйтү осталыгын күрү өчен 3 нче пәрдәгә күз ташлыйк. Колхозның хәле болай да коточкыч авыр: атлар күтәрәмгә калган, җигәрлеге нибары унау; чәчүлек орлык җитми; эшче ирләр дә аз, кайсы фронтта, кайсы читкә таралып беткән. Колхоз камытын киеп алган Миңлекамал башына яңа бәла, яңа кыенлыклар ява башлый. Биш ат военкоматта исәптә тора икән, илтергә кушалар. Биш ир-егеткә повестка килә. Ул да булмый, коточкыч хәбәр: Миңлекамалның хәзерге ире сугышта батырларча һәлак булган.

Тамашачы тетрәнеп кетә: нишләр Миңлекамал, сыгылып төшмәсме, бу чаклы авырлыкларны җиңә алырмы? Пәрдә ахырына таба укучы яисә тамашачы җиңел сулап куя. Бай колхоз председателе килеп чыга, чәчүлек биреп торырга вәгъдә итә. Бер колхозчы карт кайчандыр салынган һәм онытылган силос базын искә төшерә. Икенчесе күтәрәмгә калган атларны аякка бастыруны өстенә ала. Читтә эшләүчеләрнең берничәсе,

Миңлекамалның председатель булганын ишетеп, авылга кайта. Фронттагы улыннан хат килә.

Ләкин авырлыклар бетте дигән сүз түгел әле бу. Яңалары килеп чыга. Күбесен эшләми ашарга, кеше хисабына яшәргә күнеккән Кылый Хәлим белән Мәймүнә тудыралар. Алар хәтта Миңлекамал өстенә комиссия китертүгә ирешәләр.

Әнә шул килеш тамашачы спектакльнең башыннан ахырына чаклы драматургның нык кулыннан ычкына алмый. Миңлекамалга бәла килгәндә, авыр кичерә, уңышларын күреп, ял итеп ала, яңа бәлаларга тагын уфтана, алары да артта калгач, тагын җиңел сулап куя... Югарыда китерелгән әсәрләр янына шактый еллар буе сәхнәдә зур уңыш белән барган «Тормыш җыры» драмасын да өстәп куйыйк. Аның да үзәк герое — гаҗәеп матур кеше, эшли дә, сөя дә, көтә дә белгән яшь хатын Фатыйма.

«Кимчелексез уңай герой» концепциясе, күренә ки, М. Әмиргә зарар итмәгән, киресенчә, файда китергән. Хәер, «Ялан тау кешеләре» һәм «Саф күңел» романнарын күздә тотып, укучының бу фикергә каршы төшүе дә мөмкин. Әйе, дилогиянең төп герое Сания Миңлекамал кебек үк уңышлы булып чыкмады. Әмма «уңай герой» концепциясе гаепле түгел монда. Татарстан язучыларының III съездында бу турыда автор үзе дә әйтеп чыккан иде. «Моның сәбәбе,— дигән иде,— авторның аңардагы (Саниядәге — И. Н.) яхшы сыйфатларны геройның эше, хәрәкәтләре аша җитәрлек итеп ача белмәгәнлегенә кайта».

М. Әмир иҗатының бер ягына, иң мөһим ягына киңрәк тукталганмын икән, бу тикмәгә түгел. Уңай герой мәсьәләсе бүген, җәмгыятьне һәр яктан үзгәртеп кору процессы барган бер вакытта бөтен кискенлеге белән алга килеп басты.

Соңгы берничә дистә елда еш кына кабынып ала торган сөйләшү һәм бәхәсләр, күбрәк «әдәбиятта уңай герой нинди булырга тиеш?» дигән мәсьәлә тирәсендә барып, артык зур файда китермичә тәгәлләнәләр иде. «Идеаль герой» һәм «кимчелекле герой» дип аталган ике агач арасында да шактый адашып йөрдек. Теориядәге буталчыклар әдәбиятның үзенә дә үтеп керде. Уңайга һәм тискәрегә аерганда, мәсәлән, «кресло принцибын» үткәрү очраклары да булып торды. Әйтик, райкомның беренче секретаре — һәрвакыт уңай образ, ә райисполком председателе, бигрәк тә аның урынбасары, тискәре образ ролен уйный иде. «Геройсызлык теориясен» алга сөреп, тормышның ыбыр-чыбырында казынучылар, төссез-чырайсыз уртакул кешеләр турында язуны яклаучылар да булды, хәзер дә күренгәләп тора.

Уңай герой проблемасын, тормышның үзеннән килеп, әдәбиятның үзәгендә «заман герое» торырга тиеш дигән мәгънәдә хәл итү дөресрәк булыр. Әмма сорау туа: кем соң ул заман герое? Озын-озак уйлап тормыйча, моңа гадәттә «хезмәт кешесе» дип җавап бирәләр. Хезмәт кешесе дигәндә исә, нефтьче һәм корыч коючы, механизатор һәм сыер савучы кебекләрне күздә тоталар. Врач яисә укытучы, галим яисә инженер, әйтерсең, эшләми ашыйлар. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Икенче һәм әһәмиятлерәк ягы — хезмәтнең кем өчен, нәрсә хакына сарыф ителүе. Эшен сөеп башкару белән бергә, дөреслек һәм гаделлек, ил мәнфәгате һәм коммунистик идеал хакына, бөгелми-сыгылмый, ахыр чиккә кадәр бара торган көрәшче — менә кем ул заман герое. Механизатормы ул, райком секретаремы, академикмы, сыер савучымы, укытучымы яисә милиция работнигымы — барыбер! Менә кемнәр әдәбият түреннән хөрмәтле урын алырга тиешләр. М. Әмир тәҗрибәсе дә бу мәсьәләне хәл итүгә өлеш булып керә алыр иде.

«Балыкчы ялганнары» повестеның дөньяга килүе исә М. Әмир өчен көтелмәгән хәл булмады. Ул,— күп санлы юмористик һәм сатирик хикәяләр авторы булган кебек, һәр җөмләсе көлдерә торган «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» повестен язган әдип. «Җитди» әсәрләрендә дә юмор — сирәк кунак түгел.

Гомер һәм иҗат юлын М. Әмир биографик повестьлар циклын язып яткан хәлендә тәгәлләде. Циклның дөньяга чыгып калган кадәресенә шул ук сыйфатлар хас: гади генә, салмак кына хикәяләү, кечкенә деталь яисә эпизодта зур мәгънә күрә алу, ягымлы юмор...

Бөтен иҗатына әлеге повестьларын кушып карагач, тагын бер хакыйкать ачылып китә. М. Әмир үзенең иҗат эшчәнлеген белем ягыннан шактый түбән ноктадан башлаган икән. Берничә мәртәбә омтылыш ясап та, рәсми рәвештә югары белем алмаган килеш дәвам итә һәм тәгәлләп куя. Соң ничек итеп ул озын гомерле әсәрләр тудыра алды? Сәбәп нәрсәдә? Талант? Әлбәттә! Хезмәт сөючәнлек? Әлбәттә! Тагын бер мөһим сәбәп — гражданлык тойгысы! М. Әмир бик яшьли яңа тормыш, социалистик яшәеш өчен барган көрәш эченә ташлана, якты киләчәкне якынайту хакына бар вакытын, бөтен көчен, йөрәк ялкынын бирә. Әдәби иҗатка да ул социалистик идеалны тормышка ашыруның бер чарасы итеп карый. Күп еллар буе халык депутаты булган, сугышка кадәр дә, сугыштан соң да ике мәртәбә озак кына Татарстан совет язучылары оешмасын җитәкләгән М. Әмир җәмәгать эшлеклесе иде. Гомеренең ахырына чаклы ул Гражданин булып калды.

## Мирсәй Әмир

# ЧИРАТ

### хикәя

Уяндым.

Бүлмә яктырган — торырга күптән вакыт житкән дигән сүз.

— Житмәгәе, чәнчелеп китсен,— дим,— бүген жомга көн әле.

Юрган астыннан башны гына чыгарып, бүлмә буенча күзләрне тәгәрәтү шундый рәхәт — әйтеп бетергесез!

Шулай, юрган астыннан чыга алмыйча, рәхәт кенә иренеп ятканда, кылт итеп Гөлсем исемә төште.

— Тормыйча булмый,— дим.— Бүген Гөлсем янына барырга кирәк. Югыйсә менә төгәл бер атна — үзен бер генә мәртәбә дә күргәнем юк. Житмәсә, шуның ире исәпләнәм.

Бу укыган вакытта өйләнү — бик пүчтәк эш. Менә хәзер Гөлсемне алганга биш ай була. Ә үзебез жиде-сигез мәртәбә дә рәхәтләнеп бергә куна алганыбыз юк. Бүген, бернигә карамыйча, янына барырга кирәк. Сагындым үзен...

Шундый уйлар баштa аллы-артлы тезелделәр. Юрган астыннан чыкмыйча гына чалбар киеп алдым. Чалбар кигәч, тору жиңел эш инде — тордым. Аякка кидем дә, көн дә иртән була торган гадәт буенча, тышка чыктым. Жиде-сигез кеше чиратка тезелгәннәр. Кайсы көлә, кайсы сукрана, кайсы жырлый, кайсы тырнана.

Миңа тизрәк мондый эшләрне бетерергә дә хатын янына китәргә кирәк булганга, туп-туры уза башлаган идем — берәү шап итеп жилкәмнән тотып алды.

— Чират, иптәш! — диде. Аның артыннан бер төркем тавыш күтәрелде:

— Чират та очередь!

Очередь та чират!

Беренче чират әнә шуннан башланды.

Күзнең-башның рәте-чираты юк, юынмыйча эшкә керерлек түгел. Авыздан да тозлы балык тәмнәре килә. Хатын янына әйбәтләнебрәк барырга кирәк бит. Юынырга киттем.

Умывальник янында — гомуми жыелыш кебек. Утыз-кырыклап яртылый ялангач кеше лачтыр-лочтыр юыналар. Кайсы битен сөртә, кайсы көтеп тора. Миңа тизрәк эшне бетерергә дә хатын янына барырга кирәк. Ашыга-ашыга төрткәләп, кран янына килә башлаган идем, берәү билемнән кочаклады да алды:

— Чират!

Тезелдем.

Житмәсә, бүген бүлмәбездәге кешеләргә күмәч өләшергә минем чират икән. Йөгерә-йөгерә кухняга килдем. Кухняда полный ярминкә. Кайсы күмәч турый, кайсы күмәч сорый, кайсы үлчи, кайсы кисәк-кисәк эләктереп чыгып китә, кайсы чират тора, кайсы лач-лоч китереп ашый.

— Кая, безнең бүлмәгә тизрәк бирөп жибәрегез әле, иптәшләр, минем бик ашыгыч барасы жирем бар иде,— дидем. Әйтерсең, яңа тормыш хакында дискуссия ачтым. Барысы берьюлы кабынып киттеләр. Сүз алмаган берәү калмады.

— Очередь та чират!

— Чират та очередь!

— Минем дә барасым бар!

— Минем дә!..

— Каян килгән комиссар капчыгы!..

Тәртип бозып булмый — чиратка бастым.

Башыма баллы катык кебек тәмле бер уй килде. Күлмәк-ыштан кухарка алъяпкычы кебек булып керләнгән, юган күлмәкләр дә юк түгел, барышлый, мунчага кереп, кием алыштырырга да керле киемнәрне хатынга калдырып китәргә, юдыртып китертергә кирәк, дидем. Мунча ягына бара торган трамвайга утырырга чиратка бастым.

Сәгать унынчы ярты.

Мин мунчага барып житкәндә, төш ауган иде инде. Чират торып, вагон ишегеннән чыктым да кассага йөгердем. Касса янында, әйтерсең, аракы кибете! Әллә тагын биш йөзләп кеше, берсе өстенә берсе менешә-менешә, кассага үреләләр. Кайсының кулында ун тиен, кайсынықында бер тәңкә.

Йөрәгем сыкрана. Болай булса, бүген хатын янына барып та җитеп булмас ди башладым. Бик җебеп торсаң, гомереңә дә мунчага керә алмассың. Эткәләп, төрткәләп, ерып-ертып, алга табан сузылдым. Җан тирләрем чыгып, кассага барып җиттем дигәндә генә, берәү аркамнан борып тотып алды да иң артка чыгарып та бастырды. Битенә карадым: куркыныч. Сыер бите кебек серьезный күренә. Ул миңа куркыныч күзләре белән туп-туры карады да кырыгынчы кылдан чыккан калын тавыш белән:

— Очередь! — диде.

Тезелдем.

Билет кулга эләкте. «Өченче класс, ирләр өчен»нең ишеге алдына килдем. Тфү, тагын йөрәгемне борча талый башлады. Тас алырга чират.

Мин мунчадан чыкканда, урамнарда ут алынган иде инде. Тиз генә Гөлсем янына барып җитәргә тырышып, ашыга-ашыга алга барам. Башта тәмле-тәмле уйлар чиратка тезелгәннәр. Янәсе, хатынга бөтен күргәннәрне, атна буе алган белемнәрне сөйләп, иркәләнә-иркәләнә, кочагында утырам; төрле хәлләр турында яңа хәбәрләр сөйләшәбез; атна буенча күрешми торгач, кызлар янына барган кебек инде...

Шундый уйлар белән алга бөгелеп, кызу-кызу гына китеп барганда, күземә кооператив кибете чагылды. Чагылуы булды — исемә сабын килеп төште. Үткән күргәндә, Гөлсем сабын алып килергә кушкан иде. Акча да юк түгел. Кичә генә стипендия алдым. Юл уңаенда алып китәргә кирәк дидем дә кибеткә кердем. Кадалып кына китсен инде! Каян чыгып беткән бу халык! Шыгрым тулы. Күреп тә бетмәссең, чират торып та өлгермәссең. Тыгылып-тыкшынып, приказчик янына киттем. Ике адым да атлый алмаганмындыр, әллә кайсы берәүсе култык астымнан чеметеп тотып алды да ишек төбенә китереп тә куйды:

Йөзенә карамадым. Ватык радио шикелле тавыш колагымны ертып ишетелде:

— Очередь, гражданин...

Үзем түзәм, йөрәк түзми. Чират та чират. Мең бәла белән приказчик янына килеп, сабын яздырган идем, кассага тагын чират. Чыдап кына тор!

Чак йөрәгем тынды. Бөтен эшем бетте. Кырык бер чираттан котылдым. Инде хатын янына барып, иркәләнәсе генә калды. Общежитиеда уңайсызрак булыр инде булуын, ярар, анда-монда барып, берәр аулак урын туры китерербез әле. Укучы кызга өйләнсәң, шул инде.

Урамда күптән кич булган. Мин, чираттан-чиратка йөреп, соңга да калмадым микән, өйдә булса ярар иде дим. Йөрәгем елмая. Яшь шул әле ул — өзлексез ашкына.

Килеп җиттем. Бүлмәләр санап, алга барам.

— Беренче бүлмә, икенче бүлмә, өченче бүлмә, дүртенче бүлмә — менә шул бүлмәдә минем хатын тора. Әкрен генә шакыдым.

— Шык-шык, хатын, чык-чык!..

Берәү дә чыкмады. Тик нечкәртеп кенә кычкырган тавыш ишетелде:

— Мөмкин!..

Кердем. Стеналары чуп-чуар, таныш бүлмә. Бер кыз китап укып утыра. Бер кыз кроватьта йоклап ята. Ә минем хатын кечкенә өстәл янында бер егет белән әллә нинди алыш-биреш итеп маташа. Ул егет артына тагын унбишләп егет чиратка басканнар... Йөрәгем песи баласы кебек изелеп йоклады да китте. Иплән кенә унбишенче егет артына барып бастым.

Күбенә түзгәнне азына түзим инде, ни күрсәм дә күрермен, телне тешләп тора-тора, тагын бик күп вакыт уздырып, хатын янына барып җиттем. Хатыным күтәрелеп тә карамый. Кооператив чеге кебек кечкенә генә кәгазь суза миңа. Түзмәдем. Йөрәгем ярыла язды. Кычкырдым да җибәрдем:

— Җитәр инде, ул кәгазьне тотып, тагы чират торыр хәлем юк!..

Хатыным ялт итеп башын күтәрде, күзләремә карап, шундый матур итеп көлеп җибәрде — эредем дә төштем, бөтен күргәннәрем онытылды.

Ул мескен культкомиссиядә эшли икән дә активистларга театрга барырга контрамарка өләшә икән. Ә мин, юләр, хатын тирәсендә чибәр-чибәр егетләр тезелешеп торгач, әллә ниләр уйлый язганмын!

*1928*

# Ибраһим Гази

*Укучылар әдипне зур масштаблы «Онытылмас еллар» трилогиясе, «Гади кешеләр» романы һәм әдәбиятыбызның алтын фондына кереп калган күп санлы хикәяләре буенча яхшы беләләр. Укучылар игътибарына әдипнең моңа кадәр басылмаган берничә әсәрен тәкъдим итәбез.*

## БЕЗ КОМСОМОЛ ЧАКЛАРДА

Егерме тирәләрендәге бер кеше... Арыш басуыннан бара, тузанлы юлдан... Шәһәрчәрәк киенгән, ә үзе яланаяк. Кем икән ул? Кая бара икән? Ботинкаларын иңбашына аркылы салган. Ялан тәпиләре кайнар юл тузанына батып-батып китә.

Туктады да, бер башакны өзеп, уып, арыш бөртекләрен учыннан-учына сикертеп, авызына капты... Чәйнәп карады.

Агрономмы әллә? Юк, бу мин үзем, Кукмарада комсомол комитеты секретаре чагым, авыл ячейкаларының эшен тикшереп кайтырга дип, юлга чыктым. Яланаяк? Әйе. Ботинка белән ерак араны йөрү кыен, ә ялан тәпи уңай. Машинада тагын да уңайрак булыр иде, дисезме? 1926 елда районнарда машина юк әле. Ат кына. Бөтен волисполкомга бары ике генә ат, ул ике атта исполком председателе йөрсенме, партия секретаре йөрсенме, финанс башлыгымы, хатын-кызлар арасында эшләүче кыз йөрсенме?

Комсомол — яшь, комсомол — җиңел аяк. Ул ат дип аптырап тормый, җәяү чыга да китә... Иң ерак ячейка Кашкара авылында — егерме километр... Иң якыны — биш километр. Өлге авылында... Көз дип тормыйм, кыш дип тормыйм, җәяү чыгам да китәм. Җыям, сөйләшәм, эшкә канатландырам. Спектакльләр куешам, үзем дә берәр рольне уйныйм; урак өсте булса, субботник оештырам; кызылармеец семьяларының урагын урып бирәбез... Рабфакка яисә вузга керергә җыенучы комсомолларның әзерлеген тикшереп карыйм, арифметикадан, алгебрадан мәсьәләләр чишәргә булышам, агайларның зарларын тыңлыйм, сораулары булса, сорауларына җавап бирәм. Мин бөтенесен дә «беләм» (дөнья хәлләрен дә, ил хәлләрен дә): ни өчен авыл кооперативына ситсы товар әз кайта? — Мин җавап бирергә тиеш. Ни өчен авыл кибетендә кадак юк, керосин юк? — Мин моңа да җавап эзләргә тиеш. Мин бөтенесе өчен үземне җаваплы сизәм... Ни сәбәптән Англия белән безнең ара бозылыбрак тора, Чемберлен ник безне яратмый?.. Мин монысын да җавапсыз калдырмыйм. Кыскасы, нинди генә сорау бирелмәсен — барысына да җавап табам; нинди генә йомыш төшмәсен — барысын да эшлим, эшләргә үземне мәҗбүр саныйм, чөнки мин «югарыдан» килгән, чөнки мин комсомол секретаре, чөнки мин үземне авылда Совет власте итеп сизәм... һәм мин чынлап та Совет власте...

Көз җитте исә, без — комсомоллар — дәүләткә ашлык әзерли башлыйбыз. Ул заманда колхозлар әле юк. Икмәк крестьян кулында, кулак кулында. Кулак икмәкне Совет властеннан яшерә: җиргә күмә, я тагы ничек...

Бер тапкыр шулай бер кулакның яшергән игенен таба алмыйча йөрдек. «Юк ашлыгым»,— ди, бетте-китте, ә авыл комсомоллары әйтәләр: бар, яшергән... Чыгып барганда урыс капкасын катырак яптым бугай (ачу килде, ни гомер йөрибез!), япкан шәпкә капка башыннан арыш бөртекләре коелмасынмы!.. Кулак, мәлгунь, артык игенен урыс капка башына тутырган икән... Таптык бит!

Кукмараның үзендә киез итек фабрикасы. Андагы комсомоллар да минеке — цехларда йөрим, эшчеләрнең тулай торакларында булам, клубларында докладлар ясыйм... Цехка кергәч, йонга буялудан бер дә тартынмыйм, киресенчә, буялып чыгарга тырышам, эшчеләр «үзебезнең кеше» дип санасыннар. Тора торган баракларына барып, шашкада «тартышып» кайтам. Поселок комсомоллары белән хәрби уеннар оештырабыз. Түгәрәкләрдә яшьләргә сәяси белем укытам. Хәтеремдә: электр янмаган көннәрдә ай яктысында укып утыра торган идек.

Ни өчен әле гел мин дә мин? Нигә мин шул хәтле «мактанам»? Чөнки бөтен волость комсомол комитеты бер кешедән тора: җаваплы секретарь да ул, җавапсызы да ул, техник секретарь да... Сәяси агарту эше дә аның кулында, оештыру эше дә, взносны да комсомоллардан ул җыя, фабрикага да ул йөри, авылларга да ул, чаба... Көненә биш утырышта биш чыгыш ясый, биш җыелышта тагын биш чыгыш, өч җирдә доклад сөйли, ә иртәгәге көн өчен тагын өч доклад әзерләп куярга тиеш... Шуның өстенә ул әле газета-журнал да укый, ашарга да вакыт таба, хәтта йокларга да бераз вакыты кала.

...Каты яңгырдан соң, ялан аяклары белән пычрак изә-изә, кемдер Кукмарага килеп керде. Үлән өзеп аякларын сөртте, ботинкаларын киде... Бу — мин, атна буе авыл ячейкаларында йөргәннән соң, кайтып киләм. Кукмара урамнарыннан ялан тәпи йөрү секретарь кешегә килешеп бетми, ни әйтсәң дә, мин башлык кеше бит, мин — комсомол, Совет власте мин...

## СИНЕҢ ХАТЛАРЫҢ

Мин синнән еракта, еракта... Дошманны куып, дошманны җиңеп, чит-ят туфракларга аяк бастык без. Баш очымда — ят күк, ят йолдызлар. Ят чишмәләр суын эчәм мин; ят һава сулыйм; ят җырлар тыңлыйм...

Ә сез, туган-үскән җирләр, карт Иделнең күңелле дулкыннары, таныш күкнең җем-җем йолдызлары һәм син — йөрәгемнең өзелеп калган яртысы — сез хәзер миннән еракта, еракта...

Сез еракта, ләкин минем күңелем һәрвакыт сезнең белән. Мин сезне бервакытта да телемнән төшермим. Мин сезне сагынам, юксынам. Мин сезне җырларымда җырлыйм.

Төнлә төшләремдә күрәм,
Көндез әллә кайда сез,—

дип җырлыйм мин.

Кайвакыт тынгысыз хыялым мине яңадан сезнең янга алып кайтып китә. Кайчандыр үткән тузанлы юллардан гүя тагын үтәм мин; кайчандыр эчкән салкын чишмәдән гүя тагын эчәм мин; кайчандыр кулларымны кыскан җылы кулларны гүя тагын кысам мин; кайчандыр үпкән кайнар иреннәрне гүя тагын үбәм мин.

Эх, хыял, татлы хыял... Син мине алдыйсың ич: алар миннән еракта, еракта...

Ләкин ерактан миңа күңелле хатлар килә. Мин аларны зарыгып көтеп алам. Әгәр яңалары озак килми торса, мин синең иске хатларыңны кесәмнән чыгарам да, окоп стенасына сыенып, йөз дә беренче кат аларны укый башлыйм.

Син миңа матур хатлар язгансың. Ул хатларыңда мин синең күз карашларыңны күрәм; синең ягымлы тавышыңны ишетәм; синең елмаюыңның җылысын тоям.

Бу авыр сыналу елларында кайбер хатын-кыз үзенең күңел сафлыгын саклап кала алмады: ирен, баласын онытып, биргән вәгъдәләрен онытып, үзенең йөрәк җылысын җиде ятка бүләк итте. Син алай булмадың. Шуның өчен мин синең саф кулларыңны, саф күзләреңне, саф иреннәреңне үбәм.

Хатларыңны ешрак яз, бәгърем. Синең хатларыңны укыгач, бөтен кайгыларым тарала минем. Синең хатларың минем күңел азыгым бит. Алар минем дусларым, сердәшләрем бит.

Өстемә салкын яңгыр коеп торсын; җылан кебек сызгырып, колак төбемнән әче җил иссен; баш очымнан чинап, миналар очсын — бөтенесе берни түгел, тик син бәгъремнән хатлар гына килсен дә синең йөрәк җылың салкын окопта мине җылытып торсын.

Көрәшү көннәре ерак түгел инде. Туган-үскән илгә кайтып, синең саф кулларыңны, туган җиреңнең изге туфрагын үбәр минутлар якынаялар.

1944. Польша.

# СИНЕҢ БАТИСТ ЯУЛЫГЫҢ

Әллә кемнән көнләшеп, син минем кулъяулыгымны алып калдың. Алдың һәм аның урынына үз кулың белән каеган кечкенә генә батист яулык бирдең.

Поезд мине еракларга алып китте. Син, мине озатып, еракларда калдың.

Шул вакыттан бирле, батист яулыгыңны кулыма алган саен, синең күзләрең, синең кулларың, әйткән сүзләрең исемә төшә дә, күңелемне, ялкын шикелле, газап чолгап ала. «Бу яулыкны ул тоткан иде»,— дип уйлыйм мин. «Бу яулыкка аның күз нурлары сеңеп калган» — дим һәм, күзләремне яулыктан аерып ала алмыйча, бик озак карап торам.

Үлчәсәң, Җидегән йолдызга җитәрлек озын юллар үттем инде мин. Аларның тузаны минем битем аркылы кечкенә яулыкка күчте. Яулык караллы, ләкин мин аны һаман юмадым. «Аның бармаклары тоткан бит моны» — дип уйладым мин. «Кайчандыр мин берәм-берәм үбеп чыккан, мине иркәләгән һәм мин яраткан бармаклар тоткан бит аны»,— дип уйладым.

Сердәшем дә, уйдашым да шул яулык минем. Көзге тын кичләрдә, шаулап коела торган яфрак астына утырып, кулларыма алам да мин аны, саташкан кеше кебек, аңа үземнең серләремне түгә башлыйм. Мин әйтәм: «Яулыгым, җансыз батист кисәгем, син бәхетле: син ялгызлыктан газап чикмисең, сагыну әчесен белмисең, бераү өчен дә саргаймыйсың... Сине каеган кадерле бармакларны тагын үбәр көннәрем булыр микән!»

9.X.44. Польша.

# УЛЫМ

Улымны сагынам. Үзем яшьтән үксез калып, бер сынык икмәккә табынып үскәнгәме, бичараның үксез калуыннан куркам.

Күзләрем туйганчы күрә дә алмадым үзен. Башта — ул читтә, аннары — үзем, аннары — бу сугыш... Ул мине онытты. Ул хәзер мине юксынмый да торгандыр инде: әллә әтисе бар, әллә юк аңа...

Соңгы кайтуымда ул, миннән бигрәк, мин биргән икмәккә шатланды. Ул мине оныткан, ә икмәкне ул ничек онытсын! Икмәк аңа туйганчы эләкми булса кирәк. Нәзек бармаклары белән икмәк кисәген йомарлап алгач, аның ябык йөзендә елмаю кебек бер нәрсә күренде: ул инде яхшылап елмая да белми иде ахры...

1944. Польша.



**Р. С. Мөбарәкҗанов,**
КПССның Чирмешән райкомы беренче секретаре

# ЧИРМЕШӘН БУЙЛАРЫ ЯМЬЛЕ

Төбәгебезнең кай тарафындагы матурлыгына гына игътибар итсәк тә, сүз кешеләребезнең фидакарь хезмәтенә, тырышлыгына, белем һәм теләкләренә барып тоташыр иде. Дөрес, чал тарих җирлегеннән торып караганда, безнең хөр тормышка ирешүебезгә әле күп вакыт үтмәгән. Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгән данлы көннәргә быел нибары 70 ел тулып килә. Мәгълүм булганча, шуңа кадәр хезмәт ияләре, төп хокуклардан мәхрүм ителеп, күп төрле кыерсытылуларга дучар кылына.

Безнең яклар тарихына патшаның 1732 елгы указы аерым бер тәэсир ясый. Бу указ нигезендә Мәскәү дәүләтенең чикләрендә Кама аръягы дип аталган махсус ныгытма булдырыла. «Ныгытма» патша власте өчен җан аямаучы ышанычлы кешеләрне берләштергән авыллардан һәм Чирмешән, Чишмә крепостьларыннан төзелә. Безнең районда авылларның күбесе шул вакыйга аркасында җыелган кешеләр тарафыннан салынган. Ул кешеләрнең кайбере власть кушуы буенча, башкалары буш җир барлыгын ишетеп, ачлыктан-хәерчелектән качып килеп урнашкан.

Бу хәлләрдән соң Бөек Октябрь революциясенә кадәр ике гасырга якын гомер узган. Патша власте үзенең таянычы булырдай «ныгытма» халкына нинди рәхәт күрсәткән соң? Статистик мәгълүматларга мөрәҗәгать итсәң, гаҗәпкә каласың. 1917 елга кадәр әлеге төбәк халкы тәмам хәерчелеккә бата. Ирләргә бирелгән 1,9 дисәтинә җирдән алынган уңыш ясак түләүдән дә артмый. Крестьяннарның 16 процентлабы исә әле ул җирдән дә мәхрүм ителә. 36 проценты атлары булмаудан интегә. Андыйлар өлешләренә тигән җирләреннән дә баш тартырга мәҗбүр булып, читкә «бәхет эзләргә» — Баку якларына, Себергә үк китеп бара.

Ниһаять, телеграф тасмалары Петроградта социалистик революциянең җиңүе турындагы хәбәрне китереп җиткерә. Революция куйган бурычлар, якты максатлар халык күңеленә ифрат та хуш килә. Совет власте авыл кешесенең хыялында гасырлар буе яшәп килгән теләкне тормышка ашыра: җир, аны кем эшкәртсә, шуңа бирелә. 17 ноябрьдә ике урында крестьян депутатларының Советлары оештырыла. Аның составына үз күкрәк көче белән көн итүче кешеләр кертелә. Советларны оештыруда 1905—1906 елларда Владивосток солдат һәм матросларының восстаниеләрен җитәкләүчеләрнең берсе, политик каторжан Михаил Михайлович Титов зур активлык күрсәтә. Аңа революцион эшчәнлеге шулай ук 1905 елгы вакыйгалардан башланып киткән Демид Иванович Кочкин булыша.

Юк, крестьяннар аңындагы революция шома гына бармый. Безнең төбәкнең ул вакыттагы үзәге — Самарада уздырылган крестьяннарның губерна съезды Совет властен инкарь итә, властьны Учредительный собраниегә бирергә кирәк дип чыга. Шулай итеп, оештырылуларына бер ай тулыр-тулмас, Советлар кире таратыла. Бу хәл большевикларда һәм алар яклы активистларда көрәш рухын яңартып җибәрә. Совет властена кул күшырып утырып кына ирешеп булмаячагы аңлашыла. 1918 елның беренче көннәреннән үк көрәш уты кабынып та китә.

Бу вакытка авылларга күп кенә кешеләр фронттан өйләренә кайталар. Солдат-матрос хезмәтендә булучыларның күбесендә революцион көрәш дәрте кайный. Арадан берәү — Андрей Федорович Малешин Самарада В. В. Куйбышев белән дә очрашкан, аңардан файдалы киңәшләр ишеткән, Җир турындагы декретны өйрәнгән икән. Өстәвенә, аның кешеләрне оештыру, җитәкләү һәм рухландыру сәләте дә көчле була.

Чирмешәндә Совет власте урнаштыру өчен барган көрәшнең яңа дулкыны шактый көчле шаулый. 1918 елның 27 январенда Советларның яңа комитеты оештырыла. Башкарма комитет председателе итеп элекке солдат П. Г. Титов сайлана. Комитет тегермәннәрне, трактирларны, күн заводларын национализацияли, спекулянтларга каршы кискен сугыш ача. Җирне крестьяннарга гадел иттереп бүлеп бирә. Бу эшләрнең нинди зур каршылыклар аша башкарылуын күз алдына китерү кыен түгел. Көрәш биниһая кискен һәм кан коюлы була. 1918 елның җәендә, төбәкнең бер өлеше фетнәче чех корпусы кулына күчеп, губернада кабаттан Учредительный собрание комитеты хуҗа булып алгач, иске тәртипләр тергезелә башлый. Актив көрәшчеләрдән М. Д. Шиповалов атып үтерелә, А. С. Малешин кулга алына. Җирне байлар тартып ала.

Бу гыйбрәтле хәлләр крестьяннарның көрәш дәртен дөрләтеп җибәрә. Совет власте яклы ир-егетләр, авылларын ташлап, урманнарга китәләр, партизан отрядларына кушылалар.

Шушы елның октябрендә, Совет власте кабаттан урнаштырылгач, Чирмешәндә партиянең башлангыч оешмаларын булдыру алга сөрелә башлый. 1919 елның февралендә ленинчыл партия членнарына беренче билетлар тапшырыла. Беренчеләр арасында П. Г. Титов, М. М. Титов, В. Г. Дуглав, Д. Г. Тумбинский кебек элекке солдат һәм матрослар, агалы-энеле Фроловлар кебек гади крестьяннар, И. Е. Соловьев кебек эшчеләр сыйныфы вәкиле саналырдай тимерчеләр һәм И. Сенотов кебек укытучылар да була. Ленин партиясенә чын күңелдән бирелгән бу кешеләр авылларда зур политик эш алып баралар. Кулаклар тарафыннан оештырылган фетнәләрне, Колчак бандаларының һөҗүмен, 1921 елгы ачлык китергән фаҗигаларны җиңгәндә, алар хезмәтенең күркәм нәтиҗәсе аеруча нык сизелә. Беренче большевикларның күбесе колчакчыларның канлы кулыннан һәлак була.

Чирмешән районы үзәгендә кечкенә генә тын бакча бар. Бакча уртасына, Ватан, социализм, тынычлык өчен җаннарын аямаган батырлар истәлегенә багышлап, һәйкәл куелган. Бөек Ватан сугышына гына да бездән егерме меңләп егет-кыз китә, шулардан тугыз мең каһарман Ватан иминлеге хакына яу кырында һәлак булган. Районыбызның биш егетенә Советлар Союзы Герое исеме бирелгән: П. А. Цаплин, Б. Г. Габдрахманов, И. Н. Конев, П. С. Курасанов, С. А. Ларионов. Хөкүмәтебез орден-медальләренә лаек якташларыбыз меңнәрчә. Кыскасы, яшь буынга үрнәк булырдай кешеләребез, тәрбия максатында мисал итеп күрсәтердәй эшләребез күп.

Чирмешән районы 1929 елны оештырыла. Хәзер бездә унтугыз колхоз, ике совхоз исәпләнә. Районыбыз элек-электән авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче төбәктән саналып килде. Соңгы елларда районда нефть ятмалары ачылды, һәм без илгә шактый күләмдә сыек ягулык та бирә башладык.

Асфальтланган юллар, тоташтан электрлаштыру, газ уздыру, радио-телевидение керту, хезмәтне механикалаштыру — болар барысы да районыбызның йөзен танымаслык үзгәртте. Безнең авыл кешесенең хәзер нинди икәненә игътибар итегез! Кагыйдә буларак, аның, кимендә, урта белеме бар. Гади гаилә елына уртача өч мең сумнан артыграк хезмәт хакы ала. Үз хуҗалыгындагы мал-туары, яшелчәсе-бәрәңгесе тагын мең-мең ярым сумлап керем бирә. Шуларга колхозчыларга җәмәгать фондларыннан бара торган файданы да өстәргә кирәк. Бу хәлләр — бер безнең район өчен генә түгел, ил күләмендә табигый күренеш.

Бер карасаң, хәйран калырлык. Шул гаҗәеп яңалыклар хәзер безнең өчен гадәти хәлгә әйләнеп калды. Минемчә, үткәнне алай тиз онытырга ярамый. Үз төбәгебез мисалында элекке чорга тагын бер мөраҗәгать итик әле! 1914 елда, мәсәлән, хөкүмәт безнең губерна кешеләренең мәгърифәтен арттыруга җан башына елына — 7 тиен, социаль тәэминат хаҗәтләренә 2/3 тиен акча тоткан. Хәзер уку-укытуга җан башына елга — 118 сум, социаль тәэминат буенча 190 сум бүленә.

Без бүген хәлебезнең ныклыгы турында гына түгел, чорга лаек совет кешеләре тәрбияләвебез белән дә горурлана алабыз. Безнең яшәү рәвешебез, омтылыш һәм хыялларыбыз, теләк һәм максатларыбыз яңача. Күптән түгел без район яшьләренә сораулыклар тараткан идек. Җавап бирүчеләрнең 94 проценты, тормыш ямен хезмәт-

тәге уңышларымнан табам дип язган; 80 процентлабы үзен гомум коллектив хезмәтенең нәтиҗәсе өчен җаваплы саный; 70 проценты җәмгыять тормышына актив катнашырга теләвен әйтә. Яңа кеше өчен көрәш туктаусыз дәвам итә, чөнки, яшерен түгел, әлегә ямьсез күренешләр дә очрап куйгалый. Тик тормыш-көнкүрешебез социаль гаделлеккә, коллективизм һәм иптәшләрчә ярдәмләшүгә нигезләнгән икән, яман хәлләрдән арынырга мөмкин булыр дип ышанабыз.

Колхоз-совхоз кешеләре, аерым хуҗалыклар чорына караганда, бөртеклеләрне — 12, итне — 5, сөтне — 3,5 мәртәбә күбрәк җитештерә. Эшләүче һәр колхозчы хәзер берүзе 60 кешене — икмәк, 10 кешене — ит, 25 кешене шикәр белән тәэмин итәрлек күрсәткечләр бирә. Соңгы бишьеллыкларда район сөт, ит җитештерүне гел арттыра бара. Бөртекләләр мәсьәләсе генә төрле тибрәлүләр кичерә. Уңыш түбәнгә тәгәрәсә, барыбыз да табигать шартларына ышыкланырга өйрәнеп киләбез. Алай гына җаваплылыктан котылу килешми. Җирне өйрәнергә, бу эшне фәнгә нигезләргә кирәк. Бу юлдагы тырышлыкларыбызның беренче нәтиҗәләрен күрә дә башладык инде. Бигрәк тә хәзер, партия бездән хуҗалыкның һәр тармагында фәнгә таянуны, тизләнешне таләп иткәндә, кырчылыктагы кимчелекләребездән кыска арада котылырга тиешбез. Шикәр чөгендере игүне индустриаль алымга күчерү тоткан юнәлешебезнең дәреслеген раслады. Кул хезмәте кимеде, уңыш артты.

Эшне җиңеләйтү белән бергә колхозчыларның көнкүрешен яхшырту, аларга медицина, культура хезмәте күрсәтүне юлга салу да ныклы планга кертелде. Күп хуҗалыкларда профилакторийлар ачылды. Хәзер көн тәртибенә яшь гаиләләрне өйләр белән тәэмин итү ихтыяҗы килеп басты. Бу мәсьәлә буенча да эшлекле чаралар күрәбез.

Партия оешмалары да, хуҗалык җитәкчеләре дә алга куелган бурычларны хәл итү өчен иң отышлы ысулларны эзлиләр. Сынатырга һич хакыбыз юк. Безнең район моңарчы сер бирмәде. Исмәгыйль Әхмәдуллин, Гөлсем Минһаҗева, Габбас Гыйматдинов кебек Социалистик Хезмәт Геройларын үстергән район бу! Укымышлылыгы, сәнгатькә-гүзәллеккә омтылышы белән дә элек-электән дан тоткан. Шагыйрь һәм галим Габдрәхим Утыз-Имәни төбәге бу!

Чирмешән районы Искәндәр Биктаһиров, Миңхәмәт Гыйлаҗев кебек җырчыларны, Наил Шәйхетдинов, Рәис Вәлиев, Рәйсә Мөхәммәтшина кебек артистларны, Камил Биктаһиров, Сәгыйт Хәйруллин, Сәгыйт Хафизов кебек галимнәрне үстерде. Безнең районда драматург Шамил Шаһгали яшәде һәм иҗат итте.

Киләчәк тагын да матур, кешеләребез тагын да күренеклерәк булсын өчен, район яңадан-яңа мөмкинлекләр ача, иҗади хезмәттән ләззәт алып яши.

Дамир Шәрәфетдинов

# ЯҢА ГАДӘТЛӘР, ЯҢА ЙОЛАЛАР

Сөн елгасы ике ут күршене аерып тора. Актаныш районының Шәймәрдәнов исемендәге колхозы белән Илеш районының «Сигнал» колхозы арасындагы чик шушы елга буйлап уза. Ләкин Сөн суы аларны аермый, киресенчә, берләштерә, тимер-бетон күперләр белән генә түгел, күзгә күренмәс, әмма өзелмәс ныклы җепләр белән тоташтыра. Экономик яктан көчле ике хуҗалык дистәләрчә еллар буе үзара ярышып, бер-берсенә ярдәмләшеп яши. Инде күптән гадәткә кергән «Бердәм гаиләдә» дигән уртак бәйрәм үткәрү дә — әнә шул тирән дуслыкның чагылышы.

Бу бәйрәмгә бик күпкә алдан хәзерләнә башлыйлар. Юллар, күперләр төзекләндерелә, ихаталар чистартыла, урамнарга авыл һәм район эшчәннәренең уңышлары, алдагы бурычлары турында сөйләүче плакатлар, рәсемнәр элена. Сөн буендагы аланлыкта зур сәхнә ясап куела.

...Кояшлы җәйге иртә. Елганың һәр ике як ярыннан йөзләрчә кешеләр бәйрәмгә ашыга. Юлларда автобуслар, машиналар, атлы экипажлар. Күп тә үтми, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар килеп төшә. Алар үзләре генә дә өч йөздән артык. Колхоз эшчәннәре кадерле кунакларны чәчәк бәйләмнәре һәм татар халкының милли ашы чәк-чәк белән каршы ала. Өстәлләргә Сөн буе урман-болыннарының хуш исен, кояш нурын җыйган гәрәбәдәй бал куела. Һәркайда җанлы әңгәмә башлана. Һәр ике колхоз җитәкчеләре, сыер савучылар һәм механизаторлар, бригадирлар һәм укытучылар үз хуҗалыкларының казанышлары, хезмәт уңышлары турында, бу дуслыкның эштә көч бирүе, ярышка дәрт өстәве турында рухланып сөйлиләр.

Шәймәрдәнов исемендәге һәм «Сигнал» колхозлары, Актаныш һәм Илеш культура йортлары һәвәскәрләре биш меңнән артык тамашачы карап чак бу концертка бай һәм кызыклы программа әзерлиләр. Сәхнәдә татар, башкорт, рус һәм илебезнең башка халыклары көйләре яңгырый, егетләр һәм кызлар дәртле бию тактына кушыла. Берләштерелгән хор башкаруында «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Туган ил» җырлары, көчле дулкын булып, аланлыкны күмеп китә.

Сөн буендагы һәр бәйрәм хуҗаларда да, кунаклар күңелендә дә җуелмас тәэсир калдыра. Тугандаш халык вәкилләренең мондый очрашуы милли культураларны үзара баетуда, хезмәт ияләрен социалистик интернационализм рухында тәрбияләүне көчәйтүдә зур әһәмияткә ия.

Хәзерге вакытта бөтен илебездәге кебек үк Татарстанда да традицияләр, йолалар, гадәтләр һәм бәйрәмнәрнең мәгълүм системасы барлыкка килде, алар иҗтимагый һәм шәхси тормышның төрле якларына кагыла.

Иҗтимагый-политик һәм дәүләт бәйрәмнәрен билгеләп үтү тормышыбызда мөһим социаль вакыйгага әйләнә. Җәмгыятебезнең коммунистик идеалларын, социализм тудырган мораль кыйммәтләрне гәүдәләндерүче Бөек Октябрь бәйрәме, 1 Май, 8 Март, Җиңү көне, СССР Конституциясе көне әнә шундыйлардан. Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты көне, В. И. Ленинның туган көне, профессиональ бәйрәмнәр, данлы юбилейлар бөтен халык бәйрәме төсендә билгеләп үтелә. Шулардан соңгы елларда аеруча популярлашкан берсенә тукталып үтәсе килә. Ул — Советлар Союзы Герое,

Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең туган көнендә үткәрелә торган көрәшче-антифашистларны искә алу бәйрәме. Ялкынлы шагыйрь һәйкәле янындагы митинг, Татарстан берләштерелгән дәүләт музеенда «Моабит дәфтәрләре»н алып чыгу церемониясе, Җәлил замандашларының, батыр якташыбыз исемендәге комсомол премиясе лауреатларының почетлы каравылда торуы — барысы да дулкынландыргыч тәэсир калдыра. Бәйрәмдә Советлар Союзы Геройлары, Хезмәт алдынгылары, укучы яшьләр, хәрби училище курсантлары, Казан гарнизоны сугышчылары катнаша. «Төп нөсхә көне» исеме белән гадәткә кергән бу тантана кичен тулай торакларга, культура сарайларына һәм клубларга күчә.

Батыр якташларны искә алу һәм хөрмәтләү фабрикаларда, колхоз-совхозларда да традициягә керә бара. Актаныш районының «Гигант» колхозында, мәсәлән, Бөек Ватан сугышында һәлак булган Советлар Союзы Герое Баян Дәүләтшинның туган көнен ел саен билгеләп үтәләр. Шушындый ук традиция Лениногорск районының «Шушма» һәм Калинин исемендәге колхозларында — Ватаныбызга биш батыр, шул исәптән Газинур Гафиятуллинны бүләк иткән колхозларда да яшәп килә.

Көнкүрешкә яңа йолалар керү — үтә катлаулы процесс. Ул эшнең практикасына гына түгел, теориясенә дә кагыла. Бирәдә сүз халыкның борынгы йолаларын һәм гадәтләрен тәнкыйть күзлегеннән карап бәяләү, алар арасыннан заманга яраклыларын яңарту турында бара. Кызганычка каршы, бу өлкәдә әлегә төгәл критерийлар эшләнмәгән. Бу үз чиратында борынгылык исе килгән һәр нәрсәне кире кагуга, я булмаса халык белән бернинди уртаклыгы булмаган формаларны куллана башлауга китерә.

Илебездәге башка халыкларныкы шикелле үк татар халкының да тамырлары белән бик тирәнгә киткән күркәм традицияләре, гадәтләре һәм йолалары күп. Алар яшьләрдә хезмәткә мәхәббәт, өлкәннәрне зурлау, гуманизм, дуслык һәм интернационализм, коллективизм, намуслылык, тугандаш халыкларга хөрмәт белән карау, Ватанны сакларга әзер булу, кыюлык һәм ихтыяр көче тәрбияләүгә булышлык итәләр.

Борынгы халык бәйрәмнәренең бүгенге социалистик чынбарлык белән органик кушылуын сөйләүче мисалларны тормышыбыздан күп китерергә мөмкин.

...Казан, Зеленодольск, Түбән Кама шәһәрләрендә, республикабызның байтак районнарында ел саен оештырыла торган чәчәк күргәзмәләрендә гаҗәеп матур, затлы гөлләрдән эшләнгән композицияләр, кешенең гүзәллеккә омтылуда иксез-чиксез фантазиясе булуын раслаучы чәчәк натюрмортлары күрергә мөмкин. Мондый күргәзмәләр инде күптән халык бәйрәменә әйләнде, кешеләр аларга бик теләп йөри. Аларда һәвәскәр бакчачылар да актив катнаша. Зеленодольскида күргәзмә көннәрендә әңгәмәләр уздырыла, йортларда, бүлмәләрдә чәчәк үстерү, букетны зәвык белән ясау турында белгечләр киңәшләрен бирәләр.

«Түбән Каманы югары культуралы шәһәр итик!» — нефтехимиклар каласында чәчәк бәйрәме гадәттә әнә шундый девиз белән үтә. Бирәдә бакчачылар тәҗрибә уртаклашалар, ул чын мәгънәсендә киңәш-табыш итү, үзара аралашу мәктәбенә әверелә.

Лениногорскилыларның да үзләренә генә хас төсмерләре бар. Нефтьчеләр шәһәрендә ул «Чәчәк балы» буларак уза, викториналар, уеннар оештырыла, чәчәкләр турындагы җырлар башкарыла. Сүз дә юк, мондый бәйрәмнәр — яшьләрдә табигатькә мәхәббәт хисе тәрбияләүдә үтемле чара.

Чәчәк бәйрәме — татар халкының ел фасылларына туры китереп үткәрелә торган борынгы йолаларына барып тоташа. Элекке заманнарда ул шомырт чәчәк аткан чакта, май урталарында уздырыла торган булган. Егет-кызлар, яшь җилкенчәкләр, урманга җыелып, төрле уеннар, күмәк биюләр оештырганнар. Бу борынгы йола хәзер яңа формаларда, яңа эчтәлек белән баеп, яңадан туа. Киләчәктә ул тагын да киңрәк таралыр дип өмет итәргә була.

Кышны озату бәйрәме дә традициягә кереп бара. Аның шулай ук гасырлар тирәнлегеннән килүче тамырлары бар. Төрки халыкларда ул иске календарь белән 22—23 мартта, яңа елны каршылау йоласы — нәүрүз буларак билгеләп үтелә торган булган. Аның үзенә генә хас катлаулы йолалары да билгеле. Гадәттә авыл халкы шыттырылган арпадан нәүрүз боткасы — кужа пешергән, төннең кыл уртасында — тәхвил вакытында урамнарга чыгып, бер-берсен котлаган. Икенче көнне иртән шәкертләр, җыр-бәетләр әйтеп, өйдән-өйгә йөргәннәр, халыкны котлаганнар. Авыл җыенында ел дәвамында булган эшләр турында хисап тотканнар. Шул ук вакытта ел фасылларына багышланган күмәк уеннар, алдагы елда ярәшелергә тиешле егетләр өчен кыз

багу (нәүрүзбәк) уздырылган. Бу бәйрәмнең атамасы тәрки-татар фамилияләрендә сакланып калган. Әзербәйҗанда нәүрүз ритуаллары хәзерге чорда да «бахор бәйрәме», ягъни яз бәйрәме үткәргәндә киң кулланыш таба.

Кышны озату һәм язны каршы алу Казан, Брежнев, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендә, район үзәкләрендә һәм авылларда чын мәгънәсендә бөтен халык бәйрәме төсен ала. Күргәзмәләр һәм концертлар, спорт уеннары һәм шаян ярышлар, әкият персонажларының чыгышы — болар барысы да Казанның М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркындагы бәйрәмнең аерылгысыз атрибутлары. Җыелган халык яшь фигурачылар чыгышын, юртаклар узышын яратып карый. Һәркайда җыр, уен-көлке.

* * *

Соңгы елларда Татарстан авылларында борынгы һәм мавыктыргыч бәйрәм — каз өмәләренең яңадан тууы күзәтелә. Өлкән һәм урта буын кешеләречең күңелендә онытылмас хатирәләр булып саклана торган бу йола хәзер бөтен матурлыгы һәм кабатланмас төсмерләре белән яңа эчтәлек ала.

Көзге эшләр инде тәмамланган, басу-кырлар бушап калган чак. Җәйге муллык инде амбарларда. Авыл кышка хәзерләнә. Нәкъ менә шундый чакларда каз өмәләре башлана. Яшь кызлар, яшь киленнәр, бизәкле көянтәләренә каз түшкәләре асып, елга, инеш, чишмә буена төшеп китәләр. Кызларның өлгерлеге, житезлеге менә шунда сынала да инде. Ә яшьләр булган җирдә уен-көлкесез, җырсыз-биюсез, шаян сүзсез буламыни?! Өмәдән соң тагын хуҗабикә өендә кич утыру. Кичке тынлыкка чумган урамнар өстенә гармун моңы түгелә, шат авазлар яңгырый.

Өмәгә әзерлек күп алдан башлана. Алдан ук туган-тумача, дус-ишләргә, күршеләргә хәбәр җиткерелә. Каз маенда кайнар коймак пешә, ә кичкә инде зур каз бәлеше дә өлгереп җитә. Кызлар булган җирдән егетләр дә читтә йөрми. Кем белә, бәлки нәкъ менә шушы өмәдә яшьләр бер-берсен сыңыйдыр, кемнәрнеңдер чәчләре-чәчкә бәйләнәдер...

Иң мөһиме, бу бәйрәмнәрдә дуслык һәм үзара ярдәмләшүнең тирән мәгънәсе, асылы ачыла. Халкыбызның гасырлар түреннән килгән канатлы сүзләрендә дә бу ачык чагыла. «Бердә түгел, илдә көч», «Киңәшле эш таркалмас», «Әртилнең өйрәсе куе», «Кумәк күтәрсә, күлне күчерер» һәм башкалар нәкъ шул кумәклек кадере турында сөйлиләр.

Өй өмәсе, күмәкләшеп бура күтәрү, өй юу, тула өмәсе кебек күркәм гадәтләрдә дә халыкның дуслыкка, үзара ярдәмләшүгә омтылышы гәүдәләнгән. Хәзерге вакытта хезмәттәшләренең, колхоз идарәсенең эчкерсез ярдәме белән меңнәрчә яшь игенче, терлекче, механизатор гаиләләре яңа йортларга күченә. Республикабыз авылларында хуҗалык көче белән төзелгән йортлардан яшьләр урамнары үсеп чыкты. Аларга нәкъ менә шулай «Яшьләр урамы» дип исем кушалар да. Борынгыдан килгән гадәт буенча өй туйлары үткәрү дә, шулай итеп, яңа, социалистик эчтәлек белән баеый. Бу бәйрәмнәр, табигый ки, халыкчан, оптимистик характерда була.

Халкыбызның иң яраткан, иң борынгы бәйрәмнәреннән берсе, әлбәттә, Яңа елны каршы алу. Башка бик күп халыклар шикелле үк безнең борынгы бабаларыбыз да кышкы кояш торгынлыгын белгелеп үтә торган булганнар. 25 декабрьдән кыш чилләсе — иң суык кырык көн башлана. Аларның баштагы уникесе нардуган бәйрәме дип атала. Бу чорда яңа елның ничек булачагын багу да, төрле маскарадлар да уздырыла. Аерым төбәкләрдә нардуган егерменче йөз башына кадәр сакланып килгән. Аның аерым элементлары, әйтик, багу, кияү яки кәләш сайлау кебекләре хәзер дә үзешчән сәнгать коллективлары репертуарында файдаланылып килә.

Яңа ел алдыннан бизәлгән чыршы урнаштыруның тамырлары бик еракка барып тоташа. Иң зәһәр суыкларда да яшеллеген саклап калган агач борынгы заманнарда кешеләргә сихри, тылсымлы һәм гайре табигый булып тоелган. Рухларның мәрхәмәтен казану өчен, кешеләр ул агачларга төрле бизәкләр, бүләкләр элгәннәр, чыршы янында ритуал биюләр биегәннәр. Соңрак христиан чиркәве бу гадәтне дин белән бәйле йолага әйләндерә.

Яңа ел чыршысы, үзенең традицион элементларын саклаган хәлдә, безнең социа-

листик көнкүрешебезгә бөтенләй башка эчтәлек белән килеп керде. Ул иң тантаналы һәм күңелле, киләчәккә өмет һәм ышаныч белән тулы бәйрәмнәрнең берсе. Бу көнне ел дәвамында башкарылган эшкә йомгак ясала, киләсе елга яңа үрләр билгеләнә. Шәһәрләрдә һәм авылларда бәйрәмне әзерләү һәм үткәрү өчен махсус комиссияләр төзелә, алар яшьләр карнавалын, балалар кичәләрен, төрле конкурслар, күмәк уеннарны оештыручы буларак чыгыш ясыйлар. Аңлашыла ки, бу чараларда төп йөк культура-агарту хезмәткәрләренә төшә.

Чыршы бәйрәмен үткәрүнең яңа формаларын эзләү күпчелек хезмәт коллективларында, авылларда бу йоланың бик күп яңа төсмерләрен булдырырга ярдәм итте. Моннан берничә ел элек кенә, мәсәлән, Мамадыш районында чыршы бәйрәме гадәттә тар даирәдә — гаиләдә, иң киң дигәндә дә авыл клубында гына үткәрелә иде. Социалистик традицияләр һәм йолаларны пропагандалау комиссиясе бәйрәмне урамнарга, мәйданнарга чыгарырга карар бирде. Шәһәрнең үзәк мәйданында мәһабәт чыршы урнаштырылды, аңа тоташучы урамнарда кар калалары, төрле җанвар сыннары, халык әкиятләре персонажлары куела башлады. Хезмәт коллективлары рапортлар һәм бүләкләр, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар кызыклы концерт номерлары әзерләделәр. Кыңгыраулы пар атлары да табылды. Бәйрәм сәүдәсе, кибет һәм ашханәләргә генә сыеша алмыйча, урамнарга ташып чыкты. Кышкы суыкта, авызыңны пешерә-пешерә, кайнар чәй эчү, табадан яңа гына төшкән пәрәмәч, коймак белән сыйлану бәйрәмгә өстәмә ямь һәм тәм өстәде.

Актаныш һәм Мөслим якларында да Яңа елны үзенчәлекле каршылыйлар. Актаныштa, мәсәлән, ул кышкы сабан туе төсен ала. Агыйдел өстендә, бозны чистартып, мәйдан ясала, тик аның уртасына традицион багана урынына бизәлгән чыршы утыртыла. Аның янында гына шугалак, берничә чиләк сыешлы самавырлар гөжләп утыра, казаннарда пилмән өлгерә, шашлык кыза.

Тантана иртәнге унда район җитәкчеләреннән берсенең чыгышы белән башланып китә. Чәчәкле тастымаллар, тасмалар белән бизәлгән атларга төялеп, колхоз һәм совхозлардан килгән Кыш бабай һәм Кар кызларының мәйданда очрашуы бәйрәмнең иң югары ноктасына әйләнә. Алар үз хуҗалыкларының хезмәт уңышлары турында рапорт тапшыралар. Аксакаллар һәр җигүле экипажга смотр үткәрә, җиңүчеләргә дипломнар, күчмә кубоклар тапшырыла.

Хезмәт коллективларында шулай ук еллык йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәгән алдынгы звенолар, бригадалар, сменалар, цехлар хөрмәтенә чыршы кабызу гадәте дә традициягә кереп килә.

* * *

Партия, совет һәм җәмәгать оешмалары тәҗрибәсе күрсәткәнчә, социалистик традицияләр һәм йолаларны тирәннән уйлап, тарихи һәм җирле үзенчәлекләрне искә алып үткәргәндә һәм пропагандалаганда, алар хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүнең үтемле чарасына әйләнәләр, аек, сәламәт көнкүреш урнаштыруга ярдәм итәләр. Эчкечелек һәм алкоголизмга каршы киң җәелдерелгән көрәш барышында заманга ярашлы прогрессив йолалар активлашты. Мәсәлән, Казанның С. Сәетгалиев исемендәге культура сараенда республикада беренче булып «Аеклык клубы» оештырылды. Клубка йөрүчеләр бәйрәмнәрне, туган көннәрне һәм башка истәлекле даталарны исерткеч эчемлекләрдән башка билгеләп үтәләр. Озакламый шундый ук клуб төзүчеләр культура сараенда, Казанның Ленин һәм Совет районнарында, Зеленодольскида, Тукай, Сарман һәм башка районнарда эшли башлады. Аек бәйрәмнәр ясауның үзенә генә хас төсмерләре, үзенчәлекләре бар. Әйтик, эчемлек сөреме белән исереп ясалма күңеллелек тудыру — бер нәрсә, ә аек күңеллелек — бөтенләй башка. Беренче очракта магнитофоннан шау-шулы, зәвыгы шикле ансамбльләрнең кычкырып торуы да җитсә, икенчесендә бәйрәмдә катнашучылар үзара аралашудан, аңлашудан, үткен сүздән, җыр һәм биюдән тәм тапсын, күңел ачсын өчен, никадәр фантазия, сәләт һәм тырышлык кирәк. Ләкин, ничек кенә булмасын, киләчәк әнә шуларда. Соңгы елларда никахлашуларның 90, бала тууның 70 процентын тантаналы шартларда үткәрүне оештыра алганбыз икән, бу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Тарихка күз салсак, эчкечелекнең халкыбыз өчен чит, ят күренеш булуын ачык күрәбез. Каяндыр читтән кергән бу зәхмәт белән араны никадәр тиз өзә алсак, киләчәге-

без дә шул кадәр якты һәм сәламәт булыр. Ә бу юнәлештә байтак эш башкарылды инде. Шул уңайдан «Труд» газетасының 1985 ел, 13 июнь санында басылган «Аек бәйрәм сабантуй» дигән мәкаләгә игътибарны юнәлтәсе килә. Аның авторы журналист Н. Молчанов Балтач районында узган милли бәйрәм турында болай дип яза: «Соңгы вакытта кемнеңдер җиңел кулыннан шау-шулы эчке мәҗлесләрен сабантуй дип атау гадәткә кергән иде. Ихластыр, күмәк халык бәйрәмнәреннән иң аегына карата болай әйтү күңелне рәнҗетә. Райбашкарма председателе урынбасарыннан (ул бәйрәм комиссиясенә дә җитәкчелек итә) бәйрәмдә күпме исерткеч эчемлек сатылуын сораган идем.

— Бер шешә дә сатылмады,— диде ул.— Аның каравы лимонадны гадәттәгедән өч, квасны ике ярым тапкырга күбрәк саттык. Район чәйханәсе бер атналык нормасын диярлек үтәде — баллы, мәтрүшкәле, хуш исле чәйдән башка нинди сабан туе булсын ди ул?..»

Хәзер бәйрәм-йолаларны үткәрүдән ирешелгәннәр белән чикләнеп калмаска, тупланган тәҗрибәне киңрәк тарату турында кайгыртырга, аның һәркайда тормышка үтеп керүенә ирешергә кирәк. Аларны сәнгатьчә нәфис бизәү турында да уйланырга вакыт. Яңа йолаларны кертү белән бәйле кадрлар булдыру мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп басты. Бәлки, мондый белгечләрне уку йортларында махсус әзерләргә кирәктер. Чөнки хәзергә аның белән нигездә энтузиастлар гына шөгыльләнә, аларны күбесенә белем дә, тәҗрибә дә җитми.

Йолалар һәм бәйрәмнәр сәнгатьнең бик күп төрләре үзара бәйләнгән синтетик берлекне хасил итәләр. Аларда музыка, драма, хореография һәм сынлы сәнгатьнең төрләре һәр жанрлары яңа сыйфатта үзара бәгләнышка керә, бер-берсен тулыландыра, баета. Язучылар, режиссерлар, композиторлар, рәссамнар, балетмейстерларның иҗади фикере һәр бәйрәмне яки йоланы чын мәгънәсендә сәнгать әсәренә әйләндерә алыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, бу өлкәдә актив эшләүче әдәбият һәм сәнгать әһелләре бик аз.

Клубларны, культура йортларын, стадионнар һәм спорт мәйданчыкларын, сабантуй мәйданнарын декоратив һәм техник җиһазлау мәсьәләсен дә хәл итәсе бар. Һәр шәһәрдә, авылда яшел театрлар булса, начар булыр идемени?! Бер сүз белән әйткәндә, бу эштә проблемалар әле шактый. Аларны хәл итү социалистик йолаларның нәтиҗәлелеген күтәрергә, һәркайда аек бәйрәмнәр һәм гадәтләр булдырырга ярдәм итәр иде.

Совет традицияләре һәм йолалары — алар социалистик яшәү рәвешенең үзенчәлекле көзгесе. Ул чынбарлыкны төгәл һәм якты, тәэсирләндергеч һәм гүзәл итеп чагылдырырга тиеш. Менә шунлыктан традицияләр белән бәйле һәр нәрсә җентекләп уйланырга, такт, зәвык һәм чаманы югалтмау хисе белән сугарылырга хаклы.

*Журналда мәкалә чыккач...*

# «БЕЗГӘ НИЧЕК ХЕЗМӘТ КҮРСӘТӘЛӘР»

Журналның беренче санында шундый баш астында урнаштырылган мәкаләдә халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүдәге кайбер кимчелекләр тәнкыйтьләнгән иде. Аерым алганда, ул язмада квартиралар ремонтлаудагы тәртипсезлекләр, кием-салым тегү ательеларындагы башбаштаклыклар, «Автосервис» станциясендә машиналар төзәтүдәге һәм телевизорлар караудагы кимчелекләр, патронаж сестраларының эшен яхшырту мәсьәләләре күтәрелде.

Мәкаләгә шул тармаклар өчен җаваплы министрлыклардан һәм ведомстволардан җаваплар алынды. Түбәндә шуларның кайберләрен урнаштырабыз.

## Татарстан АССР Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгы:

«Квартиралар ремонтлауны һәм бизәүне яхшырту, аларны заказчы теләгәнчә җиһазлау максатларында Казанда махсус эксперименталь ремонт-төзү идарәсе оештырылды. Островский урамындагы 104 нче йортта урнашкан бу идарә (телефоны 32-29-79) коллективы заказлар кабул итә башлады. Хәзерге вакытта керамик плиткалар һәм төзү материаллары белән тәэмин итү җайга салынды.

Өйләрне җыештыру өчен махсус оешма бар. Заказлар Кави Нәҗми урамындагы «Гаиләгә хезмәт күрсәтү бюросы»нда кабул ителә. Телефоны 32-24-81.

Журналдагы мәкалә «Татшвейбыт» берләшмәсенең «Людмила» ательесында производство киңәшмәсендә тикшерелде, заказларны үтәү срогын кыскарту, тегелгән киемсалымның сыйфатын күтәрү чаралары билгеләнде.

Ватык телевизорларны төзәтергә илтү мәсьәләсен тулысынча чишү, транспорт җитмәү сәбәпле, хәзергә мөмкин түгел. «Таттелерадиобыттехника» берләшмәсе абонементка куелган һәм гарантия срогы чыкмаган телевизорларны гына үз машинасы белән килеп ала.»

Хатка халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министры урынбасары Н. П. Прохоров кул куйган.

## Татарстан АССР Сәламәтлек саклау министрлыгы:

«Ялгыз яшәүче авыруларга һәм инвалидларга медицина хезмәтен шул районлардагы поликлиникалардан тыш республика Кызыл Хач җәмгыятенең патронаж сестралары да күрсәтә. Хәзер Татарстанда 34, шул исәптән Казанда 14 шәфкать туташы эшли,— дип хәбәр итте редакциягә республика сәламәтлек саклау министры урынбасары Р. Г. Ямалеев.— 1987 елда Кызыл Хач җәмгыятендә штатлы патронаж сестраларының гомуми саны тагы 16 кешегә арттырылды. Бу авырулар һәм инвалидларга хезмәт күрсәтүне шактый яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Республика Кызыл Хач җәмгыяте бу игелекле эшнең формаларын һәм ысулларын камилләштерү буенча даими эш алып бара».

# ӨМЕТЛӘР АКЛАНСЫН!

***«Казан утлары» журналы каршында эшләп килүче яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенең чираттагы утырышында «Бүгенге әдәби тәнкыйтьтән без нәрсә көтәбез?» дигән сорау көн тәртибе итеп куелган иде. Әлеге проблема буенча кайнар әңгәмә барды. Түбәндә яшь тәнкыйтьчеләрнең кайбер фикерләре урнаштырыла.***

## Фәрит Бәширов:

Тәнкыйтьче, беренче чиратта, әзерлекле булырга тиеш. Аның алдында зур, җитди бурыч — язучыны укучыга җиткерү бурычы тора. Язучы тормыш турында язса, тәнкыйтьче исә бер үк вакытта әдәбият һәм тормыш турында яза. Ә менә әсәрнең гадәти эчтәлеген генә сөйләп чыгу — һич гафу ителми. Теге яки бу язучы иҗаты турында сүз әйтергә алынгансың икән, син әдәби хәрәкәт, заман таләбе, үзебезнең һәм совет әдәби тәнкыйтенең дәрәҗәсе белән хәбәрдар булырга тиешсең. Югыйсә, укучыга инде күптән мәгълүм фактларны санап чыккан әһәмиятсез сүз боткасының авторы булып калуыңны көт тә тор. Тәнкыйть принципиаль, объектив булырга тиеш. Фәнни дә булырга тиеш! Аң булыйк, укучы аңламый торган терминнар белән куык очыручылар фәнни стильдә язалар икән дигән фикер тамырыннан ялгыш. Гадәттә мондый «фәннилек» мәгънә фәкыйрьлеген каплаучы чаршау хезмәтен генә үти.

Укучыга материалны бирү рәвеше — шулай ук җитди мәсьәлә. Мәкалә тәнкыйтьченең укучы белән җанлы сөйләшүе рәвешендә барса, монда беренчедән, тәнкыйтьче үзе ота — аның сүзенә һичшиксез игътибар итәчәкләр, икенчедән, язучының иҗаты белән кызыксыну арта һәм, өченчедән, тәнкыйть сүзенә дә ихтирам уяна. Акыллы, төпле сүзне укучы тыңлый да, хөрмәт тә итә белә. Тәнкыйтьченең хөрмәт ителүе аның үз кулында! Яшерен-батырын түгел, аерым әдипләр тәнкыйтьне икенчел дәрәҗәдәге хезмәт дип карыйлар. Монда тәнкыйтьче үзе дә гаепле! Чөнки юк кына әсәрне баллап-майлап мактап, купшы рецензияләр язучы һәм үзен кадерсезләп шуны бастыручы ул бит!

Хәзер бездә тәнкыйтькә каршы да тәнкыйть булырга тиеш! « Тәнкыйть мәкаләсе» исеме астындагы чүп-чарларга каршы көрәшү дә — принципиаль тәнкыйтьченең төп бурычы. Тәнкыйть — проза, поэзия, драматургия белән бер үк дәрәҗәдәге иҗат эше. Һәм аның дәрәҗәсе бу өлкәдә каләм тибрәтүчеләрнең ничек язуы, ни рәвешле фикер йөртүе белән бик нык бәйләнгән. Акны ак дип язу, кимчелекләрне кимчелек дип атау тәнкыйтьченең намус эше булса, уңышларның һәм уңышсызлыкларның сәбәбен ачу, үтемле дәлилләр белән фикереңне кире каккысыз итеп бирү — талант эше.

## Газинур Моратов:

Соңгы елларда әдәби тәнкыйть адресына усал сүзләр шактый күп әйтелде. Аның торышыннан бүген берәү дә риза түгел ахрысы. Шул исәптән тәнкыйтьчеләр үзләре дә... Гәрчә «берәү дә» дип әйтү бигүк дөрес тә булмас. Комплиментар тәнкыйть тарафыннан һәрдаим макталып, хупланып килгән язучы өчен моннан да шәбрәк «тәнкыйтьнең» булуы мөмкинме соң?! Хәтта ни өчен макталуын белмәгән тәкъдирдә дә... Андый язучының чын, ихлас тәнкыйть сүзен кабул итә алачагына да шикләнеп

карарга кирәк. Димәк, тәнкыйть әдәбиятның саулыгы өчен көрәшәсе урында, аны чиргә сабыштыра дигән сүз.

Тәнкыйтьтә әдәби әсәрләргә темасы һәм күтәрелгән проблемасының актуальлегенә карап кына бәя бирү очраклары ешайды. Сүзгә, җөмләгә игътибар бик нык кимеде. Тәнкыйтьнең әдәби әсәр теленә саңгыраулыгы үз чиратында әдәбиятка да тискәре йогынты ясамый калмады, билгеле. Без, үзебез дә абайламастан, стилистика кануннарына бөтенләй сыешмый торган калька җөмләләр белән язарга өйрәнеп киттек. Чиле-пешле тел белән язылган әсәр актуаль дә, тирән мәгънәле дә була алмый торгандыр. Әдәбият бит ул сүздән башлана. Әнә, Әмирхан ага Еники, бер җөмләне кәгазьгә төшерер өчен, әллә ничә вариантта язып карыйм, ди. Коеп куелган әсәрләр миңа ничек языла! Ә. Еники, Г. Бәширов, А. Гыйләҗев иҗатлары мине нигә сокландыра безне! Камил әсәрләрнең теле дә камил була. Кирпеч калынлыгы романга да, 2—3 битлек хикәягә дә таләп бер үк — һәр икесе дөрес әдәби җөмләләр белән язылырга тиеш. Шул исәптән тәнкыйть мәкаләләре үзләре дә!

## Радик Нуретдинов:

Әдәби тәнкыйтьнең сүрелүе турында соңгы вакытта күп сөйләнә икән, биредә хаклык юк түгелдер. Ул йокымсыраган арада, Такташ теле белән әйтсәк, әдәбиятка шабашниклар килә. Һәм алар тәнкыйтьне читләтеп үтү юлын да табалар.

Күптән түгел Рамазан Байтимеров үзенең яңа гына басылып чыккан китабын редакциягә китерде. Килгәч, журналистлар белән ипле генә танышып чыкты. Үзенең җыентыгына карата «Татарстан яшьләре» газетасында рецензия бастыруны үтенде. Билгеле, без шатланып риза булдык, тәнкыйтьчеләргә заказ бирү хәстәрлеген күрә башладык.

— Сез борчылмагыз, мин аны мин яздырдым инде,— диде автор шунда!

Сер түгел, әзер әйбер булу — редакция хәлен шактый «җиңеләйтә». Моны истә тотып, үзебезгә тәкъдим ителгән язманы укыйбыз. Мәкаләне укыган арада китап авторы автографын язып, җыентыгын да бүләк итеп өлгерде.

Язма Р. Байтимеровның әсәрләрен күккә чөеп мактауга корылган иде. Әлбәттә, бу хәл безне сагайтты.

Җыентыкка күз салабыз... Беренче әсәрендә үк җитди кимчелекләр барлыгы күзгә ташлана. Поэманың тәнкыйть утына эләккәнен күреп, автор бүләк иткән китабын да, язылган рецензиясен дә кире алды да: «Мин башка җирдә бастырып чыгарып, алдыгызга китереп салачакмын!» — дип «куркытып» чыгып китте...

Бу күңелсез мисал белән шуны әйтәсем килә: әдәбиятка ындыр артындагы сукмактан килү булырга тиеш түгел. Югыйсә әрсезләр берничә китап чыгарып алалар да: «Мине Язучылар союзына кабул итегез»,— дип, дәгъва белдерә башлыйлар.

## Рәшит Минһаҗев:

Василий Шукшинның җитмешенче еллар тормышы турында уйланып әйтелгән: «Эпоха великого наступления мещан. И в первых рядах этой страшной армии — женщины. Это грустно, но так»,— дигән сүзләре бар.

Бу фикер әдәби тәнкыйть фикеренең ни өчен сүрелүен дә аңлата төсле. Тәнкыйть йомшару, чыннан да, тормыштагы сәбәпләргә бәйле иде...

Әнә шул сәбәпләргә минем тагын түбәндәгене өстисем килә: университетның татар журналистикасы һәм татар әдәбияты бүлеген ел саен дистәләгән яшьләр бетерә. Ә үз белгечлекләре буенча аларның сирәге генә эшли. Теләсә нинди эшкә кереп булса да, Казанда калырга тырышалар. Эшне дә яратмыйлар, фатир да берничә дистә елсыз булмаячак.

Мин газеталарыбызга квалификацияле кадрлар җитмәгәнгә сыкрап яшим.

Югары белем алып та, анда-санда буталып йөрүче һәм әкренләп мещанга әйләнеп баручы егет-кызларыбыз тиз арада матбугат эшенә җигелсеннәр иде. Халык күңелен һәм үз-үзебезне дә тәрбияләү эше бит ул!

## Ркаил Зәйдуллин:

Зур әдәбиятның үзенә лаек тәнкыйте дә булырга тиеш. Пушкиннар чорында Белинскийлар булган...

Бездә дә игътибарга лаек әсәрләр дөньяга чыгып тора, югыйсә... Ә шулар турында белеп һәм йөрәк җылысын биреп язылган тәнкыйть мәкаләләре сирәк күренә.

Сирәк күренә... Әйе, аз булса да кызык кына мәкаләләр чыккалап тора. Әмма татар әдәби тәнкыйтен алар гына билгели алмый шул. Намуслы, олы йөрәкле тәнкыйтьне көтә безнең әдәбият.

Мәкаләләрдә сүз һаман бер үк кешеләр турында бара. Ләкин безнең әдәбиятта күзгә-башка күренмичә генә әйбәт әсәрләр язып ятучы кешеләр дә бар. Иҗатларына игътибар итмибез. Әдәбият мәйданы алай ук киң түгел. Анда һәркем үзенә лаек урынны алсын иде. Тәнкыйтьнең иң төп вазифасы, баксаң, шулдыр әле.

Шигырь тәнкыйте... Татар поэзиясенең бүгенге торышын белмәгән кешеләр шагыйрьләр турында зур мәкаләләр яза. Дөресрәге, бер мәкаләдән икенче мәкаләгә шул ук исемнәр, шул ук җөмләләр күченә. Бу турыда бигрәк тә хөрмәтле тәнкыйтьчебез Т. Галиуллин уйлансын иде. Егерме-утыз ел элеккеге бизмән белән бүгенге шигырьне үлчәп булмый. Яңа заман — яңа җырлар...

Миңа тагын шунысы ошамый: кайбер тәнкыйтьчеләр үз мәкаләләрендә, тырыша-тырыша, гаять акыллы, фәлсәфи фикерләр әйтергә маташалар. Булмагач булмый инде ул! Бальзакның тәнкыйть мәкаләләрен укыганым бар. Шулкадәр гади язган, һәм шуның белән бергә саллылык, олпатлылык сизелеп тора. Һәм нинди кайнарлык! Бальзак кебек титаннар, язмаларына фикерне, нигәдер, дыңгычлап тутырмаган, һәр нәрсәнең тансык булганда гына кадерле икәненә төшенгәннәр, күрәсең.

Әйткәнемчә, игътибарга лаек әсәрләр бездә дә бар. Тик күп очракта без дәшми калабыз. Үзара гына тел шартлатып сөйләшәбез дә — онытабыз. Шунда бит бер рецензия басылса да, авторга куаныч булыр иде, укучыга ул бер ориентир хезмәтен үтәр иде.

Коточкыч ялкаулар без.

Зарланырга яратабыз.

Аннары тәнкыйтьне сүгәбез. Димәк, үзебезне сүгәбез. Шигырь турында шагыйрьләр үзләре кызыклырак яза. Бу — табигый. Шигырьне шагыйрьләр ныграк тоя, зәвыклары камилрәк. Тик тою гына җитми, аны кәгазьгә төшерә белергә дә кирәк. Бу нисбәттән миңа Зиннур Мансуровның мәкаләләре ошый.

Тәнкыйть мәкаләсе язу — бик кыен эш. Бик акыллы, алдын-артын уйлап язган кеше бу өлкәдә, гадәттә, әллә ни уңышка ирешә алмый, минемчә. Күңелсез, әчпошыргыч язмаларның бик еш дөнья күрүе шуннандыр. «Юк!» — дип әйтер өчен кыюлык кына түгел, әйбәт мәгънәсендәге юләрлек тә кирәк.

Шунысы да бар, соңгы вакытта юк дип әйтү модага керә башлады. Тәнкыйть итү өчен генә тәнкыйтьләү... Тәнкыйтьнең бурычы — күсәк күтәрү түгел. Моны һәммәбез дә яхшы белә. «Юк!» — дип әйтү өчен дә кыюлык кирәк, ләкин: «Бар!» — дип әйтү өчен дә еш кына икеләтә кыюлык кирәк була.

Безгә ул сүзне киләчәктә ешрак кабатларга язсын иде.

## Галимҗан Гыйлманов:

Бездә еш кына шундый күренеш күзәтелә: җыелышларда, киңәшмәләрдә прозаның, поэзиянең яисә шул ук тәнкыйтьнең торгынлык кичерүе хакында сүз кузгалса — барысы да хуплый, барысы да риза, теләктәш. Ә инде шунда ук аерым язучының яисә шагыйрьнең иҗатын, теге яки бу «сыек» әсәрен тәнкыйтьләп сүз әйтелсә, ул язучы үз иҗатын, үз әсәрен яклап дау куптарырга әзер. «Гомумән тәнкыйть» белән «шәхсән тәнкыйть», шул рәвешле, икегә аерыла да китә. Сүз юк, беренчесе кем өчен дә уңайлы — дошманнар да аз, тавыш-гауга да юк...

Кайчак шулай да була — язучының үз иҗатын яклап дау күтәрүенә «көпшәк» тәнкыйть үзе дә сәбәпче. Бу хакта да онытмыйк. Кыскасы, «төссез» әсәр һәм «көпшәк» тәнкыйть — икесе дә әдәбиятны зәгыйфьләндерәләр, андагы теләктәшлек рухын сүндерәләр, иҗат кешеләре арасындагы бер-берсенә булган ышанычны, ахыр чиктә, үз каләмнәренә булган ышанычны киметәләр.

Аннан соң, безнең тәнкыйтьчеләр әдәбиятыбызга артык игътибарсызлар дияр идем мин. Үзебезне күрсәтә белмибез. Ә язучыларга гел игътибар кирәк, бара торган юлларында ышаныч атлар өчен кирәк бу игътибар.

Бер генә мисал. Язучы Мәхмүт Хәсәнов 26 китап авторы буларак билгеле. Дистәләгән роман, повесть язган бу язучы иҗатына игътибар ничек дисезме? — Барысы дүрт рецензия, ике мәкалә. Ә андый язучылар, шагыйрьләр күпме бездә!

Ике-өч китап чыгарып та, бер төпле мәкаләгә лаек булмаган яшь язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр бар. Аларның күбесе, өйгә килеп кергәч, биргән сәламнәренә җавап ала алмый каушап калган кешедәй хис итәләр үзләрен әдәбиятта.

Вакыты белән бик кискен итеп тәнкыйть итәргә, кимчелекләрен күрсәтергә генә түгел, әдәбиятка килеп кергән яшьләрне елмаеп каршы алырга да өйрәнергә кирәк әле бүгенге тәнкыйтькә!

Тәнкыйтьтә яңа формалар куллану да сорала. Җентекле анализны үз эченә алган зур мәкаләләр белән янәшә рецензия, реплика, эссе, пародия, диалог, түгәрәк өстәл тирәсендә сөйләшү кебек формалар да активлашсын иде.

Теге яки бу әсәр буенча ул әсәрнең авторы белән тәнкыйтьче арасында әңгәмә, бәхәс формасы да әдәби процессны яңа яктан ачып җибәрергә булышыр иде.

## Ләбиб Леронов:

Тәнкыйтьнең нинди стильдә язылуы турында уйланам. Шәхсән минем үземә гади укучыга да аңлаешлы итеп хикәяләү тонында язылган мәкалә ошый. С. Есенин һәм А. Блокның кайбер рецензияләрен мин шундыйлар рәтенә кертер идем.

Тәнкыйтьнең юмор теле белән язылуын да хуп күрәм. Аксакал язучыбыз Фатих Хөсни мәкаләләрендә юмор бар, җиңелчә көлү бар. Сарказм да юк түгел... Моннан берничә ел элек «Казан утлары»нда драматург Т. Миңнулинның яшь шагыйрь Ркаил Зәйдуллин шигырьләре турындагы язмасын укыган идек. Ялгышмасам, ул «Шигырь язарга өйрәтәм» дип атала иде шикелле. Ул язма да юмор теле белән язылган. Укырга кызыклы, тәэсир итү көче бар. Хәтердә кала торган...

С. Маннапов һәм Ф. Зөлкарнәев кебек тәнкыйтьчеләрнең кайбер язмаларында кызыклы табышлар, эзләнүләр күрәм. Язу стильләре дә үзләренчә, әсәрләренең формалары да хәтердә кала торган. «Форма — ул үзе бер әсәр»,— дигән француз язучысы Гюстав Флобер. Ул аны проза әсәрләренә карата әйткән. Минемчә, тәнкыйтькә дә кагыла бу...

Бериш язучылар бар. Аларның әсәрләре, шул әсәрләрне укучылар һәм тәнкыйтьчеләр бар.

Икенче бер төр язучылар бар. Аларның әсәрләре, шул әсәрләрне укучылар бар. Әмма тәнкыйтьчеләре юк.

Өченче берләренең инде әсәрләре бар, тәнкыйтьчеләре (махсус тәнкыйтьчеләре дисәң дә ярый хәтта) бар — әмма, кызганычка каршы, укучылары юк...

Бездә «Матур әдәбият» дигән төшенчә яши. Минем чын мәгънәсендә матур тәнкыйтьләр күрәсем килә матбугатта. Укыйсы, сокланасы, күңелгә яңалык аласы килә, Зәвык тәрбиялисе килә...

## Фәрит Яхин:

Уңышлы әдәби әсәр — теге яисә бу язучының уңышы гына түгел, ул бөтен милли әдәбият биеклеге дә. Шуңа күрә әдәби әсәргә иҗтимагый күренеш буларак карарга һәм тәнкыйть ярдәмендә аның һәр ягын ачыклап күрсәтергә, тормыш белән бәйли белергә кирәк. Бу — үз чиратында, әдәби әсәрне төрле яктан, комплекслы өйрәнү дигән сүз. Моның өчен, һичшиксез, башка иҗтимагый фәннәрнең (философия, социология һ. б.) кануннарын файдалану да зур ярдәм итә.

Әдәбиятның тормышны чагылдыруы мәсьәләсенә тукталганда, гадәттә без аның детальләрне дөрес итеп сүрәтләү проблемасын гына алга сөрәбез һәм әсәрләргә карата шушыны критерий итеп файдаланабыз, шул яктан гына бәя биреп үтәбез. Ә югыйсә әдәбият аның белән генә чикләнми бит. Әдәби әсәрнең эчтәлеген укучыга ачып бирергә кирәк. Эчтәлек сөйләү түгел, ә бәлки эчтәлеген ачу бу! Әлеге формада әдәби тәнкыйтьнең бик күп файдаланылмаган мөмкинлекләре һәм уңышлары яшеренеп ята. Без аның барлык мөмкинлекләреннән файдалана алганда гына әдәби тәнкыйтьнең, шул ук вакытта әдәбиятның үзенең дә тарихи-иҗтимагый әһәмияте югары күтәреләчәк.

библиография

# КАДЕРЛЕРӘК БУЛА БАРА

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләренең соңгы томы басылып чыкты[1]. Еллар үткән саен, аның исеме кадерлерәк, мирасы — җитдирәк, тулырак, әһәмиятлерәк булып күз алдына баса. Дөрес, Тукайның күптомлыклары моңа кадәр дә берничә тапкыр басылган иде инде. Соңгысы 1975—1977 елларда. Карасаң, ун ел эчендә халкыбыз сөекле шагыйрен нык кына сагынып өлгергән икән: күзәтелә торган биштомлыкның һәр китабы түземсезлек белән көтеп алынды, тиз арада халыкка таралып өлгерде.

Ихлас күңелле укучылар, әдәбият сөючеләр, поэзия тарихын өйрәнүчеләр мондый томнарны китап киштәләрен бизәү өчен генә алмыйлар. Яңа китаптан укучы яңалык эзли: шагыйрь турында яңа сүз яки шагыйрьнең әлегә кадәр киң катлау укучыларга мәгълүм булмаган әсәрләрен, яисә аның тормышына һәм иҗатына караган яңа фактлар көтә.

Җыелманың соңгы томында күрсәтелгәнчә, «Биштомлыкта элекке басмаларда булмаган 125 әсәр» урын алган: 1 һәм 2 томнарда 4 шигырь; 3, 4 һәм 5 томнарда шагыйрьнең әлегә кадәр билгеле булмаган 108 проза әсәре урнаштырылган. Күпме бу, азмы? — дип сорау биреп тору кирәкмәс. Күп бу, искиткеч күп! Бөек шагыйрьнең шул кадәр әсәре әлегә кадәр укучыларга гына түгел, хәтта Тукай иҗатын махсус өйрәнүче галимнәргә дә билгеле булмаган икән!..

Мәсьәлә монда гына да түгел әле. Бөек рус шагыйре А. С. Пушкинның «Һәйкәл» шигыренә һәм аның каралама язмаларына махсус монографияләр багышлана. Ә менә бездә тик соңгы 5-10 елда гына да бөек шагыйребезнең 125 әсәре табылган. Ләкин бу хакта бүгенге көнгә кадәр вакытлы матбугатта сүз булмады диярлек. Эш нәрсәдә соң? Бәлки бу биштомлыкны хәзерләүченең тыйнаклыгыдыр? Әйе, бәлки шулайдыр да. Ләкин, миңа калса, Тукайның бер генә яңа әсәре ачыкланса да, бу факт вакытлы матбугатта шунда ук хәбәр ителергә тиеш иде. Яңа әсәрнең табылу тарихы, идея-тематик эчтәлеге, Тукай иҗатында, гасыр башы әдәбият һәм журналистика тарихында тоткан урыны турында махсус мәкаләләр, күзәтүләр язып барылса, бүгенге әдәби хәрәкәт өчен дә әһәмиятле факт булыр иде.

Әдәби һәм фәнни этика чикләрен беркадәр җимереп булса да, әлеге сорауны башкача да куярга мөмкин: бәлки Тукай томнарына беренче тапкыр кертелгән әсәрләрнең әллә ни әһәмияте дә юктыр? Бәлки сүз вак-төяк язма-сызмалар хакында гына барадыр? Димәк, яңа табылган әсәрләрнең күләме, тематикасы, шигъри кыйммәте турында да берничә сүз әйтергә кирәк. Иң элек бу әсәрләрнең «тышкы» ягына игътибар итик. Шагыйрьнең ун ел элек дүрттомлыгы чыккан иде; хәзергесе — биштомлык. Димәк, яңа табылган әсәрләр тулы бер том тәшкил итә. Кайбер әдәбият белгечләренең фикеренчә, Тукай әсәрләренең ачыкланып бетмәгәннәре әле хәзер дә аз түгел.

Укучылар игътибар иткәндер, биштомлыкның һәрбер томында: «Томны, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләде Р. Гайнанов. Текстларны хәзерләүдә Лена Гайнанова булышты»,— дип язылган. Һәрбер томның 20-21 табак булуын искә алсак, ике кеше тарафыннан 100 табактан артык материал хәзерләнгән булып чыга. Шул текст һәм аңлатмаларның биштән бер өлеше бөтенләй яңадан хәзерләнгән. Бу юнәлештә күптән башланган эшне шундый ук тырышлык һәм түземлелек белән дәвам иткәндә, бәлки киләчәктә шагыйрьнең чыннан да тулы җыелмасын чыгару мөмкинлеге туар.

Яңа материалларның характерына игътибар итсәк, иң элек аларның эчтәлеге гаять киң булуын күрсәтеп үтәргә кирәк: көндәлек тормыш һәм әдәби хәрәкәт белән бәйле күзәтүләр, аерым шәхесләргә багышланган язмалар, газета-журналларга бирелгән кыска, әмма ачы телле юмористик, сатирик характеристикалар, ил эчендәге тарихи һәм иҗтимагый-политик вакыйгаларга шагыйрьнең мөнәсәбәтен чагылдырган мәкалә-эсселар, әдәби тәнкыйть материаллары. Күренә ки, форма ягыннан да алар бик күп төрле: искәрмә яки аңлатма, мәзәк, юмористик яки сатирик сүзлек, истәлек, үзенчәлекле хикәя. Ягъни, биштомлыкта урын алган яңа материаллар Тукайның иҗатын гына түгел, аның тормышын, күп кенә әсәрләренең язы-

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр, биш томда. 1, 2, 3, 4 томнар. Казан, 1985; 5 том, Казан, 1986.

лу тарихын, шагыйрьнең активлыгын, иҗади темпераментын — бик кызу, кайнар темпераментын — тагы да ачыграк күзалларга, өйрәнергә, тикшерергә мөмкинлек бирә.

Аерым томнарны төзү һәм конкрет материалны томнарга бүлү принциплары 1955—1956 һәм 1975—1977 елларда дөнья күргән җыелмалардан әллә ни аерылмый кебек. Бу басмаларның беренче ике томнары — шигъри, калганнары прозаик әсәрләрдән, тәрҗемә, әдәби тәнкыйть әсәрләреннән һәм хатлардан тора иде. Шул ук принцип биштомлыкта да саклана: 1, 2 томнарда — поэзия, 3, 4, 5 томнарда — проза әсәрләре.

Ләкин, шулай дисәк тә, Тукай прозасының җитди бер үзенчәлегенә игътибар итми мөмкин түгел: Тукай үзенең прозаик әсәрләрен шигъри юллар, строфалар (шагыйрь телендә — бәетләр), тәгәлләнгән шигырьләр белән бизи торган булган. Бу типтагы әсәрләр биштомлыкта да бар: өченче томдагы «Казан» чәйханәсендәге голяма җәмгыяте», «Уральскидә дарелмөгаллимин», «Дәхи[1] бер фетнә» һәм тагы алты прозаик әсәрдәге шигъри өзекләр; дүртенче томдагы «Ай, бат», «Идарәдән», «Безнең заман» дип исемләнгән әсәрләр h. б. Шигъри өзекләрнең әһәмияте Тукай поэтикасын өйрәнү өчен яңа материаллар бирүдә генә түгел. Алар шагыйрьнең иҗтимагый-политик карашларын, XX йөз башындагы революцион хәрәкәткә мөнәсәбәтен тәгәлрәк ачыкларга ярдәм итә. «Уральскидә думага беренче сайлаулар» мәкаләсендә, әйтик, түбәндәге юллар китерелә:

Торгыл, күтәрел, эшче кешеләр,
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңгыра дөньяга, үч авазы!
Алга, алга, алга!..

(3 том, 194—195 битләр)

Тагы да әһәмиятлерәге — бу өзеккә карата төзүче мондый аңлатма бирә: «...башта халыкара эшчеләр гимны, ә аннары Советлар Союзы Коммунистлар партиясе һәм бүтән илләрнең компартияләре гимны булып киткән «Интернационал»дан бер куплет. Бу — «Интернационал»ның иң беренче тәрҗемәсе булырга кирәк» (3 том, 355 бит). Шул ук революцион җырга шагыйрь тагы берничә тапкыр туктала. «Мөһим эш — имамнар җәмгыяте» мәкаләсендә җырның русча бер строфасы китерелә. Тукай томнарына беренче тапкыр кертелгән «Уральскидә сайлаулар»да шул ук строфаның татарча тәрҗемәсе бирелә:

Сезгә котылуны һичкем белмәс —
Нә алла вә нә падишаһ, вә нә баһадир;
Сез котылмакка җитәрсез
Үзеңезнең кулларыңыз илә...

(3 том, 261 бит)

Күптомлыктагы әсәрләр жанр һәм хронология тәртибендә бирелгән. Соңгы томның керешендә күрсәтелгәнчә, 3 һәм 4 томнарның төзелеше элегрәк чыккан басмалардан нык аерылып тора: 3 томда — 1904—1906, 4 томда — 1907—1913 елларга караган әсәрләр урын алган. Конкрет материалны болай урнаштыруның төп сәбәбе, төзүче күрсәтүенчә, Тукай томнарына «беренче мәртәбә кертелә торган проза әсәрләренең күләме (аеруча 3 нче томда) шактый зур булуы» (5 том, 5 бит). Ә инде 5 нче томда шагыйрь тарафыннан 1902—1913 елларда язылган истәлекләр, юлъязмалар, хатлар һәм мәсәләләр урын алган.

Тәнкыйть күзлегеннән караганда, биштомлыкта кулланылган фәнни принциплар хакында да уйланасы бар. Биштомлыкны укыганда, без шагыйрьнең иҗади юлы белән өч тапкыр танышып чыгабыз: 1—2 томнарда Тукай — шагыйрь; 3—4 томнарда — прозаик; 5 томда — тагы бер тапкыр прозаик. Әмма 5 нче томның бик отышлы бер ягы да бар: ул безгә Тукайны бик үзенчәлекле, катлаулы һәм каршылыклы тормыш юлы үткән шәхес буларак та күз алдына китерергә ярдәм итә.

Күзәтүдән шундый бер сәер нәтиҗә килеп чыга: биштомлыкта шагыйрь иҗаты, аның әдәби мирасы өч кисәккә бүленгән һәм укучыларга аерым-аерым кисәкләр рәвешендә тәкъдим ителгән. Җыелманы болай төзү акланамы?

Мәсьәләгә матбугат тарихы һәм бүгенге көндә күптомлыклар чыгару тәҗрибәсе күрсәткәнчә, биредә шаккатырлык берни дә юк. Рус әдәбияты классиклары Пушкин, Лермонтов, Некрасов җыелмалары да шул ук принцип нигезендә төзелә. Ягъни, бер үк тарихи шәхесләрнең әдәби мирасы өч яки дүрт кисәккә бүлеп бирелә: шагыйрь — прозаик — тәнкыйтьче һәм тарихи шәхес. Бәлки хәзер бу искергән принциптан баш тартырга, күптомлыкларны хәзерләүдә һәм дөньяга чыгаруда яңа принципларга эзләргә вакыт җиткәндер? Бәлки бөек шәхесләрнең иҗатын аерым кисәкләргә кисмичә, аны катлаулы, каршылыкны, күпкырлы һәм көчле бер агым буларак күз алдына китерү турында уйлап карарга кирәктер? Тукай үзе дә бит 1911 елның 4 мартында С. Рәмиевкә язган хатында болай ди: «Мин бит синең шикелле, саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...» (5 том, 105 бит). Шагыйрьнең әнә шул күпкырлы хезмәте иҗатының беренче адымнарыннан башлап, соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Әнә шул күпкырлы хезмәт күптомлыкның һәрбер томында һәм төрле яклап ачыкланып барса, Тукайның шагыйрь, про-

[1] Голяма — укымышлылар, галимнәр; дарелмөгаллимин — укытучылар хәзерли торган мәктәп, дәхи — тагы (төзүче аңлатмалары).

заик, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе булуын без әзлеклерәк күзаллар идек.

Биредә сүз күптомлыкны төзү принципларын «җимереп ташлау» турында бармый. Сүз тик күптомлыкларны төзүдә күптән урнашкан һәм «катып калган» принциплар хакында гына. Тукай бит гомеренең башлангыч чорында шигырь-поэмалар, аннан соң прозаик әсәрләр, иң соңыннан хатлар язу белән генә шөгыльләнмәгән. Ул барысын бергә эшләгән. Әнә шул күпкырлы, күпьяклы юлны күзалларга ярдәм итсен иде киләчәк күптомлыклар.

Шул ук вакытта биштомлыкка конкрет бер таләп тә куярга мөмкин: соңгы өч томда шагыйрьнең тик проза әсәрләре генә урнаштырылган. Шулай булгач, бу өч томда бер үк хронологияне (3, 4 томнарда — 1904—1913, 5 нче томда — 1902—1913 еллар) ике тапкыр кабатланмыйча, бер генә мәртәбә кулланганда, һичшиксез уңышлырак булыр иде. Югыйсә, бишенче томны укып чыккач, шундый бер тәэсир кала: биредә, күрәсең, башка томнарга «сыймаган» әсәрләр тупланган. Сәбәп нәрсәдә соң? Төзүче бу сорауга болай җавап бирер иде: күптән урнашкан традиция буенча, соңгы томга шагыйрьнең шәхси тормышы белән бәйле әсәрләр — истәлекләр, юлъязмалар, хатлар кертелде. Әмма бу төр әсәрләр бишенче томның өчтән бер өлешен генә алып тора. Минемчә, мәсьәлә башкада: төзүчене шагыйрьнең яңа табылган әсәрләре «әсәрләндергән» дә, ул, хронология турында онытып, яңа әсәрләрнең барысын да өченче томга сыйдырырга тырышкан. Биредә гаҗәпләнерлек берни дә юк. Иҗат кешесенең һәркайсы яңа табылган әсәрләрне җәмәгатьчелеккә тизрәк тәкъдим итәргә тырышыр иде.

Биштомлык Тукай мирасының яңа, әлегә кадәр рәтләп өйрәнелмәгән якларын ачыкларга ярдәм итүе турында югарыда әйтелгән иде инде. Биредә шагыйрь иҗатында җитди урын алып торган тагы бер төркем әсәрләргә игътибар итик. Сүз И. А. Крылов мәсәлләренең Тукай тарафыннан хәзерләнгән татарча версияләре турында бара. Крыловтан тәрҗемә дип буламы аларны? Юк, минемчә, булмый. Чөнки Тукайда Крылов мәсәлләренең берсе генә дә турыдан-туры тәрҗемә ителми. Тукай Крылов мәсәленең темасын, сюжетын, персонажларын (еш кына җитди үзгәрешләр белән) ала да шул нигездә яңа — саф татарча мәсәл иҗат итә. Әлеге әсәрләрнең формасы ук шуны раслап тора. Крылов мәсәлләренең барысы да шигырь белән язылган. Тукай мәсәлләрендә исә шигъри юллар юк дәрәҗәсендә. Булганнары да татар халык иҗаты белән бәйләнгән. И. А. Крыловның «Обед у медведя» мәсәле нигезендә язылган «Аю мәҗлесе»нә шагыйрь татар халык җырларыннан бер өзек кертә:

Ары да барып бинсең, бире дә килеп бинсең;
Бигрәк оста бинсең, күз тияр дип белмисең.
(5 том, 128 бит)

Крыловтан алынган мәсәлләрнең эчтәлеген шагыйрь татар халкы тормышына якынайтырга тырыша, аларны беркадәр конкретләштерә. Бәлки шуңа күрәдер бу мәсәлләрдә ислам руханиларына каршы юнәлтелгән юмор, бигрәк тә сатира зур урын ала. Крыловның «Плотичка» мәсәле нигезендә язылган «Чабак»та «нәтиҗә» рәвешендә мондый сүзләр китерелә: «Ишанның хәйләсен беләм дип, якын барма — кармакка эләгерсең. Ул сине чәй эчерер, аш ашатыр, шул вакыт уйла: балыкчы балыкка файда өчен суалчан ашатамы? Бу сүзем бай кешегә хитабәндер[1].— Ярлыны ишан танымас» (5 том, 297 бит).

Биштомлыкта урын алган мәсәлләр, Тукай тарафыннан билгеле әсәрләр нигезендә язылган башка күп кенә материаллар кебек үк, мөстәкыйль иҗат җимеше булып торалар. Бу яктан Тукай Каюм Насыйриның уңай традицияләрен уңышлы дәвам итә.

Бөек әдипләрне, язучы-шагыйрьләрне без гадәттә иҗатчы буларак кына беләбез, аларның язганы белән генә танышабыз — мәктәптә дә, югары уку йортында да. Шәхес буларак, алар бездән еракта калалар. Шагыйрь яки язучы белән якыннанрак танышуда аларның замандашлары тарафыннан язылган истәлекләргә таянырга мөмкин. «Тукай турында замандашлары» дип аталган китаплар бездә берничә тапкыр басылып чыкты. Алар бөек шагыйрьне шәхес буларак күз алдына китерергә ярдәм итә.

Мәсьәләнең бу ягын ачыклауда әдипнең хатлары аеруча зур роль уйный. Тукай хатлары белән без элек тә таныш идек. Биштомлыкта да аларга зур урын бирелгән: элегрәк чыккан дүрттомлыктагы 27 хатка тагы 7 хат өстәлгән. Бу материаллар шагыйрьнең тормыш юлын, хис-кичерешләрен, кайгы-хәсрәтен тулырак аңларга ярдәм итәләр дә.

Композициясе, тел-стиле ягыннан Тукай хатларын өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Апасы Сәҗидәгә, туганнары Абдуловларга язылган хатлар татар халкында киң таралган шәхси хатларны хәтерләтәләр. Шагыйрьнең апасы Сәҗидәгә язган хатының яртысын диярлек «чиксез күп һәм бетмәстәкәнмәс сәламнәр» алып тора. Тик аның дүрттән бер өлеше генә шагыйрьнең тормышы, нужалары хакында сөйли. Калган өлешендә тагы сәламнәр, шагыйрьгә ярдәм итүчеләргә рәхмәтләр белдерелә. Икенче төркем хатлар, мәсәлән, Г. Шәрәфкә, Г. Дәүләтшинга адресланганнары бик кыска, официаль формада язылган. Өченче төркем хатларда шагыйрь үзенең уйлары-фикерләре белән уртаклаша. Аларда сүз берәр әсәр, әдәби хәрәкәтнең ниндидер үзенчәлеге хакында бара. С. Сүнчәләйгә, С. Рәмиевкә язган хатлар әнә шундыйлардан.

Тукай хатлары бик гади тел белән язылган. Аларда шагыйрь үзенең кайгы-хәсрәте,

[1] Хитабәндер — төбәп, мөрәҗәгать итеп әйтү (төзүче искәрмәсе).

авыр тормыш шартлары турында гына түгел, үз характерының кимчелекләре хакында да ачыктан-ачык сөйли. Гомумән алганда исә, Тукай хатларын укыгач, ирексездән Сибгат Хәкимнең түбәндәге сүзләре хәтергә килә:

Тукай, Тукай — татар халкының ул
Бугазында газап төере...

Басманың һәрбер томында зур урын алган «Искәрмә һәм аңлатмалар»га да махсус тукталырга кирәк. Алар зур кызыксыну белән укылалар, тәфсилле язылганнар: һәрбер әсәрнең кайчан һәм нинди шартларда язылуы, беренче тапкыр кайда басылуы, шагыйрьнең кайсы куптомлыгына кертелүе турында искәрмәләр бай мәгълүмат бирә. Еш кына алар шагыйрь әсәреннән берничә тапкыр зуррак булып чыгалар. Моның үз сәбәпләре бар. Әйтелгәнчә, Тукай — үз чорының иҗтимагый тормышында һәм әдәби хәрәкәтендә актив катнашкан, төрле-төрле жанрларда һәм бик күп язган әдип. Аерым газета-журналлардан аңа заказлар, чакырулар килә торган булган. Әнә шундый күренешләрнең берсе турында ул бер хатында болай ди: «Яшен»нең секретаре мин булганга, анда бик күп язарга туры килә. Шул сәбәпле төрле-төрле мөстәгар[1] имзалар артында яшеренәм» (5 том, 91 бит).

Тукай иҗаты үз чоры тормышына искиткеч якын. Шуңа күрә аның әсәрләрендә XX йөз башы җәмәгать эшлеклеләре, шагыйрь-язучылар, редакторлар һәм башкаларның исемнәре, эшләре, чыгышлары, гадәттән тыш кыланышлары һ. б. фактлар телгә алына. Хәзерге заман укучыларына аларның күбесе билгесез. Ләкин Тукай әсәрләрен дөрес аңлау һәм объектив бәяләү өчен анда кемнәр, нинди кешеләр һәм аларның нинди эшләре турында сүз барганын белергә кирәк. Димәк, искәрмә һәм аңлатмаларда әнә шундый — безнең өчен серле исем-фактларның һәркайсына да ачыклык кертергә кирәк. Биш томның искәрмәләрен хәзерләүдә аларның авторы Р. Гайнанов зур тырышлык күрсәткән.

Биредә мәсьәләнең тагы бер ягын искә алырга кирәк. Тукай әсәрләрен эзләү, барлау, яңаларын табу юнәлешендә Р. Гайнанов ун елдан артык эшли. Димәк, биштомлыкның искәрмәләре моннан ун-унбиш ел элек башланган эшнең дәвамы булып тора. Шулай булгач, биштомлыкта искәрмәләрне Тукай иҗатын өйрәнүдә билгеле бер дәрәҗәдә яңа адым дип буламы?

Биштомлыкка яңадан 125 әсәр өстәлгән икән, аларның һәркайсына яңа искәрмә кирәк. Һәм алар бар, нигездә яхшы, тәфсилле эшләнгәннәр.

Дүрттомлыкның беренче томы «Мужик йокысы»ннан башлана иде. Ә инде биштомлыкта бу шигырь алдыннан Тукайның иң беренче басма әсәре «Гыйлемнең бакчасында күңел ачып йөрик», тагы «Бер дә бер көнне Камил әл-Мотыйгый...» шигырьләре китерелә. «Мужик йокысы»ның дүрттомлыктагы аңламасы да бер биттән чак кына артыграк иде. Ә инде биштомлыкта шул ук шигырьгә өч битлек аңлатма бирелгән. Аңлашыладыр: биштомлыктагы искәрмә киңрәк һәм тәфсиллерәк. Бу искәрмәнең тагы бер үзенчәлеге: анда А. В. Кольцов шигыренең русча тулы тексты китерелә. Башка кайбер аңлатмаларда да Тукай файдаланган әсәрләрнең оригиналь тексты яки шулардан өзекләр бирелә; әйтик, Крылов мәсәлләреннән, бигрәк тә алар Тукай тарафыннан ничек тә булса үзгәртелгән булса. Гомумән, биштомлыкның аңлатмалары, элеккеге басмаларга караганда, нык кына тулыландырылган һәм киңәйтелгән.

Тукай әсәрләрендә ислам мифологиясе белән бәйле төшенчәләр, легендар-мифик персонажлар, пәйгамбәрләрнең исемнәре еш очрый. Төзүче әнә шундый төшенчәләргә дә киң туктала: «Әгъраф — дини мифологиядә оҗмах белән тәмуг арасындагы урын» (1 том, 341 бит); «Кыямәт — мөселманнарның ышануынча, үлгәннән соң яңадан терелү, хисап бирү көне» (1 том, 345 бит); «Замана ахыры (мәхшәр көне) — мөселманнарның ышануынча, кешелек дөньясының җирдә яшәүдән туктау көне» (1 том, 345 бит).

Искәрмәләрдә рәван җан, Һарут берлә Марут, Кәүсәр, Хозыр Ильяс, Сәлсәбил һ. б. күп санлы сүз-исемнәргә тәфсилле һәм нигездә дөрес аңлатмалар бирелә. Икенче төр аңлатмаларда сүз төрле газета-журналлар, редакторлар, язучы-шагыйрьләр турында бара. Мондый материаллар матбугат тарихын, нәширләрнең, язучы-шагыйрь һәм башкаларның үзара мөнәсәбәтләрен аңлау өчен искиткеч бай материал бирә. Өченче төр аңлатмаларда сүз аерым тарихи шәхесләр һәм вакыйгалар турында бара. Әлеге аңлатма һәм искәрмәләрнең барысы белән якыннан танышкач, күңелгә шундый бер уй килә. Әгәр бу искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүче үзенең эзләнүләрен, табышларын, теге яки бу күләмдәге ачышларын бер системага салып, Ираклий Андронников тәҗрибәсе нигезендә, әнә шул эзләнү-табышлар турында бер әсәр язса, XX йөз башы әдәби хәрәкәтенә багышланган мавыктыргыч детектив барлыкка килер иде.

Биштомлыктагы «Искәрмәләр һәм аңлатмалар»ның әһәмиятен ассызымлап әйткән очракта да, андагы бер бәхәсле күренешкә тукталып үтәргә кирәк. Сүз һәрбер томда очрый торган бихисап кабатлаулар турында бара. Әдәбият һәм сәнгать тарихы белән беркадәр таныш булган һәркемгә билгеле фактларга төзүче һәм редакторлар кат-кат тукталалар. Исмәгыйль Гаспринский һәм «Тәрҗеман» газетасы хәзер бик күпләргә мәгълүм. Бу хакта биштомлыкның

[1] Мөстәгар — уйлап чыгарылган, псевдоним (төзүче искәрмәсе).

һәрбер томында диярлек, хәтта бер үк томда берничә тапкыр язу кирәк микән? Бер үк газетага яки журналга берничә мәртәбә туктап, бер үк сүзләрне кабатлау да акланып бетми. ««Ха-ха-ха» — 1906 елда... Гаспринский тарафыннан «Тәрҗеман» газетасы янында чыгарылган көлке журналы» (1 том, 347 бит). Шуңа якын сүзләр басмада тагы 2-3 тапкыр кабатлана (3 том, 361 бит; 4 том, 309 бит). Бездә хәзер Газраилне белмәүче бар микән? Шулай да бу сүзгә карата биш томлыкта бирелгән аңлатма төрле вариацияләрдә кат-кат китерелә: «Газраил — дини мифологиядә кешеләрнең җанын алучы фәрештә» (1 том, 347; 2 том, 372; 3 том, 334 битләр). Кайвакыт кабатлаулар кызык форма ала. В. В. Недоносковның адвокат һәм Икенче дәүләт думасы депутаты булуы турындагы сүзләр бер үк биттә нигәдер ике тапкыр кабатлана (3 том, 352 бит).

Биш томның һәркайсындагы кабатлауларны тикшереп чыккач, кабатланган нәрсәләр исемлеге ярыйсы ук зур булып чыга. «Аңлашылмаган сүзләрне укучы аерым томнардан эзләп аптырамасын дип, бер үк сүзгә, ул ничә тапкыр кабатланса да, һәр очракта да махсус аңлатма биреп барырга булдык диярләр төзүчеләр. Бәлки болай аңлатуда беркадәр хаклык та бардыр. Ләкин әлеге кабатлауларның санын бераз кыскартканда, дөресрәк булыр иде.

Йомгаклап, шуны әйтик: ничек кенә булмасын, бу кадәр зур хезмәттә аерым кимчелекләр, вак-төяк җитешсезлекләр булуы табигый. Тулаем алганда исә, бөек шагыйрьнең иҗади мирасын киң иңләгән биштомлык бүгенге текстологиябезнең һәм әдәбият белемебезнең җитди казанышы дип бәяләнергә тиеш. Редакторлар, аеруча төзүчеләр Рашат Гайнанов белән Лена Гайнанова тарафыннан тирән ихтирамга лаек зур хезмәт башкарылгын.

**Фатих УРМАНЧЕЕВ.**

# ТУКАЙ ТУРЫНДА ЯҢА СҮЗ

Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге галимнәр өчен бетмәс-төкәнмәс тема, илһам чыганагы булып кала. Шагыйрь шәхесен ачыклау, аның әдәби мирасын үзләштерү — бер үк вакытта халкыбызның күңел хәзинәсен, рухи-әхлакый тәҗрибәсен аңлау юлында да бер адым бит ул.

Тукайны өйрәнү юлында бөтенләй «ак калган» урыннар инде булмаска да тиеш кебек. Фатих Әмирхан, Гали Рәхим, Җамал Вәлидиләрнең Тукай турындагы беренче мәкаләләреннән башлап, Гали Халит, Мөхәммәт Гайнуллин, Ибраһим Нуруллин хезмәтләре дөньяга килгәнче, җитмеш елга якын вакыт узган. Бу чор эчендә шагыйрьнең биографиясе һәм әсәрләре ничек җентекләп өйрәнеп чыгылган, күпме мәсьәләләргә ачыклык кертелгән... Ләкин һәр яңа хезмәт әле эзләнүләрнең дәвам итүе, алай гына да түгел — куанычлы табышлар алып килүе хакында сөйли.

Шул җәһәттән күренекле галим Рәфыйк Измайлович Нәфиковның «Тукай һәм аның даирәсе» исемле китабы басылып чыгу һичшиксез игътибарга лаеклы вакыйга булды[1].

Үзәктәге һәм урыннардагы дәүләт һәм партия архивлары фондларын, музей документларын, күпсанлы газета-журнал төпләмәләрен, истәлекләр һәм хатларны, аерым гаиләләрдә кадерләп сакланган ядкарьләрне өйрәнү нәтиҗәсендә, Рәфыйк Нәфиков әлегә кадәр билгеле булмаган байтак кына вакыйгаларны, шәхесләрне, фактларны ачыклауга ирешә. Бу исә — «саф, коеп куйган поэт кына түгел, дипломат, политик һәм общественный деятель дә» булган Тукайның яшәгән тарихи мохитен генә түгел, ул иҗат иткән әдәби атмосфераны да инде безгә мәгълүм кадәресеннән баерак, этрафлырак, тирәнрәк итеп сурәтләү дигән сүз.

Үз вакытында «Фикер», «Әлгасрел-җәдид», «Уклар» кебек газета-журналларда, төрле тәхәллүс-псевдонимнар белән, шагыйрьнең күпсанлы публицистик әсәрләре басылган. Менә шул әсәрләрне тарихи-партияле позицияләрдән торып өйрәнү эшен яңа баскычка күтәргән галим Р. И. Нәфиков булды. Әлегәчә игътибардан читтәрәк калып килгән чыганакларга мөрәҗәгать итү, аларга бөтенләй көтелмәгән ракурстан карау, төрле фактларны, фараз-версияләрне чагыштырып өйрәнү дә аңа иҗади ачышлар ясарга мөмкинлек бирде.

«Тукай һәм аның даирәсе» китабына тарихчы галим утыз елдан артыкка сузылган эзләнүләр һәм тикшеренүләр аша килде. Әле 1954 елда ук, кандидатлык диссертациясенең икенче бүлегендә (ул бүлек «Г. Тукайның иҗтимагый-политик һәм философик карашлары үсеше һәм аның иҗатында социал-демократик идеяләрнең чагылышы» дип атала) Р. Нәфиков шагыйрьнең эшчеләр тормышы, аларның азатлык өчен көрәше белән бәйләнешен социал-демократлар хәрәкәтенә мөнәсәбәтен шактый тулы һәм этрафлы итеп

[1] Нафиков Р. И. Тукай и его окружение. Казань, 1986.

ачкан иде. Ул табышлар алдагы хезмәтләрдә тагын да үстерелә, тирәнәйтелә барды, яңа фикерләр һәм нәтиҗәләр белән баетылды.

Чыганакларны киң колач белән алып, эшкә җәлеп итә белү осталыгы, зур эрудиция, фикерләүдә новаторлык, анализ тирәнлеге — менә шушы сыйфатлар иҗатчы галимгә чын мәгънәсендә талантлы китап язарга нигез булган.

Иң әүвәл бу монографиядә проблеманың ачык итеп куелуы һәм тикшерү өчен алынган материалның кысалары төгәл билгеләнүе әйбәт тәэсир калдыра, хезмәтнең гомуми структурасы, фикер үстерелеше дә игътибарны җәлеп итә.

Китапның беренче бүлеге яшь Тукайның шәхес буларак аякка баскан чоры Уральск шәһәрендә яшәгән елларына туры килүе һәм аның инанулары; дөньяга карашы укылган китаплар, әзер формулалар тәэсирендә генә түгел, ә актив тормыш эчендә кайнау, бәхәсләр һәм көрәшләр нәтиҗәсе буларак формалашуы ышандырырлык итеп бәян ителә.

«Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән...» Чыннан да, Тукайны гомерен тулысы белән халыкка хезмәт итәргә багышлаган бөек шагыйрь һәм көрәшче иткән көч ул — 1905 елдан искән революцион җил. Россиядәге беренче революциянең хөр сулышыннан күкрәге киңәеп киткән, аның якты идеалларыннан күз аллары яктырган әдип дөньяны һәм тормыштагы үз урынын бик иртә аңлый, яшәү мәгънәсен хокуксызлыкка, җәбер-золымга дучар ителгән халык бәхете өчен көрәштә күрә. Татар тормышының һәр өлкәсенә үтеп керергә омтыла, андагы процессларны тарих күзлегеннән дә, илдә һәм бөтен дөньяда барган процесс яктылыгында да күзәтеп, бәяләп, алга бару юлларын ачыкларга, үсешкә ярдәм итәргә ашкына. Дәүләт думасы мөнбәреннән торып, буйсынмас татарларны Төркиягә сөрү белән куркытырга маташкан карагруһчыларга, шагыйрь һәм гражданин буларак, үз халкының һәм Россиянең патриот улы буларак, Тукай җавап бирә — атаклы «Китмибез!» дигән политик әсәрен яза. Бу вакытта аңа егерме бер яшь була.

Юк, туры Тукайның «мин бит... саф, коеп куйган поэт кына түгел...» дигән сүзләрендә бер генә мыскал да ясалмалык, рия булмаган. «Аның әсәрләрендә кешелек яшәешенең иң мөһим мәсьәләләре ачык, үзенчәлекле чагылыш таба,— дип яза Р. Нәфиков.— Фикер иясе, философ Тукай империалистик сугышның якынлашып килүче яшеннәрен күрә. Сүеш, халыклар бәхетсезлеге булган сугышны кире кагып, ул сугышны пропагандалауга каршы эзлекле көрәш алып бара. Империалистлар әзерләгән һәм кабызып җибәргән Балкан сугышларында ул Җир йөзендәге тынычлыкка куркыныч янавын күрә. Ул бөтен дөнья сугышын хәстәрләүче монополияләргә каршы чыга». Бу фикер халык шагыйре әсәрләренең иҗтимагый өлгергәнлеге, гражданлык активлыгы һәм бүген дә дөнья халкларена авваздаш булуын тагын бер кабат раслап килә.

Җитди социаль каршылыклардан бөтен әйләнә-тирә тетрәп торган бер чорда, матбугатта төрле карашлар һәм иҗтимагый агымнар чәкәләшкәндә, «ватан», «халык», «милләт» төшенчәләре еш кына «мөслим-мөселман» сүзе белән алыштырылып, дин әләме астында берләшергә өндәүләр яңгырап торган дәвердә: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үзебезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм»,— дип, ачыктан-ачык белдерү өчен, зур егетлек, гражданлык батырлыгы кирәк! «Тукай һәм аның даирәсе» китабының авторы менә шушы батырлыкның асылы һәм чыганаклары турында уйлана, Тукай тормышының гражданин һәм шагыйрь буларак формалашу баскычларын күз алдыннан кичерә. Бер-бер артлы яңа сәхифәләр ачыла, яңа фикерләр өермәсе кузгала... Һәм янә бер кат бу хезмәтнең фәнни төгәллеккә, дәлиллеккә таянып, укучыга аңлаешлы тел белән бәян итү осталыгына сокланасың.

Тукайга каршы көрәшүчеләр әле бүген дә исән. Кайчандыр аны «милләтче, вак буржуа шагыйрь» дип, халыктан аерырга тырышкан булсалар, хәзер исә шагыйрьнең заманчалыгын инкарь итәргә омтылып, каршылыкларын купайтыбрак күрсәтергә азапланалар, Р. Нәфиков сүзләре белән әйткәндә, аның дөньяга карашы, революцион көрәштәге позициясе мәсьәләләрен әле дә булса «хәл итәргә кыенсыналар». Ул гынамы, үзләренчә фикер йөртергә теләмәүчеләрне алар «шагыйрьнең каршылыкларын шомарту»да, «Тукайдан социалист ясау»да гаеплиләр.

Нишләмәк кирәк, 70 нче елларда һәм 80 нче еллар башында тамыр җәя башлаган, партиябезнең XXVII съездында кискен тәнкыйтьләнгән тискәре процесслар, торгынлык халәте фән өлкәсендә дә үзенең эзен калдырырга өлгерде. Дәрәҗәләр алдында сукырларча баш иеп, аларның бер әйткән фикерен догмага әйләндерү, «традиция», «фәндә кабул ителгән» формулалары артына яшеренеп, һәртөрле яңачалыкка каршы чыгу очраклары гыйльми эзләнүләрнең еш кына «бер урында йөгерү»гә охшап калуына китерде. Ә һәр фәнни хезмәт, һәр китап, билгеле ки, алга, киләчәккә таба бер караш ташлау булырга тиеш. Бәхеткә каршы, профессиональ тарихчы язган бу монография нәкъ әнә шул сыйфатка — киләчәк тойгысына ия.

«Революцион демократ Г. Тукай дөньяны кичекмәстән үзгәртү, самодержавиегә каршы тәвәккәл революцион сугыш ягында торган. Ләкин әле ул, идеал буларак кабул итсә дә, фәнни социализмның асылына төшенеп җитмәгән,—дип яза Р. Нәфиков.—Тукайның бөеклеге — социализмны кешелек җәмгыяте үсешенең объектив закончалыгы итеп санавында... Шагыйрьне без философ-материалист итеп күрәбез. Аның фикеренчә, дин (шул исәп-

тән, ислам дине дә) түгел, ә объектив реальлек, каршылыклардан тетрәнеп һәм көрәш казанында кайнап торган тормыш үзе кешелек прогрессын хәрәкәткә китерә. Бу әле стихияле материализм булса да, инде һич тә идеалистик караш түгел».

Тукайның карашлары иҗтимагый тормыш һәм әдәби процесста актив урын тотуында да, иҗатындагы кырыс реализм һәм халык мәнфәгатьләрен җырлавында да ачык чагылыш таба. Монография авторы шагыйрь биографиясен, шәхесен һәм әдәби-иҗтимагый эшчәнлеген тулыландыра торган җитди дәлилләр, яңа мәгълүматлар китерә. Китапның исемендә үк билгеләнгәнчә, бередә бөек шагыйрь белән бер чорда, аның белән бер сафта көрәшкән якты шәхесләр, татар милли культурасы эшлеклеләре турында да кызыклы күзәтүләр, фикерләр белән очрашабыз. Тукайның үз чордашлары белән мөнәсәбәтләрен тасвирлаган сәхифәләр, табигый ки, аеруча зур кызыксыну белән укыла.

Шагыйрьнең дуслары һәм көрәштәшләре — Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Гафур Коләхметов, Габдулла Кариев һәм башка күпләр мисалында татар революцион демократиясенең, алдынгы карашлы зыялыларның кешелеклелеге, ватандарлыгы, клерикализмга каршы чыгуы, социализмга һәм социалистик идеяләргә, революцион социал-демократиягә уңай мөнәсәбәте раслана. Автор татар халкы культурасының ике зур эшлеклесе — Г. Тукай белән Ф. Әмирхан арасындагы шәхси һәм иҗади бәйләнешләр турында тирән хөрмәт хисен, күңел җылысын салып яза. Шул ук вакытта ул безне, шагыйрьнең каләмдәшләре, мәдәният эшлеклеләре даирәсе белән генә чикләнмичә, Тукайны белгән һәм бөтен гомерләре буена аның хакында якты хатирә саклаган гади кешеләр белән дә таныштыра, бөек әдипнең халык мәхәббәтен яулавын үзенчәлекле мисаллар аша тасвирлый. Бу уңайдан, әгәр китапның ахырында исемнәр күрсәткече бирелгән булса, тагын да отышлырак булыр иде дигән фикер туа. Ул чакта галимнең нинди зур эш башкарып чыгуы, безгә нинди бай хәзинә тәкъдим итүе, ниһаять, ул ачкан яңа исемнәр аеруча ачыграк булып күренер иде.

Габдулла Тукай — туган халкының күкрәгеннән саф чишмәләр тибеп чыгасына, аның күгенә якты йолдызлар балкып күтәреләсенә, революцион көрәш мәйданына яңа көрәшчеләр үсәчәгенә чын күңеленнән ышанып яшәгән шагыйрь. «Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, ... фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы... егетләргә мохтаҗ»,— дип, тикмәгә генә язганмыни ул, үзенең әсәрләрендә шул егетләрне — заман геройларын тикмәгә генә эзләгәнмени! Шагыйрь үзен дә алар арасында күрә: «... җанымны чын юлда бирәм мең кәррә, кызганмыйм, минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай!»

Р. Нәфиков шагыйрьне ялкынлы публицист һәм нечкә лирик, һәрвакыт югары политик дулкында торучы аяусыз сатирик, чын мәгънәсендә «общественный деятель дә» итеп тасвирлый. Тукай иҗатындагы революцион рухны, интернациональ эчтәлекне ул гади халык тормышыннан, илдәге иҗтимагый-политик атмосферадан, алдынгы әдәбияттан килә торган импульслар, шагыйрьнең карашлары һәм фикер үсеше белән бәйләп карый. «Иң мөһиме шунда,— дип яза автор,— халык иҗаты хәзинәсе белән күңелен баеткан хәлдә ул үзе яшәгән дәвернең — пролетар революцияләр башланып киткән, алдынгы кешелек дөньясы бөек фикер иясе В. И. Ленин байрагына йөз тоткан чорның куәтле йогынтысын кичерә, ленинчылар, большевиклар партиясе әгъзаларының тәэсирен тоеп яши». Архивлардан яңа табылган мәгълүматларны фәнни әйләнешкә кертеп, шулай ук әлегә кадәр өстән-өстән генә әйтеп кителә килгән фактларга дикъкатьне юнәлтеп, Р. Нәфиков шагыйрьнең большевиклар белән киң элемтәләрен күрсәтә, шуның белән Тукай шәхесе һәм иҗатының үзенчәлекле сәхифәләрен ача. Китапның иң мөһим яңалыгы, галимнең аеруча тәкъдир ителергә тиешле хезмәте, минемчә, әнә шунда.

«Бөтен Русиянең мөхтәрәм мөхәррирләреннән тезелгән мөбәрәк тәсбих»тә кабатланмас үз урыны булган бөек Тукайның иҗатын гына түгел, шәхесен, даирәсен дә өйрәнү социаль-мәдәни тормышыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен зур әһәмияткә ия. Рафыйк Нәфиковның «Тукай һәм аның даирәсе» дип исемләнгән яңа хезмәте бу изге эшкә күркәм өлеш булып кушылды. Тукайны өйрәнү фәнендә ул лаеклы урын алыр дип ышанырга бөтен нигез бар.

**Мөнир ЮСУПОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ПРОФЕССОР Г. ШӘРӘФ ШИГЫРЕ

Галимҗан Шәрәф — Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле, мәшһүр рус галиме, СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты В. А. Богородицкийның (1857—1941) сәләтле шәкерте, татар теле фонетикасын тирәнтен экспериментал ьөйрәнгән һәм фәнни хезмәтләре безнең илдән тыш та билгеле булган атаклы телче-профессор, филология фәннәре докторы.

Ул 1896 елның 29 декабрендә Татарстанның элеккеге Буа өязе Кишер Аксуы авылында, мәгърифәткә омтылучы — «Шура» журналы һәм татарча газеталар алдыручы — урта хәлле крестьян Шәрәфетдин гаиләсендә дөньяга килгән. Башта мәдрәсәдә белем алган, аннан Казандагы 2 нче реаль училищеда һәм Петербургта тимер юл транспорты инженерлары әзерләүче институтта укыган. Әмма үзенең төп сәләтен тел белемен өйрәнүгә багышлаган, аспирантураны тәмамлап, татар теле белгече булып киткән.

Галимҗан Шәрәф 1950 елның 13 гыйнварында Казанда вафат була. Күптән түгел генә аның шәхси архивыннан уннан артык шигырь дәфтәре табылды. Шуннан бер шигырьне — Г. Тукайга багышланганын — укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

**Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ.**

## Галимҗан Шәрәф

### Шүрәле белән очрашу

**1**

Яратам таңнарда ялгызым гизәргә [1],
    Иртәнге саф суда чумарга-йөзәргә,
Таң җиле — хуш аңкып — уяткач урманны,
    Чык иңгән аланда чәчәкләр өзәргә;

Яратам тургайның таңдагы сайравын,
    Каенның уйланып, җилфердәп шаулавын;
Яратам кош-кортның, уятып бер-берен,
    Иртәнге төшләрен узышып сөйләвен.

**2**

Хәзер кыш. Агарган бар кырлар, болыннар,
    Ак мамык карларга төренгән урманнар;
Һәр ботак-чыбыкка ука чук асылган,
    Һәр кая ука чачаклар [2] сузылган.

[1] Шигырь Тукайның үлүенә 30 ел тулу көннәрендә «Гаенша бабай» имзасы белән язылган.
[2] Чачак — берәр нәрсәнең читенә бизәү өчен тотылган чуклар яки җепләр бәйләме (Автор искәрмәсе).

Һәр агач, һәр куак — искиткеч ак чәчәк,
Бар урман — әйтерсең бер гигант гөлчәчәк.

Әкияттә хан кызын йоклаткандай, урлап
Сихерче Кыш-Суык — ыжгырып, тылсымлап —
Карларын сиптереп, мамыгын очырып,
Бизәгән һәммәсен, урманны йоклатып.

3

Ни өчендер, бүген бик иртә уяндым,
Өс-башка, аякка киендем, кушандым;[3]
Җәй таңын хәтерләп, юнәлдем кырларга,
Әлеге тылсымлап бизәлгән урманга.

Мин барам тын кырдан, күгелҗем карлардан;
Ай-алтын урагы елмая һавадан.

Көнтуыш-офыктан таң нуры юл сала,
Җемелдәп, күкләрдән йолдызлар югала.
Таң үсә, җәелә,— аллана дөньялар,
Канәфер чәчәгедәй карлы далалар.

Ул — урман! Ул — урман!.. Гаҗәеп матурлык!
Бер тоташ ак чәчәк,— акылдан шашарлык!

Йоклаган хан кызым яртылаш уянган,—
Гөлчәчәктәй булып, яңагы алланган.

4

Урманның түренә мин барам, кар ярып,
Бу ямьгә-сихергә исереп, шаккатып.
Чү, тукта! Кем анда чыелдый-чырылдый?
Карт имән астында кем көлә, хихылдый?

Карасам, алдымда — мөгезле шүрәле:
Картайган, агарган чәчләре, төкләре.
Никтер, ул — бизәнгән: ак чәчәк — мөгезендә,
Ак чәчәк — түшендә, сөякчел иңендә.

Зур кәкре тырнаклы бармагын тибрәтеп,
Чакыра ул мине үзенең янына.
Мин — тордым да бераз каранып-шикләнеп,
Юнәлдем туп-туры карт имән астына.

— «Һич шикләнмә,— ди ул,— шагыйрем, син миннән,—
Мин тимәм һич сиңа, тидермәм беркемнән.
Шүрәле илендә бүген бик зур бәйрәм —
Сагыну кичәсе, зур шәплек[4] һәм матәм:

Нәкъ утыз ел бүген шагыйрем үлгәнгә,
Даһины — Габдулла Тукайны күмгәнгә.
Һич онытмый аны шүрәлеләр халкы,—
Олылап яд итә бар яше һәм карты».

— «Нидән соң аңарга,— дим,— болай зур хөрмәт?
Ул — килгән бит сездән, исеңдәдер әкият!»

---

[3] Биредә «кушану» — шарфлар, путалар урану (Автор искәрмәсе).
[4] Шәплек — бизәүле тантана.

— «Тыңлачы, шагыйрем, зарланыймчы сиңа:
Хәзер яшь-җилкенчәк һич ышанмый миңа.

Бары тик ышану яшәтә бит безне —
Өрәкне, убырны, бичура, пәрине.

Шул ышанмау инде үтерә илемне,
Юк итә дөньядан ыруым-нәслемне.

Ә Тукай «Шүрәле» дип поэма язып,
Хәтта «Шүрәле» дип имзалап-кул куеп,
Таратты данымны никадәр илләргә,
Калдырды яңгыратып исмемне мәңгегә...»

Шул вакыт тирәмне ал томан урады:
Шүрәле — хихылдап, күземнән югалды.

5

...Уянсам, утырам урманда бүкәндә,
Нәкъ шунда, сөялеп теге карт имәнгә.
Белмимен,— мин күрдемме аны төшемдә,
Әллә, чын шүрәле очрадымы өнемдә.

Йоклаганмын байтак,— көн тәмам яктырган;
Яз башы кояшы елмая һавадан.
Ялтырый нурларда тылсымлы урманым,—
Алмаслар бизәгән карларын, куагын.

*Март, 1943*

# ТУКАЙГА МӘХӘББӘТ БЕЛӘН

Оренбург якларында татар культурасы тарихын өйрәнгәндә, миңа халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай исеме белән бәйле күп кенә истәлекләргә юлыгырга туры килә. Билгеле ки, шагыйрь үзе дә бу төбәктәге хәл-әхвәлләргә, мәдәни тормышка битараф булмаган. Хатердә аның: «Әле Оренбурдан да, мине чакырып, хат килде; «Вакыт» гәзитәсендә, «Шура» журналларында эшләргә... Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбур язучылары илә гәзитә аркылы беразчәкәләшеп алган идек...» — кебек юллары яңара. Тукай исән вакытта ук аның исеме Оренбург халкының төрле катламнары арасында, бигрәк тә укымышлылар һәм шәкертләр даирәсендә зур хөрмәт белән искә алына. Шуңа күрә шагыйрьнең вафаты да гаять үкенечле югалту, милләт күләмендәге кайгы буларак кабул ителә.

«Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте Фатих Бакировның көндәлегендә ул көннәр менә ничек тасвирланган:

«Шагыйрь Габдулла Тукайның үлеме хакындагы хәбәр «Хөсәения» шәкертләренә бик тетрәндергеч тәэсир ясады. Шул ук сәгатьтә үзеннән-үзе матәм митингысы башланып китте. Кайгысын белдереп чыгыш ясарга теләүчеләрнең хисабы юк иде.

Зур югалтудан ачынып, шагыйрьне сагынып, татар шәкертләре генә түгел, Фирганәдән Ходжаев, Әүлия-Атадан һади Сәфәргалиев, Алма-Атадан Ситдыйк Абланов вә башкалар сөйләде. Барысының да күзләрендә яшь иде.

Аннары барчабыз бергә мәдрәсәдән чыгып, кала үзәгенә таба юл тоттык. Николай (хәзерге Совет — М. Р.) урамындагы китап кибете ишеге янына Габдулла Тукайның сурәте һәм аның вафаты мөнәсәбәте белән язылган шигырь урнаштырылган иде. Шигырьне китап кибетендә эшләүче, «Хөсәения»нең элекке шәкертләреннән Исхак Әлмәшев язган диделәр. Без төркем-төркем булып шагыйрь сурәте яныннан уздык, яшь аралаш кайгылы шигырь юлларын укыдык. Бу — Оренбург халкының Габдулла Тукай белән үзенчә хушлашуы иде...»

Кызганычка каршы, матәм көнендә шагыйрьнең рәсемен кем ясаганлыгы хәзергә билгесез булып кала. Әлеге сурәт тә, китап кибетендә эшләүче егет язган мәрсия-шигырь дә сакланмаган. Шулай да, кем соң ул — Исхак Әлмәшев, бөек шагыйрьнең вафатына аның шулай үзенчәлекле мөнәсәбәт белдерүе очраклы гына хәл булганмы?


Архивларда эзләнә торгач, мин бу кеше турында шактый кызыклы мәгълүмат табуга ирештем (Оренбург өлкәсе дәүләт архивы, ф. Р — 450, I тасв., 991 эш, 11 б.). Революциягә кадәр Фатих Кәриминең китап кибетендә эшләгән И. Әлмәшев соңра Оренбургтагы беренче совет уку йортларында (педагогия техникумында, педагогия институтында) татар теле һәм әдәбияты буенча мөгаллимлек иткән. Бер үк вакытта ул үзенең бөтен тормышын татар сәхнәсе белән бәйләгән энтузиаст та булып күз алдына килә. Ул, үзешчән артист, режиссер, 1919—1928 елларда губерна халык мәгарифе бүлегендә сәнгать секциясе җитәкчесе буларак, Оренбургта татар театрының ныгуына, үсешенә зур өлеш кертә. Җирле газеталар артист Әлмәшевның тамашачылар мәхәббәтен казануы, режиссер Әлмәшевның Оренбург сәхнәсендә рус, әзербайҗан, Көнбатыш Европа драматургларының әсәрләрен дә уңышлы куюы турында язалар. Исхак Әлмәшевны күреп белгән кешеләр, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул Габдулла Тукай шигырьләре белән чыгыш ясарга яратты дип искә алалар. 1925 елның 23 декабрендә Оренбург татар театрының 20 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә Исхак Мөхәммәтҗан улы Әлмәшевка «Сәхнә батыры» исеме бирелә, шәһәр җәмәгатьчелеге аңа зур хөрмәт күрсәтеп, бүләкләр тапшыра...

Инде башта ук телгә алынган Фатих Салих улы Бакиров (1900—1975) турында кыскача гына мәгълүмат. «Үзбәк Совет энциклопедиясе»ндә (Ташкент, 1972) аның гражданнар сугышы ветераны булуы, заманында Ташкент газеталарында редакторлык итүе, аннары исә Урта Азия дәүләт университеты профессоры, кафедра мөдире булып эшләве әйтелә, юридик фәннәр докторы буларак, күпсанлы хезмәтләр авторы икәнлеге билгеләп үтелә. Фатих ага миңа язган хатларында Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсе белән бәйле яшьлек елларын еш искә ала, мәдрәсә шәкертләренең бөек Тукайга мәхәббәтен һәм аның үрнәгендә халыкка хезмәт итәргә әзерләнүләрен тасвирлый иде. Ул үзенең дә яшьлек омтылышларына, Тукай рухына тугрылыклы булып калуы белән горурланып яшәде.

Шунысы куанычлы, Исхак Әлмәшев, Фатих Бакировлардан эстафета яшьрәк буыннарга күчә бара. Шәһәребезнең Хөсәен Ямашев исемендәге китапханәсе хезмәткәрләре, татар әдәби-музыкаль берләшмәсе җитәкчесе Зиннур Шакиров кебек ялкынлы йөрәкле энтузиастлар халык сәнгатен пропагандалау, Тукай традицияләрен дәвам итү юнәлешендә игелекле эшчәнлек күрсәтәләр.

Оренбург татар халык шагыйре турында хатирәләрне онытмый, кадерләп саклый, киләчәккә тапшыра.

**Мәдинә РӘХИМКУЛОВА,**
СССР География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы.
Оренбург шәһәре.



«Хөсәения» мәдрәсәсе
(Бурзянцев урамы һәм Мало-Торговый тыкрыгы чаты.)

# МӘГЪРИФӘТ УЧАГЫ

Оренбург — халкыбыз тарихында һәм мәгариф-мәдәният өлкәсендә тирән эз калдырган шәһәрләрнең берсе. Монда татарча газета-журналлар, китаплар нәшер ителгән, спектакльләр куелган, мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән. Либераль буржуазия вәкилләре бертуган Әхмәт һәм Мәхмүт Хөсәеновлар тарафыннан 1889 елда ачылган «Хөсәения» мәдрәсәсе Октябрь революциясенә кадәрге татар уку йортлары арасында иң атаклыларыннан саналган. «Хөсәения» — рус һәм Европа уку йортларыннан үрнәк алып, нык һәм эзлекле яңару юлына баскан җәдит мәдрәсәсе. Башлангыч чорында ул шәһәрдәге берничә йортта урнашкан була, ә 1905—1906 елларда өч катлы махсус яңа бина корыла. Анда уку класслары, төрле кабинетлар, китапханә өчен генә түгел, интернат һәм ашханә өчен дә аерым бүлмәләр билгеләнә. Мәдрәсәгә тирә-юньнән генә түгел, Себер, Кавказ, Урта Азия кебек ерак төбәкләрдән дә шәкертләр агылган. Алар карамагында әдәби, фәнни-педагогик китаплар, дәреслекләр, төрле телләрдәге (татар, рус, гарәп, француз, төрек, немец, фарсы) газета-журналлар тупланган бай китапханә була. Кыскасы, зирәк, акыллы бала «Хөсәения»дә заманасы өчен мөмкин булган белем дөньясына чумган. Мәдрәсәнең тиз арада танылуында укытучыларның тырышлыгы аеруча зур була, әлбәттә. Анда татар теле һәм әдәбияты, халык иҗаты, педагогика, методика һәм публицистика өлкәсендә тирән эз калдырган укытучы-мөгаллимнәр эшли. Күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев, шагыйрьләр Сәгыйт Рәмиев, Сәгыйт Сүнчәләй, әдипләрдән Шәриф Камал, Фатих Кәрими, Җамал Вәлиди, Төхфәт Ченәкәй, Шәрәф Борһан һәм башкалар әнә шундыйлардан. Н. В. Гогольнең «Ревизор» һәм «Өйләнү», Л. Н. Толстойның «Тере мәет», Э. Войничның «Кигәвен», Джованьолиның «Спартак», Софоклның «Әдип — хөкемдар», Г. Гейненың «Альмансор», Байронның «Шильон мәхбүсе», Н. А. Некрасов, М. Ю. Лермонтов әсәрләре, «Марсельеза», «Интернационал» кебек революцион җырлар һәм дөнья классикасының башка бик күп талантлы әсәрләре татар укучысына «Хөсәения» укытучылары һәм анда белем алган укымышлылар тәрҗемәсендә ирешә.

Мәдрәсәдә дәресләр заманча методика нигезендә, расписание буенча, кыңгырау белән алып барыла. Шәкертләр ислам дине кануннары, дин тарихыннан тыш татар тарихы, Россия тарихы, география, логика, физика, алгебра, геометрия, химия, элементар юриспруденция, туган тел һәм әдәбият, рус теле һәм әдәбияты, гарәп, фарсы, немец телләре, хисап өйрәнәләр. «Хөсәения»дә башка мәдрәсәләрдә күренмәгән педагогика, методика, гимнастика һәм гигиена, сызым һәм рәсем кебек предметларны укытуга да зур игътибар бирелә. Мәдрәсә каршында өч классл рус мәктәбе дә эшләп килгән.

Шәкертләрнең күпчелеге социал-демократик идеяләр йогынтысында революцион хәрәкәттә катнаша, демократик матбугатка языша. 1905 елны күп кенә шәкертләр, хәтта үз заманы өчен алдынгы саналган «Хөсәения» белеменә дә риза булмыйча, мәдрәсәне ташлап чыгалар.

«Дин вә мәгыйшәт» кебек клерикаль матбугат органнары (1909, 18 сан), «Хөсәения»дән елга бер түгел, ун елга бер мулла да чыкмый, дини бәйрәмнәрдә шәкертләр Гоголь кичәләре үткәреп, спектакльләр куялар дип яшь койганнар икән, бу мәдрәсәдә шәкертләрнең нинди белем һәм тәрбия алганын аңлау кыен түгел, әлбәттә. «Хөсәения»не тәмамлаган шәкертләрдән әдәбият һәм сәнгать, мәгариф-мәдәният, совет, партия, хуҗалык органнарында эшләп дан казанган шәхесләрне санап китсәк, озын исемлек хасил булыр иде. Шуңа күрә кайбер исемнәрне генә искә төшереп узыйк: Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил, шагыйрь Сәгыйт Рәмиев, гражданнар сугышы герое, әдип Шамил Усманов, галим һәм язучы Мөхәммәт Гали, татар классик драматургиясенең күренекле вәкиле Мирхәйдәр Фәйзи һәм башкалар.

Мәдрәсәнең күпчелек шәкертләре һәм укытучылары Октябрь революциясен шатланып каршы ала, гражданнар сугышы елларында дутовчыларга һәм басмачыларга каршы сугыш хәрәкәтләрендә актив катнаша. 1919—1920 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсе Татар халык мәгариф институты итеп үзгәртеп корыла. Шулай итеп, «Хөсәения» һәм аның кебек башка алдынгы мәдрәсәләр халкыбызны совет властеның беренче елларында мәгариф өлкәсендә алып барылган зур үзгәрешләргә әзерләгән дип, тулы ышаныч белән әйтә алабыз.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме,*
*Ж. Миңнуллин тексты.*

# *Нурмөхәммәт Хисамовка 50 яшь*



*1937 елны Татарстанның Чүпрәле районы Мунчәли авылында крестьян гаиләсендә туган Нурмөхәммәт Хисамов үзенең 50 еллыгын әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелеккә билгеле галим һәм әдип буларак каршылый. Бу игелекле олы юлның башы кайда соң? Әлбәттә, туган авылында, ул тәрбияләнеп үскән гаиләдә. Аның этисе Шаһвәли абзый тырыш игенче, оста умартачы булуы өстенә китаплар яраткан, көнчыгыш әдәбиятын һәм тарихын, рус әдәбиятын яхшы белгән. Әбисе Сабира абыстай исә узган гасыр азагында ук күп кенә шәкертләргә мәгърифәт нуры иңдергән мөгаллимә булган. Әнә шундый мохиттә тәрбияләнгән Н. Хисамовның әдәбиятыбыз тарихына җаны-тәне белән бирелгән галим булып үсүе — табигый хәл, әлбәттә.*

*Туган телгә, әдәбиятка мәхәббәт аны 1955 елда Казан университетының тарих-филология факультетына, аннан соң аспирантурага һәм СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына китерә. Тикшерүче галим буларак, Н. Хисамов урта гасыр төрки шагыйре, болгар-татар язма әдәбиятына нигез салучы Кол Гали иҗатын өйрәнүдә аеруча зур уңышка ирешә. Бөек шагыйрь иҗатын тәфсилләп тикшергән, Мәскәүдә һәм Казанда дөнья күргән фәнни хезмәтләре гомумсоюз матбугатында югары бәя алды.*

*Журналыбызның актив авторы, галим һәм язучы Нурмөхәммәт Хисамовны кайнар котлыйбыз һәм аңа яңадан-яңа иҗади уңышлар телибез.*

## Нурмөхәммәт Хисамов

# XIII-XIV ГАСЫРЛАРДА ИДЕЛ БУЕ ТӨРКИ ПОЭЗИЯСЕ

Төркология фәнендә урнашкан караш нигезендә XIV гасырга чаклы барлыкка килгән әдәби ядкарьләр язма культуралары борынгы булган төрки халыкларның уртак байлыгы хисаплана. Әдәби телнең нигездә уртак яки якын булуы күренекле әсәрләрне төрки халыклар яшәгән төрле төбәкләр өчен аңлаешлы иткән. Әйтик, Караханилар дәүләтендә язылган «Котадгу белек» поэмасын Идел буенда аңлап һәм яратып укыган кебек, Идел буенда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» әсәрен дә урта гасырдагы төрле төбәкләрдә яратып укыганнар.

Идел буенда язылган әсәрләр барыннан да элек һәм турыдан-туры татар әдәбиятына карый. Бу һич тә ул дәвердә безнең бабаларыбыз белән уртак культура тормышы кичергән халык һәм төбәкләрнең, әйтик, Хәрәземнең, аңа варислыгын юкка чыгармый. Әмма XIII—XIV гасырларда әле «татар әдәбияты» дигән төшенчә булмаганлыктан (чөнки халкыбыз үзе «татар» дип аталмаган), «болгар әдәбияты» исә «төрки әдәбият» дигән зур төшенчә эченә кергәнгә, бу чор әдәбиятын киң аталышында куллану фәнни объектив һәм тарихи гадел булыр.

«Татар әдәбияты тарихы»ның мең елны (VIII—XVIII йөзләр) эченә алган I томы инде укучылар кулына барып ирешә. Урта гасырның мөһим авторларына һәм иң күренекле ядкарьләренә багышланган монографик хезмәтләр дә бар. Х. Госман, Г. Таһирҗанов, Ш. Абилов, Х. Миңнегулов, М. Җәләлиева, К. Дәүләтшин, Ә. Шәрипов һ. б. тикшеренүләре, Кол Галигә багышланган безнең хезмәтләрне дә шуларга өстәп, аерым әсәр һәм авторлар турында ярыйсы ук тулы күзалларга мөмкинлек

бирә. Әмма әдәбият тарихын идея һәм сәнгатьчәлек җәһәтеннән эчке бәйләнешләр эзлеклелеге һәм үсештәге бер бөтен процесс итеп күз алдына китерү өчен, шушы чорның иҗтимагый-тарихи һәм эстетик ихтыяҗлары яссылыгында махсус тикшеренүләр сорала. Бу исә безгә әдәбиятыбызның борынгы тарихын тирәнрәк белү өчен генә түгел, соңгырак чор казанышларын, аларның идея-эстетик йөзен тулырак ачу өчен дә кирәк.

Сәяхәтчеләрнең язмалары, күпсанлы тарихи һәм географик чыганаклар, рус елъязмалары һәм тупланган бай археологик материал монгол явына кадәрге болгар культурасының шактый югары дәрәҗәдә торганлыгын сөйли[1]. Көнчыгыш илләрендәге китапханә каталогларында Болгар иленнән чыккан галимнәрдән медицина, фикһ (юриспруденция), дин гыйлеме буенча хезмәтләр һәм атаклы фәнни китапларга шәрех язган уннарча авторларның исеме теркәлеп калган. Мөселман Көнчыгышының мәдәни үзәкләре белән тыгыз элемтә укымышлы кешеләрнең җанлы аралашуы аша барган. Көнчыгыш илләреннән чыккан яшьләр еш кына болгар мәдрәсәләрендә укыса, болгар галимнәре үзләренең белемнәрен Көнчыгыш илләрендә күтәргән. Идел буеннан чыгып, шәрыктә шул чорның күренекле сәяси һәм мәдәни эшлеклеләрен тәрбияләп дан алган мөдәррисләр билгеле[2]. X гасыр башындагы гарәп сәяхәтчесе Ибне Рөстә болгар авылларында башлангыч мәктәпләр эшләвен язган. Икенче бер гарәп сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнати шуннан ике гасыр соңрак Болгар иле башкаласы Билярдә шәһәрнең баш казые, тарихчы, Нишапурның бөек галиме Әбел Мәгали Җүвәйни шәкерте Йагкуб ибне Ногман белән очрашып сөйләшкән. Ул аның «Болгар тарихы» дигән китабыннан кайбер мәгълүматлар китерә. Шунысы кызык: Әл-Гарнати язып алган вакыйгалар татар халкы хәтерендә легендалар рәвешендә әле дә яши. Фольклор экспедицияләре аларны һаман терки тора.

Иделнең түбән агымында Саксин шәһәре урнашкан булган. Аның үзәгендә «Болгар кешеләренең өмире яшәгән, аларның җомга мәчете булып, ул мәчет тирәсендә болгарлар торган»[3]. XII гасырда Саксинда күренекле галим Сөләйман ибне Дауд гомер кичергән. Кыскасы, монгол яулары алдыннан Болгар дәүләтенең культурасы күтәрелештә булган. Ил үзенең күршеләре белән тыныч сәүдә һәм экономик мөнәсәбәтләрне үстерергә тырышкан. Мәсәлән, рус князьлекләре белән экономик һәм сәяси бәйләнешләр күптәннән килгән. Ибне Фазлан Багдад хәлифәсе илчелеге килгәндә үк (922 ел), Болгарда русларның агач өйләре һәм хуҗалык корылмалары белән сәүдә пункты булганын яза. 1006 ел килешүе нигезендә болгар сәүдәгәрләре Владимир-Суздаль князьлегендә иркенле сәүдә итә алганнар, рус сәүдәгәрләре исә Болгар җирендә шундый ук ирек белән файдаланган[4].

Болгарлар монголларның беренче һөҗүмен уңышлы рәвештә кире кайтарсалар да, ул — илне һәм аның күршеләрен хафага сала. Бердәмлек һәм тынычлык халык яшәешенең иң мөһим шартларына әверелә. Болгар җәмгыятенең әнә шушы ихтыяҗларына җавап рәвешендә, монгол яуларының нәкъ икенче дулкыны алдыннан 1233 елда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» исемле зур әсәре дөньяга килә. Ул — гүзәл Йосыф турындагы Тәүрат-Коръән сюжетының беренче төрки тәрдәше һәм Көнчыгыш поэзиясендә бары каһарман исеме белән генә аталган бердәнбер поэма була.

«Кыйссаи Йосыф»ның үзәк проблемасы — хөкемдар һәм халык бәхете мәсьәләсе. Күрәсең, монголларның беренче сабагы җәмгыятьнең алдынгы кешеләрен халыкның дәүләттә төп көч һәм таяныч, аның чәчәк атуында хәлиткеч шарт булуы турында җитди уйланырга мәҗбүр иткән. Шунлыктан Кол Гали Йосыф образында мәгърифәтле, кайгыртучан һәм кешелекле хөкемдарны гәүдәләндергән. Шагыйрь фикеренчә, дәүләт идарәсе хөкемдар түбәннән күтәрелгәндә генә гадел була. Үзәк каһарман да, аның вәзире дә поэмада түбәннән күтәрелгән кешеләр итеп бирелә. Йосыфны атасыннан җитмеш елга аерган агаларының рәхимсезлеген, көнчелек һәм яласын шагыйрь кискен гаепли. Туганнар ызгышын гаепләүдә тирән социаль мәгънә яшеренгән. Поэма шул рәвешле монгол яулары алдыннан болгар җәмгыятен туплауга хезмәт иткән.

Кол Гали Көнчыгыш әдәбиятларында гуманизм чәчәк аткан дәвердә яшәп иҗат иткән. Бу — Шәрык әдәбияты Низаминың кеше гүзәллеген, аның рухани затын данлаучы даһи әсәрләре белән баеган чор. Фарсы-әзербәйҗан шагыйренең бәрәкәтле тәэсире төрки шагыйрьнең Зөләйха образын эшләвендә чагыла. «Кыйссаи Йосыф» — тагы сәламәт һәм бәхетле гаиләнең нигезе буларак бердәнбер һәм саф мәхәббәт идеясе Низами идеяләренә аваздаш яңгырый. Зөләйха Көнчыгыш поэзиясендә беренче

---

[1] Халиков А. Х. Культура народов Среднего Поволжья в X—XIII веках.— Вопросы истории, 1976, № 4.

[2] Тагирджанов А. Т. Влияние поэмы Фирдоуси «Йусуф и Зулайха» на «Кисса-и Йусуф» Али и «Йусуф и Зулайха» Шаййад Хамзы.— Палестинский сборник. Вып. 21. Л., 1970, 50-52 бб.

[3] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу. (1131—1153 гг.). М., 1971, 27 б.

[4] Татищев В. Н. История Российская с самых древнейших времен. Т. 2. М., 1963, 88 б.

тапкыр Йосыфның бердәнбер хатыны итеп тасвирлана, һәм бу мәсьәләдә Кол Гали әсәренең герое көнчыгыш поэмаларының таҗлы бүтән каһарманнарыннан, шул җөмләдән Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха»сыннан да, кискен аерыла. Болгар шагыйре әхлакый сафлыкны кеше һәм гаилә бәхетенең төп шарты итеп саный.

«Кыйссаи Йосыф» әсәре Болгар илендә хуплап каршы алынган.— Аның язылуыннан соң 60 ел үткәч, Мәмил исемле кешегә кабер ташы куела. Бу исем башлап Кол Гали поэмасында очрый. Йосыфның кече улы «Мәмил» атлы булган. Болгар дәверенең җиде кабер ташын да шушы исемне укыйбыз.

«Кыйссаи Йосыф» — сугышлар тасвирланмаган һәм аларга дан җырламаган сюжетлы сирәк әсәрләрдән. Бу яктан ул бүген дә актуаль яңгырашын җуймый.

Теленең гади һәм аңлаешлы булуы, формасының халыкчанлыгы һәм идеяләренең затлы яңгырашы поэманы болгар-татар әдәбияты тарихында озын гомерле иткән. Урта гасырларда «Кыйссаи Йосыф» калыбында һәм аңа охшатып күп санлы шигъри әсәрләр язылган. Алар сәнгатьчәлекнең үзенчәлекле мохитын һәм мәктәбен тәшкил иткән, һәм Идел буеның барлык шагыйрьләре дә шушы мәктәпне узган. Бу әсәрнең җанлы йогынтысы Тукайга, Җәлилгә һәм хәзерге татар шагыйрьләренәчә сузыла.

Кол Гали әсәренең идея-сәнгатьчә әһәмияте киң мәгънәдә урта гасыр төрки поэзиясен Низами казанышларын үзләштерүгә бик якын китереп җиткерүдән гыйбарәт. Әмма Идел буенда әдәбиятның нормаль үсеше монгол һөҗүме нәтиҗәсендә өзелеп кала. Иң күренекле кешеләрне кырып бетерү, хуҗалыкны, шәһәрләрне җимерү, күчмәләрнең яулап алынган утрак игенче халыкларны изү хисабына эре феодаль империя төзүе һәм аны ныгытуы әдәбият үсешен һәм гомумән мәдәни тормышны бөтен бер гасырга тоткарлый.

Җәмгыятьнең акылы һәм вөҗданы буларак әдәбият бары Алтын Урданың сәяси какшавы шартларында, власть һәм идарәче көчләр таркала һәм җәмгыять үзара ызгыштан интегә башлагач кына, үзенең тулы сәнгать көченә телгә килә. Ханзадәләрнең тәхет өчен талашы, сарай интригалары һәм фетнәләр мәдәни көчләргә дә зур зыян китерә. Җитди борчылуга төшкән әдипләр, тыныч һәм гадел идарә өметләнеп, тыйнаграк һәм сабыррак тоелган тәхет варисларын яклаганнар һәм, кагыйдә буларак, үзләренең яраткан шәхесләре белән бергә аларның мәкерле, кансыз һәм комсыз көндәшләре кулыннан һәлак була килгәннәр.

Әдәбият идеаль үрнәк көче белән дә, үгет һәм мактау белән дә, кырыс һәм ышандыргыч аллегорик кисәтү белән дә монархның вөҗданына һәм гамәленә йогынты ясарга тырышкан, халык алдындагы бурычын аның исенә төшереп торган. Туры сүз һәм гражданлык кыюлыгы еш кына аларга бәла дә китергән. Төрки әдәбиятларда Нәваигә кадәрге чорның иң зур шагыйрьләреннән Котб шулай һәлак булган дип санала. Сәйф Сараи исә Мисырга китәргә мәҗбүр булган.

Шигъриятнең бер гасырлык дәшми торуыннан соң беренче зур әсәр Низаминың иң яхшы поэмаларыннан «Хөсрәү вә Ширин»е нигезендә барлыкка килә. 1342 елда Котб аның иркәле тәрҗемәсен тәмамлый. Әсәр күп ягы белән нәзирәгә, ягъни шигъри ияру һәм ярышка тарта.

Поэмада фарсы шаһы Хөсрәүнең әрмән патшасының кызы Ширингә мәхәббәте сурәтләнә. Төрки шагыйрь тасвирындагы ике образ да фарсы оригиналларыннан аерылмый. Ике персонаж да үзара бертигез гашыйк булып, уртак бәхетләренә төрле юл белән киләләр. Ширин үзенең бөтен һәм саф табигате белән баштан азаккача бер мәхәббәткә тугры кала, игелеге һәм кешелеге белән халкының тугрылыгын казана. Хөсрәү холкының тигез, әзлекле булмавы белән аерыла. Ул хөкемдарлык вазифасын онытып мавыгучан, үзенең халык арасыннан чыккан көндәше — эшчән оста Фәрһадка карата мәкерле. Аның сурәтендә Алтын Урда ханнарының холкы һәм яшәү рәвеше чагылган. Гүзәл һәм гадел Шириннең мәхәббәте аны ниһаять үзгәртә. Әхлакый яктан төзәлеп, сафланып, ул үзенең затлы сөеклесе һәм хатыны Ширингә лаек булып җитә. Әсәрнең ике каһарманы да Хөсрәүнең беренче никахыннан туган хыянәтчел улы кулыннан һәлак булалар. Поэманы шушылай тәмамлап — мондый финал «Йосыф белән Зөләйха»дан башка урта гасырның барлык мәхәббәт поэмаларына да хас — Низами белән Котб феодаль чорның идарә белән чын мәгънәсендәге кеше бәхете сыеша алмаган кырыс чынбарлыгын күрсәткәннәр.

Әсәрнең гуманистик көче шунда: ул мәхәббәтне гаделлек һәм затлы эшләр чыганагы итеп тасвирлый. Каһарманнарның бәхеткә омтылышын Котб халык турында кайгырту белән гармонияле бәйли.

Поэманың тормыш-көнкүреш детальләрендә җирле, төрки колорит көчле. Ул холык һәм гадәтләр бирелешендә дә, көнкүреш реалийләрендә дә чагыла. Мәсәлән, поэмадагы итагать билгесе буларак бүрекне салу болгар этнографиясенә хас. Котбның телендә хәзерге татар теленең Көнбатыш диалекты өчен характерлы билгеләр күп. Бары татар телендә очрый торган сүзләрнең, үзенчәлекле морфологик формаларның (мәсәлән,

фигыльнең **-ырга, -ергә** формасы) күплеге авторны ышанычлы рәвештә Идел буе тел мохитенә бәйләргә нигез бирә.[5]

Котб «Кыйссаи Йосыф»ның теленә һәм шигъри гыйбарәләренә бик нык таяна. «Хөсрәү вә Ширин» текстында Кол Гали поэмасы белән тулысынча тәңгәл килгән яки аларны үстерүче рифмалар, метафоралар һәм бөтен бер юллар бар.

Бигрәк тә рифманың Кол Галидәгечә калуы күзгә бәрелә. Котб «йолдыз» сүзенә берничә урында татар халык җырларына хас булганча «кондыз» рифмасын куллана да бер урында тулысынча Кол Гали рифмасын күчереп ала. Йосыфның атасына төшен сөйләү эпизодында мондый юллар бар:

Дугар көн, тулун ай, унбер йолдыз
Дөшем ичрә сәҗдә кылдый бәңа дөб-дөз
(Туып килүче кояш, тулган ай, унбер йолдыз
Төшемдә баш иделәр миңа төп-төз).

Котбта:

Ул ай табгыйнда йыглыйб монча йулдуз
Тәразу йасый тик булдыйлар түп-түз
(Ул ай каршында җыелып бу чаклы йолдыз
Үлчәү җәясе кебек булдылар төп-төз).

«Хөсрәү вә Ширин»дә мондый мисаллар бик күп.

Төрки фольклордан һәм «Котадгу белек»тән «Кыйссаи Йосыф»кача сузылган язма поэзиягә хас шигъри чараларны Низаминың сәнгатьчә тәҗрибәсе белән органик бергә кушып, Котб урта гасыр төрки поэтикасын аңарчы күрелмәгән биеклеккә күтәрә. Низамидан ул төрки шигъриятькә таныш булмаган катлаулы метафораларны ала да аларны үз халкының сәнгатьчә фикерләвенә яраклы рәвештә үзгәртә.

Котб поэмасының мөһим бер үзенчәлеге шунда ки, аңарда лирик дулкын көчле. Бу башлангычны исә XIV гасырның талантлы лиригы Хәрәзми күтәреп ала. Ул 1353 елда «Мәхәббәтнамә» поэмасында Котбның Хөсрәү, Ширин һәм Фәрһад кебек каһарманнарын тикмәгә генә телгә алмыйдыр. Панегирик поэмасының адресаты булган бәк хатыны каршында ул үзен Ширингә гашыйк Фәрһад белән чагыштыра. Шагыйрь хатын-кыз матурлыгын данлый һәм хөкемдарның юмарт, эшлекле булуын яклый. Әсәрнең панегирик характеры шагыйрьнең ихтыярын нык кына бәйләсә дә, ул гомумгуманистик һәм фәлсәфи әһәмияткә ия. Шагыйрь үзе дә Хәрәземнән чыкканга охшый, моңа аның тәхәллүсе дәлил: «Хәрәзми». Алтын Урда дәверендә бер дәүләт эчендә булып, Хәрәзем белән Идел буе уртак мәдәни һәм әдәби тормышта яшәгән.

Хәрәзми Идел буе төрки поэзиясендә сизелерлек эз калдырган. Сәйф Сараи XIV йөз азагында аның бер шигыренә нәзирә язган. Хатын-кыз сынын тасвирлаган «Рәсем» шигырендә XX йөз башы татар шагыйре Дәрдмәнд Хәрәзминең: «Аның кем ал иңендә миң яратты, сачыны аягына тиң яратты»,— дигән юлларын файдаланган.

XIV йөзнең II яртысында гаять үзенчәлекле шагыйрь, «Җөм-җөмә солтан» дигән сатирик поэма авторы Хөсам Кятиб иҗат иткән. Әсәрнең сюжеты бер патшаның баш сөягенә бәйле тарихтан гыйбарәт. XII йөздә бу сюжетка фарсы суфи шагыйре Фәридетдин Гаттар да язган. Әлеге поэма, Е. Э. Бертельс фикеренчә, Алтын Урда ханнарының сарай тормышын чагылдыра. Анда үткен сатирик формада аларның сарай зиннәте, кәеф-сафада эшсез вакыт уздырулары һәм халыкның мохтаҗлыгына битараф мөнәсәбәте тасвирлана. Фәкыйрь кешенең күңелен калдырган өчен солтан тәмугка элэгә. Шунысы кызык: тәмугның аерым күренешләре Дантенең «Илаһи комедия»сен хәтерләтә. Илаһият, Гайсәнең үтенечен кабул кылып, гаепләрен йолу өчен, Җөмҗөмәне терелтә дә, аңа икенче гомер бирә. Солтан аны суфиларча мәгарәдә гыйбадәт кылып уздыра. Шул рәвешле, фаш итүчән гаять зур көчкә ия материалдан шагыйрь суфичылык рухында нибары үз җанының тынычлыгын кайгырту турында пассив нәтиҗә чыгара. Әмма поэманың конкрет контекстында Кятибның әлеге идея сөземтәсе дә иҗтимагый-фәлсәфи яктан киң гуманистик мәгънә ала, ягъни эшлексез һәм кешелексез хөкемдарлыктан дәрвишлек артык дигән фикер уздырыла. Бу поэма тираннарга, тигезләүчән табигать һәм илаһият (монысы урта гасыр идеологиясе күзлегеннән) каршында аларның бик кечкенә икәнлеген искә төшереп, кырыс кисәтү булып яңгыраган. Әсәрнең керешендә, кайчандыр яшәп, изге яки яман аты чыккан һәм инде күптән туфракка әйләнгән Искәндәр Зөлкарнәй (Александр Македонский), Ануширван, Мәхмүд Газнәви, Чыңгыз хан кебек борынгы хөкемдарларны санап киткән элегик юлларга да тирән мәгънә салынган. Мондый юллар «Хөсрәү вә Ширин»дә

[5] Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979, 106—109 бб.

дә байтак. Поэма каһарманы язмышына кагылышлы рәвештә автор: «Һәркем ирсә нә иксә — ургай ани»,— дигән халык мәкален китерә.

Котб, Хәрәзми, С. Сараи поэмалары Лейден, Париж кебек чит ил китапханәләрендә генә саклanса, Хөсам Кятиб әсәренең кулъязмалары татар халкы арасында бүгенгәчә табылуында дәвам итә. Казанда ул басылып та чыккан. Аның аерым мотивларын, үзенчәлекле рифмаларын һәм гыйбарәләрен Сәйф Сараида, соңрак исә Тукайда очратырга мөмкин.

XIV йөз Идел буе төрки поэзиясенең иң зур казанышы — һичшиксез, Сәйф Сараи иҗаты. Ул 1321 ел тирәсендә туган, 1396 ел тирәсендә үлгән дип санала[6]. Шагыйрьнең үз сүзләре буенча аның туган җире — Камышлы. Урта гасырдагы Идел буенда шул исемдәге берничә шәһәрчек һәм авыл теркәлгәнлеге мәгълүм. Сәйф, шагыйрь буларак Сарай шәһәрендә тәрбияләнгәнгә, тәхәллүсен «Сараи» дип алган. Иҗатының иң мөһим хезмәте булган «Китабе Гөлстан бит төрки» (Төрки Гөлстан) әсәрен ул 1391 елда мәмлүкләр Мисырында язган. Хәзергә шагыйрьнең ике кулъязмасы билгеле: берсе «Гөлстан» текстын, икенчесе «Сөһәйл белән Гөлдерсен» поэмасын эченә ала. Бу әсәрләреннән тыш беренче кулъязмага замандашларының аерым газәлләре, мәснәви һәм робагыйлары белән шагыйрьнең шуларга нәзирәләре, җаваплары һәм унөч газәле теркәлгән.

«Китабе Гөлстан бит төрки» әсәре Сәгъдинең даһи «Гөлстан»ыннан иркәле тәрҗемә булып тора. Төрки шагыйрь бу эшкә, үзе әйтмешли, «зариф галимнәрдән берәүнең» киңәше буенча алынган. Димәк, бу эшкә ул үз чорының олы иҗтимагый һәм эстетик ихтыяҗын тоеп керешкән. Сәгъди әсәре халык массаларының феодализмга протестын чагылдырган. Ул мөселман Көнчыгышындагы барлык алдынгы фикер ияләренең яраткан китабына әйләнгән, бер генә хөкемдар да аңа битараф кала алмаган. Аның төрки тәрҗемәсе Йосыф Баласагунлының «Котадгу белег»еннән соң икенче мөһим вакыйга була. Әмма Сараи әсәренең эчтәлеге җанлырак һәм үтемлерәк, шигъри дәрәҗәсе чагыштыргысыз югары.

Сәйф Сараи урыны-урыны белән «Гөлстан»ны төгәл тәрҗемә итә, урыны-урыны белән фарсыча кисәкләрнең төрки таңгәлен эшли яки бөтенләй оригиналь парчалар иҗат итә. Һәр очракта ул виртуозлык күрсәтә. Төрки телдәге шигырь урта гасыр шартларында мәгънәви тыгызлыкның һәм афористик үткен яңгырашның иң югары ноктасына күтәрелә. Тарихи шәхесләр һәм гыйбрәтле вакыйгалар нигезендә уздырылган идеяләр зур тәэсир көченә ирешкән.

Шагыйрь үз чорының ерткыч хокемдарларын, аларның яулап алу сугышларын гаепли. Мәсәлән, Аксак Тимер һөҗүмнәрен сурәтләгәндә, аның җаны шулай тетри:

Кузутты җаң белән галәмдә туфан,
Акытты су тикин йир үзрә күп кан.
Игенче эүләри йагылдый утка,
Бодай саурылдый, туфрак булдый бутка...
(Кузгатты яу белән дөньяда туфан,
Агызды су тик җир өстендә күп кан.
Игенче өйләре яндырылды утта,
Бодай коелды, туфрак булды ботка).

Сәйф Сараи, Котб сыман ук, үзенең поэзиясендә Көнчыгыштагы материалистик фикернең иң югары казанышларын чагылдыра. Аларның метафора һәм чагыштыруларыннан күренгәнчә, ул чорның алдынгы фикер ияләре шулай уйлаган:

Сөһәйлне күрдиү әйләнди бәр дик,
Гүнәш гәрдендә йөргән йир тик
(Сөһәйлне күргәч әйләнде кош мамыгы тик,
Кояш тирәсендә йөргән Җир тик).

Сәйф Сараи Гөлдерсеннең Сөһәйл тирәсендә бөтерелүен безнең заман өчен гадәти, әмма урта гасыр өчен гаҗәеп чагыштыру аша сынландыра. Моның Коперниктан бер гасырга якын элек әйтелүе мөһим. Котб та «тигмә йолдыз»ның «бер җиһан» булуын яза[7].

Сәйф Сараиның җавап һәм нәзирәләре белән шуларга өлге булган шигырьләр дә теркәп калдырылганга, без аның заманындагы поэзиянең гомуми дәрәҗәсен дә күз алдына китерә алабыз. Бөек шагыйрьнең кулъязмасы белән безгә Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүлә Исхак, Мәүлә Гыймад, Габделмәҗид, Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Туглы Хуҗа һәм Хәсән углының берәр шигыре килеп җиткән. Сәйф Сараи алар белән шигъри ярышта тиңдәшсез оста булып күз алдына баса.

[6] Миңнегулов Х. Ю. Сәйф Сараи (тормышы һәм иҗаты). Казан, 1976, 25—26 бб.; Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары. Төзүче Хатип Госман. Казан, 1981, 170—171 бб.

[7] Миңнегулов Х. Ю. Котб иҗаты. Казан, 1976, 66 б.

# «ТАҺИР БЕЛӘН ЗӨҺРӘ» ДАСТАНЫ

Татар дастаннарын өйрәнү, барлау соңгы елларда шактый җанланып китте. Шуның нәтиҗәсе буларак татар фольклорының дастан жанрына карата яшәп килгән шөбһәле фикерләрнең нигезсезлеге исбатланып килә.

Әш шунда ки, моңа кадәр Идел буе татарларында дастан булмаган, дастан — ул күчмә халыкларга гына хас фольклор жанры дигән фикер яшәп килә иде. Хәлбуки күчмәлек традициясенә килгәндә, дастанның күп гасырлык утрак тормыш алып барган төрек, уйгур, үзбәк һ. б. халыкларда бүгенге көнгә кадәр актив яшәве бәхәснең икенче өлешен уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә. Соңгы елларда чыккан «Дастаннар» җыентыгында[1] Себер татарларыннан язып алынган дастан үрнәкләре белән рәттән Идел буе татарларыннан җыйналган дастаннарның дистәләрчә үрнәкләре бар. Аларның күбесе мәхәббәт дастаннары. Идел буе татар дастаннары арасында «Йосыф белән Зөләйха», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә» сюжетлары күп таралган. Аталып киткән дастан сюжетлары халык тарафыннан сөелеп сөйләнгән, язма рәвештә таралган һәм аларның кулъязмалары сирәк булса да археографик экспедицияләр вакытында хәзер дә табылып тора. Соңгы елларда археограф-галим Миркасыйм Госманов «Түләк-Сусылу дастаны» кулъязмасын тапты[2]. Әлеге дастанның бер кулъязмасы язучы һәм галим Нәкый ага Исәнбәттә саклану хакында да хәбәр бар.

Яңа табылган татар дастаннары кулъязмаларыннан «Таһир белән Зөһрә» дастаны нөсхәләрен дә күрсәтергә мөмкин.

«Таһир белән Зөһрә» дастаны сюжеты татар халкы фольклоры һәм әдәбиятында ерак гасырлардан бирле яшәп килә. Әдәбият галимнәре тарафыннан аның иң иске версиясе итеп «Бабахан дастаны» күрсәтелә[3]. Зур күләмле бу дастанның татар әдәбиятына ясаган тәэсире хакында ныклы тикшеренүләр эшләнмәгән әле.

1876 елда күренекле татар шагыйре Әхмәт Уразаев-Курмаши бу сюжетны яңадан эшләп, халык арасында бик популяр булган «Таһир илә Зөһрә кыйссасы»н язып, бастырып чыгара. Археографик экспедицияләр вакытында Курмаши әсәренең берничә кулъязма нөсхәләре табылды. Курмаши әсәре тәэсирендә казах акыны Акылбек Сабилов, «Таһир-Зөһрә» дастанының яңа вариантын иҗат итеп, 1911 елда Казанда бастырып чыгара[4]. Дастанның үзбәк, уйгур һ. б. халыклар арасында таралган вариантлары да мәгълүм.

«Таһир белән Зөһрә» дастанының соңгы елларда моңарчы билгесез булган версиясенең ике кулъязмасы мәгълүм булды. Аларның беренчесе һәм тулы текстлысы, 1973 елда, шушы юлларның авторы тарафыннан Татарстанның Арча районы Яңа Мәңгәр авылында Хәсбиуллина Фатиха (1903 елда туган) биргән китаплар арасыннан табылды.

Икенче, тулы булмаган нөсхә, И. Гыйләҗев тарафыннан 1984 елда шул ук Арча районы Ишнарат авылында Хәйруллина Факиядән (1901 елда туган) алынган кулъязмалар арасыннан ачыкланды.

Яңа Мәңгәр кулъязмасы: иске татар телендә язылган төрле хикәятләрдән һәм мөселман әхлагы йолаларын өйрәтә торган җыентык. Дастан кулъязманың 5—9 кәгазьләренә язылган, җыентыкның 46 бите ахырында аның язылу урыны хакында: «...фи карья-и Бәрәскә, фи мәдрәсә-и мелла Бикчәнтәй бине мелла Ибраһим бу китапның иясенә һәр заман син гыйнаять әйләгилйа...»— дигән мәгълүмат бар. Кулъязмада искә алынган авыл — Татарстанның хәзерге Арча районы, Бәрәскә авылы. Андагы

---

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984.

[2] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Казан, 1984, 180—238 бб.

[3] Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963, 249—334 бб.

[4] Гашыйк-намә. Алматы, 1979, 460 б. (казах телендә).

мәдрәсәнең мөдәррисе Бикчәнтәй бине Ибраһим Байлар Сабасы авылы кешесе, 1775—1801 елларда (ягъни үлгәнче) Бәрәскәдә дәрес әйткән. Димәк, җыентык шушы елларда төзелгән, яки күчерелгән. Язуы гарәп графикасының нәстәгълик төре белән язылган.

Икенче кулъязма барысы ике кәгазьдән генә гыйбарәт. Язуы бозык тәгълик, текст кызгылт кысалар эченә алынган. Кулъязманы шулай ук XVIII гасырның соңгы чирегендә язылган дип карарга мөмкин. Аның беренче битендә дастанның баш өлеше, икенче битендә Зөһрәгә ак сакаллы пирнең төшендә гөл бирү вакыйгасы тасвирлана.

Икенче кулъязмада дастаннан өзекләр генә булса да аның ярдәмендә әсәрнең XVIII гасырда халыкта яшәеше хакында кайбер мәгълүматлар алырга мөмкин. Гомумән алганда аермалар зур түгел, ләкин әһәмиятле. Ишнарат кулъязмасында Таһир исеме бер урында Бикtаһир дип атала. Яңа Мәңгәр вариантында андый очрак юк. Шул ук вариантта Карачумак, патша вәзиренең исеме, ә тулы вариантта вәзирнең улы шулай дип атала һ. б.

Бу фактлар XVIII йөздә үк Казан артында дастанның вариантлар формасында актив яшәвен раслыйлар. Текстларны күзәтү тагын бер фикергә этәрә: язуга ул кыскартыбрак беркетелгән.

Дастанның теле татар теленең урта диалектына хас үзенчәлекләргә ия. Мәсәлән, дәрья сүзен һәр ике кулъязмада дәрҗә формасында җ-лаштырып бирелгән. Текстта татар теленә генә хас булган кузна, сага, тәрәзә, ишек, чарагъ, тал, таян һ. б. сүзләр шактый очрый. Кыскасы дастанның тел үзенчәлекләре махсус өйрәнелүгә лаек.

Текстны басмага хәзерләгәндә публикация характерын исәпкә алып, аның орфографиясе бераз җиңеләйтелеп, бүгенге татар теле нормаларына якынайтылып бирелде. Бу үзгәрешләр фигыль формаларын бирүгә һәм кайбер фонетик үзгәрешләр кертүгә кайтып кала. Алар түбәндәгеләр: бардур — бардыр, баруб — барып, белүр — белер, ирди — ирде, ирмәсмү — ирмәсме, керүб — кереп, килтүрди — килтерде, килүб — килеп, кыйлдый — кылды, кыйлуб — кылып, нә — ни, сүвенчи — сүвенче, тиб — дип, тиди — диде, торур — торыр, әйди — әйтте, әйтти — әйтте. Кыскасы, фигыль формантлары -и, -е, -дур, -дыр, -тыр, -үб, -еп, -үр, -ер үзгәртелеп алыналар.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ТАҺИР БЕЛӘН ЗӨҺРӘ

*(Яңа Мәңгәр кулъязмасы)*

## ХИКӘЯТ

Озак кичкән заманда бер падишаһ бар ирде.

Көн язылaнда, сохбәт кылып ултыруда ишекдин бер вәзир кереп: «Сүвенче, падишаһым!»— дип агаз кылды. Падишаһ әйтте: «Бунчә сүвенчедер?»— диде. Вәзир әйтте: «И падишаһым, хатыныӊ угыл тугырды!» Падишаһ әйтте: «Ир угланмы, йә кыз угланмы?» Вәзир әйтте: «Кыз угландыр!»— диде. Падишаh сор/а/ды: «Аты ни торыр?» Вәзир әйтте: «Аты — Зөһрә дип атадылар!»

Ул сохбәттә бер вәзир бар ирде. Ул вәзир әйтте: «Минем хатыным углан тугырды, исеме — Таһирдыр»,— диде. Ул падишаһ илән ул вәзир дуст ирде. Падишаһ әйтте: «Баргыл, углыңны алып килгел! Икесе бер ивдә торсынлар, бер бере илә мәхәббәт — дуст булсынлар!»— диде. Ул вәзир барып углыны килтерде. Икесе бергә уйгайдылар, бер мәктәпкә бардылар. Көнләрдән бер көн, аллаһе тәгаләнең боерыгы берлән, Таһир атасы — вәзир үлде. Такы бер вәзире бар ирде. Аның бер углы бар ирде. Аты Карамуч атлыг ирде. Зөһрәне аңар ярәштеләр.

СҮЗЛЕК:

*Озак кичкән заманда* — *борынгы заманда.*
*Көн язылaнда* — *көн туып килгәндә.*
*Сохбәт кылып* — *җыелып сөйләшеп.*
*Агаз кылды* — *хәбәр бирде.*
*Бунчә* — *нинди.*
*Ивдә* — *өйдә.*
*Уйгайдылар* — *уйнадылар.*
*Такы* — *тагы.*

Бер көн Таһир берлән Зөһрә сабакдин килә торганда, угланлар кузна уйнар ирделәр. Таһирның бер алтын сагасы бар ирде. Ул сага берлә кузнаны атып сукты. Кузна очып китте. Барып бер карчык чарагына тигде. Чарагъ парә-парә булды. Ул карый зәгыйфә әйтте: «И, Таһир, Карамуч Зөһрәне ярәшкәчен, бикәчеңне алганга офтанмай, минем чарагымны бозарсын»,— диде. Таһир аны ярәшкәнин белгәне юк ирде. Таһир әйтте: «И, карый зәгыйфә, Зөһрә бәнем карендәшем ирмәсме?»— диде. Карый зәгыйфә әйтте: «Карендәшең ирмәс, инанмас ирсәң, даясындин сорагыл!« Таһир килеп даясындин сорады ирсә, даясы әйтте: «Тачин торыр!»— диде. Андин килеп Таһир Зөһрә яңакыдин бер пүсә алды. Зөһрә әйтте: «И, Таһир, син минем карендәшем ирмәсмесән?» Таһир әйтте: «Юк, синең атаң берлә минем атамның шарты бар иркәндер. Имди, минем атам үлгән сәбәпдин, сезне Карамучка бирделәр»,— диде ирсә, Зөһрәнең Таһирга мәхәббәте бер-беренгә андаг булдыкем, һич тәгъриф итсә, булмас ул мәхәббәтлек уен.

Зөһрә атасыйга әйтте: «И, ата, миңа сув якасында бер сарай салгыл!»— диде. Атасы Зөһрәгә бер сарай ясатты, вә сыйфат итсә, булмас. Таһир берлә Зөһрә ул сарайда ултырдылар. Карамуч Зөһрәне көнләп, барып атасыйга әйтте: «Йа, ата, Зөһрә кичә — көндез Таһир берлә ятыр, миңа корыг сәламәт салыр»,— дип әйтте. Вәзир барып падишага бу сүзне әйтте. Падишаһ каһәр кылып әйтте: «Барыңлар, Таһирны алып килеңләр!» Вәзирләр Таһирны килтерделәр. Кыз белмәс, көлә-көлә калды. Таһирны падишаһ үлтермәккә әйләп, бер көндән сандыкка салып йибәрде, агыздылар.

Ул сандык Зөһрәнең сарае төшендә торды. Таһир әйтте: «Йа, раббел-галәмин, Зөһрә сарае төшендә миңа мөддәт биргел!»— дип ходай гыйззе вә җәлгәналыш кылды. Сарай төбендә сандык торды. Кыркынлар әйттеләр: «Йа, Зөһрә, атаң Таһирны сандыкка салып сувга йибәрде»,— диде ирсә, дәрҗә түшендә бер сандык бар, аваз килде, Таһир еглап мондаг әйтте:

Бәет.

Һавадин болыт күчәр һай,
Уйкум күземдин очар һай,
Залим Таһирны күрең һай,
Зөһрәсин салып качар һай.
Кил һай, сүвгән ярым һай,
Бер вафа сүвдем сине, сүкмә мине һай.
Кара сандык эчендә һай
Таһир ничек ятырсың минсез һай.
Күшекеңдин уя бак һай,
Тәрәзәңдин бире бак һай,
Мин хуҗам, актым-киттем һай,
Син күшкеңне утка як һай.
Күшекеңдин төшәең һай,
Вилаятьдин чыкаең һай,
Йөзең ачгыл, күрәең һай,
Мин Таһир, дидар күреп калаен һай.
Күшкең яны тал имди һай,
Чыка талга ҭаян имди һай,
Мин хуҗам актым-киттем һай,
Зөһрә, син хуш кал имди һай!

Зөһрә буны ишетеп әйтте янә:

Бәет

Сув акар анчалаен һай,
Яр юктыр минчәләен һай,

СҮЗЛЕК

*Сабакдин килә* — укудан кайта.
*Сага* — кузна уйнаганда суга торган махсус таяк.
*Чарагына* — савытына.
*Карый* — карт кеше, бу очракта карчык.
*Ирмәсме* — түгелме.
*Даясындин* — тәрбияче хатын-кыз(дан).
*Тачин торыр* — нәкъ шулай, тач шулай.
*Бер пүсә алды* — бер үбеп алды.
*Андаг* — шундый.
*Тәгъриф итсә* — аңлатырга теләсә.
*Сув якасында* — су кырыенда, яр буенда.
*Төшендә* — турысында.
*Раббел-галәмин* — алла.
*Мөддәт* — вакыт.
*Гыйззе вә җәл* — кодрәтле вә шанлы.
*Налыш кылды* — елап ялварды.
*Кыркынлар* — хезмәтче кызлар.
*Дәрҗә* — дәрья.
*Түшендә* — өстендә.
*Мондаг* — моны.
*Уйкум* — йокы.
*Салып качар* — ташлап качар.
*Бер вафа* — сүземдә торып.
*Күшек* — җәйге ял өчен корылган зиннәтле сарай.
*Уя бак* — уйсу җиргә, суга кара.
*Дидар* — йөз.
*Анчалаен* — шуның кебек.

Синдин үзгә яр тотсам һай,
Пычакка санчеләен һай.

Зөһрә бу бәетне әйткәч, Таһир сандыкы китте. Адәм йөзен күрмәгән кыз төшеп Таһирның ардынча йөгерде. Кыркынлары бергә бардылар. Таһир гаиб булды. Зөһрә Таһирны күрмәде. Таһир кызны күрмәде, еглады.

Йоклады ирсә, бер ак сакаллыйг кем ирсә, Зөһрәнең кулыйга бер гөл бирде, нәкый үзе гаиб булды. Кыз уйганды. Зөһрә әйтте:

Бәет

Ак сакаллыйг пир килде һай,
Кулымга бер гөл бирде һай,
Мин Таһирга йөгердем һай,
Кызлар, Таһирны тәңре бирде һай.
Килең кызлар, китәлем һай,
Күшкемезгә йитәлем һай,
Таһирның дәрде көчлүктер һай,
Кил, барчамызга өләшәлем һай.

Зөһрә даялары берлә сарайга бардылар, ултырдылар. Шат булып гөлне кулыйга алды.

* * *

Андин соң Таһир акып килә йөрүгәндә йәнә бер падишаһның кызы бар иркән, нагяһ дәрҗә төбендә бер сандык бар, даяга әйтте: «Барып ул сандыкны алып килтереңез!»— диде. Даялар сандыкны алып килделәр. Сандык агыр торыр, эчендә мал йә торыр дип, кыз атасыйга йибәрде ирсә, атасы әйтте: «Бу сандык эчендә һәр ни чыкса, кызымга булсын!»— диде. Кыз такы сандыкны ачып бакты ирсә, танә гүзәл зиба, падишаһ сыйфат, йөзе ай кебек егет чыкты. Кыз бу егетне күрде ирсә, ихтыярсыз гашыйк булды, гакылы заил булды. Даялары Таһирның йөзенә гөл сувы сибеп уйгаттылар. Үз гакылына килде ирсә, кыз Таһирны атасыйга йибәрде. Атасы һәм гашыйк булды. Андин падишаһ әйтте: «Кызыма, бу егетне үзенә никах кылырмын?»— дип йибәрде. Кыз әйтте: «Бәй, кабул кылырмын»,— диде. Җан вә баш буилә падишаһ кызны Таһирга никах кылды. Таһир ул кыз берлә никах хозур кылдылар. Мескин Зөһрә ни кылыр.

* * *

Көннәрдән бер көн Зөһрә мескин Таһирның гаме берлән ултырыр ирде. Таһир торган шәһәрдән бер кәрван килде. Бер көн кәрванлык кылып йөрер ирде. Ул кәрван Таһирның эшен белер ирде, Таһир әйтеп ирде. Зөһрә мескен Таһир гаме берлә ултырыр ирде. Ул хәлдә, дәрҗә төбендә, ул кәрван килеп буны әйтте:

Бәет

Ул җандин килдең морадым һай,
Кем белер минем дәрдем һай,
Яна-яна көл булдым һай,
Зөһрә асманга чык күрем һай.

Бәет айганны ишетеп, Зөһрәнең гакылы заил булды. Бер замандин соң үз гакылына килде ирсә, даяларына әйтте: «Ташкару бер кеше бар, алып кереңез!»— диде. Даялары чыкып бактылар ташкару, бер кеше бар торыр, әйттеләр: «И, егет, сезне падишаһ

**СҮЗЛЕК**

*Ардынча* — артыннан.
*Гаиб булды* — югалды.
*Нәкый* — катнашмый, сөйләшми.
*Пир* — борынгы татар ышанулары буенча яхшылык теләүче образ.
*Нагяһ* — көтмәгәндә.
*Танә* — таң калырдай.
*Зиба* — зифа.
*Заил булды* — югалды.
*Асманга* — күккә, күк йөзенә.
*Айганны* — әйткәнне.
*Ташкару* — тышта.

кызы Зөһрә өндәюр диделәр ирсә, рәван Зөһрә янына керде. Зөһрә әйтте: «И, кәрван/чы/, һич йирдә бунуң кеби сув якасында сарай күрдеңме?»— диде. Кәрванбашчы йир үбеп, догалар кылып әйтте: «И, падишаһзадә Зөһрә, бу сарай кеби сарай кайда булгай, вә ләкин, сув якасында, безем илдә бер сарай бар, падишаһ кызының. Бер көн падишаһ кызы сувга бакып утырыр ирде, дәрҗә төбендә, сув якасы өстендә бер сандык бар ирмеш. Ул кыз сандыкны даяларына йибәреп, атасыйна йибәрде ирсә, атасы әйтепдер: «Бу сандыкдин һәр ни чыкса, кызымга булсын!»— дипдер. Кыз сандыкны ачып бакты. Эчендән бер зиба егет чыкыпдыр. Имди, ул кызны ул егеткә бирделәр. Ул берлә егет хозурда торыр. Халаеклар тәгажҗебдә торыр дип»,— әйтте. Зөһрә кәрванчыдин бу сүзи ишетте ирсә, гакылы заил булды. Даялары Зөһрәнең йөзенә гөл сувы сибеп уйгаттылар. Үз гакылына килде. Андин соң йөзенә гөл сувы сибеп, адәм йөзен күрмәгән пәрдәсен ачып кәрванчыга әйтте: «И, егет, ул илгә барырмысән?» Кәрванчы әйтте: «Бәли барырмын!— диде. Әгәр ул илгә барсаңыз, мин сезгә бер тивә бирәен. Ул тивәнең бер ялы, теләгәнең булсын. Ул тивәне үзең берлә алып барып, ул Таһир торган сарай дәрҗә төбендә бу бәетне Таһирга айгыл. Әгәр, Таһир бу бәеткә яхшы җавап итсә, тәнкәне алыпсыз, тивәне аңа биреңез. Тивә үзе барган юлны кайыра, үзе табар»,—диде. Кәрванчы йир үбеп кабул кылды. Андин соң кәрванчы юлга төште. Зөһрә үз хәле берлә еглаю калды. Тивә берлә очты кош тик, мәгәр дигәйсен канаты бардыр. Кәрванчы Таһир торган сарай дәрҗәсе төбендә торып, Зөһрәнең бәетене әйтте:

### Бәет

Хикмәт каршыдан искән йилләр һай,  
Сагмы икән безнең илләр һай,  
Ничек ядындин китсен һай,  
Зөһрәнең нечкә билләре һай,—

дип әйтте ирсә, Таһир биһуш булып егылды. Таңа калды, такы аңа каршы әйтте:

### Бәет

Тиңездән искән йилләр һай,  
Сагмы икән безнең илләр һай,  
Ничек ядымдин китәр һай,  
Талым — Зөһрәнең нечкә билләре һай,—

дип Таһир әйткәч, кәрван тивәне Таһирга бирде, әйтте: «Тивәне сезгә Зөһрә йибәрде, килсен диде». Таһир әйтте: «Мин юлны ничек табаен?»— диде. Кәрван әйтте: «Тивәне үз ихтыярига куйса, юлын үзе табар!»— диде. Таһир кереп йаясен-укын кулыйга алды. Кыз Таһирның кулыйга йапышты, әйтте: «Кайда барырсын?»— диде. Таһир кызның сүзенә җавап әйтте:

### Бәет

Китәлем юлым ирмеш һай,  
Гакылым тулы имеш һай,  
Кил син, төрекмән кызы һай,  
Әманәт сүвдем сине һай,  
Сүкмә мине һай,—

дип әйтте ирсә, кыз атасыйга хәбәр йибәрде ирсә, атасы вәзирләре берлән килде, әйтте: «И, Таһир, кайда барырсан?» Таһир әйтте:

*Өндәюр* — *чакырыр.*  
*Ирсә* — *исә.*  
*Рәван* — *юлаучы.*  
*Бакып* — *карап.*  
*Тәгаҗҗебдә* — *исе китеп.*  
*Бәли* — *әйе, дөрес.*  
*Тивә* — *дөя.*  
*Бер ялы* — *хакы.*  
*Айгыл* — *әйт.*  
*Еглаю* — *елап.*  
*Сагмы* — *саумы.*  
*Ярыңдин* — *күңлеңнән.*  
*Биһуш* — *һушсыз.*

Бәет

Барырмын күчә берлән һай,
Күчәнең эче берлә һай,
Мине баглап салмаңыз һай
Җаным бу ярның саче берлә һай
Барырмын, юлым төздер һай,
Кичә миңа көндездер һай,
Барып ярга, ул әйткел һай,
Җаным Зөһрәм ялгыздыр һай,—

дип әйткәнен ишетте ирсә, падишаһ вәзирләре берлә киңәш кылып һич гыйлаҗын тапмадылар, әйттеләр: «Китәрмен дигәнне һич кеше туктата белмәс!»— диде ирсә, кыз әйтте: «Аңланып, бу көн минем янымда улсын!— диде.— Таңла үзе белер»,— дип әйтте:

Бәет

Буең будылар бәндәй һай,
Сачең дарьялары бәндәй һай,
Син бу йирдә улмандыр һай,
Залимсез син, аякым бәндәй һай.

Кызның яңакындин үбеп, күңлен хуш кылып, таң берлә юла төште, тивә берлә китте. Барып Зөһрәнең шәһәренә йитеште.

Нагяһ, Зөһрә, гамь берлә булып, Карачумак[5] килмәсен дип, ишекне баглап торыр ирде. Таһир килеп ишекне какты ирсә, Карачумак дип, ишекне ачмады ирсә, Таһир әйтте, минем килгәнемне хәлифә белмәсә яхшыракдыр дип куркып әйтте:

Бәет

Зөһрә ятыр тәхеттә һай,
Килдем сәхәр вакытта һай,
Чарлап аваз бирмәде һай,
Залим Таһир, вакытында һай,—

диеп айганып ишетеп, Зөһрә сөвенеп ишекне ачды. Таһир керде. Зөһрә катыйга кергәч, җан-тел берлә ушбуны әйтте:

Бәет

Инеп килдем тагыңдин һай,
Бер гөл өздем багыңдин һай,
Сусадым, сув теләдем һай,
Зөһрә кырмызый дутагыңдин һай,
Сув акар гөлдер-гөлдер һай,
Яңакың кызыл гөлдер һай,
Тотгыл авызың, үбәем һай,
Таһир аерылганы азмыдыр һай,
Эстәдекем гөл имәсме һай,
Вакыты йитсә сулмасмы һай,
Ни куркырсын атаңдин һай,
Кыз-углан, яр тотмасмы һай,
Торгыл буең күрәен һай,
Килтер агзың үпәем һай,
Син ди-ди үләрмен һай,
Йөрәкигә даг куяем һай,
Китәр йә гаклың китәр һай,
Үпмәгә мохтаҗ итәр һай,
Синең үпмәкең булса һай,
Минем йә гаклым нитәр һай.

Таһир Зөһрәнең яңакыдин үбеп кочты. Такы икесе сохбәт иттеләр. Мәгәр ай көнгә кушылды көн, сәддин мәхәббәтләр ирде. Көннәрдә бер көн ул хәрами монафикълар барып, бу эшләрне белеп, Карачумак

СҮЗЛЕК

*Күчә — урам, юл.*
*Гыйлаҗен — эмәлен.*
*Таңла — таңда.*
*Нагяһ — вакытсыз, көтмәгәндә.*
*Сәхәр — таң.*
*Катыга — каршына.*
*Инеп — үтеп.*
*Тагыңдин — тавыңнан.*
*Багыңдин — бакчаңнан.*
*Сув — су.*
*Кырмызый дутагыңдин — янып торган кызыл иреңеңнән.*
*Эстәдекем — теләгәнем.*
*Имәсме — түгелме.*
*Даг — дәва.*
*Сәддин — инсафлы.*
*Монафикълар — әчкерле кешеләр.*

[5] Текстта Карамучны шулай Карачумак дип кителә.

атасыйга хәбәр бирде. Атасы барып падишаһка әйтте. Падишаһның хаты килде. Әйтте, җәлладларга боюрды: «Барып, алып чыкып үлтерегезләр!»— диде ирсә, җәлладлар бардылар ирсә, икесе шәрап эчеп ултырыр ирде. Таһирны якасыйндин тотып чыктылар. Зөһрә көлә-көлә калды. Таһирны алып бара торганда бер нигяр кылады ирсә, Таһир падишаһның йөзен күрмәк теләде ирсә, җәлладларга әйтте: «Мине бабам катыйга илтеңләр!»— диде. Падишаһ янына илттеләр ирсә, Таһир әйтте:

Бәет

Агачның очы — койрыкы һай,
Ходайдин булыр бойрыкы һай,
Мин Зөһрәне сүвдем һай,
Башыма тигде бабам йомрыкы һай.

Кара куйның янбашы һай,
Яңа айның унбише һай,
Мин ни сәбәпдин сүккәнле һай,
Бабам, унбиш-уналты яши һай?

Падишаһ бу бәетне Таһирдан ишетте ирсә, җәлладларга әйтте: «Парәләңләр, һәр парәсен бер дарга асың»,— диде. Җәлладлар Таһирны үлтерделәр, шәһид булды. Такы һәр парәсен бер дарга астылар.

Зөһрәнең даялары еглап килеп Зөһрәгә әйттеләр: «Таһирны падишаһ каһәр итеп үлтерде, һәр парәсен бер дарга асып куйдылар»,— дип әйттеләр ирсә, Зөһрә ике әлегә ике пычак алып, адәм йөзен күрмәгән кыз кубып, баш ачып, ялаң аяк, ялаң баш зар-зар аглады ирсә, галәм халкы барча еглады. Зөһрә җәлладларның берсен үлтерде. Падишаһ әйтте: «Яныма йибәреңләр!»— диде. Зөһрә падишаһның катыйга керде. Такы Зөһрә әйтте бер бәет:

Бәет

Бер гариб башың өчен һай,
Кыярсаң минем өчен һай,
Таһирны үптем-кочтым һай,
Коч кызый корбан өчен һай.
Ни солтанлык, ни ханлык һай,
Бабам, юк сездә мөселманлык һай,
Катар-катар тыйгалар һай,
Катарлар, шаех үтәрләр һай.
Базарда итме төкәнде һай?!
Бабам Таһирның итен эстәр һай.

Такы Зөһрә әйтер ирде, Таһир синдин үзгә яр тотсам пычакка санчеләен, дип гайрәт иткән ирде. Ул сәбәпдин Зөһрә Карачумакны һәм үзен пычакка орды-үлтерде.

Андин соң Таһирны кабергә куйдылар. Карачумакны Таһир берлән Зөһрәнең арасыйга куйдылар. Таһирның каберегә бер гөл чыкып, Зөһрә каберенә йәнә бер гөл чыкты. Бу ике гөлләр чыкып, икесе бербергә кушылдылар.

Карачумак каберендин бер тигәнәк чыкып, бербергә явыклады. Халаеклар тамаша кылдылар. Карачумакны каберендин чыкарып, үзгә йиргә килтереп күмделәр.

Ул икесе бер-беренә кушылдылар. Барча кеше таңладылар.

Андин соң падишаһ әйтте: «Үз углым тик асраганны, үзем үлтердем»,— дип, күп казгырды, үзе һәм үлде.

СҮЗЛЕК

*Нигяр кылады ирсә* — *сурәт ясыйсы килеп.*
*Сүвдем* — *сөйдем.*
*Тигде* — *тиде.*
*Йомрыкы* — *йодрыгы.*
*Парәләңләр* — *кисәкләргә чабыгыз.*
*Каһәр итеп* — *җәзалап.*
*Әлегә* — *кулына.*
*Аглады* — *елады.*
*Кыярсаң* — *кисәрсең.*
*Катар* — *рәт.*
*Тыйгалар* — *тыюлар.*
*Төкәнде* — *бетте.*
*Явыклады* — *якынлады.*
*Казгырды* — *кайгырды.*

Ул ике гашыйк ахирәттә кушылды. Бу дөньяда дустлыгы булса, ахирәттә һәм бер-беринә кушылыр, димешләр.

*Тәммат — тәмам — бетте.*

*Тәммат — тәмам.*

# ТАҺИР БЕЛӘН ЗӨҺРӘ

*(Ишнарат кулъязмасы)*

...падишаһ әйтте: «Ир угланмы?— диде,— йә кыз угланмы?»— диде. Вәзир әйтте: «Кыз угландыр!»— диде. Падишаһ сорады: «Аты ни торыр?» Вәзир әйтте: «Аты — Зөһрә дип атадылар!» Ул сохбәттә бер вәзир бар иде. Ул вәзир әйтте: «Минем хатыным угыл тугырды, аты Биктаһирдыр»,— диде. Ул падишаһ илән вәзир дуст ирде. Падишаһ әйтте: «Баргыл, углыңны алып килгел, икеси бер ивдә торсыннар, бер-берлә мәхәббәт дуст булсыннар!»— диде. Ул вәзир барып углыны килтерде. Икеси бергә уйгайдылар, бер мәктәпкә бардылар.

Көнләрдә бер көн аллаһе тәгаләнең боерыгы берлә Таһир атасы — вәзир үлде.

Такы бер вәзир бар ирде. Аты Карачумак атлыгъ ирде. Зөһрәне аңар йәрәштеләр. Бер көн Таһир берлә ...

2 бит.

Кызлар, Таһирны тәңре бирде һай,
Килең кызлар, гөнаһым һай,
Күшкемезгә йитәлем һай,
Таһирның дәрде көчлүдер һай
Кил барчамызга ө/лә/шәлем һай

Зөһрә даялары берлә сарайына бардылар, ултырдылар. Шат булып гөлне кулыйга алды.

Андин соң Таһир акып килә йөрүгәндә йәнә бер падишаһ кызы бар иркән. Нагяһ дәрҗә төбендә бер сандык бар. Даяларыга әйтте: «Барып ул сандыкны алып килтерүңез!»— диде. Даялары сандыкны алып килделәр. «Сандык агыр торыр, эчендә мал бар торыр»,— дип, сандыкны кыз атасыйга йибәрде ирсә, атасы әйтте: «Бу сандык эчендә һәр ни чыкса, кызымга булсын!»— диде. Кыз такы сандыкны ачып бакты ирсә, данә гүзәл зиба, падишаһ сыйфат, йөзе ай кеби егет чыкты. Кыз бу егетне күрде ирсә, ихтыярсыз гашыйк булды, гакылы заил булды. Даялары Таһир...

.................

## Рашат Низамиев

### Кояш кайчан йоклый?

Ни хикмәттер: кояш көн дә
Бездән иртә уяна.
Уяна да ефәк нурын
Сибә башлый дөньяга.

Җилләрне һәм болытларны
Кырдан-кырга чаптыра.
Ә үзенең ике бите
Яктырганнан-яктыра.

Безнең белән уйнарга да
Вакыт таба — су керсәк.
Аркабыздан сөеп кала
Ярдан аска сикерсәк...

Тирләп-пешеп көннәр буе
Басуларны кыздырды,
Әнкәй мичкә яккандагы
Эсседән дә уздырды.

Йокламый кояш. Бездән ул
Китеп кенә торачак —
Җирнең икенче яртысын
Нурга коендырачак...

### Буранда үсә кыяр

Колакларны чеметә җил,
Тышта буран котыра.
Ә кыярның сабаклары
Чәчәк атып утыра.

Теплицаның ишегеннән
Җәйгә атлап кердем мин.
Бүрекләрне салган килеш
Рәхәтләнеп йөрдем мин.

Безнең әнкәй теплицада
Яшел кыяр үстерә.
Кыярларның симезлеген
Күрсәгез иде менә!

Сабаклары өскә кадәр
Ничек менгән үрмәләп?
Түтәлләргә су сибәбез
Әнкәй белән бергәләп.

Шаян буран көткән әнә
Өйгә кайтыр чагымны:
Кыяр исе аңкып торган
Кулларыма сарылды...

## Хәерле юл!

Безнең авыл кырыенда,
Күрче, нинди яңарыш:
Уң ягында йортлар калка,
Сул ягында — яшь арыш.

Автобуска төялешеп
Килә эшче абыйлар.
Иң зур йортның түбәсенә
Кызыл әләм кадыйлар.

Безнең авыл кырыеннан
Башлана зур киләчәк —
Атом дигән тылсымлы ут
Илгә якты бирәчәк.

«ВАХТА» дигән сүзен укыйм,
Китеп бара автобус...
Яратып эндәшәм аңа:
— Хәерле юл, вахтобус!

## Рәсем ясаганда

Кулымда — пумала. Мин аны
Манчыймын төсләрдән төсләргә.
Күрегез: ямь-яшел яфраклар
Талпына үсәргә, үсәргә.

Тылсымлы хәрәкәт ясагач,
Каршымда яңа көч ачылды:
Тургайны күтәргән күкләрем
Тоташтан зәңгәргә манчылды.

Сары төс. Мин аны яратам —
Кояшның үзе күк ягымлы.
Батырлар кабере өстендә
Кып-кызыл чәчәкләр кабынды.

Монысы — дәһшәтле ракета,
Аһ, нинди куркыныч кашлары...
Сыздым да аркылы-торкылы,
Мин аны чүплеккә ташладым!

## Йоклый кырда кибәннәр...

Белмим, безнең басуларга
Каян килеп чыккан ул —
Тау кадәрле динозавр!
Башын көрткә тыккан ул.

Туңып калган гәүдәсенә
Карлы бозлар эленгән.
Әллә кунакка килгәнме
Туң гасырлар иленнән?

Кояш астында җылынгач,
Кыймылдап алыр кебек.
Койрык сукса, кар диңгезен
Урталай ярыр кебек.

Иң өстемдә — агач мылтык...
Кышның якты көнендә
батыраеп йөрим шулай
Динозавр өенендә.

## Февраль

Түбәгә җиткерде көртләрне,
Лапаска качырды этләрне.

Инешләр-елгалар боз гына,
Урамда җил-буран сызгыра.

Калтырый сыерчык оясы, —
Кар белән тулгандыр дөньясы.

Бакчада шырылдый саескан,
Көн инде язларга авышкан.

Абага-абага урманнар
Йөзләрен кояшка борганнар.

Усал кыш күтәрер чаңгысын,
Песнәкләр җырында — язгы чың!

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

20 январьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышы булды. «Иҗат секцияләренең эше турында» отчет белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары Р. Хәмид чыкты.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар: М. Хәсәнов, А. Гыйләҗев, Р. Ишморатова, Р. Мостафин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Гатауллин, М. Галиев һ. б. чыгыш ясап, иҗат секцияләре алдында торган кичектергесез проблемалар турында сөйләделәр, иҗат эшләрен яхшырту мәсьәләләренә тукталдылар.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

4 февральдә Әлмәт шәһәрендә «Яшьләргә — кайгыртучанлык һәм таләпчәнлек» девизы белән зона конференциясе уздырылды. Татарстан Язучылар союзы идарәсе, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм Әлмәт язучылар оешмасы тарафыннан оештырылган бу конференциядә Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Җәлил һәм Сарман иҗат берләшмәләре вәкилләре катнашты.

Конференциядә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин доклад белән чыкты.

Аннары конференциягә килүчеләр секцияләргә бүленеп эшләделәр. Секцияләрдә язучылар: И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Кутуй, К. Кәримов, М. Галиев, Ә. Мушинский, Р. Мингалимов, Н. Гыйматдинова, Х. Гайнетдинов, Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Ә. Гаффар чыгыш ясады.

Язучылар Әлмәт районында иң алдынгы хуҗалыклардан саналган Токарликов исемендәге совхозда булдылар, авыл культура йортында совхоз хезмәтчәннәре һәм мәктәп укучылары белән очраштылар. Бу кичәдә КПССның Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Г. Галиев катнашты.

5 февральдә әдәбият һәм сәнгать бәйрәме Техника йортында дәвам итте. Биредә язучылар һәм шагыйрьләр үзләренең әсәрләрен укыдылар. Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин әдәбият һәм сәнгать сөючеләрнең күпләгән сорауларына җавап бирде.

## ТЕАТР ЮБИЛЕЕ

7 февральдә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының яңа бинасында татар театрының 80 еллыгына багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мустаев котлау сүзе белән чыкты, коллективка ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын тапшырды.

Театрның иҗат юлы турында ТАССР культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Театр коллективын олы юбилее белән «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең ташчылар бригадиры, СССР Верховный Советы депутаты В. С. Мәүликов, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Алма-Ата, Уфа, Чабаксардан килгән театр эшлекләре, республикабыз театр коллективлары вәкилләре котлады.

Аннары театрлаштырылган тамаша күрсәтелде.

Тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев, ТАССР Халык контроле комитеты председателе И. П. Наумов, КПСС өлкә комитеты бюросы члены Н. В. Фролов, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Д. К. Шәяхметов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, ТАССР Верховный Советы Президиумы Секретаре Д. С. Дәүләтшина иптәшләр катнашты.

## Г. ӘПСӘЛӘМОВНЫ ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

16 январьда Казанның Актерлар йортында ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмовның тууына 75 яшь тулуга багышланган искә алу кичәсе булып узды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты.

Язучының тормыш һәм иҗат юлы турында шагыйрь Әхсән Баянов доклад сөйләде. Язучылар Л. Ихсанова, Г. Ахунов һ. б. үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## М. ӘМИР ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

26 январьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының иске бинасында күренекле татар совет язучысы Мирсәй Әмирнең тууына 80 ел тулуга багышлан-

ган әдәби-драматик кичә булды. Аны ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты. Язучының тормыш һәм иҗат юлы турында филология фәннәре докторы Ф. Мусин сөйләде. Язучылар А. Расих һәм Р. Ишморат Мирсәй Әмир турында истәлекләре белән уртаклаштылар. Кичәдә М. Әмирнең туган җире — Башкортстанның Мәләүез район Советы башкарма комитеты председателе З. Г. Бикбулатов, тәнкыйтьче И. Вәлитов чыгыш ясады.

Аннары сәнгать осталары концерты булды.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова иптәшләр катнашты.

1 февральдә Оренбургның Х. Ямашев исемендәге шәһәр китапханәсендә Мирсәй Әмирнең тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Язучының тормыш һәм иҗат юлы турында китапханәнең уку залы мөдире Л. Рафыйкова сөйләде. Китапханә хезмәткәре Н. Бадамшина язучының китаплары буенча библиографик күзәтү ясады. Х. Ямашев исемендәге китапханә каршында эшләүче әдәбият түгәрәге җитәкчесе З. Шакиров Мирсәй Әмир турындагы истәлекләре белән уртаклашты.

Кичәнең икенче бүлегендә тамашачылар Оренбург филармония артистлары һәм Тәзүчеләр культура сараеның үзешчән коллективы чыгышын карадылар.

## БРЕЖНЕВ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

27 январьда Брежневта яшәп иҗат итүче язучылар, «Ләйсән» һәм «Орфей» әдәби берләшмәләре членнары «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое, ТАССР Верховный Советы депутаты Е. Н. Батенчук белән очраштылар. Ул Түбән Кама ГЭСы, Татарстан АЭСы, Кама трактор заводы, шәһәр төзелеше проблемалары турында бик җентекләп сөйләде, язучыларның сорауларына җавап бирде.

28 январьда язучылар оешмасы һәм шәһәр китап сөючеләр җәмгыяте тарафыннан «Глобус» китап кибетендә татар китабы бәйрәме үткәрелде. Анда язучылар оешмасының җаваплы секретаре Я. Игәнәй, шагыйрь К. Сибгатуллин татар телендә китаплар басылу тарихы, китапларның кешенең рухи тормышындагы роле, әһәмияте турында сөйләделәр, яңа шигырьләрен укыдылар.

## БӨЕК ПУШКИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

6 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында бөек рус шагыйре А. С. Пушкинның һәлак булуына 150 ел тулу датасына багышланган әдәби кичә булды.

Бөек шагыйрь турында кереш сүз белән Р. Гатауллин чыкты.

Кичәдә А. С. Пушкинга багышланган шигырьләре белән Ә. Исхак, Н. Арсланов, Р. Харис, Зөлфәт, Ф. Сафин, Г. Моратов чыгыш ясады. РСФСРның халык артисты А. Арсланов Пушкин шигырьләрен (М. Җәлил тәрҗемәсендә) укыды. Пушкин сүзләренә язылган романслар, җырлар артистлар Р. Гобәйдуллин, Л. Хангильдина башкаруында яңгырады.

## ЛЕНИНГРАДТА ТУКАЙ КИЧӘСЕ

17 январьда Ленинградның Октябрьская тимер юлчылар клубында бөек шагыйрь Габдулла Тукайга багышлап әдәби кичә уздырылды. Татар шигыре һәм җыры бәйрәме булып күңелләрдә матур эз калдырган бу кичәдә филология фәннәре кандидаты Э. Сәгыйдова, РСФСРның атказанган артисткасы Э. Җиһаншина, артист Р. Хабруллин һәм һәвәскәрләр чыгыш ясады.

Бу турыда журнал укучыбыз Н. Юсипов хәбәр итте.

## ШАГЫЙРЬЛӘР КИЧӘСЕ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе шагыйрьләребез иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәләр уздыруны дәвам итә.

Шундый кичәләрнең берсе 26 январьда Казан шәһәренең Киров исемендәге культура йортында шагыйрьләр Равил Фәйзуллин һәм Марсель Галиев иҗатына багышлап уздырылды.

Әлеге әдипләр иҗаты турында шагыйрь Р. Гатауллин сөйләде. Артистлар Э. Җәләлетдинов, В. Гыйззәтуллина, Р. Ибраһимова, Ә. Яһудин, Ф. Сөләйманова, И. Әхмәтҗанов, Х. Тимергалиева, И. Биктаһиров һәм композитор Л. Батыркаева катнашында узган әдәби-музыкаль кичәне тамашачылар яратып карады.

## Г. ШАМУКОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Күренекле сәхнә остасы, язучы һәм тәрҗемәче Габдулла Шамуков гомеренең соңгы елларында Казанның Большая Красная урамындагы 59 нчы йортта яшәде. 6 февральдә шушы йортка аның истәлегенә мемориаль такта куелды. Анда рус һәм татар телләрендә «Бу йортта 1963 — 1981 елларда СССРның халык артисты Шамуков Габдулла Рухулла улы яшәде» дип язылган.

Мемориаль такта ачу тантанасына республикабыз башкаласының партия һәм профсоюз оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, шәһәр җәмәгатьчелеге, Г. Шамуковның туганнары җыелган иде.

Тантананы ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев ачты. ТАССРның халык артистлары Һ. Солтанов, И. Баһманов, язучы Р. Мостафин Габдулла Шамуков турында истәлекләре белән уртаклаштылар.

## БӨТЕНРОССИЯ СЕМИНАРЫНДА

23 октябрь — 6 ноябрьдә Дубултыда язучыларның Я. Райнис исемендәге иҗат йор-

тында яшь тәнкыйтьчеләрнең VII Бөтенроссия семинары булды. Анда Татарстаннан яшь тәнкыйтьче Әхмәт Сәхапов катнашты. Аның иҗаты күренекле тәнкыйтьчеләр җитәкләгән группада тикшерелде һәм уңай бәя алды.

### ШЕФЛЫК ЯРДӘМЕ БЕЛӘН

Шагыйрь Ш. Маннапов, бер ай дәвамында район газетасы редакциясенә шефлык ярдәме күрсәтү максаты белән, Балтач районында булды. Ул район авылларында хезмәт иярләре һәм мәктәп укучылары белән очрашты. Ш. Маннапов шулай ук «Янар чәчәк» район әдәби берләшмәсенә йөрүче яшь иҗатчылар белән очрашып, аларның яңа әсәрләрен укып тикшерүдә катнашты.

### СИРИННЫҢ МИРАС КОМИССИЯСЕ

Татарстан Язучылар союзы шагыйрь Сиринның (Сирин Батыршинның) мирас комиссиясен төзеде. Комиссиягә түбәндәге иптәшләр кертелде: Рәшит Әхмәтҗанов (председатель), Ә. Шәрипов (секретарь), С. Сабиров, Р. Фәйзуллин, М. Латыйфуллин, К. Әхмәтҗанов.

Мирас комиссиясе кулларында шагыйрьнең иҗатына, тормышына караган материаллар, истәлекләр, фоторәсемнәр булган иптәшләрдән, аларны шушы адрес буенча җибәрүләрен үтенә: 420012, Казан шәһәре, Комлев урамы, 14 йорт, Татарстан Язучылар союзы идарәсе.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры режиссеры Празат Нәкыевич Исәнбәткә, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 26 декабрь Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет культурасы өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен язучы Габдулла Шәрәфигә, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 30 октябрь Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Сынлы сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәннәре өчен һәм Татарстан АССР Художниклар союзы оешуга илле ел тулу уңаеннан, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 19 декабрь Указы белән, Зуев Евгений Владимировичка, Скобеев Валерий Николаевичка һәм Попов Владимир Александровичка «Татарстан АССРның халык художнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Сынлы сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәннәре өчен һәм Татарстан АССР Художниклар союзы оешуга илле ел тулу уңаеннан, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 19 декабрь Указы белән, Абзгильдин Абрек Әмировичка һәм Имашев Рәшит Фатыйховичка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Наил Галимуллович Әюповка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 5 февраль Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 5 февраль Указы белән, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Әхмәтҗанов Илдус Хәнифовичка һәм Шамкаев Рәшит Мирзаевичка «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

### ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Сынлы сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәне өчен һәм Татарстан АССР Художниклар союзы оешуга илле ел тулу уңаеннан рәссам Зөфәр Фаатович Гыймаев, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 19 декабрь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Республика сынлы сәнгатен пропагандалау буенча озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм Татарстан АССР Художниклар союзы оешуга илле ел тулу уңаеннан, ТАССР сынлы сәнгать музееның сәнгать белгечләре Шаһиева Розалина Гомәровна һәм Цой Вера Алексеевна, КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм Татарстан АССР Художниклар союзы оешуга илле ел тулу уңаеннан рәссам Сутюшев Мәэмүн Галиевич КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының оештырылуына сиксән ел тулу уңаеннан театр артистлары Җәләлов Хәлим Бәдриевич, Камалова Гәүһәр Абдулловна, Касыймов Дусил Гаязович һәм Миңлебаева Мәрзия Галимбаевна, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 5 февраль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

# «СӨЕМБИКӘ КУВШИНЫ»

1966 елда Казанның К. Насыйри урамындагы бер йорт нигезенә ремонт вакытында табылган бу нәфис савыт — культурабыз тарихы өчен зур әһәмияткә ия. Беренчедән, ул — Идел буе төрки халыкларының XV-XVI гасыр тел һәм язма культурасы ядкаре. Икенчедән, татар халкының борынгы заманнардан килгән ювелир сәнгате традицияләренең билгеле бер этаптагы үрнәге дә...

Сынлы сәнгать формалары белән әдәбият, шигъри сүз стихиясенең үрелеп үсүе — татар культурасы өчен характерлы факт; моның мисалы — Болгар архитектурасының сырлап һәм нәкышләп эшләнгән текстлы фриз-паннолары, шигъри юллар белән бизәлгән савыт-саба, бакыр, көмеш тәңкәләр, сыннар, ачкычлар, афоризмнар язылган йөзек кашлары.

Татарстан Дәүләт музее залларының берсенә куелган әлеге алтынсу-сары төстәге җиз кувшинга чүкеп һәм уеп төрле орнаменталь бизәкләр төшерелгән. Җентекләп караганда, аның формасы кош гәүдәсенә охшаш. Күз алдына Ленинградта Эрмитажда һәм Мәскәүдә Дәүләт тарих музеенда сакланган болгар чорының «тылсымлы үрдәк» сыннары формасында эшләнгән чигә асылмалары килеп баса. Ювелир сәнгате, керамика, халык авыз иҗатында киң таралган бу космогоник зат су төбеннән Җир «төше» — тормыш, яшәү башлангычы табучы мифологик «энҗеле үрдәк» образы булуы мөмкин.

Савытның түгәрәк аскы өлешенең ике ягына зур бадам чикләвеге формасында ике кургаш күзгә эретелгән. Бу күзгеләрне йөзек кысасы кебек ике орнаменталь бизәк тоташтырып тора. Күзгеләр үзәгендә заманында кыйммәтле асылташлар җемелдәп торган булырга тиеш; сакланган чокырчыклар әнә шул турыда сөйли.

Кувшинның тоткасына, уеп, «Әмин ханның оста бакырчысының улы оста Насыйрдан» дип язылган. Димәк, оста Насыйр — татар культурасы чәчәк аткан атаклы Казан ханлыгы чорында хан булып торган Мөхәммәт Әминнең (1484—1519) сарай ювелиры — бакырчысы булган.

Кувшинның муенында язу: «Барлык көчлеләрнең көчлесенә [багышлап] чокып язам... Сугышлардан соң арыгач, капкачын ачып, һәркем иренен тидереп, сусавын бассын».

Савытның кемгә атап сынландырылуы турында да әһәмиятле мәгълүмат бар. Уң ягында «И раббем, синең бөек йортыңда тулы [хокуклы] гаскәр башлыгы булган бәхетле Күбәк [исемле] данлы ир-егеткә» дигән башлама бар. Ир-егет Күбәк кем соң ул?

Татар халкында «Ак күбәк» дигән ярым тарихи, ярым легендар бер дастан бар. Аның сюжеты конкрет тарихи детальләрнең байлыгы, татар алыпларының милли психология үзенчәлекләренең чагылышы, халыкчан теле, патриотик интонацияләре белән аерылып тора. Бу дастанның герое — Русь елъязмаларында Аккубек, Кобяк, Кубек дип телгә алынган, Казан, Касыйм, Әстерхан ханлыкларына мөнәсәбәтле, бер сугышта каһарманнарча һәлак булган Күбәк Тугаев исемле ханзадә («царевич Аккобяк») булырга мөмкин.

> «Йөзеңне күрдем инде күзләрем белән,
> Әмма тарафыңа чыгарга кыймадым мин»,

— кебек шигырь юллары кувшинның иясе хатын-кыз булуы ихтималы турында сөйли.

Бакырчы улы оста Насыйр, әлбәттә, атасының замандашларыннан һәм Әмин ханнан соңрак яшәгән. Бу хронологик вакытны XVI гасырның беренче яртысы дип алсак, һәм населдән килгән традиция буенча, оста Насыйр дәрәҗәле хан ювелиры булса, әлеге кувшин ясалу чоры, тексттан күренгәнчә, тарихи сугышлар чорына (1540—50 еллар) — Казан ханлыгында Сөембикә патшалык иткән дәвергә туры килә.

Укымышлылыгы, зирәк акылы, гүзәллеге белән чит мәмләкәт илчеләрен таңга калдырган, драматик язмышы халык иҗаты әсәрләрендә чагылыш тапкан, соңра рус культурасында поэмалар, сәхнә әсәрләре, картиналар тууга рухландырган Сөембикә — югарыдагы шигырьнең авторы һәм шәраб савытының рухи нәкышчесе булырга мөмкин.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстанның сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Тышлыкның беренче битендә** Валентин **САВЕЛЬЕВ** фотосы.
**Тышлыкның дүртенче битендә:** Куйбышев мәйданында Г. Тукай һәйкәле. **Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена коп.

Индекс 73210




КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)